Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

# РУХИ МИРАС
## эзләнүләр һәм табышлар

3 нче чыгарылыш

Казан
2017

Институт языка, литературы и искусства
им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

# ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ

## поиски и открытия

Выпуск 3

Казань
2017

УДК 801.82(082)
ББК 63.2:80я43
Д 85

*Печатается решением Ученого совета
Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан*

Проект реализуется Центром письменного и музыкального наследия
Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук РТ – Мирасханэ

Сборник подготовлен при финансовой поддержке
РФФИ и Правительства Республики Татарстан
в рамках научного проекта № 17-14-16502

**Редколлегия:**
***И.Г. Гумеров*** *(руководитель проекта и ответственный редактор),*
***М.И. Ахметзянов, З.З. Рамеев***

**Составители выпуска:**
***Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова, Л.Ш. Давлетшина***

**Д 85** **Духовное наследие: поиски и открытия** / под ред. И.Г. Гумерова. – Казань: ИЯЛИ, 2017. – Вып. 3. – 336 с.
ISBN 978-5-93091-217-3

Сборник продолжает традицию публикации малоизвестных письменных источников; изучения произведений, составляющих основу духовного наследия татарского народа; знакомства читателей с новейшими исследованиями в изучении татарских текстов.

Очередной выпуск серии посвящен жизни и творчеству классика татарской литературы, общественного и государственного деятеля Галимджана Гирфановича Ибрагимова (1887–1938). В сборнике представлены художественные тексты писателя, его публицистика, доклады; воспоминания современников об Г. Ибрагимове, рецензии на его произведения и труды; архивные документы, связанные с надзором над писателем и его арестом. Тексты впервые предлагаются вниманию читателей в переложении на кириллический алфавит.

ISBN 978-5-93091-217-3

© Институт языка, литературы и искусства
им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2017

## КЕРЕШ СҮЗ

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең чираттагы чыгарылышы татар әдәбияты классигы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче Галимҗан Ибраһимовның (1887–1938) тормыш һәм иҗат мирасын барлауга багышлана. XX гасыр башы төрки-татар мәдәнияте алгарышында гаять әһәмиятле урын тоткан бу шәхеснең иҗат һәм эшчәнлек дәвере шактый катлаулы инкыйлаби үзгәрешләр чорына, илдә иҗтимагый-сәяси формацияләр алмашынган вакытка, кара репрессия елларына туры килә. Бу Галимҗан Ибраһимовның әдәби иҗатына да, милли мәдәниятне, фәнне торгызу, оештыру өлкәсендәге эшчәнлегенә дә, хәтта ахыр килеп, язмышына да хәлиткеч йогынты ясый. Сәясәт һәм мәдәният мәйданына аяк баскан беренче көннәреннән үк башта патша жандармериясе, соңыннан большевиклар күзәтүе һәм эзәрлекләве астында яшәргә һәм эшләргә мәҗбүр ителгән әдипнең тормышы 1938 елда төрмә хастаханәсендә тәгәлләнә. Әмма шунысы игътибарга лаек: аның тормыш һәм иҗат драматизмын, фаҗигале язмышын искәрткән хәлдә дә, мирасын туплау һәм өйрәнү ягыннан, башка чордашлары белән чагыштырып караганда, «онытылган» яки «аз өйрәнелгән» дип әйтү дөрес булмас, мөгаен. Монда Галимҗан

Ибраһимовның инкыйлабтан соң төрки-татар алгарыш хәрәкәтенең үзәгендә торуы, кайсы гына өлкәне алмыйк – әдәбият һәм тел үсеше өлкәсендәме яки халыкның милли үзбилгеләнү омтылышында булсынмы – аның әйдаманына, җитәкчесенә әверелүе хәлиткеч роль уйный. 1927 елда Галимҗан Ибраһимов иҗатының 20 еллык юбилее Казан, Татарстан белән генә чикләнмичә, Уфа, Мәскәү, Ташкент кебек зур шәһәрләрдә дә узуы, 1928 елда Хезмәт Герое исеменә лаек булуы – моның ачык мисалы.

Галимҗан Ибраһимовның иҗат мәйданы киңкырлы, калдырган мирасы гаять бай. Аны туплау, өйрәнү әдип үзе исән чорлардан ук башланып китә һәм бүгенгәчә дәвам итә. Дөрес, бу юлда төрле этаплар була. Әйтик, югарыда искәртелгән юбилей бәйрәме уздырылган вакытта бу өлкәдә зур активлык күзәтелә: 1928 елда Галимҗан Ибраһимовның әдәби, гыйльми һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенә бәя биргән берничә җыентык дөнья күрә (Галимҗан Ибраһимов. 20 еллык әдәби, гыйльми, иҗтимагый хезмәт туена каратып чыгарылган мәҗмуга. Ташкент, 1928; Галимҗан Ибраһимов. 20 еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәменә каратып чыгарылган гыйльми-тәнкыйди җыентык. Казан, 1928), газета-журнал битләрендә күпсанлы мәкаләләр басыла. 1936–55 еллар аралыгында мәгълүм сәбәпләр аркасында бу өлкәдә зур тынлык урнаша. Бары тик илленче елларда Галимҗан Ибраһимовның исеме акланганнан соң гына мирасын өйрәнү эше янәдән дәвам иттерелә. Бу җәһәттән Г. Халит, М. Гайнуллин, И. Нуруллин, М. Хәсәнев, А. Шамов, С. Поварисов, Д. Заһидуллина һ.б. язучы һәм галимнәребезнең хезмәтләре игътибарга лаек. Шулай ук соңгы елларда Галимҗан Ибраһимов иҗаты буенча диссертацияләр яклануын да атап үтәргә мөмкин.

Галимҗан Ибраһимов мирасын барлауда Татарстан Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең керткән өлеше аерым игътибарга лаек. Бу мәсьәләгә

институт икеләтә җаваплылык хисе белән якын килә, чөнки бер яктан институтның нигезе узган гасырның егерменче елларында нәкъ Галимҗан Ибраһимов җитәкчелек иткән һәм хезмәт куйган Академик Үзәк белән бәйле булса, икенче яктан ул 1967 елдан алып аның исемен йөртә башлый. Юбилей елларында күпсанлы фәнни конференцияләрнең һәм башка чараларның нәкъ биредә үтүе, әдипнең 9 томлык басмасы дөнья күрүе, диссертацияләр яклануы табигый рәвештә аңлашылып та тора. Язучының 130 еллыгын да институт хезмәткәрләре зур гамәлләр белән каршы алалар: Галимҗан Ибраһимовның 15 томлык академик басмасын әзерләү эше дәвам итә, апрель аенда «Мәдәниятләр төрлелеге контекстында Г. Ибраһимов мирасы» исемле Халыкара фәнни-гамәли конференция планлаштырыла, «Галимҗан Ибраһимов фотографияләрдә», «Мин хәят эзләдем, хәяттән мәгънә эзләдем» һ.б. китаплар басмага әзерләнә. «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» җиентыгының өченче чыгарылышы да бу исемлекне тулыландырып тора.

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» китабында Галимҗан Ибраһимов иҗатына кагылышлы текстлар урын алды. Шунысы мөһим: бу текстларның күбесе фәнни әйләнешкә һәм укучы игътибарына бүгенге гамәлдәге язуда тәүге тапкыр тәкъдим ителәләр. Беренче бүлекне язучының үз текстлары – 1910 елда басылганнан соң башка бер дә нәшер ителмәгән «Татар хатыны ниләр күрми» әсәренең беренче варианты (1909), ХХ гасыр башы төрки-татар дөньясының көнүзәк мәсьәләләренә багышланган публицистик язмалары, Беренче Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда (Мәскәү, 1917) һәм Беренче Бөтенсоюз Тюркология съездында (Баку, 1926) ясаган чыгышлары алып тора. Икенче бүлек язучының дуслары, чордашлары, хезмәттәшләре тарафыннан язылган хатирәләрдән гыйбарәт. Алар язучы шәхесен бөтен тирәнлеге белән аңларга, үз чорының билгеле бер вакыйга һәм ситуацияләренә ачыклык кертергә мөмкинлек бирәләр. Өченче бүлектә

Галимҗан Ибраһимов турында 1910–1930 елларда вакытлы матбугат битләрендә дөнья күргән мәкаләләр, аның әсәрләренә бәяләмәләр урын ала. Дүртенче бүлектә әдип иҗатының аерым бер мәсьәләләре хакында бүгенге галимнәребезнең фикер-карашлары бәян ителә. Бишенче бүлек Галимҗан Ибраһимовка кагылышлы архив документларын үз эченә ала. Биредә Татарстан Республикасы буенча РФ Федераль иминлек хезмәте идарәсе архивында, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана торган документлар туплап бирелә. Болар барысы бергә Галимҗан Ибраһимовның иҗатын өйрәнүдә яңа сүз, яңа фикер тудырырга мөмкинлек ачыр дип уйланыла.

Җыентыкта урын алган текстлар, аңлатмалар һәм шәрехләр институтның текстология бүлеге, Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәрләре З.З. Рәмиев, Ә.Х. Алиева, И.Г. Гомәров, Ф.Г. Фәйзуллина, Э.М. Галимҗанова, Г.А. Хөснетдинова, Г. Батыршина, Г.Н. Зәйниева, Н.Н. Насыйбуллина, А.И. Әхмәтова, Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова, А.А. Хасавнех, А.Р. Мөбарәкшина тарафыннан гамәлдәге язуга күчерелде һәм язылды.

*Китапның җаваплы мөхәррире*
*И.Г. Гомәров*

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ИҖАТ МИРАСЫННАН

## ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘР

### «Татар хатыны ниләр күрми» әсәре хакында

Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрен 1909 елда язып, 1910 елда Эстәрлетамакта «Нур» матбагасында «Каләм» көтепханәсендә нәшер итә. Бу повесть (әмма шул чор әдәбият белеме кануннарына таянып, автор аның жанрын роман дип билгеләгән) әдип иҗатының романтик чорына караган әсәрләреннән берсе санала.

1929 елда әсәрнең төзәтелгән, өр-яңа сюжетка корылган, романтизм иҗат ысулының төп сыйфатларыннан азат, нигездә социалистик реализм дип аталган принципларга таянып язылган икенче варианты мәйданга чыга. Һәр ике вариантта да вакыйгалар әсәрдә төп каһарман булган Гөлбануның фаҗигале язмышына бәйләп тасвирлана. Әсәрнең эчтәлегенә туктап тормастан, шуны гына әйтергә кирәк: беренче варианты күләм ягыннан 80 битләр булса, икенче варианты 185 биттән артыграк, сюжеты үзгәртелгән, әдәби алымнар белән баетылып, киңәйтелгән.

«Татар хатыны ниләр күрми» повестеның романтик метод белән иҗат ителгән беренче вариантында кеше иреген буып торган җәмгыятькә каршы чыккан каһарман Гөлбануның, ягъни «шәхеснең югары күтәрелүе милләтнең, халыкның югары күтәрелүен аңлата... Татар милләтенең уянып килүче милли үзаңын гәүдәләндерә»[1]. Икенче варианты язучының кешеләр арасындагы социаль мөнәсәбәтләргә мөрәҗәгать итүе белән әһәмиятле. Бу аның яңалыгы да. Биредә, кешене, шәхесне буып торган искелеккә каршы нәфрәт уяту, хатын-кызның шул җәмгыятьтәге аяныч хәле һәм котылгысыз халәте, чарасызлыгы, ниһаять, һәлакәте социаль шартларда икәнлеге ассызыклана. Димәк ике вариантта хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе төрлечә хәл ителә. Беренчесендә язучы хатын-кыз идеалын сурәтләсә, икенчесендә исә хатын-кыз язмышы яңа идеология кысаларында яктыртыла.

---

[1] *Нигматуллина Ю.* Национальное своеобразие эстетического идеала. Казань: КГУ, 1970. Б. 71.

Повестьның беренче варианты төп герой Гөлбануның табигый асылына кайтуы, аның хатын-кыз икәнлеге ачылу белән төгәлләнә. 1929 елда язылган икенче вариантында исә Гөлбануның язмышы фаҗигале рәвештә суга батып үлүе белән тәмамлана.

1911 елда «Татар хатыны ниләр күрми» әсәренең беренче вариантын «Нур» матбагасы икенче тапкыр нәшер итә. Шуннан соң бу әсәр Г. Ибраһимовның күптомлык басмаларына да, сайланма әсәрләренә дә кертелмәгән. Биредә текст 1910 елгы басмадан тәкъдим ителә.

## Татар хатыны ниләр күрми

*(Роман. Беренче басма)*

### I

Гөлбану 17 яшендә иде.

Ул кайсы яктан караганда да саф авыл кызы иде. Аның ата-анасы авылныкы, туган җире авыл, тәрбияләнүе авыл кызларыныкынча булган кебек, үсеп буйга җиткәнче ул үзе дә авылдан башка һичбер җирне күрмәгән иде. Яп-якын шәһәрләрнең дә тик исемнәрен генә ишеткән иде.

Аның бишектән алып «җитү кыз» булгангача үткәргән гомеренең тарихы күздән кичерелсә, һәр эше, һәр хәрәкәте авылларча булганлыгы ачык күренәдер.

Ул дөньяга килеп аз гына кузгалып йөри башлагач та үзе кебек малайлар, кызлар белән бергә дә, ялгызы да һаман су вә балчык белән генә уйный иде. Кайда су күрсә, ул шуңа барып кулын тыга иде. Ишек төбендәге пычрак сулы таз (ләгән), тышта чебешләр өчен су белән икмәк салынган таба һәм баткаклы кое тигәнәләре аның иң кызыкланып уйнаган нәрсәләреннән иде. Кеше күрмәсә, ул бу нәрсәләргә барып балчык, таш кебек нәрсәләр тутыра, кулы белән дә, агачлар белән дә чат-чат сугып чәчрәтә иде. Кайда туфрак күрсә, ул аңарга барып чума, ауный иде. Шунлыктан аның өст-башы гына түгел, бите-күзе, авызы-борыны һәрвакыт балчыклы вә керле була иде. Күп вакыт аның балчык ашаганына да очрала иде. Азрак үсеп күңеле теләгәнне кулы ясаштыргалый башлагач, аның һәммә уены диярлек курчактан гыйбарәт булып китте. Ата-анасы аңарга балалар өчен ясалган курчак вә уенчыклардан һичбер нәрсә алып бирмәсәләр дә, ул шылдыравыктан

башка базар уенчыгын күрмәсә дә, бер дә аптырамый иде. Үзе мең төрле уенчык, мең төрле курчак таба. Аның курчаклары төрлечә була: кайвакыт ул, зур калын шәлдән бәбәй ясап, яулык ябындыра да, шуны мендәргә салып «әү-бәү» дип тирбәтеп уйный иде. Күбрәк вакытта исә анасы күлмәк кискәндә алып калган корама вә чүпрәкләрдән ясалган бик кечкенә курчаклар белән уйный иде. Боларга җиңнәр, куллар куеп, бөрмәле күлмәкләр, калпаклар да кидерелгәнгә, бик кызык һәм күңелле була иде. Бу курчак уеннарында ул, әлбәттә, ялгыз булмый иде. Иптәшләре белән бергә ширкәтләр тәэсис[1] итеп, курчаклар өчен йортлар, өйләр вә маллар хәзерлиләр, балчыктан кечкенә күмәчләр ясап, аларны шул курчаклар өчен кояшта пешерәләр иде. Яше үткән саен, аның уеннары алышына һәм күбәя барды: курчаклар өстенә таш-таш уйнау да, ашка чакырышу вә йөгерешеп уйнаулар да кушылган иде.

Су буенда киндер агарткан өлкән кызларга булышу да аның өчен бер кызык кына иде. Һәр яз башында алтын төсле сары вә матур каз бәбкәләрен каргадан алдырмау өчен сазга сакларга бару, бозауларны кайтару, көтүгә каршы сыер алырга бару кебиләр тыштан караганда бер хезмәт төсле булсалар да, иптәшләре белән бергә һаман уйнап кына эшләгәнгә, болар да бер күңел ачкыч вә бер кызык кына иде.

Бу вакытлар аның киемнәре дә, әлбәттә, бик мәхдүд[2] булып, ялгыз бер күлмәктән гыйбарәт диярлек иде. Башы да ялангач булып, кара чәчен үреп кенә сала да, яулык-фәлән күп ябынмый иде. Аягы да ялангач булып, чабата-оек киеп ул, әлбәттә, мәшәкатьләнми һәм башка нәрсә дә кими иде. Тик якын тауга җиләккә барганда гына, җылан чакмасын өчен, ак оек белән кечкенә матур чабата кияргә мәҗбүр була иде.

Ул бу вакытларда, әлбәттә, садә[3] иде. Аның бөтен зиннәте алка белән «сәйлән»нән гыйбарәт булып, бизәнү өчен үзенә махсус кершән һәм инлек тә тотмый иде. Тик җиңгәләре үзләре сөртенгәннән соң учларында калган кершәнне кайвакытта аңарга да сөрткәлиләр иде.

Яше уннарга җиткәч, ул өй эчендәге вак-төяк хезмәтләргә дә кул сала башлады. Аш пешерүгә катышмаса да, чәй хәзерләү,

---

[1] Тәэсис – төзү, оештыру.
[2] Мәхдүд – чикләнгән.
[3] Садә – саф.

жыю, чынаяклар юу, самовар агарту кебек эшләрдә булышлык иткәли иде. Ул күндәм иде. Эшкә истигъдаде[1] шәп иде. Яшь кенә көенчә кулына энә тотып тегүгә, оек вә бияләй бәйләргә өйрәнде. Дәхи бераз күтәрелгәч, бәрән җонынннан һәм кәҗә мамыгыннан бик нечкә һәм килешле итеп шарфлар, шәлләр һәм перчаткалар да бәйли башлады. Чигүгә дә өйрәнеп, атасы аңарга бер начар гына кирге дә тапкан иде. Ул моның белән чалма һәм кесә яулыклары, намазлыклар, өстәл япмасы һәм чолгаулар чигә иде. Ул 13–14 яшькә җитү белән киндер сугарга да керешкән иде. Һәр язда ай ярым вә ике ай кадәрле заман киндер сугып, ябыгып агарып бетә иде.

Ашъяулык, сөлге, салфет, чолгау һәм ыштан кебекләрне базардан сатып алу юк, һаман шул киндерләрдән эшләнә иде. Һәр елда кеше башына бер-икешәрдән күлмәк тә сугыла иде. Гөлбану үзенә дигән күлмәкләрне нечкә һәм матур эшли иде. Аның йорт кирәге өчен суккан киндерләре әһәмиятсез бер кыйсем булып, иң соңгы дикъкать вә мәһарәт[2] сарыф кыйлганы приданлык өчен хәзерләнә торган нәрсәләр иде. Төрле җирдән күчергечләр эзләтеп алып чүпләнгән яхшы сөлгеләр, зур-зур ашъяулыклар, салфетлар, өлкән чаршау, күлмәк-ыштан вә чолгау кебек нәрсәләр зур әһәмият белән сугылып, Гөлбану артыннан барачак приданнар рәтенә тезелә бара иде. Авыл кызлары арасында придан өчен сугылган бу нәрсәләрнең күплеге һәм яхшылыгы иң соңгы теләк вә иң олугъ шәрәф[3] саналганга, Гөлбану боларга бөтен дикъкатен сарыф кыла иде. Гөлбануның анасы Фәтхия карчык та үзенең бердәнбер кызы өчен барлык көче белән тырыша, ярдәмләшә иде. Боларны сугуда кирәк булган нәрсәләр өчен, урлашып булса да, акча таба һәм ала иде.

Җитенне үзләре чәчкәнгә аңарга акча чыкмаса да, киҗе мамык, дебет, буяу кебиләргә, әлбәттә, күп акча кирәк иде. Боларның күбрәге Гөлбануның атасы Нурый карт тарафыннан алынып бирелсә дә, ул гына җитми, җитмәгәнне табу анасы Фәтхия әби өстендә иде. Тавыкларның җәй буена салган күкәйләре шунда керә, Нурый картка яшереп кенә кибетче хатынга ашлык та иteлә иде. Ничек тә приданлык өчен сугылган нәрсәләрнең мөкәммәл[4]

[1] Истигъдад – тырышлык.
[2] Мәһарәт – осталык.
[3] Шәрәф – кадер, бәхет.
[4] Мөкәммәл – камил, тулы.

булу җәһәте өчен мәшәкатьләр чигелә һәм тәкмиль[1] ителә иде. Яз буена Гөлбану белән Фәтхия әби шул үзләренең кечкенә фабрикалары тирәсендә һәм шул сугылганнарны яхшылау өчен тырышып үтә иде.

Сугып беткәннән соң ак булырга тиешле киндерләрне агарта башлыйлар иде. Бусы бер күңелле тоела иде. Кызлар белән җыелып, су буена яшел чирәмгә төшеп җуалар, чәпиләр, җәеп киптерәләр дә, йортка алып кайтып аларны тукмый башлыйлар иде. Киндер тукмау да бер кызык булып кала иде. Җәйнең саф вә ләтыйф[2] һавалы айлы кичләрендә чирәмгә бүрәнә салып, шуның өстендә шакы... шакы... шакы... шакы... итеп тәмле сүзләр вә көлкеләр белән киндер тукмау бикләнеп торган бер кыз өчен хозур төсле була иде. Бөтен авыл тын вә шым йокыда заманында гел кызлар җыелып киндер тукмау тирә-якны яңгырата иде. Күп киндер тукмаганнан соң, «көн дә шакылдыйлар, ахыры, киндере күптер» дип халык тарафыннан сөйләнә башлаганга, моның бер мәгънәви ләззәте дә бар иде. Бу бер шәрәф кебек иде.

Яз белән җәйнең күбрәк көннәре шул киндер фабрикасы, авылча әйтсәк, «киндер урыны» тирәсендә үтеп, көз килсә тегүчигү башлана иде.

Гөлбану йорт кирәкләрен тиз-тиз тегеп бетереп, тагын шул приданлыкка тотына иде. Яулыклар, намазлыклар, өстәл вә түшәк япмалары һәм чолгаулар эшләп әлеге мәүһум[3] егеткә алып китәчәк нәрсәләр хәзерләнә иде.

Кыш һәм көз шулар белән үтә иде. Болар бар да өй хезмәтләредер. Ләкин Гөлбану мондый өйдәге хезмәтләре белән генә калмый: ул бил сызганып ялан һәм иген кәсепләренә дә керешә иде. Ул боларга да бик ихлас һәм батыр иде. Авырсынмый сабан, сука, урман кисү, печән чабу кебек гадәттә ирләр генә эшли торган эшләргә катышмаса да, печән җыю, чүмәлә җибәрү, кибән салышу, урак уру, борчак йолку, чапкан ашлыкны бәйләү кебек эшләрдән бер дә калмый иде. Һәм калырга да теләми иде. Һәм беркемнән дә ким дә эшләми иде. Уракта аның арты көлтә белән тулы булып, алар нык һәм өлкән булалар иде. Ярышып, үчекләшеп урганда күп вакытта агаларыннан да арттыра иде.

---

[1] Тәкмиль – җитештерү, тәмам итү.
[2] Ләтыйф – йомшак, нәфис.
[3] Мәүһум – хыялдагы.

Елның күбрәк көннәрен өйдә бикләнеп яткан бер кыз өчен бу җәйге ялан хезмәтләре бер яктан тансык та була, күңеле дә ачыла иде. Бөтен авыл кешеләре иртә барып кич кайтып йөрегәнгә, бик күмәк халык белән очрашырга туры килә иде. Эш арбасының яхшысына пар ат җигеп, ике якка аяклар салындырып тезелешеп утырып, шул күмәк халык белән бергә тузан туздырып чабышу бер кызык төсле була иде. Бу кадәрле халык эчендә кайнагач, Гөлбану инде, әлбәттә, үзенең кызлык хөрмәтенә кимчелек китермәслек сыйфатта күренергә тырыша иде: аның урагы да, тырмасы да үзенә махсус булып, матур һәм буяулы була, җиңсә дә бөрмәле ак һәм яңа була, оек та ап-ак булып, чабатаның да кечкенә башлысын сайлый иде. Барганда, кайтканда гына киеп, эшли башлагач салып куя торган шәл, күлмәген ул бер дә калдырмый иде, бик аз гына вә бер дә беленмәслек кенә кершән дә яккалый иде. Көн буена бите бик тузанланып беткәнгә, кич кайтканда җуыну өчен су артса гына, эчеп бетермәсәләр генә ярар иде дип йөри иде. Калса, әлбәттә, җуына һәм матурлана иде. Урак, печән эшләрендә Гөлбануның мәһарәте[1] «өмә»ләрдә беленә иде. Авылда өмәләр булгалый, чакырсалар ул, әлбәттә, бара иде. Анда кызлар да, егетләр дә булып, бергә эшләгәнгә, ярышу күп була, эш җәһәтеннән булсын, сүз белән булсын, бер-бер мөсабәка[2] булса, Гөлбану, әлбәттә, катыша, күп вакыт алгы сафта була иде. Бу өмәләрдә егет тә, кыз да булып, уен-көлке, шау-шу һәм җырлар күп булганга, эш, хезмәт диюдән дә, уен дияргә лаек була иде. Хосусан, бару-кайту бигрәк хозур иде. Ялан эшләре, әлбәттә, Гөлбануның йөзенә лазем булган хиҗабны[3] муәккать[4] ташларга мәҗбүр итә, ул йөз капламый һәм мөмкин дә булмый иде. Иген эшләренең актыгы булган ашлык сугуда Гөлбануның кулы кысылмый калмый иде. Кысыла гына түгел, ул моңарга бик нык җигелә иде. Кыш көне әвенгә чыкмаса да, җәй вә көз көне теләсә яланда булсын, теләсә йорт ындырында булсын, сугучылар арасында Гөлбану да була иде. Аның таза һәм көчлелеге бу тугрыда бигрәк ачык күренеп, ул һичбер вакыт чабагачына кешедән суктырып оятка калмый. Билгакес[5], үзе башкаларныкын сугып төшергәли иде. Менә шулар – Гөлбануның ялан һәм

---

[1] Мәһарәт – осталык, сәләтлелек.
[2] Мөсабәка – ярышу, узышу.
[3] Хиҗаб – пәрдә, оялу.
[4] Муәккать – вакытлыча.
[5] Билгакес – киресенчә.

иген эшләредер. Күрәсез, болар һәммәсе дә эш-хезмәттер. Дөньяда һичкем ялгыз эш, хезмәт белән генә яшәми. Азрак уен-көлке вә күңел ача торган нәрсәләре дә була.

Табигый, авыл кызларында мәгъруф[1] булган уен-көлке вә күңел ачкычларының һичбереннән Гөлбану да мәхрүм түгел иде. Болар җәенә, кышына карап төрлечә була иде: матур яз килеп җирләр кипсә, сахралар яшәрсә, ул бөтен авыл кызлары белән бергә җыелышып тау башларына, авыл артларына чыга иде. Болар көннең, һаваның бик матур вә ләтыйф чагын сайлап чыкканга, музыка, җыр вә бию белән дә бик рәхәт кенә кәеф ачканга, әллә нинди хозур вә күңелле була иде. Монда егетләр, ирләр булмый, фәкать кара кашлы, алсу йөзле, нечкә билле назлы туташлар гына җыелып, алар бик киенеп, ясанып чыкканга, карап туялмаслык бер манзара була, һәр җирдә күңеллелек, ләтафәт[2] вә шатлык сизелә иде.

Авылның бик ярлы кызлары да үзенә бер шәл белән бер яңа күлмәкне саклаганга, тыштан караганда һәммә кызларның киеме яхшы күренсә дә, Гөлбанунықы материясенең яхшылыгы, килешлелеге белән, әлбәттә, башкалардан аерыла иде.

Хосусан[3] аның бик өлкән ике көмеш чулпысы, беләгенә тулган беләзекләре, бармагындагы йөзекләре, муенындагы төрле төймә һәм тәңкәләренең күплеге аны башкалардан имтиязлы[4] күрсәтә иде. Буяну-сөртенүләр дә, әлбәттә, шәп була иде. Монда һәр бәхәсләр шәл чугы, күлмәк оборкасы, беләзекләрнең маниры хакында булганга, болар исә Гөлбануда бик шәп күренгәнгә, ул аста калырлык түгел һәм башкалар тарафыннан тәгъйиб[5] ителү ихтималы аслан юк иде.

Аның иң башлап кешегә күрсәтү өчен хәзерләнгән киемнәре вә зиннәтләре күп вакыт башкаларның күзене кыздыра иде. Садә кызлар, аның бу нәрсәләрен күреп: «Әй генәм! Бигрәк матур икән... ни хакка алдыгыз?» – диләр, көнче кызлар исә моңарга каршы: «Былтыр мин аның берсен алып туздырган идем, һәйбәт була ул!» – дип, сер бирмәгән булалар иде.

---

[1] Мәгъруф – билгеле, яхшы.
[2] Ләтафәт – матурлык.
[3] Хосусан – аеруча.
[4] Имтиязлы – өстен, аерылып тора торган.
[5] Тәгъйиб – гаепләү.

Менә Гөлбануга язның биргән иң беренче бәйрәме шулар иде. Мондагы кебек үк күп җыелмасалар да, ун-унбиш кыз бергә җыелып чишмәгә суга йөрүләр дә Гөлбану өчен бер рәхәт кенә, бер шатлык кына була иде. Ерак урманнарга, тауларга җимеш өчен бару, кеше кумаса, бояр җирләренә җиләккә йөрүләр дә бер күңел ачылып кала торган эшләрдән иде.

Җәйнең иң җанлы, иң күңелле заманында кыз озату, килен төшерү өчен йөрүләр дә «кайчан җитә» дип көтеп ала торган бәйрәмнәрдән иде. Бу мөнәсәбәт белән авылның бөтен кызы, егете бергә җыелганга, яңа тегеп тә, кешегә күрсәтелмәгән киемнәренә халык күрү, теләгән иптәше белән сөйләшү мөмкин булганга, болар бик кызык һәм күңелле була иде. Сагынып алына, бармый калынмый иде. Фәкать якын дус китсә, шунда гына күңелсез булып, Гөлбануның күзеннән бераз ук яшьләр түгелә иде. Ләкин болар сирәк иде. Гөлбану өчен җәйге кызыклар шуның илә тәмам булып, көз килсә, дәхи икенче төрлеләре була башлый иде. Җәйге кебек күмәк җыелу мөмкин булмаса да, унбиш-егерме кыз бергәләшеп күңел ачарлык эшләр булгалый иде. Боларның иң беренчесе: тула басудыр. Сарыгы бар кешеләр чикмән һәм оек өчен һәр ел көздә тула бастыралар, бу, әлбәттә, фәкать кызлардан гына гыйбарәт бер «өмә» белән эшләнелә, монда ир дә, хатын да булмый иде. Өйне аулак ясап, ун-унбиш кыз җыелалар. Яулыкларны артка бәйләп, ап-ак симез беләкләрне сызганып, кара-каршы тезелешеп утырып басалар, әвәләндерәләр, бу баштанаяк җыр, көлке белән, егетләрне сөйләү белән үткәнгә, чакырмасаң үпкәләнә торган җыелышлардан санала иде.

Болар үтсә, Гөлбану инде тизрәк көн суытып кар явуны тели башлый иде. Чөнки ул вакыт бөтен авылда казлар суела, аларны йолку өчен дәхи гел кызлардан гына гыйбарәт «өмә»ләр лязем иде. Авыл халкының бае-ярлысы бар да каз асраганга, каз йолку өмәдән башка булмаганга, бу мөнәсәбәт илә Гөлбану байтак җыелышларга барырга муаффәкъ[1] була иде. Үзләренең казы бик күп булып, бөтен тирә-якны чакырганга, «бәйрәм ашы кара-каршы» булганга, Гөлбану бик күп каз өмәләрендә була иде. Башкалардан артыграк йөри иде. Кичтән чакырылып, алар иртә намаз вакытында җыелалар, чәй эчәләр. Яхшы киемнәрен салалар да, казлар суйдырырга чыгалар иде. Каз суючы, әлбәттә, кызлар качмаслык бер

[1] Муаффәкъ – ирешү.

картрак кеше була. Алар кеше башына берәр-икешәрдән йолкып бетерәләр дә, ул казларны җуу өчен су буена алып китәләр. Каз җуугa бару үзе махсус тантана белән була: өмә итүче кеше, читтән табып булса да, яхшы чаналарга икешәр ат җигәргә мәҗбүрдер. Шул чаналарга кызлар бик матур киенеп-ясанып төяләләр. Алар монда махсус тәкәллеф[1] белән булып, чанага утырмыйлар, бәлки чананың артына, читләренә терәлеп кенә аягүрә баргансыман торалар. Казлар исә арттагы бер чанага төялә. Шулай чаналарга төяләләр дә, авылның бөтен урамнарын әйләнеп чаптырып йөриләр. Соңра гына бәкегә китәләр.

Бу йөрүләрдә каз җуу җәһәте буяу гына булып, асыл матлуб[2]: урамнарны әйләнүдер. Бәкегә барган соңында кызлар казга якын да бармый, аны бер-ике хатын гына башкарадыр. Гомуми гадәт булганга, һәркемдә өмә була, һәркем кызларны шулай йөртергә мәҗбүр булып, һичкем дә котыла алмыйдыр. Гөлбану өчен болар һәрнәрсәдән кызык булган кебек, башка кызлар өчен дә чакырылмаса, үпкәнең дә һичбер бетми торган булуында шөбһә юктыр.

Кыш озак... Төннәр озын... Көннәр күңелсез... Әлбәттә, бөтен кышны мондый каз бәйрәме белән генә үткәреп булмый. Ул бәйрәмнәр ун-унбиш көндә бетә дә китә... Шунлыктан авыл кызлары азрак күңел ачар өчен икенче юллар да тапканнар: аталары кунакка китеп, берәрсенең өе аулак калса, алар шунда кунарга җыелалар иде. Гөлбану агасыннан гармун өйрәнеп, кирәк вакытта гармун табарга да җае булганга, аны мондый җыеннардан калдырмыйлар, чакыралар иде. Ул үзе чакырылган җирдән һичбер калмый, бара гына иде. Атасы Нурый карт ачулырак вакыты туры килеп, Гөлбануны «Юк, булмас... йөрмә! Ни бетмәгән кунарга бару? Сине анда гармун уйный, имеш, дип сөйлиләр», дип манигъ кыйлса[3] да, анасы Фәтхия карчык бердәнбер кызын җылатмый, «бөтен кызлар йөргәндә бер ул гына өйдә утырмас инде», дип, Нурыйны ризалата... сораган җирдән Гөлбануны калдырмый иде. Тик ышанычсыз җир булса гына җибәрми иде.

Ничек тә Гөлбану барырга муаффәкъ була иде. Монда гел кызлар гына булып һәрнәрсә ирек булганга, бик моң иттереп музыка да уйнала, татарның кыска такмакларыннан башлап иң озын,

---

[1] Тәкәллеф – кылану, тартыну, көчләнеп эшләү.

[2] Матлуб – теләк, максат.

[3] Манигъ кыйлса – тыйса.

иң моң җырлары: ашказарлар, тәфкиләүләр, сакмарлар да җырлана. Парлап-парлап биюләр дә була иде. Аһ, мондагы ләтафәт, мондагы моңлык, мондагы музыкальный вә нечкә тавыш белән татар кызының өздереп, өзелеп җырлаган гашыйканә вә мөтәхәссиранә[1] җырлары адәмнең иң соңгы тамырларын типтерә, иң ерак хисләрне кузгатадыр иде. Гөлбану үзе музыкачы булганга, аңарга бер фәхер[2] дә бар иде. Болардан туктап егетләрне сөйләргә, алардан көләргә, аларга җирәбә салырга керешәләр, шулай итеп, озын төнне һич йокламый үткәрәләр иде. Болардагы күңеллелек, болардагы сафаны Гөлбану башка һичбер җирдән күрә алмый иде. Менә шул җыелышлар өстенә бик сирәк кенә чәйгә чакырышулар, кияүгә киткән кызның туйдан соң «кияү бүләге» бирергә дип җыйган мәҗлесләре булгалый... Озын кышны Гөлбану шулар белән үткәрә иде. Беррәттән санаганда бу нәрсәләр байтак күренсә дә, 365 көнне фәкать шул кызыклар белән генә уздыру Гөлбануга авыр, күңелсез тоела иде. Ул боларны гадәттә бикләнеп ятып та вакытлы гына уенга, ireккә чыгарылган кебек хис кыла иде. Күңеле боларга канәгатьсез иде. Күбрәк тели, ирек сөя иде. Ләкин булмый иде. Ул болардан калган озын кышның көннәрен һәм башка фасылларны дүрт стена эченә бикләнеп, ата-анасы күрмәсә, тәрәзә аркылы урамга карап үткәрергә мәхкүм[3] вә мәҗбүр иде. Нурый картның бала тәрбиясендәге бөтен кавагыйде фәкать «кысып тоту»дан гына гыйбарәт булганга, Гөлбану бик кысык яши иде. Атасы аны беркая да чыгармый, йөртми... Бикләнгәндәй тота иде. Теге җыеннарга җибәрүе дә бөтен авылда гомуми вә лязем булган гадәтләр булып, манигъ мөмкин булмаганга гына иде, мәҗбүри генә иде. Тыюга имкян булмаганнан гына иде. Бер Гөлбану түгел, бәлки бөтен авыл кызлары да шулай иде. Теге бәйрәмнәр, җыелышлар аларга көч белән тартышып алган кабилендә генә иде. Бу яклардан караганда Гөлбану шул авыл кызларының берсе булып, һичбер аермасы булмаган кебек, уку, гыйлем вә тәрбия ягыннан да шул иптәшләре кебек иде. Һичбер имтиязы юк иде.

Мәхәллә имамы Фәрит хәзрәтнең абыстаеннан дүрт ел укыгач, «остабикә булмас әле», дип, Гөлбануны сабактан туктаттылар. Зирәк бала! Ул шул дүрт кенә елдан гыйбарәт аз бер заманда

---

[1] Мөтәхәссиранә – кайгылы, хәсрәтле.
[2] Фәхер – горурлык, дан.
[3] Мәхкүм – хөкем ителгән.

да байтак нәрсә алган иде. Теләгән нәрсәсен укырлык, язарлык икътидаре[1] булмаса да, абыстайдан кат-кат укыган «Йосыф китабы»[1*] вә «Мөхәммәдия»[2*] кебекләрнең бәгъзе бер җирләрен карап та, яттан да бик яхшы укый ала иде.

Бу, әлбәттә, аңарга җитмәслек түгелдер. Болар өстенә аның башка фәннәрдән дә мәгълүматы бар иде. Җәгърәфиядән үзенең торган авылын, һәр ел кунакка барган бер авыл белән күренеп торган өч күрше авылны, мәҗмугы 5 авылны бик яхшы белә иде. Дәхи бер-ике шәһәрнең исемен ишеткән иде. Җир йөзе, аның вәһеменчә[2], өч-дүрт йөз чакрым кадәрле үк зур иде. Ул тарихтан да бихәбәр түгел иде: Адәмнең бодай ашап җәннәттән куылганын, хәзрәте Галинең җирне күтәрә язганын[3*] вә Әбүгалисинаның фокусларына[4*] әһәмият бирмәсә дә ишеткәләгән иде. Хисаптан да бөтенләй мәхрүм булмаса да, ләкин монда чамалырак иде. Җитү кыз булгангача үз хисабы, үз хуҗалыгы белән һичбер нәрсә алмый, сатмый вә һичбер тугрыда да хисапламый, һаман абзый-җиңги, эти-әни аркылы гына булганга, исәп-хисапта аның зиһене шомармаган иде. Ике бишнең ун булуын тиз үк белсә дә, ике унөчнең егерме алты булуы, утыз белән унбишнең кырык биш булуы кебек чобалчыкларны озак исәпләми чыгара алмый иде. Һәм шулай булуы табигый да... чөнки аның башы бу тугрыда һич уйламагандыр. Җирнең үгез мөгезендәлеге, җир-күкнең катлаулары кебек һәйәт[3] вә табәкательарзга[4] гаид[5] мәгълүмате фәниягә ата-анасы һәм башкалар зур әһәмият биреп ул тугрыда төрле тәфсыйләт[6] вә гаҗәип сөйләсәләр дә, кызлар арасында мондый нәрсәләрнең һичбер игътибары булмаганга, һаман күлмәк белән шәл вә приданлыкка әһәмият бирелеп, башкага дикъкать итәрлек вакыт калмаганга, Гөлбану алар тугрысында да чамалы иде. Аның бөтен зиһене вә барлык дикъкате үзенең чын вазыйфасы дип ышанылган шәл, күлмәк вә приданлыкка махсус булып, шуңардан үтә алмый иде. Бу фәннәрдән нәкыс[7] булса да, педагогия – бала тәрбиясе фәненнән хәбәре күп иде: баланы иске чүпрәккә бик каты биләп, кабык

---

[1] Икътидар – кулдан килү.
[2] Вәһеменчә – уенча, фикеренчә.
[3] Һәйәт – тышкы күренеш, кыяфәт.
[4] Табәкательарз – җир катлаулары, геология.
[5] Гаид – караган.
[6] Тәфсыйләт– җентекләү.
[7] Нәкыс – кимлек, җитешсезлек.

бишеккә салып дыңгылдатып тирбәтергә, җыласа яки карышса кыйнарга, һәр эштә бик каты тотарга тиешлеген ул билгамәл[1] белгән иде. Үзенең истикъбале[2] тугрысында да аның фикер вә теләге башка иптәшләреннән ким түгел иде. Ул теләкнең әүвәле-ахыры халык телендә макталып сөйләнерлек бер яшь кияүгә бара алудан гыйбарәт булып, хәзерге көндә приданны шәп хәзерләү вә халык исе китәрлек киенештә; аның бөтен идеалы шуннан гыйбарәт иде. Моның хәзергесе хакында үзе тырыша, әмма истикъбальдәгесен язмышка тапшыра иде.

Боларга башка нәрсә хакында ул инде, әлбәттә, борчылмый һәм кирәксенми дә иде. Уйлап зиһен ватарга хаҗәт тапмый һәм ватмый иде. Тирә-ягын сырып алган, көн-төн бергә кайнап шулардан башканы күрү мөмкин булмаган иптәшләре һәм өйдәгеләр авызыннан шуларга башка бер максат чыкмаганга, аның уе шулардан үтә алмый иде. Менә шул эшләре өчен ул саф авыл кызы иде, бу яклары белән ул үзенең йөзләрчә иптәшләренә тиң иде, бәрабәр һәм тигез иде, артык та, ким дә түгел иде. Бу җәһәтләрдән аңарда имтияз юк иде. Фәкать... фәкать... табигатьнең аңарга биргән бәгъзе бер кәмаләте[3] генә аны үзенең бөтен иптәшләреннән аера, аңарга имтияз бирә иде.

Аның табигый булган бәгъзе бер кәмаләтенә караганда «табигать бу кызны үзенең иң соңгы мәһарәтен сарыф итеп вөҗүдә[4] китергәндер» диясе килерлек, табигатьнең аңарга биргән имтиязларыннан әүвәл күзгә чалынганы – аның матурлыгыдыр, матурлыкта ул авылда бер иде. Халык та аны тиңләштереп тормый, ул инде авылда бер, дип кенә куя иде. Авылда бер!.. Ни өчен?

Менә шул сөальнең җавабы Гөлбануны бер күрүдә үк синең күз алдыңа киләдер: аның кызгылт алсу йөзе, сызылып торган кыйгач вә җем-җем кара кашы, өлкән кара күзе белән озын һәм сузылып торган керфеге, нечкә вә бераз биегрәк борыны, кечек авызы белән кызыл иреннәре, ак, вак һәм тигез тешләре, болар өстенә, ни дип тә тәгаен итеп булмый торган җәмал[5] нураниять[6] вә җазибәсе[7] күргән бер кешене табигатьнең бу сәнгате

[1] Билгамәл – гамәлдә.
[2] Истикъбале – киләчәге.
[3] Кәмаләт – җитешкән, тулы.
[4] Вөҗүд – бар булу, гәүдә.
[5] Җәмал – матур, гүзәл.
[6] Нураниять – нурлылык, яктылык.
[7] Җазибә – кешенең күңелен үзенә тартучы көч.

өчен тәхсин[1] иттерерлек иде. Күз күрсә, күңел мотлак аңарга мәел итә[2], кеше үзендә мәхәббәт хисе уянганны сизә иде. Аның буе уртача булып, һичбер әгъзасында кимчелек юк, һәммә әгъзалары мөтәнасиб[3] иде, гәүдә кызларга килешмәслек дәрәҗәдә калын булмаса да, бигрәк нечкә түгел иде. Шуның илә бәрабәр ул көчлелек вә тазалыкта һәммәдән өстен, бөтен иптәшләреннән алда иде. Ул сүзне оста вә килешле сөйли, фәкать җырга гына шәп түгел иде. Үзенең әйтүенә караганда, яшь чагында җырга шәп, тавышы матур булса да, чамадан тыш тегү-чигү, киндер сугу кебек нәрсәләр белән шөгыльләнү аның җырга ярарлык тавышын бетермештер.

Ләкин аның гармунга осталыгы җырсызлыктан килгән норсанны[4] каплый иде. Башка кызлар аталарының тыюы сәбәпле гармун өйрәнүдә икътидар итә алмыйлар, фәкать мунчага-фәләнгә качып, курай вә кубыз кебек нәрсәләр генә белеп калалар. Гөлбану исә бер бәхет аркасында гармун да өйрәнә алган һәм кирәгендә табарга җае да бар иде.

Ул музыкага үзендә булган истигъдадын бик гүзәл рәвештә эшләтеп, «маһир гармунчы» булган иде. Кызлар арасында аның кадәрле гармун уйный алучы юк иде. Кызлар гына түгел, егетләр дә аның гармун уйнаганын ишетсәләр, үз гармуннарын ташлап, моныкын тыңлыйлар иде. Кайвакыт егетләр тыштан, Гөлбану өй эченнән бергә вә бер көйне дә уйнап җибәрәләр, бу ике якка да бик кызык була иде. Ләкин халык белсә, эш харап... Хосусан Гөлбануның атасы Нурый карт сизеп калса, Гөлбану өчен зур бер һәлакәт чыга иде. Фәкать кызларның гомумән Гөлбануны саклаулары аның гармунчылыгын яшерергә тырышулары аркасында гына мондый куркынычлардан котылына иде.

Гөлбану салкын канлы, сабырлы иде. Шуның илә бәрабәр, үз башына төшкән авырлыкны бетерү хакында теле белән түгел, бәлки гамәл белән, хәйлә белән көрәшергә истигъдадлы иде. Шулар аркасында ул кыз вакытта ук өстенә төшәчәк авырлыклардан, атасының шелтәләреннән котылгалый иде. Тәрбия аркасында түгел, бәлки тәбган ул йөрәкле вә батыр иде, куркусыз иде. Үзе дәхи

[1] Тәхсин – мактау.
[2] Мотлак аңарга мәел итә – тәмам аңа тартыла.
[3] Мөтәнасиб – тигез.
[4] Ноксан – җитешсезлек, кимчелек.

истиһза[1], тәхкыйрьгә[2] вә золымга чыдамый иде. Гакыл вә тәдбире[3] дә гүзәл иде. Фәкать болар кирәгенчә эшләтелмәгән иде. Табигатьнең аңарга биргән шул кәмальләр аркасында аны авылда бер диләр иде. Һәм бер иде. Һәммәсеннән өстен иде, нөфүзле[4] иде. Аңарда булган бу табигый кәмаләт кызлар арасында хасидәләр[5], рәкыйбәләр[6] тудырган кебек, бөтен егетләрне мәел дә иттерә һәм мәхәббәтләр дә күбәү иде. Күп егетләр аңарга кызыгалар, аның белән йөрергә, алдарга, кайсылары хатынлыкка да алырга төрле юллар белән тырышалар иде. Күргән саен аңарга күз кысалар, каш сикертәләр, аулаграк булса, сүз дә кушалар иде. Дөрес, бу һәр кызга була, ләкин Гөлбануга дәхи күп иде.

Болай гына әйләндерә, сөйдерә алмагач, дога вә тылсым белән сөйдермәк булып, шул эштә мәһарәте белән мәшһүр булганнарга мөрәҗәгать кылалар иде. Гөлбануга төрле васиталар[7] аша сөйдергеч догасы белән өшкергән алма, конфет вә прәннек бирәләр, күкәй кабыгына зәгъфран белән тылсым яздырып утка яндыралар, йөргән җиренә өшкергән су сибәләр, киеменнән алып сихерлиләр, тагын әллә ниләр кыланалар иде. Ләкин һичбере муаффәкъ була алмады. Егетләр шул гамәлләреннән соң, «инде хәзер Гөлбану үзе гыйшкына түзә алмыйча безгә чыгып ябышыр... ялыныр», дип өмит итсәләр дә, ул һаман борынгы Гөлбану була, һичберсенә илтифат итми иде. Һичберенә мәел итми, йөрешми вә катышмый иде.

Авыл кызлары арасында өч-дүрт егет белән йөрешеп, һәрберсеннән конфет, прәннек кебек бүләкләр ашаган кызлар, дүрт-биш кыз белән берьюлы йөрешкән егетләр күп булса да, Гөлбануга күп егетләр мәхәббәт гарыз[8] итсәләр дә, ул берәүгә дә бирелми, кул бирми иде. Һичбер егет аның илтифатына мәзъһәр түгел[9] иде. Мәгәр... мәгәр... соңгы елларда гына Зыя дигән бер егет Гөлбану тарафыннан илтифатка алына башлаган иде. Гөлбану Зыяны ярата, күңелендә аңарга мәел сизә. Зыя төскә-башка чибәр, тәүфыйгы

---

[1] Истиһза – көлү, мыскыл итү.
[2] Тәхкыйрь – түбән күрү, хурлау.
[3] Тәдбир – эшнең ахырын уйлап эшләү.
[4] Нөфүзле – абруйлы, авторитетлы.
[5] Хасидә – көнче.
[6] Рәкыйб – конкурент.
[7] Васита – арадаш.
[8] Гарыз итү – аңлату, тәкъдим итү.
[9] Илтифатына мәзъһәр түгел– игътибарын җәлеп итә алмый.

яхшы булган кебек, байлыгы һәм игътибары да шәп иде. Үзе авылның бердәнбер сатучысының бер генә угылы иде. Күптән үк Гөлбануны ничек әйләндерергә белми йөреп, соңгы елларда муаффәкъ булгач, моны ул бик ганимәт белде. Гөлбануга бик зур илтифат, хөрмәт күрсәтте. Аңарга ялыну, вакланудан бер дә тартынмый, ничек тә ныграк багъларга тырыша иде.

Алар кара-каршы яратышалар, йөрешәләр иде. Авыл кызлары вә авыл егетләренең җанлы булудан бигрәк гәүдәле булу ягы көчле булганга, алар гашыйкларча янып-көеп, өзелеп сөймәсәләр дә, күңелләрендә бер-беренә мәел куәтле иде. Гыйшык булмаса да, ярату бар иде. Зыя Гөлбануга конфет, прәннек кебек бүләкләр бирә, аңарга каршы Гөлбану Зыяга сары чүпрәкне дебет белән бик куе итеп чигелгән кульяулыклар бирә иде.

Алар шулай бүләкләшәләр, аулакта күрешеп сөйләшәләр, үбешәләр, кочаклашалар иде. Зыя Гөлбануның кич утырган чакларында караңгы төнне килеп, тәрәзә аркылы сөйләшкән, үбешкән чаклар аларга бик хозур була иде. Зыя хайванрак булса да, Гөлбану алданмады. Араларында даирә гыйффәттән читкә чыккан нәрсә булмады. Аталары байлык җәһәтеннән бәрабәр булып, дуслыклары да яхшы булганга, үзләре дә бер-берене яратканга, болар арасында гомерлек юлдаш булудан манигъ булган нәрсә күренми иде.

Үзләре дә моны бик өмет итәләр иде. Һәр икесенең дә күңелендә бер-беренә өйләнү дәрте бик мөхкәм[1] булып, үз ихтыярлары белән башкага катышачак, өйләнәчәк түгелләр иде. Гөлбану, әгәр дә ир сайлау хокукы үзенә бирелсә, үзе теләгән егеткә бару ихтыярына малик[2] булса, һич шөбһәсез Зыяны ихтыяр кылачак, шуңа барачак иде. Зыя исә бөтен вөҗүде белән Гөлбануны тели, аны алырга бик тырыша иде. Гөлбануның үзенә дә кат-кат «мин сине алам», дип әйткән иде. Гөлбануның кызлык назы «мин сиңа барам», диюдән манигъ булса[3] да, бу сүзне теле белән әйтә алмаса да, күңелендә бик нык урнашкан иде; «мин сине алам», дигәч рәхәтләнеп китә... шатлыклары бөтен вөҗүдене тутыра иде. Шөбһәсез, барачак иде.

190... елда ашлыклар да шәп үскәнгә, көзге байлыкта туй ясап калу өчен Гөлбануга Зыя тарафыннан яучы җибәрергә карар

---

[1] Мөхкәм – нык, анык.
[2] Малик – хуҗа, ия.
[3] Манигъ булса да – тыелса да.

бирелде. Зыя моны биззат[1] үзе Гөлбануга теле белән әйтеп, һәр икесе дә тиздән кавышачакларына ышандылар. Гөлбану моңардан чиктән тыш шат булды. Үзен бәхетле һәм мәсгуд[2] санап, шул карарның тизрәк вөҗүдкә чыгуын, тиз генә зөфаф булуын тели башлады. Хәзер аңарга көннәр озын булып, шул өмитне әбәдийять[3] кадәрле ерак кебек тоела... Тиз генә җиткерәсе килә иде. Зиһене башка һәр нәрсәдән бушанып, ул хәзер Зыяга кавышу, Зыя белән яшәп мәсгуд булудан башканы уйламый торган булды.

II

Гөлбануның атасы Нурый карт, яшь чагында ярлы һәм тәүфыйксыз булып, урлау-талау кебек эшләрдә генә йөрсә дә, тапкан берсен эчеп бетерә барса да, өлкәнәя төшкәч, баеп һәм тәүфыйкланып киткән иде. Халык телендә аның тиз баюы хакында «бердән күп акча эләктергән, имеш» дип сөйлиләр иде. Баеганнан соң байтак еллар яшеребрәк эчеп йөрсә дә, хәзер анысы да беткән иде.

Аның тәкъва вә суфыйлыгы яхшы иде. Эчми, тартмый, урламый вә биш вакыт намазны калдырмый иде. Башында чалма, кулында яшел таяк вә өстендә җилән булган хәлдә, һәрвакыт аның мәчеткә йөргәне күренә иде. Аның киеме дә баштанаяк мөселманча булып, чәчен дә җомга саен алдыра, мыегын да астан һәм өстән кырдырып җеп кебек кенә калдыра, анда кунган фәрештәләрне төшерүе муҗәб[4] булганга, сакалга һичбер кул тидерми иде. Шуңа күрә аның сакалы көрәк кебек була иде. Яше 70 ләргә үк җиткәнгә, ул инде чәче, сакалы агарып, үзе дә үлемнең якынайганын хис кыла, шәригать эшләрендә кимчелек кылмаска тырыша иде.

Байлыгы нисабтан[5] күп артып, зәяттән һичбер тиен бирмәсә дә, һәр ел гошердән бирми калмый иде, мәшруг[6] булган уннан берне чыгарып бетмәсә дә, начаррак арыштан кечерәк берәр арбаны мулла белән мөәззингә, әлбәттә, илттерә иде. Берничә елдан бирле Сафа ишанга мөрид булганга, һәр ел аңарга да сәдака чыгара иде. Корбан бәйрәмендә бер сарыкны да бер дә җәлләми, корбанга чалып, өстеннән фарызны төшерә иде. Мәчет вә мәдрәсә өчен акча

[1] Биззат – турыдан-туры.
[2] Мәсгуд – игелекле, бәхетле.
[3] Әбәдийять – мәңгелек.
[4] Муҗәб – бер эштән килеп чыгарга ихтимал хәл, нәтиҗә.
[5] Нисабтан – зәкят бирерлек күләмнән.
[6] Мәшруг – шәригать каршында дөрес эш.

җыйган вакытларда ул кайсы елларны илле тиен үк биреп ташлый иде. Менә шундый изгелекләре өчен Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре аның малына, дәүләтенә бәрәкәт бирә, бәхете ачыла, ул елдан-ел байый гына бара иде. Көз көне аның өлкән ындыры ашлык кибәннәре белән тулы булып, күп елларда еллаган кибәннәре дә була иде.

Күп еллардан бирле ул ашлык сатып алуны бөтенләй куйган, һаман сата гына иде. Ел тәүлегенә ашарлык ашлыгы булып, һичбер сатып алмау авыл халкында зур байлыктан саналганга күрә, Нурый карт һәрвакыт: «Без гер табагыннан үлчәтеп алып ашауны күргәнебез юк... Аллага шөкер», – дип мактана иде. Аның йорт-җире, абзар-курасы да шәп иде. Такта белән япкан ике зур өе, бер мал өе, кара булса да мунчасы, ике келәте, амбар, лапаслары, тезелеп киткән азбарлар күргән кешене «калын бай» дидертмәктә иде. Ул үзе тәкәллеф сөйгәнгә, кунаклар килгәндә кертә торган өлкән өен мөмкин кадәрле матур вә зиннәтле ясаган иде. Анда үзенең һәр байлыгын күрсәтә иде. Сәгать, көзге, шкаф кебек кирәкле нәрсәләрдән башка ул бик күп кирәксез нәрсәләр дә куя иде. Шәмаилләр, өйнең бөтен эчен әйләндереп алган сөлгеләр һәр өйдә булса да, Нурый карт аларга гына канәгатьләнми иде. Шкафның эче чынаяк вә чәй посудасы белән генә тулмагач, аны матур бизәкле эче буш калай тартмалар белән тутыра, хәтта ватык посудаларның да ватык ягын эчкә куеп төзек шикелле күрсәтеп тезә, сабыны алынган, чәе бушатылган кәгазьләр һәммәсе эчендә нәрсә бар кебек итеп кабартылып шунда куела иде. Нурый картның хәйләсен белмәгән кеше боларны күреп әллә ни кадәрле исле сабыннар, бик күп кадаклы чәйләр тора дип ышануында шөбһә юк иде. Нурый карт үзе дә ул буш кәгазьләрне шулай ышандыру өчен куя иде. Ул өст-башын да шулай тәкәллефле тота... күп вакыт кама бүркен кырын сала, өстенә яңа вә ялтыравыклы җилән кия, күзенә сөрмә тарта, толып кисә, аның якасын җилкән ясап торгыза иде. Ул үзе теле белән дә бик мактана, минем фәләнем-төгәнем бар дип, борчак сибә иде. Һәм гамәлдә дә шуны тырыштыра иде. Арба һәм сбруй гомумән агач вә мунчаладан гыйбарәт булса да, ул үзе яхшы ат, яхшы арба җигә, сбруйны да шәп итеп үзе өчен бер атлык асрый иде. Болай тәкәллефләнү өчен малы, байлыгы мөсагыйд[1] иде.

---

[1] Мөсагыйд – мөмкинлек бирә.

Аның җигәрлек аты уннан, савым сыеры 7–8 дән өзелми иде. Сарык, кәҗә, үрдәк, каз һәм тавык кебек нәрсәләрне дә күп асрый иде. Үз тәгъбиренчә[1] әйтсәк, аның малдан, игеннән бәхете дә бар иде. Һәм үзе заманы белән мал табарга бик тырышып, хәзер исә угыллары да үзе кебек мал өчен тырышучылар иде. Малны табучы үзе булгач, үзе тырышлык белән таптым дип уйлагач, ул рәхәтен дә үзе күрергә, үз кирәгеннән малны кызганмаска да иҗтиһад кыла иде. Үз гомерендә җиде хатын алып, боларның алтысы кыздан булуы бу сүзнең раслыгына гуаһлык[2] бирә иде.

Өлкәнрәк яшьле кешегә, хосусан көндәш өстенә булса, яшь кызны бик арзан сатмаганга, ул боларны алу өчен, әлбәттә, күп мал сарыф кыла иде. Һәм күпме сарыф кылса да, шәригать юлына булганга, бер дә кызганмый иде. Байлыгы шәп булганга, ул үзе ир уртасы заманында хатынны дүрттән ким тотмады. Берсе үлсә яки аерылса, ул тиз үк икенчене алып, дүрткә тутыра иде. Байлыгы яхшы, игътибары бар булып, малны да кызганмаганга аңа, әлбәттә, яшь кыз табыла иде. Башкача бирмәсәләр, берәр зур хәзрәтне майлап, шуның яучылыгы белән булса да алмый калмый иде.

Фәкать картаеп, үзе бераз йомшара башлагач кына хатыннарны азайтты. Гыйбадәткә кимчелек китерәләр дип, бер карт хатынын аерды. Бер яшьрәге үзе аерылды. Кайсысы үлде. Шулай итеп, башка хатыннары бетеп, ялгыз Гөлбануның анасы Фәтхия карчык кына калды.

Фәтхия әби юаш, сабыр, бала җанлы булып, иренә бик итагатьле һәм хезмәтле иде. Нурый карт аны кызлата матурлыгына кызыгып алган иде. Ул яшь вакытта матур иде. Фәкать инде хәзер хәят аны билен бөгеп, битләрен бераз җыерчыклаган иде. Иртәрәк булса да, тешләре дә төшкән иде. Ул үзен иртә картайган, хосусан тешләре бигрәк иртә төшкән дип хисаплый иде. Моңа сәбәп тә Нурый картның холыксызлыгы дип белә иде. Җиде хатын белән яшәгән Нурыйның балалары, әлбәттә, күп булды, аңардан 23 бала дөньяга килде. Ләкин боларның күбесе яшәмәде, кызлардан фәкать Гөлбану калып, угыллардан җиде калмыш иде. Башкалары кабердә иделәр.

Боларның һәммәсе 3–4 ел мәдрәсәдә укысалар да, һичбере уку-язу белә алмаган иде, уку-язудан мәхрүмнәр иде. Фәкать берсе

---

[1] Тәгъбир – фраза, телдән әйтү.

[2] Гуаһ – таньк, шаһит.

генә үзләрендә торган учительдән ике ай укып русча һәм язарга, һәм укырга өйрәнеп кала алган иде. Башкалар өмми[1] иде.

Бу угылларның һәммәсе өйләнеп, дүртесе күптән үк аерылып чыккан, йортта калган өчесе исә күптән таралырга теләсәләр дә, Нурый карт ирек бирмәгәнгә мәҗбүри генә бергә торалар иде. Әгәр карт үлсә, көне белән сугышып аерылачаклар иде. Бу өч угыл бер-бере белән бер дә тыныша вә тату яши алмыйлар, юк-бар өчен дә талашып сугышырга торалар иде. Фәкать Нурыйның хуҗалыгы һәм калын таягы гына аларны канга батудан тыя иде.

Нурый үзе карт һәм өлкән булып, күптән үк эш вә хезмәтне ташлаган исә дә, йортка вә һәр нәрсәгә хуҗалык, хакимият вә тәсаррыф[2] аның кулында иде. Ул башкара, ул боера иде. Һәр эшне үзе дигәнчә генә йөртә иде. Аның бу хуҗалыгы, хакимияте тиешеннән артыгракка да чыгып киткән иде. Ул, бик мөстәбид[3] булып, һәммә эшне үзе уйлаганча, үзе теләгәнчә генә булдырырга тырыша иде.

Аның бөтен эшләрдә хәтта «хәрәкәт табигый»сы[4] «үземчә генә булсын»нан гыйбарәт иде. Аның өстенә ул бик кызу канлы һәм тиз ачучан иде. Бик кечкенә бер эш үз кәефенчә булмаса, хәзер кызып ачуланып сүгенеп бара, сизми дә калына, яңаклап та ала иде. Ялчылары, хатыннары һәм угыллары аңардан бик күп таяклар ашыйлар, ишан биргән шул яшел таяк шифасы аркасында күп вакыт авырып та яталар иде. Ул үз гомерендә бик күп таяк сындырды, бик күп тәннәрдән кан чыгарды. Кара яндырды. Имгәтте, ләкин үзе шуңа мокабил[5] һичбер җәза күрмәде. Аның таягының икенче башы һичбер вакыт үзенә тимәде. Үзе бай, үзе карт булганга, һәммәсе ябылды, бетте. Ялчысы «баем кыйнады» дип сельски старостага барса, «ярар карарбыз» дип кенә кайтарыла иде. Берничә көн үткәч, староста чәй эчәсе килсә генә Нурый картка килеп: «Синең ялчың жалуга[6] барган иде әле»,– дидер иде. Моңа каршы Нурый карт, сөкүт итеп[7], сүзне икенчегә бора... старостаны сары майлап чәй эчерә дә, эш шуның белән төзәлә иде.

---

[1] Өмми – укый-яза белмәүче.
[2] Тәсаррыф – хуҗа булу, кулда тоту.
[3] Мөстәбид – үзе теләгәнчә эш йөртүче, деспот, изүче.
[4] «Хәрәкәт табигый»сы – холкы-гамәле.
[5] Мокабил – каршы.
[6] Жалу – (жалоба) – шикаять.
[7] Сөкүт итеп – дәшми торып.

«Ирем кыйнады» дип, хатыннары муллага барса, ул аларны вәгазьләп кайтара, мәхәлләсенең бердәнбер бай һәм вәли нигъмәте булган кешенең кәефен кырасы килмәгәнгә, хатынны: «Бар, кайт, итагать кыл[1]... үзең яхшы булсаң тимәс... түзсәң, теге дөньяда савап булыр», – дип кенә җибәрә иде.

Кыйналучылар староста белән мулладан югары хакимгә мөрәҗәгать кыла алмаганга, кылган тәкъдирдә дә байныкы хаклы чыгачагы билгеле булганга, түзәргә мәҗбүр булалар, теге дөньяда булачак гомуми мәхкәмәгә эшне калдыралар иде. Нурый карт боларның жалуга барганын белгәч, ул аларны: «Әле сиңа аз булган икән!» – дип, бик каты тагы яра да, шуннан соң алар жалуга йөрми башлыйлар иде. Нурый картка тыныч була иде. Күпме кыйнаса да, сүз булмый иде. Бу таяктан, бу чабаклардан башка һичкем котыла алмый, мәгәр Гөлбану гына имин иде. Ул бер генә һәм төпчек кыз булганга, Нурый карт аны таяклауга базмак итми, юк-бар өчен аны шелтәләми иде. Берничә кәррә кыйнарга касд кылса[2] да, Гөлбануның җылгыр вә саклыгы, анасының ярдәме аркасында, Нурый муаффәкъ була алмаган иде. Бу музыка тугрысындадыр: бервакыт Нурый картның колагына «Гөлбану музыка уйный, имеш» дигән бер хәбәр кермеш иде. Ул шуңардан каны кызып ачуына чыдаша алмый кайтты да, сорашмый-нитми: «бердәнбер кызыңны тыймыйсың», дип, Фәтхия әбине, «бер сеңлегезне карамыйсыз», дип, угылларын бик каты ярды, таяклады.

Гөлбану өйдә юк иде. Аның кайтуын саклап, сүгенеп: «Кайтсын әле! Ул оятсызга бирим мин кирәген»,– дип, кыйнарга көтсә дә, тугры китерә алмады. Аны, кайту белән, атасына күрсәтмичә кире озаттылар.

Нурый карт тиз ачуланган кебек, аның ачуы да тиз басыла иде. Берничә сәгатьтән соң Гөлбану кайтса да, һичнәрсә булмады. Мондыйлар берничә мәртәбә булгаласа да, һәрберендә Гөлбану котылмыш иде. Я өйдә булмый, яки булса да, сиздерми генә кача иде. Бу таяклар, бу чабакларның иң күбе, иң ачысы Фәтхия әбигә эләгә иде. Аның түзүенә, чыдавына ис китәрлек иде. Нурый картның һәр эшне үзе дигәнчә генә йөртүеннән, кешегә киңәшне бер дә белмәвеннән һәм кызу канлылыгыннан Фәтхия әби үзе бик күп

[1] Итагать кыл – буйсын, сүз тыңла.
[2] Касд кылса – ният итсә, теләсә.

газаплар, бик күп зарарлар күрдегеннән, шул табигать Гөлбануны кияүгә бирү хакында бер мосыйбәт[1] чыгармаса, үз белдеге белән биреп, бердәнбер кызымны харап итмәсә ярар иде, дип бик кайгыра һәм курка иде.

Гөлбану җитү кыз булгач, Нурый картның аны бирү хакындагы сүзенә, хәрәкәтенә бик дикъкать итә башлаган иде. Авылның бай сәүдәгәренең тәүфыйклы һәм игътибарлы булган бердәнбер углына Гөлбануны соратмакчылар, имеш, хәбәре аның колагына кергәч, ул бик шатланган иде.

Егете яхшы, байлыгы да бар, атасы дус та, шулай булгач, Нурый карт та карышмас, бирер дип өмит итте. Нурый карт та Зыяның сорату ихтималын, озын колактан ишетеп, бик кире күрмәгән иде. Хосусан, авылның бердәнбер сәүдәгәренә кода булуга аның кәефе бик килә иде. Шул ноктасын уйлап, күңеленнән бирергә дә карар биргән иде. Яучы килсә, кайтармаячак, бер сүз белән бирәчәк иде. Шул бай сәүдәгәргә кода булу өмете белән ул башка җирдән килгән яучыларны «бу елга бирмим... кызым яшь әле!» дигәләп кайтара. Яучы килгәнне сизеп калса, Гөлбану каушап, калтырап, йөрәге ярылырга җитешеп, кая басканын белми, бөтенләй шашып калып, Зыядан аерылу куркынычлары күз алдына килсә дә, рәд кылганны[2] ишеткәч, шатлыгы чигеннән аша... аягы җиргә тими җиңеләя иде. Ерактан аның колагына «Гөлбануны Зыяга бирәләр, имеш», дигән хәбәр кергәли башлагач, ул бөтенләй икенче Гөлбану, бөтенләй бәхетле кыз булып киткән иде.

Ул инде Зыяга баруына тәмам ышанган иде. Ләкин... ләкин язмыш башкача, имеш. Адәм теләгәнне түгел, бәлки язылганны күрә... Өмит, адәмне бераз җуатканнан соң югалып, кан-яшь еглата. Гөлбану белән Зыя озакламый кавышуларына ышанып йөрсәләр дә, тәкъдир аңарга каршы барды. Гөлбану да, анасы да белмичә үк калдылар, Нурый карт маһирәнә корылган бер тозакка төшеп, киңәшсез-нисез Гөлбануны Зариф углы Закир дигән бер мәҗһүл[3] егеткә бирде, һәм мәһәр акчасы да алды. Гөлбану, Зыядан ычкынып, Зариф углы Закирга эләкте. Дәрьяларча күз яше һәм аһ-зардан һичберсе аны моңардан котылдыра алмады.

---

[1] Мосыйбәт – кайгы, башка төшкән авырлык.

[2] Рәд кылганны – кире какканны.

[3] Мәҗһүл – билгесез.

III

Гөлбануның булачак ире Закирның атасы Зариф агай бүген-иртәгә кабергә керәм дип йөргән бер карт иде. Нурый картларның авылы Күлбашыннан 35 чакрым кадәрле ераклыкта Курайлы дигән авылның алгы сафтагы байларыннан иде. Тирә-як халкы аны атадан бай килгәнгә, «ул Зариф карт черегән бай инде», дип йөртәләр иде. Аның игене, җир-суы күп, малы да күп иде. Ләкин аның йорт-җире, тормышы саран һәм тәдбирсез вә тәрбиясезлеген күрсәтә иде. Ул хакыйкатән дә саран вә тәрбиясез кеше иде. Мал вә акча, хәят вә сәгадәт өчен, бәлки, хәят үзе мал зә акча җыю өчен дигән, малдан файдалану өчен түгел, бәлки нәфесе, заты өчен тырышкан кешеләрнең берсе, бәлки, беренчесе иде.

Һәрбер рәзаләткә[1], уңайсызлыкка түзә, фәкать акча сарыф итәргә зарур урында, мал түгәргә риза булмый иде. Акча чыгару аның каршында җан чыгару белән бәрабәр иде. Гомерендә ике хатын алса да, аларны да акча чыга дип, кыздан алмаган, бәлки малларына кызыгып толдан алган иде**.** Өйләнгән дүрт углы булып, алар да Зариф карт балалары икәнлекләрен тыштан ук белдереп торалар иде. Җәмәгать вә бала-чага күп булса да, артык саранлык, аңарга кушылган тәрбиясезлек, тәдбирсезлек аркасында алар җыенысы кечкенә генә ике өйгә тыгылып, лыгырдап яталар иде.

Өйләренең тыш ягыннан караганда ярлы бер кешенең йорты кебек күренгән шикелле, эченә керсәң дә, бик кабахәт иде. Өйләре коры стена белән сәке һәм пичтән гыйбарәт булып, күп вакыт ишеге тупсасыз, тоткасыз, тәрәзәләре ватылып карындык яки чүпрәк каплаган була иде. Сәгать, көзге, шкаф кебекләр түгел, аш-чәй әсбабы да бик зәгыйфь, бик рәтсез иде.

Самовар кечкенә, каралган, канфаркасыз булып, галибә[2] борыны да җимерек була, чынаяк, чәйнекләр замаска белән сыланган, ашъяулыклар керләнгән күренә иде. Үзләренең өс-башы, арба-чанасы, камыт-сбруйлары начарлык белән авылда мисал хөкеменә кергән иде. Киемнәр тула, алача, тышсыз туннан гыйбарәт булып, ул да җыртылган, эштән чыккан булганга, бер хәерче төсле күренәләр иде. Йорт һәм өй эчләрендә кая карасаң, ватык, сынык, ауган, егылган, җимерелгән, кер вә нәҗескә[3] болганганлык очрала

[1] Рәзаләткә – хурлыкка, яманлыкка.
[2] Галибә – күп вакытта.
[3] Нәҗескә – пычракка.

вә тыгызлык һәм быламалык хөкем сөрә иде. Монда ялгыз саранлык түгел, бәлки пис[1], хәсислек[2], нәзафәтне[3] белмәү, белсә дә ригая кылынмауның[4] да зур катышлыгы мәгълүм иде. Шул начар тормышның тәэсиреннән булса кирәк, аларның күбесе күзгә-башка зәгыйфь булып, төрле авырулар белән мөбтәляләр[5] һәм табган бик түбән, бик истигъдадсыз булып, рәтле сүз дә, мөгамәлә дә, эш тә булдыра алмыйлар, гомуми эшләргә якын да бара алмыйлар иде. Үзләре һәр урында нөфузсез вә мәгълүб[6] булалар иде. Әгәр дә болар тереклек, бәхет вә байлык «көрәш-тәназыг[7]» аркасында була торган галәмдә яшәсәләр, һичбер байый да алмаслар, тора да алмаслар иде. Хәзерге байлыклар аларга тырышып түгел, бәлки атадан калганны гына өзмәгәнлектән иде. Халык телендә шул пислекләре[8] өчен аларны «чуашлар» диләр. Начар вә тәрбиясез нәрсә күргәндә «Заркай чуашлар» кебек дип тәмсил итәләр[9] иде. Халык каршында алар бик игътибарсыз вә кадерсез саналалар иде. Шунлыктан аларны чын таныган кеше аларга кыз бирми, кода булуны теләми иде. Ул үзенең дүрт углына да үзләрен белми торганрак җирдән төрле васиталар белән генә хатын тапты. Иң кече углы Закир исә гаиләсендәге кимчелек өстенә шәхси кабахәтлекләре дә кушылган иде. Ул солдаттан бик бозылып, бер туктамый эчәргә һәм тартырга салышып кайткан, өстәвенә бик кызу һәм җиңел гакыллы вә тотнаксыз булуы халыкның бигрәк нәфрәтен җәлеп итә, бинаән галәйһи[10] кызны да еракта эзләргә мәҗбүр булына иде. Ямьсез төсе, бозык табигате, урынсыз усаллыгы халыкның «аңарга кызыңны бирсәң, ул кыйнап үтерер» диюенә сәбәп була иде. Шуңа күрә Закирга тирә-яктан кыз табылмады. Еракта эзләргә тотындылар. Аларның колагына әллә кайдан Күлбашы авылы Нурый картның кызы барлыгы ишетелеп, шуңарга кул сузмакчы булганнар иде.

---

[1] Пис – пычрак, начар.
[2] Хәсислек – түбәнлек, саранлык.
[3] Нәзафәтне – арулыкны, пакьлекне.
[4] Ригая кылынмауның – кайгыртмауның, карамауның.
[5] Мөбтәляләр – дучар булганнар.
[6] Мәгълүб – җиңелгән, аста калган.
[7] Тәназыг – тартышу.
[8] Пислекләре – шакшылыклары.
[9] Тәмсил итәләр – охшаталар, чагыштыралар.
[10] Бинаән галәйһи – шул сәбәпле.

Турыдан-туры үзләре барып сораса, бирмәячәкләреннән куркылганга, алар эшне Нурый картның мәхәллә имамы Фәрит хәзрәт аркылы йөртмәк булып, аңарга мөрәҗәгать кылдылар. Аңардан Нурый картның кызы Гөлбануны Закирга сорарга үтенделәр. Фәрит хәзрәт үзенең иптәш мулласы өстеннән «патшаны сүкте» дип гариза биреп, Зариф картның ике углы шул дәгъвага шаһит булганга, Фәрит мулла яучылыкны өстенә алырга мәҗбүр булды. Чөнки суд тиздән булачак... әгәр дә Фәрит хәзрәт яучылык кылмаса, Зариф ачу итеп аның угыллары шәһадәтләрен ташлаячакларына шөбһә юк иде. Эш бозылачак иде. Менә шуңардан курыкты да, Фәрит хәзрәт Нурый картның кызы Гөлбануны Закирга алу өчен яучылык кылды. Майлады, көчләде, үтенде. Ничек тә эшне Закир файдасына чыгарды.

Фәрит мулла Нурый картның каршында сүзе мәкъбүл[1] һәм ышанычлы бер хәзрәт булганга, хәзрәтебез, урынсыз булса да, сүз чыгарып, Зыяны яманлап, Закирны мактап һәрьяктан мөстәхикъ[2] дип күрсәткәнгә, Нурый бабай каршы тора алмады. «Хатыннарның чәче озын булса да, гакылы кыска... алар берни дә белми... киңәш итсәң, белмәгән башлары белән эш бозалар», дип, хәзрәт Нурыйның истибдаден[3] хаклаганга, бер мәҗлестә үк вәгъдә булды. Гөлбануны Закирга бирергә сүз бирде, ныгытты. Рәсми яучы килгәнгәчә бу мәсьәлә Нурый белән Фәрит арасында сер тотылып, Гөлбануга да, Фәтхиягә дә, башка һичкемгә дә белдерелмәде. Эшне рәсмиләштерү өчен Зариф карт тарафыннан яучы килде. Әле һаман Гөлбану һәм Фәтхия бихәбәр иде. Сөйләшелеп мәһәргә килештеләр. Мәһәр акчасын Нурый карт алды. Яучы китте. Менә шуннан соң гына алар хәбәрдар булдылар. Бу хәбәр, Гөлбануга да, Фәтхиягә дә яшен кебек тәэсир итеп, аларны изде... чәнечте, ватты.

Фәтхия карчык үзе Курайлыга якын бер авылныкы булганга, Зарифны да, Закирны да белә иде. Бөтен көче белән каршы торды, бирергә риза булмады. Кайтарырга тәклиф[4] итте: «Харап иттең кызымны... бер пьянич[5] чуашка кеше кыз бирә микән?.. Кайтар... кайтар... зинһар, кайтар!.. – дип, кат-кат ялынды... ялварды. Еглады, ләкин муаффәкъ була алмады.

---

[1] Мәкъбүл – яраклы, яхшы табылган.
[2] Мөстәхикъ – хаклы, лаеклы.
[3] Истибдад – чиксез власть, деспотизм.
[4] Тәкълиф итте – көчләп кушты, боерды.
[5] Пьянич – (пьяница) – исерекбаш.

Васита хәзрәт булгач, акча да алынгач, үз авызы белән бер мәртәбә «бирәм» дигәч, хатыннар сүзенә карап, вәгъдә бозуны, үзе теләп эшләгән бер эшне хатын сүзенә карап сүтүне Нурый карт кабул итмәде. Еламагайлары әллә ни эшләсәләр дә, үзе дигәнчә булды.

Гөлбану үзе теле белән атасына әйтергә булдыра алмаса да, анасына үзен-үзе белми елап: «бармыйм... кайтарыгыз», дисә дә, кызының риза булмыйча көн-төн елаганын Фәтхия карчык Нурыйга әйтеп, Нурый моны үз күзе белән күрсә дә, һичбер йомшармады. Билгакес сүкте. «Лыгырдамагыз юкны... мин сезнең кадәрле белмим мени? Күп тавышлансагыз, барыгызны да йорттан таяк белән куып чыгарырмын... оятсызлар... Хатын башыгыз белән мин эшләгән эшне бозарга уйлыйсыз...» – дип, өсләренә мәкруһ[1] тавышы белән җикерде. Гөлбану, Фәрит мулланың кызы Нәфисә дусына елап, аның аркылы Фәриткә үзенең риза түгеллеген белдерсә дә, аннан да һичбер файда чыкмады. Һичкем аның мохтар[2] икәнен тасдыйк итмәде[3]. Аның күз яше кыйммәт дип, берәү дә игътибарга алмады. Гөлбану кайда караса да, үзенең өстенә төшкән бу һәлакәттән котылырга һичбер юл таба алмады. Ул өметсез вә мәхзүн[4] иде.

Халык телендә хәзердән ук Закирның мең төрле кабахәтлекләре сөйләшә башлап, бу турыдагы сүзләр аның йөрәгенә ук кебек кадалалар, шул вөҗүден агулыйлар иде. Ул изелде, җәнчелде. Күзе даими агар чишмә хәлен алып, көн-төн ул гүзәл күзләрдән, алсу йөзен каплап, энҗе бөртекләре түгелә иде. Ул һаман еглый гына иде. Ләкин бу яшьләргә файда бирмәде. Эш Нурый дигәнчә булып, 40 сум, 7 күлмәк, ике шәл, камзул, бишмәт, бер пот бал вә бер туш иттән гыйбарәт мәһәр бәрабәренә Гөлбану Закирга бирелде. Туйга ун кеше килергә сөйләшелде. Туй көне, тәгаен ителеп, «өндәүгә» дә җибәрелде...

Тиздән туй булачак...

Ноябрьнең соңгы көннәре иде.

Кыш, үзенең ак кардан гыйбарәт кәфеннәре белән килеп, бөтен кяинаттан[5] хәятне алмыш, кәфенләмеш иде. Аның дәһшәте

---

[1] Мәкруһ – сөйкемсез, усал, ямьсез.
[2] Мохтар – ирекле.
[3] Тасдыйк итмәде – расламады.
[4] Мәхзүн – кайгылы, моңлы.
[5] Кяинат – бөтен дөнья, галәм.

һәрнәрсәне дер-дер калтырата иде. Авыл халкы, башка һичбер кызык калмагач, җәйге ашлыкны сатып сыйлашырга, кунак чакырырга тотынганнар иде. Бае, ярлысы – берсе дә калмый кунак чакырганнар, бөтен авылда ду иттереп кунаклашу дәвам итә иде. Мулла, мөәззин вә могътәбәран[1] иртәдән кичкәчә өйдән-өйгә ашка, чәйгә йөрүдәләр иде. Күп кешеләр кыз бирә, углын өйләндерә, туй була, никахлар укыла иде. Менә шул туйлар, кунаклар белән бер чорда Гөлбануның да туе булырга карар бирелеп, икенде алдыннан байтак халык туйны каршы алырга җыелган иде. Җилнең катылыгына, буранның шәплегенә карамыйча, Нурый картның ишек алдын, капка төбен халык сырган иде. «Гөлбану, ахрысы, касмак ашагандыр... туенда буран булды» диешеп, һәммәсе дә кодаларның килә торган ягына күз яганнар[2] иде.

Күп үтмәде: «Туй килә... туй килә...» дип, бик каты балалар кычкырыша-шаулый башлады. Авылның очыннан күмәк чаналар килгәне күренә һәм кыңгырау тавышы да ишетелмәктә иде. Халык ике якка тезелде. Дүрт чана белән туй һәйәте килеп, Нурый картның йортына керде.

Иң алдагы өлкән чанага аллы-артлы ике ат җигелгән, кыңгырау таккан, кучер утырган иде. Монда кияүнең атасы белән анасы, ягъни өлкән кодалар иде. Иң артта «аш чанасы» булып, анда күчкән-тулган аш, бер сарык һәм төенчекләр булып, фәкать бер малай гына утырган иде.

Уртадагы ике чанада кияүнең бер апасы белән җизнәсе, агасы белән җиңгәсе иде. Халык боларны бик шау-шу белән каршы алып өйгә керттеләр. Кодалар ирләр өенә, кодагыйлар хатыннар өенә кереп урнашты. Кияү шул туй һәйәте белән килсә дә, гадәт буенча ул Нурый картның өенә төшмәгән, бәлки өндәүгә баручылардан Кәмалинең өендә иде. Ул, яхшы чанага бер ат җигеп, фәкать бер кияү егете белән генә утырган иде.

Халык хәзердән үк кодаларны һәм кияүне тәнкыйть итә башладылар. Кодаларның прастуйлыкларыннан көлделәр. Чөнки алар бик ярлы урыннарда да кодаларны тәкәллефле күреп өйрәнгәннәрдер. Кияү балакай Закир әфәнде хакында исә һәммә сүз һөҗү[3] вә көлкедән гыйбарәт иде: кайсылары «башы күккә тиярлек», ди.

---

[1] Могътәбәран – ихтирам ителә торган кешеләр.
[2] Күз яганнар – күз текәгәннәр, караганнар.
[3] Һөҗү – мәсхәрәләү.

Икенче берәүләре «буе манара кебек», ди. Икенчеләре «чуаш күз», ди. «Шадра... кара... битен таракан ашаган... борчакка егылган... кашын мәче ялап бетергән...» кебек сүзләр халык арасында сөйләнә иде. Һичкем мактамады.

Бар да яманлап, Гөлбануны кызгандылар.

«Авылда бер кыз иде, әрәм иттеләр», диештеләр.

* * *

Кайсы кешеләрдә туйдан ун-унбиш көн элек кода белән кодагый килеп никах укытылса да, Нурый карт, кабат-кабат мәшәкатьләнәсе килмәгәнгә, никахны туй көнендә генә булдырырга шарт кылган иде. Туй килеп, 2–3 сәгать үткәннән соң, дәгъват буенча, мулла, мөәззин, күрше-күлән вә могътәбәран һәммәсе никах мәҗлесенә җыелды... Кеше бик күп иде. Чит авылдан килгән кунаклар һәм кодалар да бар иде. Өйнең сәке һәм сандыклары алынып, идәнгә хәзерләнгән мәҗлескә халык, аякларын бөкләп, түгәрәкләнеп утырганнар иде. Иң түрдә Фәрит хәзрәт, Салях мулла, болар чалма-чапаннан булып, белмим никтер, йөзләре бик шат иде. Аларның ике ягында Нурый картның кодалары булып, башкалар да дәрәҗәсенә күрә урын алганнар иде. Тыгыз һәм тарлык иде. Кеше килүе тукталды.

Нурый карт «кирәкле кеше калмасын» дип, халыкка тагы бер кәррә күз йөртеп чыкты да, Фәрит муллага карап: «Хәзрәт, киләсе кеше бетте... укысагыз да ярар инде»,– диде. Хәзрәт дәхи ачылды, күтәренке тавыш белән: «Алайса укырбыз... ике кеше чыгып кыздан ризалык сорасыннар»,– диде, үзе елмайды. Нурый картның ишарәсе белән ике мут кына кеше чыгып киттеләр. Болар икенче өйдәге Гөлбануга барып ризалык сораячаклар, имеш. Хәзрәт тә, Нурый да, халык та боларның нишләп керәчәген, сорамый кереп, «сорадык... риза», диячәкләрен beләләр иде. Чөнки гомер буена шулай алдашканнар.

Теге ике кеше чыктылар да, берсе ишек төбендә торып, берсе, хәляэга[1] барып, берничә минут үткәрделәр. Тыштан керә башлагач, берсе иптәшенә: «Безгә гөнаһ булмасмы?» – диде. Икенчесе, бөтенләй юкка санап: «Ни булсын, ул бит бөтен илдә шулай», – диде дә, кереп киттеләр. Кыздан сорау түгел, өенә дә, янына да кермәделәр.

---

[1] Хәляэга – буш урынга.

Алар керүгә хәзрәт: «Нихәл, ризамы?» – диде.

«Риза, хәзрәт, риза»,– диделәр. Мулла дәхи азрак көлде. Ике ирнең шәһадәте белән ризалык сабит[1] булганнан соң, Фәрит мулла Зариф, картка карап:

– Кияүнең вәкиле кем? Сезме?– диде.

– Әйе, без булабыз.

– Ярый алайса,– диде дә, мулла әфәнде Нурыйга карап:

– Кызың Гөлбануны... сум мәһәр могаҗҗәл[2]... сум мәһәр мөәҗҗәл[3] бәрабәренә Зариф угылы Закирга хөсне[4] ризаң белән бирдеңме?

Нурый йомшаграк тавыш белән:

– Бирдем.

Мулла әфәнде Зарифка карап:

– Гөлбану бинте Нурулланы шулкадәр мәһәр бәрабәренә кабул кылып алдыңмы?

– Алдым.

Сөаль вә җаваплар өч кәррә тәкрар ителде. Бисмиллаһ, хәмед[5] белән никах хөтбәсе укып, дога кылынды. Муллаларга өчәр сум, мөәззингә бер сум сәдака җыелды. Дәфтәргә гакыйд,[6] никах шәһадәт[7] язылып, ике шаһитның берсе сәнәк тамга, икенчесе көрәк тамга салды. Бу аларның имзасы урынына каим[8] булып, язу белмәгәнгә шуларны салганнар иде. Эш тәмам булды. Халык арасында «Алла бәхет бирсен... мәхәббәтле булсыннар» догасы әйтелмәктә иде. Кечек бер табак белән шикәр, бал вә суның тәркибеннән[9] ясалган ширбәт китерделәр. Һәркем чынаякка салып өч кәррә йотты. Тәбәррекән[10] битенә, күзенә, кашына сөртте.

Ашлар чыгарыла башлады. Иң әүвәл кодалар тарафыннан китерелгән-күчкән ашларны – ләвеш, билдәмә вә казылыкларны бусы фәләннеке, бусы фәләннеке дип, атап дога кылганнан соң, кабат кайтардылар.

---

[1] Сабит – шиксез, ачык.
[2] Могаҗҗәл – ашыктырылган.
[3] Мөәҗҗәл – кичектерелгән.
[4] Хөсне – күркәм, яхшы.
[5] Хәмед – мактау, шөкер итү.
[6] Гакыйд – сүз беркетү, договор.
[7] Шәһадәт – таныклык.
[8] Каим – терәк.
[9] Тәркиб – терәк.
[10] Тәбәррекән – кадерле дип санап.

Соңра Нурый картлар тарафыннан хәзерләнгән ашларны чыгарып, ит, шулпа, бәлеш белән халыкның корсагын туйдырып, никах мәҗлесен тәмам иттеләр. Гөлбануны Закирга бик мөкәммәл рәвештә багладылар. Шәһадәт биреп кайд иттеләр[1]. Мәхкәмәи вөҗдан[2] бу урында бик кабих җинаять таба. Хокукы бәшәр вә ихтияры бәшәргә[3] бу дәрәҗәдә хилаф[4] бер эшне имам әфәнденең белә торып та, дәвамән иҗраэ кылуын[5], шәһадәтнең ялганлыгы, кызның ризасызлыгы, ап-ачык мәгълүм була торып та, вәрәсәтел әнбиядәнмен[6] дәгъва иткән затның, күз йомып, дәфтәргә кайд итүене бик фахиш гамәлдән саный... Каты һәм ачы газап тиеш күрәдер.

Ләкин имам әфәнде үзе дә халкы кебек сукыр булганга, аның да вөҗданын май каплаганга, бу фахиш җинаятьтән тартынмады. Һәр ел берничә дистәсен эшли... Үз теле белән даимә харамга бисмиллаһи хәмед көфер дип сөйләсә дә, бу урында ул сүзгә караганда үзенә көфер төшкәнне сизми, игътибар кылмый... чирканмый иде.

V

Никах укыган чакта Закир кияү, бу өнемме, төшемме дип шатланып, тизрәк кыз янына керергә ашыгып, Кәмали өендә утыра иде. Никах укылып бетеп, гакде никах вә шәһадәт язылуга тиз үк килеп Закирдан сөенче алдылар. Ул арада атлар да килгән иде. Чаптырып алып, Нурый картның йортына китерделәр. Халык дәхи дә байтак җыелган иде.

Кышның салкын чагы исә дә, гадәт буенча, зөфаф өчен урын келәттә хәзерләнгән иде. Бу асылда ашлык келәте булып, аның бер ягын тәмам бушатып, тазартып, шунда чаршаулар корылган иде. Бер сәке, бер өстәл һәм берничә урындыклар куелып, сәке өстендә кыз белән кияү өчең ятаклык урын салынган иде. Гөлбануны киендереп, ясандырып никахтан соң шул келәткә китерделәр. Ул үзенең нишләгәнен, кайдалыгын да белми иде. Һушсыз кебек иде. Елап башы да каткан иде. Үзе сөйли дә, бер эшне рәтләп башкара да алмый иде. Тавышы калтырый иде. Аны идарә вә кияүне каршы алу өчен янында берничә җиңгә тора иде.

---

[1] Кайдиттеләр – беркеттеләр, теркәделәр.
[2] Мәхкәмәи вөҗдан – вөҗдан хөкеме.
[3] Хокукы бәшәр вә ихтияры бәшәргә – кеше хокукы һәм кешенең ихтыярына.
[4] Хилаф – ярамаган.
[5] Иҗраэ кылуын – эшкә ашыруын.
[6] Вәсәрәтел әнбиядәнмен – пәйгамбәрләр нәселеннәнмен.

Бик каты өч кәррә мылтык атылуы кияүнең капкадан керүеннән хәбәр биреп, ул арада чаж-чож килгән чана тавышы зөфаф өчен хәзерләнгән шул келәт алдына кияүнең килеп җитүен белдерде. Ах, хәзер Гөлбану мең бәла белән генә егылып китүдән үзен саклый алды. Йөрәге ярылырга җитешә, суга... Үзе калтырый, каушый, әллә нишли иде. Кияү ишеккә килде. Ишек бикле иде. Аны ике малай, бикләп тотып, кияүдән «ишек бавы» – акча сорадылар. Унар тиен бирде дә, ишек ачылып кияү келәткә керде. Аның белән бергә күп ирләр дә кергән иде. Кайсы идәнгә, кайсы югарыга утырып дога кылдылар да, мәхәббәт теләп ул кешеләр чыгып киттеләр.

Келәттә ялгыз кияү дә кыз вә берничә җиңгә калды. Гөлбану әле һаман күрешмәгән иде. Аны бер җиңгә алып чыкты, күрештерде. Бичара Гөлбану ни күрсен: матур йөзле, сөйкемле Зыяга барырга дип өметләнеп йөргән кешегә бик озын буйлы, кара шадра йөзле, анда бер, монда бер мыеклы, өстенә җилән киеп билбау бәйләгән, аягына солдат итеге кигән князе Закирны күреп, әүвәлгедән дә яман каушау, калтырау, тирләү белән күреште. Закир аның маңлаеннан суырып үбеп, соңра ике рәкәгать намаз укыды.

Чәй бөтенләй тәмле ашамлыклар белән хәзерләнгән иде. Эчәргә утырдылар. Закир белән Гөлбану янәшә булып, бер җиңгә чәй ясады. Закир берне эчте дә каплады. Никадәрле кыстасалар да, кабат эчмәде. Коймакка һәм өч җиңгәгә Закир 20 шәр тиенлек тәңкә салды да, чәйне алдылар. Җиңгәләр чыгып, ялгыз Закир белән Гөлбану калды.

Келәт ягылмаганга, әлбәттә, бик салкын иде. Шулай да чишенми яту мөмкин булмаганга, Гөлбану Закирны чишендерә башлады. Юри табылмасын, чишә алмый азаплансын өчен Закирның билбавы бик чобалтып, очлары яшереп бәйләнгән иде. Гөлбануга аны чишү бик читен булды.

Һәр икесе күлмәккә кадәрле чишенеп беткәннәр иде. Закир үзенең каты һәм озын кулы белән Гөлбануны биленнән кочаклап алып, кечек авызы белән иреннәреннән суырып үбеп яткырды. Яттылар...

Закир фәүкыльгадә мәмнүн[1] иде. Хатын табудан гаҗиз булган озын буйлы вә кара шадра Закирга Гөлбануның мамык кебек йомшак вә саф тәне, кайнар кочагы, кызыл ирене белән кечек авызы

---

[1] Фәүкыльгадә мәмнүн– гадәттән тыш канәгать, шат.

Закир төшендә дә күрмәгән җәмал вә нураниясе[1] бу салкын келәттәге сәгатьләрне «оҗмах хәяте» ясамыш иде.

Закирга шулай хис кылынды. Ләкин Гөлбануга бөтенләй башкача тәэсир итмеш иде. Халык сүзе белән үк күңелендә мәнфур[2] урын алган Закир үзенең колга кебек озын буе, кап-кара шадра, кашсыз вә чобар йөзе белән күренеп, агач кебек куллары белән кысып, сөйкемсез иреннәре белән үбә башлагач, Гөлбануның күңелендәге нәфрәт вә кәраһәт[3] бигрәк артты. Иң әүвәлге ятуда ук ул чирканды, җаны да, тәне дә тартылды.

Бөтен вөҗүде бизенә, әллә ни якынаясы килми иде. Авыр иде. Бусы бер бәла булып, эчендәгесен яшерергә, яраткан рәвешчә мөгамәлә кылырга мәҗбүр булуы аны бигрәк изде. Шулай булса да шул мөгамәләне мәҗбүр күрде. Ул эчендәге нәфрәтне яшереп, көләч йөз бирергә, кулын кысарга көчләнә, үбәргә тырыша иде. Ләкин һичбере теләп түгел иде. Закирның кулын кысу аңарга боз тоткан кебек салкын тоела иде. Көлүе дә җан белән түгел, бәлки мәҗбүрияттән вә җәгъли[4] генә иде. Ул көлгән иреннәрнең астында «мин синнән нәфрәтләнәм» дигән бер мәгънә бар иде. Үбешүләр исә әллә нинди тәэсир итеп, бөтен тәнне чиркандыра, теге Зыя белән булган үбешүләргә бөтенләй нәкыйз[5] иде. Әгәр мөмкин булса, үбешкәнән соң төкереп ташлар иде.

Менә шул зөфаф булды. Кич үтте.

* * *

Кичәге яшь кыз бүген таңга хатын булып керде. Аның «кызлык чаклары» дәхи бер кәррә килмәс шарты белән видаг итеп[6], бу кич аларга хәтимә[7] бирде. Ул хәзер ирекле кыз түгел, бәлки кеше хатыны иде. Аңарга бер хәят видаг итеп, икенче бер хәят башланган иде.

Бу кичә аның гомерен бөтенләй аерым ике кыйсемгә бүлмеш иде. Аның кызлык хәяте үтеп, хатынлык хәяте килмеш иде. Гөлбануның шул яңа хәятне тәбрик өчен диикме, әллә юкса үткән

---

[1] Җәмал вә нураниясе – гүзәллеге һәм күркәмлеге.
[2] Мәнфур – җирәнеч.
[3] Кәраһәт – чиркану.
[4] Җәгъли – ясалма.
[5] Нәкыйз – капма-каршы.
[6] Видаг итеп – хушлашып, саубуллашып.
[7] Хәтимә – тәмам итү, нокта.

хәят өчен тәгъзия[1] өчен диикме? Кайсы өчендер инде... таң атуга күрше-тирә вә ага-эне малайлары зөфаф булган келәтнең тирәсен сырып алып, «җизни пәке бир» дип, ишек дөбердәтә башлаганнар иде. Закир үзенең бу кайнишләренең сораячагын белгәнгә, 4–5 тиенлектән байтак пәке алып килгән иде. Беткәнче шуларны өләшеп, җитмәгәннәренә конфет, прәннек вә акча бирделәр. Алар бетте. Өйләгә таба тагы шул күрше-тирә, ага-эненең кечкенә кызлары килеп, нечкә тавышлары белән: «Җизни, бүләк бир», – дип кечкенә куллары белән шык... шык келәт ишеген сугарга тотындылар.

Боларга дистәсе 10 тиенлек көзгеләр, сабыннар, кершән һәм иннекләр алып килгән иде. Шуларны тараткач, алар да китте. Бу бүләкләрнең бераз яхшырак вә кыйммәтлерәкләре дә булып, туйдан соң Гөлбану иптәшләрен җыеп, «бүләк мәҗлесе» ясау мәҗбүри булганга, аларны алып калганнар иде.

* * *

Туй гомумән караганда яхшы үтте. Авылда кунак чоры булганга, кода-кодагыйлар иртә таңнан алып төнге сәгать 12 ләргәчә ашта да чәйдә генә йөреп үткәрделәр. Бәгъзе бер туйлардагы кебек үпкәләшүләр, бозылышып кайтып китүләр берсе дә булмады. Рәсми сурәттә эчү-исерү дә булмады. Фәкать Гөлбануның агалары гына яшь кодаларны аулаклап, ак чәй белән кунак иткәләделәр.

Дүрт көн торып, бишенче көнне өйләдән соң туй китте. Гадәт мөҗибенчә, Закир да үзенең кияү егете белән бер атка җиккән чанасына утырып иң арттан шылды. Уңайсызланырлык эшләр булмады. Фәкать кияү җиккән ат белән Зариф картның төпкә җиккән бер атының ялын һәм койрыгын, бөтенләй кырып, яп-ялангач калдырулары гына бераз кәефләрен бозды. Атлар бөтенләй ялсыз һәм койрыксыз калганнар иде. Моның кемнән икәнен ачык белә алмадылар. Исбат ителмәде. Моны эшләүче Зыя иде. Ул үзе алырга йөргән кызны алган өчен, үчегеп, шулай кылган иде.

## VI

Туй үткәнгә дүрт көн булган иде. Атнакич кияүләрнең килүе гадәт булганга, Гөлбану, урам як тәрәзәсеннән карап, Закирның килүен көтә иде. Ул бүген, әлбәттә, киләчәк иде. Башка кызларга кияүләренең килүе бер сәгадәт булып, дәрт вә иштиһа[2] белән

---

[1] Тәгъзия – юату, кайгырмаска өндәү.

[2] Иштиһа – теләк.

көтсәләр дә, Гөлбану бик күңелсез вә кәефсез көтә, авыр, басынкы һәм мәгълүб тора иде. Өстендә бер йөк бар төсле иде. Аның йөзе бик аяныч булып, «мин теләмәгән эшкә көчләндем» дигән мәгънә чыккан иде. Зыяга барам дип, шатланып йөргән заманда аның башына килгән бу тәмсез инкыйлаб[1] хакында хәйран булып... аптырап, ни дияргә белми утыра иде. Ул уйлана иде... яшьтән бирле тик яткан зиһене хәзер тәфәккер[2] хезмәтенә башлаган иде. Аның уйлары гомумән тәмсез... көенечле... изтыйраблы[3] иде.

Сәгать үткән саен бу уңайсызлык арта бара. Закирның тиздән килеп сөя, үбә, кочаклый башлавы, күз алдына килеп, аны изә иде. Әгәр ихтыярында булса, ул көтмәс, илтифат та итмәс иде дә, ләкин кияүгә чыгып, капка ачып каршы алмау зур үпкәгә сәбәп булуы мәгълүм булганга, мәҗбүри көтә иде. Ерактан Закирның килгәне күренде. Закирның ерактан күренүе Гөлбануның нәфрәт хисен кузгатып, аның авызыннан ачу вә нәфрәт белән шул сүз чыкты:

– Хәерсез!

Тиз генә, сикереп торып, көзгегә карады. Күз яшьләре аның кершәнен азрак бозган иде, төзәтте дә, калфагын ипләп, каршы чыкты. Капка ачып кертеп, тагы шул зөфаф булган келәткә керделәр. Закир ике кич кунганннан соң шимбә көн кайтып китте.

Шул вакыттан башлап җәй уртасынача Закир, шул рәвешле һәр атнакич[4] килеп, икене куна да, шимбә көн кайтып китә иде. Бу моттарид[5] вә даими булган бер йөреш иде. Бу кияүләп йөргән чакларда аңарга фәүкыльгадә хөрмәт ителә иде. Ат җигү, тугару түгел, киендерү-чишендерү дә Гөлбану өстендә иде. Аны ифрат дәрәҗәдә иркә һәм кадерле тоталар, аш-су, сый-хөрмәттән Фәтхия әбинең дөньяда белгән ни нәрсәсе бар исә, һәммәсе Закирга хәзерләнә иде. Чөнки шулай итмәгәндә, кияүнең, үпкәләп, икенче атнада килми калуы, халык каршында оятка төшерүе ихтимал иде.

Берничә айларгача Закир шул келәттән чыкмады. Һичкемгә кунакка, ашка-чәйгә йөрмәде. Туры шул келәткә килеп керә, җигелгән атка чыгып утыра гына иде.

Фәтхия әби белән Нурый картлар да аңарга өч айдан соң гына күрештеләр. Язга таба инде һаман келәттә бикләнүне ташлап,

---

[1] Инкыйлаб – асты өскә килү, үзгәрү.
[2] Тәфәккер – фикерләү, уйлау.
[3] Изтыйраблы – интегүле.
[4] Атнакич – пәнҗешәмбе.
[5] Моттарид – эзлекле, тәртипле.

чыга, йөри башлады. Күрше-тирәгә Гөлбану белән парлап та, бабасы Нурый карт белән дә кунакка баргалый торган булды.

VII

Шул елның 3 июль көне иде.

Табигатьнең дүрт фасыл арасында артыграк дикъкать вә мәһарәт сарыф итеп, вөҗүдкә китергәне матур җәйнең дә иң күңелле вә иң хозур бер чагы иде. Таулар, болыннар һәм яшел үлән белән капланып, аллы-гөлле, кызыллы-сарылы чәчәкләр белән зиннәтләнгән иде. Ашлык басулары, бөтенләй күгелҗем игеннәр белән капланып, бик моң гына дулкынланып торалар иде. Җәйнең бу җәмалына гашыйк булып, ерак мәмләкәтләрдән килгән сандугачларның сайрашуы адәмнәргә җан вә дәрт бирә, рухларын голүләндерә[1] иде. Һәрнәрсәгә хәят биргән кояшның яктылыгы һәм эсселеге бу көннәрдә гүзәл рәвешчә тәэсир итеп, кяинатта гомумән күңелле бер хәят башланган иде.

Озын кыш буена салкын вә бураннан йөдәгән адәмнәр җәйнең бу нигъмәтләренә рәхәтләнеп, акрын гына дулкынланган игеннәргә карап шатланалар иде.

Һәрнәрсәдә, һәр җирдә хәят, дәрт вә рух әсәре сизелә, кешеләр башка вакытта булмаган хозур, рәхәт, шатлык хис кылалар иде. Табигый булган бу шатлыклар, бу хозурлар өстенә авыл халкы үзләре тарафыннан да шатлык вә рәхәтләр кушып, бик күңелле бәйрәм – кыз озату, килен төшерү бәйрәме итәләр иде. Каты кышның дәһшәтеннән калтырап, яз чыккач сабан, сука, парна[2], утау хезмәтләре белән йончып беткән егетләр, ирләр, балалар, киндер сугып, тегү тегеп өйдә үткәрүдән ялыккан кызлар һәммәсе эшләрен ташлаганнар, бер атнадан бирле шулай бәйрәм ясыйлар иде. Инде бер-ике көннән бу бәйрәм бетеп, һәммәсе дә бил сызганып печән, урак хезмәтләренә керешүләре мәгълүм булганга, бу бәйрәм аларга елында бер генә килгәнгә, бик тансык, бик ганимәт иде. Авыл арасында байтак ук кунаклар, мәҗлесләр дә бар иде. Халык гомумән эшсез иде.

Кемнең кызы китсә, кемгә килен төшсә, шунда җиткән егетләр, җиткән кыз һәм балалар һичберсе калмыйча җыелалар иде.

---

[1] Голүләндерә – күтәрә, дәртләндерә.

[2] Парна – каты басу.

Бу өченче июль көнендә Гөлбану китәчәк булганга, нәүбәт Нурый картның йортына җыелырга җиткән иде.

Өйләгә таба кызыллы-сарылы күлмәкләр, матур шәлләр дә калфаклар кигән авылның кара кашлы сөйкемле туташлары белән Нурыйның йорт һәм өй эче зиннәтләнә башлады.

Якынрак кызлар Гөлбану тирәсендә, башкалар йорт алдында торып, шәл астыннан гына егетләрне күзлиләр иде. Егетләр дә бик күп булып, алар да матур гына киенгән иде. Берничә арбага Гөлбану һәм иптәш кызлары вә егетләр төялеп, гармуннар уйнап, ун чакрым кадәрле яланны әйләнеп кerделәр. Бусы Гөлбануны үзенең үскән сахраларына видаг иттерү кабиленнән иде. Бүген Гөлбану үзенең кызлыгына тәмама хәтимә биреп, туган иленнән аерылачак булганга, бик бетеренгән иде. Һаман еглый, үкси иде. Еглау гадәте озатылган һәр кызда да бар... ләкин бигрәк мәнфүр күргәнгә, Гөлбануның еглавы дәхи башка, дәхи моң иде.

Ул бүген берни карый, башкара алмый иде. Өстенә дә кеше ярдәме белән киенә иде. Закир һәм Гөлбануның агалары исә бик ашыгып-ашыгып придан булып барачак нәрсәләрне сандыкка тутыралар, киезгә урап бәйлиләр, ни дә булса хәзерләнәләр иде. Придан күп иде: сәгать, көзге, 12 сумлык самовар, җиздән тас-комган, дюжинасы белән чынаяк вә чәй әсбабы, кашык, тарелка, һәммәсе киҗе вә мамыктан Гөлбану кулы белән сугылган әгъла 12 ашъяулык, 30 сөлге, 50 салфет, бик өлкән һәм бик гүзәл чүпләнгән чаршау, 12–13 күлмәк, чолгау, киез, өйдә сугылган яңа мода палас, ике зур сандык... илх[1] кебек нәрсәләрдән гыйбарәт булып, болар зур ике сандыкка тутырыла, анда салу мөмкин булмаганны, яхшы итеп урап, арбага шул көенә салына иде. Бу приданнар өчен махсус ике арба бара, аларга да Гөлбануның агаларының угыллары утырачак иде. Картлар өйләдән чыкты.

Аш-чәй үтте. Дога кылынды да, еглаганын яшерергә теләгән кебек, Гөлбануның битен бөтенләй үк җилән белән каплап алып чыктылар. Атлар һәммәсе дә җигелгән, беткән иде. Гөлбануны кияүнең җигеп килгән өлкән көймәсенә[2] утырттылар. Көймә яхшы иде. Аңарга өч ат җигелгән, кияүнең алып килгән кучеры утырган иде. Ул кучерга Гөлбану тарафыннан биленә әгъла, сөлге бәйләнеп, аның кып-кызыл очлары салындырылган иде.

---

[1] Илх – һәм башкалар.
[2] Көймә – ябулы арба (экипаж) яки бөркәүле арба (кибитка).

Гөлбану, Закир, кучер һәм арттагы арчилар[1] бар да утырганнан соң, авылны чыкканчы атларны тотып озату өчен утырган үткен татар егете күтәренке вә мәһабәт тавышы белән: «Әй...!» диде. Дилбегәләрне какты. Атлар кузгалып капкадан чыктылар. Иң алдан көймә, аның артыннан өч арчи: икесе Гөлбануның агалары, берсе әҗнәби[2] булып, һәммәсе икешәр ат җигеп хатыннары белән утырганнар иде. Иң артта приданнар белән тулган ике сандык арбасы иде.

Капкадан чыгуга атлар бик гайрәт белән кузгалып, аллы-артлы алты арба тузан туздырып бик кызу чаптырып киттеләр. Өй һәм йорт эче тулган, бөтен урамны каплаган халык диңгезе селкенеп һәр якка «кыз китә... кыз китә... кыз...» дигән тавышлар чыга... шау-шу... тавыш-кычкырыш... көлү... әллә ни эшләүләр башланды. Малайлар кая басканны белми, әллә нинди шатлык килгән кебек сикерә... чаба... дулый... «ау... ай... һай-һай» кычкыралар, һәркем үз юлын алып, халык тарала... юнәлә башлады.

Гөлбану китте... яңа дөньяга керә.

VIII

Гөлбану көймәгә утырып, Нурый картның йортыннан атлар кузгалган заманда Курайлы авылының халкы, Насрый мөәззиннең кызын озатып, килен төшерү өчен Зариф картның өенә, йорт тирәсенә җыела башлаганнар иде. Авылларның кыз озату, килен төшерү бәйрәмнәре бер чорда булганга, монда да бәйрәм, монда да шулай эш ташлап азрак ял итү, кунаклашу хөкем сөрә, монда да җыелышлар була иде.

Монда да кунаклар, мәҗлесләр бар, монда да шулай кыз озату, килен төшерүләр дәвам итә иде. Насрый мөәззиннең йортыннан халык дәрьясы агып, Зариф карт йортына килде. Килен төшерүнең әһәмияте кыз озатуга караганда алдарак тотылганга, халык бик күп иде.

Авылда егет, кыз, бала, исемләнгән һичкем калмаган, ирләр, хатыннардан да күп кеше килгән иде. Өй эчләре, йортның өй буйлары шул хатыннарның аллы-кызыллы, сарылы төсле киемнәре белән бик матур рәвештә күренә иде. Егетләр, ирләр исә капка буйларында, урамнарда кара бүрек, итек һәм казакилар киеп,

---

[1] Арчилар – кияүгә чыккан кызны кияү ягына озатып баручылар.
[2] Әҗнәби – чит кеше.

карачкыл бер манзара тәшкил итәләр иде. Һәркем имкяны булган дәрәҗәдә матур вә гүзәл киенгән, ясанган, хосусан кызлар бик тырышып киенгәннәр иде. Фәкать балалар гына садә булып, аларның киенүдә, бизәнүдә кайгы юк, шулай ук егетләр күзләү, кызлар күзләү белән дә эшләре юк иде. Алар һаман уйныйлар, сикерәләр, кычкыралар гына иде. Үзара уйнап арганнан соң шунда җыелып бөтен өй, йорт, азбар һәм урамны каплаган халык белән уйный башлыйлар иде.

Авылның очыннан бер арба күренсә яки бөтенләй юкка да «килен килә!.. килен!» дип кычкырып йорт тирәсендә җыелган халыкны кузгаталар... алдыйлар иде. Әгәр дә халык боларга алданып кузгалса, урамга чыкса, алдый алганнары өчен дәхи бер дөнья тутырып шатланып кычкырышалар... шаулыйлар иде, көләләр иде. Берничә мәртәбә алданганнан соң дәхи бер мәртәбә төрле яктан, ләкин бик чынга охшашлы «килен килә!.. килен килә!..» дигән тавыш күтәрелә иде. Бу тавышның кәйфияте[1] дөреслегенә шәһадәт биргәнгә, халык ихтыярсыз ышанып, өй һәм йорт вә азбарга тулган адәмнәр бөтенесе шау-шу, кычкыру белән урамга чыгып, килен киләчәк якка карадылар. Вакыйган, киләдер шул. Бөтен күзләр атларга юнәлде.

Ерак җирдән бик кызу каулап килгәнгә, атлар бик ялыккан иде. Шулай да сер бирмәделәр, бик шәп килеп җиттеләр. Бөтен урамны тыгызлап каплаган халык диңгезе Муса таягы белән суккан чактагы кебек ике якка ярылды[5*]. Уртадан атлар чаптырып керделәр.

Көймәне азбар ягыннан уратып китереп болдырга туктатты. Гөлбануны Закир, көймәдән төшереп, култыклап өйгә кертте. Ул моңарчы күрмәгән, белмәгән кешеләр вә ят йортлар эченә аяк басты. Гөлбану кереп китүгә егетләр төрле яктан: «сөзмә чыгарыгыз... сөзмә», дип кычкырып та бетмәделәр, өлкән ике табак сөзмә чыгып килде. Халыкның җанлы вакыты менә хәзер башланды. Елгыр егетләр, сөзмәнең чыгуын саклап торып, кулларына бик күп сөзмә алдылар да, халыкны куып-куып буярга, агартырга тотындылар. Монда фәкать кызлар имин иде. Башкалар һәрбере азмы-күпме сөзмә эләктереп, бик кызулап бер-берсен буяшырга керештеләр. Халык йөгерә... куа... кача... кем туры килсә, шуңа буйый, битне, башны, киемнәрен сөзмә агартып бетерә... иде.

---

[1] Кәйфияте –рәвеше.

Һәркемдә сөзмә... Һәркем буйый., буяла... кычкырыш... шау-шу... «тот»... «тот» тавышлары чыга... качалар... егылалар... кайбер балалар егылып җылый башлыйлар... әллә ниләр була иде.

Егетләр, ирләр һәм балалардан буялмаган кеше калмады. Күбесе, катык мичкәсенә тыгып алган кебек баштанаяк сөзмәгә буялып, ап-ак булган иде. Байтак заман шул рәвешле шау-шу... кычкырышу... йөгерү... куу... качу... чабу тоту... егылу... еглау белән ду китереп, җенләнеп буяшканнан соң, икенче берәүнең килене төшәчәк иде, шунда киттеләр.

* * *

Гадәт буенча, Закир Гөлбануны култыклап керткәннән соң, килен күрү өчен өйгә шыгрым тулган кызлар, җиңгәләрдән бер кыйсме белән Гөлбану чәй эчте. Чәйдән соң гел кызлардан гына гыйбарәт бөек бер «һәйәт»[1] Гөлбануны су юлы күрсәтергә алып бардылар. Ул, шул һәйәт белән бергә барып, көянтә белән су китерде. Судан кайткач, киемнәрен салып, беләген сызганып, алъяпкыч ябып, «килен камыры» басты. Аннан соң аш пешерү, чәй кую, сыер саву, мунча ягу кебек эшләр аңарга берәм-берәм тезелде. Ул шул көнне үк күптән шул йортта торган бер хатын кебек хезмәткә тотынды. Чөнки киленгә шулай тиеш иде.

Иртә белән арчиларга беленне дә үзе пешерде. Хасил: арбадан төшеп чәй эчү белән бөтен гаилә хезмәтенә җигелеп китте. Хатыннарга гаид[2] авыл җирендә ни эшләр бар, һәммәсе аңарга тагылды.

Чөнки яшь киленгә шулай тиеш иде.

IX

Киленлек Гөлбануның тормышына һәр яктан бик зур үзгәрүләр бирде. Ул чынлап ук яңа тормышка, яңа дөньяга кергән иде. Яшь килен булганга, сыер саву, аш-чәй хәзерләү, суга бару, мунча һәм өйләргә ягу вә кер юу кебек йорт эшләре аңарга гаид булган кебек, урак, печән, утау һәм ашлык сугу, әвенгә чыгу кебек иген эшләренең дә һичбереннән котылырга имкян юк иде. Бу эшләрнең байтагын ул кыз чагында да эшли иде. Ләкин андагы эшләү белән хәзергесе арасында зур аерма бардыр: ул анда иркә һәм хуҗа иде. Арзулары[3] табыла иде. Ә монда исә үзе икенчеләрне

---

[1] Һәйәт – делегация.
[2] Гаид – караган, тиешле.
[3] Арзу – теләк, омтылыш.

иркәләргә мәҗбүр. Ул анда ялан, иген эшен эшләгән чагында йорт эшенә һич катышмый иде. Иртә торуга, кич кайтуга аш-чәй хәзер була иде. Ә монда иртә белән эшкә киткәнче, сыер савып чәй хәзерләргә, кич кайткач, дәхи шулай эшләргә мәҗбүр иде.

Кыш көне әвенгә чыгу, 60–70 бәрәнне имезү кебекләр дә аңарга киленлекнең арттырган хезмәтләреннән иде. Әүвәлгечә киенү-ясанулар кайда?!. Ул хәзер күлмәк юарга да чак кына вакыт таба иде.

Өлкән йорт, җәмәгать вә мал күп булып, шулар аның тынын бетерә иде. Кыз вакыттагы уен-көлкеләр, тауга чыгып, кунарга җыелып музыка, җыр вә биюләр белән кәеф ачу, тула басу, каз җуулар кебек күңелле эшләр һәммәсе, Гөлбануга видаг итеп, ул аларны күрү түгел, хәзер уйларга да вакыты, имкяны юк иде.

Кыз вакыттагы хозур вә сәгадәттән ни бар, һәммәсе беткән, башкасын ни әйтергә, көләч йөз дә калмаган иде. Җылы вә тәмле сүз дә юк иде. Хәзерге хәле белән кызлык чагын чагыштырып караганда кызлык – хөрлек, киленлек – коллык диярлек иде. Аңарга һичбер илтифат, игътибар юк, яшь килен булгач, ул хокуксыз... Һәркемнән түбән, һәркемгә мәхкүм[1] иде. Һәркем аңарга әмир, хаким була, һәркем аны җиңә һәм җигә иде. Кыз чагындагы наз вә иркәлекләрне ул хәзер төшендә дә күрә алмый иде. Бу йортта аңарга мәлҗәэ[2] булган һичкем юк иде... Аның аяныч хәле һәм күз яше берәүгә дә кыйммәт түгел... берәүнең дә мәрхәмәт хисен уятмый иде. Еглаганын күрсәләр, аңарга бик залимәнә тавыш белән:

– Сидермә күзеңне!.. – дип кенә куялар иде. Ул һәркемне үзенә дошман, үзенә залим дип күрә иде. Наз вә кадердә генә үскән кызга дәфгатән[3] шундый кешеләр эченә төшү, әлбәттә, авыр иде. Ул һәркемнән бизар[4] иде.

Гөлбануга хуҗалык, хакимлек иткән, күбрәк вакыт җанны газаплаган кеше – ире Закир белән кайнанасы Сабира иде. Сабира... бу зәһәрле... гыйфрит һәрвакыт Гөлбануның җәрәхәтенә тоз сибеп кенә тора иде.

Үзе табгандә[5] каты күңелле, таш бәгырьле, тәрбиясез булып, гадәттә кайнаналарга бирелә торган хокук аның табигый булган бу

---

[1] Мәхкүм – буйсынырга тиеш.
[2] Мәлҗәэ – сыену, котылу.
[3] Дәфгатән көтмәгәндә.
[4] Бизар – аптыраучы, интегүче.
[5] Табгандә – табигате белән.

сыйфатларын дәхи куәтләгән иде. «Киленне шулай тоталар аны!» дип, бу Сабира һәрвакыт Гөлбануны тәнкыйть итеп, урынлы-урынсыз ажгырып тора иде. Һичбер урында гафуны да белми иде. Мәрхәмәтнең исеме дә юк иде. Гөлбануның арзуларыннан бернәрсә вөҗүдкә китерелергә уйланса, иң әүвәл бу карчык каршы тора, мәкруһ тавышы белән: «без дә килен булдык, бер дә алай кыланмадык... түздек. Үлмәс әле, түзәр! Җаны учында түгелдер», дип аяк тибеп кычкыра һәм мөманәгать итә[1] иде.

Сабираның Гөлбануга һичвакыт бетми, югалмый торган иң беренче җәрәхәт салуы Нурый картка кунакка бару тугрысында булды. Авыл җирендә яшь киленнәр кайнеш йортына төшеп унбиш көн, өч атна чамасы торгач, аталарына кунакка барып кайталар. Бу бер гадәт, бер ихтыяҗ кебектер.

Табигый, Нурый карт та Гөлбануны озатып, унбиш көн үткәннән соң, кызы белән киявен: «Һич булмаса ике генә кичкә килеп китсеннәр»,– дип кунакка чакырды. Гадәттә бу чакыру рәд кылынмый, кабул итеп барыла иде. Ләкин Сабира карчык бөтен көче белән каршы торды. Авызыннан зәһәрле күбекләрен чәчеп: «Булмас... йөрмәс! Эш вакытында кеше кунакка барамы? Түзәр әле, җаны чыкмас», – дип акыра. Төрле сәбәпләр табып җибәрмәде. Зариф карт җебегән, изелгән бер нәрсә булганга, ул да бер нәрсә кыла алмады. Шулай итеп, кунакка бару айдан артыкка кичте. Бу манигъ[2] Гөлбануны бик изгән, ваткан иде. Ул бөтен эчке өзелүләр белән: «Әй Илаһым! Башымны ашый икән бу убырлы карчык», – диде. Бер аулак табып бик озак еглады.

Бу манигъ аның сәгадәтенә, өмитенә мөһлик[3] бер зарабә[4] кебек булып, аның күңелендә һичвакыт бетми торган җәрәхәт ясады. 17 яшенәчә һичкая чыкмаган, наз вә иркә эчендә анасының канат астында үскән Гөлбану өчен, бердәнбер килеп эләккән киленлек газабыннан бер генә көн котылып, туган иленә бару аңарга бик кыйммәт иде.

17 еллык мәсгуд хыял үткән, бөтен яшьлек хатирәләре сакланган, яшьлек оясы булган мөкатдәс иленә бер-ике генә кичкә булса да кайтасы, йөргән җирләрен, иптәшләрен күрәсе, сөйләшәсе, сер

[1] Мөманәгать итә – каршы тора, аркылы төшә.
[2] Манигъ – киртә, каршылык.
[3] Мөһлик – һәлакәт, үлем.
[4] Зарабә – бәхетсезлек.

сыйганнарына киленлектән зарланып елыйсы, азрак куанасы килә иде. Бу аңарга бик мәсгудиятъ кебек хис кылынган иде. Ләкин муаффәкъ була алмады.

Яшь киленнәрдән күбесе бу уңайсызлыкларга дучар булмакталар исә дә, Гөлбануның үзенә махсус авыр хәлләре дә бар иде: ул ире Закирны һичбер яратмый, бәлки аннан нәфрәт итә. Зыяны сагына иде. Нәфрәтләнгән кеше белән юлдашлык, әлбәттә, мөшкелдер. Сабира карчыкның теге зәһәрлеге, аңарга кушылып, юньсез Закирның да котыруы, йорт эчендә күңел сөйгән, көләч йөз биргән бер генә адәм дә булмавы Гөлбануны изә генә иде. Ул тәмле сөйләшүдән дә мәхрүм иде. Кайгысын сөйләп егларга бер адәмнең табылмавы аңарга бигрәк кыенлык бирә иде. Өстәвенә: килен булып төшкән йорты үзенең үскән җиренә бөтенләй нәкыс булып тәрбиясез, низамсыз, пис, хәсис булуы да аңарга авырлык сала иде.

Боларга Закирның эчкечелеген, Сабираның золымыннан ләззәт алуын кушсак, аның уңайсыз хәлләрен беркадәр күргән булырбыз... Мондый вакытта да мәнфур[1] булган Закирның эчеп, сасып кайтуы Гөлбануга аны мөҗәссәм[2] иблис кебек күрсәтә иде. Шул сасы көенчә үбә, коча башласа, Гөлбану чиркануыннан ни кылырга да белми иде.

Бу уңайсызлыклардан, әлбәттә, Гөлбану бик мөтәәссир[3], фәүкыльгадә мөтәхәссир[4] иде. Тыштан никадәрле белдермәскә тырышса да, эченнән һәр заман егълый... яна... көя иде. Зыяга барырга торганда, хәзрәт сүзенә карап, бер пьянич чуашка бирде дип, атасына да үпкәли, язмышка да сылтый иде. Алладан да күрә иде. Әллә гөнаһ шомлыгымнан микән, дип тә уйлый иде.

Әүвәлге елларны бу зарларны, бу газапларны фәкать үз эчендә йөртсә дә, соңга таба аңарга үзе кеби ышанычлы бер мазлумә дус булып, шуңа гына сөйли башлаган иде. Башкалар алдында җәбер нәфес белән ризалыкны белдерсә дә, яшьләрен тыйса да, бу дусы янына килсә, ихтыярсыз аның күзеннән мөлдер-мөлдер яшьләр тәгәрәп, йөзеннән эз салып китәләр, ул аларны тыймый, еглый иде. Тыярга теләсә дә, эчкә тулган хәсрәт аларны бәреп чыгара иде. Аның киленлек хәяте менә шул рәвешле үтә иде.

---

[1] Мәнфур – җирәнгеч.

[2] Мөҗәссәм – артык зурайтылган.

[3] Мөтәәссир – кайгы-хәсрәткә төшкән.

[4] Мөтәхәссир – хәсрәт чигүче, кайгылы.

X

Өч ел үткән иде.

Закирның атасы Зариф карт вафат булып, аның йорты, җире, мал-туары бөтенләй тузган, таралган иде. Аның ике хатыны, дүрт угылы, үзара тыныша, тату яши алмый аерылып, йорт вә малны дүрткә бүлеп, дүртесе дүрт җиргә бик ярлы вә кечкенә йортлар ясаганнар иде. Авыл эчендәге урыннар кыйммәт булганга, Закир гел шул үзе кебек төп йорттан атасыннан аерылган яшьләр генә утыра торган арткы һәм саңгырау бер урамга читкә генә кечек бер өй салып, шунда тора башлаган иде. Сабираның башка баласы булмаганга, ул да Закир белән булып, Закир, Гөлбану һәм Сабирадан гыйбарәт бер гаилә булган иде.

Боларның тормышлары бик ярлыларча иде. Зариф карт үзе терек заманда ук аяклы малларын бусы Кәримнеке, бусы Салихныкы дип, угыллары арасында бүлеп тәгаен итеп беткәнгә, Закир исә үз инчеләрен[1] солдатка киткәндә сатып беткәнгә, аларга бер колынлы бия белән бер сыердан башка мал тимәгән иде. Өйләр дә башка варисларга бирелеп, Закир фәкать бер келәт алган иде. Ул шул келәтне сатып, Нурый картның да ярдәме аркасында, бер өй ясап керде. Бу өй кечкенә, иске, бүрәнәләре вак булып, тәрәзәләре дә өч кенә вә башы да салам белән ябылган иде. Ишегалды читән белән әйләндерелеп, йорт тирәсендәге читән һәм начар абзардан башка бер нәрсәсе дә юк иде. Утын беткән саен яга барганга, бу читәннәр дә бетеп бара иде. Боларның күрше-тирәсендәге яшьләр дә болар кебек ярлы булсалар да, алар үзләренең эшлеклелеге аркасында йортлар барынча төзек вә бөтен иде. Закир исә үзе игътибарсыз, эшлексез бер нәрсә булганга, аның йорты ташландык йортлар кебек күренә иде. Өенең эче дә тышыннан алда түгел иде. Дүрт стена белән сәке вә пичтән башка бернәрсә дә юк иде. Закир үзе атасыннан соң эчүдә бигрәк тәрәккый иткәнгә, Гөлбануга придан булып килгән нәрсә берсе дә калмаган иде. Кайсысы эчәргә сатылган, кайсысы исереп ватылган, кайсысы ашарга беткәннән сон рәһенгә[2] салынып алынмаган иде. Сәгать, көзге, киез, палас вә ястык кебекләр шунда кереп, теге күп ашъяулыклар, сөлге-салфетлар төп йортта чакта ук чуаш кебек холык истигъмаль кылып[3],

---

[1] Инче – терлек, аяклы мал.

[2] Рәһен – заклад.

[3] Холык истигъмаль кылып – холык кулланып, холыклы булып.

яланга икмәк ташырга капчык ясап бетерелгән иде. Хәзер алар кирәгенә тотылырга да чамалы калган иде.

Өч ел буенча Гөлбануга һичбер яңа кием ясалмаганга, ул үзенең алып килгән киемнәрен бетерә язган, калганнарын да Закирның сатып эчүеннән куркып аталарына илтеп куйган иде.

Һәрнәрсә үзгәргән, алышынган иде. Ярлылык көчле иде. Бай угылы Закир, бай кызы Гөлбану һәм бай хатыны Сабира өчесе дә ярлыларча тормышка мәхкүм иде. Дөрес, бу бөтен авылда диярлек шулай була. Бай кызы бай угылына бара да, егет атасы йортыннан аерылып чыгып, шундый саңгырау урамда ярлы гына яшәргә мәҗбүр була. Ләкин алар бик нык тырышып эшләү аркасында, күбесе баеп та китәләр. Ә Закирныкы исә баю кайда, көннән-көн түбәнгә кала бара иде. Закирның эчүе һәм эшсезлеге тәрикәдән[1] алган малны да бетерә генә бара иде.

Гөлбануның атасы Нурый карт кызын кызганып, мал вә ашлык белән баштарак байтак ярдәм итсә дә, килгән берсен сатып эчә барганга, бусы Гөлбануга газап кына арттырганга: «Юкка әрәм итмәгез!» – дип, Гөлбану аталарын ярдәмнән тыйды. Инде алар да бирми башлаган иде.

Хәзер Гөлбану өчен бигрәк тә ямьсез-тәмсез генә түгел, бәлки изгеч бер хәят башланган иде. Яшь вакытта шундый аянычлыкта яшәүче адәмнәрне күреп, кызганып күзеннән яшь чыга торган тормышка ул хәзер үзе мәхкүм иде. Ире һаман эчә... күз булып, ашлык җитсә, аз-маз азыкларын да сатып аракы алганга күрә, ел тәүлегенә тамак туйдыру өчен бик аптырала иде. Тәмле вә төрле ашау түгел, ялгыз арыш икмәгенә дә туя алмый иде.

Закир вакытында утын хәзерләүне белмәгәнгә, һәр язда Гөлбану үзе тизәк сугып, Фәтхия әбинең назлы, кадерле кызы баштанаяк нәҗескә болгана иде. Аз малның тизәге генә озын кышка өйне җылытырга җитмәгәнгә, суыктан дер-дер калтыранып чыккан көннәр күп була иде. Кием мәсьәләсе дисәк, ул инде бик ачык иде. Гөлбану килен булып төшкәннән бирле һаман атасыннан килгән киемнәрне киеп, хәзер ярлылангач, салкыннан сакланырлык киеме калмаган иде.

Тамак ач, өс ялангач... өй салкын, туңдыра... шул газаплар эчендә Гөлбануның озын кышлары үтә иде. Аңсыз өйләнү аны шул хәлгә салган иде. Әгәр дә уңайсызлык фәкать шулардан

---

[1] Тәрикәдән – мирастан.

гыйбарәт булса, ул, бәлки, түзәр дә иде, ләкин язмыш Гөлбануга ачу иткәндәй итеп, аңарга дәхи күп авырлыклар, газаплар кушкан иде. Бу ярлылык, бу бәхетсезлекләр Сабира карчыкның канын һәм нервыларын бик бозып, хәзер аның бөтен вөҗүде ачу, дошманлык вә әрнү белән генә тулган иде. Башка һичнәрсәдән үч алырга, ачу басарга белмәгәч, Сабира һаман Гөлбануны әрләп-тиргәп кенә тора, шуның белән генә йөрәген, ачуын баса иде. Һәм ачуларын Гөлбанудан ала... аны талап кына юана иде. Бөтен бәхетсезлекне Гөлбанудан күрә иде. Ярлылыкларын да, Закирның эчүен дә, теге йорттан аерылуын да вә башка һәр бәхетсезлекләрне дә Гөлбанудан күрә иде. Аз гына бер нәрсә килешмәсә, хәзер дөнья җимердәй ачу чыгарып, сүздән-сүзгә күчереп, «син генә харап иттең безне»,– дип сүгәргә тотына, Гөлбануның күзләрен дә ачырмый иде. Сабира белән җаваплашу аның ачуын гына, ныграк сүгенүен генә арттырган кебек, бер генә сүз әйтелсә дә, Закирга җылап: хатының сүкте... «курба, карт марҗа... диде», дип, Закирдан да кыйнатачагы мәгълүм булганга, Гөлбану никадәрле сүгелсә, тиргәлсә дә, җавап бирми иде. Ике җәһәттән кыен алганчы дип, сабыр итә иде.

Сабира авызыннан төкерекләрен чәчеп: «Синең явызлыгың аркасында гына без аерылдык... син генә безне бу хәлгә төшердең», – диюенә каршы: үзе көндәше белән, Закир агалары белән тыныша алмый аерылганнарын әйтмәк булып авыз ачса да, тагы туктый, тагы сабыр итә иде.

«Закирым синең кайгыңнан, синең шайтанлыгыңнан түзә алмаганга эчә», – дигән ифтирасына[1] каршы: бөтен нәселләренең эчкечелеген, Сабираның үз иренең дә эчеп үлгәнен әйтеп рәд кылмак булса да, җавапларының файда бирмәвен белгәнгә, ихтыярсыз сөкүт итә[2] иде.

Он, чәй вә шикәр бетә башласа, Гөлбану өчен дәхи караңгы көннәр килә иде. Фәлән бетте... фәлән кирәк, дип әйтү Сабираның җеннәрен котыртып: «Онны тиз бетерәсең... саткансыңдыр, тәмле ашагансыңдыр», дип, яндырып тиргәвен лязем[3] иткәнгә, бер нәрсәнең бетүен хәбәр бирү җан газабын арттыра иде.

Сабираның Гөлбануга карашы менә шул иде. Аныкы тәгаен иде. Ләкин Закирның Гөлбануга карашы тәгаен мөшкел иде. Ул

[1] Ифтирасына – яла ягуына, ялган гаеп тагуына.

[2] Сөкүт итә – эндәшми.

[3] Лязем – тиеш, зарур.

кайвакыт Гөлбануны яраткан да, сөйгән дә төсле күренә иде. Иркәли дә... кадерли дә иде. Хәтта Сабираның күп тиргәвенә каршы «куй инде!» дип мөдафәга[1]дә кылгалый иде. Ләкин бу даими түгел, сирәк була иде. Һәм булуы да булмавыннан зарарлы иде. Чөнки Сабира угылының мондый яхшы мөгамәләсен кызгана... хөседе кайный иде дә, тагын Гөлбануны: «син сихерче... анаң да сихерче... сез Закирны сихерлисез, бозасыз», дип, таларга тотына иде. Шул иркәләүне ул сихер әсәре дип әйтә иде.

Ләкин бу сихерче диюгә сәбәп булган мөгамәләләрне Закир бик сирәк вөҗүдкә китерә иде. Аның күп вакытта йөзе Гөлбануга караңгы, ачулы булып, юк-бар нәрсә өчен дә кыйнап, ватып бара иде. Хосусан ул эчкән чакларында ифрат дәрәҗәдә женләнә, котыра... дөньяны куптара иде. Ул күп эчә... эчкән саен Гөлбануга кыен вә газап өелә генә иде. Анда гаҗәп бер гадәт бар иде: ул шулай эчә, исерә, изгәнче Гөлбануны кыйный иде дә, күп вакыт үтмәенчә ачуы басылып: «кәләш... җанаш... Гөлбанукаем», дип үбә, кочаклый, аркасыннан кага башлый иде. Айнык вакытында да мәнфүр булган Закирның исереп сасыган чагында үбүе, кочаклавы Гөлбану өчен кыйнаудан да яман... кыйнаудан да изгеч иде.

Кайсы яктан караганда да Гөлбану бик авыр, түземсез изгеч тормышка мәхкүм иде. Аның алды-арты, уңы-сулы бар да караңгы, куркыныч, өметсез, көенеч һәм күз яше генә иде. Ул хәзер җан җәһәтеннән дә үзгәргән иде. Эчендә җаны даимә газаплы иде... өзелә... яна... көя... сызлана иде. Аулак тапса, мотлак еглый, Аллага зарыйлык кыла, ялвара, үлем дә сорый иде. Бу аяныч хәле өчен атасына да үпкәли, Алладан, язмыштан да күрә, гөнаһ шомлыгым дип тә уйлый иде. Теге дөньяга баргач, сәгадәт вә интикам[2] өмете аны бераз җуатса да, аңсыздан бер дәһшәт зоһур итеп[3], бу өметенең юанычларын югалта иде. Аның төсе дә бик үзгәргән, йөзе яшь кыз Гөлбануга бер дә охшамаслык хәлгә килгән иде. Бите карачкыл-сарыга әйләнеп, күзләре эчкәрәк баткан, караган саен бер аянычлык хис кылына, «минем еглыйсым килә», дигән бер күренеш сизелә иде. Кызганудан егламый карау читен иде. Үзе дә яшь чагында хәят дәртлелеген югалтып, авыр вә басынкы булып калган иде.

---

[1] Мөдафәга – каршы тору.
[2] Интикам – үч кайтару.
[3] Дәһшәт зоһур итеп – куркыныч күренеп.

190... елның көзге фасылында ул менә шул дәрәҗәгә, шул хәлгә килеп җиткән, киленлек тарихы баштанаяк авырлык, кыйналу, тиргәлү вә күз яше түгү белән тулы иде. Килен булып төшкән көннән башлап шул көнгәчә ул үзендә һичбер төрле сәгадәт вә җуаныч хис кылмаган иде. Бу ел ашлыклар шәп булып, Закирның эчүе бигрәк артканга, Гөлбану өчен тарихның дәхи дә караңгырак, дәхи дә газаплырак сәхифәләре ачыла башлаган иде. Беренче октябрь көне менә шул кара сәхифәләрнең мөһимнәреннән берсен билфигыль[1] ачты.

Бүген күрше авылга базарга китеп, халык өйләгә кайтса да, Закир ярты төнгәчә кайтмаган иде. Сабира өйдә юк иде. Гөлбану ире кайтуына самоварны кайнатып баскан, үзе, урам як тәрәзәнең күтәрмәсен күтәреп, Закирны көтә иде. Авыл гомумән йоклап, бөтен кяинатта[2] тирән тынлык вә мөхкәм сөкүнәт[3] хөкем сөрә иде. Төн караңгы, һава ләтыйф вә саф иде. Баштарак күк йөзе ачык булып: «Әй бичара! Хәлең бигрәк аянычтыр!» дигән төсле ай һәм йолдызлар кызганышып карап торсалар да, соңга таба аларны да болыт каплап, Гөлбану калын караңгылыкта япа-ялгыз калды.

Сабира күптән түгел «онны тиз бетергәнсең!» дип сүгеп чыкканга, Закир озакламый кайтып әллә ниләр кубаруы, җенләнүе мәгълүм булганга, Гөлбану бик тулган, моңайган иде. Закир бер капчык солы алып китеп, үзе дә яп-якын җирдә бу кадәрле озак торганга, исереп кайтуы, кыйнавы билгеле иде. Ул моңарга ышанган иде. Боларга кушылган ялгызлык, төннең караңгылыгы, кяинатның гомумән тынлыгы аны ихтыярсыз уйга вә хыялга чумдырды. Үткәнне уйлау! Бу өметсез вә мөтәхәссирләргә гаиддер[4].

Гөлбануның бала-чагыннан башлап бүгенгәчә үткән гомере һәм киләчәге бар да берәм-берәм күз алдына килде. Үткәнне әләм вә изтыйраб[5] эчендә, кайгы вә хәсрәттә күрү киләчәген караңгы һәм өметсез дип ышану анын уйларының тәмсезлеген арттырды. Хыял аның хатирәләрен гәүдәле ясап, алдына китерә иде. Аның бала чагында үзенә хаким, хуҗа вә манигъ тапмый яланаяк, яланбаш һаман уйнап, сикереп шатлыктан башка һичнәрсә белми йөрүләре, иптәшләре белән киенеп, ясанып тауга чыккан, кунарга

[1] Билфигыль – чынлап.
[2] Кяинатта дөньяда.
[3] Сөкүнәт – тукталу, оеп калу.
[4] Мөтәхәссирләргә гаиддер – кайгы-хәсрәт чигүләргә бәйләнешле.
[5] Әләм вә изтыйраб – кайгы, хәсрәт һәм газаплану.

җыелган заманнары, кызлар эчендә моң иттереп үзенең музыка уйнавы, андагы җырлар, биюләр, яхшы чанага төялеп авыл буена каз җуарга йөрүе, Зыяны яратып, аның белән үбешеп, кочышып, барырга өметләнүләре, хәзрәт сүзенә карап Закирга бирелеп тә, шул көнгә төшүе, Сабираның акырулары, Закирның кыйнаулары, үзенең өсте ялангач, тамагы ач, өй салкын булулары, тагы әллә нинди уңайсызлыклар берәм-берәм зиһененнән кичеп, аны соң дәрәҗә мөтәэссир кылды.[1] Күңеле тулды. Йомшарды. Энҗе бөртегенә охшап, күптән бирле кайда төшәргә белми торган кебек калтырашкан күз яшьләре саргылт йөзеннән берәм-берәм акрын гына тәгәри башладылар. Боларны башкалары тәгъкыйб итеп[2], аның күзе бер чишмә хәлен алган иде.

Ул бик озак еглады, эссе яшь түкте. Бу елау аңарга бераз юаныч булган иде. Ул азрак җиңеләйде. Гүя күз яшьләре аның эчендәге кайгыларын юды яки кайгылар күз яше сурәтендә гәүдәләнеп актылар да, ул азрак бушангандай булды. Җаны бераз тынычлана төште. Ул аз гына булса да җиңеләйгән иде.

Фәкать еравктан ишетелеп, боларга таба килгән бер исерекнең тавышы гына аның бу җуанычларын кабаттан бетереп, тәннәре әллә нинди булып китте. Ул моны Закир дип уйлаган иде. Яңгылышты. Ул Закир түгел иде. Җырлап Гөлбануның тәрәзә төбеннән үтеп китте. Бу исерекнең үтүе озакламый Закирның да шул кыяфәттә кайтачагын күз алдына китергәнгә, аны дәхи дә әләм вә изтыйраб истиля[3] кылды. Ул тагы изелә, тагы борчыла, тагы газапланырга тотынды. Тагы бик тәмсез нәрсәләрне уйларга чумып китте.

Никтер ул хәзер бик өметсез иде. Сабыр вә түземлеге беткән төсле, моннан соң бу йортта тора алырлык тәкате калмаган төсле хис кыла башлады. Ихтыяры тәфәккернең нәтиҗәсе түгел, бәлки гайре ихтыярый бер хис аңарга: «Юк, Гөлбану, син монда тора алмыйсың! Тәкатең бетте. Син китәргә юл кара!» дигән төсле иде. Аңарга өмет: «Түз әле... бәлки, төзәлерләр», дисә дә, өч еллык киленлек хәяты ул өметнең нәсыйхәтен урынсызга чыгара иде. Өмете җиңде. Баягы хис аның гакыл вә мөхакәмәсенә дә хуҗа булып, Гөлбану ихтыярсыз ук үзе шул хиснең ягына ава башлады. Ул китәргә мәҗбүр күрде. Хиссият аның тора алырлык тәкате

---

[1] Мөтәэссир кылды – кайгыга салды, үкенечле итте.

[2] Тәгъкыйб итеп – эзәрлекләп.

[3] Истиля кылды – басып алды.

калмаганына ышандырды. Китү ягын уйлый башлады. Закирдан, Сабирадан котылу чараларын эзләргә тотынды. Ничек китәргә? Ул бу хакта аптырый иде. Ничек китсен? Ул бит ирекле түгел... кол. Китә алу ихтыяры аңарда юк. Китү өчен Закирның җибәрүе, талак кылуы лязем. Закир хуҗа... бу аңарга багъланган.. җибәрсә дә, тотса да, ихтыяр аныкы. Гөлбану боларны бик яхшы белгән кебек, Закир мең бәла белән тапкан хатынны үз ихтыяры белән аермаячагына да ышана иде. Закир үзе аермаса, аңардан көчләп, судлашып аерылырга да имкян тапмый иде. Закир – ир. Бу – хатын. Ул – хуҗа, бу – колдыр. Ир аермавы билгеле. Ул аермаса, шәригать тә, Алла да, мулла да аермый, һичкем аермый, теләсә дә аера алмый, һәркем ир яклы, һәрнәрсә аны гына яклый... Аны гына яклый... Аны гына хаклыйдыр... Гөлбануның күз яше берәүгә дә кыйммәт түгел... Җылап җаны чыксын, аны химаяче[1] юк... булса да булдыра алмыйлар... Гөлбану боларны нәзар вә тәфәккер[2] белән түгел, бәлки һәр көн күз алдында булган вакыйгалардан күреп белә, шулай булуына якыйнән[3] ышана... эче шуны сизенә иде.

Ирләреннән көчләшеп аерылырга тырышкан хатыннарның йөзләрчә вакыйгасы Гөлбануның да Закирдан көчлек белән аерылырга имкян юклыгына борһан[4] була иде. Шул хакта уйлана торгач, аның күз алдына кичә генә булган бер вакыйга килде. Ул шуннан гыйбарәт иде: күрше хатыны Нәгыймә ире Зарифның һәм кайнанасының җәбер вә җәфасына түзә алмыйча җылап, хәзрәткә барып: «Хәзрәт! Минем түзәрлек хәлем калмады. Мине аер», – дип шикәят кылды. Имам әфәнде Нәгыймәнең ире Зарифны чакырып, хатынының түзә алмый аерылырга теләвен сөйләде. Ир бер дә каушамый, йөзен дә чытмый гына: «Хәзрәт, ул алдый... ялганлый... без бик яхшы торабыз... ул маена чыдаша алмый килгәндер ...ышанмасагыз, күршеләрдән сорагыз»,– диде. Күршеләр килде. Ни күрәсең! Алар да бит ирләр. Әгәр дә хатыннарны яклау башланса, үз хатыннарының да шулай судлашып талак кылынуыннан куркалар. Дәхи аларның Зарифка ихтыяҗы да төшә, ә Нәгыймә бер тиенгә кирәкми. Шуның өчен күршеләре иманлы авызлары белән: «Алар яхшы торалар, җәбер, җәфа юк», – дип,

---

[1] Химаяче – яклаучы.
[2] Нәзар вә тәфәккер – уйлау һәм фикер йөртү.
[3] Якыйнән – ачык рәвештә, шиксез.
[4] Борһан – факт, дәлил.

ялганнан шәһадәт бирделәр. Соңра имам әфәнде: «Ирең аермый... шәригать талакны ир кулына биргән... ул аермагач, син китә алмыйсың! Бар кайт! Итагать кыл! Яхшы булсаң, берәү дә тимәс»,– дип кайтарды. Менә бу факт... бу хакыйкатьтер, кичә генә Гөлбануның күз алдында булды. Ир аермады. Ул аермагач, шәригать тә аермады. Алла да... мулла да... берәү дә аермады. Хәзер ул хатынны баш тарткан өчен бигрәк җәфалый башладылар. Әле кичә кояш баегач кына Нәгыймә, җылап-җылап, Гөлбануга шуны зарланды.

Гөлбану үз гомерендә мондый Нәгыймәләрне бик күп күргән иде. Көчләнеп аерылырга теләп, кунакка баргач атасыннан кайтмый калган хатыннар һәм качып кайтканнарның ничә еллар буена ирләре аермый, килеп тә алмый, икенче иргә дә җибәрми азаплаганнары, кайбер хатыннарны ирләре көчләп арбага салып, чыбыркы белән ярып алып кайтулары кебек вакыйгалар Гөлбануның зиһененнән кичте.

Бу вакыйгаларның һәрберсе Гөлбануның Закирга багълы икәнен, көчләшеп аерылырга дәхи дә имкян юклыгын ышандырганга, аны бигрәк измеш... бөтен өметләрен җимермеш иде. Ул дәхи еглады. Бусы зәһәрле дә, агулы да иде. Кайда барса да, шул җәфалы тормышыннан котылырга юлларның бикле булуын күреп, ул инде «мин аерылам, китәм», дип сүз кузгатырга да, шул юлда хәрәкәт башларга да курыкты.

Инде нишләргә? Ничек котылырга?

Торырга тәкате калмаганны хис кыла. Ул эченнән китәргә мәҗбүр күрә... Ә моны ире җибәрерме? Ул җибәрмәгәч, бу китә алмый. Моңа ни чара? Ни юл? Тәмам аптырап, нишләргә дә гаҗиз булып меңтөрле агулы уйлар, зәһәрле юллар зиһененнән кичеп, шул рәвешле әләм вә изтыйраб эчендә изелгәндә, аның колагына бер тавыш ишетелә башлады. Тавыш ерак булса да, бер русча, бер татарча сүзләр, мәгънәсез җөмләләр моның бер исерекнеке икәненә дәлаләт итә иде. Бераздан соң Закирныкы булуы да беленде. Гөлбануның бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. Каушый, калтырый башлады. Йөрәге дә сугарга тотынды. Теге тавышның якынаюы аның бу халәтен бигрәк тә арттыра иде.

Бик ашыгып капкага чыкты. Ачты. Төн бик караңгы булганга, бернәрсә дә күренми, тик тавыш кына килә иде: «Ах... милинки... муй милинки... лублу... муй душенка... ахай-һай.. Итдрире... рирайра... Зиләйлүк...» кебек русчадан да, мөселманчадан да

җыелган мөһмәлят[1] тавыш ишетелә... «На... ну... я... т...» дип атка да сүгенә иде. Ат бик арыганга, акрын килә, туктый иде. Закир һаман пычрак сүзләр белән сүгенә иде. Бераздан соң капкага килеп җитте. Закир бик нык исерек иде. Күзене адәм куркырлык рәвешле кызыл кан баскан, йөзе тузан, пычрак, авызы күбекле иде. Башындагы бүреге дә төшеп калган иде. Кесәсендә берсе буш, берсе аракылы ике бутылка бар, арбасындагы капчыкка базардан алган чүлмәкне салган икән, ул ватылган, тик кисәкләре генә ята иде. Арбаның арткы тәгәрмәчләреннән берсе төшеп калып, күчәр юл буена өстерәлеп килгән иде.

Гөлбану аны култыклап өйгә кертте дә, өс киемнәрен салдырып җуындырды. Бу аңарга авыр иде, җирәнгеч иде. Эченнән генә: «Тәгәрмәчең калганчы, үзең кадалып калсаң, җаным тынар иде, ичмаса», – дип, әрни, сукрана иде. Закирның һәр эчүендә җенләнү, котыру һәм сүгенү гадәте булса да, хәзер аның буыннарына аракы төшкәнгә, күп котыра алмый, алай-болай омтыла башласа, чалкан төшә иде. Теле көрмәкләнгәнгә, рәтләп сүгенә дә алмый, тик: «анаң... кере...» кебек сүзләрне генә тәкрарлый иде. Гөлбануның самовары кайнаулы иде. Бик каты ясатып, шул самоварның суы беткәнче эчте. Менә шуннан соң аңарга бераз хәл кереп, җенләнә башлады. Хәзер теле дә, үзе дә куәтләнгән иде. Әле бер нәрсәдән, әле икенчедән гаеп эзләп, сүгенә, бәйләнә иде. Нәкъ ерткыч, вәхши кебек кылана иде. Бүген берәрсе белән ачуланышкан булса кирәк, бик озак бер мәҗһүл[2] кешене «мин белерем... кирәгеңне биререм... фәлән итәрем, мин синең кебекләрне күргән кеше»,– дип, бер күкрәгенә, бер өстәлгә сугып сүгенде. Гайрәт орды да, соңра ятмак булып, Гөлбануга аягын чишендерергә кушты. Аягында тула оек белән чабата иде. Оеклары вакыйгда[3] да тыгыз булып, бүгенге яңгырда бигрәк бүрткәнгә, соң дәрәҗә тыгызайган иде. Ябештергән төсле булып, бер дә чыкмый иде. Шул тыгыз оекны салдыру өчен тартып маташа торгач, Гөлбану Закирны утырган сәкесеннән, шарт иттереп, идәнгә тартып төшереп җибәрде. Закирның төшкән җиренең бер ягында кайнар сулы таш чәйнүк бар икән. Ул кулы белән шунда таянып аны ватты. Кулы бик аз гына суга пешеп, чәйнүк ватыклары аның кулыннан азрак кан да

[1] Мөһмәлят – буш, мәгънәсез.

[2] Мәҗһүл – билгесез.

[3] Вакыйгда – чынлыкта.

чыгарган иде. Ничек бәйләнергә белмәгән Закирга бу җитә калды. Шарт итеп идәнгә төшүгә ачуланып, сүгенеп торды да, янындагы каеш чыбыркыны алып, Гөлбануны ярырга тотынды. Кай җирең кычыта, дигән кебек, әле чыбыркыны бөкләп, әле сабы белән, әле йодрык белән изгәнче кыйнады. Гөлбану күлмәкчән булганга, күлмәге телем-телем ярылып бетеп, тәне кара янган, битенә дә аркылы-буйлы өч урында чыбыркы белән кара көйдергән иде. Күз төбе кап-кара иде. Болар гына җитмәгән кебек, Гөлбануны идәнгә сугып екты да, аягы белән күкрәген, бөтен гәүдәсен типкәләде, изде. Гөлбану никадәр тырышса да, үзен котылдыра алмады. Бөтен тәне изелгән... сызлый... әрни... ватыла иде. Закир, үз өстеннән лязем булган бер эшне төшергән кебек, кыйнап туйганнан соң сәкегә сузылып ятты.

Гөлбану аның янына ятарга җирәнгәнгә, сандык өстендә утыра иде. Бәгъзе вакыттагы кебек үз янына ятарга көчләмәсә ярар иде, дип тора иде.

Куркылган нәрсә күп вакыт өскә һөҗүм итәдер. Закир, ятып бераз хәл алганнан соң, тагы җеннәре качып, Гөлбануга көлә, иркәли... аркасыннан кага башлады. «Җанаш... кәләш» дип кочакларга, үбәргә омтыла башлады. Бусы Гөлбану өчен кыйнаудан да яман һәм җирәнгеч булганга, ул бик тартыла, ычкынырга тели иде. Никадәрле тартылса да, Гөлбану ычкына алмады: Закир аны агач кебек куллары белән биленнән кочаклап алып янына яткырды. Китмәсен дип кысып кочаклый иде. Һич җибәрмәде. Төн буена шулай үзенең сасы, нәҗесле тыны-сулышы белән җанны рәнҗетеп, Фәтхия әбинең кадерләп үстергән назлы, иркәле Гөлбанусының кечек авызы, кызыл ираннәреннән аракы аңкып торган пычрак, сасы, күбекле, селәгәйле авызы белән үбеп, суырып җирәндереп чыкты. Закир йоклап киткәнче үзенең аракылы, сасы, селәгәйле, пычрак, күбекле авызын Гөлбануның кыйммәтле авызыннан алмады. Үпте... Суырды. Болар Гөлбануны чиктән тыш җирәндерде, биздерде. Аның бөтен җаны, күңеле җирәнә, косасы килә иде.

* * *

Гөлбануның түзәрлек тәкате калмаганга, ул бу төн: «Ни күрсәм дә күрермен, валлаһи, бу таңда китәм!» – дип, ант иткән иде. Антын җиренә җиткерде. Иртәнге кояш Гөлбануны Закирлар йортында күрә алмады.

Сабира өйдә юк... Закир әлсерәп йоклый иде. Гөлбану бар кадәре белән киенде дә, караңгылы-яктылы чакта бу йортка мәңге килмәскә теләп, акрын гына сызды. Югалды. Гаип булды. Сабира белән Закир, иртә торгач, Гөлбанудан җилләр искәнен күрделәр.

Гөлбануның югалу хәбәре, тиз заманда бөтен авылга таралып, халыкның дикъкатен җәлеп итмеш иде. Бу халыкка сөйләр, тикшерер өчен яңа бер вакыйга булды. «Гөлбану югалган...» Бу хәбәр башка һәр сүзне, һәр гаҗәпне җиңеп, телләрдә шул гына сөйләнә, шул гына мөхакәмә кылына башлады.

Ул кайда булыр? Атасында да юк... хәбәр дә юк... һәркем шуны тикшерә... шуны сөйли иде. Ләкин һичбере Гөлбануны яманламыйлар, «авылда бер килен иде», дип мактыйлар гына иде.

Моңарчы нинди җәфа күрсә дә, тиргәшми, даулашмый, мотыйганә[1] килгән бер киленнең үз ихтыяры белән качып китүенә һичкемнең зиһене бармый, алай булыр дип берәү дә уйламый иде. Хатыннар, гомумән, Закирны гаепләделәр.

«Һәрвакыт шешендергәнче, изгәнче кыйный иде. Беркөн дә агач белән сугып үтерә язган иде. Кичә базарда эчеп кайткандыр да, кыйнап үтереп, берәр җиргә яшергәндер», дип, Закирны сүгәләр, кабахәтне аңарга аударалар иде. Картлар да бер шикләнми, шөбһәләнми генә кискен сүз белән: «Алама малай... харап иткәндер бичараны...» – диләр.

Аңсыздан югалган башка кешеләр хакында булган кебек, Гөлбану хакында да тентү чыгардылар. Закирның йорт тирәсен, су буйларын, урманнарны, чокыр һәм мәмерҗәләрне[2] эзләделәр. Ләкин һичбер нәрсә табылмады... Хәбәре дә беленмәде. Өч елгача ул мәҗһүл[3] калды.

Югалды... китте... бетте... вәссәлам.

## XI

Октябрьның икенче көне иде.

Һава салкын булып, җил дә ыжгырып тора иде. Күк йөзе болытлар белән капланып, карлы-бозлы яңгыр да ява иде. Юллар вә, гомумән, аяк асты бик баткак һәм пычрак иде. Көннең, һаваның шул уңайсызлыгына карамыйча, Курайлы авылыннан ике ат

---

[1] Мотыйганә – буйсынып.
[2] Мәмерҗә – ышыклану урыны.
[3] Мәҗһүл – билгесез.

җиккән бер арба кояш чыкмас борын чыгып китте. Арба яхшы ук зур булса да, бөтенләй нәрсә белән тулганга, түргә бер генә хатын утырып, урын булмаганга, иркәге кучерга утырган иде. Арбада шул икедән башка кеше күренми иде. Юлның пычраклыгына, атларга авырлыкка карамыйча, болар бик кызу куалыйлар, чаптыралар иде. Шималь шәркыйга таба юл алып берничә авылларны үткәннән соң, Курайлыга 30 чакрым чамасында хисапланган бер урманга барып керделәр. Кучердагы ир атларны туктатты да, як-ягына дикъкать белән карап, хатынга нәрсәдер ишарә кылды.

Хатын бу ишарәдән бер мәгънә аңлады булса кирәк, арбадагы нәрсәләр өстенә япкан паласны ачып, йомшак вә иркәле тавыш белән: «Бик уңайсызлангансыңдыр... ерак киттек... инде белмәсләр... торып утырсаң да ярар», – диде. Бу сүздән сон палас астыннан бер хатын килеп чыкмасынмы? Ни күзең белән күрәсең! Җылап, куркып, тыгызланып йөзе бозылган, чәчләре битенә төшкән хәлдә әллә нинди моң вә аяныч сыйфат белән Гөлбану заһир булды[1]. Ул бичарага, Закирдан качып, язмыш әйдәве буенча шул арбага эләгеп, яшеренеп килергә тугъры килгән иде.

Бу гаҗәбрәк бер тәсадефтер[2]:

Курайлыга 50 чакрымда Атлаш дигән авылның Галиулла исемле бер кеше үзенең хатыны Шәрифә һәм гаиләсе белән бергә күп елдан бирле Урал тавының Златоустка якын җирендә Сөләйман авылында сату итеп тора иде. Елдагы гадәтенчә, Галиулла бу ел да үз атларын җигеп, хатыны белән Атлашка кунакка кайткан иде. Ул Атлашта ун көн кунак булып, беренче октябрьда кабаттан Сөләйман авылына сәфәр кылды. Курайлы авылында аның Касыйм исемле бер баҗасы бар иде. Көн дә кич булганга, баҗасы да үтенгәнгә, кичкә каршы алар шул Курайлыдагы Касыймга кереп кундылар.

Закирның исереп, Гөлбануны газаплаган кичендә алар менә шул Касыймда иделәр. Болар Гөлбануны борыннан белгәнгә, аның начар һәм җәфалы тормышы хакында сөйләшеп тә утырганнар иде. Хосусан Касыймның хатыны, Гөлбануны кызганып, бик күп вакыйгаларын сөйләгән иде.

Гөлбану, бу авылда сер сыйган вә ярдәм өмет ителгән кешесе һәм дусы фәкать шул Касыймның хатыны гына булганга,

[1] Заһир булды – күренде.
[2] Тәсадеф – туры килү, очрау.

Закирлардан качкач, туры шуларга килде. Җылап, ялварып: «Мине коткарыгыз... атама илтегез!» – дип үтенде. Бу хәбәр тиз үк Касыймга да, Галиулла белән Шәрифәгә дә ишетелгән иде.

Алар өчесе дә беравыздан: «Атаңа кайтуда файда юк... Барыбер сине Закирга көчләп алып килер... алыр... аермас, котыла алмассың!» – дип, кайтуны файдасыз, бәлки зарарлы күрсәттеләр. Ул һаман исрар итте[1]. Җылады: «Мин (минем) анда торырлык тәкатем юк, тора алмыйм», – диде. Бәйләп илтмәсәләр, үз ихтыяры белән Закир йортына барачак ихтималы юклыгын белдерде. Касыймның хатыны, Гөлбануны чын күңеленнән кызганганга, котылдыруны бик тели иде. Касыйм гына тик тәрәддед[2] белән генә: «Галиулла җизниләр белән китсә, ничек булыр?» – диде. Бераз уйлаштылар да, соңра моны Галиуллаларга сөйләделәр. Алар кабул итте. Үзләре белән бергә алып китәргә риза булдылар. Аларның алып китүе фәкать Гөлбануны кызганудан гына түгел, бәлки үзләренең икесендә ике төрле максуд бар иде. Башкорт хатынының бик ярлысы да кешегә өй хезмәте итмәгәнгә, Шәрифә бер хадимәгә[3] мохтаҗ иде. Атлашта сораштыргаласа да, табылмаган иде. Әгәр дә бара калса, ул Гөлбануны үзе өчен хадимә мөгайян[4] булыр дип уйлады. Галиулланыкы тагы башка иде: аңарга башкорт байлары һәр елда илгә кайткан саен: «Татар кызы куштан була диләр... миңа берне тапчы! Хезмәтеңне буш итмәм», – дип, бер татар хатыны яки кызы сорыйлар иде. Гөлбану барса, ул аны үзе башкортларга биреп файдалануны уйлады да, алып китәргә риза булды.

Гөлбануның уйларлык, алдын-артын үлчәрлек мөхкәмәсе[5] калмаган иде. Ул болар белән качуны тәклиф кылгач[6], каршы да тормады, кабул да итмәде. Фәкать бик тәрәддед белән: «Белмим шул... мин анда нишләрем», – диде. Галиулла да, Шәрифә дә икесе берьюлы: «Безгә ышан! Без сине әрәм итмәбез», – диделәр. Гөлбану, барачак җиренең ерак һәм ятлыгын, анда ничек көн итәчәген уйлап, бер карар бирә алмады. Озак торса, Закирның сизеп килеп тоту ихтималы булганга, ике кеше ачык йөз белән «без сине әрәм

[1] Исрар итте – үз сүзендә нык торуды.
[2] Тәрәддед – икеләнү.
[3] Хадимәгә – хезмәтчегә, асраугa.
[4] Мөгайян – билгеләнгән.
[5] Мөхкәмәсе – чыдамлыгы.
[6] Тәклиф кылгач – тәкъдим иткәч.

итмәбез», дип торганга, болар белән китү бер мәлҗәэ[1] төсле булды. Эшне бөтенләй аңлый, төшенә алмады.

Касыйм белән хатыны, Гөлбануның каршы тормаганын күргәч, көчләп утырткандай утырттылар да, паласлар астына яшереп юнәлделәр. Курайлыдан чыгып, биш көн дигәндә Галиулланың тора торган авылы Сөләйманга барып кerделәр. Сөләйман белән Курайлы арасы өч-дүрт йөз чакрым кадәр иде.

XII

Сөләйман, Троицкий өязе булып, Златоустка якынрак җиргә, Урал тавының арасыннан аккан кечкенә бер елгага утырган бер авылдыр. Тирә-ягы, гомумән, урман вә тау булганга, мәнзара табигыйясе фәүкыльгадә гүзәл булып, әһалисе[2], гомумән, башкорттыр. Бу башкортларда җир, су, урман, агач бик хисапсыз күп булып, бу елларга кадәр авыл авылга бүленмәгән иде. Фәкать соңгы елларда гына хөкүмәт җирләрен бүлде. Бераз кысты, һәр авылның үзенә махсус «буш вә саклык кыйсем» дә тәгаен итеп, анысы хәзер хөкүмәт кулындадыр.

Ләкин бу бүлү генә аларның табигый байлыгын киметмәде. Әле хәзердә дә җир шулкадәр иркен ки: әллә ни чаклысы чәчелми дә, чабылмый да кала. Печән, утынның хисабы юк. Аның өстенә монда мәгадиннән[3], җимешләрдән дә күп нәрсә бардыр. Башка мәгадиннән файдаланмасалар да, алтынны бик казыйлар. Гомумән, алтынлы җирләр приискалар кулында исә дә, башкорт моңарга карамый, һәммәсе дә урак-печәннән калган вакытны шул алтын казуга бирәләр. 3–4 кеше бергә кушыла да, чокый, җуа. Аны кибеткә илтеп сата. Кибетчеләр аны бер дә шикләнми алалар. Прииска идарәләре бу казучыларны тоту өчен махсус каравылчылар йөртсә дә, башкортлар аларның күзен ришвәт белән каплаганга, берни дә күрмиләр, тотмыйлар иде.

Шулай итеп, алтын эше башкортларда хорсый[4] белән дәвам итә. Башка бик күп төрле мәгадин бар исә дә, алардан әле хәзер файдаланмыйдыр.

---

[1] Мәлҗәэ – котылу урыны.
[2] Әһалисе – халкы.
[3] Мәгадиннән – җир асты байлыкларыннан.
[4] Хорсый – хирыслык.

Монда җимешләрнең дә һәр әнвагысы[1] фәүкыльгадә күп, ләкин башкорт моңардан файдалана белми... черетәдер.

Мондагы табигый күренешләрнең гүзәллеге адәмне хәйран итәдер. Кайда карасаң да, ямь-яшел агач белән капланган өлкән вә биек-биек таулар, урманнар, карагайлар, акланнар, җимешле агачлар арасыннан, таш эченнән шылдыр-шылдыр агып яткан көмеш кебек елгалар адәмнең мәхәббәтен җәлеп итә... рәхәт вә шатлык бирә... уйлата... уйгатадыр. Ләкин башкорт моны сизми, ул йоклый гына... Бу башкортлар кыш көне гомумән кышлауда яшиләр. Кышлаулар безнең Уфа ягына бер дә охшамый, карагайдан эшләнгән яхшы өйләр бар... Авыл матур гынадыр. Яз көне биясе булган башкорт киез өйләр белән җәйләүгә чыга, булмаганы авылда каладыр. Авылда бер мәчет, начар бер мәктәп бардыр. Җәйләүнең кызыгы – кымыздыр. Башкорт шуны эчә, йоклый, ауныйдыр. Монда хәят мөхарәбәсе[2] юк, икътисадый җәһәттән дә кайгы-хәсрәт күрми, тыныч, рәхәт яшиләр. Гали матлаблар[3], уку вә укытулар өчен баш вату күптән юк.

Җәй алтын хирысы белән җир казыса да, кыш буена йоклый гына. Читкә чыкмый. Кәсеп эзләми. Ни бар, шуңа риза. Үзләре садә... беразрак пис... нәзакәтсезләр... Сәүдәгәрлек башкортка әҗнәби[4] булганга, авылдагы ике кибетнең икесе дә читнеке: берсе Казан татары Әхмәдинеке, икенчесе Галиулланыкыдыр. Галиулла бер тиенсез килгән булса да, шунда сату итеп, хәзер яхшы гына баеган иде. Йорт-җире, мал-туары яхшы иде. Бу ел кайтып Гөлбануны китергәч, башкортлар тәгаҗҗеп итте[5]. Хосусан үз авылыннан читкә чыкмаган башкорт хатыннары Гөлбануның бу кадәрле ерак җиргә килгәненә хәйран булдылар. Сорашып йөдәтәләр иде. Ерак җир вә гадәтләре башка бер халык эченә килеп төшү Гөлбану өчен, әлбәттә, бигүк күңелле булмады. Фәкать көн-төн ажгырып, талап торган Сабира белән исерек Закирның булмавы, Галиулла белән Шәрифәнең һәрвакыт көләч йөз, тәмле сүз белән мөгамәлә кылулары гына аңарга җуаныч кебек була иде. Закирда күргән җәфаларын уйлый башласа, хәзерге көне ганимәт төсле була иде. Шатланып та куя иде.

---

[1] Әнвагысы – төре, сорты.

[2] Хәят мөхарәбәсе – яшәеш, тормыш өчен көрәш-сугыш.

[3] Гали матлаблар – бөек максатлар.

[4] Әҗнәби – чит, ят.

[5] Тәгаҗҗеп итте – гаҗәпләнде.

Әйтерлек хезмәт тә юк. Бөтен эше тик Шәрифәгә могавәнәттән[1] гыйбарәт, өс-баш ару, тамак тук. Җанны газаплый торган нәрсәләр дә очрамый. Менә шулар теге аяныч тормыштан чыккан Гөлбануга мәсгудиять төсле хис кылына иде. Туган иле, аналары сагындырсалар да, андагы Закир, Сабиралар исенә төшкәч, ул Эстәрле өязеннән Троицкий өязен алгарак чыгара иде. Чөнки теге тормыш йөрәгенә бик үткән, үзәген бик өзгән иде. Аңарга караганда хәзерге тормышы сәгадәт иде.

Дөньяда иң аз дәвам иткән нәрсә сәгадәттер. Гөлбануның бу сәгадәте озакка бармады. Галиулланың астан сүз йөртүе аркасында, Гөлбануга бер башкорттан яучы килде. Шәрифә каршы торса да, Галиулла барырга тәклиф итте[2]: дөньяда алардан башка таянычы калмаган кешеләрнең сүзенә карышу мөмкинме, карышса да, булдыра аламы? Һич!.. Гөлбану һичбер теләмәсә дә, риза булмаса да, ихтыярсыз ул башкортка барды. Бу башкортның исеме Солтан, яше илле биштә булып, үзе авылның байларыннан иде. Бик юан корсаклы, калын гәүдәле, урта буйлы, ифрат симез, кып-кызыл йөзле, чал сакаллы бер кеше иде. Соң дәрәҗәдә зинахур, шәһвәтпәрәст[3] булып, дөньяда хатын белән чуалудан башка һичбер нәрсәдән ләззәт алмый торган, уе, теләге гел генә хатынга багъланган бер кеше иде. Гөлбану өчен дә Галиуллага зур мәкяфәт[4] бирмеш иде. Кайда матур хатын күрсә, аны алдарга, хайванланырга бар көче белән тырыша иде. Шөһрәте дә шул эш белән иде. Элек күп хатыны булса да, хәзер икәү генә иде. Гөлбануны өченчегә алды. Мулла әфәндене яхшы майлаганга, Гөлбануга никах уку өчен талак хаты да, метрикәдән копия да соралмады. Тыныч кына, Закирның хатынын Солтанга никахлап, эш тәмам булды. Гөлбану Солтанга күчте. Тагы бер кешегә хатын булды. Ләкин мондагы хатынлык башка иде. Өс-баш бөтен – укалар, ефәкләрдән, тамак тук, һичкемнән шелтә юк иде. Солтан үзе Гөлбануны табыну дәрәҗәдә ярата, иркәли, орышмый, сукмый иде: «Гөлбануга начар карасагыз, башыгызны сугып ярырмын», – дип тәһдид[5] кылганга, көндәшләре дә бер сүз әйтә, тирги алмый иде. Авырсынырлык хезмәт тә юк иде.

---

[1] Могавәнәттән – ярдәм итүдән, булышудан.
[2] Тәклиф итте – таләп итте.
[3] Шәһвәтпәрәст – җенси дәртле.
[4] Мәкяфәт – хезмәт бәрабәренә бирелгән премия, бүләк.
[5] Тәһдид – куркыту, янау.

Закирда яфаланган нәрсәләрдән берсе дә калмаган иде. Инде ул мәсгуд[1] булырга тиеш иде. Ләкин болар Гөлбануны мәсгуд итә алмады. Табигый, ул юан корсактан Гөлбану нәфрәтләнә иде. Аның өстенә Солтанның аңарга чиктән тыш куштанлык тәклиф кылуы, әллә ниләр кыландырып бетүе Гөлбануны изә иде. Кеше алдында Гөлбануны мактаган булып, әллә нинди оят һәм пычрак нәрсәләрдән бәхәс итеп, аны бик кызарта... газаплый иде.

Башкорт ирләренең, гомумән, Гөлбануга кызыгып, аны алдарга, үзләре белән пычранырга тырышулары, шул морадлары өчен Гөлбануга юк-барны сөйләп, аның тирәсендә әйләнүләре дә Гөлбануга хурлык тоела иде. Башкорт хатыннарының ирләре һаман Гөлбануны мактап: «мин дә татар кызы алам», диюләре өчен хөсед итеп, үзара һаман аны тиргәүләре, алдында, артында да «бернәрсәсенә баш була алмаган... бер... таба алмый монда килгән...» – дип сөйләүләре Гөлбануның йөрәгенә кадала... аны хурландыра... изә иде. Күңеле җәрәхәтләнә... җаны газаплана иде.

Кыш үтте, кар бетеп, җир кипте. Дөнья дәхи дә матур кыз кебек бизәнергә тотынды. Гөлбану әле һаман шул рәвешле бара иде. Биясе булган башкортлар җыелып мәҗмугы 20 кадәрле гаилә, кечерәк киез өйләр белән җәйләүгә чыктылар. Гөлбанулар да чыкмыш иде. Табигатьнең матурлыгы әйтеп бетерерлек түгел иде. Дөнья ямь-яшел... агачлар яфраклар белән капланган, күңелле вә моңлы итеп кошлар да сайрый иде. Бу сандугачлар Гөлбануның туган илен исенә төшереп сагындырсалар, бик тирән уйга чумдырсалар да, аның өчен монда бераз гына рәхәтрәк ягы да бар иде.

Аның тирәсендә бәйләнеп Гөлбануны алдарга йөргән тәрбиясез башкортларның сүзеннән котылган иде. Эшкә ярарлык ирләр, гомумән, алтын казуда булып, картлар вә байлар иртәдән кичкәчә әле берсенә, әле икенчесенә җыелып кымыз эчү белән үткәргәнгә, ул азрак тынган иде.

Мондагы гадәт буенча, үзе кебек киленнәр ирләр белән бергә печән чабып йөрүгә борыннан өйрәнмәгәнгә, уңайсыз булган иде.

Шулай бер салкын вә тәмсезрәк кенә юлдан аның көннәре үтә иде. Бердәнбер көн Солтан югалып китте. Ул моңарга бик шатланган иде. «Табылмаса гына ярар иде. Галиуллаларга барып торыр идем», дип теләде, һәм бер дәрәҗәдә муәффәкъ та булды. Солтанны караклар үтереп ташлаганнар иде. Дүрт көннән соң тау

[1] Мәсгуд – бәхетле.

арасыннан үләксәсен таптылар. Гөлбану моңардан соң дәрәҗә мәмнүн иде. Фәкать нәтиҗә ул өмет иткәнчә булмады. Солтанның анасы Гөлбануның эшкә осталыгы, шәплеге өчен бик яраткан иде. Аны җибәрәсе килмәде. Үзенең 11 яшьлек сабый угылына хатынлыкка алып, үзенә килен итәргә теләде. Гөлбануны мәҗбүр иттеләр. Ул шулай лязем... шулай гадәт, ихтыярсыз 11 яшьлек сабыйга хатын иттеләр. Ул: «Теләсәгез нишләгез, мин аңарга бармыйм», – дияргә уйласа да, Галиулла бер дә риза булмаганга, көчләгәнгә һәм: «Ихтыяр үзеңдә... риза булмасаң, бар илеңә кит!..» дигән сүзе ирен очында гына күренгәнгә, Гөлбану барырга мәҗбүр булды. Өченче кәррә буларак 11 яшьлек сабыйга хатын кылынды.

Никах юк... фәкать гакыд[1] белән генә аларны кушмышлар иде. Бала яшь булганга, әлбәттә, ояла иде. Гөлбану янына китереп яткырсалар да, «мин җиңги янына ятмыйм», дип, торып кача иде. Аны тагы күтәреп китерәләр, ул тагы китә иде. Гөлбану моңардан фәүкыльгадә[2] хурланды. Үз-үзен суга ташлыйсы, асылып үләсе килә, гомердә колагы ишетмәгән бер хәкарәттән[3] котылырга тели иде. Халык көлә... көлмәсә дә көлгән төсле тоела иде. Оят... намуска авыр, өзелә, өзгәләнә... әллә нишли иде. Тыштан белдермәсә дә, эчендә утлар яна иде... көя... еглый... ватыла иде. Ниһаять, түзә алмады, моннан да качты. Югалды – гаип булды.

Бу вакыт аңарга 22 яшь иде. Исерек Закир, шәһвәт әсире юан корсак Солтан һәм 11 яшьлек сабый белән мәҗмугы өч иргә хатын булса да, баласы булмаган иде.

Язмышның Гөлбану өстенә бер-бер артлы китергән фәлякәтләре[4] аңарга бер дәрес, гыйбрәт булмыш иде. Ул хәзер Фәтхия әбинең канат астында торган Гөлбану гына түгел иде. Аңарда табигый булган тәдбир,[5] тәвәккәл вә батырлыклар яхшы ук уянган һәм эшләтелгән иде. Ул хәзер дөньяны, тормышны азрак аңлап, көрәшү кувәсе хасил иткән иде. Эшләрнең алдын-артын уйларлык, хатты-хәрәкәтне тәгаен кылырлык тәҗрибәсе дә бар иде. Галиуллага ялынып та, муллага шикаять итеп тә һичбер эш чыкмаячагын ачык аңлаганга, былтыргы кебек әүвәле-ахыры мәҗһүл[6]

---

[1] Гакыд – сөйләшеп килешү төзү.
[2] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш, чиксез.
[3] Хәкарәттән – хурлыктан, кимсетелүдән.
[4] Фәлякәтләре – бәхетсезлекләре, афәтләре.
[5] Тәдбир – эшне ахырын уйлап эшләү.
[6] Мәҗһүл – билгесез.

бер юл белән качу да файда бирмәүне билгамәл белгәнгә, үзендә түзәрлек тәкать калмавын сизгәч, качу өчен ысуллы хәзерләнмеш иде. Беркадәрле акча да җыеп, хатты-хәрәкәтне тәгаен итеп, башка хәзерлекләрне дә җитештергән иде.

Төн караңгы һәм уңайлы бер заманда үзенең урман арасына куйган нәрсәләрен алып, акрын гына сызган иде. Борыннан тәгаен кылган бер аулаграк җиргә куркып, каушап, кайда басканын белми аптырап килеп җитте дә, кесәсеннән бер кайчы чыгарды.

Бу җир җәйләүгә өч-дүрт чакрым кадәр булып, кеше килеп чыгудан курку юк иде. Ләкин әллә нәрсә куркыта, Гөлбануның йөрәге ярылып чыгар дәрәҗәдә суга... иде. Күз алдына әллә нинди куркыныч сурәтләр килеп китә иде. Кайчы аның кулының калтыравыннан шылдыр-шылдыр селкенә иде. Башындагы яулыгын ташлап, сул кулы белән беркадәрле чәчен тотты да кисә башлады.

Ни өчен чәчен кисә? Әллә дивана булганмы? Хәер... миллионнар эчендә бер гакыйләдер[1]! Ләкин ул хатынлыктан туйган... табигатьнең аны хатын итеп ясавына риза түгел... Хатын булып түзә алмый... ир буласы, чәчен бетереп хатынлыгын яшерәсе, ирләр рәтенә тезеләсе килә... Коллар сыйныфыннан хуҗалар сыйныфына күчәргә тели... килә... тели... дип хата әйттем. Ул үзе моны теләми... бәлки тормыш... язмыш... фәләк[2] мәҗбүр итәдер. Ул хатын булып качкан тәкъдирдә былтыргы кебек эшләр очраячагын, дәхи һәр җирдә үзен ирләр тотып көчләячәген белгәнгә, тагы әллә нинди авырлыкларга төшүе ихтим Алланганга, хатынлыкны яшереп, ирләр сурәтендә качарга карар биргән иде. Шул максатына муафыйк хәзерләнеп, үзе белән кайчы да, ирләр киеме дә алган иде.

Шул карары буенча бу урынга килеп утыруга чәчен кырка башлаган иде. Чәчен кырку аңарга бик вә бик кыен булды. Үзенүзе кая куярга белмәгән бу газаптан ничек котылырга аптыраган минутында карар биреп, шуны зурайта-зурайта, ниһаять, билфигыльгә[3] чыгарган, мәҗбүрән эшләгән булса да, кисә башлагач кулы бармый, күңеле теләми, тартыла иде. Каушый, калтырый, кулыннан кайчылары төшеп китә иде. Күңеленә төрле уйлар килә: ир булып нишләр?.. Ни булдырыр? Беренче ни кылыр? Бу бит гөнаһтыр әле... Алла каршында ни җавап бирер? Тагы икенче якны уйлап:

---

[1] Гакыйлә – акыллы хатын-кыз.

[2] Фәләк –язмыш, тәкъдир.

[3] Билфигыльгә – фактка, реальлеккә.

теге башкортка кайтса, ничек түзәр? Анда ничек яши алыр? Сөале зиһененә килә. Үткәндәге куркыныч, изгеч тормышлары күз алдына килә... иде. Кисә алмыйча озак азапланып, рухы риза булмаган кебек тоела, әллә нинди бер җинаять тә төсле... кабахәтлек тә төсле күренә иде. Киселеп алдына төшкән чәч бөртекләрен кулына алып, бик озак хәйран булып торды. Бу ни эш? Нәтиҗә ни була? Болар аңа мәҗһүл иде. Ачы изтыйраб, агулы хәсрәт вә авырлык аны мәҗбүр иткән, башка чара күренмәгәч, шуңа ябышкан... башка юк...

Борын кара ефәк кебек булып биленә төшеп торган вә шуның белән ифтихар иткән[1] көлтәдәй чәчне мең бәла вә курку белән кисеп бетерде. Башы ялангач калды.

Башын сыйпап карап, бөтенләй ялангач икәнен сизгәч, әллә ниләр уйлады. Бер җинаять, бер инкыйлап хис кылды. Изелде. Бер үкенде... бер бик ачынып:

– Нишлисең соң? – диде.

Төрле уйлар зиһененнән кичте. Үзендә әллә нинди мескенлек тә, түбәнлек тә булган кебек сизенде. Дөньяда үзе кадерле аяныч хәлгә дучар булган һичкем булмас төсле, бу эшкә мәҗбүр булган адәм юк төсле тоелып китте. Таң да якынайган иде. Шәрекъ ягыннан дөньябызга бик аз якты чәчелә башлаган иде. Гөлбануның кайгысыннан мөтәәссир булып, сандугачлар да бик моң вә бик кайгы белән сайрарга керештеләр. Сандугачның моңлы вә музыкальный иттереп чут-чут сайравы анын иң соңгы тамырларына кадәр китте. Зиһенен әллә кайларга алып китеп, эссе яше белән ниһаятьләнде. Ул бик өзелеп, бик ачынып озак еглады, Сандугач тавышы аның зиһенен назлы, кадерле кызлык чагына кадәр алып киткәнгә, ул үзенең шул дәрәҗәдән бүгенге хәлгә төшәргә мәҗбүр булуын уйлап, шул дәрәҗә яшь түкте лә; моңача мисле[2] түкмәгән иде.

Бу яшьләр аны азрак җуаткан, җиңеләйткән иде. Ул үзен һәм башлаган фәүкыльгадә эшен тәмам аңлап, батырлыгына хәйран калмыш иде. Ышанасы килми... әллә бу төшемме? Әллә хыялмы?... дидер иде.

Ләкин ул хакыйкать иде. Ачы хакыйкать иде.

Хатыннар киемен ташлап, чиктән тыш кысып ачу белән күкрәген бәйләде. Әллә нигә аны бәйләгәндә ачуы, дошманлыгы килә иде.

---

[1] Ифтихар иткән – горурланган.

[2] Мисле – шул кадәр.

Үзе белән алып чыккан ирләр киемен киде дә, Алла... бисмиллаһ дип урыныннан торды. Атлый барды. Якын урыс авылына барып, шуннан ат яллап, Верхний Урал шәһәренә барачак иде. Бичара ялт-йолт тирә-ягына карана... килеп тоталар төсле тоела иде. Киемнәрен ташлау кыен булмаса да, чәчен калдыру уңайсыз булды. Аны әйләнеп карый, кабат барып аласы килә иде.

Аның янында акча бар иде. Авылның очындагы бик карт бер урысны яллап, максатына юнәлде. Аның татарча белүе Гөлбану өчен зур бер ганимәт булган кебек, картлыгы, начар күзлелеге дә куркуны киметә иде.

Шулай итеп, Гөлбану икенче кәррә качты. Фәкать бу качуы башкача булып, ул ялгыз илдән, ирдән генә түгел, бәлки бөтенләй хатынлык галәменнән югалды. Ул үзен Габдулла дип атаган иде. Фәтхия әбинең назлы, иркәле кызы Гөлбану табигатьнең хәлькатенә рәгъмән[1] ирләр сыйныфына күчеп яшеренергә мәҗбүр булды. Гөлбану Габдуллага әйләнде.

* * *

Габдулла Верхний Уралга килеп берәр төрле хезмәт эзләсә дә, көнлеккә табылмады. Айлап керергә урыннар булса да, шәһәр җирендә паспортсыз ялламаганга, дәхи керә алмады. Монда булмагач, ул якын бер башкорт авылының базарына барып, шунда бер башкортка кыш буена ялчылыкка ялланды. Эш-хезмәт йорттагы карны себерү, мал карау, урман, печән ташу кебекләр иде. Габдулланың кышы менә шул башкортта үтте. 23 еллык табигый Гөлбанулыкны дәфгатән[2] ташлап, җәгъли[3] Габдулла булып китү аңарга бик кыйммәт төшмеш иде.

Ул ирләр галәменә яңа аяк басканда да, соңрак та һәр заман, һәр минут бер-бер фаҗиганең очравыннан курка, үзен даими мохатарәдә[4] күрә иде. Аңарга тыныч вә куркусыз һичбер минут тору мөмкин түгел иде. Бер кеше аның йөзенә тугъры караса, ул бичара «ахрысы белде» дип ярыла... каушый, калтырый башлый иде. Көрәшү, кочаклашудан бик саклана иде. Һәрнәрсәдән бигрәк, башта күкрәген саклау бик мөшкел булды. Бер кешенең кулы ялгыш аның күкрәгенә бәрелсә, җаны чыгарга җитешә, «ахыры

[1] Хәлькатенә рәгъмән – яратуына (барлыкка китерүенә) каршы китеп.
[2] Дәфгатән – кинәт, көтмәгәндә.
[3] Җәгъли – ясалма, уйдырма.
[4] Мохатәрәдә – хәтәр, куркыныч янаган халәттә.

белендем... харап булам», дип коты чыга иде. Ул кеше алдында чишенми, якын ятмый, мунча керми иде. Җибәрсәләр дә барып утырып кына кайта иде. Кич йокларга соң ята, иртә тора, тәмам чишенеп ятмый иде. Йоклау аңарга бер һәлакәт төсле иде. Һәр ятуында «йокы арасында сизмәсәләр генә ярый иде», дип тели иде. Ничек тә ул бик тынычсыз вә фәүкыльгадә куркуда булып, һәр минут бер афәт, бер фаҗиганең чыгуыннан шикләнә иде. Йөз каплап, 22 ел хатынлыкта яшәгән бер кеше өчен бердәнбер ирләр галәменә атылып ияләшү дә җиңел булмады. Ул, кайбер вакыт ирләр гадәтен онытып, хатыннарча эшләп җибәрә иде. Хәтта Габдуллалыкны онытып китеп, капыл килеп чыккан ирләрдән йөзен каплап ташлаган чаклары да булгалый иде. Бу куркынычларның иң катысы, теге урыслар авылына барып, ат яллаган чаклары белән базарда урын эзләгән заманнары булды. Башкортка ялланып яңарак хезмәткә керешкән вакытларда да үзен даими бер һәлакәт каршысында хис кыла иде. Үзе белән фәүкыльгадә фаҗига арасында бик нечкә пәрдәдән башка бернәрсә дә юк кебек, бик аз нәрсә дә моны шул һәлакәт, афәт эченә ыргытырга җитәчәк кебек сизә иде.

Хосусан, башкортның 15 яшьлек бер угылының моңарга мөгамәләсе моның куркуын бигрәк арттыра иде. Ул малай моның тирәсеннән бер дә китми, форсат булган саен кочаклый, өстенә атлана, фәлән итә... ничек тә сынап йөргән төсле күренә иде. Ләкин монда Гөлбану курыккан афәтләр чыкмады, кыш буена ул шунда Габдулла булып яшәп, яз көне авылдагы егетләр белән кәсепкә чыгып китте.

Урман кисеп, бүрәнә өеп йөри торгач, ул Сакмар суына салбүрәнә агыза торган җирләргә килеп чыккан иде. Монда халык та күп, эш тә күп иде. Ул көненә 50–60 тиеннән ялланып, бераз йөргәннән соң башкортлар белән бергә кушылып, Сакмар суыннан Оренбургка сал белән барып чыкты.

Ул килгәндә монда бик күп халык эшли иде. Рус, татар, башкорт – һәрбере бар иде. Оренбург тәңгәлендә югарыдан агып килгән бүрәнәләрне туктату өчен канатлар ясалып, шуннан бүрәнәләрне ярга чыгаралар иде. Башка хезмәт күренмәгәнгә, Габдулла да шул кешеләр белән хезмәткә керешкән иде.

Ләкин монда аңарга саклану бик читен булды. Халык бик күп булып, тыгызлык иде. Бүрәнә артыннан суга кереп йөрелгәнгә, кешеләр ыштансыз йөриләр, көн эссе булганга, өскә дә ялгыз күлмәк кенә кияләр иде. Болар кигәнчә генә киенү Габдулла өчен мөмкин

түгел иде, ыштансыз йөрүнең һәлакәте аны бер минутта басачак булган кебек, ялгыз бер күлмәк белән йөргәндә дә күкрәкне саклап булмаячак иде. Халыкка караганда калын киенсә, шикләнерләр дип курка иде. Халык бушаган саен уйнап, көрәшеп торганга, ятканда чатырлар тыгыз булып бик якын ятылганга, аңарга фаҗига вә афәтләр бигрәк якынайган иде.

Көнозын багор белән бүрәнә тартып арыганга, ул кич бик изелеп йокларга мәҗбүр була... шунлыктан беленмәсә генә ярар иде дип, җаны чыга иде. Моннан китәргә теләсә дә, урынга керү өчен паспорты булмаганга, мойкаларда җон җуу башланганчы шунда йөрергә мәҗбүр булды.

Июньдә мойкалар хезмәткә керешкәч, ул моны бик ганимәт белеп, шунда күчте. Монда хакы барыбер, тегендәге кебек көненә 60–70 тиен чамасы иде. Акча ягы ул кадәр мөһим дә түгел, асыл матлуб – беленмәү иде. Ул бер дәрәҗә моңа муәффәкъ та булды. Монда да ирдән, хатыннан халык бик күп булса да, тегендәге кебек мохатарәдә булынмый иде. Ыштансыз йөрү, күлмәк кенә кию мәҗбүрияте монда юк иде. Ул ир булгач, ирләр хезмәтендә йөри, носилка ташый, капчык тутыра, ничек тә бергә тыгылынмый һәм сакланырга мөмкин була иде.

Кич йоклаудагы куркулар да азайган иде. Халыкның күбрәге кайтып киткәнгә, кич кунучылар аз була... урын бик иркен булып, җон арасында ялгызы да йоклап була иде. Бергә йоклаганда да тыгыз булмагач, саклану җиңел иде. Монда ир, кыз, егет бар да бергә болама булып, оят вә тәрбиянең һичбер булмавы, пычрак сүзләр генә түгел, пычрак гамәлләрнең дә яшерелмәве, ирләр җырткыч, хатыннар, гомумән, юмарт булып, бик киңлек хөкем сөрүе башта кыенрак төсле булса да, тиз арада өйрәнеп алар да бер гади эшләр булып калган иде. Ул үзе дә шул оятсыз егетләрнең берсе булырга тырыша иде. Башка егетләр кебек Габдулла да кызлар белән уйный, сөйләшә... үбә, кочаклый, аларны шаркылдатып кычкыртып ега да, җон арасында угалый иде. Бергә ята иде. Алар белән йөрешкән булып, кайсыларына алам дип вәгъдә дә бирә иде. Кызлар аңардан мәмнүн булып, тик бигрәк хайванлашканнары гына: «ул суфый... ул ирлексез», дип яманларга итәләр иде. Чөнки ул башкалар кебек...

Ул инде ничек тә белдермәскә тырыша иде. Хәзер яхшы ук ирләшкән дә иде. Кыенрак булса да, пычрак сүзне бик күп ычкындырырга, оятны ташларга, урыны белән аракысын, тәмәкесен

дә кире сукмаска өйрәнгән иде. Ул боларны һичбер теләмәсә дә, Габдуллалыкны исбат итәр өчен мәҗбүрән эшли иде. Ун сумга яхшы гармун да алып, шәпле егетләрне үз көенә биетә иде. Хәзер ул гармунны теге Күлбашы авылындагы кебек куркып, посып уйнамый иде. Никадәрле уйнаса да, сүз әйтүче юк, хәтта аның Габдуллалыгы шул гармун аркасында бигрәк исбат ителгәнгә, ул аз гына бушаса, гармунга тотына иде. Гармуны яхшы, үзе уйнарга оста булганга, ул моның белән бик җуана, күңелен күтәрә иде. Моңлы гармун аны җуаткан кебек, уйларын да бик ерак, бик тирән алып китә иде. Күп вакыт гармун тотуга аның назлы Гөлбану чаклары исенә төшеп, тауларда, аулак өйләрдә гел үзе кебек кызлар арасында иркәләнеп кенә уйнаулары, андагы җырлар, биюләр, сөйләшүләр, Зыя белән үбешүләр берәм-берәм күз алдына килә ашлый иде.

Зиһене хәят мазыясы[1] хакында уйга чумып ул шул дәрәҗәгә җитә: бу инкыйлабатка, бүгенге хәленә ышанасы килми... «Әллә бу төшемме?» дип уйлана иде. Башына килгән фәлакәтләр, тормышындагы үзгәрүләргә хәйран булып тора иде.

Ул кем иде? Назлы бер кыз иде. Назлана, иркәләнә, тирә-ягы да шундый кызлар белән тулы була иде.

Ә хәзер кем? Эчеп, исереп йөри торган Габдулла... Бөтен тирә-ягы фахиш вә фахишәләр белән тулы. Алдагы көне мәҗһүл... караңгы... дәһшәтле... һәр минутта зур бер афәтнең чыгу хәтәре бар... куркыныч... һәлакәт... никадәр аерма! Ул моны аңлый алмый, уйлап очына чыга алмый иде. Болар нидән? Боларны ни өчен күрә? Моңа катгый җавап бирә алмый иде.

Ул тыштан караганда шарт та март булып, бик шат күренергә тырышса да, аның эчендә утлар яна иде. Бик аз нәрсәләрдән дә мөтәэссир булып, тирән уйларга чума иде. Аның уйлары тәмсез һәм зәһәрле иде, өмете беткән иде. Киләчәген ни диеп тә тәгаен итә алмый иде.

Фәкать бер куркыныч караңгы истикъбаль[2] даимә үзенең дәһшәте белән хыялында гәүдәләнеп, аны тәһдид итә[3], калтырата иде. Ул киләчәктә нишли? Ни өчен бу хезмәтләрдә йөреп акча җыя? Максуд нәрсә?

---

[1] Хәят мазыясы – үткәндәге тормышы.

[2] Истикъбаль – киләчәк.

[3] Тәһдид итә – куркыта.

Болар хакында, мөгаен, бер җавап юк... мәҗһүл иде. Ник эшләгәнен, акча белән ни кылырга теләгәнен ул үзе дә белми иде. Тик торып булмый, кешеләр эшлиләр... менә шуның өчен ул да эшли иде.

Сабирадан, Закирдан, Солтан белән баладан котылуын, һәр эштә үзенең ирекле булуын уйлап шатлангаланса да, бу шатлыклар аңарга уйламаганнан гына килеп, озакка бармый, аны тагы бер яктан кайгы чиметә башлый, үзенең хәлен аңлап, ул тагы истикъбальнең дәһшәтеннән тетри башлый иде.

Ул нишләр? Ничек гомер итәр? Ул хәзер ни ир түгел... ни хатын түгел... Иргә бара алмый... чәче юк... һәм үзе теләми. Хатын ала алмый... чөнки табигать бирмәгән... димәк, аңарга гаилә тормышы мөмтәнигъдыр[1]. Ул шулай гомергә гаиләле тормышта изелер... гомергә шулай көнлекче һәм ялчы булып, кабергәчә шулай йөрер.

Гөнаһ шомлыгына каршы пәрдә ачылып, Гөлбанулык беленсә, анда нишләр? Ул һәлакәтне ничек күтәрер? Менә шул уйлар аның зиһененнән кичеп, ул үз-үзен югалтырлык әләм-изтыйрабка[2], көенечләргә чума иде.

Ян! Көй! Сызлан! Газап чик! Бет!

Гүя табигать аңарга шулай дип хөкем итеп, язмыш аны шул юл белән сөргән кебек хис кыла иде.

Кайбер вакыт «әллә илемә барыйм микән? Әллә тагын хатын булып яши башлыйм микән?» дигән уйлар да килгәли иде. Ләкин болар бик тиз югала иде. Хатынлыкта күргән авырлыкларны, зәһәрле Сабираның ажгыруы, исерек Закирның моны көчләп хатыны кылуы, изүе, бөтен халык моны гына сөйләп гаепләячәге, итагатьсезлек, ахмаклык белән төһмәт итеп[3] ике ел буена әллә нинди мөнкәрәт[4]вә мәгъшиятьтә[5] йөрегәндер дип ифтира кылачагы[6], чәчсезлеге, тагы әллә ниләр күз алдына килә дә, хатын булуның имтинагы[7] тәкаррер ителеп[8], бик кискен вә катгый карар

[1] Мөмтәнигъдыр – мөмкин булмаслык хәл.
[2] Әләм-изтыйрабка – кайгы-газапка.
[3] Төһмәт итеп– гаепләп.
[4] Мөнкәрәт – гөнаһ.
[5] Мәгъшиятьтә – фәхишәлектә.
[6] Ифтира кылачагы – яла ягачагы.
[7] Имтинагы – тыелуы.
[8] Тәкарер ителеп – хәл ителеп.

белән: «Юк, булмас... булмас!..» дип, урыныннан тора, бер эшкә ябыша иде.

Көз килеп, сулар туңып, мойкалар ябылганчы ул шунда хезмәт итте. Байтак акча да ясады.

Мойкалар ябылгач, күнлеккә керергә урын булмаганга, еллап, айлап керү өчен паспорт лязем булганга, ул хезмәт таба алмый аптырабрак йөри башлаган иде. Менә шулвакыт аңарга Сакмарда бергә хезмәт иткән бер татар егете очрап, Уфа ягына китәргә киңәш бирде: «Анда барыйк, бу ел ашлыклар да үскән, авыл җирендә урын булыр. Боярга булса да ялланырбыз», – диде. Бу сүз Габдуллага гаҗәп бер тәэсир бирмеш иде. Әллә нинди хисләрен уяндырып, күңелен шул якка мәел итмеш иде.

Эш вә хезмәттән бигрәк күңеленең мәеле, хиссиятенең көчләве өчен ул: «Әйдә, китәбез», – диде. Уфа ягы дигәч, туган илгә мәхәббәте артып, ихтыярсыз ауган иде. Шул дәрәҗә ки: «Барма! Монда кал! Яхшы урын бар!» – дисәләр дә, ул калачак түгел иде.

Егетләр модасы үзәренә: яңа кара чикмән, кечкенә кара бүрек, кызыл билбау, базар шарыфы, итек, күн бияләйдән гыйбарәт киемнәр ясап, култыкка гармунны алып, поезд белән Уфага юнәлде.

Йөрәге суга... күңеле курка... зиһене әллә ниләр уйлый... начар төшләр күрә иде.

Самара – Златоуст тимер юлында Уфага якын Дәүләкән дигән станциягә төштеләр. Анда базар иде. Тирә-яктан күп халык җыелган иде.

Иптәше бер урыска ялланды. Габдулла үзе Карылман дигән авылның Исмәгыйль исемле бер кешегә очрап, шуңа бер елга кучерлыкка керде.

Һәм китте.

## XIV

Карылман – Габдулланың туган-үскән иле Кулбашы авылыннан утыз чакрым ераклыкта зур гына бер авылдыр. Халкы усаллык, угрылык һәм шәкыйлык[1] белән мәшһүр булып, тирә-якта атаклыдыр. Габдулланы елга кучерлыкка яллаган Исмәгыйль исә шул авылның алдагы байларыннан иде. Йорт-җире, малы, игене яхшы булып, аның өстенә сату да итә иде. Яше 50 дә булып, ир

---

[1] Шәкыйлек – юлбасарлык.

баласы юк, өч кызы булса да, икесе кияүгә киткән, йортта фәкать 16 яшьлек кызы Нәфисә генә бар иде. Хатыны да карт булып, бу гаиләдә шул өч әгъзадан башка кеше юк иде. Авылда бер кибетләре бар, аның өстенә һәр атнада дүрт-биш җиргә чит авыл базарларына да сату белән бара иде. Габдулланы үзе белән базарга кучер булып йөрү өчен яллаган иде. Паспорт-фәлән соралмады. «Минзәлә ягынныкымын», дип, Габдулла тыныч кына хезмәт итә башлады.

Эшләр ике якка да муаффәкыятьле бара иде. Габдулла көчле, эшлекле булып, үткән кыш ирләр хезмәтендә, ат-арба тирәсендә йөргәнгә, Гөлбанулыкны сиздерерлек эшләми иде. Аңарга ватылып эшләрлек хезмәт тә юк иде. Ул үзләренең базарга йөри торган өлкән тимер арбага яхшы өч атны кыңгыраулап җигә, бае түргә, бу кучерга утырып төнен дә, көндез дә базарга китәләр, кайталар иде. Атларны җигү, тугару, ашату-эчертү, җуындыру, арбалар майлау – һәммәсе моның кулында иде. Арбага әрҗәләрне тутыру, бушату, кибеткә малны тарату, җыю да аның хезмәте иде. Кайбер вакыт авыррак нәрсәләр күтәрергә туры килсә дә, табигатьнең аңарга биргән көче моңа мөсагыйд иде[1].

Мондый урынның туры килүе аның өчен бер ганимәт булганга, ул бик иҗтиһад вә бик ихласы белән хезмәт кыла иде. Тырыша, көчен кызганмый иде. Угрылык, хыянәт кебек нәрсәләргә һичбер якын бармый иде. Үзе мәгъюб[2] кеше булганга, ничек тә ярарга тырыша иде. Аз гына бер заманда ул сатуга да өйрәнеп, Исмәгыйльгә могыйнлек[3] тә итә башлаган иде. Шулар аркасында Исмәгыйль үзе дә, хатыны да аны бик ярата, халык, гомумән, аны мактый иде. Ул кучерлар вә ялчылар арасында мөмтаз[4] иде.

Өйгә кайткан чакларда хатыннар эшенә катышып, үзенең бу эшләргә кулының ягымлыгы белән күргәннәрне хәйран итә иде. Аны күрүчеләр: «Син хатын булсаң, бигрәк оста булыр идең», – диләр иде. Аңарга монда Гөлбанулыкны яшерү дә тегендәге кебек үк кыен түгел иде. Үзе тәмам ирләшеп, күкрәге дә беленмәслек дәрәҗәдә кысылганга, йөзенә дә ирләрчә пәрдә капланганга,

[1] Мөсагыйд иде – мөмкинлек бирә иде.
[2] Мәгъюб – гаепле.
[3] Могыйн – ярдәмче.
[4] Мөмтаз – өстен.

сизелү ихтималы азайган иде. Үзе сүзгә оста, әллә ни кадәрле кызларны харап иткәнлеген ялганнан сөйләргә дә өйрәнгән иде. Гармунга шәплеге, өстендәге киемнәренең яхшылыгы, үзенең үткенлеге аны авыл егетләре арасына кертә, аларның илтифатын җәлеп кыла иде.

Ул базарга бармаган кичләрдә, төнне егетләр белән урамда йөрергә чыга, анда гармун уйный, бии, сикерә иде. Аның кулыннан кызлар да котылмый иде. Ул алар белән шаяра, каш сикертә, күз кыса... аулакта үбә... кочаклый... угалый иде. Кайсылары белән йөрешеп, бүләкләр дә бирә иде. Ләкин кызларны күрү, катышу аның үзенең назлы кызлыгын искә төшереп, ул кызларны мәсгуд төсле күрә, үзе шулар кебек тоела иде. Егетләр арасында чибәрлек, үткенлек, яхшы киемлелек белән алда булганга, кызлар аны яраталар, аның тәнен, кулын башка егетләрдән йомшак һәм сөемле күрәләр иде. Күп кешеләр аны Исмәгыйльнең кызы Нәфисә белән йөри, имеш, дип сөйлиләр иде: «Ул үткен егет, әйләндерми калмас», диләр иде.

Вакыйган, Нәфисәнең дә бу матур, сөемле егеткә мәеле юк түгел иде. Халыкның бу шөбһәсе Гөлбанулыкны бер дә сизмәүләрен белдергәнгә, Габдулла моңардан шатлана һәм шуның дәвамын тели иде.

Болар Габдулланың зиһенендәге мохатарәне[1] азайтканга, ул монда тынычрак яшәде, һәр эш аңарга мөмкин иде. Саклану аз иде. Фәкать су керү, кеше белән мунча керү, тәмам чишенеп йоклау гына мәмнүгъ[2] иде. Дикъкате азайган, калынлык баскан халык аны бер дә сизмәделәр, һичкем шул егет эчендә бер кыз йөрегәнне уйлый алмады.

Ул ничә кәррә үзенең туган авылы Күлбашыннан үтте. Ничә кәррә анда кунгалады. Базарларда үзе белән бергә үскән егетләрне, алырга вәгъдәләшкән Зыяны күрде. Атасына һәм иренә дә бик күп очрады. Аларга товарлар үлчәп бирде, һәм башка кешеләр белән дә очрашты. Сөйләште. Ләкин һичбере сизмәде. Гөлбану дип уйламады. Чөнки алар уйлары белән аны кабергә тykканнар иде. Башка кешеләр белән очрашу аңарга әйтерлек бер тәэсир бирмәсә дә, атасы, ире һәм Зыя белән очрашу аңарда бик көчле үзгәреш ясый иде.

---

[1] Мохатарәне – куркынычны.

[2] Мәмнүгъ – тыелган.

Ире Закирга очраса ачуы, дошманлыгы кузгала... аңардан үч аласы, бер-бер сәбәп чыгарып кыйныйсы, изәсе килә иде. Ләкин муәффәкъ була алмады. Тик чабата һәм аркан алганда гына: «Беркөнгеләрең бернигә ярамады... начар булды... кулың чергәнмени яхшылап эшләмәскә...» – дип сүгенә башлый. Кулына аның нәрсәсен тотып, ачу белән: «Ирлегең корысын!.. Шулай эшлиләр мени?!» – дип яманлый иде.

Атасы очраса, аны кызгана, тәне эсселе-суыклы булып, әллә нинди хисләр кузгала иде. Тәэсиреннән аның йөзенә тугъры карарга, аның белән сөйләшергә дә курка иде. Бәгъзе вакытларда шулай карый торгач, үзен югалтып, базардалыгын онытып, катып та кала иде.

Зыяга очрау тагы башка төрле тәэсир итә иде. Бу аның кыз чакларын, Зыя белән йөрешү, үбешүләрен искә төшереп, аның «мин сине алам», дигән сүзе әле дә колагына ишетелгән кебек була иде. Зиһененә төрле уйлар килеп: «Зыяга барсам, мин бу һәлакәтне күрмәс идем», дигән фикер төшә дә, йомшарып үз-үзен еглаудан бик чак тыеп кала иде.

Авылларыннан узган чакта ул бичара өйләрен бик ерактан карый башлап, үтеп киткәннән соң да, әйләнеп-әйләнеп карый иде. Хосусан, тәрәзәдән, капкадан әнисе Фәтхия карчык карап калса, ул шул дәрәҗәдә әсәрләнә иде ки: үзе кучердан егылып, кулындагы дилбегәләрнең төшеп китүеннән бик кыенлык белән сакланып кала иде. Моннан үтү, гомумән, изгеч һәм авыр тоела иде.

Тыштан караганда ул уен-көлке, бию, сикерү эчендә йөзсә дә, шулар белән гомер үткәрсә дә, аның эчендә бөтенләй башка галәм иде.

Анда дүзәх[1]... тәмуг... иде.

## XV

Исмәгыйльгә ялланулына ел ярым булган иде. Габдулланың тормышында дәхи бер инкыйлап баш күрсәтте. Исмәгыйль үзе авырып вафат булмыш иде. Габдулла шул ел ярымлык гомерендә боларга яраган иде. Аның һәр эшкә булдыклылыгы, хыянәт вә угрылык кебек нәрсәләргә якын бармавы, тәүфыйк вә әхлагының яхшылыгы үзен сөйдергән иде.

---

[1] Дүзәх – җәһәннәм.

Исмәгыйль үлгәннән соң аның хатыны һәм якыннары Габдулланы үзләренә кияү ясап кызларын бирергә, сәүдә вә йортка хуҗа кылырга уйладылар.

Һәр ягы яхшы, өйрәнгән, белгән кеше булганга, аның кебек яраклы башка егетләр күренмәгәнгә, болар Нәфисәгә кияүлеккә аны бик мөстәхыйк[1] таптылар. Ярлы бер егетнең шул малга, шул кызга мәмнүният белән риза булуында шөбһәләре юк иде. Мәсьәләне бик җиддият белән Габдуллага белдерделәр. Ул бик шатлык белән кабул итеп, хәтта арага икенче кешенең төшүеннән курыккан сыман, киная белән генә эшнең ашыгуын теләгәнен белдерде. Карар бирелде. Габдулла кул бирде. Вәгъдә булды.

Борыннан яратып йөргән матур егет Габдуллага бирелүеннән Нәфисә бик шат иде. Аулакта Габдулла белән илтифат белән сөйләшүдән дә, үбешүдән дә тартынмый башлаган иде. Һәркем шат, һәркем күңелле, Габдулла исә һәммә кешедән дә шат күренә иде.

Эш бетеп, алты көннән зөфаф булуы да тәгаен ителмеш иде.

Инде нишләргә?

Бу сөаль Габдулланың зиһенендә бик озак әйләнде. Ниһаять, аңа «качудан башка котылып булмый», дип җавап бирелде. Рәд кылса,[2] шундый бай һәм матур кызны нигә алмады? дип шикләнүләреннән курыкканга, Габдулла Нәфисәне кабул итсә дә, эш бу ноктага җиткәч, качудан башка чарасы калмаган иде. Ул аңа өйрәнгән... инде бусы өченче буладыр. Исмәгыйльнең хатынына киңәш итте дә, ат-арба җигеп: «Атама акча салам... хәбәр бирәм... киемнәр алам», – дип, Эстәрлегә юнәлде. Максуд: Эстәрлетамакка барып, аннан шоссе юлы белән Оренбургка чыкмак, анда ат-арбаны сатып, поезд белән дәхи икенче якка китмәк иде. Шул уй белән чыгып, юлда аталары авылыннан үтәргә туры килде. Көн кич иде. Бик караңгы булып, яңгыр да ява, юллар бик пычрак иде. Ул бу авылда кунмый чыгып китәргә уйласа да, күңеле курка, әллә нәрсә булыр төсле тоела иде, Юлга чыгарга шикләнә, эче поша, йөрәге суга иде.

Ни булса да булды. Ул үзен Күлбашыннан алып чыга алмады. Кунарга мәҗбүр күреп, берәүдән фатир сорады. Ул ярлы һәм кечкенә йортлы бер кеше иде. «Без төшермибез... сезнең кебек

[1] Мөстәхыйк – лаеклы.

[2] Рәд кылса – кире какса.

юлчылар әнә Нурый картка төшәләр, шунда бар!» – диде. Нурый карт кем? Атасы түгелме? Димәк атасына һәм үзенең туган-үскән йортына төшәргә киңәш бирәләр.

Йөрәге суга... каны кайный... ни кылырга аптырый башлады. Зиһененә төрле уйлар килде: «Нишләргә? Аларга керсәм, танымасларммы? Әллә кабат юлга чыгыйммы? Әллә булмаса, икенче кешедән фатир сорыйммы? Белерләр төсле дә була... Шулкадәрле очрашып танымаганны, бүген генә нишләп таный алсыннар», – дип тә уйлый иде. Инде бәлки бу хафизәи хатирәт[1] булган мөкатдәс авылга мәңге килә алмау ихтималлары аны кунарга көчли, пәрдә ачылу куркусы атасына бармаска өнди иде. Ниһаять, ул әллә нәрсәнең көчләве белән башка җиргә китә алмады. Нәрсәдер аны җибәрмәде. Ул аталарына кереп кунды. Нурый да, угыллары да өйдә юк иде. Ялгызы гына чәй эчте дә, йокларга ятты. Ах, хәзерге уйлар... хәзерге хисләр әллә нинди иде! Гомерендә бер кәррә булмаган халәтләр хәзер аңарга килде. Табигыйлек бетте. Ул шул дәрәҗәдә уйга вә хыялга чумган иде ки, төн буена бер генә минут та йоклый алмады. Өйдәгеләр соң торды. Ул озын төнне үткәрә алмый җөдәп чыкмыш иде. Китәргә ашыга... тотып алып калырлар төсле тоела иде. Иртә белән Габдуллага чәй ясап эчерергә Фәтхия әби үзе утырды. Габдулла моңардан бик мөтәәссир булды. Аның йөзенә тугъры карарга курка иде. Анасының йөзе аңарга бигрәк аяныч вә бигрәк үзгәргән, анасы вакытыннан әүвәл картайган төсле күренде. Фәтхия әбинең җыерчыкланган бите, эчкә баткан күзләре аны кызгандыра, йөзендәге күп еглаганнарда була торган аяулы күренеш аны бигрәк мазлум вә бигрәк шаян[2] мәрхәмәт күрсәтә иде. Әлбәттә, тик торып булмый. Сүз башланды. Юмарт карчык күп нәрсәләр сөйләде. Сүздән сүз чыгып, үзенең иң бөек кайгысы итеп, Фәтхия әби үзенең бердәнбер кызы югалып, өч елдан бирле һич хәбәре булмаганын да әйтте. Сүз бу мәсьәләгә кергәч, Фәтхия әбидән бигрәк Габдулла бозылды. Хосусан, Фәтхия әбинең саргылт йөзеннән күз яшьләре тәгәри-тәгәри вә бик моң вә хәсрәт белән: «Бигрәк ярата идем... һаман шуны уйлыйм... сагынам... саргаям, беттем», – дип өзелеп чыккан сүзләре аның түзәрлек тәкатен бетерә иде. Үзенең иң сөекле вә иң мөкатдәс булган анасының үзе өчен каршында еглап утырганын күрү аны шул дәрәҗә

---

[1] Хафизәи хатирәт – күңелдә саклanучы, истәлек.
[2] Шаян – тиешле дәрәҗәдә.

мөтәэссир кылды ки, күңеле тулып күзләренә һөҗүм иткән яшь туфанын ул мең бәла белән генә басып калды. Аның төсе үзгәргән, тавышы һәм хәрәкәте башкарып, үзе авыр, басынкы вә мәгълүб булып[1] калган иде. Теле багъланып, рәтле сүз дә чыкмый, чыкса да еглап җибәрүеннән курка иде. Тамагында әллә нинди бер төер бар кебек иде. Нишләргә дә аптырады. Күңеленә төрле уйлар килде. Каршысында үзе өчен еглап торган анасының хәлен кызганып: «Җаным, анам! Еглама! Өзелмә! Гөлбануың алдыңда, мин синең кызың!» – дип, анасының муенына асылырга уйлады. Шул сүзләр тел очына килеп кочаклау өчен урыныннан кузгала башлагач, тагы туктап кала иде. Башында чәче юк... үзе әллә ничә ел әллә кайда йөргән... качкын... алдар... ялганчы... итагатьсез булган... Халык әллә ни сөйләр. Сүгәр... гаепләр! Закир көчләр. Тагы зур фаҗигаләр чыгар... Хәзергедән яман хурлыкларга төшәр... Их! Менә шул уйлар аның зиһененнән кичеп туктата... һаман шул Габдулла булып калырга өнди. Хәзер аның өчен Гөлбанулыктан Габдуллалык уңайрак булыр төсле тоела башлый иде. Чәй эчелеп бетте. Яңгыр бик шәп коя иде. Урам ап-ак су булганга, ат җигеп чыгарлык түгел иде. Шуның өчен ул бераз кичегергә мәҗбүр иде. Ул хәзер бик бетеренгән... мөхакәмәсен җуйган иде. Янып-көеп һаман шул уйда утырды. Хиссияте забытсыз[2], уйлары юлсыз иде. Бу өй аның туган-үскән җире булып, эчендәге һәр нәрсә аның кыз вә Гөлбану чакларын аңдыра иде. Яшьлек хатирәсе мөкәммәлән шул мөкатдәс өйдә сакланганга, күзе ни нәрсәгә төшсә, ул шуңа мөнәсәбәтле бер вакыйганы күз алдында күреп, тирән уйга чумарга мәҗбүр була иде. Хатирәләр бер-бер артлы күз алдына тезелеп килеп, зиһене шуларны тәгъкыйб итә торгач үзен оныта... югала иде. Һәр нәрсә, һәр күренеш аңа бертөрле хис, бер төрле тәэсир биреп, ул торган саен югала гына, ихтыярын бетерә генә бара иде. Аның әле бер якка, әле икенче якка карап уйга чумуы аның йөзендә «мин бу нәрсәләрне таныйм», дигән бер күренеш чыгара иде. Ул тәмам үзгәреп, изелеп, гайре табигый вә мөтәэссир төскә кергән иде. Аның йөзенә караган кешенең күңеленә ихтыярсыз ук: «Моңа ни булган?» сөале киләчәк иде. Тәгаҗҗеп итәрлек иде. Вакыйган, бу шулай да булды. Килгән бер ирне чаршау аркылы карап, матур булса, сокланып тормак гадәтләреннән булган хатыннар матур егет

---

[1] Мәгълүб булып – җиңелеп, изелеп.

[2] Хиссияте забытсыз – хисләре үзенә буйсындырылмаган.

Габдулланы да бик озак сокланып караганнар иде. Аның йөзендә вә бөтен әхвәлендәге гайре табигыйлекне алар кызык итте. «Ник бу кадәрле кайгылы икән бу?» – дип кызганыштылар. Йорттагы киленнәр дә, кызлар да, күршедән кергән хатыннар да бу матур һәм кайгылы егетне озак-озак карап чыгалар иде. Һәркем аңардан бер-бер нәрсә сизә, бер гаҗәп дип уйлана иде. Шул хатыннардан берсе: «Бичара, Гөлбануга охшаган», – диде. Башкалары да моны тасдыйк итеп: «Алай, әй! Адәм бу чикле охшар икән!» – диешteләр. Бераздан соң җиңел гакыллы вә җөзаф[1] сөйли торган бер хатын: «Әйгенәм! Әллә бу Гөлбану микән? Бигрәк охшый бит...» – диде. Моңардан һәммәсе кычкырып көлде, һәммәсе дә беравыздан: «Закир кыйнап үтергән Гөлбану терелеп кайтмас инде», – диделәр. Арадан бер хатын бигрәк юкка чыгарып: «Сөйлисең Алла язмаганны! Шул Гөлбану була микән? Ул бит хатын, ә бу – ир», – диде.

Бу сүз теге Гөлбану түгелме дигән хатынның киберенә[2] тукынмыш иде. Ул сүзен куәтләү өчен: «Гөлбануның үтерелүе билгеле түгел бит, кем белә аны, әллә ул качкандыр, – дәхи дәвам итеп, – борын заманда җиде кыз ирләр сурәтендә йөргәннәр бит. Шулар кебек булмасын дим», – диде.

Бу сүз бөтен хатынны шөбһәгә төшергән иде. Аларның күңелендә «әллә чынлап ук шул булыр микән?» сөале урын алды. Алар хәзер чын дикъкать вә җиддият белән карый башладылар. Икенче хатыннар кереп, алар да бу шөбһәгә кушылдылар.

Тышта һаман яңгыр ява иде. Габдулла әүвәлгечә мозтариб[3], мотаәләм[4] вә гайре табигый сыйфатта иде.

«Мин бу нәрсәләрне таныйм» дигәндәй, һаман күзләрен тутырып-тутырып тирә-якка карый да уйга чума иде.

Үзен һаман забыт итә[5] алганы юк иде. Бераздан соң Фәтхия әби кереп, шөбһәне аңарга да белдерделәр. Ул шашып китте. Күзләре начарайган иде. Танып түгел, бәлки өмет белән: «Чынлап ук охшый бит»,– диде. Хатыннар Габдулланың йөзен, күзен, кашын, авызын, борынын, хасил, һәрбер әгъзасын, буен, гәүдәсен тәмам

---

[1] Җөзаф – үлчәүсез.
[2] Кибер – һавалану, тәкәбберләнү, үзен зур күрү.
[3] Мозтариб – аптырауда калган, тетрәнгән.
[4] Мотаәләм – кайгы-хәсрәткә бирелгән.
[5] Забыт итә – кулга ала, җиңә.

охшаттылар. Үзләренең хафизәсендәге[1] Гөлбану белән шул егет арасында тәмам берлек таптылар. Бөтенләй Гөлбану кебек, тик өстән бер пәрдә генә капланган кебек иде. Хосусан аның битендәге миңе аларга бер куәтле дәлил булды. Гөлбану яшь чагында бит алмасына инә белән кара җеп кертеп калдырган, шул җептән матур гына миң ясалган иде. Габдуллада да шул миңне күргәч, ышанулары дәхи артты. Байтак заман караган, тикшергәннән соң, арадан бер хатын: «Валлаһи шул», – диде. Моңарга һич кем җавап бирмәде. Чөнки алар шул булыр дип ышанганнар иде. Үзара шыпыртын гына сүз башланды. Сөйләшеп: «шул, шул», диештеләр. Ләкин һәммәсе дә каушаган иде. Мәсьәләнең чынын белергә, пәрдәне ничек ачарга аптырадылар. Бер хатын Фәтхия карчыкка карап: «Мунчагыз яккан бит... кереп чыгарга үтенегез! Шунда белеп булмасмы!» – диде. Моны мәгъкуль күрделәр. Фәтхия әби Габдулла янына чыкты да, мазлумәнә бер тавыш белән ялынып кына: «Угылым, яңгыр да бик ява... барыбер китә алмыйсың, бар, мунча кереп чык!» – диде. Үз алдына килеп кызганыч йөзе, егълаган вә мазлумәнә тавышы белән анасы тарафыннан әйтелгән бу сүз, бу үтенеч Габдуллага хаким мотлак вә әмер катыйгъ[2] булып, аның җанына үтә китте. Каршы торырлык куәт калдырмады. Моның ни сүз вә ни нәрсә икәнен яхшы төшенмичә үк ихтыярсыз: «Ярар, әби», – диде. Ул мөхакәмәсен җуйган, анасының кыяфәте, сүзе аның үзендә куәт вә ихтыярын бетереп, мәхкүм ясаган иде. Бу эштән тууы ихтимал булган нәрсәләрне уйлый, сизә алмаенча, мунчага барып керде.

Мунча аңарга бәгъзе бер мөһим хатирәләрне күз алдына китермеш иде. Ул кыз чагында үзенең дусты Камилә белән аталарыннан качып шул мунчада курай һәм кубыз уйный иде. Аның утырган урыннары, ләүкәләре әле дә һаман борынгыча иде. Шулар зиһененә килеп, хәйран булып торды. Чишенмичә бераз утырып кына чыгарга уйласа да, тиздән мунча керә алмау ихтималы, тагы әллә нинди уйлар аны чишендерде. Ул мунчаның түренә арка терәп аякларын ишеккә таба сузып утырды да, су белән уйнаган кебек, бик ялкау гына, акрын гына җуына башлады. Зиһене Закир белән иң әүвәл кергән мунчасын уйлау белән мәшгуль иде.

---

[1] Хафизәсендәге – хәтерләрендәге.
[2] Хаким мотлак вә әмер катыйгъ – обсолют хуҗа һәм боерык кебек.

* * *

Берничә минут үткән иде.

Баягы җиңел гакыллы хатыннардан икесе аяк очы белән генә басып, бер дә белдерми генә килделәр дә, бик тиз ишекне ачып мунчага керделәр. Ни күрсеннәр? Аләтеннәсел[1] һәм күкрәк ярылып ята... һәрнәрсә ап-ачык күренде. Ах, харап булды... эш бетте... пәрдә ачылды. Исмәгыйль кызын алырга вәгъдә биреп, алты көннән зөфафка керергә карар биргән егет үзе хатын булып чыкты.

Хакыйкать халь мәгълүм булды.

Кара бүрек, чикмән һәм итек кигән вә билбау бәйләгән Габдулла исемле сурәт эчендә Фәтхия әбинең күз яше, назлы вә кадерле кызы Гөлбану килеп чыгып, авылны һәм бөтен тирә-якны хәйранга калдырды.

Тәмам.

**Искәрмә һәм аңлатмалар**

1* *«Йосыф китабы»* – XII гасыр азагы һәм XIII гасыр башында яшәгән мәшһүр шагыйрь Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы. Бу әсәр Болгар чоры әдәбияты җәүһәрләреннән берсе, татарлар арасында иң киң таралган һәм яратып укылган әсәрләрдән санала.

2* *«Мөхәммәдия»* – төрек шагыйре Мөхәммәт Чәләби Язычы угылы (1451/52 елда үлгән) тарафыннан төзелгән көйле әсәр. Эчтәлеге Мөхәммәт пәйгамбәр һәм мөселманнар турындагы дини-әхлакый хикәятләрдән гыйбарәт. Китап төрки халыклар, шул исәптән татарлар арасында киң таралган, аны җыелышып көйләп укый торган булганнар.

3* *Адәмнең бодай ашап җәннәттән куылганын...* – дини әдәбиятта аерым алганда «Кыйссасел-әнбия»дә, шулай ук халык арасында таралган риваятьләргә һәм хәдисләргә караганда, Аллаһ Адәмне, үзенә охшатып, «үз сурәтендә» яраткан. Адәмнең кабыргасыннан беренче хатын-кыз Хаува яратыла. Алар башта җәннәттә яшиләр. Коръән аңлатмасы буенча, Адәм белән Хаува оҗмах эчендә үскән (әмма аларга рөхсәт ителмәгән) агачның җимешен ашап «гөнаһлы» булалар. Шуның өчен Аллаһ аларны оҗмахтан сөрә. Җиргә төшеп яши башлагач, алардан кешелек башланып китә. Раббыбыз Адәмне, гафу итеп, туры юлга юнәлтә. Шуннан башлап Адәм Аллаһның җирдәге илчесе, беренче пәйгамбәре санала.

---

[1] Аләтеннәсел – нәсел арттыру әйбере, җенес әгъзасы.

4* *Хәзрәте Галинең ...* – Гали ибн Әбүталип (661 елда үлгән). Мөхәммәт пәйгамбәрнең тарафдары, иң якын көрәштәше-фикердәше, Фатыйма исемле кызының кияве. Ул Мөхәммәт җитәкчелегендәге барлык сугышларда диярлек катнаша, кыюлыгы һәм батырлыгы белән дан тота. Урта гасырлар язма әдәбиятының шактый популяр, билгеле бер дәрәҗәдә мификлаштырылган персонажларыннан берсе. Заманнар үтү белән халык арасында фантастик геройга, гадәттән тыш куәтлелек символына әйләнгән. Биредә сүз хәзрәте Гали турындагы дини-фантастик риваятьләр турында бара.

5* *Әбүгалисинаның фокусларын...* – Әбү Гали Хөсәен ибне Габдулла (Ибне Сина 980–1037). Урта Азиянең (Бохара өлкәсендә туган) бөек энциклопедист галиме, Көнчыгышның, гомумән, ислам галәменең мәшһүр философы һәм табибы, астроном шагыйрь, музыкант. Аның трактатлары бөтен дөньяда шөһрәт казанган. Аның турында халык арасында йөргән күп санлы фантастик риваятьләргә нигезләнеп төрек телендә «Әбүгалисина» дигән китап та чыгарганнар. Китап төрек телендә килеш 1864 елда Казанда басылган. 1872 елда бу әсәрне К. Насыйри татарчага тәрҗемә итеп укучылар хозурына ирештерә. Китап, әлбәттә, бик тиз таралып (1900 елга кадәр ул биш мәртәбә кабат басыла) халыкта зур кызыксыну уяткан һәм яратып укылган. Әбүгалисина төрле могъҗиза һәм фокусларга – күз буу (гипноз), кинәт кенә юкка чыга алу сәләтенә ия, ул рәмел тактасына карап кешенең киләчәге турында хәбәр бирү осталыгына да, сихергә дә махир булган имеш, дигән фаразларны аңа тәгаенләп телдән-телгә дә сөйләп йөргәннәр.

6* *... халык диңгезе Муса таягы белән суккан чактагы кебек ике якка ярылды ...* – дини риваятьләр буенча Муса галәйһи вәссәлам энесе Һарун белән үзләрен эзәрлекләп килүче Фиргавен гаскәреннән качып барганда юлларында зур су очрый. Муса пәйгамбәр кулындагы могъҗизалы таягы белән суккач, дәрья ике якка аерылып, уртада юл ачыла, шул юлдан энесе белән Муса дәрья аркылы чыгып өлгерәләр. Артларыннан куып килүче Фиргавен гаскәре исә суга кергәч, дәрья суы яңадан кушыла, дошман гаскәре шул рәвешле суга батып һәлак була.

*Текстны, кереш, искәрмә һәм аңлатмаларны басмага*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының текстология бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты*
*Әнисә Алиева әзерләде.*

# ӘДИП ПУБЛИЦИСТИКАСЫ

Г. Ибраһимовның әдәби әсәрләре, гыйльми хезмәтләре, мәкаләләре үз заманының иҗтимагый-сәяси фикер көрәшен гәүдәләндерү белән бергә, бүгенге тормышыбызны да тирәнрәк аңларга, милләтебезнең үткәненә, бүгенгесенә һәм киләчәгенә нисбәтле уй-фикерләребезне ачыклауга хезмәт итәрдәй хосусиятләрен югалтмыйлар.

Г. Ибраһимов әдәбият-матбугат мәйданында актив иҗат итүчеләрнең берсе була. Аның каләме матур әдәбият, әдәбият мәсьәләләре, тел, тарих, педагогика өлкәләрендә дә бердәй кыю тибрәнә. Тынгысыз җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе булуы аны үтә сизгер публицист итеп тә формалаштыра.

Г. Ибраһимовның әдип буларак та, журналист-публицист буларак та иҗат юлы шәкертләр газетасы «Әлислах»тан башлана. Ул «Әлислах»ның Уфадагы үзхәбәрчесенә әйләнә. Алга таба аның төрле мәктәп-мәдрәсәләр турындагы мәкаләләре бер-бер артлы «Йолдыз», «Вакыт» газеталарында, «Аң» журналы битләрендә дөнья күрә. Ул вакытта татар мәдрәсәләре заман таләпләренә җавап бирерлек булмаганлыктан, эзләнүчән табигатьле Ибраһимов үзенең каләме белән аларга каршы көрәшкә күтәрелә.

Октябрь инкыйлабыннан соң Г. Ибраһимовның фикер үсешендә яңа этап башлана. Аның тормышны ныклап өйрәнүе, илдәге зур иҗтимагый-сәяси вакыйгалар эчендә кайнавы нәтиҗәсендә дөньяга карашы көннән-көн киңәя һәм тирәнәя бара. Ул яңа җәмгыять төзүгә тугрылыклы хезмәт итә. Әдәбият һәм сәнгатьнең роле, язучының дөньяга карашы, иҗат методы, әдәби осталык, үткәндәге мираска мөнәсәбәт һәм әдәбиятның сыйнфыйлыгы мәсьәләләренә дә зур игътибар бирә.

Г. Ибраһимовның бай мирасын туплау һәм өйрәнү, басмаларын әзерләү эшенә үзе исән вакытта ук керешелә.1929–1931, 1933–1934, 1936, 1956–1957 елларда аның әдәби әсәрләрен генә эченә алган басмалары, 1974–1987 елларда күпчелек әдәби әсәрләрен, әдәбият, сәнгать, тарих, тел мәсьәләләренә багышланган мәкаләләрен һәм хезмәтләрен, публицистикасын, хатларын эченә алган сигез томлы «Әсәрләр»е дөнья күрә. 2000 елда әдипнең хатларын, аңа кагылышлы документларын эченә алган тугызынчы том нәшер ителә.

Бүгенге көндә тугызтомлык иң тулысы дип саналса да, күренекле әдип һәм галимнең әлегә кадәр фәнни әйләнешкә кертелмәгән әсәрләре, мәкаләләре, хезмәтләре шактый. Аларның кайберләре идеологик күзлектән карап кыскартылган яки бөтенләй томга кертелмәгән. Шуны истә тотып, институтның текстология бүлеге хезмәткәрләре Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 15 томлык басмасын әзерләү белән шөгыльләнә.

Эш барышында табылган моңа кадәр басылмаган кайбер мәкаләләрне укучыларга тәкъдим итәбез.

Текстлар хәзерге орфография һәм пунктуация кагыйдәләренә туры китереп бирелде. Ләкин ул иҗат иткән чорга хас тел-стиль үзенчәлекләре сакланды.

## Шәкертләр һәм уку

Мәктәп, мәдрәсә вә шәкертләр әхвалене ислях хакында татар гәзитәләре бу соңгы көннәрдә бик җиңел юл таптылар. Һәммәсе дә: «Татар мәдрәсәләреннән эш чыгу ихтималы юк. Хөкүмәт мәктәпләренә керергә кирәк», – диләр. Бу фикер тугры. Вакыйган, шулай тиеш. Фәкать бу фикернең тугрылыгыны кулына гәзитә алып укырлык истигъдады[1] булган һәркем үзе үк белә. Гәзитәдән укымаса да, гыйлем мәгърифәт мөхибе[2] булган шәкертләр рус мәктәбенә керергә җан ата. Шуның өчен мин гәзитәләрнең бу сүзене бер җитди, бер файдалы сүз, дия алмыйм. «Рус мәктәбенә керү» – хәзерге татар шәкерте моны гәзитә мөхәрриреннән башка да белә.

Фәкать чара юк. Мөмкин түгел. Бердән, картайганнар, бердән, финанс абзый ирек бирми. Хәзерлек юк. Мин, мөхәррирләрнең бу сүзене тәкрарлап, башка һичбер чара, юл бәян итмәенчә калуларына карап: «Әй, шул һәркем тарафыннан әллә кайчан мәкъбүл булган[3] бер фикерне тәкъдим итү сезгә асат, төрлечә уйлап, баш авырттырасыңыз юк», – диясем килә.

Рус мәктәбенә керүне аны күпләр белде инде. Хәзер анда керүгә өндәүдән бигрәк, керергә тырышып та чара таба алмаганнарга ярдәм бирергә кирәк.

Ничек итеп, матди вә мәгънәви җәһәттән хәзерләп, яшьләрне русча укытырга? Русчага керәсе килгән яшьләрне ничек теләкләренә ирештерергә? Аларга кайдан акча табарга? Ничек хәзерләргә? Матбугат менә шуны тикшерсен. Шул хакта ярдәм бирсен.

Сез әйтәсез: «Татар мәктәбендә файда юк, рус мәктәбенә кереңез», – дип. Сезнең бу сүзеңезә каршы яшьләр, шәкертләр әйтә: «Без аны сездән башка да беләмез, ләкин мөмкин түгел, акча юк,

---

[1] Истигъдады – сәләтлелеге.
[2] Мөхибе – дусты.
[3] Мәкъбүл булган – кабул ителгән.

яшь үткән. Хосусый сурәттә хәзерләнергә акча табылмый. Сез менә шуңарга чара табыңыз», – диләр.

Вакыйган[1], яшьләр өчен, укучылар өчен чынлап кайгырылса, шул ноктаны тикшерергә, укучы яшьләргә ярдәм итәргә чара эзләргә кирәк. Матбугат шуны күрсәтсен.

Андый бер игътираздан[2] имин булган фикерне тәкрарлап, башкадан күз йоммасын! Безнең татарның канына сеңгән: «Бер эшне кызу-кызу башлап та, тәмам итмәенчә ташлау гадәте». Әле менә бу көннәрдә татар мөхәррирләрендә гәзитә сәхифәләрендә күренә башлады: исляхе мәдарис[3] лөзүмне, мәдрәсәләрдән заманга ярашлы тәрбия бирүне тиеш күреп яздылар, яздылар да, хәзер инде, юк, дини мәдрәсәләр әһәмиятсез, алардан эш чыкмый, дип, алар хакында фикер йөртүдән дә ваз кичтеләр. Бичара татар шәкертләренә мөмкин булмаган бер эшкә тәкълиф итәргә керештеләр.

Менә сезгә үземезнең шәкертләр гәзитәсе вә хәзерге татар шәкертләрене кызганучы «Әлислах»ымызның 40 нчы номерына караңыз! 7 нче сәхифәдә «Ислях мәсьәләсе»ндә «Әфәнде» әйтә: Хәзерге мәдрәсәләрне дини итеп ислях бик ансат булдыгыннан һәм дини итеп ислях кылынган мәдрәсәләрнең «тереклек көрәшендә» һичбер әһәмияте булмаячагыннан мин дини итеп ислях хакында сүз озайтмыйм», – ди.

«Әфәнде»нең бу сүзләрене күргәч: «Әфәндем! Син әллә үзеңне французлар галәмендә хыял итеп, бу сүзләрне франса халкына карап сөйлисеңме? Татарның әхвале руханиясене дин вә руханилар татар галәмендә, татар тормышында ни дәрәҗәдә көчле хөкем сөреп, иң бөек рольне уйнадыгыны хәтереңнән чыгардыңмы?» – диясем килде.

Әгәр татар халкының дингә карашыны, дин аларның һәрбер эшенә хаким мотлак булдыгыны хәтергә алсак, бу сүзләргә урын булмас иде. «Рухани галимнәрнең хуҗалыгыннан котылган мәгарифле милләтләрдә дини мәдрәсәләрнең тереклек күрмешендә һичбер өмиде юк» дигән сүзләр бик тугры вә бик вакыйгый булса да, татарда алай түгел шул, җаным! Татарның күңелендә дин, ахирәтдән башка нәрсә юк. Татар дөнья тереклегенә, дөньяда

[1] Вакыйган – чыннан да.

[2] Игътираздан – каршы сөйләүдән.

[3] Исляхе мәдарис – мәдрәсәләрне үзгәртү.

мәсгудиятькә[1] гөнаһ вә нәфрәт күзе белән карый. Хәят, мәгыйшәт[2], истикъбал[3], сәгадәт кеби нәрсәләр татар кашында чүп тә түгел. Татар боларны кирәксенми. Болар өчен кайгырмый, тырышмый. Аларны бер кирәкле нәрсә, дип тә белми.

* * *

Ул тизрәк кыямәт булуыны, озакламый бу дөнья бетеп, ахирәт туачагыны гына көтә. Аныңча инсан дөньясы өчен кайгыру ярамый.

Татарлар тиздән дәҗҗал[4], яэҗүҗ, мәэҗүҗ[5] чыгуыны, күктән Гайсә инүене, Мәһди[6] килүене, даббател-арзның адәмнәрнең маңлаена көфер вә иман пичәтләре басып йөрүене, кыямәттә, үзенең корбанга чалган кәҗә тәкәсенә атланып, сыйраттан чыгарак, оҗмахка керүене, анда хуриләр[7] кочуыны, җирне күтәргән үгезне, балыкны пешереп ашауны гына өмид итә. Ул шулар өчен генә тырыша. Аның башкада кайгысы юк. Бу фикердән котылган татар меңнән бер булыр. Меңнең 999 ы һәммәсе шул фикердә, шул игътикадда[8]. Башка нәрсәгә нәфрәт күзе илә караучыдыр. «Әфәнде»: «Диннең тереклек көрәшендә әһәмияте юк», – ди. «Әфәндем»! Сүзең бик дөрест. Вакыйгда[9] диннең әһәмияте тормыш көрәшендә булмаска тиеш. Фәкать татарда алай түгел.

Иске тормышны җимереп, хөр вә яңа тормышны кору хакындагы һәрбер хәрәкәткә дин исеменнән каршы сугыш ачканнары күз алдыңызда бит. Бик аз вә бик җөзьи[10] кешеләремез яңалык өчен көрәшәләр. Ә күплек? 100 нең 99 ы дин исеменнән яңалыкны чыгармаска тырыша. Дин коллары, дин тәэсире белән искелекне саклар өчен яңаларга каршы сугыш ача.

---

[1] Мәсгудиятькә – рәхәтлеккә.

[2] Мәгыйшәт – тормыш.

[3] Истикъбал – киләчәк.

[4] Дәҗҗал – алдакчы, ялганчы.

[5] Яэҗүҗ, мәэҗүҗ – дини хорафат буенча дөнья бетәр алдыннан озын һәм кыска буйлы ике төрле халык чыгып, дөньяның астын өскә китереп, төрле әшәкелекләр эшләячәк, имеш. Шуның кыска буйлысы Мәэҗүҗ исемле булачак, имеш. Озын буйлысы Яэҗүҗ дип атала, имеш.

[6] Мәһди – туры юлга төшерүче.

[7] Хуриләр – хур кызлары.

[8] Игътикадда – ышануда.

[9] Вакыйгда – чынлыкта.

[10] Җөзьи – бик аз.

Рәхим итеп, ысуле җәдидә хакындагы нәзарларга һәм яңа матбугат, уку-укыту, гыйлем, мәгариф эшләрендә дин исеменнән каршы сугышларны һәм дин, мәгыйшәтне, ысуле җәдидәләрне вә башкача татарларның һәр яңалыкка һәрбер тормышны алга өстерәү хакында дин тәэсире, рухани голяманың тәэсире белән каршы сугышуларына күз салыңыз әле.

Болар тереклек көрәшендә диннең әһәмияте ни дәрәҗәдә хөкем сөргәнне ачык күрсәтмиме? Шуларны күрә торып, дин вә рухани галимнәрнең тереклек күрмешендә әһәмияте юк дияргә мөмкинме? Әйтергә дә юк. Яңа мәгыйшәт өчен булган көрәшнең бер тарафы да яңалар. Алар хакыйкатьне корал итә. Бер тарафы да яңа мәгыйшәтне чыгармаска тырышучы булган динчеләр. Аларның кулында диннән башка корал да юк. Аларны сугышка мәҗбүр иткән нәрсә дә дин генә. Димәк, дин вә рухани галимнәр бездә хәзерге тормыш, көрәшнең уң сафында торалар. Алар һәр яңага каршы сугышалар. Яңа мәгыйшәтне чыгарырга каршы сугыш ачучы галимнәр, мәгълүм ки, бар да дин исламны искечә аңлаучылар вә иске мәдрәсәдә тәхсил итеп, шуның биргән игътикадында сабит[1] булучылардыр.

Аз булса да динне соңгы фәлсәфи нәзарлар белән аңлаучылар исә, динне корал итеп, яңалыкка каршы тору түгел, бәлки дин исеменнән халыкны иске тормышны бозып, яңага чыгарга өндиләр. Дин исеменнән искеләргә каршы сугыш ачалар. Һәм шул дин исеменнән яңалыкка өндәү кадәрле мөәссир[2] бернәрсә булмавы табигый бер эштер.

Кеше үзенең ышанган нәрсәсе буенча тиеш табылган эшне тиз кабул итә. Татарларны иске мәгыйшәттән биздереп, яңага чыгаруда иң җиңел юл «шул динемез яңа тормышка каршы түгел, бәлки аңарга чакыра» фикерене кабул иттермәк һәм дин галимнәрене шул яңа рухта тәрбия итмәк. «Дин үзе яңа тормышка өнди» фикерене күңеленә урнаштырып, халыкны дин исеменнән яңалыкка чакыртмак идекендә шаяд[3] шөбһә юктыр. Дин галимнәрене җитештерә торган мәдрәсәләр һаман искечә булса, аннан, әлбәттә, яңа тормышка дин исеменнән каршы сугышлар ачучы галимнәр җитешәчәк. Әгәр ислях ителеп, тиешле тәрбия бирелсә,

---

[1] Сабит – кузгалмаучылар.

[2] Мөәссир – тәэсир итүче.

[3] Шаяд – бәлки.

анда дин исеменнән искелеккә сугыш ачып, яңалыкка өндәүче һәм мөмкин кадәрле яңалык өчен теле, каләме илә хезмәт итүче галимнәр җитешәчәк.

Диннән башканы белмәгән татар өчен болар әһәмият җәһәтеннән һәр икесе берме? Көрәштә соңгыларның әүвәлгеләрдән аермасы, әһәмияте бер дә юкмы? Бак, «Әфәндем»!

Шуның өчен мин тереклек көрәшендә дини мәдрәсәләрнең һич тә әһәмияте юк фикерене кабул итә алмыйм. Дини мәдрәсәләрне ислях бик ансат һәм әһәмиятсез, дип, алар хакында каләм дә озайтмавы тиешсез күрәм. Татар халкына катышмаудан идарә тирәсендәге аз-маз аңлылар хәленә генә караудан килә, димен.

Гомумтатарның дин вә рухани галимнәргә ни дәрәҗә баглы икәнне, дини галимнәрнең тәрбия вә тәгълим кәйфияте[1] аларның яңа, иске рухта булуы тормыш көрәшендә бик зур роль уйный, дип ышанам.

Тормыш көрәше дигәч тә сез моны милләтләрнең башка хәлләренә, андагы руханиларга карамаңыз! Алар башка, без башка. Әле безнең хәзерге тормыш көрәше дигәнемез дә гел нәзар вә фикердә яңалудан вә бик аз-маз яңа галимнәргә шөругъдан[2] гыйбарәттер.

Безгә хәзер иң каты сугыш ачу тиеш булган нәрсә – халыкның иске фикере, аның гакыл, фикергә иярмәй мөкаллид[3] булуы, аның туңганлыгыдыр. Әле бездә иң көчле сугыш шул фикрән[4] тәрәккый өчен булырга тиеш.

* * *

Инсанга бер гамәлне тиеш икәнне тәклиф[5] өчен иң әүвәл ул гамәлнең дөрест вә тиеш икәнене аңлату тиеш. Эш вә гамәл исә аңлаган соң тиз вөҗүдкә килә[6].

Бездә дә хәзерге көн иң мөһим нокта татарны иске фикергә тарта торган игътикадлардан[7] чыгарып, анарга яңа рух бирүдер. Һәм аннан башка тәрәккый дә мөмкин түгел.

---

[1] Кәйфияте – рәвеше.
[2] Шөругъдан – керешүдән.
[3] Мөкаллид – иярүче.
[4] Фикрән – уйлап, фикер итеп.
[5] Тәклиф – көчләп кушу.
[6] Вөҗүдкә килә – барлыкка килә.
[7] Игътикадлардан – ышанулардан.

Буның өчен иң әүвәл динне яңача аңлау тиеш. Татар дин кушкан өчен иске була. Аны искелектән чыгару өчен «юк, дин яңалыкка куша», дип ышандырмактыр.

Мин дин руханины голяма бездә беразгача хаким мотлак[1] булачагыннан, татар аларның хуҗалыгыннан котылганчы байтак заман кирәк булдыгыннан, дини мәдрәсәләрне ислях өчен, андагы тәгълим вә тәрбияне яңа рухка кертү өчен һәммәмез бу эш тормыш нәзарыннан да файдалы, дип керешүне тиеш күрәм. Дин – вөҗдани эш. Анда син ирекле, ышанмасаң, ышанма, фәкать, аның миңа кирәге юк, дип, анардан ваз кичмә! Үзең өчен кирәкмәсә, мәсләгең өчен, халкыңны төзәтү өчен кирәк.

Син халыкны исляхка, яңа тормышка чыгарырга телисең түгелме? Әгәр теләсәң, син халкыңа хаким мотлак булган динне үз мәсләгеңә муафикъ[2] сурәткә кертергә тырыш. Халык шул үзенең ышанган дине әмер итә, дип, синең мәсләгеңә яңалыкка чыксын.

Буның өчен дини мәдрәсәләрне исляхтан башка ни чара бар? Озын сүз кирәк түгел. Татар халкы хәзер дә дин кайсы якка илтсә, шунда баручы халык булдыгыннан, аларга динне яңа рухта тәгълим лөзүме бәдиһиятдән[3], бу һәм тормыш күрмеше нәзарыннан да мөһим эшләрдәндер. Без, чынлап ук та, татарны яңа тормышка өстерәсәк, юлы белән барырга кирәк. Татар кайсы юлдан барганда җиңелрәк яңарса, шуны эшләргә кирәк.

Татар халкына дин исеменнән дә, хәят, мәгыйшәт, сәгадәт, истикъбаль фикерләрене салып, аларның башындагы хорафатны, тормышка зарарлы фикерләрене ташлатырга кирәк. Шуларны уйлыймын да мин, – динне игътикад кылганлыктан гына түгел, татар тормышыны үзгәртүдә яңалыкка чыгуда зур әһәмияте бар, дип, дини мәдрәсәләрне исляхка ныграк әһәмият бирүгә, динле вә динсез берләшеп, аннан һич булмаганда яңа тормышка зарарсыз кешеләр чыгуы өчен тырышырга тиешле табам. Татар халкының дингә нәзары, баглануы, мәхкүмияте[4] бу фикеремне чын дидертә.

Шуның өчен мин татар гәзитәләренең һәм «Әлислах»ның дини мәдрәсәләрне исляхка әһәмият бирмәве, аларга булды ни,

[1] Хаким мотлак – хокукы чикләнмәгән хаким.
[2] Муафикъ – яраклы.
[3] Бәдиһиятдән – хакыйкатьләрдән.
[4] Мәхкүмияте – хөкем ителгәнлеге.

булмады ни дигән кебирәк карап куюны тиешсез табам. Аларга: «Дөрест, сезнең үзеңез өчен кирәк түгел дә, шул татар халкының хәле кирәк ясый», – диясем килә. Һәм матбугат бу мәдрәсәләрне исляхтан ваз кичкәндәй итеп торуыны зарарлы күрәм.

Татар әүвәлдән үк «башлый да ташлый» иде. Бер башлагач ташланмасын, тәмам ителсен иде.

«Әфәнде» үзенең мәкаләсендә аларны ислях бик ансат, ди бит. Шул ансат кына ислях юлны күрсәтсен иде. Башка милләтләрдә дини мәдрәсәләр ничек була? Аларда ни кадәрле фән укыла? Бездә дә шулай ясалсын иде.

«Әфәнде» шәкертләрнең фән соравыны тиешсез күрә, анардан көлә. Алайса инде ни эшләсеннәр?

Сезнеңчә әллә исхоластик[1] истинҗа хәезгә[2] риза булып ятсыннармы? Үзе белмәгән мелла нәрсә укытсын, ди. Хәер, «Әфәндем», алар мелладан син үзең шул фәнне укыт, димиләр. Бәлки безгә шул фәннәр укытырлык мөгаллим булсын, диләр.

Әллә инде тагы безнең гәзитәмез шул иске хәлгә риза булып, фән ислях сорамый ятуны тиеш күрәме?

«Әфәндем»! Алай итмик! Шәкертләр фән, ислях сорасыннар, тырышсыннар, әле бит шул сораулар аркасында шул әсассыз хәрәкәтләр сәбәпле, һич булмаса аз-маз фәннәр гәрчә исемнәре булса да мәдрәсә программасына керде. Милләт тә азрак аңласа һәм шәкертләр дә юлы белән тырышсалар, ихтимал киләчәктә чынлап ук та ислях ителер.

Халкымызда аң вә фикернең тәрәккыйсенә хезмәт итәрдәй яңа рухипәрвәрдәй хәят, мәгыйшәт, истикъбаль, сәгадәт вә боларның әсбабы хакында аз булса да тугры фикер салырдай рухани галимнәр җитешеп чыга башлар. Хәят, мәгыйшәт көрәшенең матди вә гыйлем кыйсемендә хезмәт итәрлек кешеләр дини мәдрәсәләрдән чыкмаячагы бик заһир[3] булган хакыйкатьләрдән фәкать әле безнең халыкка иң элек хәят, мәгыйшәткә дөрест вә тугры карарга, аларны яңа тормышны кабул итәрлек аң-фикер бирергә кирәк. Безгә халыкны иске игътикадыннан чыгарып, иске нәзар вә фикердән дүндереп, яңа тормыш җәһәтеннән, мәдәни хәят ноктасыннан караганда иң уңайлы бер дәрәҗәгә аңлы халәткә килтерергә кирәк. Бу нокта җәһәтләрдә яңа рухта тәрбия күргән голяманың безнең

[1] Исхоластик – схоластик.

[2] Истинҗа хәезгә – чистарынуга.

[3] Заһир – билгеле, ачык.

татарга бик көчле тәэсир итәчәге мәгълүмдер. Бу көннән үк бер генә данә булсын фәнни мәктәп тәэссис итү булырлык хәлемез бар, дип, һичкем әйтә алмый. Шөбһә юк, әле бик тиз генә фән мәктәпләре вөҗүдкә килмәс... Шулай ук һәммә татар яшьләре, шәкертләре рус мәктәбенә кереп бетү дә мөмкин түгел.

Ни өчен дисезме? Менә ни өчен:

б) рус мәктәбендә кемнәр укый ала? Анда ни кирәк? Анда байлар укый, анда акча кирәк. Без, рус мәктәбе, рус мәктәбе, дип торсак, әле моңарчы бар кадәресе белән гавамы булган уку эше башкалардагы кеби аксөякләргә генә калыр. Чөнки ярлы баласы русныкына керү читен.

т) рус мәктәпләре халыкка җитми. Әле бит күз алдыңызда, һәр мәктәпләрдә 10 кешелек буш урынга 40–50 прошение бар. 50 урынга 2–3 йөз прошение бар. Руслар үзләре дә бик узышып кына, медальләр аркасында гына керә алалар.

Кайда калды ярты-йорты хәзерләнгән татар баласына? Мәктәпләр арта, фәкать мәктәптән дә бигрәк әллә ничә өлеш артык укучы да арта.

с) бу көндә гомумтатар мәдрәсәләрендә наданлыктан кан аглап ничә «ун меңләп» шәкертләр ята. Сез боларга торасыз да, рус мәктәбенә кереңез, дисез. Алар аны сездән башка да белә. Фәкать чара юк. Мөмкин түгел. Түбәнгеләр дә алмыйлар, яшь үткән, хәзерләнергә акча юк. Менә болардан русчага керә алучы ничә йөзгә бер генә, башкалар мәхрүм. Ишетә – күп кешеләрнең аталары ярлы, акча юк. Теләсәләр дә, керә алмыйлар. Бәгъзылары атасы бай, фәкать ирек юк. Рус мәктәбенә кереңез, дип, башка исляхтан күз йомгач, фән мәктәбе дә мөмкин булмагач, бу ун меңләгән бичара татар шәкертләрене, җәһаләт корбаннарыны ни эшләтмәк буласыз?

«Әфәнде» әйткәнчә, дини мәдрәсәләрне ислях әһәмиятсез булса, боларга башка бер чара табарга кирәк. Бу кадәрле шәкерткә, аз булса, якты көн кирәк, аларга аз гына булса да, фәнни белем дә кирәк. Әгәр һәммәмез, кул берләшеп, алар дини, алар безгә әһәмиятсез, дисәк вә мөмкин кадәре фәнни дәресләрне арттырсак, бөтенләй мәхрүм калганнан, әлбәттә, файда булыр иде.

Хасыйл: без халыкны рус мәктәбенә тулыңыз, дип кенә калу ярамый. Аны күп кешеләр белә инде, бәлки рус мәктәбенә кереп укый алуның чарасыны табарга ярдәм итәргә юллар хәзерлик. Аның өстенә дини мәдрәсәләрне дә халыкны яңа тормышка

өндәрлек булган галимнәр чыгарырлык хәлгә китерергә тырышыйк. Дин татарга хаким мотлак икәнене хәтердән чыгармыйк. Һәм ул ун меңләгән шәкертләрнең хәлене аз булса да яхшылау, шуларны мөмкин кадәрле исләх белән була икәненә шөбһә итмик.

*Мәкалә «Әлислах» газетасының 1908 елгы 8 сентябрь (№ 44), 15 сентябрь (№45), 23 сентябрь (№ 46) саннарында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән дөнья күргән. Гарәп графикасында. Гамәлдәге татар хәрефләре белән беренче тапкыр басыла.*

*«Исләх мәсьәләсе»ндә «Әфәнде» әйтә* – «Әлислах» газетасының 1908 елгы 20 июль (№38), 27 июль (№ 39), 6 август (№ 40) саннарында «Әфәнде» имзасы белән «Исләх мәсьәләсе» исемле мәкалә басыла.

## Уфа, мәдрәсәи «Галия»дә тентү

Белмим ни өчендер? Уфаның моннан өч ел элек тәэсис кылынган[1] мәдрәсәи «Галия»се вөҗүдә килгәне көннән бирле һәр тарафыннан һөҗүмгә очрыйдыр. Искеләр аны, дин бетерә, дип сүгәләр. Бәгъзы хәзрәтләр үзенең шәхси мәнафигына[2] каршы булганга, шәкертләре «Галия»гә китеп, мәдрәсәләре буш калганга аны дошман күрәләр. Дөньядан аның бетүене чын күңелләре белән сөяләр.

Тройски ишаны үзенең тирә-ягындагы барлык казакъ волостьларына: «Галия» шәкертләре дәһри[3]. Аларны меллалыкка ала күрмәңез!» – дип, хат таратты дигән сүзләр бар. Бөре өязенең бер ахуны, кырык мелладан имза алып, «Галия» исламияткә зарарлы. Аны яптыр!» – дип, мөфтигә гариза биргәнлегене дә сөйлиләр. Динче мөтәгассыйблар[4] тарафыннан дәхи башка төрлерәк һөҗүм касды[5] барлыгы хакында хәбәрләр юк түгелдер.

Коръән, фәлсәфәи диния укылган бер мәдрәсәне дошман күрүләре вә бу мәгънәсез хәрәкәтләре үзләрендә генә калса, тагы бер хәл иде. Алар бит бу хакта хөкүмәт кешеләрене дә буш тотмыйлар. «Алар падишаһны сүгә. Алар хөкүмәткә каршы хәзерләнә.

[1] Тәэсис кылынган – төзелгән.
[2] Мәнафигына – файдаларына.
[3] Дәһри – динсез, атеист.
[4] Мөтәгассыйблар – фанатлар.
[5] Касды – нияте.

Аларда ливальвир[1], бомба бар, имеш» дигән хәбәрләр күпвакыт әүля әл-әмер[2] колагына ирешкәләп, шөбһәгә төшерә, куркытадыр.

Хөкүмәттә бу мәдрәсәнең шәкертенең андагы тәрбиянең нидән гыйбарәт икәнене аңламый, никадәрле мактасалар да, һаман да «надан татарныкы» икәнлегене белми, анда әллә ни бардыр, әллә нинди тәрбия бирәләрдер, дип уйлый. Аның шәкертләре һаман шул черегән татар шәкерте икәнене төшенми, урынсызга шикләнәдер. Хөкүмәтнең бу шикләнүенә мин бер дә хакыйкый сәбәп тапмыйм. Мөгаллимнәрнең кызыл төрек фәсе белән озын җиңле, киң чабулы җәбәләреннән[3] башка һичбер куркырлык эш күренми.

Хөкүмәтнең бу шикләнүе күптән үк мәгълүм иде. Ул да булмаса ярар иде, дип, бик куркыла иде. Бу курку урынсыз булмады. Хөкүмәт мәдрәсәне, кереп, тентеде.

Гыйнварның унбишенче көне мәдрәсәи «Галия»дә, икенче дәресләр тәмам булып, тәнәфес өчен звонок булган иде. Аңсыздан мәдрәсәне палитсә[4] килеп басты.

Палитсәнең килүенә сәбәп булган шөбһәсе бик зур булса кирәк, алар бик зур хәзерлек белән килгәннәр иде. Палитсәмейстер[5], пристав, берничә помощник пристав, әллә ничә околоточный, ун-унбиш стражник, байтак кына кулына штык тоткан солдатлар сиздермәй генә мәдрәсә эченә килеп керделәр. Өстәвенә тышта унбиштән зиядә[6] атлы стражник та мәдрәсәнең тирәсене әйләнеп алганнар иде. Палитсә килеп керү белән тиз үк һәммә ишекләрне бикләтте. Мөгаллимнәрне канцеляриягә җыеп, аларны саклау, беркая да җибәрмәү өчен ике штыклы солдат куеп, һәммә шәкерт партасынага утырып торырга, һичкая кузгалмаска әмер бирелде. Шәкерт чыкмасын, андый-мондый нәрсәне яшермәсен, дип, һәр класска ике мылтыклы солдат куелды. Эчтән һичкемне чыгармыйлар, тыштан кертмиләр иде. Бөтен шәкертне шулай мәхкүм[7] итеп куйдылар. Азлап-азлап ятак бүлмәләренә чакырып, тенти башладылар.

---

[1] Ливальвир – револьвер.
[2] Әүля әл-әмер – өстән әмер бирүчеләр.
[3] Җәбәләреннән – киемнәреннән.
[4] Палитсә – полиция.
[5] Палитсәмейстер – полицмейстер.
[6] Зиядә – артык.
[7] Мәхкүм – хөкем.

Тентү бик каты иде: хәтта бик күп шәкертләрне күлмәк-ыштаннан башка һәммә киемне салдырып, читекләренә, чолгауларынача карадылар.

Шәкертләр белән бергә монда дәрес тыңларга кергән гавамнар, авылдан килгән меллалар да эләкте. Бу бичаралар шул дәрәҗәдә каушаганнар иде ки: йөзләре агарган, күз алларына караңгы төрмә килеп, исән-сау котылсак, дип, нәзер әйтергә мәҗбүр булырлык хәлгә килгәннәр иде. Дәрес тыңлау өчен килүчеләрне палитсә тентү белән генә чыгарып йибәрмәде, аларны өйләренә солдат белән озатып тикшертте. Шулар җөмләсеннән улган Казаннан килгән бер яшь егет бичараны палитсә номерына барып тентегәндә, юк-бар нәрсә табып, участкага алып киткән.

Мәдрәсәдә тентү заманында һичкемне ирекле көйгә хәляэга[1] йибәрмиләр, бәлки янына бер солдат биреп, андый-мондый нәрсәләр ташламасын өчен каравыллаталар. Хәляэга кергәндә тентеп кертәләр иде.

Мәдрәсәдә кунучыларны тентеп беткәч, фатирдан йөреп, укучыларның һәммәсене тентеп, адресларыны язып алдылар. Һәр ни мөгаллим, шәкерт, мәдрәсәгә вакытлы килүче – бар да тикшерелде, бар да тентелде. Солдатның мылтыгы астында байтак заман мәхкүм булды.

Тентү дүрт сәгать ярым дәвам итте. Күп нәрсәләр алынды. Палитсәнең үзенчә, яхшы ук муаффәкыятьле чыккан булса кирәк. Зур өч чәй яшчиге[2] шәкерттән табылган хөкүмәткә зарарлы саналган (!) мәмнүгъ[3] нәрсәләр белән тулган иде: истинҗа хәез[4] фәлсәфәсе һәм намаз, таһарәт хикмәтләре язылган кульязма мәҗмугалар, шәкертнең атасыннан килгән: «Углым! Зинһар сом[5], зинһар судинлар (студентлар)га катыша күрмә! Боларга якын барсаң, фатиха бирмәм», – дип язылган мәктүбләр, варидәт[6] вә мәсариф[7] язылып, шимбә көн ярты кадак шикәр, якшәнбе көн асмуха[8] чәй алынганлыгы, күмәчкә бер сум түләп, мунчага ун тиен

---

[1] Хәляэ – монда бәдрәф мәгънәсендә.
[2] Яшчиге – ящигы.
[3] Мәмнүгъ – тыелган.
[4] Истинҗа хәез – пакьлану.
[5] Сом – саңгырау.
[6] Варидәт – керемнәр.
[7] Мәсариф – чыгымнар.
[8] Асмуха – дөресе: әчмуха – кадакның сигездән бер өлеше.

биргәнлеге хакындагы хисаплар белән тулган кесә дәфтәрләре, озын казаки һәм читек киеп төшкән патритлар[1], ике елдан бирле җыелган «Әлислах», «Вакыт», «Шура»лар, белмим, тагы шундый хөкүмәткә ифрат зарарлы булган нәрсәләр, һәммәсе дә җыелып, пичәтләнде, алынды. Эш моның белән дә бетмәде, мәдрәсәи «Галия» хәлфәләреннән беренең өенә барып, һәммә тәфсирләрне, барлык китапларны, чанага төяп, палитсәгә алып киткәннәр.

Чыбыксыз телеграм бу хәбәрне тиз үк Уфага таратып, палитсә килигүк, мәдрәсәнең тирәсене халык сырып алды. Бу вакыйгага бөтен Уфа татарының исе киткән. Моңарчы күрелмәгән мәдрәсә тентүене күрү өчен балалар, яшьләр, картлар һәм хатыннар – һәммәсе дә мәдрәсә янына җыелды. Болар бар да тәгаҗҗеб итә[2]. Бунның сәбәбе, нәтиҗәсе хакында һәрбере үзенең дәрәҗәи фикеренә карап хөкем итә. Картлар: «Бу мәдрәсә башдук фатихасыз ачылганга, хәерле булмас, дигән идек, сүземез дөрест чыкты», – дияшәләр. Гомумның сүзене тыңласаң, әллә нинди мөхаль[3] сугалар. Мәдрәсәдән бер савыт патрон чыккан, имеш. Палитсәмейстер бер йомыш белән мәдрәсәгә килгәч, шәкертләр аны кыйнаганнар, имеш тә, шуннан соң гаскәр килгән, имеш. Мәдрәсәнең эчендә биш фахишә асыралган, имеш тә, ачуланып, шулар барып әйткән дә, палитсә шуның өчен килгән, имеш. Ике шәкерт бер-берене пычаклаганнар, имеш. Биш шәкертне төрмәгә алып киткәннәр, имеш. Мәдрәсә ябыла, имеш, кеби ялганнар, мөхальләр мәдрәсә тирәсендә сөйләнә. Аннан бөтен шәһәргә тарала иде.

Тентү тыныч вә монтазам[4] үтеп китте. Мәдрәсәгә кара ягарлык нәрсә чыкканы беленмәде. Ахыры ни булыр.

*«Әлислах» газетасының 1909 елгы 26 февраль (№ 62) санында «Гыйрфанзадә» имзасы белән дөнья күргән. Гарәп графикасында. Гамәлдәге татар хәрефләре белән беренче тапкыр басыла.*

*Текстларны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының текстология бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре Фәния Фәйзуллина әзерләде.*

---

[1] Патритлар – дөресе: портретлар.
[2] Тәгаҗҗеб итә – гаҗәпләнә.
[3] Мөхаль – мөмкин булмаган хәл, чаң.
[4] Монтазам – тәртипле.

## Пролетариатның
## яңа гыйлем йортлары арта

Казанда октябрьнең 23 ндә татар рабфагының ачылуы көне ясалачак. Гыйлем техника йортларын эшче-крәстиян яшьләре белән тутыруда бердән бер дөрест чара булган рабфаклар Русиянең һәр җирендә бик зур урын тоталар. Ләкин татар хезмәт халкы балалары башкаларга керүгә хәзерләнеп җитмәгәнгә, бу рабфакның кирәклеге шәрекъ тормышында аерым зур бер эш иде. Моның нинди әһәмияте булачагын алдагы цифрлар күрсәтәчәк. Хәзерге көндә бу рабфакка 190 кеше алынган. Разверстка буенча мәркәз һаман җибәрә тора. Барлыгы – 271. Болар эчендә: крәстиян яшьләре – 105, эшчеләр – 45, хайван асраучылар (кыргызлар) – 11, башка төрле кәсепләрдән –29, партия ягыннан 18 коммунист, 43 коммунист яшьләрдән, арада 80 ләп хатын-кыздан бар. Төрле өлкә буенча бүлгәндә 91 е татар җөмһүриятеннән, калганнары РСФСР ның төрле җирләреннән. Арада Казакъстан, Төркестан, Башкортстан өлкәләреннән байтак егетләр бар. Яшь буенча күбрәге, әлбәттә, уку дәверенең егетләре-кызлары. Ләкин арада революциянең сыйнфый көрәшенең канлы көннәрендә пролетариат сафында буржуазиягә каршы көрәшеп, гамәли тәҗрибәдән соң марксизм нәзарияләре белән гыйлем-техника белән сугарылырга килгән утызар яшьлек иптәшләр дә бар.

Без бу рабфакка аеруча өмид баглыйбыз. Чех-Колчак җимерелгәннән соң гына революциягә, Советка кушылган зыялыларның кирәге юк түгел. Ләкин пролетариатның коммунизм өчен көрәшендә иң ышанычлы терәкләре безнең хәзерге гыйлем йортларында укып чыккан эшче-крәстиян яшьләре булачактыр. Хозяйствада, аппаратта, сугыш мәйданында, әдәбият, фән, фәлсәфә, тәрбия, идеология фронтларында барган авыр көрәшләрдә безнең бу революция гыйлем казаннарда кайнаган яшьләр иң гайрәтле көрәшчеләр булачак. Безнең өмиднең төбе менә шунда. Гыйлем-техника белән корылган пролетариат диктатурасы аркылы коммунизмга баруда болар безгә яңадан яңа көчләр арттырачаклар. Шуңа күрә боларга зур әһәмият бирергә кирәк.

*«Татарстан» газетасының 1923 елгы 22 октябрь (202(807)) санында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган. Гарәп графикасында. Гамәлдәге татар хәрефләре белән беренче мәртәбә дөнья күрә.*

## Бондюг пролетариаты арасында

I

Камадан ике чакрымда түгәрәкләнеп, әйләнеп тезелгән сыртлар[1] уртасында тирән киң казан рәвешендә чокырланып, уйсуның төбендә сазлы, баткаклы җиргә мәшһүр Бондюг заводы салынган. Моның уртасыннан кечкенә су ага. Бу елганы вак канауларга бүлгәләп, урыны-урыны белән кечкенә-кечкенә күлләр ясалып, заводның бөтен утырган җире гадәттән тыш пычрак. Яз-көз, шулай ук җәйнең яңгырлы чакларында адәм йөри алмаслык сазламык хәлендә бата.

Алабугадан барып, урманлы түбәләрнең өстенә менгәч, башта бер-береннән озаеп күккә таба күтәрелгән зур-зур морҗалар күренәләр. Минем өчен [19]20–21 нче елларда Уралның бик күп зур заводларының үлек, кабер хәлендә яшәгәннәрен күргән, шуңа пошынган бер коммунист өчен бу морҗаларның куе кара, соры төтен белән якты күкне каплап торулары аеруча бер күңеллелек булды. Чөнки бу хәзер безнең индустриянең терелүен, эшләвен күрсәтә иде. Завод төбәгенең тирә-ягын әйләнеп алган сыртларның кабыргасында бер-беренә тоташып тезелгән тәбәнәк, киң, зур тәрәзәле агач өйләрнең тезелүе, тышкы яктан караганда, монда эшләүчеләр өчен квартир мәсьәләсенең начар булмавын уйлатырга мөмкин иде. Ләкин сыртның түбәсеннән түбәнгә, теге төтенләп торган морҗаларга, андагы корпусларга, андагы эшче кварталларга якыная барган саен саф, ачык, яхшы һавалы, коры урыннарыннан казанның төбенә таба төшкән саен күренеш үзгәрә, күңел начарлана барды.

Алабуга секретаре Игнатьев белән Недачин, Хәбибуллин белән Курочкин алдан киткәннәр иде. Без кантонда помпрокурор Габдулхак Мөслимев белән соңгарак калдык. Сәгать бергә Бондюг районының мәсьүл хезмәтчеләренең җыелышы Бигәштән телефон аркылы билгеләнгәнгә атларны ашыктырырга куштык. Ләкин мөмкин түгел иде.

Иңе-буе берничә чакрым җирне алган завод төбәге шулчаклы пычрак, сазлык, баткак, юллар шул дәрәҗәдә начар иде ки, коры, пакъ сыртлардан төшеп, менә кул астында гына торган райкомга барып кергәнче безгә бик күп мәшәкатьләнергә, берничә җимерек күпердән кире борылырга, берничә ат үтә алмаслык сазлык урамнардан икенче юл эзләргә туры килде.

[1] Сыртлар – буйга сузылган калкулыкның, тауның өсте.

Областком безне (Недачинны һәм мине) сәяси бер эш өчен IX нчы өлкә конференциясе турында докладлар ясап, кайбер аңлашылмауларны чишү өчен җибәрсә дә, Бондюг төбәгенең эченә кергәч, бу мәсьәлә белән бер дәрәҗәдә үк мине бу җирдәге пролетариатның көндәлек хәле үз эченә тартып алды.

Бондюг пролетариатының тормышы, чыннан, бик чыннан, артык авыр хәлдә икән.

Заводтан ике чакрым югары сыртның һәйбәт коры җирендә Бондюг дигән авыл бар. Шуның бер мужигы Ушков моннан бик күп еллар элек, хәзерге завод урынында тегермән тоткан, сумала кайнаткан. Аннан соң үзенең эшен арттыра барып, акрын-акрын башка нәрсәләр «кайната» башлаган. Ахырда мәркәзнең зур капиталы дөньясына катнашып, ышанычка кереп, сума[1] кушып зур химически завод хәленә китергән. Менә шул әкренләп үскән. Тарихы начар, баткак урында хәзерге көндә дә зур җәфа чигәләр. Язны-көзне әйтәсе дә юк. Җәйнең азмы-күпме яңгырлы көннәрендә дә урамнар уртасында адәм йөри алмаслык пычрак, сазлык була. Заводның үз кирәге өчен елгадан төрле якка тартылган канаулар, кечкенә-кечкенә күлләр бу сазлыкны тагы да начарлата, тагы да тирәнәйтәләр. Безнең кебек вакытлы эш белән баручылар атта да йөрер, урамнарның ике ягы белән салынган тар такта басмалардан да файдаланып, сазга батудан котылыр, ләкин монда даим торучылар, бигрәк тә балалар өчен Бондюгның урыныннан да яман, мондан да сәламәтлеккә зарарлы бер җир табу читен булыр.

II

Мәсьәләнең аеруча тукталырга тиешле урыны менә кайда: әлбәттә күп еллар буенча төзелгән завод корпусларын, серный, хлор корпусларын, сульфат мичләрен тиз генә күчереп булмаячак. Болар күп заман шунда торачак, эшләячәкләр, ләкин эшчеләр тора торган квартирларны бу сазлыктан бу малярия, бизгәк, башка һәртөрле агулы газлар сазлыгыннан бераз читкә, служащийлар яшәгән сырт буендагы коры таза, һәйбәт урыннарга таба күчерү эше, әлбәттә, әлбәттә, әлбәттә, беренче планда булырга тиешле иде.

Атасы Бондюгда эшләгән, шунда чехоткадан үлгән, үзе егерме еллар буенча шунда татар пролетариатының мәдәни күтәрелүе юлында туктаусыз эшләп килгән учитель коммунист Кәшшаф иптәш Сәхаутдинов белән без бу эшче квартирларның байтагында булдык.

[1] Сума – акчалата булган байлык.

Күз алдыгызга китерегез: яңгырлы көндә тездән пычрак, саз эчендә кала торган җирдә зур, озын иске таш корпус. Тышкы ишекне ачу белән әле һаман да җүеш, пычрак, сасы ис борынны яра. Корпус – караңгы. Коридор рәвеше белән салынган. Тар, биек, җүеш, сасы коридорның ике ягы буйлап вак кына «номерлар» – бүлмәләр китә.

Бу «номерлар»ның иңе 2–3 аршин, буе 5–6 аршин. Бер тәрәзә, юеш черек стена. Менә шунда 7–8 кешеле эшче семьялары тора. Хлор заводы бар. Бу үзенең тирә-ягындагы пычрагы, әллә нинди яшелле, сарылы су тулган кечкенә пычрак канавы белән тирә-якка агулы газ тарата. Менә шул заводның алдында ишекләренә каршы, тик 5–6 гына сажин аша, сазламыкның эчендә тәбәнәк иске агач корпус. Менә ишекләре тышка чыга. Һәммәсе вак, тыгыз бүлмәләр. Ишек ачкан саен хлорның агулы һавасы бүлмәгә керә. Шунда, квартирлар белән завод уртасында, яшел сулы канаулар буенда, сазлыкта татар эшчеләренең балалары уйнаган булып йөриләр. Һәммәсе ябык, сары йөзле, өмидсез күзлеләр.

Бу заводта урыслар, татарлар өчен аерым клублар, библиотекалар, мәктәпләр бар. Боларны карап беткәч, клуб каршындагы озын кара, соры агач казармага кердек. Тагын шул коридор, тагын шул ике яклап тезелгән кечкенә вак бүлмәләр, имеш «номерлар». Боларның күбе бер ишектән кергәч, «номерның» эче икегә бүленә. Бер эшче татар хатыны безне каршы алды да ачык шаян тавыш белән:

– Менә шул инде тормыш... Аның нәрсәен карыйсың?! Җәй көне тышта йоклыйбыз, кыш төне сыймагач, бер-беребез өстенә ятабыз, диде.

Бүлмәнең иңе 2,5 аршин, буе 4,5 аршин булыр. Менә шунда алты кешелек бер семья тора...

### III

Әгәр бу общий хәл булса, бер чара иде. Ләкин мәсьәләнең үзәге менә кайда: җүеш, пычрак, тар, сасы таш «номерлар»да, саз эчендә, хлор агуы астында агуланган начар сасы квартирларда бу «җәй көне тышта йоклап, кыш көне сыймагач, берсе өстенә берсе ятарга мәҗбүр кечкенә тар бүлмәләр» дә торучылар һәммәсе, һәммәсе тик татарлар, тик татар эшчеләре генәдер.

Әмма урыс иптәшләрнең квартирлары гәрчә күңел туларлык дәрәҗәдә шәп булмасалар да, һәрхәлдә алар бу иң начар саналган корпусларда, казармаларда тормыйлар. Байтагы сазлыктан югары,

сырт буена салынган коры агач квартирларда, түбәнгеләр дә боларга караганда яхшырак урындалар.

Моның сәбәбе кайда? Һәркемгә мәгълүм, революциягә чаклы завод хуҗасы Ушков урыс капиталисты иде. Татар эшчеләренең квалификациясе түбән, аңнары зәгыйфь, көрәшләре аз, тыңлаучанлыклары зур булганга, күп эшләтеп, аз түләп, начар квартирда тотып, боларның канын, пролетариатның оешып, көрәшкә барган катлавы булганга, күбрәк эчәргә корган эксплуатациясе моңа сәбәп иде.

Монда мөнәсәбәт крәстиянгә дә, зыялыга да бар иде.

Җөмһүриятнең дүрт җылы үтте. Без, татар эшче-крәстияне, изелгән, аны күтәрергә, элеккедән калган начар кара мирасны бетерергә, татар массасын элекке заманның кара мирасыннан коткарырга кирәк, дип кычкырдык. Кайбер иптәшләр бу мәсьәлә белән гадәттән тыш спекуляция дә ясадылар. Ләкин гамәли һич, һич, һич нәрсә эшләмәгәннәр. Өч ел буенча кычкырылган сүзләр демагогиядән үтмәгән. Алабуга исеме белән һәркайда селтәнеп, аңа таянып йөрүчеләр шул Алабуга, Бондюг пролетариаты өчен берни дә кылмаганнар.

Хәзер сүздән эшкә күчү вакыты килде. Икътисади тигезләүне тормышка кертү, бу юлда иң беренче планга пролетариатны кую, дип, IX нчы конференция карар чыгарды, инде бу хакта бер чара күрә башларга кирәк.

Ләкин күреләчәк чара тик квартир мәсьәләсендә генә түгел:

а) Бондюг заводында утыз (30) цех бар. Болар эчендә тик бер генә, тик бер генә заведующий татардан. Ул да әле яңа гына кергән. Хәлбуки, элеге заманның кабахәт мирасы белән көрәшеп, татар пролетариатыны күтәрүне чыннан уйланса, бу 30/1 не байтак арттырырга мөмкин.

б) Бондюгның фабзавучы бар. Монда 130 дан артык эшче яшьләр укыйлар. Шуның 39 ы гына татар. Хәлбуки, моның санын, һич булмаганда, якын елларда 50%, аннан 60–70% ка мендерергә лязим.

Шулай эшләнмәгәндә элекке вакытта изелгән татар массасын күтәрәбез, дип сөйләү юк сүз. Бу эш, сүз спекуляция яки демагогия булачак.

Тик шул юл белән генә без татар пролетариаты арасында квалификацияне, сәяси аңны күтәрербез.

Фабзавуч мәктәбенең директоры Сәхәутдинов иптәш икән. Моның татардан булуы, әлбәттә, яхшы эш. Ләкин бу гына җитми, аңа ярдәм бирергә, партия, профсоюз бу хакта нык чара күрергә кирәк.

IV

Бондюгда биш меңгә якын пролетариат бар. Шуның яртысы татар. Мондагы татар эшчеләренең күбе шунда туганнар, шунда завод һавасында үскәннәр. Арада 1905 нче елларда ук революциягә кушылганнары бар.

Болар үз эчләреннән аз булса да, пролетариат зыялылары да хәзерләп өлгергәннәр.

Шул заводта эшләп үлгән татар эшчесенең балалары Сәхәутдиновлар егерме еллар буенча эшче балаларын укытып, мәдәни яктан күтәреп эшләп яталар. Безнең татар җөмһүриятенең мәсьүл урыннарында Бондюг, Кокшан татар пролетариаты эченнән чыккан байтак иптәшләр бар. Ләкин мин шелтә өчен, алдагы хәлне күреп җаным әрнегәнгә, бу иптәшләргә ул Фәсхи, Саттаров, Шакиров һәм башкаларга әйтергә мәҗбүрмен:

– Сезне Бондюг, Кокшан пролетариаты үз эчендә күтәреп, революциянең алдынгы сафына чыгарган. Әмма сез артта калган иптәшләрне оныткансыз, оныттыгыз, сез тик алар үзегезгә кирәк булганда гына аларны хәтергә төшерәсез... Сүзне, интриганы, Кокшан, Бондюг белән спекуляцияне ташлап, чыннан алар өчен кайгырырга, аларны күтәрү чарасын карарга, бу юлда гамәли, реальный эш кылырга кирәк.

V

Без Недачин белән бергә Алабугада да, Бондюгта да IX нчы өлкә партия конференциясе турында докладлар ясадык. Гәзит укучылар беләләр, бу организацияләрдә бераз эсклука[1] бар кебек иде. Ләкин ачык күренде, һәммәсе югарыдан җибәрелгән төтен икән. Һәммәсе тиешле дәрәҗәдә мәгълүмат булмауның сәбәбе икән. Бондюгдагы докладлар соңында бу бигрәк тә ачылды.

Бондюг райогпартия организациясенең секретаре Усачов иптәшнең председательлеге астында булган общий җыелышында моның сәбәбен ачык күрсәткән пролетариатча ачык ихлас сүзләр булды.

Карт эшче татар коммунист Гайнуллин абзый әйтте:

– Ара-тирә яңлышлар булгалар, әмма пролетариатны оештырып алып барырга кирәк. Туры, дөрест, ачык сөйләргә кирәк. Аның йөрәге төз, юлны тиз сизә, ди.

Рус иптәш Юсупов болай диде:

---

[1] Эсклука – склока – каршылык, ызгыш, итрига.

– Моңарчы кимәнең[1] бер ягына салдылар (бер яклы мәгълүмат бирделәр.) Шуңар күрә бер якка авып, чалыш бардык. Хәзер икенче якка төялде, инде хәзер тигезләнде, туры китәр, ди.

Иң шәп моментның бере әле өч-дүрт ай гына элек станоктан аерылган Хәбибуллин иптәш пролетариатча ачык, ихлас сүз белән чыкты да мәсьәләне ачып салды:

– Без моңарчы яңлыштык... Инде яңадан ул хаталар булмас, областком белән, партия белән бергә-бергә барыйк, юк бар интригаларга юл бирмәбез, ди. Һәм үзе шул юлда резолюция кертә.

Алабуганың, Бондюгның резолюцияләре татар, рус гәзитәләрендә бөтен көенчә басылыр. Мин монда үзәген генә әйтәм.Бондюг пролетариаты Хәбибуллин тәкъдиме буенча болай кабул кылды:

а) IX нчы өлкә конференциясенең һәммә карары, сызган юллары әлбәттә дөрест, туры;

б) Бондюг организациясе боларны гамәлгә куюда бөтен куәте белән ярдәм кылачак;

т) «39 группасын» партия оешмасына каршы баручы дип табабыз. Боларга протест ясыйбыз һәм боларның юлын осуждать итәбез...

Алабугада яшьләр конференциясе белән шәһәр организациясе дә шундый резолюция чыгарды.

Болар һәр икесе бер авыздан кабул кылындылар.

Ахыр сүз шул: күпчелеге вак буржуа булган җөмһүриятебез эчендә Кокшан, Бондюг пролетариаты партиянең, советның иң ныклы терәкләреннән берсе булып каралырга, боларга бик зур әһәмият бирергә кирәк.

*«Кызыл Татарстан» газетасының 1924 елгы 2 июнь (107 (1019)) санында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган. Гарәп графикасында. Гамәлдәге татар хәрефләре белән беренче мәртәбә дөнья күрә.*

*Бондюг заводы* – 1868 елда Бондюг авылында (хәзерге Менделеев шәһәре) П.К.Ушков тарафыннан нигез салынган химия заводы.

*Бигәш* – Менделеев районы Бигәш (Иске Гришкин) авылы.

*Кокшан* – хәзерге Менделеев районы Яңа Кокшан поселыгы. 1850–1925 елларда химия заводы эшли. Монда шул заводта эшләүче пролетариат турында сүз бара.

[1] Кимәнең – көймәнең.

## Татарстан җөмһүриятенең дүрт елы эчендә партия оешмасы

Татарлаштыру турында дүрт ел буенча күп сөйләдек. Кайбер эшләр дә юк түгел. Ватык, җимерек тел белән булса да, һәммә вывескаларга татарча яздырдык. Мәктәпләргә, совет аппаратларына азмы-күпме татарны керттек. Татардан совет чиновнигын беркадәр арттырдык. Ләкин бөтен хәрәкәтнең төп үзәге булган партия организациясендә татарлашу, татар эшче-крәстиянләрен партиягә һәм аның аппаратларына кертүдә эшләнгән эшләр әле һаман бик аздыр.

Сүзне цифрларга бирик:

1921 нче елда партия оешмасы (партияне тазарту комиссиясе доклады буенча).

Тазартканчы – 6751;

Чыгарылган – 1585 (24%);

Калды – 5166.

Болардан:

Эшчеләр –1723;

Крәстиян – 2651;

Служащий –776.

Милли яктан сан күрсәтелмәгән.

1922 нче ел составы. Бу ел өчен ике мәгълүмат бар. Беренче – Бөтенруссия партия членнарының исәбен алгач, мәркәзнең бастырып тараткан материалы. Анда болай күренә:

Татарстан оешмасында татарлар – 612 (20%);

Урыслар – 2077;

Башкалар – 400;

Барлыгы – 3089.

(Бу санга кандидатлар керми).

Икенче – шул ук елның октябрь конференциясендә (V) секретарь Живов иптәш түбәнгечә цифр бирде.

1922 нче елның сентябрендә партия составы:

Татарлар –1095(28,4 %);

Урыслар – 2464 (64,2);

Башкалар –284 (7,4).

Бу исәпкә членнар да, кандидатлар да керәләр.

Бөтенруссия переписы белән бу соңгы материалда татарларның проценты турында аерма – сигез. Моның сәбәбе кандидатлар арасында татар күп булудан, беренче исәпкә кандидатлар кермәгәнгә, татар проценты ким күренәдер.

1923 нче ел, март:

Урыслар –2914(66%);

Татарлар – 1054 (24%);

Башкалар – 429.

1923 нче ел, июль аенда татарның проценты 24 тән 25 кә менә. Димәк, бер процент арткан була.

1924 нче ел, гыйнвар. Бажановның рәсми доклады буенча Татарстан организациясендә татарларның артуы күренми. 1923 нче елның җәендә 25 процент булган икән. Шуннан алып декабрьгә үсү юк, ди. Димәк, 1924 нең гыйнварына безнең организация 25 процент татар белән килеп керде.

Төрлечә үзгәрә килгән составны уңгайгатып карасак без шуны күрәбез:

Татарстан оешмасында бары 5 процент кына татар арткан, [19]22 нче елның язында 20 процент, [19]24 нче елның башында 25 процент. Әгәр без бу артуның бик зур өлеше Татарстанда эшләр һәм уку өчен читтән килгән татар коммунистлары хисабына булганлыгын хәтерләсәң, җирле масса эчендә яңа көчләр тартып чыгару, җитештерү эшенең бик акрын барганын күрәчәкбез.

Хәлбуки, Татарстандагы халыкның 53 проценты татарлар, әмма коммунистка килсәк, 25 проценты гына татар.

Иҗтимагый яктан тикшерсәк, тыш яктан караганда Бондюг, Кокшанда пролетариатның яртыдан артыгы татар. Алафузов, Пороховой, Крестовников заводларында да боларның саны байтак. Татарның шәһәрендә генә түгел, авылында да сәүдә капиталы тарафыннан бик каты эксплуатация астында изелгән татар вак һөнәрчеләре бездә урысларга караганда күп артык сандалар. Әгәр крәстияннәр арасына килсәк, монда да партиягә керергә тиешле булган ярлы, урта батрак татарлар бик зур процент урын тоталар. Димәк ки, материалны алганда татар эчендә партия өчен иҗтимагый элемент бик җитәрлек. Шулай булганы хәлдә татар эшче-крәстиян массасының партиядә азлыгын күрәбез. Моның сәбәбенең берсе – объективный шартлар. Электән татар массасы караңгы, надан, артык изелгән иде. Квалификациясе бик аз, бик түбән иде. Самодержавиянең кара мирасы булган бу хәлдән революция тиз арада татар массасын чыгара алмады. Шуңа күрә хәрәкәтнең авангарды булган партиягә керүләре бик акрын барды. Икенчесе, дүрт еллык гомер эчендә мәсьәләнең бу ягына тиешенчә әһәмият бирелмәү, татаризацияне вывескага язды. Татар чиновнигын арттыру

кебек күбрәк шаблон эшләр тирәсендә әйләнүе, татарлаштыру эшендә партия эчендә татар массасын кертү ягына куәтне юнәлдермәү кебек субъектив сәбәпләрдән Ленин наборы вакытында партиягә барлыгы 2672 заявления бирелгән, шуннан 1427 се кабул кылынган. Болар эчендә күпме татар барлыгы әле һаман исәпкә алынып бетмәгән, ләкин һәрхәлдә татар пролетариатының партиядәге урыны моның белән бераз артканлыгында шөбһә юктыр.

Бишенче елга кергәндә безнең алдагы зур эшләрнең берсе бу яңа иптәшләрне Ленин юлында тәрбияләү булса, икенчесе татаризацияне вывескалар, татар чиновниклар мәсьәләсеннән күтәреп, төп үзәккә, партия эченә татар эшче-ярлы крәстиян массасын чынлап тарту-кертү булырга тиешле, шуның белән генә без үткәннең авыр мирасыннан котыла алырбыз.

II

РКП(б)ның Татарстан организациясендә татар пролетариаты белән ярлы татар крәстияненең азлыгы мәсьәләсе коры бер цифр, протест мәсьәләсе генә түгел икәнлеге мәгълүм. Соңгы ике-өч ел эчендә кичергән төрле авышулар да, бөтен [19]23 нче ел буенча барган кризислар да әнә шул состав мәсьәләсендә зур катнашы барлыгында шөбһә юк. Бу авышуларга каршы көрәшнең озак сузылуында да составның милли иҗтимагый әһәмияте зур роль уйнады.

Боларга аерым тукталыйк. Авышуларга, кризисларга каршы көрәшнең башлыча моментлары шулар булды:

а) үткән 23 нче елның мартында булган VII нче конференциядә организациянең югары башында булган яралар бик нык ачылган иде;

б) Солтангалиев мәсьәләсе июнь-июльдәге Казан, Мәскәү партия киңәшләре юлны тагы да ныграк ача төштеләр. Көрәш тирәнәйде һәм киңәйде, ләкин верхушка һаман үз авыруын бөтен организмга җәюдә дәвам итәргә калды;

т) IV нче совет съезды бу көрәшне тагы көчәйтте, организациянең татар /…/[1] фронтны киңәйттеләр. Ләкин һаман җырып чыга алмадылар;

ж) дискуссия килде. Монда партия массасы үзен гаҗиб[2] дәрәҗәдә туры ачык тотты.

---

[1] *Бу сүз укылмады.*
[2] Гаҗиб – искитәрлек.

Бөтен резолюцияләрдә, сөйләүләрдә төп өч матдә ачык барды: 1) партиянең мәркәз комитетына тулы ышаныч; 2) партиянең 5нче декабрь карары белән игълан кылынган эшче демократиясен гамәлгә кую; 3) партия эчендә һичбер төрле группачылыкка, фракциячелеккә һичбер төрле юл бирмәү, боларга каршы бару.

Бездә бөтен дискуссия менә шул өч маддәне, төп нигез итеп алынганнан соң шулар буенча барып, шулар үлчәве белән үзебезнең организациянең эчендәге, дөрестрәге, башындагы хәлләрне тәнкыйть кылды. Шул юлда Татарстан оешмасының 95 проценты берләште, ләкин һаман да мәсьәлә чишелмәде. Тик VIII, IX нчы конференцияләр генә татар эшче-крәстияннәрен ул озак бизгәктән чыгарып, таза юлга төшерде.

Бик ачык мәсьәләләр турында булганы хәлдә көрәшнең болай каты булуы, озак сузылуында шөбһәсез организациядә татар пролетариатының татар ярлы крәстияненең саны, куәте азлыктандыр.

Чөнки урыс иптәшләр милли мәсьәләдә артык саклык һәм дикъкать күрсәткәнгә, һәркайда «татар» исеменнән сөйләп, шуны куертып йөргән татар верхушкага ачыктан-ачык каты көрәшкә чыгуны бераз уңгайсыз таптылар. Мондый урыс шовинизмы дигән сүз белән спекуляция ясарга зур урын булачак иде. Җирле пролетариат һәм ярлы крәстиян партия эчендә санын, куәтен туры аңлап баруын тиешле дәрәҗәдә күтәреп җиткермәсә, алда да төрле бәндәләрнең, төрле «15»ләрнең, «39»ларның «татар» исеменнән төрлечә кыенлык чыгаруларының юлы бикләнмәгән була. Өч еллык тәҗрибә, бигрәк тә соңгы ел ярымлык каты көрәш моны ачык күрсәтте. Хәлбуки, мондый эчке көрәшләр өлкәнең хужалык эшләренә, мәгариф, мәдәният тарату һәм башка иҗади хезмәтләренә гадәттән тыш зур киртә булып торалар. Организациянең күп куәте, вакыты, гайрәте, дикъкате шундый кирәксез нәрсәгә түгелеп, кирәк юлда тыныч эшләргә җай калмый.

Дүрт елның хисабы – эшләрнең яхшымы, начармы булуы турында уйлаганда менә бу момент күз алдында булсын, алдагы планнар шул тәҗрибәләрдән чыгып эшләнсен, организация өченче елга менә шул өмид, шундый ышаныч белән керә.

### III

Үткәннең тәҗрибәләрен VIII нче, XI нче партконференцияләр нык исәпкә алды. Кичкән хаталарны төзәтүгә юл сызганда

һәрнәрсәдән алга эшләүне, иҗади хезмәтне куйды. Татарстанның дүрт елы буенча җыела килгән конференцияләрнең күбенә катнашкан вәкилләр моны үзләре таралганда ачык әйттеләр.

Конференциянең тоткан юлы урыннарга таралгач, ясалган докладлардан соң, Татарстанның бөтен оешмаларында дөрест дип табылды.

Кантоннардагы унөч, шәһәрдәге дүрт, барлыгы унҗиде организация (членнар, кандидатлар саны – 5756) нең һәммәсе шуны хаклап карарлар чыгардылар.

Арада ялгызрак торган Бондюг пролетариаты да ачык кискен рәвештә: «Конференциянең сызган сызыкларын туры, обласкомга камил ышаныч һәм ярдәм, «39»га каты протест» , дип резолюция чыгарды. Шул юлда эшли башлады. Димәк, 5756 га каршы «39» ялгызы калды. Моның эчендә дә таркалу башланып, Усманов кебек кайбер иптәшләр ачыктан-ачык аңардан ваз кичтеләр. Башкаларның күбе дә Татарстанның организациясенә буйсындылар. Арада төзәлмәслек берничә кире, тискәре иптәш калган икән, ансы инде бик кечкенә әһәмиятсез эш. Уңган ашлык эчендә дә берничә кара чүп була түгелме? Ачык әйтергә кирәк, тиешеннән артык озак сузылган көрәштән Татарстан организациясе тазарып, ныгып, масса алдында авторитетлы булып чыкты. Шуның белән бергә мәркәздә дә үзенең юлы дөрест икәнлеген күрсәтте.

Сүз ахыры итеп, «Правда»[1] гәзитенең 136 нчы номерында партиянең мәркәз комитетында каралып үткән төрле милли организацияләр хакындагы мәгълүматның бер өлешен китерәм: «Партиянең мәркәз комитетында соңгы ике атна эчендә милли өлкәләр, җөмһүриятьләр турындагы мәсьәләләр каралды; ...татар коммунистлары арасында милли сәясәтне гамәлгә кую турында ихтиляфлар[2] бар. Бу ихтиляфлар соңгы конференциядә бик ачык күренделәр. (Татар) иптәшләрнең бер кыйсьме масса белән бәйләнуда һәм сәясәтне татар пролетариатына таянып үткәрүдә кискен тактика тотуны требовать итәләр. Партиянең мәркәз комитеты (Татарстандагы) соңгы конференциядә күрелгән настроение белән исәпләшә һәм аларның предложениеләрен кабул кылып, (татар җөмһүриятендә) аңарчы юлбашчылык иткән работникларны алмаштыра...», ди. Димәк, безнең организация татар җөмһүриятенең

---

[1] *Бу сүз кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Ихтиляфлар – каршылыклар.

бишенче елына эчтән тазарган, мәркәз тарафыннан да юлы дөрест дип танылган хәлдә керә.

Хәерле юлга!

Зур иҗади хезмәтләргә!

Бишенче елны шул теләк каршы алыйк.

*«Кызыл Татарстан» газетасының 1924 елгы 25 июнь (124 (1036)) санында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган. Гарәп графикасында. Гамәлдәге татар хәрефләре белән беренче мәртәбә дөнья күрә.*

*Текстларны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының текстология бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты*
*Эльмера Галимҗанова әзерләде.*

## Әдәби тарихыбызның кадерле битләре болай таптатылмасын иде

### I

*«Җиңел юл белән»*

Татар пролетар әдәби хәрәкәтенең беренче тулкыны кадерле әдип Гафур Коләхмәтев турында Газиз Гобәйдуллин тарафыннан язылган[1] «Истәлек» – һичшиксез җавапсыз мәкаләләрнең берсе булса кирәк.

Монда, әлбәттә, һәммәсе ялган, һәммәсе бозык, һәммәсе рия, нифак[2] яки черек дипломатия генә дип әйтергә ярамаячак. Арада шиксез бик дөрес җирләре, ышанырга мөмкин урыннары да бар. Мәсәлән, Газиз белән Гафурның: 1) бергә балык тоткан чаклары, 2) бергә ауга-сунарга йөрүләре, 3) куркак «профессор»ның ялгыш атып җибәрүләре, 4) Гобәйдуллиннарның дачаларына барулары, 5) алма паштеты белән чәй эчүләре, 6) Гафур Коләхмәтевнең нәселдән килгән туберкулез белән каты җафалануы шикелле моментлар – болар истәлектә дөрес китерелгәннәр. Чөнки әдип турында моңарчы җыелган материаллар, фактлар белән чагыштырганда, алай күзгә бәрелеп торган каршылык күренми, шуңар күрә боларына ышанганда зыян юк.

---

[1] *«Яңалиф», № 6, 1930 ел (Г. Ибраһимов искәрмәсе).*

[2] Рия, нифак – икейөзлелек.

Әмма башка бик күп әйберләр турында истәлек үзенә тарихи материалларда бер төрле дә терәк таба алмый, һичбер сүзен куәтләрлек, һичбер төрле документ китерә алмый: болар һәммәсе ялангач сүзләр генә.

Без ике төрле типтагы истәлекләр – мемуарлар беләбез: мәшһүр Август Бебельнең һәм Д. Фурмановның мемуарлары һ.б. Алар бик күп кеше катнашкан мәгълүм вакыйгаларны язуларына карамастан, төп нигездә үзәк моментларны һәркайда төпле документлар белән, ышанычлы материаллар белән нигезлиләр, ныгыталар. Болар шуңар күрә кыйммәтлеләр дә!

Икенче бер тип мемуарчы – истәлекчеләр «җиңел» юл тоталар. Документ, материал юк. Ул бары үзенең «миен» казый да, шуннан тапкан нәрсәсен үзенең иҗтимагый-шәхси тенденциясенә буяп чыгара.

Газиз Гобәйдуллин менә шул соңгы «җиңел» юлны тоткан. Шуңар күрә үзе дә әллә ничаклы каршылыкларга баткан. Кирәксез шәхси мактану, капитал җыеп калу кебек, Гафур өстенә таянып аны вак исәпләргә корал итү кебек, шул уңай белән үзенең дус-ишен, фамилиясен революциягә чаклы бер сафта эшләгән сыйнфый «группадашларын» тарих эченә көчләп тыга бару кебек бик күп күңелсез, ямьсез эшләр белән тутырып биргән. Болар нигә кирәк булгандыр? – Анысы инде башка мәсьәлә.

II

*Агиев «төзәтә»*

Гомумән әле безнең әдәби тарихыбызның Гафур Коләхмәтевкә багышланырга тиешле битләре өчен материал җыю, боларны тикшерү эше бик фаҗигале хәлдә тора. Гафурны яратабыз, татар пролетариат әдәби хәрәкәтенең беренче төпле таза адым атлаганы өчен яратабыз, әсәрләрен әдәби тарихыбызның иң кадерле битләренә куярга тиешлеген беләбез. Ләкин трагедия шунда: бу әдипнең барлык әдәби мирасы Ф. Агиев кебек бер совет, пролетариат революциясенең ачык дошманы кулында яталар. Аның иске заманда басыла алмаган «Ике фикер» кебек кадерле драмасын шул ук Агиев кулъязмадан дөньяга чыгарды. Бу бик уңайсыз эш булып төште. Чөнки шул ук «редактор» әйтә:

– «Гафурның өслүбен һәм телендә булган кайбер авырлыкларын төзәтү минем тарафтан булды!» – ди (22 нче бит).

Хәлбуки үзе үлгән әдипнең әсәрләрен бастыруда иң беренче шарт: аларны үзгәртмичә, бозмыйча, «төзәтмичә», мөхәррирнең үзе калдырганча чыгарудадыр. Бу – бер. Икенчедән, инде большевик әдипкә редактор Агиев булса, җитмәсә бу редактор «төзәтә» башласа, «каберендә яткан җирдә чыдаша алмый әйләнерсең» ич!

Газиз Гобәйдуллин бөтеннәй шул Агиев сызган юлдан бара. Икесендә дә бер үк «дипломатия», бер үк тактика. Икесендә дә Гафурның үзләренә бик «якынныгы»н, үзләренең һәркайда, һәр турыда аңа җитәкче, ярдәмче булуларын сөйләп, аның исемен вак исәпләргә корал итү дәрте ялтырап бара. «Гафурны корал итәләр, Гафур белән спекуляция ясыйлар» дисәм, бәлки зуррак чыгар, һәрхәлдә Агиев һәм Гобәйдуллинның һәр икесе берсенә ошашлы бер «тактика» тоталар.

Әдәби тарихыбыз мондый «истәлек-биография»ләрдән файдалану юлында бик каты тәнкыйди анализ аша гүя эш итсә кирәк. Болар турында башка бер уңай белән нечкәләп тикшерү бирергә кирәк булачак, мин бу җирдә, укучыга мисал өчен, берничә урынга гына тукталам. Берәр ялган, берәр ямьсез мактану, берәр бозык характерлау, бер-ике черек «дипломатия» – менә шундый берничәгә генә кагылам.

III

*«Мин» генә, ди*

«Яңалиф»нең 56 нчы битендә Гобәйдуллин туп-туры күзен дә йоммыйча менә болай әйтә:

– «Гафурның әсәрләре хакында милләтче гәзитләр бер сүз дә язмадылар. Бары мин “Вакыт” гәзитенә Гафурның бер-ике әсәренә тәнкыйть яздым» – ди.

Мин мондый тере ялганга чыннан гаҗәпләндем. Чөнки миңа әле ул заманның матбугатын актарып карамыйча, тик хәтеремдә калган буенча гына санаганда да, бөтеннәй башка фактлар мәгълүм: ул чакның милләтче гәзитләреннән милләтче «Вакыт»та милләтче Гобәйдуллин гына түгел, бәлки милләтче-динче Сәйдәш картның «Бәянелхак-мөхбир»ендә Гафурның «Яшь гомер»е турында су буе озын бер мәкалә булды; милләтче «Әлислах»та икенче бер милләтченең кыскарак «тәнкыйте» чыкты. «Йолдыз»да милләтче Кәбир Бәкернең Гафур китабы «Ник уйгандым?» турында җүнсез генә әйбере басылды. Актарсаң тагы да күп чыгачак, ләкин Гобәйдуллин бу фактларга да канәгатьләнсә кирәк; икенче

урында алай алдына-артына карамый сүз сөйләп карталарны бутамаска кирәк. Профессор дип кул куелган тарихи мәкаләләрдә бу дәрәҗәдә ялганга бару – һич тә килешмәгәнен башка һәркемнән бигрәк Гобәйдуллин үзе аңнарга, икенче вакыт сак булырга тиеш. Чөнки бик гади мәсьәләдә бу дәрәҗә ялган кертү – бөтен истәлекне шөбһә астына төшерә. Гомумән: – «мин» – «мин генә»ләрнең бер чиге бар.

Гафур Коләхмәтев авыру булды. Төп килере учитель булып алган: айлык 27 сум 50 тиен иде. Ул заманның гонорары исә, кәгазь-каралык кына иде.

Шулай да Гафур туберкулезына карамастан, әдәби әсәрләргә башка масса өчен тарихи популяр китапчыклар да язгалады («Тарих сәхифәләре»).

Боларны язган дәвердә үзенең методологиясе буенча Гафур шиксез үз юлын, нәрсә язарга теләгәнен яхшы аңнаган, хәзерлекле бер язучы иде. Безгә мәгълүм барлык материал ул дәвердәге Гафурны, ул дәвердәге Гобәйдуллиннан күп дәрәҗә пешеп өлгергән итеп күрсәтәләр. Ләкин начар гадәт монда да калмый, моны язганда Г.Г. үзенең «мине», үзенең бу тарих язуда Гафурга «җитәкчелек» итүе белән килеп тагыла. 55 нче биттә туп-туры болай яза:

– «Гафур Коләхмәтев, ди... популярный материалистический бер общий тарих язам, “Гасыр” белән[1] договор ясадым. Беренче “Тарихтан элек адәм балалары” ди. Минем белән киңәш кыла. Өстәл өстендә Спенсерның “Социалогия нигезләре” дигән китабының ике җилде ята. Мин аңа Зибль белән Липпертне һәм Реклюнең “Кеше һәм Җир” дигән анархизм нигезендә язылган китабын күрсәттем. Шуларны укып язды ул брошюраны», – ди.

Бу брошюраны язган Гафур кем? Гобәйдуллин моңар 55 нче биттә ачык җавап бирә:

– «Шуның өчен мин Гафурны беренче марксист шәрык тарихчысы, дим» – ди.

Күрәсез монда бик ачык куелган. Гафур тарих язмакчы. Гобәйдуллин белән киңәшә, бу Гафурга китаплар күрсәтә, Гафур шуны тыңный, «шуларны укып брошюра яза» һәм бу брошюралар шәрыкчә беренче марксист тарихлар булып чыгалар. Без Гобәйдуллинның бу сүзләренә, әлбәттә бик ышаныр идек, тик безгә бер

[1] *«Гасыр» түгел, «Сабах» белән (Г. Ибраһимов искәрмәсе).*

генә нәрсә комачаулый: Гобәйдуллин үзе тарих язуда Гафур җитәкчелек итә, Гафур ул биргән әйберне укып, шуның буенча бара, нәтиҗәдә Гобәйдуллин җитәкчелегендә язылган Гафурның бу китабы шәрыктә беренче марксист тарих булалар.

Ләкин шунысы гаҗәбрәк: Гафурга шундый марксист китап язарга булышкан Гобәйдуллин, шул Гафур китапларыннан соң, үзе үз кулы белән тарих язарга тотынгач: «Диннәр тарихы» (1918 ел) кебек, «Милләтчелек әсаслары» кебек бөтеннәй чеп-чи ялган идеализмга нигезләнгән тарихи нәрсәләр чыгара. Шуңар күрә, әгәр Гобәйдуллин әйтсә: – «Гафур бөтеннәй марксист, материалист тарих язмакчы иде, ул замандагы фикерем буенча мин аңа тәэсир итә алдым, материаллар бирдем, шул минем тәэсирем сәбәпле Гафурның тарихларына кайбер идеализм хаталары керде, минем тәэсирем сәбәпле ул әсәрләр бөтеннәй ук марксизм юлында чыга алмадылар» дисә иде – без бу сүзне дөрес табар идек; чөнки ул заманның барлык материалы Гафурны, әлбәттә, марксизмга таба омтылучы итеп күрсәтсәләр, Гобәйдуллинны бөтеннәй чепчи идеализм юлында гына барганын кычкырып торалар.

Газиз монда кире кайтып, «тарих»ны борырга, Гафур аркылы нидер «төзәтергә» тели; ләкин файдасыз эш, буш дәгъва, дөньяда Гобәйдуллинның «Истәлеген» сынап карар өчен, башка материал күп бит. Шулар утында, шулар яктысында карагач, алтынның чыны – сахтәсе[1] ачык аерыла.

IV

*Ике дошман*

Бу «мемуарчы»ның колачы байтак киңгә ошый. Ул Гафурны гына түгел, татар большевик гәзите «Урал»ның башы Х. Ямашны да йотмакчы була. Дөрес бу каты большевикның алай тиз генә Газиз бугазына кереп китә алмавын сизә, әле бу «Истәлек» беренче тәҗрибә генә бит! Шуңа күрә әле саграк маташа, шулай да сынау өчен булса кирәк, берничә бик яман «кыю» адым атлап куя. Ямаш белән үзен, ниндидер мәсьәләләрдә бер тактага янәшә куя, бер мәҗлескә, бер түгәрәккә кертеп җибәрә, Гафур аркылы гына булса да, хәзер инде Ямашка таба күпер салырга чамалый, никтер бер куркып, бер шикләнеп, як-ягына каранып, шул дәверендә Ямашны

---

[1] *Сахтә – фальше дигән сүз (Г. Ибраһимов искәрмәсе).*

үз тирәсенә көчләп ябыштырырга азаплана, ләкин куркып тагын шунда ук кире чигенә. Тарих мондый икеләнүне яратмый, ул чактагы хәлләргә багланган бөтен материаллар, фактлар һәммәсе менә нәрсә сөйлиләр:

Х. Ямашев большевик мәсләгендә[1] үлде (яки үтерелде). Барлык шаһитларның кискен, ачык күрсәтүенчә, Х. Ямаш Гобәйдуллиннар фирмасы кебек бөтен Казанга данлыклы эре капиталист элементлардан, шуңа нигезләнгән динче, тар милләтче түгәрәкләрдән туп атарлык дәрәҗәдә ерак торды. Бу ике лагерь арасында уртак нәрсә бер генә булды: ул да һәр ике якның бер-беренә дошманныгы!

Ямашны якын белгән, аның белән революция һәм реакция көннәрендә бергә булган иптәшләре, Алафузов-Пороховой татар эшчеләре, аеруча Сәгиевләр, мәрхүм эшче большевик Миңнулла Вахитовлар, аны эре капиталист фирмаларның идеология казаннарында бергә кайнарлык, яки якын барырлык кеше түгел икәнен миңа ачык сөйләделәр. Миңнулла һаман әйтә иде:

– Менә җегет Ямаш! Безнеке булып эшләде, безнеке булып үлде! Аны татар буржуалары – динче милләтчеләре яшерен рәвештә зәһәр биреп агулап үтерделәр, Казанның кара университетының анатомия театры да сатылды, Ямашның ни белән агуланып үтерелгәнен яшереп калдырды! – дип әрнеп сүгенә иде.

Гомумән, әгәр тарих өчен берәр файдалы материал бирергә теләсә, Гобәйдуллин безгә хәзер эш үткәч Ямашка таба Гафур аркылы күпер салырга азапланмасын, чөнки бу көлке чыга, оят, ялган булып чыга. «Мемуарчы» мондый тайгак нәрсәләр тирәсендә биеп маташканчы, турыдан-туры үткән дошманнык, үткән каршылыклар турында ачык кына сөйләсен дә бирсен.

Тарих буенча мәгълүм ич: Казанда ул дәвердә татар яшьләре эчендә бер-берсен бөтен мәгънәсе белән сыйнфый-фикри 100 процент кара-каршы торган ике полюс (котып) булса – моның берсе Х. Ямашлар, икенчесе Гобәйдуллиннарның сыйнфый фикер лагерьлары иде.

Хәзер кулыбызга җыела алган бөтен материал безгә моны ачык күрсәтә. Шуңар күрә, Г.Г. өчен иң дөрес юл: менә шул ике сыйнфый-фикри полюсның, ике идеология лагерының тыштан аз-маз «исәнме-саумы» дип пәрдәләнүенә карамастан,

[1] Мәсләгендә – карашында.

төбендә ни дәрәҗәдә һәм нинди конкрет моментлар аркылы дошманнык, ачык, яшерен көрәш барганын туп-туры язып бирү генә файдалы булачак. Әгәр моны язса – ул дәвернең хәрәкәтләрен дөрес аңнарга, тарихи кирәкле материал биргән булачак. Шулай бит: без коммунистлар тиешле урында үзебезнең үткән хаталарны туп-туры ачып икърар кылабыз ич! Буржуа тарихчылары да, әгәр чыннан советчы булырга теләсәләр, бездән гыйбрәт алып эшләсәләр, үзләре өчен дә, гыйлем өчен дә файда булачак.

V

*Гафур Марксны аңнамады?*

Бөтен материаллар, фактлар, документлар, әсәрләр буенча без һәммәбез бик ачык беләбез: Гафур Коләхмәтев үз заманы өчен яхшы хәзерлекле язучы, аңны социал-демократ, Ямашларның якын фронтташы булды.

Аның учительлек дәрәҗәсендәге рәсми мәгълүматы өстенә, ул үз алдына нык системалы рәвештә хәзерләнүне дәвам иттергән бер әдип икәнен «Яшь гомер», «Ике фикер» һәм «Тарих сәхифәләре» күрсәтеп торалар. Ләкин ни өчендер, нинди сәбәп беләндер «Истәлек» менә Гафурның бу ягын кимсетергә көчәнә. Ул шушы мәкаләсендә үк Коләхмәтевнең Дарвин, Спенсер, Кантлар белән таныш икәнен, димәк шул чама гыйльми-фәлсәфи хәзерлеге булганын яшерә алмый. Шулай да шунда ук китереп чуалтырга кирәк таба. Гобәйдуллин болай ди:

– «Маркснең «Капитал»ы юк. Аны бер мәртәбә Хөсәен[1] мәрхүмнән алып кайтып миңа биргән иде. «Капитал»ны аңнарлык көч Гафурда юк иде» – ди (54 нче бит).

Фу!! – Бу нинди нәрсә тагын? Ахмаклыкмы, ялганмы? Әллә икесе дә бергәме? Без беләбез, Маркснең «Капитал» кебек әсәрен аңнау өчен хәзерлек кирәк, нык, каты шуның өстендә эшләргә кирәк. Ләкин шуны да беләбез: эшче җегетләребез Маркснең «Капитал»ын идән асты түгәрәкләрендә качып-посып кимерделәр һәм аңнадылар. Партиябезнең тарихы барлык эшче түгәрәкләрдә програмның үзәгендә «Капитал» торганын ачык күрсәтәләр. Әмма «мемуарчы» хәзрәтнең үз сүзе буенча да Дарвинны, Спенсерны,

[1] *Ямашев (Г. Ибраһимов искәрмәсе).*

Кантны үтеп кичкән Гафур, имеш Марксны аңнарлык дәрәҗәгә җитмәгән имеш, – «Гафурда «Капитал»ны аңнарлык көч булмаган», шуңа күрә (сизәсеңме җепнең очы кая бара), Ямашевтан «Капитал»ны алып үзе укымаган, бәлки Гобәйдуллинга гына китереп тапшырган.

Тагы бер кат мәгълүм тарихи фактны искә төшерергә мәҗбүрбез: ул дәвердәге Гафур, мондый мәсьәләләрдә ул дәвердәге Гобәйдуллиннан бик күп дәрәҗә югары тора иде, шуңар күрә без «мемуарчы-батырның»:

– Ямаштан алып миңа китерде, мин аңнадым, әмма Гафурда аны аңнарлык көч юк иде! – дигән мәгънәдәге сүзләрен тарихи бер зур оятсызлык санаячакбыз. Гафур турында язган булып үзенең үткәнен бөтеннәй ялган рәвештә Ямашларга, Маркска, «Капитал»га бәйләргә көчәнү дип табачакбыз. Дөрес Гобәйдуллинның «Капитал»га бәйләнеше зур, тирән; ләкин Маркснең «Капитал» китабына түгел, бәлки Салих-Газиз-Кадыйр-Гобәйдуллиннар фирмасының эре капиталына! Әмма бу ике «капитал» арасында «аз гына» аерма бар бугай!

«Истәлек» Гафурны шулай Марксны аңнарлык дәрәҗәдә көче булмады, ди дә, ә шуның икенче битендә үк үзе утырган ботакны кисеп төшерә. 55 нче биттә болай яза:

– «Мин Гафурны беренче марксист шәрык тарихчысы дип беләм!» – ди.

Бераз аптырабрак каласың – тукта бу ничек булды әле: 54 нче биттә, Гафур – Марксны аңнамый иде, 55 нче биттә шул Марксны аңнарлык көче юк «Гафур – «Беренче марксист шәрык тарихчысы булып китә».

Бу гади укучыга үзе генә аңнашыла алмыймы, әллә болаймы? Ямаштан «Капитал»ны алып кайтып Газизгә бирә, чөнки үзе аңнамый, әмма Газиз инде Марксны су кебек эчә-эчә дә, Гафурга аңнатып язып бирә, шуннан инде Гафур беренче марксист тарихчы булып өлгерә. Шулай чыга түгелме?

Чынын әйтергә кирәк: мондый урыннарда «мемуарчы»ның һәммә әйбере ак җеп белән тегелеп бара. Укучы күләргә дә, сүгенергә дә аптырый. Монда икенең берсе икенчесен ялганга чыгара: йә – Гафур «Капитал»ны аңнарлык түгел дигән сүз ялган, йә булмаса, мемуарчы «Мин Гафурны беренче марксист шәрык тарихчысы дип беләм!» – дигән кебек сүзләрен риядән сөйли. Шулай күз буяр өчен генә тузан җибәрә.

Әмма без кисеп әйтәбез: бөтен материалның күрсәтүе буенча әдип Гафур Коләхмәтевнең яхшы гыйльми-сәяси хәзерлеге булды, Марксны иркен аңнарлык көче булды. Гафур гомеренең беренче дәвер әсәрләрендә менә бу момент ачык чагылды, соңыннан томаннанды, дибез. «Мемуарчының» Гафурга биргән бу характеристикасын тарих буенча бөтеннәй хата дип табабыз.

## VI

*Черек «дипломатия» һәм үпкә*

«Истәлек»тә бер фальше бар. Моңар туктамый ярамый. «Мемуарчы» әйтә (56 нчы бит): «Гафур начар агитатор иде. Миңа сәяси яктан тәэсир итәргә тырышмады. Мин аңар үпкәлим, мин аның сүзен тыңный идем. Аның көчле волясына бу яктан да ияргән булыр идем» – ди.

Моны укыгач күңелгә бер сорау килә: Гафурга ничек үпкәлисез, Газиз Салихович? Әгәр Гафур яхшы агитатор булган булса, сәяси яктан сезгә тәэсир итәргә тырышса – мин Гобәйдуллин да ул заманда ук Гафур кебек большевик, социал-демократ булган булыр идем, дип әйтергә телисезме? Үпкәләвегез, аның сезне, шул чакта ук агитация кылып, большевик ясамавы өченме? Шулай чыга бит!

Ләкин безнең яшь пионерлар бар. Алар бик шаян халык. Әгәр «мемуарчы»ның бу сүзе аларның күзенә чалынса, алар бер сорау бирәчәкләр:

– Ә алаймы? Гафур агитация ясый алмады, шул сәбәпле ул чакта большевик була алмадыңмы? Шуңар күрә аңар үпкәлисеңме? Менә бит хәзер 14 ел инде. Ленин кебек дөньяның иң зур агитаторлары һәм аның фикердәшләре ачыктан-ачык партия өчен агитация, пропаганда алып баралар. Коммунизм юлына көрәшчеләр чакыралар, җитәкчелек итәләр. Син кая калдың? Әллә Гафур кебек Ленин да сиңа начар агитатор булдымы? Элекке вакыт өчен Гафурга «үпкәлим» дисең! Әмма менә бу 14 еллык агитация эчендә дә «коммунист» була алмавың өчен кемгә «үпкәлисең». 1918–1920 нче елларда син советка-пролетариатка каршы чех-Колчак ягында безгә, революциягә каршы сугышып йөрдең! Моның өчен кемгә – Колчакка «үпкәлисеңме»? – дип сораячаклар.

Кыскасы монда «мемуарчы»ның «үпкә»се бер рия, бер нифак, бер черек «дипломатия» булып чыга. Монда безнең пионерыбыз әйтәчәк:

– Син Гафурга «үпкәләмә», үзеңнең сыйныфыңа «үпкәлә» – эре капиталист фирмаңа «үпкәлә», шуларга төбең-тамырың, каның, фикерең белән эзмәслек нык бәйләнгән булуыңа «үпкәлә» диячәкләр. Эш – «үпкәләү»дә түгел, сыйнфый җепләреңне эзмәвеңдә.

Гомумән, монда Гафурга «үпкәлим» дип күз буяу – сыйнфыйтарихи хәрәкәтләребездән аз гына хәбәре булган кеше өчен – бик мәгънәсез, ямьсез чыга, ихлас түгел, тик тактика маневры булып чыга; Гафурдан бигрәк «мемуарчы» үзен кайгыртканы, үзенең үткәнен башка төс белән буярга план тотканы күренеп тора.

VII

*Гафурның гомерендә ике баскыч*

Шулай итеп, безнең кадерле әдибебез, үзе үлгәч, пролетариат революциясе чорында, менә шундый ике төрле бәхетсезлеккә очрады:

1) Аның барлык әдәби мирасы Агиевлар кулына эләгергә мәҗбүр булды: «Яшь гомер» белән «Ике фикер» кебек әсәрләр Агиев редакциясендә, Агиевның «төзәтүе» буенча чыкты. Барлык биография материаллары да беренче кул булып Агиевка эләктеләр. Әмма Гафур белән бергә эшләгән ул замандагы татар эшче большевикларыннан материал җыю, боларны төп нигез итеп алу – бөтеннәй онытылды. Шуңар күрә Гафурның хезмәтләрендәге иң нигез кирәкле як: аның татар эшче хәрәкәтенә багланган, Ямашлар белән бер фронтта актив көрәшкән моментлары әле хәзергәчә ачылмый, тикшерелми калдылар.

2) Гафур өчен Агиев кулыннан «төзәлеп» үтү, аңа әлегә беренче зур бәхетсезлек булса, икенче иң авыр бәхетсезлек үзе үлгәч, эре капиталистларның реакция чорындагы «тарих»ларын акларга «буярга» мемуарчы Гобәйдуллин тарафыннан көчләп хезмәт иттерелүе булды.

Агиев белән Гобәйдуллин элек үзе исән чагында да Гафурны реакция ягына тартып, Ямаш – 1905 «Урал» традицияләреннән ераклатырга өстерәүче активның алдынгы кешеләре иде. Шул ук Агиев белән Гобәйдуллин икәүләп Гафурга үлүеннән соң да килеп ябыштылар. Каты, оста ябыштылар. Җәфалыйлар.

Иптәшләр, кадерле әдип Гафурны бу ике кешедән коткарып алырга кирәк!

Бу сүзне уйнап түгел, чыннап әйтәм!

Барыбыз да бик яхшы беләбез ич: Гафур безнең әдәби тарихыбызның кадерле битләреннән. Ул татар пролетариат әдәби хәрәкәтенең – беренче тулкыны. Аның «Ике фикер» белән «Яшь гомер»ендә татар әдәбиятында беренче тапкыр социализм өчен көрәш моментлары чагылды. Ул беренче башлап әдәбиятыбызда татар эшчеләренең буржуазиягә каршы, капитализмга каршы көрәшләрен гәүдәләндерде, ә татар эшчеләренең «үз» – «милли» буржуаларына каршы чалмалы, кәләпүшле татар кадеты «Иттифак» партиясенә каршы чыгышларын без беренче тапкыр анарда очраттык.

Гомумән, Гафур безгә кадерле әдәби мирас, әдәби байлык. Ләкин бу әдәби хәзинәне, тарихи дөрес анализ буенча, марксист кул белән аера-аера файдалана белергә өйрәнергә кирәк. Чөнки бу хәзинә эчендә мәгъдәннәрнең[1] һәммәсе бер үк кыйммәттә түгел. Арада иң югары кыйммәтле әйберләрдән икесе: «Яшь гомер» белән «Ике фикер» булачак.

Без беләбез урыс әдәбиятында беренче классиклардан булып, беренче дәрәҗәдә торган мәшһүр Грибоедов үз гомерендә бик күп әсәрләр чыгарды, ләкин шулар арасыннан бары берсе – «Горе от ума»[2] гына авторны күтәреп калды. Икенче яктан, без хәзер Плехановны өйрәнгәндә аның бөтен нәрсәсен бер үк кыйммәттә йөртмибез. Аерабыз, төрлесен төрле кыйммәт белән тикшерәбез. Аның да бик күп ялгышларын каты тәнкыйть итәбез. Гафурны тикшергәндә дә безгә аның бөтен әдәби хәзинәсен бер аршин белән үлчәү ярамаячак.

Чөнки болар эчендә – 1905–[190]7 революциясенең, «Урал»-ның, актив большевик Ямашның фронтташы Гафур иҗатлары булган кебек, каты авыру сәбәпле активлыгын бетереп, реакция сөремнәренә каршы тора алмый башлаган, әнә шул Агиев, Гобәйдуллиннар чолгап алган дәвернең эзе төшкән китаплар да бар.

Дөрес анализ өчен Гафурның гомерен, иҗатын ике дәвергә бүлеп тикшерергә кирәк булачак:

---

[1] Мәгъдәннәрнең – байлыкларның.

[2] *Кирилл хәрефләре белән.*

1. Беренче дәвер, беренче баскыч – 1905 нче ел революциясенең кызу чагы һәм шуңа ялганган, турыдан-туры шул юлның дәвамы булган заман. Бу дәвердә Гафур – активист. Ул «уралчы», «Урал»га хәбәрче, аңа Казан Алафузов-Пороховой татар эшчеләреннән җыеп акча җибәрүче Ямашлар белән актив фронтташ чагы. Гафурның исемен безгә аеруча кадерле ясаган «Яшь гомер» белән «Ике фикер» менә шул беренче актив баскычның, революция кайнаган чорның иҗатлары, шуның җимешләре. Бу баскычта Гафур эшчеләр эчендә торып капиталистларга каршы әдәби-сәяси актив көрәшкән кеше. Монда Ямаш белән бәйләнүы актив бәйләныш.

2. Революция җиңгәч, каты рәхимсез караңгы реакция еллары килде. Бу шундый авыр караңгы заман булды ки, Максим Горький, Луначарский кебек Лениннан турыдан-туры җитәкчелек, тәрбия алган зур большевиклар да, партиянең, марксизмның дөрес юлыннан яздылар, – дин эзләү, Алла эзләү кебек зур ялгыш юлларга кереп киттеләр. Казан кебек җирләрдә реакциянең кара сөреме, фикри сөрем тагы яман куерды. Монда партия оешмасы җимерелде. Большевиклар сөрелде, ябылды, атылды, асылды. Исән калганының теле киселде, авызы бикләнде. Идеология дөньясын дини-милли реакциянең иң авыр кара томаны каплады. Менә шул каты реакция томаны эчендә әдип Коләхмәтевнең шәхси трагедиясе килеп басты; аның туберкулезы көчәйде. Аның алдында үлемгә каршы газаплы – өметсез көрәш урын алды. Сәяси-фикри реакция эчендәге бу шәхси авырулык Гафурның активлык көчен алдылар, элекке Гафурга каршы тирә-якның барлык томаны аны басты. Ямаш үлүе ( яки үтерелүе) аны бөтен Казанда диярлек бердән-бер фикри таянычыннан-иптәшеннән мәрхүм, ялгыз калдырды. Аңарчы да Гафур тирәсендә буталып йөргән чит элементлар аны хәзер бөтеннәй чолгап алдылар. Агиевлар, Гобәйдуллиннар менә шул реакция чорында авыру Гафурны чолгап алган, аны элекке Гафурлыктан менә шул икенче дәвергә – реакция сөременә өстерәгән элементлар, һәм аның шул чордагы – «дуслары»-«якыннары»дыр. Беренче дәвергә Ямаш характерлы булса, икенче дәвергә шул Агиевлар, Гобәйдуллиннар Гафурның муенына таш булып бәйләнгән, аны элекке активлыгыннан реакция сазлыгына, түбәнгә өстерәгән көчләрдер.

Гафурның бер яктан большевик Ямашларга, икенче яктан Казанның атаклы эре капиталисты Гобәйдуллиннарга, Агиевларга

багланышы кебек тышкы чуалчык моментны менә шулай аңнарга кирәк. Соңгы дәвердә язылган кайбер әсәрләренең «Ике фикер» белән «Яшь гомер»ләр нигезеннән читкә таба тайгалавының тамыр сәбәпләрен: менә шундый диалектика белән бер үсеп, бер төшеп барган тарих – иҗтимагый моментлардан эзләргә бурычлыбыз.

## VIII

*Конкрет тәкъдимнәр*

Карап үтелгән бар материаллардан сөземтә ясасак болай чыга:

Гафурны эре капиталист «мемуарчы» Гобәйдуллиннар, Агиевлар богавыннан коткарырга кирәк. Ул аларның «үткәннәрен» буярга, фамилияләрен күтәрергә, «чибәрләргә» корал ителеп йөртелмәсен. Бу – бер.

Боларга каршы Гафурның татар эшчеләре белән багланышлы якларын тулы ачарлык материалларны җыярга тиешлебез. Гафур Елга аръягы эшчеләре бистәсендә учитель булды. Шундагы актив белән нык катнашын мәрхүм Миңнулла Вахитовлар, хәзер дә исән эшче Сәгыйтовлар ачык сөйлиләр. Ул төбәк татар пролетариатының картрак буыны һәм «Урал-Ямаш» большевик активының хәзер сәламәт калганнары безгә бу турыда материал бирерләр. Тик җыя белүебез генә кирәк. Боларның бары җыелганда марксист бер коллектив тарафыннан тулы дөрес биография эшләп чыгарыла алачак.

Гафурның әдәби мирасын җыйнау-тикшерүне Татар гыйльми тикшерү институты алынгандыр инде. Монда бер генә нәрсәне искә төшерәсе килә: «Ике фикер»не Агиев «төзәттем» ди. Шуңар күрә, 1925 нче елгы Мәскәү басмасыннан бигрәк, әнә шул «төзәтелмәгән» көенчә Гафурның үз кулъязмасы безгә нигез оригинал булырга тиеш. «Әбүҗәһел»не дә реакция чорында тукталган басма-оттискалар буенча түгел, Гафурның үз оригиналы белән карарга кирәк. Моны табарга, тик шуның буенча гына эш кылырга тиешлебез. Чөнки басма-оттиск үткәрү өмете белән нашир һәм цензур «бармагы» уйнаган нәрсә була. Гомумән, Гафурның үз карамагында басылып чыга алмый калган һәммә әсәрләрендә кулъязма оригиналга гына таянырга ярый, бу – өченче момент.

Әле бүгенгәчә яңалиф белән Гафурның бер әсәрен дә яхшылап, дөрес килеш бастырып чыгара алганыбыз юк. Минемчә аның

әдәби мирасы эчендә бүгеннән масса һәм мәктәп өчен чыгарырга тиешле булган – «Яшь гомер» белән «Ике фикер» булырлар: болар кәгазь мәсьәләсенең иң авырайган чагында да «Татиздат»ның планында, әдәби бүлектә алдынгы урында торачаклар. Әмма аның тулы җыелмасы һәммә ягы белән тикшерелеп, материалы тупланып беткәч, академик басма рәвешендә чыгарылса – бу инде шиксез әдәби тарихыбызның ул кадерле битләрен өйрәнүгә зур кыйммәтле байлык булачак.

Сүз ахыры итеп күңелгә шул килә: Гафур безнең татар пролетариат әдәби хәрәкәтенең беренче тулкыны дибез, шуңар күрә Гафурга багланган бөтен эшләрне башкаруда ТАППның турыдан-туры җитәкчелеге, катнашы кирәк дип беләм. Моның белән сыйнфый момент яхшы тәэмин ителгән булыр иде.

*Мәкалә «Яңалиф» журналының 1931 елгы 5/6 саннарында «Яңалиф» трибунасы» рубрикасында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган. Латин графикасында. Гамәлдәге татар хәрефләре белән беренче мәртәбә дөнья күрә. Мәкалә тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, язучы Газиз Гобәйдуллинның (1887–1937) «Революционер Гафур Коләхмәтев турында истәлекләрем» исеме белән «Яңалиф» журналының 1930 елгы 6 санында басылган мәкаләсе уңае белән язылган.*

*Гафур Коләхмәтев* – Коләхмәтев Гафур Юныс улы (1881–1918), язучы.

*Ф. Агиев* – Агиев Фәхрелислам Нигъмәтулла улы (1887–1938), язучы, журналист.

*«Яшь гомер»* – Г. Коләхмәтевнең «Яшь гомер» (1908) драмасы.

*«Ник уйгандым?»* – Г. Коләхмәтевнең «Ник уйгандым?» (1911) хикәясе.

*«Тарих сәхифәләре»* – Г. Коләхмәтевнең 1909 елда басылган китабы.

*«Милләтчелек әсаслары»* – Г. Гобәйдуллинның «Милләтчелекнең бәгъзе әсаслары» (1918) китабы.

*«Ике фикер»* – Г. Коләхмәтев бу әсәрен 1906 елда язып тәмамлый. Беренче мәртәбә «Гафур Коләхмәтев мәҗмугасы»нда (Мәскәү, 1925) басыла.

*«Әбүҗәһел»* – Г. Коләхмәтевнең «Әбүҗәһел» (1908) драмасы. Китап булып басылып чыкмаган.

*Текстны, искәрмә һәм аңлатмаларны басмага*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре,*
*филология фәннәре кандидаты Гөлназ Хөснетдинова әзерләде.*

## РӘСМИ ЧЫГЫШЛАР

### Галимҗан Ибраһимовның Беренче Бөтенсоюз Тюркология съездында ясаган төрки телләрнең орфографиясе турындагы докладлары һәм чыгышлары

I

1926 елның 27 февраленнән 6 мартына кадәр Бакуда Беренче Бөтенсоюз Тюркология съезды үткәрелә. Оештыручылар: Бөтенсоюз Көнчыгышны өйрәнү Фәнни Ассоциация (ВНАВ; җитәкчесе профессор М.В. Павлович) һәм «Әзербәйҗанны өйрәнү җәмгыяте» (җитәкчесе профессор Самед Гасан-Оглы Агамали-Оглы). Заманы өчен бу истәлекле вакыйга була. Съездда 131 делегат катнаша. Шуларның 98 е төрки республикалар вәкилләре була. Корылтайга Совет көнчыгышын өйрәнү фәненең атаклы вәкилләре чакырыла: академиклар В. Бартольд, С.Ф. Ольденбург, А.Е. Крымский; профессорлар А.Н.Самойлович, И.Н. Бороздин, Л.И. Жирков, Н.Ф. Яковлев, Л.В. Щерба, Н. Ашмарин, С.И. Малов, А.А. Миллер һ.б.; чит ил галимнәре дә була: төрек профессоры Ф. Күпрүлү, немец тюркологы Менцель һ.б.

Корылтайда СССРда яшәүче күп санлы (30 миллион) «төрки халыкларның мәдәни тормышындагы кайбер проблемалар»ны ачыклау девизы астында гарәп графикасына нигезләнгән алфавит, орфография һәм терминология мәсьәләләре карала. «Нәкъ менә шулар төрки халыкларның мәдәнияте, мәгарифе үсешен тоткарлый, Европа халыклары цивилизациясе дәрәҗәсенә ирешергә мөмкинлек бирми» ди үз чыгышында М.П. Павлович.

Съездда Көнчыгышны өйрәнүгә төрле яклап якын килгән докладлар сөйләнелә: төрки халыклар тарихын өйрәнүнең хәзерге торышы һәм алдагы бурычлары, төрки телләрнең үзара якынлыгы, уртак яклары һәм аерымлыклары; гамәли яктан хәреф, имля, атамалар ясалышы һ.б. күп мәсьәләләр карала. Әмма шулай да көн тәртибенә төп проблема итеп алфавит мәсьәләсе куела. Үзәк мәсьәлә яңалиф була. Барлык төрки халыклар өчен дә бер төрле булган латин графикасына нигезләнгән алфавит үткәрү алга сөрелә. Съездда төп көрәш яңалифне яклаучылар һәм аңа каршы торучылар арасында бара.

Татарстаннан съездга 9 кеше делегат итеп җибәрелә: Гыйбад Алпаров, Сәлах Атнагулов, Сибгат Гафуров, Гали Рәхим, Галимҗан Шәрәф, Гаяз Максудов, Габдрахман Сәгъди, Нигъмәт Хәким һәм делегациянең җитәкчесе итеп Татарстан Мәгариф комиссариятының Гыйльми

үзәк рәисе Галимҗан Ибраһимов. Ул, билгеле булганча, бераз үзгәртелгән гарәп алфавитын яклый. Татарстан делегатлары үз чыгышында алфавит, орфография мәсьәләләренә караган, атамалар ясалышы, шрифтлар системасы турында булсын, гарәп алфавитында калуны, аны реформалау юлы белән үзгәртеп, камилләштерү юлын яклыйлар. Татарстанның һәм татар җәмгыятенең яңалифкә күчү өчен тарихи-мәдәни, икътисадый яктан әзер түгеллеген, һәм моның кискен зарурлыгы да юк дип белдерәләр.

Казакъстан Республикасы делегаты Ә.Б. Байтурсунов та латин алфавитын кабул итүгә каршы чыгыш ясый. Казакъларның инде гарәп шрифты нигезендә алфавиты бар һәм ул безнең барлык ихтыяҗларны да канәгатьләндерә, ди. Безгә латин алфавитына күчүнең кирәге юк. Әгәр күчсәк тә иң идеальные рус алфавитына, ди. Чөнки Россиядә яшәгәч, безнең балалар русча белергә тиешләр. Ә латинны бер дә алфавиты булмаган халыклар кертсен. Бүгенге көндә съезд алдында мөһим мәсьәлә алфавит сайлау түгел, ә иң әһәмиятлесе – артта калган төрки халыклар өчен уку әсбаплары, дәреслекләр төзү проблемасы торырга тиеш, барлык культура хезмәткәрләренең төп игътибарын шуңа юнәлдерергә кирәк, ди.

Татарстан делегатлары съезд эшендә докладлар һәм чыгышлар белән дә актив катнашалар.

Академик үзәк рәисе Галимҗан Ибраһимов 1 нче мартта, корылтайның 6 нчы утырышында «Төрек телләренең имлясы» («Об орфографии тюркских языков»)[1] дигән доклад ясый. Ул докладын татар телендә укый. «Съездда [нинди телдә] сөйләү мәсьәләсе бераз куркыткан иде. Истанбул, Казан, Сәмәрканд, Кызыл Урда һәм башкалар бер-берсен аңлый алмаслар, төрек мәҗлесендә тик русча ярдәме белән генә аңлашырга мөмкин булыр дигәннәр бар иде. Ләкин алай булмады. Анатоли төрекләренең әдәби телләрендә сөйләгән Фуад бәкне [Күпрүлү-задә] Башкортстан, Төрекмәнстан вәкилләре җиңел аңлаган кебек, безнең әдәби татар телендә язып барган докладларны да һәммәсе мәшәкатьсез аңладылар (тик руслар өчен генә докладның кыскачасын, тәрҗемә итеп бирергә туры килде ...)»[2] дип яза үзе бу хакта.

Г. Ибраһимов докладының русчага тәрҗемә ителгән өлеше съездның стенографик отчетына кертелгән. Текстны шуннан алып тәкъдим итәбез.

---

[1] *Аның бу докламы турында «Кызыл Татарстан» газетасында (1926, 3 март, № 51) «Галимҗан Ибраһимов доклады» исеме белән кыскача информация чыга.*

[2] *Ибраһимов Г.* Тюркология съездында тикшерелеп үтелгән мәсьәләләр // Кызыл Татарстан. 1926. 21 март. № 65.

II

Съездның 7 нче утырышы (1 март, 1926) тулысынча орфография мәсьләләренә багышланган докладлар буенча фикер алышуларга һәм докладчыларның йомгаклау чыгышларына багышлана. Г. Ибраһимов докладына мөнәсәбәттә фикерләрен әйтеп Х. Габитов, Г. Сәгъди, Ш. Манатов, Г. Алпаров, Г. Алиев, Н. Хәкимов, Б. Чобан-задә чыгыш ясыйлар. Әмма стенографик отчетта аларның текстлары юк. Фамилияләре күрсәтелеп, «выступили на тюрко-татарском языке» дип кенә әйтелгән.

Г. Ибраһимов үзенең соңгы сүзендә әлеге оппонентларга һәм орфография турындагы 6 нчы утырышта үзеннән соң ясалган докладларга карата фикерен белдереп чыгыш ясый (Тексты тәкъдим ителә).

III

Съездда гарәп һәм латин алфавитларының өстенлекле һәм кимчелекле якларын яклап көрәш кызганнан кыза, бәхәсләр куера бара. Татарстан делегатлары Г. Алпаров һәм Г. Шәрәфнең гарәп алфавитын яклап ясаган докладларына карата кискен тәнкыйть фикерләре яңгырый. Мәсәлән, Мәскәүдән Центроиздат җитәкчесе Н. Түрәкулов үзенең чыгышында: «Иске гарәп алфавитына яңалыклар кертеп кенә берни дә үзгәрмәде, катлауланды гына. Саннар, химик формулалар уңнан сулга таба язылып – көлке хәлгә кала», – ди. Тагын да кызып китеп: «Старое арабское письмо, старая арабская грамота осуждена историей и отвергаются раз навсегда. Необходимо и пора покончить со старой арабской системой письма и алфавита», – дип, катгый итеп әйтә.

Проблеманы тагын да кискенләштереп: «...әйтергә теләгән фикерем шул: Г. Шәрәф һәм Г. Алпаров үзләренең дәлилләре белән бераз соңга калдылар, чөнки татар укытучылары һәм татар яшьләре 1924 елда Мәскәүдә конференциягә җыйналдылар. Анда җитәкчеләр сыйфатында, биредә, безнең арада утыручы иптәшләр, шул исәптән председатель һәм Татарстан делегациясенең җитәкчесе иптәш Г. Ибраһимов та катнашкан иде. Аның докладында латин алфавитының гарәпнекеннән бөтен яктан да өстенлеге танылган иде һәм шунда татар укытучылары принципиаль рәвештә латин алфавитын кабул итәләр дигән карар кабул ителгән иде. Бәлки ул чакта иптәш Ибраһимовка шунда чыгыш ясаган мәрхүм Наримановның тәэсире булгандыр. Мин моны, Г. Ибраһимовны гарәпчеләр алдында «реабилитацияләү» рәвешендә әйтәм. Әмма тегеләйме, болаймы халык арасында мәгърифәтчелек белән шөгыльләнүче татар яшьләре һәм укытучылар шул карарлары белән, ике төрле уйларга урын калдырмыйча, латин алфавитына күчүгә уңай мөнәсәбәтләрен белдерделәр.

Мәсьәләнең практик ягына якын килгәндә, яңа төрки алфавитны (яңалифне) кабул итүне тормышка ашыру методлары аерым

тикшереләчәк. Мәсәлән. Г. Шәрәф, Г. Алпаров һәм башка иптәшләрдән 1927 елның 1 гыйнварында яңа төрки алфавит белән язуларын беркем дә таләп итмәс», – дип, татар алфавиты реформаторларын төрлечә «гаепләп», «һөҗүмнәр» ясап, гарәп алфавитыннан баш тартып, яңалифчеләр ягына аудармакчы була.

Г. Алпаров һәм Г. Шәрәф докладларына караган башка чыгышларда да яңартылган гарәп алфавитын гамәлдә калдыруны яклаучылар терминология, орфография һәм туган телне укыту методлары мәсьәләсен хәл итүдә зур кыенлык тудыралар дип күрсәтелә.

Татар телендәге авазларга хәрефләр җитмәве ассызыклана. Яңалифнең бу яктан да өстенлекле икәнлеген исбатларга тырышалар.

Мондый гаепләүләр, бәйләнүләрдән соң, Г. Ибраһимов, мәсьәләгә ачыклык кертеп, съездда өченче мәртәбә чыгыш ясый. Биредә ул үз карашларында мөстәкыйль һәм үзенең тоткан позициясен җиңел генә ташларга теләми торган, нык ихтыярлы шәхес булып күз алдына баса. Аның бу ныклыгы съездда яңалиф мәсьәләсендә дә ачык күренә. Башка халыкларның тәҗрибәләренә таянып, алфавит алыштыруны революцион юл белән түгел, ә эволюцион юл белән хәл итәргә кирәклекне дәлиларгументлар белән аңлата.

Әдип, фикер иясе буларак, тел гыйлеме өлкәсендәге белеменә таянып, аек акыл, салкын канлылык саклап, оппонентларына проблеманың асылын сабырлык белән җиткерергә тырыша.

Г. Ибраһимовның съезда сөйләгән докладын һәм чыгышларын стенографик отчеттан алып, алда сөйләнгән эзлеклелектә тәкъдим итәбез.

## I
## Галимджан Ибрагимов об орфографии тюркских языков
(*доклад*)

(1 март, 1926)

Доклад мой распадается на три части. Первая часть включает критический анализ тех старых систем уйгурской, орхонской и старо-татарской орфографии. Во второй части описываются те движения, которые были направлены к реформе арабского шрифта и уточнению орфографии тюркских народов. Тут описываются османско-турецкое движение, башкирское, узбекское, крымское и т.д. Главное внимание этих движений было обращено на то, чтобы установить, сколько гласных звуков в том или другом наречии, какими буквами их надо изображать, потому что в арабской орфографии из 10-ти гласных изображается только три. Потом,

как быть с арабскими словами, которые употребляются много и пишутся они не татарским, узбекским, казакским правописанием, а чисто арабским, и, таким образом, создаются три орфографии в одном языке: тюркская, арабская, а иногда и персидская. Движение это было также направлено к ликвидации исключений. В третьей части моего доклада заключаются те конкретные предложения, которые могут до некоторой степени облегчить, а, во-вторых, покончить с тем разнобоем, разногласием, которое существует между тюркскими народами. И предлагается для уточнения тюркской орфографии принимать во внимание следующие особенности тюркских языков:

1. Сингармонизм – это не требует объяснений и заключается в том, что буквально все слова во всех тюркских наречиях бывают твердые или мягкие, по этому закону подчиняются все суффиксы; при составлении нашей орфографии эту особенность надо принять во внимание.

2. Агглютинация. Известно, что языки разделяются на 3 группы: урало-алтайские принадлежат ко второй группе, где корень и суффикс остаются одинаковыми во всех падежах. В русском языке, например, имеются падежи и соответственно словам изменяются, а у нас, например, «сүз» (слово) во всех падежах остается в таком же виде, и все падежные окончания повсюду, в именах существительных и прилагательных, остаются одинаковыми. Это свойство общее для всех [тюркских] языков, и это надо принять.

3. Третьим моментом для уточнения орфографии надо взять не только фонетический момент, но необходимо, главным образом, принять во внимание морфологический момент. Дело в том, что у нас в тюркских литературных языках особенно много наречий, например: у казанских татар 6–7 литературных наречий – наречие мишерское, казанских татар, касимовских татар и т.д.

Все они по своему фонетическому составу очень разнообразны, и если мы будем принимать во внимание только фонетические основы, то нужно взять одно наречие, а для остальных это будет уродством, а потому я предлагаю принять морфологический момент.

4. Тут я предлагаю практический метод для того, чтобы покончить с анархией, которая имеется у нас во всех буквально языках. Необходимо от имени Курултая сказать веское слово, т.е. с

попытками подчинения правописания отдельным наречиям – надо вести борьбу.

5. Для того, чтобы облегчить нам образование турецкой литературы, необходимо принять такую меру, что во всех случаях, когда предлагаются новые слова, новые буквы, необходимо, чтобы тюркские литературные языки согласовывали эти моменты между собой. Например, казакский язык по закону сингармонизма употребляет обозначение мягких слов, а татарский и башкирский для обозначения твердости. Мы на это должны обратить внимание. Необходимо также урегулировать и привести в порядок, чтобы у всех наречий были общие знаки и буквы. Дальше мною предлагается еще один конкретный метод. Радлов составил научную академическую транскрипцию, это очень хорошо. Мы, тюркологи, этим пользуемся, но когда нужно писать по-татарски, по-узбекски арабским шрифтом – это создает большие затруднения. Поэтому я предлагаю на основе академической научной транскрипции создать арабский шрифт для словаря. Это будет не для практического потребления, а для точного изображения звуков и еще маленьких оттенков, как например, у нас во всех тюркских наречиях гласных больше. Это не для орфографии – это для научного употребления.

Выражаю общее положение, что для урегулирования тюркской орфографии необходимо, вообще, сохранить и практические термины. Я немного осторожно употребляю этот принцип культурно литературной федерации тюркских языков. Мы не можем создать единого тюркского языка, – это не позволяет ни фонетика, ни морфология, и главным образом социально-экономическое положение, но мы, тюркские народы, не можем изолироваться. Например, Якутская область очутилась в очень трудном географическом положении, якуты оторваны от нас, не могут пользоваться нашим опытом, и мы не можем пользоваться тем, что есть у них. Поэтому полагаю, что в будущем для всех работ по орфографии этих языков эта терминология должна быть взята в основу, а также не оторванность каждого языка от другого. Я настаиваю: не оторванность будет заключатся в федерации, даже не в конфедерации, а в федерации тюркских языков, что каждый язык будет автономен в своем строении, но у всех тюркских языков есть общие основы, общие законы, общие черты, которые. должны быть приняты во внимание. Это понятие федерации неточно,

но, я думаю, злоупотреблять этим словом не будут. Я хочу принять во внимание, что при составлении будут две категории свойств: первая категория – это свойство и особенности каждого языка, вторая категория – свойства, общие всем тюркским языкам. Вот беглый обзор моих материалов, которые были изложены на татарском языке.

*Первый Всесоюзный Тюркологический съезд.*
*Стенографический отчет. Баку, 1926. С. 163–165.*

## II
## Заключительное слово докладчиков

(1 март, 1926)

***Галимджан Ибрагимов.*** Товарищи, мне трудно говорить на русском языке, все же я вынужден это сделать, потому что мой утренний доклад был не всем понятен. Я начну с конкретных моментов. Габитов[1] упрекал меня в том, что я дал неправильную информацию относительно башкирского наречия. Я много в этой области работал, и хорошо знаю, а кроме того есть сборник, который посвящен целиком Тюркологическому съезду. Этот сборник издан под редакцией Габитова. Он говорит, что у башкиров имеются две категории наречий: основное и татаризированное. К основным он причисляет: кубели, эйзе и т.д. – это основные, а татаризированные – копсак (кыпчак) и т.д. Таким образом, я не знаю, чему верить – этому выступлению, или тому сборнику, который посвящен Тюркологическому съезду.

Относительно выступления Манатова[2]. Он упрекает меня, что я дал здесь слишком неточные и краткие сведения относительно движения по реформе орфографии в Турции и Азербайджане. Но я был ограничен временем и не мог на этом остановиться. Все же я подчеркнул, что подробности можно получить из книги Ага-Заде, там есть подробности, но на основных моментах, о том, какие были

---

[1] *Габитов – Хәбибулла Габделкадыйрович Габитов (1886–1939), шагыйрь, тел белгече, фольклорчы, педагог. Башкортстан делегаты, Уфадан.*

[2] *Манатов – Шәриф Әхмәтҗанович Манатов (1887–1936), күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, башкорт милли хәрәкәте лидерларының берсе, хөкүмәт рәисе; көнчыгышны өйрәнүче галим, тюрколог, педагог, журналист. Башкорстан делегаты.*

съезды в 5, 6 годы [в 1905-ом, 1906-ом году], я все таки останавливался. Если Манатов интересуется этим вопросом, я могу дать ему эти материалы. Кроме того тут произошла путаница. Товарищ Манатов говорил, что как будто я предлагаю турецкий язык взять за основу, и основываясь на этом языке, создать орфографию. Товарищ, вы не так меня поняли, я сказал, что в наших отдельных турецких наречиях – узбекском, башкирском и т.д. есть основные общие черты в фонетике и морфологии. Это должно быть взято за основу, и, кроме того, я сказал, что не надо допускать провинциализма, а провинциализм есть – фонетический, морфологический и орфографический. Я, может быть, неточно выразился, но я хотел сказать, что не надо допускать провинциализма в орфографию. Товарищ Рахими[1] говорил и запутался. Он говорил, что в своем докладе Самойлович[2] говорил, что туркмены и азербайджанцы входят в южную группу. Я, конечно, это знаю, и я не говорил о таких классификациях. Я говорил только, туркмены, по тем результатам, которые они сделали в орфографии, стоят ближе к казакам и узбекам, чем к азербайджанцам. Еще серьезный вопрос возник с выступлением товарища Чобан-Заде[3]. Из его выступления на мою долю относится два момента. Он отрицает значение сингармонизма и значение основных моментов агглютинации. Я считаю, что это неправильно, особенно по отношению к родственным языкам. Чобан-Заде хороший филолог и знает древние тюркские языки. Ему известны все работы и все ученые тюркологи, как арабские так и русские, особенно Радлов и другие; все эти ученые указывали, что во всех этих наречиях это свойство определенно было. Во всех академических изданиях это подчеркивается, как особая теория, а в практическом отношении во всех реформированных орфографиях говорится, что в этом отношении тюрки отстали. Суиндж…

---

[1] *Рахими – Шакирҗан Рәхими (1893–1938), үзбәк мәгърифәтчесе, педагог, лексикограф, Ташкент Халык университетын оештыручыларының берсе, күп санлы мәктәп дәреслекләре авторы, латин алфавитына нигезләнгән үзбәк орфографиясенә нигез салучы. Үзбәкстан делегаты.*

[2] *Самойлович – Александр Николаевич Самойлович (1880–1938), Ленинград университеты пофессоры, академик (1929), востоковед, тюрколог, съездны оештыру комитеты әгъзасы.*

[3] *Чобан-Заде – Бекир Ваһапович Чобан-Задә (1893–1937), кырымтатар шагыйре, тюрколог, Баку университеты профессоры, оештыру комитеты әгъзасы. Азәрбайҗан делегаты (чыгышы белән кырымтатары).*

говорит в своей грамматике (*читает по-тюркски*). И во всех тюркских языках, и во всех грамматиках это принято во внимание. Он определенно говорит: «…тогда мы можем объединить все урало-алтайские наречия». Это немного не то; эти народы культурно разобщены и я настойчиво предлагаю вашему вниманию при составлении тюркской орфографии, это основные моменты учесть, это явится и экономией и облегчением. Байтурсун[1] сказал, что тюркские языки строгие (*по-тюркски*), и это еще больше усилится, если мы будем изучать эти два момента.

*Первый Всесоюзный Тюркологический съезд.*
*Стенографический отчет. Баку, 1926. С. 177–179.*

## III
## Выступление Г. Ибрагимова на прениях

(3 март, 1926)

***Г. Ибрагимов.*** Товарищи, я взял слово не для полемики, а только для того чтобы дать несколько справок. Справки мои относятся к трем основным вопросам: во-первых, принципиальный подход к этому вопросу, во-вторых, оценка того опыта, который производится в Азербайджане среди северо-кавказских народностей, а также в некоторых тюркских республиках. Третий момент моей справки будет относится к тому, как относится к этому вопросу в своей практической работе Татарская республика, в частности, татарская советская общественность вообще.

По первому вопросу я выскажу не только мое личное мнение – а я буду исходить из некоторых постановлений, которые были в течение последних двух лет. В 1924 году в Москве был Всероссийский Съезд татаро-башкирских просвещенцев. На этом съезде обсуждался вопрос орфографии, шрифта. Было постановлено съездом, что принципиально латинский алфавит возражений не встречает. Наоборот, он имеет некоторые преимущества перед арабским (*аплодисменты*). Товарищи, во избежание недоразумений не надо пока аплодировать. Дальше было сказано, что главное

---

[1] *Байтурсун – Әхмәт Байтурсунович Байтурсынов (1872–1937), күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, Казакъстан Мәгариф комиссариятының Гыйльми үзәк рәисе, тел галиме, тюрколог, профессор, казакъ орфографиясенә нигез салучы. Казакъстан делегаты. Кызыл-Урдадан.*

внимание будет обращено на реформу. Еще раньше, в 1921 году, в Казани было совещание и конференция журналистов. Там тоже было постановлено, приблизительно, в таком же духе. Это – официальное постановление не отдельных лиц, а общественного характера. В связи с Тюркологическим съездом, так как нам было известно, что здесь будет поставлен вопрос о шрифте, нам нужно было в Татарской Республике выяснить мнение по этому вопросу. У нас, – сообщаю официально, – мнение такое, что принципиальных возражений против латыни мы не имеем. (*Продолжительные и бурные аплодисменты. Возгласы: «браво»*). Как мы понимаем принципиальный подход к этому вопросу? Мне приходилось много говорить по этому вопросу. Некоторый подход с точки зрения религиозный, некоторый подход с точки зрения национализма говорит, что арабский шрифт – это есть один из элементов нашей национальности и т.п. Говорят еще, что наша восточная культура имеет свои особенности. Одной из этих особенностей является шрифт, который имеет свою историю и т.д. Когда мы говорим, что принципиальных возражений нет, мы подходим к этому вопросу, главным образом, из тех соображений, что он имеет больше преимуществ перед арабским алфавитом. Как мы относимся к тому опыту, который производится в Азербайджане, в Северо-Кавказских республиках, о чем говорил товарищ Алиев[1], и, как я понял, товарищ из Киргизской Республики? Как мы относимся? Мы на этот опыт смотрим, как на крупный исторический важности опыт, безусловно очень ответственный, но, товарищи, вы знаете, что не всякий опыт и даже очень не исторически-важный бывает удачен. За исход опыта еще трудно отвечать. Во всяком случае, мы смотрим на этот исторический опыт, как на великий опыт, и если даже он не удастся, даже в этом случае нужно считать его исторически важным. Третья справка будет относится к вопросу о том, как относится у себя Татарская Республика к этому вопросу. Нужен

---

[1] *Алиев – Гомәр Джашуевич Алиев (1895–1937), карачай тел белеменә нигез салучыларның берсе. Карачай теленең грамматик төзелешен системалы язган галим, лексикограф, күп санлы дәреслекләр авторы, шәрыкъ телләре белгече, тюрколог, Мәскәү университетында гарәп телен укыта, профессор. Съезддагы чыгышында ул Төньяк Кавказ республикаларында 1921 елдан латин алфавитын гамәлгә кертү турында сөйли. Латин алфавиты нигезендә мәктәпләрдә укыта башлыйлар, дәреслекләр язалар, хәтта газета да чыгаралар. Бу төрки халыкларны латин графикасына күчерүнең беренче тәҗрибәсе була.*

принципиальный ответ. Приветствуется опыт Азербайджана, мало этим обойтись. Этот вопрос относится к нам самим, к Татарской Республике, в частности к татарской советской общественности. Не все татары живут в Татарской Республике, больше половины татарского народа живет вне ее. В прошлом и позапрошлом году были попытки некоторых товарищей, которые организовали латиндуст и хотели там работать, но сочувствия не нашли, и в дальнейшем у нас вопрос о латинизации идет безусловно очень туго. Причины в следующих моментах: во-первых мы, татары, имеем литературу с историей не менее 600 лет, мы имеем сейчас печать, а именно печатное слово на татарском языке, уже более 125 лет. Дальше, татарская общественность работает над реформой арабского шрифта уже более 50 лет, причем последние 25 лет мы имеем огромные достижения в этой области. У нас нет ни одного более или менее культурного совещания, где бы не обсуждались вопросы арабского шрифта. У нас работают над этим вопросом не отдельные личности, а вся общественность. Каждый Съезд, каждая конференция вносили свою лепту в эту большую коллективную работу. В результате у нас получились более или менее, – подчеркиваю, – более или менее сносные результаты (похвалиться пока еще нечем), хотя, конечно, есть недостатки, на которые мы не закрываем глаза.

Напрасно товарищ Бердиев[1] старался доказать, что это самый неудобный шрифт. Нет, это неверно. Он среди всех реформированных шрифтов является более или менее сносным. Мы сейчас подошли к последнему моменту, когда необходимо выбрать, какую из трех арабских форм необходимо оставить. Практически этот вопрос еще не был разрешен. Когда мы приехали сюда на Съезд то мы говорили, что латинизация не может быть для нас центральным вопросом потому, что у нас нет в ней особенной потребности, как у Азербайджана и Турции, потому, что они находятся в совершенно ином положении, чем мы.

Дальше, я обращу внимание на печать. Я мог бы вам изложить, что в этом году Татарской Республикой принят план издания

---

[1] *Бердиев – Бекги Эмирович Бердиев (1897–1954), төрекмән мәгърифәтчесе, Төрекмән Халык мәгарифе комиссарияты (Наркомпрос) хезмәткәре, тарихчы, тюрколог, лексикограф. Съездда «Төрки халыкларның алфавиты» дигән темага доклад ясый, «Төрекмәнстан тарихы турында очерклар», «Русча-төрекмәнчә сүзлек» авторы.*

3000 печатных листов: 1000 листов политической литературы, 1500 листов для Наркомпроса, т.е. учебников, а остальные – краеведческие, и на русском языке. Может быть этот план не удастся выполнить полностью, но, во всяком случае, на 70–85 % он будет выполнен. Это конечно, огромная литература. Кроме того мы собираемся издать до 100 000 экземпляров букварей. Но, может быть, мы не являемся единственными представителями татарского печатного дела. В Астрахани, в Москве, даже в далекой Сибири идет повсюду огромная работа по издательству книг, по издательству учебников. Это с одной стороны. С другой стороны, такую же огромную работу мы имеем в отношении ликвидации неграмотности. Некоторые из присутствующих здесь могут подтвердить, что у нас имеется по три учебных заведения, включая избачей и учебные заведения низшего и высшего типа; детских домов и школ у нас около 2000. У нас остается больше 2000 мугаллимов татар.

Надо подойти к вопросу конкретно и деловито, декларацией я заниматься не буду. Если мы скажем, что переходим на латынь, то с завтрашнего дня надо заняться этим начать переподготовку: переподготовить избачей, переподготовить огромную машину, которая теперь работает хорошо. Сейчас мы не хотим ее остановить, нам важно, чтобы по возможности эта машина усовершенствовала и работала. Благодаря проводимой нами реформе, которую мы стараемся проводить сразу на все 100%, наша машина ни на одну минуту не остановится. Таким образом, татарская общественность, которая обслуживает 5 000 000 народ, достигнет больших результатов.

Вот почему, товарищи, латинизация для нас вопрос. У нас понемногу все было подготовлено к реорганизации алфавита, когда мы сюда приехали. На нас отчасти здесь смотрели так, как будто мы приехали сюда для борьбы, но у нас совершенно не было мысли о борьбе. Мы почувствовали здесь, что оказывается, не во всех республиках вопрос обстоит так, как он обстоит у нас. В Азербайджане еще употребляется старый шрифт, который безусловно никуда не годится, реформой здесь не занимались, хотя первую мысль о реформе дал азербайджанец Фатали Ахундов[1], но

[1] *Ахундов – Мирза Фатали Ахундов (1812–1878), азәрбайҗан мәгърифәтчесе, язучы, шагыйрь, философ һәм җәмәгать эшлеклесе. Азәрбайҗан драматургиясенә һәм әдәби тәнкыйтенә нигез салучы.*

тогда еще не получило практического применения. Теперь, если мы возьмем Северный Кавказ, то мы очень хорошо понимаем товарища Умара Алиева, когда он говорит, что они уже проводят латинский алфавит. Когда я читал его статьи, то я увидел, что у них ликвидация неграмотности уже проводится в деревнях на латинской графике.

Я хочу подчеркнуть, что в этом вопросе, к великому сожалению, – но боюсь, что меня обвинят в пантюркизме, – есть большая опасность. Но здесь дело не в полемике. Мне не приятно полемизировать, но я хочу сказать, что здесь трагический момент для кара-киргизов, – к сожалению, мы до сих пор плохо знаем наши тюркские братские народы – у кара-киргизов не было алфавита, нет культурных работников. Поэтому для них, может быть, удобнее применить латинский алфавит, а для других, как например, Туркреспублики, это не будет полезно, а послужит только задержкой огромной машины, которая там сейчас работает.

Товарищ Байтурсун говорит, что не нужно единого алфавита. Не знаю, удастся ли нам вообще сохранить единый алфавит, но во всяком случае это очень серьезный вопрос и к нему надо подходить очень осторожно, потому что здесь играет роль социальные, культурные, экономические и исторические условия. Эти условия у различных народов различны, с этим надо считаться; в силу этого получается и различное положение. Один народ имеет 500-летнюю историю, а другой ничего не имеет. Это возможно в одном месте, а в другом месте невозможно.

Этот вопрос еще важен потому, то тюркские народы, благодаря этому, могут разъединиться на очень маленькие группы и это будет иметь значение для дальнейшего развития.

Татарская Республика в этом вопросе исходит только у своих данных конкретных условий. Этим своим выражением я обращаюсь особенно к марксистам. Когда мы говорим, что на 100% наше внимание будет направлено на реформу арабского алфавита, то мы должны исходить из наших данных конкретных условий. То, о чем я говорю, о принципиальных моментах, на основе которых ведется работа, я должен еще раз подтвердить и сказать, что наша позиция верна.

В вопросах реформы арабского шрифта, я резюмируя свою мысль, должен сказать, что старый арабский шрифт никуда не

годится (*аплодисменты*). Я подчеркиваю, чтобы все хорошо слышали, что старый арабский шрифт никуда не годится (*аплодисменты*).

Дальше, для того, чтобы освободиться от этого хлама, нужны были методы. Есть два метода: я не боюсь, чтобы нас обвиняли в консерватизме, – есть метод реформы и метод революции. Мы держимся реформы, товарищи меня знают, – я, во многих случаях революционно настроенный человек, но в данном случае мы держимся метода не революционного, а метода реформы, потому что наши конкретные данные условия заставляют идти за остальными опытами. Я уже сказал какими.

(Председатель. Заседание объявляю закрытым.
Заседание закрывается в 9 часов вечера.)

*Первый Всесоюзный Тюркологический съезд. Стенографический отчет. Баку, 1926. С. 277–280.*

*Текстларны басмага Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының тестология бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты*
*Әнисә Алиева әзерләде.*

## Галимҗан Ибраһимовның Беренче Бөтенрусия мөселманнары корылтаендагы чыгышлары

1917 елны Галимҗан Ибраһимов Уфада «Галия» мәдрәсәсендә татар теле һәм әдәбиятын укытучы буларак каршылый һәм, Февраль революциясе булуы ишетелү белән, килеп туган катлаулы вәзгыятьне татар халкы мәнфәгатьләре яссылыгында файдалану юллары турындагы уй-фикерләре белән таныштыра башлый. 1908 еллардан башлап татар вакытлы матбугатында әледән-әле чыгыш ясап торган әдип бу юлы махсус газета чыгару фикеренә килә, һәм тиздән Уфада аның редакторлыгында (Фатих Сәйфи-Казанлы наширлегендә) иҗтимагый-сәяси мәсьәләләрдә эсерлар (социалист-революционерлар) юлын тоткан, Россиядә «идарә ысулының федерация нигезенә төзелүен куәтли» торган, башлыча, Россиядәге иҗтимагый үзгәрешләр белән таныштыруны да максат иткән «Ирек» газетасы чыга башлый. Аның 1917 елгы 30 мартыннан 11 сентябрьгә кадәр нәшер ителгән саннарының һәрберсендә диярлек «Г. Ибраһимов», «Г.И.» имзалы (һәм имзасыз да) үз мәкалә һәм чыгышлары урын алган.

1917 ел май аеның 1–11 нче көннәрендә Мәскәүдә Бөтенрусия мөселманнарының I съезды барган вакытларда Г. Ибраһимов та анда була, делегат буларак гомуми җыелышларының секция эшләрендә катнаша. «Ирек» газетасының хәбәрчесе сыйфатында да эшчәнлек күрсәтә. Бу турыда әлеге газета битләрендә аның кайнар рухлы унлап репортажы, мәкаләсе басылган.

Россиянең бөтен тарафыннан диярлек сайланып килгән 800 делегет катнашында уздырылган съездда сәяси, милли мәсьәләләрне тикшерү һәм карарлар кабул итү шома гына бармаган, бәхәсләр дә кузгалган, кыскасы, төрле ситуацияләр дә булган. Әйтергә кирәк, алар татар вакытлы матбугатында да чагылыш тапкан, аерым алганда, «Вакыт», «Йолдыз», «Кояш» шикелле татар газеталары битләрендә яктыртылган. Алардагы мәкалә-хәбәрләрдә, репортажларда күп очракларда Гаяз Исхакый, Әхмәтбәк Салихов, Фатих Кәримиләр телгә алына, берничә тапкыр Галимҗан Ибраһимов исеме белән дә очрашабыз. Бу урында без андый моментларны җентекләп анализларга алынмастан, укучыларны бары берсе белән генә таныштырмакчы телибез. Ул «Йолдыз» газетасының 1917 елгы 19 май (1795 нче) санында «Гомуми мөселман съезды» исеме белән урнаштырылган. Репортажга тартым, шактый гына күләмле бу язмада сүз 10 майдагы җыелыш турында бара. Ул Гаяз Исхакыйның Бөтенрусия мөселманнарының гомуми оешмасын булдыру мәсьәләсен күтәргән докладлы белән башланып китә, әмма анда чыгыш ясаучылар әүвәлдә мөселманнар тотарга тиешле тактика һәм платформа (Учредительный собраниягә сайлауларда) мәсьәләсен нәүбәткә алып тикшерүне алга сөрәләр. Шунлыктан көн тәртибе үзгәрә. Уфадан килгән делегат Гомәр Терегулов, сүз алып, фикер алышуга үзенең резолюциясен тәкъдим итә. Ул ике маддәдән тора: «1) халыкчылык әсасенә корылган мөселманнар блогы ясау; 2) мөселманнарның хатты хәрәкәләрендә трудовиклардан башлап, суллар белән бергәләшүләр мөмкин булыр». Репортажда Гаяз Исхакый тәкъдим иткән резолюциядә исә, «Сәяси хәрәкәтебездә безнең уң канатымыз монархистларны кертмәс өчен, сул канатымызда анархистларны йибәртмәс өчен казык кагылсын, сызык сызылсын» диелгәнлеге әйтелә. Бу фикергә чыгыш ясаучылар тарафыннан «бик каты һөҗүмләр» ясала. Аеруча Галимҗан Ибраһимов кискен каршы чыга. Аныңча, мөселманнар өчен блок ясарга кирәк, иң кирәк партия – социал-революционерлар партиясе. Ул «Учредительный Собраниягә сайлауларда зур көч ясау өчен, мөселманнарга кушылып бергә хәрәкәт итәргә социал-революционерлар партиясенең муафикъ икәнен» исбат итә: «Русиядә крестьяннар күп, алар революционерлар белән бергә баралар. Учредительный собраниягә крестиян вәкилләренең күп үтүенә күз йитәдер. Безнең халкыбызның да күбрәк кыйсеме (өлеше) – крестьян. Шулай булгач, безгә дә блок ясауны алда тотарга кирәк».

Әмма Галимҗан Ибраһимов фикере Гомәр Терегуловка һич тә охшамый, ул, мәсьәләне кискенләштереп: «Минем социал-революционерлар белән кушылу ихтималым юк. Алар үтерүчеләр», – дип кычкыра. Җыелышта зур тавыш күтәрелә, «Долой, долой!» тавышлары астында ул мөнбәрдән куып төшерелә. Репортажда Мохтар Мутинның да Г. Терегуловка каршы чыгуы әйтелә. «Безгә бу көнге хөрриятне алып бирү өчен корбан булган революционерларга Гомәр әфәнде шакшы ташлый. Соң Александр Икенчене кем, башка залим түрәләрне үтерүче кемләр булган?. Алар хата эшләгәнләрме, халыкны золым-җәбер кыйлып торган ерткычларны үтермәсәләр, бу көнге хөрриятькә ирешер идекме?» – дигән сорау куя ул.

Шулай да мәҗлес тынычлана алмый, президиум хәтта урынын ташларга мәҗбүр була. Халык эченнән: «Безне кысасыз, үз теләгән әйберләреңезне генә йоттырырга телисез. Без монда ярты миллион акча туздырып килдек. Иркенләп сөйләргә бирмисез», – дип кычкыралар.

Бераздан җыелыштагылар тынычлана, кайбер башка мәсьәләләр дә карала. Ахырда кабул ителгән мәгъруздә[1] «Русия мөселманнары эчендәге бөтен оешмаларның бергәрәк хәрәкәт итү өчен мөштәрәк[2] бер юл табулары» кирәклеге әйтелә һәм аны табуны съездда сайланачак Милли Шурага йөкли, Учредительный собраниягә сайлауларда тактиканы билгеләү өчен 25 августта Мөселманнарның икенче съездын уздыруны кирәк дип таба...

10 майдагы шау-шулы мәҗлеснең барышы ул заманда татар телендә чыккан башка кайбер газеталарда да чагылыш таба. Билгеле инде, газетадагы мәйданда вакыйгаларның барысын да тәфсилләп бирү мөмкин булмаган. Әмма шунысы бар, съездны оештыручылар, Русиядә яшәүче барлык мөселманнар тормышында гаять тә әһәмиятлелеген искә алып, аның материалларын китап итеп бастыру чарасын да күрәләр. Ул «Бөтенрусия 1917 елда 1–11 майда Мәскәүдә булган гомуми съездының протоколлары» исеме белән Петроградның «Әманәт» ширкәтендә басыла (тәртип итүче – Кәрим Сәгыйд). Китапның 407–410 битләрендә съездның әлеге 10 майда булган җыелыштагы (мәҗлестәге) хәлләр турында да шактый җентекле язылган. Шул исәптән, аерым ораторларның чыгышлары шактый зур күләм алып тора. Кайберләрен аннан күчереп алып, фикерләре аңлашыларак төшсен өчен, укучылар игътибарына да тәкъдим итәргә кирәк дип уйладык.

*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре Зөфәр Рәмиев,*

[1] Мәгъруздә – проект, доклад.

[2] Мөштәрәк – уртак.

1. Съезднын башка мәҗлесләрендә дә мөнбәргә еш күтәрелгән **Гомәр Терегулов (**җыелыш рәисе аның чыгышын доклад дип атый):

«Әүвәлдә мөселман партиясе бар иде («Иттифакы мөслимин» истә тотыла; 1906–1908). Бу партиянең программасы кадетлар партиясенең программасы белән бер иде (дөресрәге, кадетларга якын мөнәсәбәттә). Хәзер инде без бу партиягә хәкарәт итеп карый башлаганга, ул партиянең программы буенча бара алмыйбыз. Хәзер мөселман халкы бер партиясез калды. Безгә бер платформа төзергә кирәк булды. Безнең бу җыелышымыз, башка милләтләрдәге кебек түгел: безнең бу съездымызда бер генә сыйныф халык түгел, төрле сыйныфлардан гыйбарәт. Бунда эшчеләр булганы кебек, муллалар да, укытучылар да, йир эшләүчеләр дә (дәһканнар да) һәм башкалар да бар.

Инде менә бу көн – съездның ахыргы көне. Без моңар кадәр бер платформа ясый алдыкмы? Юк, дип җавап бирәсе килә минем. Чөнки бу съезд беренче булганга һәм аны җыйганда вакыт аз булганга, бу съездга кертелгән докладлардагы мәсьәләләр төрле яктан каралып эшләнеп йитмәгәннәр иде. Без ысул идарә мәсьәләсен генә тик төрле яктан карап тикшердек. Бу сәяси мәсьәлә булганга күрә шулай кирәк тә иде. Ләкин бу мәсьәләне генә хәл кыйлу белән бер платформа ясап булмый.

Тактика мәсьәләсендә дә, мәсьәләне озакка сузып, төптән уйлап хәл кыйла алмыйбыз. Шуның өчен мин хәзерге съезд, платформа һәм тактика мәсьәләләрен тикшереп һәм төптән уйлап хәл кыйлуны Милли Шурага тапшырырга кирәк диясем килә. Мин съездга шуларны уйлап, шундый резолюция тәкъдим итәм:

«Ил корылтае карыячак мәсьәләләрнең иң мөһиме – аерым милләтләрнең үз теләгәннәренчә үз тормышларын төзү хакы мәсьәләсенә тәэсир итәчәк, мәмләкәтнең ысул идарәсе булганлыгын игътибарга алып, гомуми мөселман съезды ошбу карарны чыгарды:

«1) сайлаулар алдында мөселманнар үзара бер демократический блок ясарга тиеш;

2) ил корылтаена һәм мәхәлли идарәләргә кешеләр сайлаган вакытта башка халык партияләре белән сүз беркетү фәкать трудовиклардан да уңда булмаган партияләр белән генә мөмкин, чөнки фәкать иҗтимагыйун[1] партиясе генә рус булмаган халыкларга

[1] Иҗтимагыйун – социалистлар.

чын мәгънәсе белән үз тормышларын үзләре теләгәнчә төзү хакы бирәләр;

3) платформа һәм тактика мәсьәләсен тәфсилләп тикшерү һәм бер дәстүр[1] төзү Мәркәзи Милли Шурага тапшыру».

2. **Галимҗан Ибраһимов чыгышы:** Без хәзер мәсьәләнең мөһим ноктасына килеп йитдек. 4–5 социалист фиркасе бар. Болар арасында аермалар күб. Ачык карар кирәк. Поезддан төшкәчдән дә кирәк бер нәрсә хакында мөзакәрәне[2] дәвам итдерергә кирәк. Сайлауларда кулга-кул тотынып барырга тугры килер. Шул вакыт сорасалар бездән: Без кайсы партия белән барабыз, дип; без нишләрбез, әйтеп бирә алырбызмы? Социал-революционерлар беләнме? Социал-демократлар беләнме? Кайсы белән? Менә шул партия белән дип кенә әйтеп бирә алмыйбыз бит! Шулай булгач, мөзакарәне туктатырга мөмкин түгел. Мәгълүм бер кагыйдә куеп, билгеле бер карарга килергә кирәк. Безнең барыбыз да социалистлар фиркасендән түгел. Бездә сәнагый аермалыклар да бар. Безне бергә җыйган нәрсә – миллият хисе. Бу хис сәнагый хисләрдән өстдә тора. Вакытлы сәнагый хисләрне онытып, миллият белән берләшергә кирәк. Милли өмидләремезгә киң юл – сул партияләр юлы. Милли әмалемезнең[3] вөҗүдкә килүен теләгән мөселман халкы шундый бер партия белән берегеп бер блок ясамый хале юк. Ул Гомәр әфәнденең докладында бар. Трудовиклардан уң булмаганнары белән».

3. Мәҗлеснең рәисе фикер алышуны дәвам иттерү мәсьәләсен тавышка куеп, уңай җавап алынгач, Г. Ибраһимов тагын мөнбәргә күтәрелә.

**Г. Ибраһимов**: «Әфәнделәр! Мин иң әүвәл Милли Шура вазыйфасына керешәм. Аны күрсәтәләр Русия мәмләкәтләре өчен фәрман чыгара торган бер урын дип. Юк, ул фәрманнар чыгара торган урын түгел. Ул – фәрманнарны гамәлгә куя торган бер урын. Шуның өчен без тактиканы Милли Шурага тапшырып калдыра алмыйбыз. Ул безгә хуҗа булмаска тиеш. Менә хәзер безгә бер партия белән кушылып блок ясарга кирәк. Уң булган партияләр белән кушылып блок ясарга мөмкин, диләр. Без болар белән

[1] Дәстүр – инструкция.
[2] Мөзакәрә – фикер алышу.
[3] Әмалемезнең – теләкләребезнең.

кушыла алмыйбыз. Шәһәр вә управаларга кешеләр сайлаганда, мөселманнар, үзләре генә барсалар, җиңеләчәкләр. Менә шул вакытта җиңелеп калмас өчен, бер партия белән кушылып блок ясарга, бу блок программасының кайсысы мөселманнар файдасына якын килә? Блок ясарга мөмкин 5 төрле социаль фиркаләре арасында безгә якын булганы белән. Болар арасында иң зурлары – социал-революционерлар, социал-демократлар. Болардан кайсысы безгә якын?

Карыйк иң элекге үзебезнең карарларымызны. Без, федерациягә карар бирдек. Демократлар федерациягә каршы. Шулай булгач, Думага сайлаганда демократлар белән сайларга мөмкин түгел.

Килик йир мәсьәләсенә. Без, йиргә мәмләкәт хуҗа түгел, дидек. Демократлар исә – йир государство кулында, ул, районнарга мәгълүм рәвештә халыкны тарата, диләр. Хәлбуки, без йиргә милек юк, диләр.

Социал-революционерлар – федерация яклылар. Йир мәсьәләсендә дә безнеңчә. Алар кашында йир – эшләгән кешенеке. Бу безнең әсасый (йир, ысуле идарә) карарларымызга тугры килә.

Народный социалистлар, боларның программы кадетларныкына якын. Алар йир хуҗасына гадел бәһа бирелүне тәкъвия итәләр[1]. Мөхакәмә һәм тел мәсьәләләрендә безгә каршы.

Дин тугрысында, с.р.лар болай: мәмләкәтнең рәсми дини булмаска, һәммә динләр мөсави[2] булырга тиеш, тел тугрысында демократларның революционерлардан аермалары бар: демократлар – халык телләре дә мөхакәмә[3] кашында хаклы булырга тиеш, диләр. Революционерлар – һәрбер милләт теле граждан булсын, диләр. Шулай булгач, иң муаффәкъ теләк – революционерлар теләге. Әлбәттә, суд һәр халыкның үз телендә булырга тиеш.

Блок сүзе үзебезнең мөгаен хокукымызны алу юлында җиңелмәс өчен оешу. Бу максад, революционерлар белән генә булачак. Шулай булгач, катгыян социаль фиркаләрендән берсе белән оешып блок ясарга кирәк. Революционерлар программасы безнең карарларымыз белән муаффәкъ[4]. (*Алкыш!*).

---

[1] Тәкъвия итәләр – куәтлиләр.
[2] Мөсави – тигез хокуклы.
[3] Мөхакәмә – судта тикшерү.
[4] Муаффәкъ – туры килә.

Монда бер сөаль бар: без төрек-татар, диләр. Җәмәгать! Без һәммәбез дә бер. Ләкин безнең арамызда төрле кешеләр бар. Социалистлар да бар. Безгә бер сәяси вә икътисади юл кирәк. Социалистларның минимум программасын мувәкъкать уларак[1] кабул итәек дә алар белән тотынышып китәек. Фабрика-завод мәсьәләләрендә без аларга катышмайбыз. Шулай ук без тактика мәсьәләсен советка тапшырып кала алмыйбыз, ул закон урыны түгел. Безгә трудовиклар белән берләшү мөмкин түгел. Программалары каршы. Безгә блок ясау мөмкин булган бер генә партия бар. Ул да – социал-революционерлар партиясе. Мөселманнар Учредительный собраниягә сайлауларда социал-революционерлар белән блок ясарга тиеш, дип карар бирәм».

[1] Мувәкъкать уларак – вакытлыча.

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР

Гыйльми һәм иҗтимагый эшчәнлеге, иҗаты хакында әсәрләренең күптомлыкларында, газета-журналларда, фәнни конференция җыентыкларында һ.б. матбугат чараларында төрле фикерләр, күп мәгълүмат тәкъдим ителсә дә, әдипнең, бу очракта Галимҗан Ибраһимовның, яшәешен, тормыш-көнкүренешен, биографиясенең нечкә моментларын ачуда, әдәби портретын тагын да тулыландыруда аның туганнары, таныш-белешләре, сабакташлары, фикердәшләре калдырган хатирәләр һәм истәлекләр иң мөһим рольләрнең берсен уйный.

Үзе яшәгән заман кебек каршылыклы, катлаулы һәм фаҗигале язмышка ия Галимҗан Ибраһимов турындагы истәлекләр мәгълүмати яктан бай һәм гаять кызыклы. Әдип турындагы истәлекләрне үз эченә алган беренче җыентык, 1966 елны «Г. Ибраһимов турында истәлекләр» исеме белән дөнья күрә (җыентыкны төзүче һәм текстларны әдәби эшкәртүче А. Шамов). Биредә Г. Ибраһимовның туганнары, якыннары, бергә укыган, төрле урыннарда бергә эшләгән иптәшләренең аның турындагы хатирәләре, биографиясенә караган әһәмиятле фактларны үз эченә алган истәлекләр урын алган.

Соңрак, 2007 нче елны, «Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр» (төзүчесе Рөстәм Акъегет) исемле тагын бер җыентык басылып чыга. Монда истәлек-хатирәләр белән беррәттән, әдипнең тормыш һәм иҗат юлын яктырткан уйланулар, фикер алышулар рәвешендә язылган мәкаләләр дә тәкъдим ителә.

Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә, Г. Ибраһимов фондында (65 ф.) әдип турында истәлекләр, шул чор мәдәни-иҗтимагый тормышын яктырткан язмалар да урын алган. Аларның бер өлеше төп нөсхәдә, кулъязма рәвешендә булса, икенче өлеше күчермә нөсхәдә, машинка басмасы рәвешендә сакланып калган. Биредә, укучылар игътибарына, Г. Ибраһимов фондында саклана торган, алда әйтелгән истәлек җыентыкларына кермәгән хатирәләрнең берничәсе тәкъдим ителә. Алар татар әдәбиятының иң күренекле әдипләренең берсе, зур галим һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимовның портретын тулыландыруда, яңа һәм әһәмиятле штрихлар белән баетуда ярдәм итәр дип өметләнәбез.

*Ф. Корбангалиев*

## Галимҗан Ибраһимов турында...

### *«Галия» мәдрәсәсенең дөньяга килүе, аның беренче елдагы укытучылары һәм беренче елда урнашкан йорты (Зариф мулла мәчете)*

Зыя Камали 1897 нче елларда ук Уфаның «Госмания» мәдрәсәсендә күренекле хәлфәләреннән санала иде. Аны Пәрвәз хәлфә дип йөртәләр иде. 1900 нче елда ул чит илгә китеп, 1904 нче елда кире Уфага кайта да, шул ук «Госмания» мәдрәсәсенең югары сыйныфында укучыларга дәрес бирә башлый.

«Госмания»дә дәресләр – атнага бер-ике мәртәбә ахун-хәзрәткә кереп тыңлаудан гыйбарәт. Соңыннан, кемнән булса да өйрәнеп, дәрес хәзерлисең. Бай балаларына өйрәтүчеләр табыла, ләкин безнең кебек крестьян балаларына өйрәтүче табу авыр иде.

Зыя Камали һәр көн берничә мәртәбә кереп дәрес бирә. Әгәр көндез кирәк тапкан дәресләрен биреп өлгермәсә, кичләрен дә керә иде (Бәйрут, Истанбул гали мәдрәсәләрендә шул метод белән укыталар ди торган иде ул).

Зыяның укытуы шәкертләргә бик ошый иде. Гәрчә аның укыткан дәресләре шул ук дини китаплардан булса да (Коръәннең тәрҗемәсе, хәдис, мантыйк, гакаид һәм башкалар). Аның өстенә атна саен мәҗлес үткәрә иде. Бу мәҗлесләрдә үзе генә сөйләми, шәкертләргә дә биремнәр биреп сөйләтә иде. Зыя Камали атнага берничә көн Уфалы морзаларга һәм байларга да дәрес бирә иде. Шул сәбәптән Янтурин, Алкин, Акчурин кебек татар морзалары-алпавытлары аны бик күтәрделәр.

Хәйрулла ахун Усманов: «Минем урыныма мәдрәсәгә хуҗа була күрмәсен!» дип куркып, Зыяны Госмания мәдрәсәсеннән китәргә мәҗбүр итә.

Шәкертләр, Зыя Камали киткәч, иске тәртип белән укырга бер дә теләмәделәр, бәхет эзләп чыгып киттеләр (мин дә март аенда киттем). Зыя Камали безгә:

– Уфада, я булмаса Бакуда гали мәдрәсә ачылачак. Бакудан Тагеевлардан хәбәр алдым. Вәгъдә итәләр. Ләкин минем Уфада каласым килә. Гали мәдрәсәнең Уфада булуын телим. Сез көзгә Уфага кайтыгыз, – дип, безнең исемнәребезне язып алды.

### *«Галия»нең беренче уку елы (1906–1907 нче уку елы)*

«Галия»нең бу беренче уку елында үз бинасы юк иде әле. Шуның өчен укучыларның күбрәге Нижгород мәхәлләсенең мәчетенә урнаштылар. Бу мәчет Зариф мулла мәчете дип йөртелә иде. Шәкертләрнең беразы башлангыч мәктәп өчен салынган кечкенә генә ике бинада урынлаштылар. Бу биналар Зариф мулла мәчете янында иделәр.

Зариф мулла мәчетенең байтак авылларда очрый торган гади мәчетләрдән аермасы юк дияргә мөмкин, тик ул ике катлы иде. Аскы каты – таштан, өске каты – агачтан ясалган. Һәр ике каты өчәр бүлмәле (башмак бүлмәсе, сөннәт булмәсе һәм зур бүлмә). Аскы катта михраб (мулла кереп намаз укый торган урын). Ул стенадан алгарак чыгарып ясалган. Өске катта да михраб бар. Бу ике михраб арасында, мулланың командасы ишетелер өчен ачыклык бар.

Бу мәчетнең өске каты сыйныф бүлмәсе булып, аскы каты ятак бүлмәсе булды. Ләкин сыйныф бүлмәсендә парталар яки өстәлләр юк иде. Идәнгә калын итеп яшел постау җәелгән булгач, артык кыенлыгы сизелми иде.

Укытучыларыбыз: Зыя Камали, Лотфулла, Гариф Байчурин. Ул да Мисырдамы, Төркиядәме укып кайткан кеше. Ул безгә хисаб, тарих укытты, Зыя Камали исә Коръәнне татар теленә тәрҗемә итеп укытты. Моннан башка гарәп теленең сарыфын, нәхүеннән дәрес бирде, табигатьтән дип тә сөйли иде. Кыскасы, аның безгә беренче елда укыткан дәресләре соңыннан «Гыйбадәте исламия», тагы да ниндидер исламия дигән исемләр астында ике брошюра рәвешендә басылып та чыкты. Анда оҗмах, тәмуг юк, ураза исә гигиена тарафыннан кирәк, чөнки ул ашказанын тазарта, намаз – гимнастика, хаҗ – мөселманнарның җыелышы дигән кебек фикерләр әйтелә. Кыскасы, ислам диненә чалма урынына шляпа кидертергә тырышулар иде.

3 нче укытучы Хәтмулла Фазылов дигән кеше иде. Ул да чит илләрдә әзрәк укып кайткан. Башта үзе Госмания мәдрәсәсендә укыган да, укыткан да. Ул безгә җәгърафиядән дәрес бирә иде.

Беренче уку елында «Галия»нең укытучылары шулар булып, хуҗасы телдә Зариф мулла булып исәпләнә иде. Ул да атнага бер тапкыр кереп, «Мөхтәсар» дигән чын дини китаптан дәрес биреп маташты, ләкин соңыннан, күбебез «Мөхтәсар»ны аңардан

яхшырак белгәч, керсә дә, сафсата сатып кына утыра иде. Дәрес бирүен бөтенләй ташлады.

### *Укучылар турында*

Беренче уку елында барлыгы 40 ка якын укучы булып, 3 сыйныфка бүленделәр:

1 нче тәхзыйрия. Монда унлап шәкерт иде. Белемләре бик төрле иде. Үзләре Зариф мулланың агач мәдрәсәсендә укыдылар. Аларга күбрәк Хәтмулла Фазылов дәрес бирә иде.

2 нче тәхзыйрия[1]. Бу сыйныфта 20ләп укучы булды. Галимҗан Ибраһимов та шушы сыйныфта укыды.

3 нче сыйныф «Беренче галия» дип атала иде. Бу сыйныфта барлыгы дүрт кенә шәкерт укыды: Мәҗит Гафури, Мөхәммәт Нәҗип Хәкимов, Зәки Ишаев һәм Зәки Казанлы (аны зур баш Зәки дип йөртәләр иде).

Соңгы ике сыйныфлар мәчеттә укыдылар. Элек ничек булгандыр – анысын белмим, ләкин без укыган вакытта җомга көннәрдән башка көннәрдә халык мәчеткә килеп безне бик мәшәкатьләмәделәр. Тик иртәнге намазга 2–3 сукыр карт килгәлиләр иде. Җомга көндә исә, өстке катта әзрәк кеше була иде. Бу вакытта шәкертләр, я чыгып китә иделәр, я Зариф хәзрәтнең үтенүе буенча шауламыйча утыра иделәр. Шәкертләрне намазга куу түгел, укыгыз дип әйтүче дә юк иде.

Кичләрне мәчетнең өстке катында дәрес хәзерли идек. Көндезләре өстке катта дәрес хәзерләүдән башка төрле шигырьләр – «Сада»лар, француз «Марсельеза»сын җырлашулар да, биешеп җибәрүләр дә була иде. Кыскасы, Зариф хәзрәтнең яхшылыгы аркасында, мәчет безнең кулда булды дип әйтеп була.

«Галия» мәдрәсәсендә беренче уку елы 1905–06 нчы елда башланды дип санала. Ләкин беренче уку елында шәкертләр бик аз булды, укыган фәннәрнең дәрәҗәсе бик түбән иде, кайбер фәннәр исә бөтенләй укылмады. Хисап ялгыз дүрт гамәл укытылды (кәсерсез, ягъни дробьсез). Физика, химия, алгебра кебек фәннәр, гомумән, булмады.

Шулай булуга карамастан, укучылар бик тырышып укыдылар, чөнки алар бу мәдрәсә киләчәктә чын мәгнәсе белән югары

[1] Тәхзыйрия – әзерлек.

мәктәпләр программасы белән укыта торган «Галия» булачак дип ышаналар иде.

Бу ышану, бер тарафтан, Зыя Камалинең сүзләренә нигезләнгән булса, икенче тарафтан, Уфаның бик матур бер җиренә «Галия»нең бинасы өчен дип ташыла башлаган таш, ком һәм башка төзелеш материалларын үз күзләребез белән күрүгә нигезләнгән иде. Моннан да башка, Уфаның байтак байлары, кайбер алпавытлары «Галия» мәдрәсәсе өчен күп кенә акча биргәннәр дигән хәбәрләр шәкертләр арасында таралган иде. Беркемнән дә уку хакы алмау гына түгел, хаксыз ашханә ачып, укучыларны тигез ашатулар бу хәбәрләрне ныгыталар иде.

1907 нче елны җәй көне «Галия» өчен менә дигән өч катлы бина салынды. Әлбәттә, ташлар, комнар өелгән җиргә түгел. Шәһәр читендәрәк тау башында бер урынга. Карагруһ Сабир мулла Хәсәнов:

– Минем мәхәлләмә салмасыннар! – дип, губернаторга жалоба биреп, төзелеш материалларын әүвәлге урыннан алдырткан. Ул урынга бик зур чиркәү салдылар. Бу чиркәү соңыннан «Сабир хәзрәт чиркәве» дип йөртелде. Хәзер, чиркәүне сүтеп, зур мәктәп салынды.

1906–07 нче уку елында «Галия»гә җан биргән 2 нче тәхзыйрия шәкертләре иде дип әйтергә ярый. Бу – укучыларның ишлегеннән түгел, бәлки белемнәренең дәрәҗәсе бер төсле, үзләре үткер, күпне күргән, җанлы, оештыручылык кабилиятьләре[1] булганнары өчен. Иң олы, беренче галия сыйныфында, югарыда әйтелгәнчә, бары 4 кеше генә укыды. Боларның өчесе квартирада тордылар. Алар дәрестә генә очрашалар иде. 1 нче тәхзыйриядә укучылар бөтенләй аерым яшәделәр, җыелышларга катнашмадылар. Аларның нәрсә укыганнары да беленмәде, белем дәрәҗәләре дә бик түбән һәм төрлечә иде. Шуның өчен мин 2 нче тәхзыйрия турында язам. Шул ук сыйныфта Галимҗан Ибраһимов та укыды. Төп сүз аның турында бара бит.

Галимҗан Ибраһимов «Галия»гә килеп кергәч тә, башка шәкертләргә караганда өстен икәнлеген, ничектер, тиз танытты. Ул һәркем белән иптәшләрчә сөйләшә. Дәресләрне башкалар белән бергә хәзерләшә. Ул барыбыздан күбрәк белә, тиз төшенә. Гарәп теленең сарыфын, нәхүен, мантыйгын бик яхшы белә. Мин ун ел

---

[1] Кабилиятьләре – сәләтләре.

буе шул гарәп телен укыган булсам да, ул моны миннән яхшы белә иде. Программада куелган күп нәрсәләрнең кирәкмәгәнлеген бик яхшы белсә дә, бу турыда сөйләсә дә, дәрескә чынлап хәзерләнеп керә.

Галимҗан килгәч тә фатирга күчте. Шулай булса да, көн буе мәчеткә килеп бергә дәрес хәзерләшә, кызык сүзләр сөйләшеп утыра. Ул җыр тыңларга бик ярата иде. Җырлаган вакытларда кулы белән дирижировать итә иде. Безнең арада Мөхәммәтдин исемле Кырмыскалы районыннан килгән шәкерт бик оста башкорт көйләрен җырлый иде. Без аны еш кына җырлата идек. Мин дә казанча җырлый идем.

Галимҗан торган квартираның кайсы урамда булганын әйтә алмыйм. Мин аның квартирында ике генә кат булдым. Ләкин квартирасы бик шәпләрдән түгел иде. Һавасы начар, бик авыр исле кебек истә калган. Тизрәк чыгып китәсе килә иде. Квартирасы «Галия»гә якынрак урында иде.

Галимҗан башка шәкертләргә караганда яхшы, иркен торды. Киеме дә әйбәт кенә: өстендә пальто, башында каракүл бүрек. Бәлки аңарга атасы ярдәм иткәндер. Гыйрфан карт берничә кат Уфага килде. Аннан соң аның Оренбургта Хөсәеновларда ару гына хезмәттә эшли торган агасы бар иде. Бәлки ул да ярдәмләшкән булгандыр. Һәрхәлдә, агасы мәдрәсәгә дә бер килеп китте. Аның да өсте-башы без – шәкертләрнең карашында байларча иде.

### *Галимҗанның башлап җибәрүе белән яшерен газета чыгару*

Җилем матбагасын кем, кайдан ничек алганын мин белмим. Галимҗан белән Фәйзерахман Урманов аны кайдан да булса тапканнардыр дип уйлыйм. Җилем матбагасы дигәне 5 сантиметр калынлыкта, «Правда» газетасыннан дүрттән бер өлешеннән аз гына зуррак калай тартма иде. Шуңарда эретеп җилем тутырып суытылган. Яхшы химик кара белән язылган бер битне салып алсаң, башка ак кәгазьләрне салып, сыпырып ала бирәсен. Басылган кәгазьләр бөтерелеп чыгалар. Алар белән дөнья тула. Шуларны тигезләп салып бастыра барыр өчен 4–5 кеше кирәк була иде. Вәсим Солтановның кульязуы бик матур булганлыктан, язу аңа тапшырыла иде. Мин исә бастыруда катнаштым һәм берничә мәкалә яздым. Берсе бик хәтеремдә калган. Бу мәкаләдә мин «Госмания»

мәдрәсәсендә 500 дән артык шәкерт изелеп ятуы турында язган идем. Зур ялгашка (каретага) күп шәкерт башларын йөкләп, Хәйрулла ахун Усманов аларны калак белән изүен күрсәткән карикатура да ясаган идем. Газетаның беренче номеры Фәйзерахман Урмановның квартирасында чыкты. Урманов үзе урта буйлы, бик матур, сүзгә оста, бик яхшы киемле егет иде. Квартирда ул үзенең бер иптәше белән бергә тора иде.

Вәсим Солтанов буйга бәләкәй, бите ап-ак иде. Атасы аның укуына риза түгел иде. Вәсим исә укуга бик тырыш күңелле. Зыя Камалиның дәрес вакытында сөйләгәннәрен бик яхшы итеп язып бара иде. Зыя үзенең безгә укыган лекцияләрын бастырганда, Вәсимнең шул язуларыннан файдаланган диделәр.

Хөснетдин Кәримов, тагы ике шәкерт белән бергә, Дүртиле Максутовлар мәдрәсәсеннән килделәр. Алар бик кызык кына шәкертләр иде. Җырга осталар. Аның бер иптәше – Мирзаянмы, Мирзабаймы – нәзек, озын, сап-сары бер кеше иде. Аның бер чалбары өчкә бүленгән: ике балагын бәйләп куя. Элек кайсы балагын бәйләргә дип язып куя.

Баш мәкаләләрне, башка күп кенә мәкаләләрне дә Галимҗан үзе яза иде. Газетаның исемен оныткანмын. Әллә «Ирек» иде инде, белеп әйтә алмыйм. Газетада күбрәк иске мәдрәсәләрне яманлап, шәкертләрне бу мәдрәсәләрне ташлап чыгарга һәм «Галия»гә килеп укырга өнди торган мәкаләләр языла иде. Алдагы 1907–08 нче уку елында «Галия»нең берничә катлы үз бинасы салынып бетәчәге турында, андагы сыйныфларда парталарга утырып укылачагы, шәкертләр өчен аерым ятак бүлмәләре булып, һәркемгә аерым кроватьлар, простыня-одеяллар булачагы турында әйтелә иде. Укулар турында – «Галия»дә иң кирәкле фәннәр укытылачак. Аның өчен яхшы, зур белемле укытучылар киләчәк, уяныгыз, шәкертләр, гафил булмагыз, иске схоластик мәдрәсәләрне ташлап, «Галия»гә килегез» дигән сүзләр языла иде. Кыскасы, газетаның төп теләге шәкертләрне иске мәдрәсәләрдә черүдән коткару иде.

Яшерен газетаны басып чыгарудан да авыр эш – аны тарату иде. Газетаны чыгаручы 4–5 кешелек актив белән генә бу эшне булдырып булмый. Шуның өчен 2 нче тәхзыйриянең бөтен шәкертләрен иплəп кенә аңлатып, бу эшкә катнаштырырга туры килде. Шул ук шәкертләрнең конвертлары, маркалары белән газетаны Оренбург, Казан, Уфа, Троицк, Әстерхан һәм башка шәһәрләрдәге

мәдрәсәләргә, Кыешкы, Буби шикелле авыл мәдрәсәләренә, танышларга җибәрә башладык.

Бәлки шул яшерен газетаның файдасы тигәндер, 1907–08 нче уку елында «Галия» мәдрәсәсенә 300 дән артык укучылар җыелды.

Таныш мәдрәсәләргә җилем басма газетаны җибәрү белән генә калмый, якын мәдрәсәләргә барып, шәкертләрне иске мәдрәсәләрне ташлап чыгуга өндәүләр дә була иде. Минем истә бик ачык калганы шул: Галимҗан үзе белән тагы бер шәкертне алып (бу шәкертнең кем икәне истә калмаган), Кыйка авылына барып, Мирсаев хәзрәт мәдрәсәсендә мәҗлес уздырып кайтты. Кайткач безгә отчет ясады, киләсе елга шәкертләрнең «Галия»гә киләчәкләрен сөйләде. Анда матур җырчылар барлыгын әйтте.

Галимҗан Ибраһимов шунда ук Мәҗит Гафури белән бик дуслар иде. Хәер, Мәҗит аганы яратмаган кеше булмагандыр. Бигрәк тә аның шагыйрь булуы аны безгә бик гаҗәп якын күрсәтә иде. Шул ук елда аның «Яшь гомерем» дигән беренче китабы басылып чыккан иде. Мәҗит ага үзе дә бик садә[1], бик ачык, сүзчән кеше иде. Аның шәрикләре[2] бик сирәк күренсә дә, Мәҗит ага һәр көн дәрескә килгәч:

– Нихәл, егетләр! – дип, турыдан-туры мәчетнең өстке катына, безнең яныбызга керә иде.

Ул елдагы шәкертләр арасында иң матур мәдәниятле киемлесе Мәҗит ага иде: өстенә бик яхшы каракүл якалы пальто, башында яхшы бүрек, кулында башка бер кешедә дә булмаган матур портфель.

Гомумән алганда, күпчелек шәкертләр бик ярлы – ачлы-туклы тордылар. Аталары иске мәдрәсәне ташлап киткәннәренә риза булмыйча ярдәм итмиләр, чөнки хезрәтләрнең бәддогасыннан куркалар. Зариф хәзрәтнең иске агач мәдрәсәсендә бик гади генә көненә бер мәртәбә буш ашата торган ашханә булгач, бик куанып шунда ашап чыга идек. (Бу ашханәне мөфти Солтанов ачты дип сөйләделәр, ләкин, дөресме-түгелме – анысын белмим). Бу ашханәдә Галимҗан, Мәҗит ага һәм Урманов ашамадылар бугай. Һәрхәлдә, аларның монда ашаганлыкларын һич күз алдыма китерә алмыйм.

---

[1] Садә – гади.

[2] Шәрикләре – иптәшләре.

Безнең дәрескә керү, әзрәк дәрес хәзерләүдән башка, бер төрле дә эшебез юк. Эчебез пошса да, бер кайда барыр урын юк. Ул вакытларда Уфада татар театрлары да, кино да бөтенләй юк. Аптырагач, я төрле көлке сүзләр сөйләп утырабыз, я шигырьләр әйтәбез, я төрле җырлар җырлашабыз. Көненә берничә кат «Марсельеза» җырлыйбыз. Ул безгә, бердән, яңа нәрсә, икенчедән, көе бик матур. Аны Галимҗан бигрәк ярата иде. Җырлый башласак, ул каршыга басып, кулын күтәреп дирижировать итә [...].

Без «Марсельеза»ны мәчетнең өстке катында тәрәзәне ача биреп, хор белән кычкырып җырлыйбыз. Бервакыт шунысы гаҗәп булды: мәчеттән бер йорт аша гына өйдә бик зур корсаклы пристав тора иде. Без «Марсельеза»ны җырлаганда ул мәчет алдыннан арлы-бирле үтеп киткәләде. Әллә инде ул нәрсә җырлаганыбызны белмәде, гыйбадәт кылалар дип уйладымы, әллә бик яхшы кеше булып:

– Пускай себе орут! – дип уйладымы, һәрхәлдә, безгә һичбер нәрсә әйтмәде.

Күп вакыт Галимҗан шәһәрдән яңа хәбәрләр алып килүчән иде. Бер вакыт ул:

– Иртәгә II Думага сайланган татар-башкорт депутатлары Думага озатыла. Әйдәгез, без дә аларны озатырга төшик, аларга үз теләкләребезне белдерик, – диде.

Без барыбыз да Галимҗанның бу сүзләрен бик дәртләнеп каршы алдык, теләкләребезне язарга утырдык. Безнең фикеребезчә, башта Рафиков дигән шәкерт сөйләргә тиеш, чөнки ул Дума вәкилләрен таный. Вакытында I Дума әгъзасы алпавыт С. Янтуринның шәхси секретаре булган, Дума куылгач, Выборг обращениесен язар өчен вәкилләр белән йөреп кайткан кеше ул.

I теләгебез: Мәскәү, Петербург халкының партияләренә каршы булган партияләргә димләп килсәләр, аларга ышанмаска.

II. Үзләрен Думага сайлаган халыкларның ышанычларын акларга тиешлекләре.

III. Шул ук мәгънәдә Мәҗит Гафури ярдәме белән бер шигырь язып, аны «Сада» көенә җырларга.

IV. Барганда да, кайтканда да кечкенә группаларга бүленеп барырга һәм кайтырга.

Без Уфа вокзалына барганда анда Стәрлебашның зур бае Шакир Тукаев белән Златоуст өязеннән сайланган старшина – әллә Тукумбаев, әллә Туктабаев утырып торалар иде. Күп тә үтмәде,

Уфадан сайланган Сабир мулла Хәсәнов кереп килде. Аның шәкертләре артыннан зур-зур төеннәр күтәреп керделәр.

Без каршыларына барып басып, сәлам бирдек. Аларның безгә бер дә исе китмичә, үзара:

– Абыстай исән калдымы, фәләнме? – дип сөйләшеп кенә утыралар.

Сәлимгәрәй Рафыйков:

– Сез сак булыгыз! Сезне халыкка каршы байлар файдасына закон чыгарырга өндәрләр! – дип сүз башлаган иде, жандармлар килеп, безне вокзалның беренче класс залыннан куа башладылар.

Безнең арада бик кызу канлы әстерханлы Гәбдерәхим исемле шәкертебез үзенең бик көчле тавышы белән:

– Сезне халык министрлар өстеннән закон чыгарырга дип Думага сайлады, ә сез арт ягы пычрак жандармнарга бер сүз әйтергә куркасыз! – дип кычкырды. Шуннан соң жандармнар безне тагы да артыграк көчләп төрткәләп куа башладылар.

Шул арада сап-сары бобрик тышлы күк якалы пальто кигән, күк каракүл бүрекле бер кеше утыргычка сикереп менде дә:

– Мин дә Дума депутаты! Минем фамилиям – Кугушев. Сез аларны куып чыгарырга хакыгыз юк. Алар татар-башкортлар – 300 елга беренче мәртәбә үзләренең вәкилләрен озатырга килгәннәр! – дип безнең тарафтан төште.

Без теге сатлык җаннарны ташлап, князь Кугушев янына килдек, ура кычкырып, аны кул өстендә югары күтәрдек, һәм «Сада» көен җырлый-җырлый килгән поездга каршы чыктык. Сабир мулла мәхәлләсеннән күп кенә толчокчылар килгән иде. Алар тәкбир әйттеләр. Башта планлаштырган булмаса да, безнең арадан кемдер «Марсельеза» җырлый башлады. Без барыбыз аңа кушылып соңына кадәр җырладык. Безгә кушылып тимер юл эшчеләре дә русча җырладылар. Без җырлап бетерүгә, бер кеше килеп:

– Шәкертләр, тизрәк таралыгыз, жандармнар начальниге телефон белән казаклар чакырды! – диде.

Без вокзалдан чыгып киттек. Бераз баргач, безгә каршы атлы казаклар төшеп килгәнен күрү белән, вокзал ягына карап атлаган булдык. Алар үткәч, үзебезнең юл белән киттек. Икенче көн «Уфимский вестник» газетасында бәләкәй генә бер заметка чыкты. Анда шулай язылган иде: «Вчера, во время проводов депутатов, избранных в Думу, какая-то толпа пытались нарушить порядок».

Кугушев – Цурюпа[1] иптәшнең хезмәт иткән алпавыты. Хәзерге Цурюпа исемендәге совхозның җирләренең элекке хуҗасы.

Укулар үз агышы белән барды. Укыган фәннәр 2 нче тәхзыйрия белән 1 нче гали сыйныфларда бер төслерәк иде. Үзара сөйләшкәндә без:

– Ни эшләп Галимҗан 1 нче гали сыйныфка кермәгән икән? Аның белеме, зирәклеге 1 нче гали сыйныфтагыларныкыннан да бәлки өстендер бит, – әйтә идек.

Бәлки ул 1 нче гали сыйныфта шәкертләр бик аз, шуның өчен күңелсез булыр дип уйлагандыр? Ул бит шау-шулы халык арасында катнашырга, көйләр-җырлар тыңларга ярата!

### *Беренче имтихан*

«Галия»дә беренче имтихан язда – март аенда булды. Имтиханга «Галия»нең дустлары да, дошманнары да бик күп булып килгәннәр иде. Шулар арасында Саратовта яши торган Минһаҗ Һинди дигән кеше дә килгән. Бу кеше Зыя Камалиның иң усал көндәше. Зыя Камали Уфада «Галия» мәдрәсәсен салам дип хәбәр таратып халыктан ярдәм сораса, Минһаҗ Һинди Саратовда «Галия» мәдрәсәсен салам дип акча җыя башлаган иде. Ләкин җыйган акчасын үз кесәсенә тутырып, Минһаҗ «Галия»не онытты, өйләнеп туй ясады. Бу турыда Тукай болай дип язган иде:

Таш ташыйлар: анда Минһаҗ «Галия» нигезен сала.
Туй ясыйлар: монда Минһаҗ гаилә нигезен сала.
Салыныр да, төпләнер дә, бик уңайдыр соңгысы;
Шикләнәм мин, әллә ник, булмас кебек әүвәлгесе.

Дөрестән дә, «гаилә нигезен» салганнан соң, «Галия»гә акча калмады.

Имтихан вакытында без шәкертләргә җирәбә-билетлар өләшенде. Шул билетлардагы сорауларга без җавап бирергә тиеш идек. Шәкертләрнең биргән җаваплары бик яхшы булгач, Минһаҗ:

– Бу билетлар шәкертләргә алдан бирелгән булса кирәк, шуның өчен алар җавапларын алдан хәзерләп килгәннәр булса

---

[1] *Цюрупа Александр Дмитриевич (1870–1928) – большевик, совет дәүләте һәм партия эшлеклесе. 1905–1917 елларда Уфа губернасында алпавыт В.А. Кугушев утарының җитәкчесе.*

кирәк! – дип, безне халык алдында оятлы итмәкче, белемнәребезне ялганга чыгармакчы булып маташты.

Зыя Камали бик кызып китте. Гарьләнде.

– Алай булгач мин һәрбер шәкерттән бөтен кыш буе укыганнарын сорыйм, – дип. Мөдәррис дигән шәкертне 2–3 сәгать буена сораулар биреп торды. Мөдәррис йөзгә кызыллык китермәде. Һәрбер сорауга тулысынча җавабыны биреп торды. Ләкин көн буе 2–3 кешене генә имтихан кылганда безнең сыйныф өчен генә 6–7 көн кирәк булачак.

Без тиз генә үзара сөйләштек тә, тәнәфес вактында Минһаҗны уратып алдык, чак якасыннан тотмадык.

– Без 2–3 көннән таралырга тиеш. Болай барса, имтихан ай буена да сузылачак. Монда артык торырлык безнең акчабыз юк. Әгәр имтиханны шулай суздырам дисәң, безнең белемебезгә ышанмасаң, «Галия» салам дип халыктан җыйган акчаңны бир! – дидек.

Ул калтырап-тетерәп калды.

– Бәбкәйләрем! Мин мәгънә белән әйтмәдем. Бик яхшы укыгансыз икән… – ди башлады. Соң, эшләр нормаль китте.

Халык безнең укуны бик яратты. Тик кайдадыр хезмәт итә торган Харис исемле кеше миннән:

– Бу мәдрәсә гали мәдрәсә ич. Нигә хисап, җәгърафия дигән фәннәр шул дәрәҗә түбән монда? – дип сорады.

– Чыннан да шулай шул, – дидем мин. Элекке без укыган мәдрәсәләрдә хисап бөтенләй бит укытылмады. Шулай булгач, «Галия»дә ничек итеп кәсерләр[1] – җәберләрдән[2] башлап китәсен.

Шулай итеп, алдагы елга чын мәгънәсендә «Галия» мәктәбенә килергә вәгъдәләшеп, таралдык.

Яхшы укытучылары булмаган хәлдә, кулында акчасы юк көйгә, байлар кесәсендәге акчага карап «Галияне» төзүе – Зыя Камалинең заманы өчен зур хезмәте, әлбәттә.

### *«Галия»нең икенче елы*

1907 нче ел октябрь башларында «Галия»нең яңа бинасына керү белән искиткеч күренеш каршы ала. Таштан салынган өч катлы бинаның өске катында сыйныф бүлмәләре. Анда ялт итеп торган яңа парталар. Идәннәргә постау җәйелгән. Татар шәкерт-

---

[1] Кәсерләр – бүленешләр.

[2] Җәберләрдән – кушулардан.

ләренең төшенә дә кермәгән күренеш! Дәрескә керүгә-чыгуга кыңгырау. Урта катта ятак бүлмәләре. Койкаларда матрац, мендәр, простыня һәм одеяллар хәзерләр. Иске мәдрәсәләрдә башка-баш, аякка-аяк куеп идәндә түшәлеп ятуга караганда, койкаларның ике катлы булуы беленмәде дә. Ятак бүлмәләрендә дә идәнгә постау җәелгән. Аскы катта ашханә, кухня һәм башка хуҗалык бүлмәләре. Кухняда эшләүчеләргә квартиралар…

Бөтен укучылар ашханәдә ашадылар, чөнки аш бик яхшы хәзерләнә, укучыларның хәле-акчасы җитәрлек арзан сатыла иде.

Укытучылар үткән елга караганда күбрәк. Закир Кадыйри, Габдулла Шөнаси, Гобәйдулла (фамилиясе истән чыккан) исемле укытучылар килгән. Гобәйдулла дигәне һәндәсәдән[1] тагы нәрсәдәндер дәрес бирде. Шәкертләр бик сорагач, кышның соңында рус теле укытучысы китерелде. Гомумән алганда, шәкертләрнең уку турындагы бөтен теләкләрен үтәп бетерерлек түгел иде. Алгебра, химия, рус теле кебек фәннәр бик аз, бик түбән укытыла иде.

Икенче уку елында 300дән артык шәкерт килеп, болар 4 сыйныфка бүленде: 1 нче тәхзыйрия, 2 нче тәхзыйрия 1 нче галия, 2 нче галия.

2 нче гали сыйныфына байтак яңа кешеләр өстәлде. Болар арасында Хәлим Искәндәрев, Бикбулат Сәлиев кебек иптәшләр бар иде. 1 нче гали сыйныфына да күп кеше өстәлде. Шакир исемле шәкертләр үзләре генә дүрт булганын күрсәтсәк тә җитәр.

2 нче тәхзыйриядә дә шәкертләр артты. Болар арасында соңыннан халыкка танылган Шәһит Әхмәдиев, Галә Ходаяров, Фәрхи Әхтәмов кебек укучылар бар иде. 1 нче һәм 2 нче тәхзыйрия сыйныфларында барысы да яңа кешеләр иде дип әйтсәң дә була.

Мәдрәсә белән идарә эше бөтенләй шәкертләр кулында дип әйтергә мөмкин. Эчке мәсьәләләр буенча атна саен мәҗлесләр үткәрелә. Назир куелган шәкертләр арасында Хәлим Искәндәрев тә бар иде. Шәһит Әхмәдиев эконом булып эшләде.

Бу уку елындагы шәкертләрнең күпчелеге яхшы киемле. Матур итеп чәч үстереп җибәргәннәр. Урамга чыкканда башларына бәләкәй генә бүрек өстеннән башлык бәйлиләр. Җылы көннәрдә башлыкның бауларын кулбашларына салып җибәрәләр. Сары

---

[1] Һәндәсәдән – геометриядән.

постаудан тегелгән һәм ике якка салынган озын баулы бу башлыклар япон сугышыннан кайткан солдатлардан таралган иде.

Атнакичләрдә мәҗлесләр үткәрелә иде. Бу мәҗлесләрдә мәдрәсәгә бәйләнеше булган рәсми мәсьәләләр карала. Рәсми мәсьәләләр булмаса, төрле темада фикер алмашулар була. Мәсәлән: Татар милләтен ничек алга җибәрергә? Ни өчен татарлар артта калганнар? Хатын-кызларга хокук кирәкме? Фән-уку ни өчен кирәк, җырлау кирәкме? Музыка ни өчен кирәк?

Бу мәсьәләләр буенча кайбер кешеләргә алдан хәзерләнергә кушалар. Кайбер мөһим тема буенча Галимҗан да доклад ясый. Ләкин ул, күбесенчә, азаккы сүзне әйтә. Галимҗан ул чакта ук бик матур, ихлас һәм җанлы сөйли иде. Без күбебез «Ул язучы булыр әле» – дип үзара сөйләшә идек һәм шулай булды да бит. Озак та үтмәде Галимҗанның Казанда «Әлислах» дигән газетада «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән әсәре басылып чыга башлады. Без ул газетаны бик көтеп ала идек. Безнең өчен, үзебез белән укыган шәкерт тарафыннан «китап» язылуы гаҗәп тә, горурлык та булды. Галимҗан Ибраһимовның авторитеты шәкертләр арасында тагы да күтәрелде. Бикбулат Сәлиев, Хәлим Искәндәрев, Галә Ходаяров, Фәрхи Әхмәтов, Шәһит Әхмәдиев кебек шәкертләр Галимҗанның аерылмаслык дуслары булдылар.

Атна саен үткәрелә торган җыелышларның рәсми бүлеге беткәч, укытучылар кайтып китәләр. Алар китү белән икенче бүлек – иң күңелле бүлек башлана. Бу бүлектә шигырьләр сөйләнә, матур җырлаучылар җырлыйлар, оста биючеләр – бииләр. Безнең поварларның берсе оста скрипкачы, берсе – гармунчы иде. Алар үз коралларында уйнап, шәкертләргә дәрт бирәләр иде. Галимҗан кичәнең бу бүлеменә дә бик яратып катнаша иде. Шәкертләрне җырларга, биергә димләп йөри иде. Нәтиҗәдә, Хәмит кебек (фамилиясе исемдә калмаган, үзе Әлшәй районындагы Никифор авылыннан иде) бик матур җырчылар, Абдулла Сайманов кебек кызыклы такмаклар әйтеп биючеләр күбәйделәр.

Бара-тора шундый әдәбият кичәләрен мәдрәсәдән тыш шәһәрдә дә булдыру мәсьәләсе туды.

1908 нче елның март айларында «Галия» шәкертләренең кузгатып җибәрүләре буенча татар телендә «Әдәбият кичәсе» ясау турында мәҗлес үткәрү өчен губернатордан рөхсәт алынды.

Бу җыелыштан максат: Уфа җәмәгатьчелеге белән сөйләшеп, киңәшеп «Әдәбият кичәсе» үткәрү турында рәсми карар чыгару

иде. Бу зур эштә кемнең хезмәте булгандыр, анысын атап әйтә алмыйм, шулай да булса, мин үзем монда Галимҗан Ибраһимов катнашмый булмагандыр дип уйлыйм.

Уфаның Успенская (хәзерге Коммунистическая) дигән урамындагы приказчиклар клубында җыелыш булды. Без барып керүгә халык туп-тулы иде. Иң почетный урында губернаторның «чиновник по особым поручениям» дигән кешесе – Әхмәтсолтан Гали улы Терегулов утырган. Кулбашларында куш йодрык зурлыгы ялтырап торган эполетлар. Янда берничә околоточный надзирательләр. Калган халыклар: Уфаның кайбер мулла-мөэзиннәр, Духовное собраниедә эшләүчеләр, яшерәк байлар, морзалар, байларның приказчиклары һәм толчукчылар.

Башта Галимҗан Ибраһимов чыгып сөйләде. Мәдәниятле милләтләр күптән инде әдәбият кичәләре, концертлар, театрлар куеп күңел ачалар, мәдәниятләрен арттыралар. Безнең татар халкы үз мәдәниятен күтәрергә теләсә, башка мәдәни халыклар белән бер сафта торасы килсә, безгә дә, башка халыклар кебек шундый мәдәни әмәлләрне башлап җибәрергә, юк дигәндә, әдәбият кичәләре куярга күптән вакыт. Әдәбият кичәсе дигәне – ул нәрсә? – дисәгез, бу кичәдә нәсер сүзләр – хикәяләр укыла. Шигырьләр әйтелә. Шулай итеп җыелган халык мәдәни генә күңел ача, ял итә…

Шул араны:

– Кирәкми! Юк! Рөхсәт итәргә ярамый! Бара-бара җырлар, музыкалар башланыр! – дигән тавышлар ишетелә башлады.

Шәкертләрнең берсе:

– Җырны мөселман дине кире какмый. Коръәндә «Шөгарә» (җырлар[1]) дигән сүрә бар. Кәгъбәтуллада Имрул Кайс шигырьләре алтын белән язылып куелган. Әле дә тора. Ниндидер бер домбра уйнаучыны күреп, Гомәр сәхабә туктата башлагач, Мөхәммәт, аңар тимә, – дигән. Музыканы хайваннар да ярата. Африкалылар филләрне музыка белән алдап тоталар, – дигән кебек күп дәлилләр китерелсә дә, бик күпчелек якын да килмәделәр.

– Башлап шигырь, аннан музыка, аннан театр куерлар, аннан хатын-кызларны чакырып, безнең белән уйнагыз дип әйтә башларлар… Харап эш! – дип акыра башладылар.

Безнең кызу канны Габдерәхим Әстерхани югарыга басып:

---

[1] Дөресе «шагыйрьләр» булырга тиеш.

– Иптәшләр! Хәйрулла ахунның өендә музыкальный ящик бар. Хәсән Гата Габәшинең өендә гармонь-скрипка һәрвакыт гүрләп тора. Бөтен байларның өендә граммофоннар, пианинолар бар. Күңелләрен зуррак ачарга уйласалар, аларда акча күп – ресторан һәм башка урыннар аларга хәзер тора. Нәрсә без капиталистларга карап торабыз! – дигән иде.

Әхмәтсолтан Терегулов кып-кызыл булып кызарып аягына басты:

– Губернатор хәзрәтләре капиталист, буржуазия дигән кебек политический сүзләргә рөхсәт бирмәде. Мондый сүзләр сөйләнсә, мин собранияне ябам! – дип кычкырды.

Бу сүзләрне ишеткәч, толчукчыларга, байларның тәлинкәләрен ялаучыларга җан керде. Алар:

– Галия шәкертләре алар бары да стужистлар-гыйсьянчылар! – дип кычкырырга тотындылар (Стужист дигәннәре – студент димәк – алар бу сүзне гыйсьянчы мәгънәсендә кулландылар). Ахырда, безнең өстебезгә ташланып, безне этеп-төртеп, хәтта суга башладылар. Без чак качып котылдык.

Урамга чыккач:

– Ярый әле, студент исемен алдык. Бу – безнең өчен зур дәрәҗә! – дип көлешә-көлешә кайтып киттек.

«Галия»нең бинасында үзебез теләгән вакытта әдәбият кичәсе генә түгел, кайвакыт спектакль дә куйгаладык. Ниндидер бер пьесада үзем дә тегермәнче булып уйнаган идем. Хәтеремдә: пьесаның барышы буенча сәхнәдә аш ашарга кирәк иде. Ашханәдән китертеп бик тәмле аш ашаган идек.

1907–08 нче уку елын бетергәч, мин яңадан «Галия»гә бара алмадым. Казанда солдатка каралдым. Рус телен өйрәнеп кайтырмын дип бик барасым килгән иде, ләкин ике генә кеше калгач, миңа җирәбә җитмәде, соңыннан эти җибәрмәде, акча бирмәде. Мин авылда калып, балалар укыттым.

Галимҗанны мин тагы «Галия»нең 10 еллык юбилеен үткәргән вакытта гына күрдем. Бу вакытта ул «Галия»дә укыта иде инде һәм әсас докладны[1] ул ясады.

«Галия»нең беренче елында да, икенче елында да Хөсәен Ямашевның шәкертләр арасына килеп йөргәнен мин белмим, күрмә-

---

[1] Әсас докладны – төп докладны.

дем. Бәлки ул квартирада торган шәкертләр янына килгәндер. Галимҗан белән дә күрешкәндер – анысын әйтә алмыйм. Тик шуны гына әйтә алам: Хөсәен Ямашев социал-демократ-большевиклар партиясенә Галимҗаннан күп вакыт элек кергән. Галимҗан исә 1917 нче елларда социал-революционерлар платформасын яклап, хәтта Учредительное собраниягә социал-революционер списогы белән сайланды (3 нче список), большевиклар исә, Уфада 10 нчы список белән сайландылар.

Шәһит Әхмәдиевнең истәлегендә (Г. Ибраһимов турында истәлекләр, 237 нче бит) Галимҗан 1907 нче елда «Галия»дән чыгарылды дип язылган. Бу – хата. 1907–08 нче уку елында Галимҗан да, Шәһит Әхмәдиев үзе дә «Галия»дә укыдылар. Мин бу турыда Шамовка да язган идем. Әллә Шәһит үзе яңлышканмы, әллә күчергәндә яңлыш күчергәннәрме? Хәбиб Зәйни «Галия»гә 1907–08 нче уку елында килде. Ул да бит шул ук елда «Галия»дә җыелышлар булганын һәм Галимҗан бу җыелышларга актив катнашканын ачык яза. «Галия»нең беренче елында да, икенче елында да берәр кешене куып чыгару, яки нинди дә булса буталыш кебек нәрсәләр булмады. Зыя Камали:

– Сез шәкертләр үзегез хуҗа. Без – укытучылар сезләрнең хезмәтчеләрегез – ди торган иде. 1908–09 нчы уку елыннан башлап кына ул байлар сүзенә карый башлаган иде.

1917 нче ел февраль революциясеннән соң, авылларда митинглар үткәрелеп, Советлар сайланганнан соң, апрель башларында Уфада крестьяннар җыелышы чакырылды. Кайбер кешеләр бу җыелышны съезд дип атадылар. Сафар волостеннән мин дә делегат булып бардым.

Бу җыелышка делегатлар шулчаклы күп килгән иде, Уфа гимназиясенең, реальное училищесының залына халыкның яртысы да сыймады. Ахырда, салынып бетмәгән клуб бинасында үткәрергә булдылар. Монда да делегатларның яртысы эчтә, калганнары тышта, тәрәзә төпләрендә торып тыңладылар. Тәрәзәләрнең рамнары куелмаган иде әле. Бу җыелышта татар-башкорт делегатлары белән юлбашчылык итү эшен Галимҗан Ибраһимов алып барды. Аның янында сул канатны яклаучылардан Фатих Сәйфи Казанлы, Абруй Сәйфи, Баһау Нуриманов, Шәриф Сүнчәләй, Әүкәев Абделхәй, Хөсәинов Әкрәм, Фарси Юсупов һәм башкалар булганын хәтерлим. Ни өчендер күпчелек татар-башкорт иде.

Көн тәртибе шулай иде:

1. Платформа партии социал-революционеров. Докладчик – Бернштейн, содокладчик – Бриллиантов.

2. Платформа партии социал-демократов большевиков. Докладчик – тов. Цурюпа.

3. Ответы на вопросы.

Беренче доклад буенча сөйләгән кешеләр җир крестьяннарга биреләчәк дип әйтсәләр дә, ничек биреләчәк? Бушмы? Акчагамы? Акчага булса, нинди хак белән? Помещикларга җир калдырыламы? – дигән кебек сорауларга җавап бирә алмадылар. Ахырда:

– Учредительное собраниедә билгеле булыр, дип котылдылар.

Галимҗан Ибраһимов, Фатих Сәйфи, Әкрәм Хөсәенов һәм башкалар бу партиянең җир турындагы платформасына турыдан-туры ризасызлык күрсәтеп, бу – җир мәсьәләсен помещиклар файдасына чишү була дип аңлаттылар.

Кайбер эсэрлар һәм меньшевиклар помещикларның җирләрен хаксыз алырга ярамый дип сөйләделәр.

Социал-демократ большевиклар партиясе исеменнән сөйләгән иптәш Цурюпа ачыктан-ачык эшчеләргә 8 сәгать эш көне булырга тиеш, завод-фабрикалар эшчеләрнең контроле астында эшләргә тиешләр, бөтен җир – аны эшләүче крестьяннарга түләүсез бирелергә тиеш! Помещик, чиркәү җирләрен бүгеннән үк тартып алырга кирәк! – дип сөйләде.

Һәр ике доклад татар теленә тәрҗемә ителеп барылды. Тәрҗемәче Шәриф Сүнчәләй иде.

Бу җыелышта Галимҗан Ибраһимов кат-кат сүзгә чыгып, ачык, әче тел белән кадетларны, меньшевикларны, эсерларны тәнкыйть итте, халык файдасына көчен кызганмыйча көрәште. Шуның өчен дә аны кат-кат алкышладылар. Бу аның уфалылар һәм авыл халкы каршында беренче хезмәте.

3 нче мәсьәлә губерна советына председатель сайлау булды. Күп кандидатлар күрсәтелде. Кайберләре риза булмыйлар, кайберләре бөтенләй үк Уфада юклар. Рус телен һәм татар телен яхшы белгән кеше булсын, – диләр. Ике телне дә бик оста сөйләшәләр, – дип яшь адвокатларны: Ибраһим Әхтәмов белән Ибнеәмин Әхтәмовны күрсәттеләр. Галимҗан Ибраһимов белән Фатих Сәйфи Казанлы:

– Бу кешеләр меньшевиклар, алар эшче-крестьян мәнфәгатьләрен якламаячаклар! – дип каршы тордылар.

Халык бер авыздан Фарси Юсуповны күрсәттеләр. (Ул губернская управа члены князь Мәхмүт Юсуповның племяннигы. Сафар волостенда библиотекарь булып эшли).

Фарси Юсупов трибунага менде дә:

– Сез мине җир бирер дип сайладыгызмы? Шуны белегез, мин сезгә җир бирермен дип вәгъдә итә алмыйм. Җир мәсьәләсендә күп эшләр бар әле… – дип сөйләп башлаган иде, халык бер авыздан аны:

– Долой! Долой! – дип трибунадан куып төшерделәр.

Бу мәсьәлә шулай хәл ителде: моңарчы губернская управаның председателе булып эшләп килгән Крубачинскийны икенче собраниегә чаклы вакытлыча губернский совет председателе итеп калдырырга дип кул күтәрдек.

Мондый җыелышлар Февраль революциясеннән соң гына үткәрелә башлады. Аннан ары мондый җыелышлар бик еш кына була торган иде. Патша вакытында яшерен яшәгән партияләр халык каршына чыгып үзләренең платформалары турында ачыктан-ачык сөйләүләре дә беренче булгандыр. Февраль революциясенә кадәр, эсерлар турында булсын, большевиклар, яки башка партиялар турында булсын, докладлар тыңлау түгел, аерым кешеләр авызыннан да ишеткәнем юк иде. Бу собраниедән соң миндә дә яңа уйлар, яңа фикерләр туды.

1917 нче елда Галимҗан Ибраһимовны халык өчен эшләгән эшләрен санасаң – искитәрлек!

Март аенда ук «Ирек» газетасын чыгара башлап, аның укучыларын канәгатьләндерерлек итеп оештыру эшләрен алып баруы, тиражын зурайту, аңарга акча табу үзәгендә булуы Галимҗанда искиткеч организаторлык куәте барлыгын күрсәтте.

Мәскәү, Казан съездларына актив катнашу өстенә, Уфада да нинди генә җыелыш булса да, анда Галимҗан актив катнаша һәм күп вакытта юлбашчылык итә иде. Билгеле, Фатих Сәйфи аңардан бер вакытта да аерылмый иде.

Шул ук елны, май ахырларында Видинеев (хәзерге Луначарский) бакчасында бик зур җыелыш булды. Бу җыелышта Милли Шура сайланды. Ләкин Милли Шурага күбесенчә Гомәр морза Терегулов, Закир Кадыйри, Садрый Максуди кебек милләтче меньшевик, кадет партияләрен яклап йөрүче татар буржуйлары сайландылар.

Июнь-июль айларында фронтовиклар кайттылар. Алар арасында Галимҗан Ибраһимов, Шәһит Ходайбирдин, Исмәгыйль

Рәмиев, Нигъмәтулла Еникеев, Гомәр Әлмөхәммәтов, Әхмәт Хәбиби, Зыя Насыйров, Зыя Маликов, Фәтхи Әхмәдуллин (ул Фәтхи солдат дип йөртеләә иде) бик актив рәвештә халык файдасына эшләп йөрделәр. Бу иптәшләргә башка яңа көчләр дә килеп кушылды.

Озак та үтми, Милли шураны Вилаять мәҗлесе итәргә дигән лозунг астында Милли шура башында утырган түрәләрдән бик каты отчет алынды. Гомәр Терегулов белән Закир Кадыйринең битләреннән тир агып, үз хаталарын – халык акчаларын урынсыз тотканнарын танып-сөйләп маташканда, бер төркем коралл солдатлар:

– Кадет, буржуй ялчыларын алыгыз, себерепташлагыз! – дип кычкырып алга таба атылдылар. Милли шурачыларның кайберләре тәрәзәдән чыгып качтылар. Закир Кадыйринең:

– Бәбкәйләрем, ике балам хакына мине үтермәгез, терек калдырыгыз! – дип калтырап-тетрәп ялварганы әле дә күз алдымда.

Президиумда утырган Галимҗан белән Сәйфи халыкны тынычландырдылар. Вилаять мәҗлесенә халык яклы кешеләр сайландылар. Бу җыелыш приказчиклар клубында булды. Морзалар-түрәләр отчет һәм сайлаулар дөрес булмады дип, Бирскийгә барып җыелыш үткәрергә булсалар да, анда шул ук фронтовиклар барып, аларны туздырып кайттылар. Тагы бер җыелыш Учредительное собраниега депутатлар исемлеге турында булды. Монда да Галимҗан сул канат башында торды. Югарыдагы фронтовиклар 3 нче номерлы исемлек төзеделәр. Галимҗан шул исемлек буенча Учредительное собраниегә сайланды. 1 нче номерлы исемлектә кадетлар, милләтчеләр, буржуйларның кандидатлары иде. Калган исемлекләрдә октябристлар һәм башка буржуа партияларнең кандидатлары иде. 10 нчы исемлектә большевикларның кандидатлары иде. Бу исемлек буенча кемнәр сайланганын хәтерләмим.

Безнең Сафар волостендә абсолют күпчелек белән 3 нче номерлы исемлек үтте.

Көзгә таба тагы бер зур көрәш булып алды: милләт мәҗлесенә сайлау булды. Бу сайлау Уфа губернасы өчен генәме, әллә башка губерналар да катнаштымы – анысы хәтеремдә юк. Тик шуны хәтерлим: ике исемлек төзелде. Исемлекнең берсендә зур дин башлыклары, буржуазия язучылары иде. Мөфти Галимҗан Баруди, Риза казый Фәхретдинов, Салихҗан казый Урманов, Садрый Максуди, Гаяз Исхакый, Зыя Камали һәм башка шуның кебек кешеләр

бу исемлектә иделәр. Галимҗан Ибраһимов тиз генә Зәки Вәлиди белән (ул вакытта бу кешенең председатель булуын белмиләр иде) киңәш итеп, башкортлар белән бер исемлек төзергә булды.

Зәки Вәлиди:

– Җыелышка килгән халыкның күпчелеге дини халыклар, муллалар, морзалар. Шуның өчен исемлеккә Риза казый Фәхретдинов белән Зыя Камалине кертергә кирәк, – диде.

Исемлек төзер өчен комиссия сайланды. Бу комиссиягә мин дә сайландым. Комиссиянең утырышы вакытында Зәки Вәлиди:

– Мине исемлекнең беренче урынына куегыз, – дип тартыша башлады.

Галимҗан:

– Аз дигәндә 20 кеше сайланачак. Шулай булгач, беренче-икенче урынның ни әһәмияте бар? – дип, ничаклы аңлатырга тырышса да, Зәки Вәлиди үзенең исемен икенче урынга куйдырды.

Галимҗан минем исемне 11 нчеме, 1 нчеме урынга язарга булды.

Мин:

– Кирәкми! Миннән башка кешеләр дә күп, – дигәч, Галимҗан:

– Не надо скромничать! Сине министр итеп күрсәтсәләр, син үзен падишаһ булырлык кешемени, – дип әйтергә кирәк дип тиргәде.

Шулай да мине 22 нче урынга куйды. Сайлау нәтиҗәсендә беренче кандидат Баембетов (Гәләмдәр бугай), икенче кандидат мин булып калдым.

Милләт мәҗлесе ачылыр алдыннан Галимҗан миңа:

– Баембетов килә алмый, син килеп җит! – дип хат язса да, мин дә чирләп ята идем, бара алмадым.

Октябрь алдындагы көрәшләр шуның белән бетте дияргә ярый.

Галимҗанның шул чаклы тырышып, бөтен көче белән төне-көне армый-талмый эшләве, чын халык уллары булган аңлы-белемле активистларны җәлеп итеп, безнең кешеләрнең башына да килмәгән мәсьәләләрне алдан күреп, дөрес уйлап чын халык файдасы өчен тырышуы гаҗәпләнмәслек түгел. Ул бу вакытта да: «Ярар, карарбыз… эшне кичектерми, вакытында үтәп бетерә бара... [...].

1920 нче елда Алкин авылында мин укытучылар хәзерләү курсларында ана теле укыта идем. Шунда ул курсларга кереп мине

күреп чыкты. Минем ВКП(б) партиясенә керүемне белгәч, мактады. Шушы тирәләрдә бер авылда хәл итәргә уйлаганын әйтте.

1926–27 нче уку елында мин Казанда юридический курсларда укыдым. Мин аның янына Наркомпроска кереп күрешеп чыктым. Моннан күп тә үтмәде, ул каты авырып, Кырымга озатылды. Соңгы күрешү шул булды.

*Г. Ибраһимов белән «Галия» мәдрәсәсендә укыган иптәше Фәтхел Корбангалиев (1887–?) истәлеге Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә, Г. Ибраһимов фондында саклана (65 ф., 4 тасв., 13 с.б.). Истәлек машинка басмасында, татар телендә кирилл хәрефләре белән язылган. Текст басмага әлеге нөсхәдән бераз кыскартылып алынды.*

*К. Хәсән*

## Галимҗан Ибраһимов янында

Севастополь. Поезд акрын гына стансага килеп туктады. Вагоннардан, юл чемоданнарын күтәреп, пассажирлар төшә башладылар.

Вокзалның бер ягыннан аларга каршы бер төркем курорт агентлары килеп чыктылар. (Аларны сул җиңнәренә бәйләгән язулы кызыл ленталары буенча танып була иде). Гаҗәп яхшы күңелле кешеләр. Син сорашып өлгергәнче, алар шунда ук сиңа үзләренең хезмәтләрен тәкъдим итәләр.

– Әйдәгез, иптәш, машина сезне көтә... – ди агент һәм үзе безнең юл чемоданнарыбызны күтәрешеп, вокзал аркылы шәһәргә озатып чыга.

Вокзал артындагы площадкада, пассажирларны көтеп, уннарча ябык, җиңел автомобильләр тоталар.

Без шунда, Ялта шәһәренә бара торган машинаны эзләп таптык. Ул арада безнең машина янына тагын беничә ял итәргә баручы килеп басты.

Машина урыныннан кузгалды... һәм озак та үтмәстән, күз иярмәслек тизлек белән шәһәрне үтеп чыктык. Тигез һәм туры юл белән шактый озак барганнан соң, безнең машина, кинәт ике биек тау арасына килеп керде. Без тәрәзәләргә текәләбез. Безнең алда экрандагы кебек, әледән-әле яңа һәм кызыклы картиналар үтәләр. Безнең машина шунда кинәт текә борылыш ясый һәм кызу рәвеш-

тә тауга күтәрелә. Безнең юлыбызның бер ягында, үзенең бөтен авырлык һәм зурлыгы белән биек тау – скала асылынып тора. Икенче ягында исә, әкияттәге кебек коточкыч тирән чокыр ярылып ята. Без акрын гына скаланы әйләнеп югары күтәреләбез һәм бары 18 борылыштан соң гына үзебезне көньяк ярларның биек түбәсендә күрәбез. Биредә безнең күзләргә чиксез төсле булып Кара диңгез күренә. Һәм без шунда беренче мәртәбә диңгез дулкыннарының ерактан шаулавын ишеттек. Безнең юл яңадан текә борылыш ясап түбәнгә төшә башлады... Шофер рольне тоткан хәлдә, тиз генә тормозны басты. Без, егылудан курыккан шикелле, сизгерсез рәвештә бер-беребезгә тотынабыз.

Бу вакыт безнең искә, Кырымның көньяк ярларына бара торган шушы баш әйләндергеч борылыш юллар турындагы истәлекләр төшә. Алар болай да сөйләп бетергесез күңелле һәм матур юлларны тагын да баеталар һәм онытылмаслык булып хәтергә урнашалар.

Бары биш сәгатьтән соң гына без Алупка һәм Ливадияне үтеп, Ялта шәһәренә керәбез.

Ялта үзенең урыны ягыннан Кырымның көн ярларында иң матур һәм иң күңелле урыннарыннан берсен билэп тора. Аның бер ягында куе яшел агачлар белән капланган биек таулар, икенче ягында туктаусыз биек таулар, икенче ягында шаулап торган Кара диңгез. Диңгез ягыннан җил белән иснәп туйгысыз җылы, йомшак һава исеп тора. Шәһәрнең тар урамнары мәңге яшел кипарислар, пихта, магнолия, роза агачлары белән һәм шунда ук оста рәвештә кыркылган самшит һәм лавр агачлары белән яшәреп торалар.

Биредә һәр елны 10 меңнәрчә кешеләр илебезнең ерак почмакларыннан килеп дәвалананалар. Биредә сөйләп бетергесез табигый байлыклардан тыш, дәвалану өчен Семашко исемендәге атаклы институт бар. Анда авырулар өчен 123 кә якын төрле процедуралар кабул ителә. Менә биредә үк илебезнең шушы ерак һәм гүзәл шәһәрендә безнең сөекле язучыбыз, совет яшьләренең якын дусты Галимҗан Ибраһимов тора. Аның йорты диңгезгә бара торган үзәк урамнарның берсендә. Диңгездән ерак түгел юл өстендәге бер ишек алдында тора. Йорты алдында яшәреп биек кипарислар үсәләр. Шунда ук кечкенә генә парк һәм аны үтеп киткәч Галимҗан аганың тора торган йорты.

Без Янбулатов (*Янбулатов Мөслим районында, район газетасының редакторы булып эшли.* – авт.иск.) белән икәү бергә басма

буйлап ак таш өйнең өске катына күтәрелдек. Безне Галимҗан аганың иптәше Хәдичә апа каршы алды.

Ишектән кергәч тә, мин үземдә яңадан уңайсызлану сиздем. Мин яңадан, беренче мәртәбә Галимҗан ага белән телефон аркылы сөйләшкәндәге кебек, каушап калдым. Ләкин мин моны бөтен көчем белән сиздермәскә тырыштым. Мине уйга китермәслек бәхетле һәм җанлы очрашу көтә иде. Мин тиз генә өс-баш киемнәремне салдым да, чишенү бүлмәсе аркылы Галимҗан аганы күрергә ашыктым. Ләкин мин дә, минем иптәшем Янбулатов та Галимҗан ага белән таныш түгел. Без аны моңар кадәр бары әсәрләре аркылы гына белеп килдек. Шуңа күрә менә бу беренче очрашу минем өчен авыр һәм уңайсыз булып тоелды.

Бүлмәдә җыйнак кына итеп җыештырылган аш өстәле янында өстенә җылы, кыска куртка кигән, чәчләренә ак чал төшкән, шактый ук карт һәм ябык йөзле Галимҗан ага утырып тора иде. Без аның белән җылы һәм ягымлы гына күрештек. Ул безне ачык йөз белән каршы алды. Бераздан соң мин үземнең урынсызга алдан каушап һәм уңайсызланып калып тирән ялгышканлыгыма төшендем. Галимҗан ага шунда ук, безнең оялып һәм тартынып торганыбызны сизгән шикелле, сүзне башлап җибәрде. Без аңа республиканың күп кенә яңалыклары турында сөйләдек. Ул безгә:

– Мин соңгы вакыт Казанда 1933 нче елда булдым. Аннан соң минем булганым юк, әгәр бераз сәламәтлегем яхшырса, мин алдагы язда кайтып килергә уйлыйм, – ди. Билгеле, ул үзенең хәле яхшыруына шикләнми. Аның сөйләвенә караганда, хәзер ул бөтен көчен һәм игътибарын дәвалануга, үзен тәрбияләргә биргән. Врачлар рөхсәт иткән кадәр генә укый, ял итү, шулай ук алар кушканны гына ашау-эчү Галимҗан аганың хәзерге тормышында каты закон булып тора. Ул законны бозу, һичсүзсез, аның өчен зур җинаять булыр иде.

Без язучының тормышы һәм эше белән тагын да тирәнрәк кызыксынабыз һәм бер-бер артлы аңа үзебезнең алдан ук хәзерләп килгән сорауларыбызны бирәбез. Ул:

– Мин хәзер бер нәрсә өстендә дә эшләмим. Моңа кадәр, сәламәтлек яхшырып киткән араларда яхшы ук эшләдем. 1927 нче елдан соң мин «Безнең көннәр», «Тирән тамырлар» һәм «Татар хатыны ниләр күрми» дигән әсәрләремне төзәтеп бастырдым. Аларның барсына да, аеруча соңгысына күп көч куярга туры килде, – ди.

Галимҗан Ибраһимов белән даими элемтә тотучы берәү үзенең хатында: «Сез читтә яшисез. Сезгә ялгыз күңелсез түгелме?» дип сорау куйган. Турысын әйтергә кирәк, бу сорау Галимҗан Ибраһимовны шактый ук борчыган. Ул безгә шуны исенә төшереп:

– Мин, читтә яшәсәм дә, ялгыз түгел. Күңелсезләнүне һәм ялгызлыкны бөтенләй белмим, – дип җавап бирде.

Аның алдында әле яңа гына почтальон китереп киткән бер бөктәр[1] газеталар һәм хатлар торалар. Галимҗан ага аларны җентекләп укып бара һәм хатларга вакытында җавап яза. Шул сәбәпле, Казандагы кайбер язучыларның аның турындагы, тормыштан һәм сәясәттән артта кала, дип сөйләнүләре бөтенләй дөрес булмас иде.

Ул шунда, акрын гына урыныннан күтәрелеп, безне үзенең йокы бүлмәсенә алып керә. Бу бүлмә аның шуның белән бергә уку һәм эш бүлмәсе дә. Бүлмәнең караңгы ягында йомшаграк карават куелган. Бүлмәдә берничә йомшак урындык, бер эш өстәле һәм аның баш-башында китаплар белән тулы ике шкаф тора. Аларда классик язучыларның әсәрләре, бүләк итеп җибәрелгән башка күп язучыларның дистәләрчә истәлек романнары һәм җыентыклары саклана. Галимҗан ага шунда «Гражданнар сугышы тарихы»ның I нче томын һәм үз әсәрләренең пөхтә итеп эшләнгән соңгы басмалары белән таныштырды. Без, бераз караганнан соң, яңадан аның тормышына кайтабыз. Безне бигрәк тә аның партия тормышы кызыктырды.

– Мине үз теләгем белән электроводлар оешмасына беркеттеләр. Мин хәзер учетта шунда торам. Үзем чыгып йөри алмау сәбәпле, һәр атна саен партия оештыручысы минем өемә килә һәм оешмадагы барлык мәсьәләләр турында миңа информация ясый. Мин аның белән фикерләремне уртаклашам һәм шулай итеп оешманың эше белән якыннан бәйләнеш тотам, – ди Галимҗан Ибраһимов.

Икенче кабат без язучының квартирында яңа ел алдыннан гына булдык. Без килеп кергәндә, Галимҗан ага үзенең эш өстәле артында газеталар укып утыра иде.

Бу юлы безгә шактый күп нәрсәләр турында сөйләшергә мөмкин булды. Сүз ике йөзле француз язучысы Анри-Жидтан[2] башланды.

---

[1] Бөктәр – төргәк, төенчек.

[2] *Сүз француз язучысы, прозаик һәм драматург Андре́ Поль Гийо́м Жид (1869–1951) турында барса кирәк. 1936 елда ул СССРда була һәм шул елның ахырында аның»Возвращение из СССР» дигән очеркы басылып чыга.*

«Анри-Жид ялгышты, ди Галимҗан Ибраһимов. Ул һичбер нәрсә белән дә саклана алмаслык дәрәҗәдә безгә хыянәт итте, безнең туган илебезгә иң кабәхәт рәвештә яла якты һәм пычрак ташлады»...[...]

Беседаның ахырында Галимҗан Ибраһимов яңадан Татарстан хәлләренә кайтып, Янбулатовтан колхозлар тормышы турында, миннән Зеленый Дол шәһәренең үсешен тулысынча сөйләтте. Боларның барысын да язучының хәзерге җанлы һәм чын тормыш белән яшәве, аны тагын да киңрәк һәм тирәнрәк итеп өйрәнергә теләве аңлашыла. Ул үзен бервакытта да ялгыз хис итми. Һәр атна саен килеп торган кунаклар, һәр көн саен алына торган бу күп сандагы хатлар, газеталар, журналлар һәм башкалар Галимҗан Ибраһимовка әледән-әле тормыш якларын, илебезнең бөек, гүзл эшләрен һәм уңышларын сөйләп торалар. Шуңа күрә ул безнең белән бергә һәм безнең кебек җанланып яши. Болардан тыш Галимҗан Ибраһимов Бөтенсоюз Пушкин комиссиясенең члены буларак, аның эшләре белән якыннан танышып бара. Күп вакыт аңа теге яки бу мәсьәлә буенча үз фикерләре белән уртаклашырга туры килә. Ул бу урында комиссиягә телеграф һәм почта аркылы телеграммалар, хатлар җибәрә.

Соңгы мәртәбә очрашу ике сәгатьләрдән соң өзелде. Безгә яңа елны каршы алу кичәсенә китәргә, ә Галимҗан агага ял итәргә вакыт иде. Без бу очрашуда тагын да күбрәк йогынты алып калдык. Үзенең озак елларга тартылган каты авыруы өстеннән комсыз рәвештә тормышның эченә керергә һәм аны иң тирән, иң киң рәвештә тикшереп, белеп өйрәнергә омтылган, үзе гаять дәрәҗәдә бай һәм канәгать күңелле язучыбыз Галимҗан Ибраһимов безгә онытылмаслык якты хисләр һәм теләкләр бирде.

Без шунда, аның белән җылы рәвештә саубуллашабыз һәм тиздән Казанда очрашуны теләп чыгып китәбез.

Ялта
9.05.1937.

*Истәлек авторы К. Хәсән турында төгәл мәгълүматлар юк, китерелгән чыганак буенча фикер йөрткәндә аның хәзерге ТР Яшел Үзән шәһәреннән булуы һәм матбугат өлкәсендә эшләве аңлашыла. Истәлек Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә, Г. Ибраһимов фондында саклана (65 ф., 4 тасв., 41 с.б.). Язма машинка басмасында, 6 биттә, татар телендә, латин графикасында. Текст басмага әлеге нөсхәдән бераз кыскартылып алынды.*

*Г. Мухамедова*

## О Галимджане Ибрагимове

В 1922 году, собираясь ехать из Астрахани в Казань на учебу в медфаке Казанского университета, я решила купить книгу для чтения в пути. Зайдя в свой любимый книжный магазин, который не раз и радовал, и потрясал меня такими литературными шедеврами как «Спартак», «Железная пята», «Овод». На этот раз мне предложили напечатанную на шероховатой, желтоватой грубой бумаге арабским шрифтом толстую книгу, под названием «Безнең көннәр», что в русском переводе означает «Наши дни». Магазин и на этот раз не обманул меня. Эта книга потрясла меня не меньше, чем «Овод» Войнича. Персонажы, выведенные автором в этой книге, мне не казались абстрактными литературными героями, а живыми людьми из плоти и крови, существующими и поныне в жизни, вместе с нами. Таким образом с творчеством Галимджана Ибрагимова, с героями его произведения я познакомилась раньше, чем с ним самим.

Впервые я увидала самого автора и познакомилась с ним в одной из университетских аудиторий, куда он был приглашен для чтений студентам-татарам лекцию о современной татарской литературе. Наше знакомство укрепилось постепенно и вскоре я стала женой Ибрагимова.

Положение супруги такого исключительно многосторонне одаренного, глубоко уважаемого своим народом человека как Галимджан Ибрагимов, накладывает определенные серьезные обязанности. Конечно, в самом начале нашей совместной жизни я не была еще готова к этим обязанностям. Правда, я увлекалась рисованием, живописью, мечтала поступить в школу изобразительного искусства. Много читала. Была достаточно хорошо знакома для бывшей гимназистки, с русской и иностранной художественной литературой. Знала и татарскую. Но это знание, этот интерес были весьма односторонни, поверхностны. Я понятия не имела о значении и роли художественной литературы в общественной жизни, о течениях и направлениях в литературе и т.д. Меня увлекали лишь внешние формы, сюжет, фабула произведения, красивые фразы, насыщенные волнительными эмоциями.

Как известно, юность Галимжана прошла в схоластическом медресе. Несмотря на это, он сумел самостоятельно и скрытно от

хазрата [ознакомиться] не только с восточной, но и с европейской литературой и искусством.

Поскольку областью основной деятельности Галимжана Ибрагимова была художественная литература, он не пропускал мимо своего винмания ни одной литературной новинки. Его личная библиотека была богата. На его книжных полках можно было увидеть не только современных русских и татарских писателей, но и произведения мировой классики. Были даже печатанные древними орхонскими и уйгурскими шрифтами произведения, как например книга «Кудатку белек». Украшали эту библиотеку такие прекрасные альбомы с репродукциями картин Третьяковской, Дрезденской и Луврской галлерей.

Галимжан, конечно, прекрасно видел уровень моих познаний и восприятий произведений литературы и искусства. Он начал уделять серьезное внимание расширению и углублению моих познаний, старался приучать меня обращать внимание не только на внешние, поверхностные формы, особенности явлений, событий, а искать и постигать внутреннее содержание, внутренний их смысл.

Прошло около года такого обучения и Галимжан попросил меня помочь ему в изучении архивных документов Казанского жандармского управления. Дело в том, что ему было предложено Обкомом партии Татарстана написать книгу, посвященную участию татар в революции 1905 года, которая должна быть опубликована к 20-летию революции. Времени было мало, а кроме архивных данных надо было найти и изучить печатные исторические данные, публицистические материалы, воспоминания людей, которые имели какое-либо отношение к событиям того времени. Я с удовлетворением выполнила эту просьбу Галимжана. А когда возник вопрос о переводе этого произведения на русский язык, перевод этот был поручен мне, что говорило о том, что я заслужила и укрепила доверие ко мне и Галимжана и Сибгата Гафурова, который работал тогда в испартотделе Обкома партии. Листы оригинала с непросохшими еще чернилами из под рук Галимжана переходили ко мне для перевода. Готовый перевод главы немедленно передавался редактору. Работа шла конвейером и потому татарский и русский тексты книги вышли из печати одновременно и к сроку. Таким [образом] полностью оправдал свой девиз: «Я коммунист, я солдат пролетарской революции!», а солдат революции

и не имел права не выполнить порученную ему партией и революцией работу. Таков он был, Галимжан.

Тотчас после этой большой работы Галимжан принялся за роман, который вначале он назвал «Слово правды», а впоследствии это название переменил на «Глубокие корни». Роман был закончен в начале 1926 года, но Галимжан не спешил с его опубликованием. Он начал писать теорию литературы, назвав её «Әдәбият кануннары» – «Каноны литературы». Здесь он поручил мне работу исследовательского характера; на примере творчества трех поэтов: Г. Тукая, Дердеманда и Сагита Рамеева разобраться с вопросом ритмики и рифмы в татарском стихосложении. Но, к сожалению, эта чрезвычайно интересная для меня работа внезапно прервалась из за неожиданной тяжелой болезни Галимжана. И только в 1928 году, в Ялте, у Галимжана начала пробуждаться творческая мысль и он попросил дать ему залежавшуюся без движения «Слово правды». С этой книги он начал заново перерабатывать свои ранние произведения, которые давно перестали соответствовать его уже созревшему писательскому мастерству. Так были заново переработаны повесть «Судьба татарки», «Молодые сердца», первая книга трилогии «Наши дни». В подобных работах моя помощь в основном была чисто техническая. Когда он чувствовал себя плохо и был не в состоянии писать сам, за стол садилась я и писала под его диктовку или же переписывала набело страницы, написанные им самим.

К началу 1937 года он закончил переработку романа «Яшь йөрәкләр» – «Молодые сердца», но ему казалось, что роман все еще не дозрел и он не отправлял его в Казань. Тем временем, он написал и отправил в Казань рассказ «По возвращении с фронта». В ящике его письменного стола лежал еще один небольшой рассказ «Корбан» – «Жертва», но он, почему то, тоже не торопился предложить издательству. Настала очередь второй книги трилогии «Наши дни». Однако он не смог закончить эту книгу. Галимжан тяжело заболел, перенес хирургическую операцию. Он скончался 21 января 1938 года. Потянулись сумрачные предвоенные годы, навалились небывало тяжелые военные годы. Наступили послевоенные восстановительные годы и только в середине пятидесятых годов возникла возможность восстановления творческого наследия Галимжана. Союз писателей Татарии в лице его тогдашнего председателя Гомера Баширова, членов Союза Амирхана Еники, Афзала Шамова, Мансура Хасанова проявили в этом деле огромную энергию, помогли и мне внести

свою лепту. Благодаря поддержке этих благородных товарищей мне удалось написать и опубликовать в печати такие работы о Галимжане как «Большая жизнь» – на русском языке, «Зур тормыш» на татарском языке, «Киевское событие» – на татарском языке, «Яшьлек көннәре» – на татарском языке, «Сикәлтәле туры Юл» и закончить последнюю работу под названием «Олы юл», охватывающую период жизни Галимжана начиная с февральской революции до самой его смерти в 1938 году. Я тешу себя надеждой, что по мере своих сил воздала свою лепту памяти Галимжана Ибрагимова.

*Истәлек Г. Ибраһимовның тормыш иптәше, язучы Гөлсем (Өммегөлсем) Даут кызы Мөхәммәдова (1903–1988) тарафыннан язылган. Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә әлеге истәлекнең машинка басмасындагы нөсхәсе Г. Ибраһимов фондында саклана (65 ф., 4 тасв., 20 с.б.). Истәлек кирилл хәрефләре белән, рус телендә. Текст басмага әлеге нөсхәдән алынды.*

*Б. Умеров*

## Кырым язучысының әдәби ватаны

1914–1917 нче елларда Уфада «Галия»дә унбиш-егермеләп кырым яшьләре укыдылар. Ул вакытлар «Галия» укытучысы Галимҗан Ибраһимовның кырымлылар белән булган мөнәсәбәте менә шул елларда башланды.

Бакчасарайдан Госман Закки Бәкиров, Бәкир Сыткый Ибраһимов, Гомәр Фәхми Ипчи, Ялта районыннан Яхъя һәм Бари Габбасовлар, Алушта районыннан Габдулла Хәким Мөхәммәдов, Кизләү районыннан Хәким Гафар һәм башкалары «Галия»дә дәрес биргән Галимҗан аганы яхшы белә, аның язган китаплары һәм мәкаләләре белән таныш иделәр.

1917–1918 нче елларда, газеталар һәм журналлар аркылы, Г. Ибраһимовның исеме кырым яшьләре арасында киң сурәттә җәйрәде (таралды). 1918 нче ел башларында В.И. (Владимир Ильич) декреты белән Русия мөселманнары Халык комиссариаты башлыгы булган Мулланур Вахитов һәм аның урынбасары Галимҗан Ибраһимов эшчәнлекләре Кырым хезмәткәр халкы арасында яхшы урын казандылар.

Революция дәверендә ачылган урта мәктәпләрдә Г. Ибраһимовның «Әдәбият дәресләре» китабы без – яшьләр өчен иң сөекле дәреслекләрдән бере иде.

1918 нче ел январь 18-дә «Чулпан»да басылган аның «Мәрхүм Учредительное собрание» мәкаләсендә «...Мәркәс һәм урыннарда хакимият эшче, солдат вә авыл халкы шураларына! Менә хәзер безнең шигаребез[1] шул булырга тиеш» сүзләре безнең Кырым хезмәткәрләре өчен дә юл күрсәтү вазыйфасын күрделәр.

Галимҗан Ибраһимовның Казанда, Мәскәүдә чыккан газета вә журналларда («Чулпан», «Кызыл шәрек» һәм башкалары) басылган мәкаләләрен безнең Кырым яшьләре, бигрәк тә комсомол сафларында булган яшь буын, чын күңелдән сөеп укый иделәр. Габдулла Тукай яшьлекнең иң сөйгән шагыйре булса, Ибраһимов та яшьләр вә укытучыларның һәм дә халыкның иң сөеп укыган язучыларыннан бере санала иде.

...1927 нче елларда Галимҗан Ибраһимов Кырымга – Ялтага килгән хәбәре аз бер вакыт эчендә бөтен шәһәр һәм авылларга таралды. Сентябрь ае башларында, Мисхор санаториясенә барганда, миңа 1918 нче елда мәктәп иптәшем булган Яхъя Габбасов Галимҗан аганың Алупкада яшәгәнен сөйләде һәм өй адресын бирде.

Ул вакытта «Чаир» авыл хуҗалыгы мәктәбе директоры агроном Мамут Баясанов белән берлектә Ялта читендә Алупкага барып, Галимҗан Ибраһимов яшәгән өйне таптык. Сәгать дүрт-биш чамалары иде. Йөзендә арганлык, авырулык галәмәтләре ачык күренеп торса да, Галимҗан ага безне шатлык һәм куаныч белән каршы алды. Халыкның яшәве, яшьләр һәм мәктәпләр тормышы турында күп сораулар бирде. Аны бик күбесенчә мәктәпләрдә уку-укыту мәсьәләләре, комсомол эшләре, тел, әдәбият кызыксындыра иде. Бу сөйләшү вакытында кырым татар язучылары, газета һәм журналлар хакында да күп сүзләр булды. Сөйләшүнең иң кызып барган вакытында җир тетрәде, зилзилә булды. Шул минутта Мамут верандада яткан Рөстәмчикне кулга алып, Галимҗан аганың култыгына кереп, икесен дә ишегалдына чыгарды. Гөлсем Мөхәммәдова да шул ук мәлдә ишек алдында аларның янында күренде.

Бу җир тетрәве 1927 нче елда Кырымда, бигрәктә диңгез буенда, ярым утрауга күп зарар китергән зилзиләләрнең беренчесе иде. Галимҗан ага шул җир тетрәү вакытында үзенең салкын канлылыгын вә сабырлыгын күрсәтте. Һич тә аптырамады һәм безне:

– Куркырга, аптырарга кирәк түгел, – дип, аптыраудан шашкынлыктан алып куйды.

---

[1] Шигаребез – лозунгыбыз.

Бу күрешү минем Галимҗан Ибраһимов һәм аның гаиләсе белән беренче очрашуым иде. Табигый, җир тетрәүдән соң без язучының янында күп тукталмадык, гаиләсе һәм аның белән саубуллаштык.

1931–1932 нче елларда Ялтада «Долоссы» санаториясендә эшләгән вакытында Галимҗан ага белән күп күрешә торган идек. Район партия конференциясендә коммунист язучыбыз ревизия комиссиясенә сайланган иде. Мин дә шул комиссиядә член булганымнан, мәҗлесләрдә һәм күп вакыт райком партия секретаре Шакир Даутов иптәш тә очраша һәм дә партия эшләре, ара-тирә әдәбият һәм мәдәни пропаганда мәсьәләләре турында да сүз башлап китә иде. Бер көн Даутов кабинетында, Галимҗан ага белән мине ике ягына утыртып, фото чыгарткан иде. Ул фотолар без кулга алынганда алындылар һәм югалып киттеләр. Белмим, шул фото Даутов иптәштә калмады микән.

...1931 нче елның сентябрь соңнары иде. Ул вакыт Кырымда «Алтын көз» хисаплана, йөзем һәм башка җимешләрнең иң мул дәвере. Диңгез тыныч, һич бертөрле дулкын юк, кояш та үз нурын һәм җылылыгын Ялта тауларында кыялар, ташлар арасында үскән чам агачларына[1] бер дә кызганмый җәйрәтә, урталыкны гөлләр, чәчәкләр исе каплап алган. Галимҗан ага шәһәр бакчасында зур чинар төбендәге скамьядә берүзе күзләрен таулар, чам агачлары ягына төбәп уйга чумып утыра иде. Мин диңгез буе Набережная тарафыннан әкерен-әкерен барып сәлам бирдем дә янына утырдым. Шатланып китте, көлемсерәде.

– Ага, ни өчен диңгезгә артыгыз белән утырасыз? – дип сорадым.

– Диңгез салкынлык бирсә дә, гөлләр, чәчәкләрдән һәм чам агачларыннан килгән исле һава мине тагы да күбрәк иркәли. Уйларымны кыздыра, күңелемне ашкындыра, уйларымны тирәнләштерә, үземне Татарстан – Башкортстан урманнары вә Идел буйларына һәм киң болыннарга алып бара. Илне сагынам, балалык, яшьлек көннәрем исемә төшә, – диде. Сүз башлап киткәннән соң саулык, тормыш хакында да сорап алды.

– Үземне яхшы хис итәм. Кырымның шифалы һавасы мине аякка бастырды. Миңа эшләргә, язарга көч бирде. Ләкин ялгызлык мине бераз тынычсызлый. Яз айлары шимальдән бик күп дуслар,

[1] Чам агачларына – чыршы агачларына.

иптәшләр киләләр. Кыш көннәрендә кыенлыклар була, ул вакытларда кояш та күп көннәрдә безне оныта, болытлар арасыннан көлеп карый, диңгез дисәң, ачуланып кабара, дулкынлана, шаулап тора» – дип көлемсерәде.

Кырым татар әдәбияты турында сүз чыкканда язучы үзенә кырым татар язучыларының да еш-еш килеп киткәннәрен, бигрәк тә, язучы Гомәр Ипчи һәм шагыйрь Әшрәф Шемизаде белән күп сөхбәтләре[1] булганнарын сөйләде. Сүз соңында кырым татар телендә чыккан китапларны укыганын һәм алар арасында Ипчинең прозасы вә Шемизадәнең шигырьләре үзен кызыксындырганын һәм дә шул ике язучының үсүләре өчен мөмкинлек булса, алардан күп уңышлар көтәргә мөмкинлеген әйтеп үтте.

Минем:

– Гомәр Ипчи сезнең шәкертегез бит, – сүземә Галимҗан ага:

– Татарстаннан башка Башкортстан, Казахстан, Кырым һам Урта Азиядә күп шәкертләрем бар. Алар мине онытмыйлар, хат язалар, аратирә килеп тә китәләр, рәхмәт аларга, – дип җавапланды.

* * *

Рус бөек язучысы А. Чехов кебек, Кырымның җәннәте, шифалы һавасы, дарулы йөземе, җимешләре, зәңгәр диңгезе, чәчәкләре, гөлләре белән дан казанган Ялта-Алупкада ун ел кадәр гомер кичереп саулыгын төзәткән, язарга, укырга көч-куәт тапкан революционер, мәшһүр татар язучысы Галимҗан Ибраһимов кунак ярата торган ярымутрауны сөйде, аның кардәш халкы белән якынлашты, дуслашты.

1934–1937 нче елларда, кулга алынуына кадәр, үзен дәвалаган, һәркөн дигән кебек янында булган, өй докторы Зәминә Мустафаевна Дагджи (хәзер Сәмәркандта пенсиядә) Галимҗан аганың щул сүзләрен әле бүген дә кабатлый:

– Кырым – Ялта мине аякка бастырды. Монда түшәктә ятып, кан төкереп килгән идем. Кырым – минем икенче Ватаным.

Галимҗан аганың 1932 нче ел апрель 21 дә Ялтадан, Симферопольдә татар телендә чыккан «Большевик юлы» журналына язган хаты белән сүземне бетерергә телим. Язучы хатында шулай дип язган:

---

[1] Сөхбәтләре – сөйләшүләре.

– Каты газаплы куркыныч авыруым миңа Кырым тормышына катнашырга һич бертөрле мөмкинлек бирмәде. Тик хәзер мин бик әкерен-әкерен сәламәтләндектә, шуның белән бергә революциянең Кырым фронты билгесе белән аз-маз таныша барам. Мин моңа кадәр партиянең Казан татарына каратылган фронтында эшләдем, бөтенләй моның белән чикләнмәдем. Мин Башкорт массасы тормышыннан «Башкорт кызы Гөлбикә» хикәя яки типлар, шуның кебек Казахстан «Казакъ кызы» кебек романнар яздым.

Инде, әгәр яхшы сәламәтләнә алсам, бәлки кырым массасының җирле көрәшеннән, иҗтимагый тормышыннан да билгеле бер әсәр бирә алырмын дип өмет итәм. Мин Кырымны бик артык сөйдем, Кырым минем өчен дөньяның иң матур, иң мәгънәле, иң тирән хисләр уяткан яңа әдәби Ватаным булып чыкты.

Минем бу хисләрем каләмемне Кырым турында язарга мәҗбүр итәләр. Сәламәтлегем алга барган саен, мин үземнең бу өметемне гамәлгә ашыру өчен чаралар күрәчәкмен. Кырымның гыйльми, әдәби фронтында коммунистлык бурычымны үтәргә тырышачакмын... »

Кызганычка каршы, бөек язучы, чын коммунист атаклы галим Кырым әдәби тормышында үз коммунистлык бурычын үти алмады. Ежов, Берия башы бозыклары 1937 нче елны Галимҗан аганы икенче Ватаны – Кырым җәннәте Ялтадан «Кара карга» машинасына утыртып Симферопольгә, аннан да тимер чыбыклы Столыпин вагонында Казан төрмәсенә китерделер. Суык, караңгы төрмә камерасында мәшһүр язучының халык өчен тибрәнгән тәмиз[1] кәлебе үз хәрәкәтен туктатты. Татар халкының ялкынлы йолдызы сүнде.

*Сәмәрканд.*

*Г. Ибраһимовның замандашы Бәкер Умеров тарафыннан язылган әлеге истәлекнең машинка басмасындагы нөсхәсе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Г. Ибраһимов фондында саклана (65 ф., 4 тасв. 35 с.б.). Истәлек ахырында «Умеров Бекер Умерович, член КПСС с 1923 года, персональный пенсионер республиканского значения. 2/IV –1965 г. Самарканд – 34, ул. Гагарина 67, кв. 25» дигән өстәмә язу да бар. Истәлек кирилл хәрефләре белән татар телендә. Текст басмага әлеге нөсхәдән алынды.*

---

[1] Тәмиз – чиста.

*Л. Мухамедова*

## Память

11 марта 1988 года прервалась живая нить связующая жизнь Галимджана Гирфановича Ибрагимова с моей сестрой Эммагулесем Давыдовной Мухамедовой.

В своем поздравительном письме с Новым 1988 годом она писала мне, что на днях еще раз перечитала свою последнюю рукопись, прежде чем вернуть в Таткнигоиздат и опять внесла исправления, дополнения и даже изменила название, было «Олы юл», переделала на «Талант һәм аның фаҗигасе» (Талант и его трагедия).

Сумела дописать третью книгу о революционной, творческой и государственной деятельности Г. Ибрагимова.

Жизнь и судьба нам не подвластны. В связи с этим хочу выразить свое удивление, почему в книге «Совет Татарстан язучылары» на 197 странице написано: «Г. Ибрагимов 1938 елның, 21 январенда Казанда больницада вафат була». Книга издана в 1986 году. Не знаю, кому понадобилась эта полуправда, если уж писать, то надо писать, что он умер в больнице, то надо было указать в тюремной больнице, или вообще не упоминать слово больница.

После похорон сестры я позвонила Афзалу Шахабетдиновичу Шамову, что живая нить прервалась, хотя, наверное, еще есть люди встречавшиеся с ним, но мимолётные, недолгие встречи, не могут создать образа человека, для этого надо прожить годы и годы вместе, чтобы всесторонне охарактеризовать его. Все мы знаем, что люди в разных условиях и ситуациях проявляют себя по разному и уловить нюансы характера человека, не находясь в близких отношениях с ним, а тем более дать правильную и правдивую оценку. Взгляд со стороны не всегда точен.

Афзал абый сказал, что я не права, т.к. я прожила несколько лет в его семье и должна написать свои воспоминания о нем. Мои возражения о том, что ничего нового сказать о его творчестве, революционной и государственной деятельности не смогу, т.к. я была ребенком и вряд ли сумею изложить свои мысли соответственно требованиям литературы, будут ли они вообще интересны людям. Афзал абый полностью опроверг мои доводы и сомнения. Каким получится мое повествование не мне судить.

Многие могут сказать, что взгляды ребенка не могут являться полным отражением действительности. Не спорю, может быть и

так. Но не забывайте, что дети более чувствительнее и наблюдательнее взрослых. Дети воспринимают действительность как есть в его первозданном виде, без субъективных анализов, а взрослым это не всегда удается, так как каждый человек по своему, только ему присущим образом, понимает действия другого, как бы сравнивая с собой и по отношению к себе.

Почему и как я оказалась в семье Галимджана абый при живой матери? Я одна из тех детей, которая не испытала материнской ласки. Мои старшие сестры, а они были старше меня на 13–15 лет, старались как-то уберечь меня от побоев матери, решили сами меня воспитывать. Так впервые, в 5-летнем возрасте, я оказалась в семье у старшей сестры Гайши и ее мужа Кратаева Гарифа Ахмедовича в Саратове, тогда они были студентами Саратовского медицинского института.

Летом, уже не помню какого года, сестра решила увезти меня к матери. Почти рядом с трапом, я с сестрой стояла на палубе, а на пристани стоял провожавший нас Гариф абый. Когда я увидела матросов готовых убрать трап, стремглав выбежала на пристань, мертвой хваткой ухватилась за ноги Гариф абый, просила его не отправлять меня к матери. Матросу, подошедшему водворить меня на пароход, он сказал, не надо, она останется со мной.

Впервые проявился во мне дух сопротивления насилию, разумеется, это было не совсем осознанное действие, а инстинкт самосохранения всего живого на свете, а может начало проявления личности. Мне кажется, с этого дня началась моя осознанная жизнь.

Летом 1925 года моя старшая сестра привезла меня в Казань. Первое впечатление – это испуг от больших комнат, где я затерялась как мышонок. Хотя квартира состояла из 4-х комнат, но комнаты были огромными, за исключением кабинета Галимджана абый. Сейчас там разместилась поликлиника Казанского филиала АН СССР.

На мое счастье вскоре мы выехали на дачу в Услон, где нас поджидал Галимджан абый.

На следующий день, видимо для создания интимной обстановки для разговора двух сестер, Галимджан абый повел меня в лес. При виде леса меня обуял страх, я крепко ухватилась за его руку. Чутким знанием человеческой души он понял мой страх, погладив по голове рукой сказал, не бойся я же с тобой, посмотри вокруг сколько красивых цветов. Впервые, я тогда подняв

голову посмотрела ему в глаза, а он смотрел на меня таким добрым, ясным взглядом, что тут же исчез страх с моей истерзанной, ранимой детской души, не познавшей материнской ласки. Чутьем поняла, что он никогда меня не обидит и не даст кому то меня обидеть.

Нравственный долг, душевная красота, духовное величие, справедливость, интеллигентность сочетались с твердым характером у Галимджана абый.

Моим воспитанием в основном занимался Галимджан абый, а у старшей сестры Гариф абый, таким образом я получила мужское воспитание, в какой то мере этим я горжусь.

Галимджан абый нравоучения не читал, никаким наказаниям не подвергал, разговаривал со мной как со взрослым человеком, а не как с ребенком. Это доверие взрослого человека имел большой вес нежели наказания, которым я подвергалась ранее.

Удивительный жизненный урок врезавшийся в память, ранивший мою душу, нанесла мне моя сестра и даже замечание Галимджана абый обращенное к сестре, постой, постой, ты не так сказала, у меня есть Ляйля и Рустэмчик. А дело было так – Галимджан абый принес какие-то покупки, я ликующе высказала: «Это Вы мне купили?». Сестра глядя на меня сказала, что у твоего Галимджана абый есть сын Рустэмчик. В своей дальнейшей жизни я никогда больше не задавала подобного вопроса своим воспитателям.

Мое детское самолюбие торжествовало от обращения со мной как со взрослым человеком. Ведь дети всегда хотят скорее стать взрослыми. Доверие взрослых к детям – такое это благо для становления настоящего человека. Насилие, наказания в детстве так глубоко ранят душу ребенка, рубцы навечно.

Немногословно, слегка приглушенно-сиплым голосом произнесенные слова Галимджана абый для меня были только правдой, верой, авторитетом непогрешимым. Он мне верил, я никогда не лгала, он поддерживал мою прямолинейность в характере.

Меня учили музыке, учитель приходил домой, в один из уроков, за взятую мной не той ноты, он ударил меня по руке. Тут же я перестала играть. Для выяснения отношений и моего категорического отказа продолжать урок был вызван Галимджан абый. Он спросил какова причина отказа. Моя ранимая душа не переносила насилия, с того дня занятия прекратились, а вскоре тяжело заболел Галимджан абый.

Как-то внучка моей сестры сказала, что её педагог в училище иногда бьет смычком по руке. При встрече с её педагогом, как бы к слову, я рассказала почему прекратилось мое музыкальное образование, и знаете, смычковые терзания прекратились. Недаром говорят, слово лечит и слово калечит. Иногда родители, как бы любя, в присутствии своих детей говорят, посмотрите, что делают мои бандиты (в смысле шалят), или, а вот и моя дурочка пришла. Не могу понять, какая же связь между родительской любовью и этими словами? Для меня более приемлимо сказанное нашим гидом в Париже, когда мы проезжали мимо медицинского факультета, она сказала, что здесь учится ее сын, потому что он гениальный (видимо в это время она не смогла вспомнить слово способный). В автобусе прокатилось приглушенное ехидство.

В семье придерживались установленного порядка, за обеденным столом сидели только члены семьи, стол всегда был накрыт белой скатертью, хорошо сервирован, за обеденным столом почти не было разговоров.

В связи с каким-то моим недомоганием врач назначил для меня особый режим питания и отдыха, это строго выполнялось. Как сейчас помню это было зимой, по какой причине не помню, то ли надоело играть, то ли замерзла, вернулась раньше времени. Увидев меня Галимджан абый постучал в окно и на пальцах показал сколько времени я должна еше гулять. Вновь начала кататься на салазках, видимо я потеряла чувство времени, вдруг слышу голос: – «Ляйля, пора возвращаться домой». Видимо, так он развивал во мне чувство ответственности и времени.

Под влиянием уклада жизни в семье начал складываться характер, требовательность к себе и дисциплинированность. Когда я заболела корью, то настояла на своей госпитализации, мотивируя тем, что может заболеть Рустэмчик. В больницу приносили мне книги, а при выписке из больницы не разрешили взять эти книги домой. Просила, чтобы разрешили забрать домой самую любимую книгу «Детям о Ленине». Моя сестра уговорила, успокоила меня, пообещав завтра же купить такую же. На следующий день мне вручили книгу. Книга «Детям о Ленине» была красочно оформлена, меня особенно привлекала картинка – девочка катающаяся на велосипеде, а велосипед, для детей нашего поколения не избалованной игрушками, была недосягаемой мечтой. Глядя на эту картинку я воображала себя на велосипеде вместо этой девочки.

Один раз Галимджан абый взял меня с собой, кажется, тогда его служебный кабинет был в Казанском кремле, показал мне Казанский кремль.

Впервые в своей жизни я была в театре в Казани, куда меня отправили вместе с домашней работницей и ее дочерью Нюрой, с тех пор любовь к театру не ослабела. Ехали мы тогда от Новокомиссариатской до Проломной улицы (ныне ул. Комлева и ул. Баумана) на «Барабыз», тогда так называли сани розвальни.

Весна 1927 года принесла много огорчений, в связи с тяжелым состоянием здоровья Галимджана абый, встал вопрос о выезде из Казани в Ялту. Сестре пришлось прервать учебу на медицинском факультете университета и поехать вместе с маленьким Рустэмчиком в Ялту. Меня оставили в семье Абдурахмана Гайнановича Саади до окончания учебного года. Летом за мной приехал из Астрахани Гариф абый и увез в Астрахань.

Тяжелая утрата постигла в Ялте семью, весной 1931 года умер единственный сын Рустэм от дифтерии.

В разгар лета 1931 года неожиданно приехала из Ялты в Астрахань Гульсем апа и увезла меня. Кажется, тогда цель приезда была удочерить меня. Наши посещения ЗАГСа не увенчались успехом. Путь из Астрахани в Ялту показался мне очень долгим, особенно неприятное впечатление оставил г. Новороссийск, где я не могла раскрыть глаза из-за воспаления, кажется весь город был окутан серым песком. Настолько запечатлелось в моей памяти этот город таким, каким он был в 1931 году, что я не могла избавиться от этого впечатления до 1971 года.

Будучи в гостях у племянницы в Краснодарском крае меня они уговаривали съездить в Новороссийск, я категорически отказывалась, согласилась поехать только по просьбе её девочек. Каково же было мое удивление, это был прекрасный город с чистым небом.

По пути из Новороссийска в Ялту воспаление глаз прекратилось. В Ялте на пристани нас встречал Галимджан абый, с удивлением и восторгом заметил, что я очень выросла.

И я с удивлением обнаружила его схожесть с М. Горьким, т.к. к этому времени согласно школьной программы была знакома с творчеством Горького.

Жили тогда на улице Халтурина 5, на 2-ом этаже, занимали 2 комнаты и веранду в частном доме. В это время состояние его здоровья значительно улучшилось и он мог ходить, опираясь на

тросточку до библиотеки, набережной, парка. Обратно обычно возвращался на извозчике, т.к. идти на подъем не позволяло ему его дыхание. Часто его сопровождала я.

После одного из таких путешествий, вернувшись домой, он меня спросил: – «Ты заметила по дороге что-либо красивое?» Ответ был краткий – «нет». Тогда еще раз пройдись по пройденному пути и внимательно обследуй свой путь. Пришлось повторно совершить этот путь, оказалось на одном из окон стоял горшок с цветущим кактусом. Так предметно учил наблюдательности, внимательности и восприятию красоты мироощущения.

Нельзя сказать, что я всегда была паинькой, и у меня были шалости, непродуманные поступки. Однажды я вернулась из школы без своих кос. Галимджан абый спросил, чем объяснить такое новшество? Не приученная лгать я объяснила, что спорила со своими школьными товарищами, проспорила, а уговор был таков, если проспорю, то подстригусь. Я же должна была сдержать слово! Он тогда мне сказал, хотя как говорят, в споре рождается истина, но спор с оплатой, жертвенностью, это не спор, а сделка, никогда не прибегай в своей жизни к такому спору. Наверное, не мало нанесла я ему огорчений, но никогда не видела его огорченным.

Как-то из-за сильного шторма на море нас задержали в школе. У меня и у моей подруги появилось сильное желание посмотреть на разбушевавшуюся стихию. Удалось сбежать. На набережной нас окатила волна, мы не удержались на ногах, падая я вывихнула мезинец.

При выходе из поликлиники я увидела извозчика, который возил Галимджана абый, пожурив, нас усадил, повез домой меня, затем мою подругу.

Дома после моего объяснения Галимджан абый позвонил в школу, просил не утрировать этот поступок.

Мне доверяли и я старалась ничем не омрачать это доверие. Я обычно не спрашивала разрешения куда-либо пойти, а только сообщала, что я пошла туда-то. Никогда не возвращалась позже 10 часов вечера.

В один из вечеров я сказала, что с двумя мальчиками из нашего класса я иду на вечер в музыкальную школу. По дороге встретилась девочка из нашего класса, присоединилась к нашей компании. Возвращаясь домой слышу разговор на высоких тонах женщины, обвиняющей меня в грехах за соблазнение ее дочери

на вечерние прогулки с мальчиками. Слышу, Галимджан абый ей говорит: – «Во-первых, говорите без оскорблений и не на повышенных тонах, всех друзей Ляйли я знаю, пошли они на вечер в музыкальную школу, к 10 часам вернутся, возвращайтесь к себе домой, видимо, ваша дочь уже дома, в этот момент я подошла к ним, сказала, что Вера присоединилась к нам по дороге, мы ее не приглашали, не договаривались. Мне было очень неприятно, что из-за меня Галимджан абый имел неприятный разговор с этой женщиной. Поднималась по ступенькам на свой 2 этаж с грустной физиономией, а он посмотрев на меня своими добрыми, все понимающими глазами спросил: – «Вечер был интересный?»

– Да, я даже пожалела о своем отказе заниматься музыкой.

Странные бывают встречи в жизни, живя уже в Самарканде, я встретилась с матерью Веры. Она меня окликнула, спросила учусь ли я и где, да учусь в институте. Она расплакалась, сообщила, что Вера сбежала из дома с молодым человеком и она приехала за Верой.

По сей день я удивляюсь его стойкости характера, он оберегал нас от заражения туберкулезом. Свою посуду держал в своей комнате, после обеда его посуда, под его присмотром заливалась кипятком, после этого домашняя работница мыла его посуду, уносила в его комнату. Не разрешал находиться мне в своей комнате более 5–10 минут. Предметно учил аккуратности, соблюдению порядка, памяти. Первый раз взяв книгу в его домашней библиотеке, возвращая книгу положила на полку. Когда мне понадобилась другая книга, он спросил: – «А ты ту книгу принесла?» «Конечно» – ответила я. – «Почему-то я эту книгу не вижу на том месте, откуда ты ее взяла. Поищи, положи на место». В поте лица искала, но тщетно. Тогда он указал куда я положила ту книгу, затем указал куда положить, после этого указал, где лежит необходимая мне книга.

– А теперь запомни с какой ты полки взяла, между какими книгами находилась, или отсчитай какая по счету от края полки.

Добавил, что при беспорядке человек теряет много времени, силы, энергии на поиски. Этот урок запомнился на всю жизнь и следую ему, хотя некоторых моих родственников, родных, знакомых это раздражает.

Единственную просьбу Галимджана абый я не смогла выполнить – это просьба переписать несколько страниц его рукописи.

Когда села за стол, взяла в руки эти страницы рукописи, то поняла, что это невозможно, т.к. запись была сделана арабским шрифтом, которого не знала, от огорчения полились слезы. Застав меня в таком виде, узнав о причине слез, как-то застенчиво улыбнулся, тихо произнес, растет новое поколение не знающее арабского шрифта, ты ведь не училась в татарской школе, потому и не знаешь арабского шрифта, успокойся, придет Гулесем, она перепишет.

Единственная возможность вникнуть в его творческую деятельность была упущена из-за незнания арабского алфавита. Еще запомнился такой эпизод. Возвращаясь со школы увидела у порог стоящего нашего почтальона, человека с ампутированной кистью и части предплечья, всегда опрятно одетого, хотя на нем были заплатанные вещи, и направляющегося к нему Галимджана абый, он отдал почтальону сверток, просил не часто приходить с телеграммами, по всей вероятности будет их много: – «Не утруждайте себя, соберите и принесите к вечеру». Телеграммы были с поздравлениями о присвоении ему героя труда. А в свертке врученном почтальону была одежда.

Как-то одна любопытная особа в Казани, во время юбилейных торжеств задала мне такой вопрос: – «А правда ли Г. Ибрагимов был очень ревнив и из-за этого у них часто были ссоры?» «Этот вопрос задайте моей сестре», отпарировала я.

Теперь, когда нет в живых моей сестры, попробую порассуждать на эту тему. Мне кажется, нет ревнивых людей, на свете не существует, это мое личное мнение, никому его не навязываю. Могла ли быть ревность? Да, могла, по следующим причинам. Разница в годах, он старше на 17 лет. Она была женщиной с броской, естественной красотой, не нуждающаяся в косметике, кроме, как она говорила, в рисовании бровей, которым она занималась до последнего дня своей жизни, можно сказать почти автоматически. Он был тяжело болен. Она была очень общительная, веселая, как говорят в народе, с хорошо подвешенным языком. Любой человек проходя мимо бросал взгляд на нее, это естественно – красота притягивает внимание. Ничего зазорного в этом нет.

Как у каждого человека и у нее были недостатки, она была не совсем умелой хозяйкой, домашних дел она старалась избегать, может и потому, что всегда были домашние работницы. Очень рано, будучи гимназисткой, начала курить. Возмущаясь, когда просили мы ее бросить курить, в ответ с юмором говорила, что

это ее единственное удовольствие, когда умру, воткните мне в рот папироску. И все же нашла силу и волю, бросила курить на 8-м десятке лет своей жизни. Она не знала вкус вина, никто не мог ее уговорить попробовать.

Как то вернувшись домой я застала Галимджана абый в передней с грустным, недовольным выражением лица, с вздрагивающей ноздрей, знакомый нам признак его недовольства.

Интуитивно поняв причину, сказала, что Гулесем апа передала, что скоро придет, она на Аутской улице разговаривает с мадам. Пусть поговорит, конечно, приятно немке поговорить на немецком языке. Нервный тик прекратился.

Наверное и у них были какие-то неполадки в жизни, но я никогда не была свидетелем их ссор, раздора, раздражения, объяснений, он был очень сдержанным человеком, не позволял себе выходить за рамки приличия, у его поколения нравственность еще не была потеряна.

Когда, накануне нашего отьезда из Ялты, сестра мне сказала, что мы уезжаем в Самарканд, мне показалось, что этого не может быть. Настал день нашего отъезда, чемоданы уложены, как всегда сидим за столом, завтракаем и вдруг началось землятресение. Наш отъезд задержался до вечера, т.к. был шторм. Обед и ужин были в обычное время. Галимджан абый нас проводил до пристани, проводив меня до каюты он распрощался со мной, сказал, чтобы я всегда оставалась такой какая есть, откровенной, добросовестной, не терпящей лжи, трудолюбивой, справедливой.

Затем с палубы парохода я видела как Галимджан абый и Гулесем апа прохаживали по молу, временами останавливаясь. В этот день я последний раз видела Галимджана абый, это было весной 1932 года.

Разумеется тогда, в свои детские годы, не могла постичь умом того громадного его воздействия на становление моего характера, только повзраслев, сумела оценить как тонко, без назиданий, лишних слов, ведя разговор на равных, щадя мое самолюбие, сумел вложить в меня столь необходимые в жизни уроки справедливости, правды, честности, совести, трудолюбия, ответственности за свои действия, аккуратности, умение слушать собеседника, преодоления жизненных невзгод, стойкости.

Если даже прочитать только один его рассказ – «Любить – это счастье» можно понять каким он обладал талантом, если еще в

молодые годы, так тонко описал самые глубокие, нежные чувства пожилого человека, а рассказ был написан в 1911 году.

Думаю, благодаря только такому воспитанию я обязана возможности устоять, добиться справедливости в 1937 году. Почти перед самыми государственными экзаменами нас студентов повели смотреть в кинотеатр фильм – доклад Сталина о конституции СССР (затем названной Сталинской конституцией). Фильм был звуковой. В те годы почти не было звуковых фильмов. И вот впервые в своей жизни увидела «живого» Сталина, читающего конституцию. Возвращаясь после фильма решила высказать свое удивление по поводу выраженного грузинского акцента. Ведь нам в школе, институте так рьяно, по всей вероятности умело закладывали в нашу память образ нашего вождя, как самого единственного в мире человека без изъяна, знающего абсолютно все, диктующего как нам жить, лучше нас никто так хорошо не жил в мире, только ему мы обязаны всем, даже существованием. Мы в это верили. В результате своего высказывания о его грузинском акценте я не была допущена к сдаче государственных экзаменов. Не хочу описывать и вновь переживать события тех дней. О тех днях много пишут, надо писать, в этом я убеждена. Допустили к сдаче государственных экзаменов только тогда, когда уже сдавали 3-ий экзамен из 5-ти, сдавала по 2 экзамена в день. Радости окончания института не было. Тогда мне шел 21 год.

Сердце сжимается от боли когда вспоминаю о тех последних днях жизни Галимджана абый, со дня ареста его в Ялте 29 сентября 1937 года и помещения в тюремную больницу г. Казани, где он скончался 21 января 1938 года. Какие мысли терзали его душу. Были слухи, что он умирая написал: – «Умираю не виновным, история разберется». Только так он мог сказать. Вряд ли у него была возможность написать в условиях тюрьмы. До сих пор у меня не укладывается в голове, как можно, так потерять человеческий разум, чтобы этапировать из Ялты в Казанскую тюрьму и так обреченного из-за неизлечимой болезни человека. Жизнь его сохранялась только благодаря благодатного воздуха Крыма.

Ностальгическое желание посмотреть еще раз хотя бы на тот дом, где мы когда-то жили, потянуло меня в Казань в 1960 году, вместе со мной проделал это путешествие мой супруг Ф.Ф. Трифонов. Прибыли в Казань в 6 часов утра, не отважились беспокоить людей, к которым нам дали рекомендательное письмо, решили

посидеть во дворе Казанского кремля, подышали ароматом незабываемого запаха резеды, рассуждая о том, что природа иногда одним штрихом наделяет, совсем невзрачное на вид растение удивительными свойствами, сколько благоухания в этом цветке. Мне казалось, что в Душанбе, где тогда я жила, эти цветы не имели такого запаха. Может быть близость Волги, раннее утро, тишина, как будто бы застывшая природа и нахлынувшие воспоминания вместе взятые составили тот чарующий, неописуемый аромат этих цветов.

Купив обратный билет на ночной поезд решили посвятить день посещению музея, посещению дома, ознакомлению с городом, только после этого направиться по рекомендованному нам адресу.

В такой ранний час мы оказались единственными посетителями музея. Вдруг мой супруг мне говорит, посмотри, в том зале висит неоконченный портрет М. Горького. Ответила ему, ты знаешь, что я не люблю спорить, подойди, посмотри, прочитай, это портрет Г. Ибрагимова. Он был поражен такому портретному сходству и долго стоял у портрета. Затем увидев бюст Г. Ибрагимова он мне с таким мальчишеским фальцетом произносит, на сей раз я уже не ошибаюсь, это бюст М. Горького, все это логично, что его бюст здесь в музее, он же жил в Казани. Чтожь, еще раз убедись в своей ошибке. О своих двух ошибках одного дня он часто рассказывал, удивляясь такой портретной схожести двух писателей.

Под проливным дождем мы добрались до Комлева 33 (бывшая Новокомиссариатская). Не говоря о своем огорчении, скажу как был удивлен мой муж тем, что не увидел мемориальной доски, не говоря о доме музее. О Г. Ибрагимове он знал только по моим рассказам.

С этим досадным чувством мы уехали из Казани. Приехав домой мы написали письмо в Казанский Горисполком об этом.

История разобралась, а трагическая потеря одаренного человека невосполнима.

*Г. Ибраһимовның тормыш иптәше Г. Мөхәммәдованың сеңлесе Ләйлә Мөхәммәдова истәлеге Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Г. Ибраһимов фондында саклана (65 ф., 4 тасв. 23 с.б.). Истәлек ике нөсхәдә, машинка басмасында һәм кирилл хәрефләре белән рус телендә язылган кульъязмада. Текст басмага машинка басмасыннан алынды.*

*Г. Алмаев*

## Галимҗан Ибраһимов турында хатирәләр

*(Воспоминания, посвященные памяти писателя Галимджана Ибрагимова)*

Иске Русия хөкүмәте заманында 1905 нче ел революциясенә кадәр яшәб килгән татар халкының мәктәб вә мәдрәсәләре, алардан укыб чыккан татар укучылары.

Бәгъзе бер яшьрәк язучыларыбыз: «Октябрь инкыйлабына кадәр татарларның мәктәбләре ерак иде», – диеб язулары тарихта теркәлгән сүзләр.

Татар халкының мәктәб(мәдрәсә)ләре бар иде. Сан җәһатендән тикшереб караганда, хәтта кирәгендән дә артыграк иде. Авылда ничә мәсҗед берлә – һәр мәсҗед янында мәктәб диеб йөртелгән кечкенә генә тәрәзәле, эченә кергәндә кеше аяк басыб торырлык биеклектә. Үзенә хас сәхнәлеге белән исем алган уенчылар һәр авылда да бар иде. Мәктәб, кайсы – мәсҗед янында булса, шул мәсҗеднең мулласы мәктәбнең хуҗасы хисабланды. Мәктәбкә җыелган балаларның күб-азлыгына карамастан, ялгыз бер урыны укытучылык кылыб, һич бертөрле план-программасыз алыб бара. Гарәб хәрефләре белән язылган төрле калынлыктагы китаблар дәрестлек булыб йөртелә. Шәкертләр кулындагы букчасында (сумкасында) икешәр-өчәр китаб йөртә. Үзен артыграк белүчегә санаса, калынрак китаблар йөртер.

Мәктәбләрнең ачылу-ябылу вакытлары билгелесез. (Авыл халкының кыр эшләре белән бәйле.) Мәктәбне тәмамлаб чыгыр өчен ничә ел уку кирәклеге, 10–12 яшьдән башлаб, гаскәри яшенә кадәр укыб йөрүчеләр һәр мәктәбдә бар.

### *Укыту ысуллары (буква-логистический метод)*

Сүзне аерым хәрефләргә бүлеб укытудан башлана. Мәктәбдә төп максад дин өйрәтү булганлык сәбәбле, бер гарәб хәрефе белән язылган сүзне аерым хәрефләргә бүлеб өйрәтә башлый.

Бер нәрсә белмәгән балага (чөнки Коръән гарәбчә язылган), укый да белмәгән, мәгънәсен аңламаган сүзләрне кырышыб укырга, күнегүдә иҗектән сүзләргә күчү, сүзләрне кушыб укырга өйрәнү укучыларның ике елдан артык гомерләрен ала.

Уку белән язуны бергә бәйләб укытылмаганлыкдан, 5–6 мәктәбдә гомер үткәреб чыгыб китүчеләр дә, күбчелек яза белми, чыгыб китәләр.

### *Иске авыл мәктәбләрендә эчке тәртиб*

Һәр мәктәбдә булмаса да, күбрәк мәктәбләрдә, ахыр гомерендә ялгыз калыб, калган гомерене берәр-берәр мәктәбдә үткәрер өчен урынлашыб алган сукыр суфилар мәктәбнең төб хуҗасы булган хәзрәтнең ярдәмчесе булыб, ике бармак киңлеге каешны уртага ярыб ясалган кыска саблы камчысы белән шәкертләрне тәртибкә чакыра.

Бәйрәм көнләрен, уку булмаган кичәләрдә, лампаны сүндереб: һәр тарафдан кечкенәрәк мендәрләрен бүрекләр белән, суфины бер мәбирак итеб, дустларча гына үч алулары, хәзрәт китеб калса, икенче көн хәзрәт-суфиның каеш камчысы белән файдаланыб, усалрак шәкертләрне ничәр сәгать караңгы идән астында ябыб тота. Зуррак авылларда мәктәб бинасының кечкенә-зурлыгына карамастан, 70–80 укучы җыела, куныб укыйлар.

Пәнҗешәмбе көнләрдә төрле укушлар булмый. Хәзрәт, иртә белән килеб, гадәтдәгечә шәкертләрнең һәр атна кем биреб килә торган сәдакаларыны, дога кылыб, кайтарыб китә. Мәктәб ике көнләб шәкертләр ихтыярында кала.

Һәртөрле уенлар белән мәктәб асты-өскә килеб кала. Хәзрәт дә юк, мәктәбнең сукыр суфисы да бәйрәм итә – камчысыны ял итдерә.

Мәктәбнең сторожы юк. Бу ике көн эчендә асты-өскә килеб калган мәктәбнең ишек, тәрәзәләрен чистарту, идәнләр юыб һавасыны алмаштыру эшләргә җавабкяр кеше юк.

Берәр бәхетсезлеккә очраб калганда әйткән нәзере өчен, я булмаса, саваб өмед итеб, мәктәбдә укый торган баласыны ияртеб килеб, аналардан берәрсе килеб, чистартыб киемен, шул ук бозык һавалы, сасы мәктәбдә янә шинбә көн уку башлана! Әмма мәктәбләрдә уку булган айларда Рамазан ае килеб калса, бөтен ай берничә мәктәбләрдә тормыш башка булыб кала.

### *Иске мәктәб-мәдрәсәләрдә бәйрәм ае*

Рамазанда Коръән иңгән иң хөрмәтле ае. Һәр атна ишек-тәрәзәләр чистартылыб торганлыкдан, мәдрәсәнең һавасына кадәр башкарылыб кала. Хәтта 10–12 яшьлек шәкертләр рузә тотарга мәҗбүр.

*Рамазанның 27 нче көне – Кадер кичәсе – елга бер килә торган кадерле бәйрәм көне.*

Бер кичәдә, бәлки бер сәгатьдә «күк капусы» – күккә юл ачыла да ябылмыш. Шул сәгатькә туры килгән «дога»лар Хода каршында кабул булыб, дога кылучылар максадларына ирешәләр икән.

Авылларда иске мәктәб укытучы мулласы Бохарада укыб кайткан булса, мәдрәсә була.

Шәкертләрнең кадерле бәйрәмләренең берсе – «Бәраәт кичәсе» көне. Бу кичәдә нәкъ сәхәр вакытында шундый сәгать була икән: йир астындан мөлдерәб чыгыб торган агым чишмәләрдә сад[1] корыб бетеб тора да, янәдән ага башлавында «оҗмах»тагы «Кәүсәр елгасы» суына аралашыб: «Зәмзәм»гә әверелгән була икән. Шул сәгатькә туры килергә тырышыб, «Зәмзәм» суы алыб кайтыр өчен авыл бездән ике километр ераклыгында тау астындан мөлдерәб чыгыб, агыб торган чишмәдән «Зәмзәм» суы алыб кайтырга баруларыбыз бер көндә һәм әле хәтеремдә.

1898 нче еллар кыш көне, гыйнварь ае, төнге сәгать 12-ләрдән соң. Рамазан ае, сәхәр вакытлары иде. Без барыб җиткәндә авылыбызның бер карт мулласы, башында зур чалма муенына кәҗә мамыгындан бәйләнгән җылы шарф уралган, янында берничә иярченләре дә бар. Үзен, яшел таягына таяныб, чишмәнең суы корыганын көтеб торалар иде. Без һәм әле кичегеб калмаган идек, чөнки җирдән чыгыб торган чишмәдән җиңел генә күтәрелеб торган бар чишмәнең мөлдерәб агыб торулары кышкы ак карны ялтыраеб торган – тулган ай яктысында ачык күренеб тора иде.

Өс-башыбыз нечкә: беребезнең аягында пимасы да ерык чабата гына булганлыкдан, чишмәнең суыны корыб калганны озак керә алмадык. Нинди «Зәмзәм» булгандыр инде? Кулларыбыздагы шешәләргә табигый чишмә суын тутырыб кайтыб киттек. Мулла бабайлар чишмәнең «Кәүсәр елгасы» белән аралашыб кайткан сәгатьне көтеб калдылар.

### *«Бәраәт кичәсе»*

Олыграк шәкертләрнең дәрес укудан башка бәгъзе бер мәшгулиятләрдән:

– Мәктәбдә 6–7 ел гомер үткәреб гаскәри яшенә җитеб калган олыграк шәкертләрнең бәгъзе берсе күбрәк язу эшләре белән генә вакыт үткәреб, китаблардан төрле догалыклар күчереб алыб, күкрәксәләрендә саклаб йөртерләр. Аларны тәһарәтханәләргә кергәндә яман исләр үтеб кадерсезләндермәс өчен эретелгән балавызга батырыб алынган ак йон чүпрәкләргә ураб йөртүләр белән гомер үткәрәләр.

---

[1] Сад (диалект. мишәрчә) – үсемлекләр.

– Бәгъзеләре «түгәрәк Ясин шәриф» язганлар: үз куллары белән агачтан фәргаб (циркуль)лар ясаб, табак кәгазь өстенә түгәрәк, даирә (окружность) сызыб, даирә эченә берничә Коръәндән күчереб, бөтен «Ясин» сүрәсене языб, урталыкда калган буш урынны кисеб ташлагач, түгәрәк була.

– Баласыны тудырган хатынларга ярдәмче булыб йөргән ирләр гадәтдә муллага 2–3 тиен сәдака бирәләр – «түгәрәк Ясингә». 3 тиендән дә ким бирмиләр. Бәгъзе берсе әле 5 тиен өстенә бер күләме дә өсти.

– Бала тугач, шул түгәрәкдән, «Ясин»дән үткәрәләр.

1905 нче ел революциясенә кадәрге заманда авыл мәктәбләре белән шәһәр мәктәбләре арасында һичбер төрле аерымлык юк иде. Укыту ысуллары, программасызлык, идәнгә тезләндереб утыртканда дәреслек итеб бер китаб тотдырганлар. Укытучы мулла Бохарадан укыб кайткан булса, шул ук мәктәбне: мәдрәсә диеб атаган да.

Иске Русия хөкүмәте татар мәктәб-(мәдрәсә)ләрне бар диеб дә белмәгән, хәтта санларны да хисабка алмаса да. Татарлардан җыелган налог-салым […] татар авылларында йомшак телле, үткен, хәйләле, кара максадлы ...? йөзләгән миссионерларын йөрткән, яшәткән, хисабка алганлар.

1905 нче ел революциясе татарларда ысулы җәдид мәсьәләсене китереб чыгара (яңа ысул белән эшләш).

Җәдидчелек, кадимчелек көрәше 10 елдан артык дәвам итә.

Казанда Галимҗан хәзрәт башлаб җәдидчелекне үз мәдрәсәсендә гамәлгә куйса да, кадимче-кара... Казан губернаторына «Новые методисты: суть партии сатаны» дигән эчтәлекле доносларын яздырыб, аны Казандан ике елга сөрдерү «шәрафатенә» ирен алсалар да, ике елдан соң кайтыб, мәдрәсә Мөхәммәдияне тәрәккъкый иттерүне дәвам итдерә башлый.

Бер мәдрәсә Рөшди, Игъдади, Галия исемләре белән, өчкә бүленеб, татарларның 10-еллык дини, гали мәдрәсәсе булыб чыга. Һәммә фәнләр укытыла башлый. Дини мәдрәсә хисабланса да, рус теле һәм программага кертелеб укыла торган була. Ләкин төб максад гарәб телен өйрәнү тотыла, чөнки Коръән гарәбчә телдә язылган.

Гарәб теле яңа ысулда өйрәтелә башлаб, махсус дәреслек хәзерләнә. Галимҗан Ибраһимов, Әхмәтҗан Мостафа, Рифгать Бикбулатларның саф татар телендә язылган «Гарәб теленең сарыф

нәхү»ләре гарәб телене өйрәнүчеләргә иң зур ярдәмче диеб хисабланыб, мәдрәсәгә дәреслек итеб алыналар.

1905 нче ел революциясе рухында булган татар шәкертләре арасындагы кузгалышлар 1905–06 нчы еллар эчендә дәвам итә. Шул чорларда татар шәкертләренә махсус «әл-Ислах» газетасы чыгарыла башлый. Бер газета үзенең «Уяныгыз, бөтен татар шәкертләре!» лозынгысы астында иске мәдрәсәләрдә мөдәррис-муллаларга каршы – шәкертләрне аякка бастыра, уята. Вәли мулла мәдрәсә кеби иске мәдрәсәләрдә Г. Ибраһимов шикелле зирәк, үткен фикерле шәкертләр ташлаб чыгыб китәләр, тупас, аңсыз шәкертләр генә кала.

«Ислах» газетасы битләрендә иске мәдрәсәләрне ташлаб чыккан шәкертләрнең:

Бик күб ятдык мәдрәсәдә,
Ала алмадык бернәрсә дә.
Йөрдек без гыйлем эзләб,
Акча тузды ничә йөзләб –

дигән кеби садәләре яңгырады, яңалык авазлары күтәрелде. 1905 нче елда татар шәкертләре арасында булган кузгалышлар нәтиҗәсендә вөҗүдкә килгән: «Мөхәммәдия Чистайда, Уфада Галия кеби яңа мәдрәсәләрне татарларның иске мәдрәсәләре» диеб, барысын да бер сүз астына алыб йөртергә туры килми. Оренбург шәһәрендә Вәли муллага охшаган бәгъзе бер муллалар иске Бохарадан алыб кайткан искелекләрене, «галимлек таратабыз» диеб, хәтта 1905 нче ел революция соңында да үз мәдрәсәләрендә дәвам итдерделәр. Татарларның чын иске мәдрәсәләре шулдыр санала.

Эчке Русия татарларның мәктәб-мәдрәсәләренә тарихы бер көн салганда: һәр җәһәтдән искелекне саклаб тотыб, шөһрәт табкан бөтен яңалыкларга каршы килүче, ахыр гомеренәчә искелекне яклауга «ант» биргән Оренбург шәһәрендәге Вәли хәзрәт мәдрәсәне үрнәк итеб алышка мөмкин:

Татарларның бер мәдрәсәсе Оренбург шәһәренең мәркәз урамларындан саналган Су урамы белән Татарский переулок чатында 77 номерлы Вакыйф йортка урнашкан. Таш йорты урам ягындан кергәндә таш устинаны чыгыб, гарәбчә шул сүзләр язылган:

«Кәйфият теле вакфы мәхфузын фи әс-су. Дини палата. 1872 сәна. (вакф шартлары губерна архифда саклана дигән сүз).

Бер йортны бер көндә һәм башланган бер хәлдә күреш мөмкин.

Иске татар мәдрәсә-мәктәбләренә үрнәк итеб алынган бер мәдрәсә бер гасырга якын дәверендә ничә сукыр суфилар асрамагында вә ничә дәрвишләр җитештермәгәнме? – дисез.

Бер мәдрәсәнең эчке күренеше, тәртиб, низам, дәрес хәзерләү ысулы, дәреслекләре: ишектән керүгә бозык һавалы, ярым караңгы зур залны 4–5-шәр шәкерт безгә урындаш булыб, чаршаулар корыб бүлеб алганлар да, ярым метр биеклекдәге тәбәнәк өстәл тирәсенә тезләнеб утырганлар да, дәрес укыйлар. Өстәлләрендә ничә еллардан бирле җыйналыб килгән калын-калын, ярым фарсы, ярым гарәби иске китаблары, дәреслекләре моталәга өчен[1] һәм «Бәдавәм», «Ахыр заман», «Сөбател-гаҗизин» кеби яшьрәк вакытларында укылган дәреслекләре. Икенче бер чаршау астында башкачарак күренеш: мәдрәсәдә ничә еллар ятыб, кесәсендә генә саклаб йөрткән, кечкенә генә көзгегә караб, мыек-сакалыны төзәтеб торган указсыз мулла. Үзләре гарәбчә белмәсәләр дә, Коръән гарәбчә язылган бит! Калын итеб тышланган «Коръән тәфсире» (Казан басмасы, татарча язылган). Гарәбчә «Кырык хәдис» кеби дини китаблар өстәлгә тау итеб өелгән дә, алар өстенә койрыгыны салындырыб, чалмасыны куйган да, яланбаш калыб: «*Калән нәби* – әйтде пәйгамбәр... бәхәс, мөназәрә...».

Һәр чаршау астында үзенә хас бер тулы дәрес хәзерләү бара. Кайсыбер чаршау эчендә «Бәдавәм»дән дәрес хәзерлиләр:

*Һәр исерек – Тәңре дошманы,*
*Дошман бел һәм син аны.*
*Җәһәннәмдер мәканы,*
*Аллаһы дигел һәрдәвам.*
*Ябылмаса әсир.*

«Заман»[2] китабындан:

*Ахыр заман якын килсә, нәләр булганы,*
*Дөньяга төрле-төрле бәла туган.*
*Күб галимләр хәмер эчеб, зина кылган,*
*Андан артык дәхи гаҗәб хәлләре бар.*

«Сөбател гаҗизин» китабындан:
(Дәресләр башка көндә)

*Йирнең бардыр үгезе,*
*Үгезенең бар мөгезе.*

---

[1] Моталәга өчен – уку өчен.
[2] *«Заман» – «Ахыр заман» китабы турында сүз бара.*

*Кодрәт белән күтәреб тора*
*Бөтен йирне берүзе –*

дигән кеби кызганыч тавышлар белән.

Дәресләр хәзерләүләр намаз вакыты килкәнче дәвам итеб, намаз вакыты җиткәч: чалмаларның койрыгыны салындырыб кыр казлары сыман очыб мәсҗедгә ага башлар.

Шәкертләр төрле район, бәгъзе башка шәһәрләрдән килеб, кырыныб укысалар да, аерым ятакханә (спальня)лар булмаганлыкдан, чаршаулар белән корыб алынган бозык һавалы бүлмәләрендә һәм урын йирләре, кием-салымлары, ашу-эчүләре – барысы да шунда. Өстендәге йиргә кадәр салыныб торган кара җиләне, елында бер кәррә юыла торган каралыб беткән ак чалмасы, үзенең саргаеб торган йөзләре белән, кая барса да – башкалардан аерым аерым күренеб тора да...

Искелек каһарманы – Вәли хәзрәтнең «Дин вә мәгыйшәт» журналы моны яклый. «Дин вә мәгыйшәт» 1919 нчы ел Мәскәвада булыб үткән. Бөтен Русия татарларының съездында иске мәктәб-мәдрәсәләре хакындагы карарларына каршы чыгыб: «Коръәнгә хыйляф карарлар» мәкаләсене языб, Оренбург татарлары арасында.... ике-өч көн дәвам иткән. 200гә якын җыелыб торган татар халкы митингга «Вакыт» газетасы мөхәррире Ф.К.не[1] – халык каршы чыгыб йиргә бастырмыйча, куллар өстенә күтәреб алыб, хөрмәт белән китереб ултырталар.

### ***Бу хәлләргә кем гаебле?***

Татарларның иске мәдрәсәләрене гасырларга сөрәб китерүләренә, яки татарлар бер-берсе өстендән губернаторга донослар язучылар, кемләр икән, дисезме җавабкяр? Әллә гуманист шагыйрьләребезнең татар байларына каратыб язылган:

*Алыр гына шәйтан иманыңны,*
*Җәһәннәмлек диеб кайкырмасын. –*

дигән шагыйрьләр хаклы дисезме? – Юк.

Татар – тырыш халык, дустлыкны сөюче, тәрәкъкыйга омтылучы халык. Иске Русия пашасы тарих битләрендә үзенә «Грозный» исемен алган. Иван IV заманында татарлар төрле якларга таркалышыб калган булсалар да, саф үз көчләр, үз тырышлыклары белән нинди мәдрәсәләр асраб килмәгәндер. Иске Русия хөкүмә-

---

[1] *Ф.К. – Фатыйх Кәрими турында сүз бара.*

те татарларның укыш йортларына ярдәм бирү түгел, аларны бар диеб дә белмәгән, хисабка алмаган. Әмма үзенең йомшак телле, тирән хәйләле, кара максадлы булган миссионерларыны татар мәдрәсәләре өстендән контрольлык оештырган.

Татарларның саф үз көчләр: зәкят байлардан 40 %. Гушыр авыл халкындан 10 % фитыр сәдакалары кеби, ихтыяри-дини салымлар белән яшәб килгән мәдрәсәләре кеби, үзләре юкка чыккан булсалар да, биналары: Оренбург шәһәрендә Хөсәения мәдрәсәсендә партийный техникум, Казанда ничә корпуслардан гыйбарәт дүрт катлы мәдрәсәи Мөхәммәдия, югары баскыч һөнәр мәктәбләре урынлашыб, татарларның иске мәдрәсә биналары бу көндә гыйлемлеккә хезмәт итәләр.

II

Октябрь инкыйлабы Русия татарларына һәм яңа дөньяда бәхетле тормыш тудырды. Олугъ инкыйлаб үз хөлемне (хыялны. – *А.Х.*) йөртеб, кадими-иске татар мәктәб-мәдрәсәләрене юкка чыгарыб ташлады. Иске Русия хөкүмәте кул астында гасырларча хокуксызлыкдан изелеб килгән татар халкына Октябрь революциясе һәммә җәһәтдән дә тигез хокук биреб, Советлар хөкүмәте татарларның уку-укыту кеби мәдәни эшләрне үз даирәсенә алыб, сәдакага яшәб килгән мәктәб вә мөгаллимләрене хөкүмәт хисабына кертеб, йомышларыны тәэмин итде.

Язучылар арасында үзенең сәяси дә иҗтимагый эшләре белән танылган Г. Ибраһимов инициативасы белән Татарстанның мәркәз шәһәре Казанда: татарлар өчен «Академия наук» ачылыб, Галимҗан Ибраһимов рәислегендә дәвам итә башлый.

1905–08 нче елларда дәвам иткән татар шәкертләре арасында булыб үткән кузгалышлар нәтиҗәсендә вөҗүдкә килгән киң программалы яңа ысул белән төрле фәнләр укытылган – Казанда «Мөхәммәдия», Оренбургда «Хөсәения», Уфада «Галия» кеби татарларның яңа мәдрәсәләрене тәмамлаб, тормышның агымы белән төрле якларга таркалышыб калган татар укымышлары (гарәб теле осталары) Казанга тартылыб, әдәби хезмәтләрене дәвам итәрләр.

Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал һәм башкалар үзләренең иҗтимагый вә сәяси рухта язылган әсәрләре белән танылыб, татар әдәбияты классик язучылары исемне алган. Татар укымышлары ярым гомерләрене бәбкәләр чыгарырга, утырткан сасы каз оясыны хәтерләткән, бозык һавалы мәдрәсәләрдә

үткәреб, калган гомерләрендә ниләр эшләмәделәр дә, ниләр күрмәделәр ахыр гомерләрене вакытсыз каршылаб?

Үзләренең ничәшәр җилддә язылган әсәрләрендә көндән-көн тәрәккъкый итеб торган яшь буынга, яшь язучыларга тарихи, кыйммәтле материал калдырыб әдәби мизанларын калганларга һидаять итеб китделәр.

Үзләренең үткән заманларын тасвирлаб, мәдрәсәләрдә үткән хәлләрен, шәкертләр тормышын берәр бай үлгәч, кышның 35–40 дәрәҗә салкынлыгына карамастан, берәр байның җеназасыны күтәреб алыб барышка чакырыб килгән хәбәрне шадланыб каршылауларыны, мөгаллим-хәлифәләрнең дөньяга карашларыны тасвирлаб язылган:

*Коммунизм – нәрсә? Коммунист – кем?*
*Нишләсен соң аңлаб йитмәсә*
*Хәлифә абзый юклы дини таришкәндә*
*Бирсәң кәнфит, ашар иде шырланыб.*

Сүз белән шәкертләр дөньясын, мәдрәсә хәятен күз алдына китереб бастыра торган әдәби тәнкыйд материалларындан файдаланыб язылган романларыны укыб, кыска гомерләрене тыныч үткәрә алмаган? Классик язучылар, азсанлы татар әдибләрене хәтерләб искә алучылар кемләр булыр микән? Шөбһәләнергә әсас юк. Үтәр еллар, еллар, тагын да еллар үтәрләр дә, инсаният дөньясы, дустлык, коммунизм исемендән үзенең тарихи сәламләрен йибәрер.

Үткән гомерләрнең төб нөсхәсе архивларда саклана.

Учитель, пенсионер 1885 года рождения Алмаев Г.
Очевидец, участник митинга, проходившего в г. Оренбурге
в 1918–19 годах в Караван-Сарае. 15 августа.

*Истәлек авторы турында төгәл мәгълүматлар юк, язмадан аның Оренбург шәһәрендәге «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем алуын, замандашы Г. Ибраһимов кебек үк, мәдрәсә тәртипләре, андагы укыту алымнарына каршы булып, яңалык тарафдары икәнен әйтә алабыз. Истәлекнең кульязмасы Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә, Г. Ибраһимов фондында саклана (65 ф., 4 тасв., 1 с.б.). Гарәп хәрефләре белән татар телендә язылган. Текст басмага кульязмадан алынды.*

*Текстны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге*
*өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты*
*Алсу Хасавнех әзерләде*

# ӘДИП ТУРЫНДА ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТ (1910–1930)

Г. Ибраһимов – зур әдәби һәм гыйльми мирас хәзинәсе калдырган күренекле шәхесебез. Әдипнең әсәрләре аерым китап булып басылып чыга башлагач ук (1909), аның хезмәтләренә әдәби тәнкыйть игътибар итә һәм вакытлы матбугатта беренче рецензияләр, бәяләмәләр күренә башлый (1910). Ә иҗатын системалы рәвештә өйрәнүгә керешү 1920–30 еллардан башлана. Бу вакытта инде ул халык ихтирамын яулаган, тарихта мәңгегә калырлык, җуелмаслык әсәрләре белән танылган язучы, җәмәгать эшлеклесе, гомумән, билгеле шәхес. Матбугатта да аның хакында, иҗат казанышлары турында, теге яки бу мәсьәлә буенча тоткан позициясе, карашларына, тәкъдим ителгән әсәрләренә укучы бәясен-мөнәсәбәтен чагылдырган күп мәкаләләр дөнья күрә. 1928 елда язучының 20 еллык иҗат юбилее тантаналы рәвештә билгеләп үтелә һәм бу уңайдан аның әдәби, гыйльми, һәм иҗтимагый эшчәнлеген яктырткан, хезмәтләренә фәнни-тәнкыйди анализ ясау тәҗрибәсе булган язмалар аеруча күп басыла. Аларның беришеләре шул елда Казанда, Ташкентта әдипнең 20 еллык хезмәт бәйрәменә багышлап чыгарылган җыентыкларда урын алган. Соңрак, әсәрләре рус, казакъ, башкорт һ.б. телләргә дә тәрҗемә ителә башлагач, инде алар хакында матбугат битләрендә чагыштырма характерда фәнни анализ ясалган язмалар да күренә башлый. Җыентыкта шул еллар вакытлы матбугатында басылып чыккан гарәп графикасындагы мәкаләләрнең бер өлеше гамәлдәге язуга күчерелеп, текстологик яктан эшкәртелеп тәкъдим ителә.

*Тупый*

## Яңа әсәрләр. Татар хатыныниләр күрми

Матбугат галәмебезгә чыккан бер әсәрне моталәга итеп[1] баручылар, соңгы көннәрдә матбугатыбызны тутырган бер такым[2] тормышыбызга һичбер җәһәттән тәгъликъ булмаган[3]

---

[1] Моталәга итеп – укып.

[2] Такым – төркем.

[3] Тәгъликъ булмаган – аңланмаган, аңлашылмый торган.

муаффәкыятьсез[1] тәрҗемәләр белән əһәмиятсез, гайре мөтәнаһи[2] дәрес китаплары күреп шаять туйган булырлар инде.

Әмма бу күптән түгел генә Эстәрлетамактагы «Каләм» китапханәсе тарафыннан нәшер ителгән «Татар хатыны ниләр күрми» рисаләсе ул күрелеп туелган китаплар җөмләсеннән түгел, бәлки укыган саен укыйсы килә торган, чат үз тормышыбыздан алынган милли хикәядер. Рисалә бер-ике әдәби әсәре вә «Йолдыз»дагы гүзәл мәкаләләре белән мәгълүм булган Галимҗан Ибраһимов әсәре булып, Эстәрле өязендә булган бер вакыйгага карап язылмыштыр. Кыска мөндәриҗәсе исә моннан гыйбарәт: Гөлбану исемле бер авыл кызы, аталары тарафыннан көчләнеп, бер бик кара, чуаш кеби тора торган, авыл баеның тәүфыйксыз малаена бирелә. Гөлбануның элек вәгъдә кылышкан егете булганга киявен һич яратмый. Моның өстенә кайнанасының гаять холыксыз вә залимә булуы, иренең исереп тиргәве вә кыйнавы аны тәмам изә. Бервакыт аның кайнатасы да вафат булып, малайлары үзара талашып-сугышып аерылышалар. Соңыннан тәмам фәкыйрьләнеп, Гөлбану ашарларына икмәк, ягарга утын тапмый торган ярлы бер мужикның хатыны булып кала. Бер көн ире эчеп кайтып бик нык кыйнагач, качып китәргә мәҗбүр була…

Аны бер кеше Троицкий өязендә бер карт башкортка хатынлыкка бирә. Ул анда да тыныч тора алмаса да, карты үлгәнче сабыр итә. Карты үлгәч аның энесенә бирәләр. Гөлбану моннан бик хурланып тагын аннан качарга мәҗбүр була. Ләкин бу вакытта үзен изгән, бөтен хөрриятен бетергән, хатын-кыз галәменнән чыкмакчы булып, ирләр кыяфәтенә керә. Үзенә Габдулла дип исем бирә. Һәм шул кыяфәтендә төрле йирләргә барып, әллә нинди егетләр белән катышып, ирләр хезмәте итә башлый. Ул бу хакта төрле фидакярлекне илтизам итеп[3], үзенең кемлеген һич белдерми. Соңыннан үзләренең авылларына якын бер авылның баена хезмәтче вә приказчик булып – шунда хезмәт итә. Бае үлгәч, кызын аңа ярәшәләр. Шул вакытта ул, өченче мәртәбә качып киткәндә, үзләренең өйләренә керергә тугры килеп, шундагы хатыннар тарафыннан кем икәнлеге мәйданга чыгарыла…

Рисаләдә татар кызларының бөтен хокуклары, фикерләре, уйлары, шөгыльләре, уеннары нәкъ тормыштагыча күрсәтелгән.

[1] Муаффәкыятьсез – уңышсыз, кирәксез.
[2] Гайре мөтәнаһи – чиксез күп, бик күп.
[3] Илтизам итеп – үз өстенә алып.

Бәгъзе йирләрен гаять шагыйранә вә матур сурәтләп, бәгъзеләрен исә күздән яшьләр агарлык кызганычлы тасвир итәрәк мөхәррир үзенең мәһарәтен күрсәткән. Хосусан, Гөлбануның башкалардан качып китеп чәчләрен кискән вакытындагы тәрәддед вә изтыйраблары[1], кайчыны кулына алгач кисмәскә тырышуы, ниһаять татар тормышының хатыннарга кылган җәбер вә золымнарның аннан бөтен ихтыярны алып, ирләр кыяфәтенә керергә мәҗбүр итүе бик кызганычлыдыр. Бу рисаләнең ошбу яхшылыклары өстенә бик зур кимчелекләре дә бардыр ки: авылда кычкырып укыганда йөзгә кызыллык китерерлек сүзләрнең күплегедер. Мәсәлән, 90 нчы битенең иң ахыргы юлындагы сүзләр русча булса да, мәгънә һәр татарга бик ачык булганга ничек тә мондый китапка кермәскә тиешледер. Моннан башка да әдәпкә хилафрак байтак сүзләр бар. Мөхәррир әфәнде башка әсәрләрен мондый сүзләрдән азат итсә иде. Китапта матбага хаталары да күп.

*Мәкалә Тупый тәхәллүсе белән 1910 елда «Йолдыз» газетасының 18 ноябрь (№ 612) санында басылып чыккан. Авторның чын исеме әлегә билгесез кала.*

*Г. Газиз*

## Яшь әдәбиятыбызда «Яшь йөрәкләр»

*(Тәнкыйть)*

Яшь әдәбиятыбыз чыкты; табигый, шигърияттнең ерактагы яктысы белән җылынган тәнкыйтьчеләр дә туды. Бер дә шиксез мин матур әдәбиятны тәнкыйтькә аты булмаган адәмнәрнең ат чабышына карап хозурлануы, бер кешенең атыны мактау, башка берсенекен яманлау төслерәк бер нәрсә дип карыйм. Тәнкыйтьчедә шигърият булмаса, әдәбиятны яратмаса аны ул ничек тәнкыйть итсен? Ул да шагыйрьнең еллларча, бәлки төннәр йокламый каһармани хозурлану белән хозурланып, каһармани кәефсезләнү белән кайгырып язган әсәрен укып чыга да шагыйрьнең уты белән кабына вә каләменә сарыла; шагыйрьнең әсәрен яратканга шагыйрьнең киләчәк әсәрләренә бер файдасы тияр уе белән язарга тотына. Шагыйрьне сүгә, аны мактый... Менә шуңа күрә дә тәнкыйть, һәрвакытта дип әйтерлек «шәхси» булып чыгадыр. Тәнкыйтьче никадәр әсәргә суык кан белән карарга тырышсын, һаман да аның

[1] Тәрәддед вә изтыйраблары – икеләнүләре һәм дулкынлану, борчылулары.

язган сәхифә сәтырлары арасында әллә никадәр «үзенчә аңлаулар», үзенчә мөхакәмәләр килеп чыгадыр. Чынлап та бит ул шулай. Мин бер рәссамның әсәренә карадым да, бер төрле әсәр алдым. Әмма рәссам аны, бәлки, башка төрле нәрсә уйлап язгандыр. Шуның кебек, бер сүз белән яза алган рәсемнәрне әдәбиятта да күрә һәм шулай аңлый алабыз...

Мин бер каһарманның сүзен мөхәррир фикере дип аңлау ихтималым бар, аны бәлки мөхәррир уйламый да торгандыр. Бәлки ул каһарманның фикерен мөхәррир яратмый да торгандыр, ләкин укучының анда эше юк. Тәнкыйтьче дә укучының берсе булганга, аның да катышы юк. Ул әсәрне ничек аңлый – шулай яза, шулай хөкем итә...

Менә шундый бер тәнкыйтьче, дөресрәге укучы, Галимҗан әфәнденең «Яшь йөрәкләр»е турында бер нәрсә язарга керешә. Кешеләргә мәгълүм булган шәхсияттән [әсәрне үзенчә аңлау]дан чыгам дип, ул дәгъва итмәсә дә, ничек тә салкын кан белән күзен ачыбрак карарга ул вәгъдә итә!

Олуг мөхәрриребез Гаяз әфәнденең бөек романы «Мелла бабай»ның беренче кыйсме чыгу белән бергә дип әйтерлек Галимҗан әфәнденең «Яшь йөрәкләр» исемендә зур, 300 сәхифәдән артык, бер әсәре – романы басылып чыкты. Галимҗан әфәнденең бер әсәренең берьюлы басылып чыгуының киң катлам укучыларга читен булганлыгын әйтеп китмичә хәл юк. Вакыйган, бер сумнан да артык биреп укуы хәзерге укучыларга шактый гына авыр эштер. Әгәр китап бүленеп чыкса, бәлки, укучылар өчен җиңел дә булган булыр иде. Бу тышкы мәсьәлә. Безнең өчен дә әһәмиятсез мәсьәлә.

Хикәя, бик гади хикәяләр кеби генә, кысалы (рамкалы). Мулла угылларын укыта. Угыллары ул әйткәнчә булмыйлар; бер угылы бер морза кызына гашыйк була; морадына ирешә алмый. Икенчесе, олуг угылы, бик яхшы «мужик» булып «алпавыт» булырга тырышып гомер итә. Романның тасвир ителә торган сыйныф түгәрәге мулла, морза, бик аз гына мужик крәстиян сыйныфы. Шунысы тәәссеф ителергә тиешле[1]; безнең әдәбиятымызда, нишләптер, чын-чынлап милләтемезнең икътисадын алып баручы урта сыйныф халык тасвир ителми, ителсәләр дә, Фатыйх әфәнденең «Яшьләр»ен вә Гаяз әфәнденең бәгъзе бер әсәрләрен истисна иткәндә[2],

[1] Шунысы тәәссеф ителергә тиешле – шунысы өчен борчылырга кирәк.

[2] Истисна иткәндә – аерып алганда, чыгарма ясаганда.

дөрес тасвир кылынмыйлар. Мин моны мөхәррирләребезнең һәммәсенең дә рухани кеше балалары булганлыгыннан, урта сыйныфның хәлен аз белгәннән түгел микән диясем килә. Морзаларны тасвир иткәндә дә бик зәгыйфь тасвир итәләр. «Морзалык»ның уртасы булган Уфада тәрбия алган Галимҗан әфәнденең дә бу әсәрендә морзаларны ачык тасвир итә алмаганы күренә. Вакыйган, Гәрәй морза гаиләсе тугрысында никадәр тел белән «мужиктан, мелладан» аерма барлыгы әйтелсә дә, бер дә торуда (яшәү рәвешендә), гадәттә, диндә мин артык аерма күрә алмадым. Фәхринең «морзалыгы» морзага бик охшаса да, кигән бүреге берлә охшамый; минем белүемчә, морза җәмәгате татар киемендә булса да башына шапка, эшләпә кия ул. Әүвәлрәк Уфада өстенә тула чикмән, башына картуз кигән морзалар шактый очрыйлар иде; бу карап торуга мөһим булмаса да, тасвирны тәэсирле кылу өчен мөһимдер. Әсәрнең теленә килсәк, гадәттәгечә, Галимҗан әфәнденең теле кеби матур, ләкин бәгъзе урында фигылен[1] алдан фагыйлен[2] ахырдан әйтүләр [буладыр вакытлар кеби] кызык кеби тоела, ят кеби сизелә. Бу форма сөйләү вә җырларда [үтәдер көннәр... кеби] килешсә һәм халык җырларында да булса да, нәсердә килешеп үк бетми бугай. Өслүб тантаналы, әмма ямьсез дияр хәл юк; ләкин бәгъзе артык «шәплек», килешмәгән җирләрдә мондый өслүб истигъмаль итү[3] XV нче Луи заманындагы француз ялган классикларының өслүбен искә төшерә, тоссызланып та куя. Ләкин бу өслүб әсәрнең бөтенләй тойгыга бирелгән, романтизмга буялган рухына килешеп тә куя. Бу рухта язылган әсәргә бары бер, тантаналы, җылы, кызса котлы кыза, котыра, шәбәя торган эслүб кенә килешәдер. Романтизмга буялган дидем. Әйе, мин бу сүзне исбат итәргә дә әзер. Әгәр укучы әсәрнең халык музыкасына артык әһәмият биргәнен [«Яшь шагыйрь» авызыннан һәм Зыя авызыннан әйтәдер] яисә соңгача әллә нинди зур, хыялый, әфләтуни бер мәгънә биргәнен хәтеремездән чыгармасак, каһарманнардан Сабирдан башкасының фикере белән тормыш арасында әллә нинди бер упкын очраганын күрсәк дәгъвамны дөрест дип әйтерләр, дип уйлыйм. Минем бу сүздән романтизмга бирелгәне өчен мөхәррирне сүккәнем аңлашылмасын! Юк, мин хәзерге реалист булып газаплануны үзен ялган реализм дияр

[1] Фигылен – фигыль (эш, хәрәкәтне белдерүче сүз төркеме). Биредә җөмлә кисәге – хәбәр күз алдында тотыла.

[2] Фагыйлен – иясен.

[3] Өслүб истигъмаль итү – стиль куллану.

идем. Чөнки хәзер безнең милли хисемез куәтләнгән, милли музыка, халык җыры вә музыкасына әһәмият биргән, үзебезнең үткән көннәребезне артыбызга борылып карый башлаган бер заманыбыз – бездә ник романтизм булмасын? Гаребтә, мәсәлән, вә Германиядә дә шундый бер заманда булган иде бит! Шуңа күрә мин безнең романнарыбызның күбесендә очрый торган, бигрәк тә Галимҗан әфәнденең әсәрләрендә табыла торган, чын, яхшы яклары белән булган романтизмны чын тарихи бер вакыйга, шулай кирәк иде, шунсыз чарасыз иде, дип ышанам!

«Яшь йөрәкләр»не Ибраһимовның башка әсәрләре белән чагыштырып карасак, әсәрнең ахырын «Яшьләр хәятеннән бер ләүхә»нең башкачарак язылганы диярга ярый. Ләкин аның белән моны чагыштырганда шагыйранә язылган тасвирларга очрыйбыз. Типларның шактый муаффәкыятьле булуларын күрәмез, шуның өчен шагыйрьнең истигъдадының[1] куәтләнүе белән хөкем итә алабыз. Ләкин бу матур тасвирлар, кызык вакыйгаларны, арадагы сузылып, киңәйтелеп җибәрелеп язылган урыннары укучыны ардыралар; романның вакыйгалары берсе артыннан берсе ерак булмый, кирәк вакытта хәрәкәтләрне биреп, тасвирларны куертып, лирикага бирелгән сәтырларны урынында үлчәп кенә тагып җибәрсәң укырга күңелле була, әмма монда күп урында билгакес[2] күренә. Артык төчелек, мөхәррирнең үзенең хәттән тыш тойгылы формада язуы, укучыларны ялыктыра!

Ибраһимовның бу әсәрендәге тасвирлары эчендә иң муаффәкыятьле чыккан бәгъзе урыннарда рухның дулкынын, буранын яисә ялтыравыклы күл өсте кеби тын булган заманын күрсәтә торганыдыр. Андый тасвирлар бу әсәр эчендә күп. Шуңа күрә дә урыннарын күрсәтүне артык табам.

## II

Әсәрдә нинди типлар бар? Аларны без инде сыйныф җәһәтеннән бер әйткән дә идек бугай: алар крәстиян, мулла, морза. Әмма рухани җәһәттән алар менә нindiләргә бүленәләр: романның уртасында тора торган каһарман – Зыя. Бу – романның зәгыйфь, хатыннар табигатьле «мәңгелек трагедия әһеле», үз юлында эшлекле, шагыйранә табигатьле, музыка тилесе бер Зыядыр. Зыя

---

[1] Истигъдадының – сәләтенең, талантының.

[2] Билгакес – киресенчә.

«Урталык» җимеше: ул 1905 елларның буранлы инкыйлаблары арасыннан чыккан адәм. Ул еллар аны инкыйлабчы итеп ясамыйча, матурлык сөюче, «музыка тилесе» ясаганнар, аңар матурлык, коры матурлык кына түгел, гыйшкы милләт вә табигать белән бергә манчылган [хәтта динне дә бергә куярга кирәк] рухи бер матурлык кадерле. Ул Госманга менә нәрсә әйтә:

– Мин иптәш, мин хәзер ук халыкның «җүләр хатын» дип йөртелгән Гайшәсен аңлыйм инде, – ди. Чөнки аның [Гайшәнең] гыйшкы белән музыкасы бергә бәйләнгән иде.

Мөхәррирнең язуына караганда, алар икесе дә бергә моңланалар иде. Зыя кәмитче русның татар көйләрен уйнавын яратмый, чөнки аның музыкасы «тәэсир бирә алмый». Ул табигый татар музыкасының татар кулыннан яисә үзеннән чыкканын сөя. Зыя фикеренчә, музыка барлык нәфисәнең[1] башкаларыннан: шигырь вә рәсемнән дә югары тора. Музыка мәсьәләләренә килгәч, шуны да әйтеп китәргә кирәк, бу музыка романда «Әлфе ләйлә»дәге танбури башмагы кеби булып киткән. Һәр җирдә музыка. Аны төчеләтеп, арттырып җибәреп тасвирлаулар, хәтта шулкадәр туйдыра ки, бөтен гомереңдә музыка ишетмәскә дә риза булырсың. Чынлап та, бик татлы нәрсәне күп ашасаң тәмсез була торган, шуңа күрә дә Зыя бөтенләй музыка белән тулган бер нәрсә, бер хыялый, музыка ашап, музыка эчеп торган бер җисем, ләтыйф[2] булып чыга язган. Хәтта Зыяның Мәрьямгә булган гыйшкы да мөхәррирнең музыка сөюен бик куертуы сәбәпле зәгыйфь, сыек булып чыккан.

Ничек тә Зыя тибы бик тормышка муафыйк, бик татар галәмендә, бигрәк тә фанатизм золымы астында тәрбия кылынганда була торган бер типтыр. Зыя беренче мәртәбә безнең әдәбиятыбызда килеп чыкты: моның белән мөхәррирне тәбрик кылмый булмыйдыр. Агасы Сабир, Зыяның бөтенләй гакесе[3], ул чын Руссо фикерендә. Эш өчен, чын кол эше өчен туган бер кеше. Ул мәдәниятне яратмый, шәһәрне сөйми, аңа хәтта язу тану да мөһим түгел, ул шундый кызны хатынлыкка ала. Ул җитди кеше. Ул авыр, сабыр, гакыллы, уйчан. «Мөхакәмәнең[4] салкын колы». Зыя хис белән яшәсә, Сабир гакылы белән яши.

---

[1] Нәфисәнең – гүзәл нәрсәләрнең.

[2] Ләтыйф – фәрештә.

[3] Гакесе – каршысы, киресе.

[4] Мөхакәмәнең – хөкем чыгаруның.

Менә бу ике борадәрне[1] һәм башка әллә ничә мөгаллим, мулла, үзгәреш күргән кешеләрне язганда, тасвир иткәндә мөхәррир үзгәреш заманын һәм аның ничек акрынлап тәэсир иткәнен аз яза. Әмма бу бик мөһим мәсьәләдер. Бөтен үзгәреш заманын тасвир алты-җидедән артмый. Әмма бу типлар шуның җимеше булган соңында шактый гына язылырга тиеш иде. Бу борадәрләрнең атасы Җәлал мулла кем?

Менә мөхәррир аны шул сүзләр белән тасвир итә: ул җилҗак[2], салам кыстырганны ярата торган, дан яратучан. Җәлал мулла зур эш ярата. Аның шөһрәткярлегеме әллә җилҗаклыгымы зур. Харикылгадә[3] эш ярата торган бер табигать ясаган. Бу тип, гомумән әйткәндә, шактый гына муаффәкыятьле чыккан. Бу Җәлал мулла, мулла булса да гаиләсен рәнҗетергә, җәбер кылырга ярата торган, табигате белән гомуми татар бае, мещан һәм бай муллаларында очрый торган бер тип булып чыккан.

Монда урыны булмаса да, хәтердә вакытта шуны да әйтеп китәргә кирәк: мөхәррирнең бәгъзе типлар, бәгъзе сурәтләр, бәгъзе фикерләрене әйткәндә элек бер кагыйдә утыртып куеп, аннан соң шул кагыйдәгә бер хосусый вакыйганы чолгый торган гадәте бар. Менә бу әдәбиятта дедукция [мантыйкның гомуми бер нәрсәдән хосусый нәтиҗәләр чыгару ысулы] ысулы белән эш йөртү шактый гына уңайсыз эштер. Әдәбият бит типичный факт хакында, яисә бер башка вакытта һәм башка җирдә булмый торган бер вакыйганы хосусый бер мәсьәләләр, типлар васыйтасы белән сөйләү түгелме? Шуның белән дә әдәбиятның сәнгать кыйсмenә керә торганы гыйльми әдәбияттан аерыла да түгелме? Мондый урыннарны 8 нче сәхифәдә, 28 нче сәхифәләрдә табарга мөмкин. Әгәр без әдәбиятта дедукция ысулын куллана башласак, һәрбер гыйльми рухны аз-маз укыган адәм ул фәннең кагыйдәләре буенча хикәяләр язып чыгарыр иде. Һәм ул сонгый[4] сәнәгать бәлки мөмкиндәдер, ләкин ул чын әдәбият була алмый. Ул бары ялган сәнгать кенә булып каладыр.

Романның эчендә шактый гына зур урын тоткан Мәрьям туташ бар. Ул кыз вакытында, мөхәррирнең сүзе буенча, һәм романда күренүе буенча, «Мохитнең колы». Акрын, юаш табигатьле бер

[1] Борадәрне – агалы-энеле ир туганнарны.
[2] Җилҗак – мактаганны яратучан.
[3] Харикылгадә – гадәттән тыш.
[4] Сонгый – ясалма.

кыз. Әмма Фәхригә баргач, аның бу эшләре бетә. Ул, мөхәррирнең тасвирына караганда, җанаи[1] романнар каһарманы булырга лаек була: ул лампа белән киявен яндыра. Бәлки Фәхригә Мәрьям агу да эчерә торгандыр. Гәрчә судта «Нахак!» дисә дә… Әмма алай да бик зәгыйфь чыга… Кызлык дәвере хатынлык дәвереннән әллә ничә кат күп яхшы чыккан. Мин, дөресен әйткәндә, Мәрьямне аңламыйм. Ул – сентименталист. Ул бик зәгыйфь табигатьле, куркак. Әмма Зыя бер картны атып үтергәндә артык курыкмый да бугай… Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: хикәядә Зыяның теге картны үтерү кыйссасы бик зәгыйфь чыккан. Фикеремчә, мөхәррир үзе дә ни эшләргә белмәгән булырга кирәк. Карт Зыя белән Мәрьямне тотты, инде нишләргә кирәк? Аттыра да үтертә. Ә җәсаде? Аны теге елгага бух! Тагын табигать аңар булыша имеш, иртәгесен үк елга катып китә! Йә, анысы ярар иде. Инде, ләкин кеше үтергәч, катыйльдә булган халәте рухиясе[2] бик зәгыйфь тасвир ителгән: имеш бер-ике мәртәбә күзгә күренә, төшкә керә дә бетә. Әмма сез, укучылар, Зыяны аңлаган булсагыз, аның хисле, аның романтик, үзенең рухындагы кечкенә генә селкенүне дә санап тора торган бер адәм икәнен күреп торсагыз белерсез: Зыя гөнаһсыз адәмне үтергәнгә ничек мөтәәссир[3] булырга кирәк? Мәгәр монда иң зур «мәңгелек трагедия» булырга кирәк иде!

Мәрьямнең анасы Фатыйма бикәгә килсәк, ул «кала кызы, нечкә»… Ул үзенең морзалыгын һаман да сизеп тора. Һәрвакытта башка сыйныфка бер өстән карау белән карый. Аның ахирәте Зыяның анасы, Зөләйха абыстай исә балаларын ярата торган, иренең әмеренә мотыйгъ[4], диндар, чын бер сала остабикәсе. Аның яшь чакта укыган «Шәрхе мелла»лары, «су кеби эчкән кафия мәтиннәре[5]» һәммәсе дә очып беткәннәр.

Гәрәй морзаны мөхәррир аз тасвир иткән. Аның морза булуына карамый, чын гаилә ерткычы икәнен, Мәрьямне гимназиягә бирмәвендә, Фатыйманың кардәш ырулары белән кычкырышып торуларында күренеп тора. Ул бай, эш яратучан, гакыллы адәм. Менә аның хакында безнең белүебез шул кадәр.

---

[1] Җанаи – детектив.

[2] Катыйльдә булган халәте рухиясе – үтерүченең рухи халәте.

[3] Мәтәәссир – хәсрәткә, кайгыга төшкән.

[4] Мотыйгъ – буйсынган.

[5] Кафия мәтиннәре – рифмалы китап текстлары.

Галимҗан әфәнденең тасвир кылган вак типларыннан, хәзер без зурракларын бетердек, романда башка кешеләр күп булса да, аларның бәгъзесе [мәсәлән, яшерен шагыйрь] шул югарыда әйтелгән типларның аз гына язганнары булганга, кайсысы бик ачык булмаганга, хәзергә калдырамыз да. Сәлимгә күчәбез. Сәлим кызык тип. Ул чын-чын 1905 ел адәме. Ул, мөхәррирнең язуына караганда, шул хәрәкәтнең эчендә йөргән, әмма хәзер әүвәлге иманы беткән, бер пессимист булып калган. Ул нәкъ чабып арган ат кеби. Ул хәзер арган-талган. Әүвәлдә дә тәкълиди[1] булуы бик ихтимал булган иманы да хазыйр иткән – шәйтан алган! Ләкин ул башына әллә кайдан тарихи, иҗтимагый фикерләр тутырган, тәгаен өч тиенлек брошюра [рисалә]ләрнең тәэсиредер! Ул органическая теория шикелле бер фикер сөйли: милләтне кешегә охшата; татар милләтенең картлыгына инана, үз үлеме белән үлсен, тимәгез, ди. Бу тип хәяткә бик якын бер тип. Боларны җыйсак 1908 елларда татар галәмендә бер-ике дистә таба да алыр идек! Болар үз эчләрендәге арганлык, иманның беткән аналогия [кыяс[2] бугай] белән милләтемезгә китереп аны да үзләре кеби шәлдерәгән, какшаган итеп табалар иде. Чөнки боларда 3 тиенлек брошюрадан башка башларында бернәрсә дә булмыйдыр иде. Болар бары тик табигый үлем белән үлгән бер милләтне, дикъкать боерылсын, милләтне – кавем түгел! миңа күрсәтеңез дияргә кирәк иде. Шунда аларның бу имансызлыкка иманнары кайтыр иде. Чөнки андый бер милләтне ул күрә алмас иде… Мондый эшне гыйльми юлга салып сөйли торган бер адәмгә «яшерен шагыйрь»нең җаваплары бик аз булып калалар, бик зәгыйфь булып калалар. Чөнки аның сөйләгән сүзләре хис кенә, әмма исбат түгел! Типлар арасында мөтәрәкъкый[3] мулла типлары бар. Болар да шактый муаффәкыятьле чыкканнар. Аның берсен тип ясарга җитә торган менә шул берничә җөмлә бигрәк тә матур: « Соң хәзрәт, укыса ни булган ди, гыйлем бит барыбер, марҗадан укыдың ни! Хәзрәттән укыдың ни! Пәйгамбәремез бит, Кытайдан булса да гыйлем алыгыз, дигән.»

Менә шуның өстенә авызларыннан төшерми торган тагын берәр хәдис кыстырсаң мөтәрәкъкый муллаларның бөтен дәлилләрен мөхәррир сөйләп чыккан булыр иде.

---

[1] Тәкълиди – ияргән.
[2] Аналогия (кыяс) – охшату, чагыштыру.
[3] Мөтәрәкъкый – алдынгы карашлы, прогрессив.

III

«Яшь йөрәкләр»нең иҗтимагый әһәмияте хакында берәр сүз әйтеп китүне кирәкле табам. Чынлап та бу әсәрдә иң ачык, иң дөрес итеп «сәхәрсез рузә» мәсьәләсе күтәрелгән. Бу мәсьәләне башка формада, аяк бозу шәкелендә, Гаяз әфәнде дә «Тормышмы бу?» дигән әсәрендә күтәргән иде бугай. Вакыйган, әсәрнең иҗтимагый әһәмияте дигәч тә, хәзер шул мәсьәлә күз алдына килми хәл юк. Бу безнең, гомумән Россия гражданнарының, шактый гына авыр урыны…

*Мәкалә тарихчы, җәмәгать эшлеклесе Газиз Гобәйдуллин (1887–1937) тарафыннан язылып, 1913 елны «Аң» журналының 11 санында басылып чыккан. Текст басмага журналдан алынды.*

*Әхмәтзәки*

**Шәрекъкә гаид яңа әсәрләр**

Профессор Катанов тәхет идарәсендә чыгып барган ошбу мәҗмуга хакында үткән ел (1914, № 1295) «Йолдыз» гәзитәсендә бәгъзе мәгълүмат биргән идек. Моның бу яңа гаддләреннән[1] 7 нчесендә (б. 483–509). – Емельяновның «1913 нче елда гайре моваккат[2] татар матбугаты» дигән мәкаләсе, Васильевның чирмешләр хакындагы бер әсәргә тәнкыйте; 8нче гаддендә М. Ивановның «Мәҗүсиятьтә һәм Исламда элгәрегә ихтирам итү» дигән мәкаләсе татарча матбугаттан төрле мәсьәләләр хакында тәрҗемә, Алкин белән «Йолдыз» һәм «Кояш» мөхәррирләре арасында «Казанский телеграф»та язылып үткән нәрсәләр (тәмам гыйбрәтләре илә) март, апрель һәм май айларында «Мөселман моваккат матбугаты» дигән мәкалә дәреҗ ителгәннәр.

Емельянов мәкаләсендә, үткән 1913 ел Идел буендагы мөселман шәһәрләрендә 518 кадәр исемдә китап чыкты, боларның кырык дүрте гарәпчә, егерме алтысы гарәпчә белән татарча катыш, уникесе русча белән татарча катыш, егерме тугызы кыргызча..., дип санап китә һәм татар китапларына туктала.

Монда мөаллиф[3] иске өслүбтә язылган дини китаплар һәм гыйльме хальләр хакында бераз мәгълүмат бирә. Моннан аңа

[1] Гаддләреннән – саннарыннан.
[2] Гайре моваккат – вакытлы матбугаттан тыш.
[3] Мөаллиф – автор.

әдәбиятка күчә дә, әйтә: «Яңа әдәбият иске рухта язылган әдәбиятка караганда кайсы кабул итмәслек дәрәҗәдә төзү. Хәттә бәгъзе яхшырак мөаллифләрнең әсәрләре һичбер сүз әйтерлек түгел, ягъни яхшы. Яңа әдәбиятның тышкы яктагы кимчелекләре исемендә ошбу нокталарны күрсәтергә мөмкин. Мәсәлән: боларның күбесе әдәбиятның нәүгъ вә сыйныфларын (роды и виды) аера белмиләр. Кечкенә кулдагы 16 битле китапка роман дип, бер пәрдәлек кечкенә әсәрләргә драма яки трагедия дип исем кушалар. Әмма эчке яктан караганда бу яңа әдәбиятның яхшы ягы аның хәят берлә бергә баруыдыр. Вакыйган, татар мөхәррирләреннән бәгъзеләре үз милли хәятләрен яхшы ук дөрес тасвир итәләр. Иске мөселман дине тәгассыбыннан[1] котылган бу мөхәррирләр үзләренә ничек уйларга кирәк икәнлек тугрысында гына түгел, бүген ничек уйлаганнары хакында да язалар һәм истикъбаль[2] белән генә түгел, хәзерге мәгыйшәт һәм аның яхшы-яман якларын карау белән дә шөгыльләнәләр. Татар әдипләренең йитешмәгән йиренең башы моның артык берьяклы гына булуындадыр.

Яңалык тарафдары булган мөхәррирләр бик тиз генә үзләрен Пушкин, Лермонтовлар итеп уйларга һәм язган нәрсәләрен иң мәдәни милләтләрнең әдәби әсәрләре катларына куярга тырышалар. Моның өчен олуг мәдәни кәвемнәрнең әдәбиятының бәгъзе бер кыйсемнәре татар теле вә әдәбиятына татбикъ ителүе[3] мөмкин булмавына карамыйча, һәр эшкә барып бәреләләр. Мәсәлән: алар татар әдәбиятына кавагыйде әдәбия (теория словестности), әдәбият тарихы, әдәбиятка гаид тәнкыйтьләр язып маташкан булалар. Хәлбуки аларда әдәбият дигәннең үзе әле яңа гына дөньяга шытып чыгып килә; кая әле аны әллә нинди мәдәни милләтләрнең әдәбияты масштабына салып үлчәргә. Гомумән, яңа татар әдәбияты үзенең мондый сыйфаты белән Европа киемен киеп алып, көзге алдында әйләнеп, «ә, тәмам европалы булдым бит» дип уйлый торган эче куыш татар шәкертен искә төшерә. Безнең бу сүзләребез әлбәттә Гаяз Исхаков һәм балалар әдәбияты бабында язучы Думави вә башка берәүләргә карамый.

Искелек тарафдарлары белән яңалык тарафдарларының көрәше: яңа милләтнең тәрәккый һәм тәмәддене[4], татар хатыны-

[1] Тәгассыбыннан – фанатизмыннан.
[2] Истикъбаль – киләчәк.
[3] Татбикъ ителүе – кулланылуы.
[4] Тәмәддене – мәдәниятле булуы.

ның хәле; һәркөн булып торган олуг хадисәләр[1] кеби мәсьлә хәзерге татар галәмен шаулата. Менә шул мәсьәләләрне эшләп халыкны шаулашырлык хәлгә китергән нәрсә, әлбәттә, шул яңа әдәбияттыр».

Монан соң мөаллиф яңа татар әдәбияты ошбу зикер ителгән мәсьәләләрне ничек мөхакәмә иткәнен аерым-аерым сөйли.

«Искелек тарафдарлары милләтнең юньле яшәве өчен халыкка динне яхшы өйрәтү йитә дисәләр дә яңа әдәбият тарафдары мөхәррирләр Европа мәдәниятен алмый булмый диләр. Ләкин Европа мәдәниятен алырга өндәү белән бергә үз милли гореф-гадәт вә хосусиятләрен сакларга да бик нык тырышалар. Һәрбер мөхәррир үзенең әсәрендә милләтенең бер махсус ноктасын күрсәтергә һәм шуны халкының күңеленә сеңдерергә тели. Ләкин бу юлдагы хезмәтләр әлегә бик муаффәкыятьле[2] була алмады, чөнки аларның күбесе татар мәгыйшәтенең камиллеккә йитмәгән күп өлешен сонгый сүрәттә[3] артык матурлап күрсәтергә тырышалар. Мәсәлән, «Яшь йөрәкләр» китабының мөаллифе Галимҗан Ибраһимов үз халкының музыкасын шулкадәр күтәреп алып киткән ки, көлмәслек түгел. Андагы яшь каһарман Зыя – мөнәввир[4], зыялы татар егете – һәммә концерт вә операларга караганда авылда урам буеннан уйнап йөрүче никрутларның гармун тавышларын яки татар көен уйнаучы сукыр гармунчының уенын җитди сүрәттә артык күрә. Халыкка милли хосусиятне ныграк сеңдерүне теләп татар әдипләре укучыларның уйларын борынгы якка әйләндереп каратырга хәтта бу хосуста тарихта хуҗалык итәргә дә яраталар. Хәтта үзләренең мәдәни кәвемнәр арасында нинди урыннар алачакларын, эшлекле немецларгамы, әллә бик күңелле французларгамы, әллә артист табигатьле итальяннаргамы, әллә һавалы американнаргамы охшап чыгарларын мөхакәмә итәләр».

Хатынлар мәсьәләсендә ул кадәр әйтерлек яңа әсәр чыкмады һәм чыкканнары да әһәмиятсезрәк нәрсәләрдер, дип бу бабта эш Әхмәдиевнең «Суга баткан килен», Бикташевның «Яшь кыз», Монасыйповның «Өзелгән өмид» дигән китапларын карарга мөмкин, ди.

---

[1] Хадисә – вакыйга.

[2] Муаффәкыятьле – уңышлы.

[3] Сонгый – ясалма.

[4] Мөнәввир – мәгърифәтле.

Татар матбугатын шаулаткан зур хадисәләрдән Романовлар сөляләсе[1] бәйрәмен, Духовный собрание, мөфтилек мәсьәләләрен күрсәтә.

Моннан соң мөаллиф 1913 елгы татар әдәбиятын эчтәлек җәһәте белән 9 нәүгъка бүлә: 1) дини китаплар – 170; 2) фәнниләр – 13; 3) балалар әдәбияты – 23; 4) халык укыр өчен – 73; 5) дәреслекләр – 71; 6) әдәбият – 101; 7) төрле мәсьәләләргә гаид әсәрләр – 51; 8) календарьлар – 10; 9) музыкага гаид – 1. Араларыннан дини һәм фәнни кыйсемнәр белән әдәбият кыйсьмен тәфсилләбрәк карый.

* * *

«Галимҗан әфәнденең башка әсәрләрендәге кебек «Татар шагыйрьләре»ндә дә бер кимчелек: сүзнең күп, әмма әйтә торган фикернең, мәгънәнең аз булуыдыр. Бу мөхәррир «бездә күп мөхәррирләр мотлак сүз боткасы пешерәләр, бер сүз белән әйтеп үтәргә мөмкин булган фикерне ун сүз белән сөйлиләр, – ди. – Аның ошбу сүзе бөтен көенә үзенә кайтадыр» – ди.

Әдәби әсәрләрдән Галимҗан әфәнденең «Яшь йөрәкләре» (б. 499–504) белән Гаяз әфәнденең «Мелла бабай» дигән романыннан әүвәлге ике җөзъэн[2] (б. 505–509) карап чыга.

«Яшь йөрәкләр» хакында әйтә: «Мондый зур әдәби әсәр татарларда әлегә кадәр булганы юк иде. Шундый бик яңа эш булганы өчен булырга кирәк, ки: бу мөхәррир бу юлдагы беренче тәҗрибәне ул кадәр тиешенчә яхшы итеп чыгара алмаган. Романның мәзмуны[3] ошбу рәвештә: Мәрьям исемле беркадәр мәгълуматлы бер татар кызы – мирза баласы – үзенең анасы белән үз имениеләрендә тора. Моның бердәнбер һәм барлык шөгыле төрекчә романнар уку була. Бу романнар аңа бик яхшы азык бирәләр һәм шул романнар аркасында ул үзенең хәятеннән ясала торган бер романга каһарман булып хәзерләнә. Ул шул йирдәге Җәлал исемле мулланың углы Зыя белән сөешә, мөселманнар гадәтенчә, кызлар белән егетләрнең аулакта күрешүләре ярамаганга, болар һәрвакыт бик аулакта, кеше сизмәслек кенә йирләрдә күрешәләр. Ләкин бервакыт боларның күрешүләрен каравылчы карт күрә. Зыя эшне каплар өчен картны тотып үтерә дә шундагы елгага ташлый. Менә шундый зур вакыйга сөюче шәхесләргә, ни гаҗәп, һич тәэсир итми. Бәгъзе бер

[1] Сөляләсе – династиясе, нәселе.

[2] Җөзъэн – бүлеген.

[3] Мәзмуны – эчтәлеге.

төшкә керү кеби нәрсәләрдән башка нәрсә булмый. Алар эшләрен элеккечә дәвам иттерәләр. Укучы кеше моны күреп аптырап кала, ни өчен мөәллифкә[1] үзенең каһарманнары хәятендә мондый бер хадисә уйлап чыгару кирәк булган?

Ике яшь кешенең хәятләрендәге трагедия бик гади һәм бик әһәмиятсез нәрсә – Зыяның солдатка алынуы белән башлана. Ул киткәч, Мәрьям үзе сөймәгән бер кешегә кияүгә чыга. Боларның ирле-хатынлы мәгыйшәтләре бөтенесе бәхетсез вакыйгалар белән тулы була һәм ахырдан ирнең агуланып капыл үтерелүе белән бетә. Мәрьямнән шөбһәләнәләр, һәм хөкем соңында, ул алты елга каторгага китә. Зыяның хәяте үзенчә бара тора һәм ул авылына кунакка да кайткалый; Мәрьям белән хат та язышa. Мәрьямнең иргә чыгуы һәм аның бәхетсез тормышы Зыяга тәэсир итмәве, әлбәттә, мөмкин түгел. Ләкин ул тәэсир ничектер укучы көтеп баргандагыча көчле чыкмый. Соңыннан Зыя бер вакыт иптәшләре белән утырган урында «Алла! Алла!», – дип кычкыра да капыл үлеп китә. Ләкин бу эшнең Мәрьям вакыйгасы сәбәпле булуын аңлатырлык нәрсә хикәядә китерелми.

Ошбу күчерелгән эчтәлектән үк күренә ки бу китап тәмам булган бер әсәр түгел. Аның структурасында да төзеклек юк. Аерым кыйтгалар арасында һич вакыт мөнәсәбәт булмый. Мөәллиф әфәнде хикәясенең типичный булып чыгуы өчен күп уйлап тормаган, бәлки үзен ихата кыйлган[2] хәяттән нәрсә кулына төшсә, шуларны араларында мөнәсәбәт-фәлән эзләп тормый, аның мәҗмугасыннан бер тәмам фикер, максуд аңлашылырга кирәкме-юкмы икәнлеген һич уйламый, тоткан да сонгый бер сүрәттә ябыштырырга керешкән.

Арадагы каһарманнарның сыйфат (характер)ларын тасвир итүдә дә мөәллиф һич муаффәкыять казана алмаган; ул китабын «Яшь йөрәкләр» дип атаган. Хәлбуки анда Зыя белән Мәрьямгә караганда аларның аталары булган Җәлал мулла һәм аның хатыны, ягъни «карт йөрәкләр» артыграк роль уйныйлар. Шуның өчен исеме дә үзенә муафыйк түгел.

Мәрьямне мөәллиф үзе бик ярата. Ләкин ул вакыйгда[3] бөтенләй сөйкемсез, мәхәббәтсез кеше. Зыя да аны сөйгән урында мотлакан кашы, күзе, борынлары матур дип кенә сөя; әмма аның

[1] Мөәллифкә – авторга.

[2] Ихата кыйлган – уратып алган.

[3] Вакыйгда – чынбарлыкта.

рухани ягына әһәмият бирми һәм вакыйган монда рухи матурлык дигәнең юктыр.

Мәрьямнең мәгълүматы мөселман мәктәбендә тегендә-монда сугылып кына алган нәрсәләр. Атасы аны диннән чыкмасын дип, урыс мәктәпләре урынына, Мисыр, Истанбулдан кайткан әфәнделәрдән укыта. Бу мәктәп аңа зур тәэсир калдыра. Шул тәрбия белән ул үзенең хакыйкый хәятенә аяк баса. Ягъни аның мәктәп тәрбиясе дә аны бер төпсез, төрек романнары гына укып маташа торган нәрсә итеп чыгара. Ул анасы хозурында кияүгә чыгачак кыз булып үткәргән вакытларында мотлакан юк-бар хыял, шул төрек романнары белән үткәрә һәм Зыя солдатка киткәч тә һичкемнең көчләвеннән башка, үзе сөймәгән кешегә иргә чыга. Чөнки аны Зыя һәрвакыт язып торган хатларында вә гайре юллар белән саклашып, анасы да, үземнең бердән-бер кызым, дип аның теләген генә булдырырга теләп торалар иде.

Бу кыз инде иргә чыккач, үзеннән башкаларга каршы һичбер шәфкать, хөрмәт дигәнне белми торган былчырак адәм (преступница) гына булып чыга. Дөрес, ул Зыяга ялган хатирәләрендә үзенең хәле начарлыгын, ире аңа мотлакан шул хайвани хисләр өчен яратылган нәрсә дип караганлыгын язып кайгыра. Ләкин шунда ук иренең аны (Мәрьямне) үзенчә бик нык яратканын, әмма ул иренең шундый мәхәббәтенә мәсхәрә итеп кенә караганын яза. Ул үзенең уйсыз, төпсезлеге аркасында үзе сөймәгән кешегә кияүгә чыгып, үз ирен бәхетсез ясаганын һәм иренең мәхәббәтен тәхкыйрь итеп[1], аңа шундый мәсхәрә белән каравын һич гөнаһ дип уйламый. Хәтта, моның өстенә, кайвакыт ирен үзенең кабахәтлеге белән җәфалый. Мәсәлән: ул бервакыт ирен көнләп ачулана да, аның битенә янып торган лампа белән алып бәрә. Моннан ирнең битләре янып, җәфалана. Шул вакытта теге кеше гали табигате аркасында хатынын гафу итә. Ләкин хатыны моны тәкъдир итми[2] һәм мөхәррир дә бу кешенең гали табигатен «хатыны лампа белән бәреп үтерде» дип әйтүдән куркып кына, гафу итте, дип мәсхәрә итә. Мәрьям, түгел иренең шундый гали табигатен тәкъдир итү, хәтта аны үтереп, рәсми сүрәттә катыйлә[3] була. Суд вакытында ул гөнаһысын игътираф итә торган[4] урынга, ни өчендер «гадаләтсез-

[1] Тәхкыйрь итеп – мыскыл итеп, хурлап.
[2] Тәкъдир итми – бәяләми, рәхмәтле булмый.
[3] Катыйлә – үтерүче.
[4] Игътираф итә торган – таныйсы.

лек[1], гадаләтлезлек», дип кычкыра, ләкин нинди гадаләтсезлек? Монысы һаман караңгы кала.

Зыя да әхлакый җәһәтеннән бик югары кеше түгел, мөхәррир бу Зыяны бик нечкә хисле, хатынлар табигатьле, музыка сөя торган кеше дип бик ярата. Ләкин аның шул ук табигатьләре андагы былчыраклык белән бергә җыела. Ул бер каравылчы картны үтерә. Ләкин бу гөнаһ аның гомерендә бер дә рәтләп хәтеренә керми. Аның вөҗданы моның өчен һич тә җәфаланмый. Шулай ук ул солдатка китмәс өчен сонгый сурәттә[2] үзенең сәламәтлеген боза. Бу эш тә аның «гали вә аристократический табигате»нә килешә.

Мөхәррир иске буын әдәмнәрен тасвир иткән урында мондый түгел, ул анда яхшы ук дөрест яза алган. Мәсәлән, ул бик матур итеп Җәлал мелланы һәм аның хатыны Зөләйха абыстайларны яхшы гына тасвир итә алган», – дип яза (б. 504–506).

Бу ике каһарман турында фикерен тәфсыйл итә[3].

Соңыннан Зөләйха абыстайны романның иң төп каһарманы дип таба һәм аны шөбһәсез, яхшы (положительный) тип ди.

*Мәкалә тарихчы, тюрколог Зәки Вәлиди (1890–1970) тарафыннан язылып, 1915 елны «Шура» журналының 6–7 саннарында дөнья күрә.*

*Текстларны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Ә.Х. Алиева әзерләде.*

*С. Атнагулов*

## Безнең көннәр

«Төн караңгы. Дөнья тын.
Ләкин диңгез шаулый, диңгез төбендә кемгәдер ачулы шикаять белән үкеренә».
«Кайдадыр хөкүмәт белән халык сугыша... Кайдадыр урамнарда баррикадалар ясала. Киң мәйданнар адәм үлекләре белән тула. Кан... дәрьялар булып ага. Ләкин ул әллә кайда, еракта».
«Русия диңгезендә күтәрелгән куәтле революция тулкыны да мәмләкәтнең караңгы почмакларында яшәгән безнең халкымызга башта шулай тоелды».

(«Безнең көннәр»).

---

[1] Гадаләтсезлек – гаделсезлек.
[2] Сонгый сурәттә – ясалма рәвештә.
[3] Тәфсыйл итә – җентекләп аңлата.

I

1 – «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»,

2 – «Татар хатыны ниләр күрми»,

3 – «Ялчы», «Көтүче», «Диңгездә»,

4 – «Табигать балалары»,

5 – «Сөю – сәгадәт» атлы әсәрләре белән татар-башкортның яшь укучыларын үзенә тарткан, аларның кысынкы дөньяга хәсыйме[1], ләкин тышка бәреп чыгарга юл тапмый тарыккан күңелләренә сукмак салучы Идел-Урал буендагы татар-башкортның әдәбият бакчасына тулы типлардан гыйбарәт «Яшь йөрәкләр» тудыручы иптәш Галимҗан Ибраһимовның янә бер зур әсәре кулыбызга керде.

II

«Элек, азгын студентлар, диләр иде. Бара торгач, мәйданга яңа бер халык килеп чыкты.. Ни диләр үзләрен, социалистмы, кемме, диләр. Бер кулларында бомба – җәһәннәм машинасы. Икенче кулларында – флаг».

«Эш ташлау», «хөррият», «бүген палитсә мистергә... иртәгә губернаторга... соңра министрга... ташланган бомба тавышларыннан шәһәрләр диһшәт белән тула...». Халык: «Йа Ходай, әллә безгә дә килеп җитәме?!...»

«Шәһәрдә эшчеләр берегә... Имеш, шәһәрнең бөтен эшчеләре берләшәчәкләр дә...». Халык: «Менә мәҗнүннәр, менә җүләрләр, шәһәрне алалар, имеш...

Кем ала?

Кемнән алалар?

Ниһаять, безнең мөселман агай-эне: «Кяфер үзара сугыша...»

«Шәһәрнең иң могтәбәр хәзрәте Вафа ахун: «Җәмәгать, йир йөзе фетнә белән тулды. Урамнар фетнәчеләр белән тулы. Шул фетнәчеләр арасына кушылып, әһеле исламны сатучы булмасын. Коръән әмере белән әйтәмен ки, шул гыйсьянчылар арасында бер мөселман булмасын! Бу бөтен мөселман йөзенә кара ягачак...».

Фетнәчеләр: «Сигез сәгать эш вакыты», «Эш хакы арттырылсын!»

Шәкертләр: «Исляхат мәдарис».

---

[1] Хәсыйме – тартышучы, каршылык күрсәтүче.

Галимҗан иптәшнең бу әсәре менә шул язылып үткән җөмләләр белән, әнә шул җөмләләрнең татар-башкортлар арасында колактан-колакка бик җиңел күчкән көннәреннән башлана.

Идел-Урал буе татар-башкорт яшь йөрәкләренең «саф күңелләре алдында нурлы гарешнең ачылган көннәре»ндәге типларны саный башлый.

Тарихның черегән кискәсе белән бастырылган мөселман агай-эне, язмышка буйсынып, кул кушырган килеш башын түбән салган. Ләкин черегән кискәнең читләрен җимереп чыга алган яшь күңелләр ашкына! Алар шашалар, бу ашкыну-шашынудан берәр нәрсә чыгамы, юкмы – анда кайгы юк. Тик менә иске тормыш төбе-тамыры белән җимерелә дә яңа изге, матур тормыш иңә. Шашынучыларның зур бер өлеше менә шул күренештә иде.

Ара-тирә руслар арасында «беглец», татарларда «качкын», шәкерт арасында «Сәруҗи» аталып йөргән, бер подвалдан икенче подвалга күчеп яшәүче, артына төшү белән бер шәһәрдән икенче шәһәргә күчүче, карлы-бәзле яңгырларда күшегеп, берничә тәүлекләр ач йөрергә башын салган, төрмә-крепостьлардан кача яшәгән, бөтен уен, үзен революция иркенә тапшырган Хәбиб Мансуров таплары да юк түгел.

Фабрика-заводларда станок артындагы татар эшчеләре арасыннан чыгып, революциягә таба беренче адым атлаган өчен «эшсез» калучы сирәк очрый торган Габдулла абзый тибы күренә башлаган иде.

Татарның атаклы мәдрәсәләрен гизеп тә, берничәләреннән сөрелгәннән соң да үзенең эзләгәнен таба алмый, ниһаять, хосусый русча укырга керешүче, анда да ямь таба алмый, гомуми революция агымына кереп баручы Урманов тибын татар шәкертләрендә очратырга мөмкин иде.

«Бетсен схоластика, фөнуне җәдидә[1] кирәк» лозунглары белән бергә үк «тәфсир, рәдде насара, хәдис» сүзләрен бергә җыйнаучы «Исляхе-мәдарис» гөруһы да калка иде.

Әгәр берәр төрле кузгалыш, үзгәреш була калса, «Думага» сайланырга төрле хәйләләр әзерләп йөрүче чиновник морзалар, шундый көннәрдә, халыкчы булып күренергә теләп, «речьләр» хәзерләүче бала морзалар да өлгергән кебек, революция тулкыны арасында «кататься» итәргә теләүче Рауза типлары матур

[1] Фөнүне җәдидә – яңа фәннәр.

туташлар да күренгәли иде. Әнә шул Раузаларны күрер өчен булса да, иҗтимагый эш артыннан йөрүче, киселүче, шундый шау-шу көннәреннән файдаланып калырга теләүче, мәхәббәт утын сүндерергә теләүче тәтәй җегетләр дә үсә башлаган иде инде.

Кара йөрәк Русиянең өч йөз еллар буенча изүен онытмаган, әгәр бер талаш була калса, иң беренче эш «милләтне» күтәреп калдыру хыялы белән исерүчеләр дә күренгәли.

Революциягә яшерен өндәүнең бердәнбер юлы шапирографта берничә йөз данә кәгазь басып тарату икәнлегенә зур иман белән керешә башлаган бер генә катлаулы күңелле фидаиләр дә җитешә башлаган иде инде.

«Безнең көннәр» менә шул типларны эченә ала да татар-башкорт халкының революциягә катнашу көннәрен сүтеп күрсәтә. Әнә шул типларны ала да татар-башкорт халкының революция алдындагы иҗтимагый мәүкыйгын[1] үлчи.

III

Русиядә 1905 нче ел революциясе башлана. Фәхри приказчик, хөкүмәт мәктәбендә укучы реалист Акчулпанов, гимназиядән куылучы Тангатаров, «Фидаиләр» группасын тәшкил итәргә теләүче азгын шәкертләр пәйда була.

Революция матур күренә. Аның матурлыгы бай малае Йосыфҗан кебекләрне дә башта үзенә ияртә. Тик Кадыйр байлар гына, үзенең явыз Фәхри приказчигы кызыл булуг, артык ачулана. Вера, Гриша, Разиннар белән бергә революция юлында эшләүче, авыр, салмак табигатьле крестьянин Булатов, шахта эшчеләренең иң алдынгысы саналган Гәрәй Солтановлар күтәрелә. Качкын Хәбиб Мансуров җаннар янәдән зур дәрт, тулы гайрәт белән алган эшләрен үстерәләр.

Көн саен диярлек думага сайлаулар турысында җыелышалар, кычкырышалар, зур һәм кечкенә митинглар өзелә, полиция белән бәрелешүләр җышлана. Ябалар, качалар, чыгарылалар, революция кайный, гөж килә. Башка милләт революционерлары белән бергә үк татар-башкорт җегетләре дә эшлиләр.

Мәдрәсәләр янә дулый, мөдәррис сайлыйлар, мөдәррис куалар. Байлар, мөдәррисләр җиңсәләр, шәкертләрнең азгыннарын мәдрәсәдән сөрәләр. Менә шул котырынучы азгын шәкертләр аша

[1] Мәүкыйгын – урынын.

авыл да кыймылдый. Ләкин гомуми мәсьәләдә җирдән үтмәгән кебек, татар-башкортларның үзләренә махсус күренешләрдә дә «җәдид-кадим» исеме белән мәшһүр күренештән үтә алмый. Шулай булса да бу күренеш бөтен татар-башкорт авылын бер мәртәбә җилтерәтеп, селкетеп ала.

Гади революциячеләр алдында сәяси, икътисадый, иҗтимагый, милли мәсьәләләр барысы да бергә бутала. Болар мәгълүм бер партия дә түгел, мәгълүм бер программаны алмыйлар, бәлки, гомумән, революцияче саналалар. Шул ук вакытта алар сәүдәгәр дә, мулла, мөгаллим дә, игенче, эшче дә булып китә алган кебек, үзләренең җомшаклыгы саясендә[1], табигать тарафыннан җиңелүче булып, зарланучы, эчтән янучы булып күренү белән үзләрен һәм игенчеләрне дә ышандырырга тырышучы типлар да бергә күренәләр.

Ләкин югарырак үрләүче сирәк җаннар үзара берничәгә аерыла да башлаганнар. Халыкчы, эсер, эсдек булып, үзара аз-маз бозылышып та алалар. Революция наменә янәдән берләшкәндәй эш (иш) күрәләр.

IV

5 нче елгы революция җиңелә.

Революциягә күңелле өмәгә генә катнашучылар белән революцияне киң рәвештә аңлаучылар һәм шул юлда үзләрен сарыф кылурга хәзерләр аерылалар. Гомумән, революциянең җиңелгән күренеше бик күпләрнең хәлен ала. Күп революциячеләр яңадан урнашкан монархиянең пычрак тырнагы астында янә дә яманрак изелергә мәхкүм[2]. Охранка бөтен мәгънәсе белән эшли. Татар-башкорт арасында болай да азсанлы революциячеләр эченнән дә төрмәдә ятуны гарьлек һәм зур авырлык санап түзә алмаучы җаннар, шулай ук үзенең иҗтимагый-икътисадый мәүкыйгенә бинаән контрреволюция белән барырдай бәндәләр пычрак охранкага да сатылалар, үзләренең элек бергә эшләгән иптәшләреннән качу гына түгел, алар өстеннән төрле ошаклар, донос ясыйлар. Кайбер зәгыйфь җанлы зыялылар үзләрен-үзләре үтерү белән котылу юлын артык саныйлар. Күп кенә бер өлеш «С вином мы родились, с вином мы помрем» җөмләсен гамәлияткә куялар.

Тик Хәбиб, Булат, Габдулла абзый, Урманов, Гәрәй Солтанов кебекләр генә: җиңелгән гаскәрнең хәле башында гына начар

---

[1] Саясендә – күләгәсендә.

[2] Мәхкүм – хөкем ителгән.

була икән, хәзер эшчеләр яңадан уйлана, уяна башладылар» иманы белән «тәҗрибәләргә таяныргга да усал, курыкмас җегетләрне яңадан оештырырга, корал... почта... банка... яшерен басмаханә... көч арту белән шахталарны кузгатырга кирәк. Әйдә, кан елгалары эчендә йөзеп, реакциянең өзелгән башлары өстеннән таптап, революциягә барырга» планнарын төзиләр. Ләкин болар бер генә уч.

5 нче ел революция давылы белән күтәрелеп киткән мәдрәсә дөньясы гына туктамады, шәкертләр восстаниеләре көчәйгәннән-көчәйде. Зурга китте. Монда да реакция катнашты. Мәдрәсәләрдән куулар күбәйгән кебек, мәдрәсәләрдә палитсә тарафыннан тентүләр ясалу гади бер эшкә әверелде. «Мәдрәсәи исламия» типлары «бетте хаклык, калмады шатлык... хакыйкать яклаңыз»,

«. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .»

«Чыгабыз, кузгалыңыз, мәзлүм рафиклар, атлаңыз...» җырлары белән төркем-төркем мәдрәсәләрне ташлый башладылар. Ләкин болар гомумкешелеккә яисә фабрик-завод эшчеләре кузгалышына чагыштырганда көлке иде. Шулай булса да, татар-башкорт өчен аның иҗтимагый-революционный үсүендә зур урын тоталар иде. Милләт, дин намена эш күрүче мөдәррисләр: «Нигә бу чаклы шаулыйсыз? Тавышланасыз... Палитсә көтәсез... Мәдрәсәне – милләт йортын яптырасыз бит!» – дип ялынып карасалар да, чын иман, зур үлчәү белән:

– Ябылсын, кадалсын, мәдрәсәгез... Бу низам, бу тәртип буенча изелгәнче, бозылмаган, яхшы...» – дия алырлык җегетләр дә күренгәли иде инде.

«Безнең көннәр» менә шул күренешләрне генә түгел, ул күренешләрдәге типларның шундый иманда булуларының баш сәбәбе булган типларның иҗтимагый-икътисадый тормышын һәм мәүкыйгларын ачып сала.

V

«Безнең көннәр»дәге руслар кварталындагы исерек рабочий Абдулканың революционер булып әверелүе, аның үсә-үсә иң ышанычлы партийный иптәшләр җөмләсеннән булып китүе белән укымышлы революционер, киселгән бай баласы Йосыфҗанның революциядәге язмышы арасындагы чагыштыру әсәрнең төбенә нинди сыйнфый таш салынганны ачык аңлата дип беләм. Шулай ук Габдулла абзыйның хатыны Заһидә җиңги белән анакасы күбәләге саналган курсистка Рауза типлары да бу нигезнең даими икәнен күрсәтәләр.

Учительский школаның беренче, икенче сыйныфыннан ук куылган Хәбиб Мансуров тибы белән гимназия тәмам иткән Акчулпанов – полковник морзаны алсаң да, әсәрнең тарихи агымында муаффәкыятьле[1] барганлыгын күрәсең.

Әсәрдәге типларның байтагы гомерләрен үткәргән, соңнары беленгән, яхуд[2] көннәренең көзе кергән булу да зур тулылык саналырга тиеш. Дөрест, әле Габдулла абзый Хәбиб Мансур һәм шулар кебек башка берничә типның да ул чагында көзе кермәгән шулай ук яңа нигез белән белем алынырга керешүче камил яшәмәгән, моның өчен исә трилогиянең киләсе икенче, өченче бүлекләре булу канәгатьләндерә дип уйлыйм. Һәм шулай да. Чөнки әле иҗтимагый революция булмаган иде. Аннан соңгы иҗат дәвере дә килмәгән.

«Безнең көннәр» Идел-Урал буендагы шәрыклыларның сәяси, иҗтимагый мәүкыйгларының дөрест бизмәне.

**«Безнең көннәр»** – һичбер арттырмый, киметми **татар-башкорт эшче ярлысының – пролетарский әдәбиятының беренче нигез ташы.**

* * *

Әсәрне беренче укуда иң нык күзгә бәрелә торган кимчелек сыман күренгән бер нәрсә булса, ул да «мәдрәсә» тормышына күп урын бирелүе. Ләкин «мәдрәсә»ләргә ачыграк күз белән каралса, аларның татар-башкортның гына түгел, шул ук Идел-Урал буендагы мәдрәсәләр җимеше Кырым, Кавказ, Кыргызстан, Төркестан, Ерак Себер, хәтта Голҗа, Кашгарларга таралуын искә алынса, һәм моның өстенә, ул дәвернең инде тәмам булган күренеш чыгачагы сыгылып беткән, көзләре генә түгел, кышлары да кергәнлеген, бәлки, бөтенләй безнең арадан югалганлыкларын уйланса, бу үткәнгә тиешле бәһане биреп китү, зур урын алмаган саналырга тиеш!

Икенче, безнең романнарда, гомумән, икътисадый мәүкыйг алынмау, кешелекнең агымындагы иң зур гамил булган промышленность, техникага урын бирмәведер. Ләкин капитализм көннәренә дә кермәгән бер халыкның ул күренешләрен үлчәрлек фактларны җыйнаучы типлар ясап булмый шул. Икенче, өченче бүлекләрендә моны күтәрергә ярый дип уйлыйм.

---

[1] Муаффәкыятьле – уңышлы.

[2] Яхуд – яки.

* * *

«Безнең көннәр» – утыз табаклы, биш йөз битле зур бер китап. Нәшриятка гаид[1] ягы да тулы, иренми эшләнгән. Хәзерге көндә бу рәвешле әсәр эшләнү үзе дә бер шатлык булыр иде.

Татар-башкорт пролетарский әдәбиятының нигез ташы салынды. Шуның өстенә бина салынырга да иман китерәмез.

*Мәкалә педагог, сәяси эшлекле, публицист С. Атнагулов (1893–1938) тарафыннан язылып, 1920 елда «Эшче» газетасының 20 май санында басылып чыккан. Текст басмага әлеге газетадан алынды.*

*Текстны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Гүзәл Батыршина әзерләде.*

*Г. Рәхим*

## «Казакъ кызы»

«Казакъ кызы» дигән хикәясе белән Галимҗан иптәш Ибраһимов үзенең ни дәрәҗәдә әтрафлы[2], киң даирәле бер әдип икәнен тагын бер кат күрсәтте. «Табигать балалары», «Безнең көннәр», «Кызыл чәчәкләр», «Адәмнәр» шикелле кирәк мәүзугъ, кирәк рух вә аһәң ягыннан бер-берсенә башка булган, бер-берсеннән ачык сызыклар белән аерылып тора торган әдәби әсәрләр янына тагын бер матур әйбер өстәлде. «Казакъ кызы»н укырга керешкән кеше беренче битләрдән башлап ук үзенә бертөрле моңарчы татар әдәбиятында булмаган яңа бер хәят, яңа бер шигърият эченә кереп чума да, инде ахыргы биткә кадәр шуның тылсымыннан котыла алмый.

Вакыйга Галимҗан иптәшнең моңар чаклы язган тормышларыннан, татар-башкорт галәменнән бөтенләй читтә, кыргыз-казакъ арасында ачыла, шунда дәвам итә һәм шунда бетә. Бу, бәлки, кайберәүләргә гаҗәбрәк тоелыр: имеш, татар-башкорт арасында туып, үсеп, торып эшләгән бер әдип ни өчен үзенең иң якыннан белгән мохитеннән читкә чыга? Ник әллә кая, ят мохитләргә ашкына? Ул аларны үз мохитен белгән кадәр яхшы белә алырга мөмкинме соң? Нигә казакъ тормышын, дала тормышын, тасвирны яңа үсеп килә торган казакъ әдәбиятына, казакъның үз әдипләренә

[1] Нәшриятка гаид – нәшриятка бәйләнешле, караган.
[2] Әтрафлы – төпле.

калдырмаска? Алар кулыннан ул тагын да чынрак, тагын да дөресрәк булып чыкмас идеме? Менә мондый сөальләр бары тик китапның үзен укымый торып, аның белән чыннан таныш булмаган, коры акыллы башлык белән фикер йөртүчеләрнең генә башларына килергә мөмкин. Юк, әдип бу мәүзугъны сайлап хата кылмаган. Аның каләме астыннан бу хикәя белмәгән бер тормыштан алынып язылган зәгыйфь нәрсә булып түгел, киресенчә, гаҗәп көчле, җанлы, реаль бер әйбер булып чыккан. Дөрес, язучы казакъ тормышы белән таныш, аны күзе белән күреп белгән бер кеше, ләкин шулай була торып та ничек бу кеше бөтенләй ят бер тормышны милли-этнографик яктан гына түгел, хәтта икътисади вә иҗтимагый яктан да безгә бөтенләй ят булган бер тормышны бу хәтле дөрес тасвир итте икән, ничек күчмәле, патриархаль кыргызларның, чын дала балаларының рухына бу кадәр нечкәдән керә белде икән дип гаҗәпләнергә туры килә.

Этнография ягы да шулай ук. Казакъның бөтен матди тормышы, кием-салымы, ашау-эчүе, йорт хәяты, мал багулары, күчүләре, гадәт-йолалары – болар һәммәсе хикәянең барышы, табигый агымы белән бик нык бәйләнгән хәлдә укучының күз алдыннан узалар. Хикәянең барышы белән багланышсыз, коры этнография мәгълүматы булмаганлыктан, алар укучыны тамчы да ялыктырмыйлар, бәлки, киресенчә, хикәягә аеруча тәм бирәләр. Шуның белән бергә казакъның рухани һәм иҗтимагый тормышы да тулы бер картина булып безнең күз алдыннан үтә: казакъ кызы белән казакъ егетенең далача садә һәм табигый сөюләре, кыз урлау, үлек күмү (шунда ук татар «мүлдәкә»ләренең фидия алулары), шагыйрь-акынның җырлавы, кәефле кымыз мәҗлесләре, кабилә дошманлыгы, түрә сайлау интригалары, патриарх-аксакалның оста сәясәт йөртеп, дошманлашып китә язган ыруларны килештерүе... башкалар вә башкалар – болар һәммәсе җанлы картина булып күз алдына килеп басып, һичбер калын җилдле[1] этнография китабы бирә алмастай рәвештә хәтергә киселеп кереп кала торган мәгълүматны бирәләр. Кыскасы гына, «Казакъ кызы»н укып чыккан кеше казакъ халкын бөтен матди вә мәгънәви тормышы, бөтен психологиясе белән таныштым дип әйтә ала.

Иҗтимагый тормыш, иҗтимагый мөнәсәбәтләр ягына килгәндә инде, без бу әсәрдә (әлбәттә, әдәби вә шигъри рамкада гына

---

[1] Җилдле – томлы.

үткәрелгән) түбәндәге моментларны күрәбез: бер яктан, ыру тормышы белән хосусый милек әсасына[1] корылган иҗтимагый хәят, ап-ачык күзгә бәрелә торган икътисади тигезсезлек; меңләгән баш куйлы, елкылы зур байлар, түрәләр, үзләренең «чыңгыз нәселеннән» килүләре белән мактанучы борынгы аксөяк-хан, солтаннарның калдыклары Бай түрә морзалар, Сарсымбайлар белән беррәттән, өстенә кигән сәләмә киеменнән башка малы булмаган, ун ел эшләп тә калым түләргә берничә баш «кара» ясый алмаганга, өйләнә алмый йөрергә мәҗбүр булган, шул байлар тарафыннан эксплуатация астында тотылып та, шуның өстенә тагы исбат ителмәгән гаепләрен икърар кылдырту өчен, эт урынына кыйнала торган пролетарлашкан ялчы-байгыш «Җолкынбай»лар, байлар казанында пешкән иткә читтән генә кызыгып йөрүче, авызларына әллә нидә бер, байның рәхиме килгәндә генә, бер сыгынырлык ит эләгә торган хезмәтчеләр, актык хайваны салым өчен алынып, улы катрга[2] җибәрелгән, шуның аркасында ач-ялангач гидай булып калган, нужа күрә-күрә акылыннан язган Миңди карчык...

Икенче яктан, урыс хакимияте рәвешендә көнбатыштан бәреп кергән, капитализм орлыгын ташучы бер фактор: аның борынгы патриархаль хәятка ясаган зарбәсе[3], шуның тәэсире астында иске кабилә, ыру нигезенә корылган тормышның җимерелүе; түрә-башлык куюда урыс хөкүмәте тарафыннан кабиләләргә бүленүгә игътибар кылмастан сайлау ысулы кертелгәнгә, төрле кабилә-партияләр арасында шул җирлектә низаг чыгуы, ришвәт, сатлыклыкның чиктән ашуы; байларның, үз шәхси үчләрен алу өчен, «урыс түрә»ләргә донос ясап, ришвәт биреп, дошманнарын сәяси эшләрдә гаепләтеп, сөргенгә, катрга җибәртүләре...

Менә болар һәммәсе «иркен, ирекле, тигез, михнәтсез, саф күңелле, гөнаһсыз»... белмәм тагы әллә нинди дип фараз ителеп, шулай итеп күрсәтергә тырышылып килгән дала тормышына һичбер төрле фарази идеал күзлеге аркылы карамыйча, реаль, битараф рәвештә турыдан-туры тенденция вә агитациягә бирелмәстән, тыныч эпика тонында тасвир ителә. Әсәрнең төп әдәби кыйммәте дә менә шунда. Чынлап та, бу әсәр күчмәле төрек халыкларының шундый тыныч, мәһабәт агымлы, саф дала исе аңкып тора торган

---

[1] Әсасына – нигезенә.
[2] Катрга – каторгага (рус.)
[3] Зарбәсе – зыяны.

эпосларын, табигый дала шагыйрьләре тарафыннан тудырылган поэмаларны искә төшерә.

Хикәядәге шәхесләрнең үзара сөйләшүләре, татар теле, татар әйтеше белән язылганы хәлдә, бик оста рәвештә кертелгән казакъ гыйбарәләре, казакъча җөмлә әйләнешләре аркылы казакъ теленең колориты, аһәңе муаффәкыятьле рәвештә бирелгән. Бу әсәр казакъчага тәрҗемә кылынса, аеруча муаффәкыять казаныр иде дип уйлана. Ләкин нинди генә чит телгә тәрҗемә кылынганда да аның әдәби кыйммәте югалачак түгел. «Казакъ кызы» – татар әдибе тарафыннан язылып та, татар галәменең рамкасы белән генә чикләнеп калмастай булган сирәк әсәрләрдән берсе.

*Мәкалә язучы, әдәбият галиме Г. Рәхим (1892–1943) тарафыннан 1925 елда язылып, «Безнең юл» журналының 5 нче санында дөнья күргән.*

*Г. Ходаяров*

## «Яңа кешеләр» турында бер-ике сүз

Октябрь революциясе дүртенче яшькә чыкты. Бу өч ел эчендә, өч йөз ел эчендә була алмый торган зур, дәһшәтле, канлы вакыйгалар булып үтте. Сәүкы табигый (инстинкт. – *автор искәрмәсе*) рәвештә генә булган сыйнфый мәнфәгатьне аңаруы, сыйнфый мәнфәгатьләр өчен көрәшү теләге, бу өч елда реальный бер көчкә әйләнде. Бөтен дөнья халкы бер-берсенә кан дошманы булган ике сыйныфка бүленеп, һәр сыйныф үзенең мәнфәгатьләрен булдыру өчен канлы сугыш мәйданына атылды.

Күп вакытлардан бирле телләрдә әйләнгән «милләт», «дин» дигән нәрсәләрнең, шул канга буталдырылып ясалган агитацияләрнең, шул буяуга буялган фәннең, әдәбиятның көнһеләре[1] һәркемгә мәгълүм булды.

Күп еллардан бирле «идән астында яшәгән» большевизм киң дөньяга чыгып, фәндә, әдәбиятта, сәясәттә вә бөтендөнья матбугатында беренче гражданин урынын алды. Сыйнфый көрәш дөньяны чолгап алды. Сыйнфый көрәшнең кнопкасын каты кулда тотучы большевизм, баррикаданың сул ягындагы кешеләр өчен иман булып әверелде.

Октябрь инкыйлабы сызган шырпы, аз вакыт эчендә чиксез зур пожарга әйләнде.

[1] Көнһеләре – нигезләре, асылы.

Бәлки яратылышыннан бирле, һәрнәрсәгә читтән карап торырга өйрәнгән авыл халкы да революция тәгәрмәченә эләкте. Сыйнфый көрәш иң караңгы почмакларга да үзенең нәрсә икәнен танытты.

Октябрь инкыйлабы киңәйде – ул дөньяны каплады.

Октябрь инкыйлабы тирәнәйде – ул иң түбән катлауларга төшеп, рухта, икътисади хәяттә зур үзгәрешләр ясады.

Октябрь революциясе иске дөньяның бөтен нәрсәсен хисапка алды, бөтен нәрсәне пролетариат мәнфәгате ноктасыннан карап күздән үткәрде. Бик күп иске нәрсәләр яраксыз табылып, ташланырга тиешле табылды. Ташланган иске нәрсәләр урынына пролетариат үзенең иҗади куәсе ярдәмендә яңа нәрсәләр мәйданга китерде.

Пролетариат зәүкына, пролетариат теләгенә хөрмәт итә алачак яңа театр, яңа әдәбият, яңа идеология, яңа фән туды, яки туу юлына керде. Октябрь революциясе сәясәт, икътисад төзелешендә генә үзгәреш ясый торган революция түгел. Бу революция рухта, карашта, иманда, кыскасы, адәмнәрнең кальбендә[1] үзгәрешләр ясый торган революция, Октябрь революциянең бу хосусияте (черта. – *автор искәрмәсе*) инде нәтиҗәләр дә бирә башлады.

Өч ел буена яшен тизлеге белән алмашып, үтеп торган зур вә тарихи вакыйгалар, өч ел буенча дәвам иткән канлы көннәр, рухта, калебтә булган үзгәрешләр үз иманы, үз зәүкы, бу вакыйгаларга булган үз карашы пролетариатның үз әдәбиятында гакес итәргә[2] тиеш иде.

«Яңа кешеләр» – шул ингыйкястан[3] гыйбарәт.

Иске кагыйдә: «әдәбият – хәятның көзгесе».

Өч еллык бер вакыт – тыныч, белемсез, төссез, тонык һәм ялкынгыч хәятны, асты өскә килеп тора торган тирән диңгезгә әйләндерде.

Иске дөньяның көзгесендә ялкынсыз рухлар, сүнек йөрәкләр, иманын югалткан – Алла, изгелек, мәңгелек рух эзләүче, кадаклар, иске чиләк ватыкларын санап, барлап утыручы Плюшкин кебек үзенең иске, таралган рухының вак элементларын, юк-бар настроениеләрен тикшереп утыручы, үзенең хосусый тәэсиратын-

---

[1] Кальбендә – йөрәгендә, күңелендә.

[2] Гакес итәргә – чагылырга.

[3] Ингыйкястан – чагылудан.

да чокчынучы[1] хәлсез кешеләрне, эше юктан эш эзләүче бәндәләрне күрә идек.

Яңа дөньяның көзгесе – яңа нәрсә күрсәтә. Галимҗан иптәш Ибраһимовның «Яңа кешеләр»е Октябрь революциясе тудырган җимешләрнең берсе. Бу әсәр – Октябрь революциясенең тирәнлеген күрсәтә торган үлчәү, бу – өч ел буенча көч, тир, кан түгеп эшләнгән эшләрдән хисап бирү, бу өч ел буенча – меңтөрле манигъларны алып ташлый-ташлый барганнан соң бер мәртәбә артка борылып карау, бу өч ел буенча буталган, кайнаган инкыйлаб диңгезендә бәллүрләнгән (кристаллизацияләнгән) кыйммәтле ташларның матур сурәтләрен куәтле каләм белән тәрсим итү бу. Монда без Октябрь инкыйлабыннан төп максат булган сыйнфый аерымлыкның караңгы авылда хөкем сөргәнен күрәбез. Монда без дөньяның чын хуҗалары булган пролетариатның көчен күрәбез. Монда без иске иманнардан, рухани коллыктан котылган яңа иманлы, яңа әхлаклы кешеләр күрәбез. Мондагы егетләр: «Бу канлы юл – изге юл», – диләр. Мондагы каһарманнар әллә ничә җирдән җәрәхәтле булуларына, җиде ел буенча михнәт, җәфа күрүләренә карамастан, рухының көчен югалтмаган, үзенең дошманыннан үч ала белгән. Дошманы алдында ялыну хурлыгына төшми торган куәтле җанлы, каты куллы пролетарийны күрәбез. Без бу әсәрдә баррикаданың уң ягында калган агасын үтерүче авыл егете Тимеркәйне күрәбез. Бу әсәрдә Карл Маркcның даһилеген бер авыл егете үзенең гамәле белән тасдикъ итә. Әхлак, фән, фикер, рух икътисады тормыштан туган җимешләр. Пролетариат белән буржуаның икътисади тормышлары бер-берсенә башка, кара-каршы булган әйберләр. Пролетариат белән буржуазия арасында уртак икътисади тормыш юк. Бәс, пролетариат белән буржуазия арасында уртак фән, дин, әдәбият, әхлак та юк! Тимеркәй. Пролетарий Тимеркәйнең агасы буржуа, Тимеркәйнең әхлак агасы – буржуа әхлагына бөтенләй каршы. Агасының буржуа булуы, Тимеркәй өчен, урыс әйтмешли – все. Буржуа Тимеркәйгә ага була алмый. Тимеркәй үзенең агасын һич тартынмыйча үтерә ала. Тимеркәйнең хәрәкәтендә, уенда, рухында иске-лек юк. Ул пролетарий, чын мәгънәсе белән пролетарий, бу егетнең мие иске чүп-чардан азат.

«Яңа кешеләр» өч еллык хәятыбыздан туган бер әсәр. Бу әсәр «пролетариат менә шундый булсын» дигән вәгазь, агитация түгел.

[1] Чокчынучы – казынучы.

Бу әсәр – өч еллык революциянең биргән нәтиҗәсен дөрес күрсәтә торган картина.

Әсәренең бөтен кыйммәте революциянең агышын, аның тирән икәнлеген монологсыз, ноктасыз, фәкать рәсми хәрәкәт, вакыйга белән генә күрсәтә алуында.

Милләтче зыялының берничә җилдләр[1] белән язарга лаек булган фаҗигасе ике күренештә тәмам әйтелеп бетә. Өлеләмергә[2] буйсынырга өйрәнгән мулла, ике урындыкка утырып килгән бичара зыялы үзенең сыйнфый мәнфәгатен сизә торган авыл бае, гомер буе үз йөрәгенә тирән җирендә үзенең хуҗасына дошманлык саклаган ялчы – боларның һәммәсе сыйнфый көрәш алдына килеп баскач, бөтен мишуралардан, бөтен хорафатлардан, бөтен ялканнардан пакьләнеп, тик мәгълүм сыйныф кешеләре генә булып калалар. Боларның һәммәсе дә тик мәгълүм сыйныф кешеләре булып кына сөйлиләр, сыйныф кешеләре булып кына хәрәкәт итәләр.

Әсәр – революциянең авылдагы тармагыннан гыйбарәт.

Әсәр – көчле Батырхан, Тимеркәй, мөгаллимә, Шәйбәк бабай – әсәрнең сөйкемле, көчле techmalары[3]. Болар пролетариат. Әсәрнең революция тарафыннан куелган «син кем?» сөаленә һәр сыйныфның ничек җавап биргәнлеген тәрсим итә, әсәр – безнеке, пролетариатныкы. Әсәрдә сызлану, сыктану, икеләнү юк, әсәрдә көч бар, әсәрдә кыюлык бар, әсәрнең җөзьи[4] җитешсезлекләренә игътибар итәргә туры килми.

Галимҗан иптәш Ибраһимовның «Яңа кешеләр»е татар телендә язылган һәм инкыйлабый һәм милли пьесалар тезмәсенең бисмиллалык хезмәтен үтәргә, инкыйлаб әдәбияты нигезендә зур таш булырга ярарлыктыр.

Бу әсәр пролетариат өчен идеология эзләми, монда пролетариатка үзенең иҗтимагый мәүкыйгы[5]тарафыннан тәлкыйн ителгән[6] идеология-художество калыбына салынып, күрсәтелеп бирелә. Монда пролетариатка үзенең идеологиясен ничек итеп гамәлгә кую ысуллары күрсәтелми; монда тик үзенең сыйнфый мәнфәгатьләренә ирешер өчен пролетариатның нинди юл тотканлыгы

---

[1] Җилдләр – томнар.
[2] Өлеләмергә – зур түрәләргә.
[3] Сималары – төсләре, йөзләре.
[4] Җөзьи – вак.
[5] Мәүкыйгы – урыны.
[6] Тәлкыйн ителгән – тәфсилләп аңлатылган.

көзгедәге шикелле күрсәтелеп кенә бирелә. Монда изге максатлар өчен тартышу, сугышуның, кан түгүнең матурлыгы тасвир ителә.

Әсәрнең җөзьияте хакында тикшерүне тәнкыйть сәхифәләренә калдырам.

*Мәкалә мөгаллим, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның Мәгариф комиссары (1931) Галә (Галәэтдин) Ходаяров (1891–1966) тарафыннан язылып, 1931 елда елда басылып чыккан «Галимҗан Ибраһимов әсәрләре»нең 5 нче томында сүз башы рәвешендә бирелгән, текст шуннан алынды (б. 143–145).*

*З.Н. (Заһид Нуркин)*

## Кем җинаяте?

*(Галимҗан Ибраһимовның*
*«Яшьләр хәятеннән бер ләүхә»се мөнәсәбәте белән)*

### I

Күп иде алар.

− Ачык карашлы, үткен хисле, ялкынлы күңелле, укуга бирелгән, халыкка хезмәткә чын-чыннан дәртле, һиммәтле[1] вә өмидле егетләр... Аларның кәгъбәтү җәһләре – гыйлем, гая[2] хыялыйлары да халыкка хезмәт иде.

Халык аларны вә аларның үзенә бирелүләрен тәкъдир итеп, алардагы дәрт чишмәләрен үзенең хәят басуларына, дәртле йирләренә юнәлдерсә, якты «киләчәк»нең маясы[3] хәзерләнгән булыр иде. Ләкин безнең халык аларны тәкъдир итә алмады, алардан йөз чөерде.

Алай гына да түгел, аларның белек вә яктылыкка омтылучы ялкынлы күңелләрен төрле комачаулар васитасы белән сүндермәкче булып, юлларына имкян[4] даирәсендәге бөтен садәләрне[5] җикте, аларны сүкте, ниһаять, арасыннан сөрде: алар, Фатих әфәнденең «Яшьләр»ендәге Газиз кебек, үз башларына чыгып, үзләре акча табып укырга тотындылар. Бер ел урынына 2–3 ел укыдылар,

---

[1] Һиммәтле – ялкынлы дәртле.
[2] Гая – чик, соң.
[3] Маясы – нигезе.
[4] Имкян – мөмкинлек.
[5] Садәләрне – гадиләрне.

ачлы-туклы торып укыдылар. Шулай да укыдылар, дәртләренә хәләл[1] китермәделәр.

Халык аларны арасыннан сөрде, ләкин ... күңелләреннән гыйлем гыйшкын сөрә алмады ...

Тик аларның күңелләреннән үзләре белән бер нәрсә сөрелде, ул да ... халыкка, шушы үзләрен арасыннан сөргән халыкка хезмәт фикере, акрын, йөз мең җәфа соңында гына, ләкин инкяр итәр хәл юк, бу фикер сөрелде, ихтимал, мәңгегә...

II

10 нчы елда матбугат галәменә Галимҗан әфәнде Ибраһимовның бер әсәре – «Яшьләр хәятеннән бер ләүхә»се чыкты.

Бу әсәр, кыйммәт әдәбиясеннән катгы назар[2] илә кагылган иҗтимагый мәсьәләсенең әһәмиятлелеге белән генә дә тирәсендә шау-шу кузгатырга мөтәгаддид[3] мәкалә вә тәдкыйкларга[4] мәүзыйг[5] буларак, матбугат сәхифәләрендә зур мәбахисәгә[6] сәбәп булырга тиеш булдыгы хәлдә, без дә бүтән күп әсәрләр арасында матбуг китаплар хисабында гына зикер ителде, вә Сәгыйд әфәнденең бик гомуми генә берничә сүзе игътибар ителмәсә, үзе хакында бер сүз дә ишетмәде...

Ә ишетергә тиеш иде, чөнки аның кагылган мәсьәләсе – яшьләремезнең халыкка хезмәт фикереннән бизүе, Галимҗан әфәнде тәгъбире белән әйтсәк, аларның «үзем» тәртәсенә җигелүедер... Моның өстенә, яшьләр мәсьәләсенең һәрвакытта шушы яшьләр мәнсуб[7] булган халыкның истикъбале[8] мәсьәләсе булуын, һәм гаеп үзләрендә булмаса да, алар өчен бик үк күңелле дә булмаган бу мәсьәләнең эчләреннән берсе тарафыннан, димәк, бу тугрыда тәмам хәбәрдар вә сүзе салмаклы булырга тиешле кеше тарафыннан кузгатылуын хәтергә алсак, бу кечкенә генә әсәрнең нинди зур әһәмият вә җәдит белән каршы алынырга тиешлеге күз алдына килергә кирәк, зан итәм.

---

[1] Хәләл – зарар, кимчелек.
[2] Катгы назар – карамастан.
[3] Мөтәгаддид – берничә санлы.
[4] Тәдкыйкларга – тикшерүләргә.
[5] Мәүзыйг – урын.
[6] Мәбахисәгә – бәхәскә.
[7] Мәнсуб – куелган.
[8] Истикъбале – киләчәге.

Руслар: лучше поздно, чем никогда (бер дә булмауга күрә, соң булса да, булу яхшырак) диләр. Мин дә, соң булса да, бу әсәрне күздән кичермәкче булам.

III

Менә «Яшьләр хәятеннән бер ләүхә». Менә аның тормыш дулкыннары арасында халыкка, гомумгә хезмәт фикерләреннән аерылган каһарманы – Сәлим.

Ул – яшьләрнең берсе.

Мөхәрриринең тәкъдиме вә хикәядә күренүенчә, ул «фәгъгаль димаглы, үткен вә гали рухлы бер егет».

Яшьләрнең[1] һәрберсе шикелле, Сәлим дә гыйлем гашыйкы, хәзер дә аның ниһаясез дәрденә хәләл килмәгән:

− «Урамнан үтеп барган яки университетка кереп чыгып йөргән бер студентны күрү аның гыйбта[2] хәсән уята» ул үзенең кәгъбәтү җәһәте[3] булган университет янына килгәч, сихерләнгән кеше шикелле, аерыла алмыйча «акрын-акрын гына аның дүрт ягыннан әйләнә» вә моның белән генә дә кифаяләнмичә[4], номерына кайткач тәрәзәдән университетка карап әйтә: − «Сакалым агарыр, билем бөкрәер, ләкин мин, сау булсам, шул бинага бервакыт әгъза булырмын», − ди.

Фәкать хәзер дә гыйлем аңарга «гүзәл тормыш»ка васита булганлыктан гына кирәк, хәзер дә ул алган гыйлеме белән халыкка хезмәт итүне күңеленә дә китерми...

Ә вакытында ул да халыкка хезмәт фикерендә йөргән, хәтта үзенчә хезмәт тә иткән.

Ләкин вакытында шул.

Хәзер инде ул вакыт үткән. Хәзер «алар» андый фикерләрдән көләләр генә, «алар» үзем тәртәсенә җигелгәннәр. Шулай да Сәлимнең гали рухы моның белән килешеп йитә алмый, аның рухының иң төбендә генә хәзерге хәленнән наразыйлык чаткысы саклана, кайчан-кайчан бәгъзе бер көчле тәэсирләр сәбәпле, ул чаткы үзен сиздерә, Сәлимнең җанын рәхәтсезли.

Менә Җәлил белән булган ахыргы мосахәбәсеннән[5] соң бу чаткы тәмамән куәтләнә дә, Сәлим әрнешә-әрнешә шул сүзне әйтә:

---

[1] *Монда сүз мәдрәсәдән чыгып, русча укуга бирелгән яшьләр турысында.*

[2] Гыйбта – берәүдәге яхшы якларны күреп үзендә дә шуны булдырырга теләү.

[3] Җәһәте – ягы, тарафы.

[4] Кифаяләнмичә – канәгатьләнмичә.

[5] Мосахәбәсеннән – кара-каршы сөйләшеп утыруыннан.

– «Кайчан мин хәзерге былчырак максатларымнан пакьләнерем дә, әүвәлге идеяләрем, гали максатларым вә мәелләрем[1] үземә кайтыр, кайчан мин үземне ислах вә тәрбия итеп, шул ноктага йиткерер, шул заман минем гомеремдә иң мөһим бер период булыр вә шул көн минем өчен бәйрәм булыр», – ди.

Шул кадәр сүзләрдән дә аңлана ки, Сәлимдәге эчке инкыйлаб садә генә, тыныч кына булмаган, юк, ул шиксез зур-зур тәрәддедләр[2] вә көчле эчке көрәш – фикерләр көрәше соңында гына булган.

IV

Соң бу эчке инкыйлаб ничек вә нинди мөәссирләр[3] тәхетендә вөҗүдкә[4] килгән?

Менә миңа калса, иң әһәмият бирелергә тиеш булган вә әсәрнең чын әдәби булып чыгуы өчен, мөхәррир тарафыннан иң зур мәһарәт әдәбия белән күрсәтелергә мохтаҗ булган нокта – шушы ноктадыр.

Ләкин, Галимҗан әфәнде, мәгаттәәссеф[5] бу ноктаны бөтенләй иһмаль итә[6], шулай итеп әсәренең әдәби әһәмиятен җуя диярлек; фәкать аның белән әсәрнең иҗтимагый әһәмияте кимеми, тик, «ник болай булган. Ничек ул, Сәлим, идеалсыз калган?» сөаленә җавап үземез бирергә генә тиеш буламыз.

Эзләсәк, моңа ишарәләр әсәрдә дә табылачак. Җәлил белән мосахәбәсендә Сәлим әйтә: «Мин ихтиярән[7] бу юлга кермәдем, **мине мәгыйшәт кысты**», – ди.

Менә бу соңгы җөмлә безгә күп нәрсә сөйләргә, бу җөмлә эчендә күп җөмләләр укылырга тиешле...

Аны, Сәлимне, мәгыйшәт кыскан.

Киләчәгенең маясене мәгыйшәт шул чаклы кысканда халык, милләт ни эшләгән? Аларга ярдәмгә йитешкәнме? Аларны җуатканмы?

Юк... Халык яшьләрне сүккән, аларга нәфрәт күрсәткән, аларны арасыннан сөргән...

---

[1] Мәелләрем – кызыксынуларым, теләкләрем.
[2] Тәрәддедләр – икеләнүләр.
[3] Мөәссирләр – тәэсир итүчеләр.
[4] Вөҗүдкә – барлыкка.
[5] Мәгаттәәссеф – үкенечкә каршы.
[6] Иһмаль итә – әһәмият бирми.
[7] Ихтиярән – үз ирегe белән, ирекле рәвештә.

Шулай булгач, бу:
− Кем җинаяте?

*З.Н.*

Соңыннан: бу мәкалә «Яшьләр хәятеннән бер ләүхә» әсәренең дөньяга чыккан елында язылса да, берничә сәбәп илә матбугатка чыгарылмаган иде. Күптән түгел, бу хакта «Ил» һәм «Вакыт» газитәләрендә җитди фельетоннар чыкты да мәсьәлә соң булса да кузгалгандай күренде. Мин дә шул мөнәсәбәт илә күптән язылган мәкаләмне чыгармак булдым.

*Мәкалә журналист, тәрҗемәче Заһид Садретдин улы Нуркин (1888–1966) тарафыннан язылып, 1914 елда «Аң» журналының 4 нче санында басылып чыккан. Текст шуннан алынды.*

*Текстларны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Г.Н. Зәйниева әзерләде.*

*Габдрахман Сәгъди*

**Галимҗан Ибраһимов иҗатында типлар эволюциясе**

Дауд Урманов (Зәки + Сәлим = Дауд Урманов)

Галимҗан Ибраһимов иҗатында байтак типлар иҗтимагый-фикри эволюция кичерәләр: бер үк төрле типлар аның төрле әсәрләре аркылы фикердә дөньяга карашда баскычлап үсә, үстерелә баралар.

Бу – аның иҗадында күзгә нык фашланган аерым хосусыятьләрнең[1] бересе.

Бу типлар безнең өчен башка типларына караганда тагын да аерым әһәмиятлеләр. Шуның өчен болар аеруча ныклаб, тәфсилләб тикшерелеб үтергә тиешлеләр.

Боларның әһәмияте ике яктан: бердән – алар әдибнең иҗад психологиясенә баглый: алар безгә шул якны ачуга ярдәм итәләр. Икенчедән, алар үзләре аркылы мәгълүм бер дәвер эчендә (1905–1917 арасында) татарның иҗтимагый фикере үсүендәге тарихи баскычларны күрсәтәләр, шул дәвер өчен алар татар дөньясында бик характерлы һәм бик табигый булган типлар.

---

[1] Хосусыять – үзенчәлек, аерымлылык.

1905 нче ел революциясе белән октябрь революциясе арасындагы дәверебез эчендә күб баскычлы эволюция үткәреб килгән шул ук типларның эволюциясе әле октябрьдән соң да һаман дәвам иткәнен искә алсак, Галимҗан иҗадындагы ул типларның әһәмияте тагын да яхшы ачыла төшәр. Андый типларны без хәзерге дәверебездәге гамәли тормышыбызда аз очратмыйбыз. Хәзерге иҗтимагый-фикри хәрәкәтебездә карт буын эчендән сәвитләшеб алгы сакда баручыларның күбләре шул ук Галимҗан иҗадындагы байтак типларның шәрехләре яисә шуларның җанлы үрнәкләре була алырлар.

Галимҗан иҗадындагы андый типларның барын бергә тезеб тикшереб чыгу өчен бу мәкаләдә урын сыйдырмый. Шуның өчен башкаларын икенче вакытка калдырыб, хәзергә бу якдан әдибнең иҗадында иң әһәмиятле типларның берсе булган Дауд Урманов тибын гына бер кадәр тикшереб үтү, шуның эволюциясен бер кадәр ачыб бирү белән генә канәгатьләнәбез.

Әдибнең «Безнең көнләр» романында зур урын алган бу тиб Зәки («Зәки шәкерднең мәдрәсәдән куылуы»), Сәлим («Яшьләр хәйятендән бер ләүхә[1]» һәм «Яшь йөрәкләр»нең) йәкүне[2] яисә йомгагы. Ягъни ул шул баскычларны үтеб мәгълүм бер ноктага утырыб алган иҗтимагый-психологик бер тип. Ул шул ук Зәкинең мәгълүм бер дәвер эчендә иҗтимагый-фикри якдан төрле баскычлар аша һаман туктаусыз үзгәрә, күтәрелә килеб ирешкән иң соңгы үсү, каралану ноктасы.

Шулай булгач, тикшерүне элек Зәкидән башлыйк.

– Зәки кем?

– Зәки иң элек татарның «кадим» мәдрәсәсендә унбиш ел ятыб, шунда иске бозык тәрбия алган. Схоластика белән сугарылган бер шәкерт. Укылганлары: сарыф[3], нәхү[4], (гарәбчә) мантыйк[5], кәлям[6], осул[7], фәраиз[8] һәм азрак мохтасар.

Башда ул шул мәдрәсәдә «чын иске татар шәкерте» булыб әверелә, иске мәдрәсәнең бөтен авыр кызганыч, һәлакәтле тормышын

---

[1] Ләүхә – күренеш, картина.

[2] Йәкүне – тупламны, гомумиләштерелешне.

[3] Сарыф – морфология.

[4] Нәхү – синтаксис.

[5] Мантыйк – логика.

[6] Кәлям – сүз, сөйләм.

[7] Осул – нигезләр, нигез кагыйдәләр.

[8] Фәраиз – варисларга мирасның күпме тиюен билгели торган кагыйдәләр; фарыз – үтәлүе тиешле булган бурыч, эшләнми калмаска тиешле эш.

тәмам башдан кичерә. Аның мие тәмам иске кара фикер, тәгассыб[1] белән тула. Йөрәге бозык хисләр оясы булыб әйләнә. Иске мәдрәсә шәкердләре эшли торган бөтен тәрбиясезлек, мәдәниятсезлекләрне, бөтен ахмаклык, кабахәтлекләрне, «вәхшәт» ләрне ул да эшли башлый.

Шуның белән бергә, ахырда, ул иске мәдрәсә шәкердләренең элек характерлы сыйфатларындан булган һәм алар арасында «галим»лекнең иң ачык бер галәмәте саналган югары бер дәрәҗәгә – «моназир»лык[2] дәрәҗәсенә йөрешә.

Безем Зәки дә моназарә[3] өчен соң дәрәҗәдә тырышуы белсә дә, белмәсә дә өстәл суга, акыруга өйрәнә башлады. Шәкердләр арасында иң мактаулы вә яхшы эш белсә дә, белмәсә дә, хата булса да, туры булса да үзенең алга алган сүзене ташламау, хатасыны игътираф[4] итмәү улдыгындан, безнең Зәки дә үзенең сүзене бирмәскә, әллә нинди ялган, хата булса да, шул сүз өчен кычкырышуга вә туктаб калмаска иҗтиһад идә, тавышы беткәнчә кычкырыша вә сүгешә иде. Сүгешкән саен шөһрәтле, дәрәҗәсе артыгындан, һәммә шәкерт Зәкине мактый башладыкларындан, Зәки бигрәк дә моназарәгә мәхәббәт куйды. Алла биргән көн иртән тора да, моназарә вә сугышуга башлый да һәр көн 5–6 кеше белән сүгешмичә калмый иде. Бара торгач Зәкигә сүгешү табигый булыб китде. Зәки моназарәгә вә сүгешүгә мәхәббәт вә кәмали иҗтиһад белән Исагуҗыдан башлаб Шәмсияи сөәлләм, тәгъзиб, гакаид, тәүәззих вә Муллаи-җәләбиләргәчә укыды. Үзенең зирәк вә тырышлыгы (курсив минеке. – *Г.С.*) вә моназарәчелеге сәбәбле бу мәдрәсәнең иң галим вә иң беренчеләрендән булды, үзенең фаразынча хәзердә Зәки мәхдүмгә беленмәячәк һич гыйлем юк.

Мондан соң Зәки өчен һич гыйлемне остазга үтенеб укуның кирәге юк.

Нинди генә гыйлем булса да үзе караб беләчәк иде.

Зәкинең шөһрәте бу мәдрәсәдә генә калмады, башка мәдрәсәләрдә җәелде. Зәкигә моназарәгә килә вә үзене дә моназарәгә чакыра башладылар. Бу шәһәрдә ничә мәдрәсә булса, һәммәсенә барды, сөйләшде, галәбә итде. Ялгыз «гыйльмия» (тырнак, курсив минеке. – *Г.С.*) дигән бер осулы җәдидә белән укыта торган

---

[1] Тәгассыб – фанатизм.

[2] Моназир – бәхәсләшүче, сүз көрәштерүгә оста кеше.

[3] Моназарә – бәхәсләшү, сүз көрәштерү.

[4] Игътираф – үзенең гаебен тану, әйтү.

мәдрәсәгә алар берни белмиләр, бер ни аңламыйлар – диб бармый иде («Зәки шәкерднең мәдрәсәдән куылуы»).

Зәки шәкерднең, шулай ук шуның аркылы Даудның, иске мәдрәсә тәрбиясе җимеше булган беренче портретын күз алдына китерү өчен әдибнең тасвирындан алынган әнә шушы төзәтмәләр бик җиткән.

Менә шушы Зәки, үзенең бәхетенә каршы, әллә нинди бер эш чыгыб, аңга кичте – «Гыйльмия» мәдрәсәсендә торырга тиешле була.

Ярар, шушы җәдид мәдрәсәнең шәкердләре белән сөйләшә, бәхәсләшәләр. Тегеләр Зәкигә яңа фикер салырга тырышалар. Берничә утырышлардан ук тегеләр тарафындан юнәлтелгән яңа фикерләр Зәкинең миенә салырга итә башлыйлар. Зәкинең мантыйк хакындагы игътикады[1] бер аз гына булса да йомшара башлый.

Зәкинең әлеге җәдид мәдрәсәгә икенче баруында (хәлфәсе Мөбәрәкҗан белән бергә булалар, Хәлфә алар белән бәхәскә килгән була) аның мантыйкка мәхәббәте тәмам кими. Кыскасы, бу соңгы мәҗлесе Зәкигә ничә айлар әдәбият укыб алмаячак фикерне урынлашдыра.

Ахырда Зәки, хәлфәләре тыюга карамастан, яшерен рәвешдә һаман һәр атна шул җәдид мәдрәсәгә йөри башлый. Монда җәдид шәкердләр Зәкигә һәр төрле романлар, мирьатлар[2] тәрҗемәләр бирәләр, ки Зәкидә боларны ләззәтләнеб укый вә мәгълүмат ала.

Нәтиҗәдә Зәкидә чындан фикри уяна башлана: «Үзенең булган мәдрәсәсендәге бу укышны үзенең вә ибдәшләренең нә кадәрле нәрсә белгәнлегене тикшерә башлый. Бер тарафдан гыйльмия шәкердләре илә сөйләшеб, әдәбият укыб вә бер тарафдан мәдрәсәдәге шәкердләрнең хәлләрен караб, укуларының бик начарлыгыны, мәдрәсәләр ислахка соң дәрәҗәдә мохтаҗ идекене төшенә башлый, хәтта аңлаб җитә.

Зәки бу турыда кайбер якын ибдәшләренә – «бер кадәрле истигъдадлы[3] таләбәләргә[4] дә яшерен рәвешдә фикер тарата башлый. Бер кыш шулай үтә, яз була. Көз җитә. Зәки килеб инде игълям[5] юлында көрәш башлый.

---

[1] Игътикады – ышануы.
[2] Мирьатлар – журналлар.
[3] Истигъдадлы – сәләтле, булдыклы.
[4] Таләбәләргә – укучыларга.
[5] Игълям – аңлату, белдерү.

Яз булды. Зәки кайтыб китде вә җәйне бар гомерене әдәбият укыб вә һәр төрле зиялы вә фикерле әдәмләр илә сөйләшеб үткәрү сәбәбле Зәки бик яхшы фикер хасыйль итде. Көз көне мәдрәсәгә килгәндә, остазларның ай-баена карамаенча, гомуми шәкерткә ихлас лозүме вә мәдрәсәләрнең начарлыгы хакында сүз сөйләячәкмен, мантыйкның астын өскә китерәчәкмен диб кулларыны сызганыб килде. Мәдрәсәгә килүе илә укышларны тәнкыйд идәргә вә бу дәресләрне ташлаб заманага муафикъ[1] рәвешдә итеб гомуми диния вә фөнун[2] укырга кирәклекне сөйләргә башлады. Зәкидә табигый уларак сүзгә вә төшендерүгә бер осталык һәм дә мөхәммиз[3] кешене ригая[4] итмәүчелек бар иде. Шул сәбәбле шәкердләр арасына бик яңа ислях[5] фикере тарала башлый («Зәки шәкерт»).

Соңгы нәтиҗәдә мәгълүм: ахырда Зәки шушы хәрәкәте, иске фикергә каршы көрәшеб, яңа фикер таратуы, исляхчылыгы өчен хәзрәт һәм хәлфәләрнең карары белән мәдрәсәдән куылыб чыга, куылганда: – «ислях бер хакыйкатьдер. Хакыйкать бер аз заман кичексә дә һаман Заһир булмый калмаячакдыр». «Сез хәзрәтләр әллә нинди корал илә карышсагыз да исляхның дөньяга чыгуыны туктата алмаячксыз» дип чыгыб китә.

Менә әдибнең шушы Зәки аркылы биргән беренче портреты мәдрәсәдә тәрбияләнеб дә 1905 нче ел революцияс тулкынлары тәэсире белән күтәрелгән һәм татар иҗтимагый хәрәкәт тарихында бик әһәмиятле урын тоткан бөтен исляхчы шәкердләрнең беренче портретыдыр. Шуның өчен моңа аерым әһәмият белән күбрәк туктала төшдек.

Боларның бер өлеше Зәки шәкерднең янә шушы беренче эволюция баскычында исляхчылык, милләтчелек ноктасында катыб калган булса (мәсәлән, «Безнең көннәр»дә Нигъмәт карый), икенче бер өлеше «Яшьләр хәйятендән бер ләүхә» һәм «Яшь йөрәкләрдә»ге Сәлимләр баскычына күчеб, шулар портретына әйләнеб, иң ахырда Дауд Урманов тибында октябрьгәчә булган эволюцияләрнең соңгы баскычын күрсәтделәр.

---

[1] Муафикъ – туры килгән, урынлы.
[2] Фөнун (фән) – аерым фән.
[3] Мөхәммиз – бераз исрек; шәпләнеп йөрүче надан.
[4] Ригая – кайгырту, олылау.
[5] Ислях – үзгәртү, реформа ясау.

Шулай Зәки үзенең эволюциясендә ахырда килеб «Яшьләр хәятендән бер ләүхә»дәге Сәлимгә әйләнде. Аның соңгы баскычлары шуның портретында күренде.

– Соң Сәлим – кем? Аның ничә төрле портреты бар?

Менә хәзер шуны караб тикшереп үтик. Сәлим әүвәл:

– Бик саф вә халис милләтче.

Андан соң:

– «Ватаным бөтен җир йөзе, милләтем бөтен бәни бәшәр»че ягъни социалистик «халык хадиме».

Андан соң:

Тагы реакция тәэсире астында идеясез, идеалсыз калучы: «үзем тәртәсенә җигелүчеләрне шул хәрәкәтләрендә бик хаклы санаб, үзе дә ихтыярсыз» шул юлга бирелеб китүче. Бу Сәлимнең портреты инде, күзләре аркылы үзенең әүвәлге «идея»ле «халык хадиме» булган, булырга җилкенгән чакларын «хыялы чаклар», ул вкытларны да «вакытлы искән җил» диб уйлаганын ниндидер бер «наразыйлык[1] чаткысы» аркылы сиздереб торалар.

Иң соңында бер оптимист иптәш Җәлилнең тәэсире белән әлеге портретның:

– Рухының төбендәге наразыйлык чаткысы куәт алыб «шуның белән азабланучы һәм ахырда үзенең ике дәвердәге рухани ләүхәсен тәдкыйк[2] иткәч», ул үз үзендән бизеб, теге наразыйлык чаткысы» анда тәмам көчәеб алган Сәлимгә әйләнгәнен күрәбез. Бу Сәлим инде «идеаллы дәвере вә андагы мәкасыйде[3] гүзәл вә сөемле бер фәрештә кебек аның мәхәббәтен җәлеб кыла; соңгысы исә мөҗәссәм бер иблис кебек кабих[4] күренеб аны җирәндерә» торган бер Сәлим булыб күренә.

Сәлимнең шушы соңгы эволюция ноктасы исә аның иң ахырда:

– «Кайчан мин хәзерге былчырак максадлардан («үзем тәртәсенә җигелүчеләрдән. – *Г.С.*) пакълаб, әүвәлге идеалларым» гали максадларым вә мәйелләрем үземә кайтыр; кайчан мин үземне ислях вә тәрбия итеб шул ноктага җиткереб – шул заман минем гомердә иң мөхим период булды» шул көн минем өчен мөкаддәс[5] бәйрәм булыр» дигән фикергә (Толстойчылык фикеренә. – *Г.С.*)

---

[1] Наразыйлык – разый булмау, риза булмау, канәгатьләнмәү.

[2] Тәдкыйк – берәм-берәм нечкәләп тикшерү, җентекләү.

[3] Мәкасыйде (мәкъсады) – максаты, алга куелган бурычы.

[4] Кабих – әшәке, начар, алама.

[5] Мөкаддәс – изге, бөек.

килүендән гыйбарәт булыб кала иде. «Яшь йөрәкләр»дәге Сәлимгә бер күз ташлаб үтик.

Бу Сәлим дә иске мәдрәсә шәкерте. «Ул бу вакытларда кызылларга катышып халык эше белән дә йөри». Ул ничә еллар атасы белән бозылынышыб йөргән» булса да, ахырда атасына кайтыб, «килешеб, авылда тора башлый».

«Халык, милләт, хезмәт дигән сүзләрне ычкындырсалар, күб вакыт йөзен сыта, кашларын җыера да, кул селки, икенче якка борыла; йәйсә тфү, диб, чыгыб китә» торган була («Яшь йөркләр», 33–230 битләр).

Бу Сәлим татар турында аеруча писсимист. Ул татар ашын ашаган, яшәгән, инде картаеб хәле беткән; хәзер ул әҗәле табигыйсын көтә һәм аның килүе табигый, катгый...» диб карый. «Аңа тыныч кына үләргә ирек бирергә кирәк», чөнки «хәзер ди яшәү юллары бик авыр, бик күб таланыб, бик күб көч, бик күб гайрәт тели боларның һич бере татарда булганы да, буласы да юк .... бәс ...[1]» ди.

Бу Сәлим ахырда «бик зур җәфага төшкән адәм сынлы уйланыб, борчылыб йөри-йөри дә, иң чигендә үзен үзе үтерү белән эшен тәмамлый. Үлгәндә калдырган язуында шушы характерлы сүзләре бар.

– Алтатарымны үзем корыб, чикәмә үзем төзим... минем өчен, әлбәттә, кайгырмассыз, чөнки мин күбдән үлек идем...»

Бу Сәлимнең үзен үтерүенә дә ибтәшләре аның өчен табигый бер эш диб карыйлар:

– Гүя аның теге елларда үзен, шәхсиятен онытып, үз дөньясын ташлаб башы-аягы белән мәсләгем» дигән юлына чыгуы һәм дә ул көнләрдән бераз заман үткәч, дөнья басылгач, байтак дәверләр кичергәч, шул ук Сәлимнең хезмәт дигән, мәсләк вә халык» дигән сүзләрене үзе авызга алу түгел, кешедән ишеткәндә дә каш җыерыб, кул селкеб, икенче якка таба борылып китүләре белән хәзерге нәлякате – кара, караңгы һәм ямьсез көзге төндә, ялгызы арыга барыб тыныч кына хәятдән китүе арасында табигый бер бәйләнеш бар. Гүя бу – шулай булмый мөмкин түгел иде...» диб уйлыйлар.

Сәлимнең ибдәше Кәрим исә әлеге калдырган язу астына:

– «Мин күбдән үлек идем» дисең, кайчандан, нинди дәверләр соңында !? Теге хәятдә бердәнбер максад итеб, шуның *кодсияте*

---

[1] *Күп нокталар текстның үзендә.*

алдында даимән табынмакда булган иман вә идеалыңны югалткан көндән бирлеме?» диб языб куя.

Менә болардан бу Сәлимнең «Яшьләр хәятендән бер ләүхә»-дәге идеясез, идеалсыз каман, «үзем» тәртәсенә җигелгән, ләкин ахырда рухының төбендә наразыйлык чаткысы» куәт ала барыб, хәзерге былчырак максадларындан» бизеб, ахырда мокаддәс бәйрәм» көтү белән сулыш алучы Сәлимнең үзе икәнен инде аңлавы кыен булмас.

Димәк, шулай итеб «Зәки шәкерт»лек портретындан үзгәреб, ничә баскычлы эволюция кичереб килеб дә, «Яшьләр хәйятендән бер ләүхә»дәге Сәлимгә әйләнүче портрет ягъни әле соңгы хәле караңгы калган Сәлим – әдибнең «Яшь йөрәкләр»романында алына. Ләкин монда инде ул «наразыйлык[1]« белән үзен-үзе һәлакъ итүче булып әйләнә. «Безнең көнләр»дәге Давытта исә бу үлү, тәндән хаят көчен югалу дәрәҗәсенә барып җитми. «Рухан улудан тукталып торып, соңыдан яңадан үрелеп китә. Ләкин анда да аның соңгы хәле мәгълүм түгел.

* * *

Инде Давытка күчәргә вакыт. Давыт та иске мәдрәсә шәкерте. Зәки кебек аның да беренче фикере уянуы шундан башлана, ул да, Зәки шикелле үк, Рәшитнең «Миръат»[2]ларын, Габдулла Бубиның «хакыйкатьләрен», Ризаның «Асар»ләрен, Күлтәсинең «Хаят Җәдидә»ләрен укый һәм шуларны шәкертләр арасына тарата. Җәдитче һәм җир түгәрәк дип ышанучылардан була.

Кыскасы, Давыт әүвәл «Зәки шәкерт»дәге кебек үк: «исляхчы, тәрәкъкыятче, «Мөхәммәд Габдүһүчелек» юлындагы бер җәдитче. Аның каршында ялгыз ислам дөньясы – мөселманлар бар. Андан соң ул «Яшьләр хәятын»дагы Сәлим кебек үк «Саф милләтче» – аның алдына инде «мөселманлар» урынына «Татарлар», «Солтанлар» урынына «Чынгызлар» килеп баса.

Иң соңында исә шул ук Сәлим шикелле үк милләтчелек баскычыннан үтеп:

– социалист, социалист революционер. Ул хәзер Габдулла белән Иванны аермаучы. Ул инде кешеләрнең «буржуа белән пролетариат, талаучы белән таланучы»га бүленүен генә аңлый. Шундан башканы ул белми дә, ишетми дә.

---

[1] Наразыйлык – разый булмаган, риза булмаучы.

[2] Миръат – көзге.

– Мәсьәлә яхшы ачылсын өчен Давытның үзен тыңлыйк. Ул менә нәрсә ди:

– «Мин аңарчы дөньяда мантыйкдан башка кәмаләт[1] табу мөмкин түгел дип, барлык хәятеңне шул мантыйк, схоластика юлына корбан итүдә булса да, бу игътикадның, бу дөньяның тыгыз, юеш һәм иске һавасы мине тончыкдыра башлаган иде инде. Мин иптәшләрем арасына Рәшид казыйның миръатларын, Габдулла Бубиның хакыйкатьләрен, Риза казыйның «Асар»ы белән Күлтәсинең «Хаяте» җәдидләрен яшертен тарата, ысулы җәдид, түгәрәк-фәлән дип сөйләү өчен «Дәһри кяфир...[2] миссионер» исемләрен дә ишеткәли идем.

Минем инде низамлы мәдрәсәләрнең беренә китәргә карарым иде. Ләкин язны көтәсем килә, мәдрәсәләрдән куылу исеме анама начар тәэсир итәчәк булганга, миңа бераз яшерергә туры килә иде».

Беркөн Фатих Кәрими белән урамда сөйләшеп торганымны Йосыф җан күреп кала. Беләсең ул вакыт кадим галәмендә Фатих Кәрими исеме кяфирдән яман ишетелә, анардан иблистән качкан кебек качу лязим. Аның исемен, әсәрен, фикерен телгә алу дини җинаять санала иде. Минем бу җинаятем хәзрәткә ирешкән. Мин аң өчен җавапка, җәзага тартылам».

«Мин китәргә җыендым инде. Бу мәдрәсәгә яңадан килмәскә карар биргәнмен» («Зәки шәкерт»дәге кебек үк, ипдәшләре җайлап өйрәтеп калалар).

Менә бу мисаллар («Безнең көннәр», 177–183 битләрдә) Давыдның беренче портреты нәүбәттә шул ук Зәки портреты икәнен күз алдыбызга бастыралар.

Сезнең кебек мин дә иске татар гаиләсендә иске тәрбиядә яшәгәнен, сезнең кебек мин дә кадыйм мәдрәсәләрнең берендә бәлки иң мөтәгассыйбләрендән[3] саналган мәшһүр Нури хәзрәтдә егермегәчә тәхсилдә булганында, мин дә бер вакытлар һәр искелек мөкаддәс һәрбер яңалык көфер вә бидгать игътикадендә идем. Мантыйк белән калям мөмкин кадәр югары ашу минем гаям иде[4]. Бу вакытларда дөнья вә хәйатдан сагый тәсаувырым миңа үзебезнең дин китапларыбыздан алынып, намазлыктан төшми тәсбих тартып утырган әбиләрнеке белән бер төсле иде.

---

[1] Кәмаләт – җитешкәнлек, тулылык, өлгергәнлек.

[2] Автордагы күп нокта.

[3] Мөтәгассыйб – фанатик, берәр эшкә бик нык бирелгән кеше.

[4] Гаям – идея.

Лəкин болар мине бара торгач тончыкдырдылар, күзне ачып дөньяга узмыш карый башлау белəн минем бу, бетəргə дəҗҗал көтəргə мəхкүм ясаган ихтикадым каршы башлады.

«Андан соң шул, табигый дəверлəр бу бер вакыт ислахчы шəкерт: мəдрəсəлəр начар, миллəт артта, безне схоластика, харап ит, мəдрəсəгə яңа низам булсын, тəфсир, хəдис, гарəбият, урысча, тарих, җəгъръафия укылсын дим. Шундый үзем кебек китекле якалы казаки киеп, чəчне кире сыпыра төшеп йөри башлаган мөтəрəккый ипдəшлəр белəн караңгы тыкрыкларга качып тəмəке тартам. Фикерсезлəнəм, хəлфəлəр сүгəм... .

«Килəм мəдрəсəи исламиягə. Иң беренче гыйльме-ислам тарихы, фəлсəфəи, диния һəм Коръəн тəсфире». «Мин яңа фикерлемен, лəкин ихтикадым бик кямил». «....мин шулай игътикад кылдым. Мөхəммəд Габдухү вə Əнгани минем идеалым. Мин үземне шуларның өченчесе ясарга тели идем».

«Лəкин ул минем фикри тəкəммелемнең[1] күп баскычларындан буы булып калды (205–207 б.). Менə болар инде Зəкинең шул ук Давыт өчен беренче эволюция баскычы булганын бөтенлəй ачалар, шуннан инде икенче баскычларга күчелə:

«Мин монда тукталып калмадым. Тагы югары атладым. Яңа галəм ачылды: без ник бетдек. Без нинди юл тотарга тиеш? – сөəленə минем күз алдымда ачылган яңа фикер вə хаять галəме... .

Безне ислам бетерде, дин бетерде, залим хөкүмəт бетерде дип – җавап бирде. «...лəкин тарих һəм хəзерге хəятнең барышы миңа хəзерге заманда «Дин, үзенең җамигалек сыйфатын югалтканын, хəзер дин белəн миллəт аерылганын əйтде. Бу заманның халклары бигрəк «миллият» телəге астына җыелырга мəҗбүр булырларын ачык күрсəтте. Шуның белəн бергə миңа «мөселманлар» җирле «татарлар», Багдад, Куртаба, Гранати (Гарнати), Андалус, Харун Рəшидлəр урынына Əл-Кайы, Алтын Урда һəм Чынгызлар күренə башлады. Əл-ахыр ничекдер икенче планга кичеп, мин Сөембикə манарасының салкын ташларына яшьлек көнендə генə була торган эссе күз яшьлəремне түгə торган булдым... («Безнең көннəр», 207–218).

Менə сезгə «Яшьлəр хəятендəн» дагын Сəлимнең беренче портреты – Давыдның Зəкилекдəн Сəлимлеккə күчүе (яисə Зəкинең икенче портреты).

---

[1] Тəкəммел – камиллəшү, үсеп җитү.

Тагы Давытны тыңлыйк:

Ләкин монда туктый алмадым. Бу минем фикри тәкямилемнең баскычларындан берсе (өченчесе. – *Г.С.*) иде. Кемләрдер әйткәнчә, монда, тәкълид бәласе белән түгел, бәлки азат акылның хәйат вә тарих фактлары күрсәткән юл буенча тукталмый үсүне үзенә мәҗбүр күрүендән игътикадым икенче төс алды, гомумән миллиятнең бәни-адәм хәятенда тоткан урыны миңа чын кыяфәте белән ачылды, миллият астына яшерелгәннәр чиркен йөзләре белән мәйданга чыкты.

«Калды тик бәни-Адәм», элек кешеләр икегә – мөселманга, мөселман түгелгә (Давытның зәкилек баскычында. – *Г.С.*), андан соң татарга, татар түгелгә (Давытның мөсәллимлекдәге беренче портрете. – *Г.С.*) бүленә иде. Күземне ачкан куәткә мең шөкер булсын – инде мин бу сарыклардан[1] котылдым. Син кем – адәмме? Без кардәш, бир кулыңны, Габдулла белән Иван кочаклаштылар.... Хәзер инде адәмләр эшләүче белән эшләтүчегә, бай белән ярлыга, ач белән тукка, мәшҗүр[2] сүз белән әйтсәк буржуазия белән пролетариатка, талаучы белән таланучыга бүленәләр. Түбән сыйныф өч, аңа икмәк кирәк, һәммә халык кысылган, аларга ирек кирәк.

Бу заманның хәят агымы ач белән тук, эшләүче белән эшләмәүче арасында хөкем сөргән җәберле нисбәтнең тәэсире сәбәпле яңа бер идея – социализм идеясе тудырды һәм тарихта күрдекебез кебек беренче хәйәт барышы да шул идеянең гамәли тәтбикын эшләйәчәк пәйгамбәрләр – Маркс-Энгельсләр җибәрде. Шул пәйгамбәрләр бәни-адәмгә тигезлек, туганлык, азатлык нигезенә корылган яңа бер дин – социализм китерделәр.

Картлар картайган динне, милләтне, тагы анлардан түбәнрәк булган бер рамка эчендә кысылып катканлар. Ләкин намуслы яшь җанлар бу бөек идеянең якты нуры алдында сәҗдә итүне үзләренә ... (118–219 битләр).

Менә Давытның бу портреты инде. «Яшьләр хәйятендән бер ләүхә»дән Сәлимнең икенче портреты (Зәкинең өченче портреты була). Шул ук портрет «Яшь йөрәкләрдәге Сәлимнең дә беренче портреты – «халыкчы» социалист, революөионер чагындагы сурәте.

Инде без Давытның реакция тәэсире астында башыннан үткән хәлен шул вакыттагы бер портретын күреп үттек. Ул түбәндәгечә:

---

[1] Сарыклардан – тайпылышлардан.

[2] Мәшҗүр – телдән-телгә ботакланып йөрегән сүз.

Давыт Урманов монда тора, байлар акчасына чыга торган гәзиттә эшли, бик эчә, ди. Ирем һәрвакыт канаты сынган кош (курсив минеке. – *Г.С.*) дип кызганып сөйли («Безнең көнләр», Габдулла абзый хатыны Заһидә җиңгинең Сәхипкә сөйләгән сүзендән, 364 бит).

Син дә мин, Әмин белән Дәмин, диләр. Шуның кебек, канатлары сынган Давытлар ул байлар гәзитендә эшләсә дә, күңеле безнең якта...[1] көн-төн сүгенә, айаусыз эчә... («Безнең көнләр», Габдулла абзый сүзе, 366 бит).

Давыт шул инде. Ләкин Сәхипкә ул бөтенләй башка бер элеккенең [мөрәббияте][2] кебек күренде (371 бит). Урманов бераз уйлангач җавап бирде...

Хәбиб Мансур тагы сорады.

– Син аңларга тиешсең – мин яңадан тудым. Ләкин халык эченә кайчып, аның чишмәсендән куәт алырга телим.

– Син ни сөйлисең [...][3] бөтен яшьләрне харап иттек. Шөбһә булып үтте.

Давыт яшермәде:

– Бу хәлләрдә нинди шөбһәләр. Минем газапларым. Күрәсең, вакытсыз чәчләремне агартты. Миндә бер вакыт революциягә, социализмга гына түгел кешелеккә иман бетте. Яхшылык белән явызлык бергә буталды. Йөрәгемдәге җәбраил каядыр югалып, анда Иблис хаким булды.Иҗтимагый юллар белән дөньяның рәткә керерендән үзгәгә мин Толстойга табаладым. Аның узганы тузган, бөтен дөнья төзәлер дигән нигезләре өстендә иман ясарга теләдем, булмады, канәгатьләндермәде. Ницшегә сугылдым. Бер вакыт аның Заратустрасын потым итеп йөреттем [451].

Менә монда бер Даудның шушы портреты нәкъ «Яшьләр хәятендән бер ләүхә»дәге Сәлимнең соңгы – өченче портреты булганын күрәбез. Сәлимнең дә соңгы сүзләренә кайтып карагыз.

Хәзер Даудның актык сүзен тыңлыйк.

– Ләкин бары да тиз үтте. Актык тәңригә зинданда булды. Һәм монда мин яңардым. Дауд бөтен гәүдәсе белән сузылып Габдулла абзыйның иренләреннән үпте:

– Шулай Габдулла абзый, шулай. Безнең көнләр озатылмады, яңадан килер. Кайгырма, бу караңгы төн мәңге булмас.

---

[1] *Күп нокталар текстагыча.*

[2] Мөрәббияте – җимешләре, нәтиҗәләре.

[3] *Аңлашылмый торган урын, төсе җуелган.*

Даудның менә бу соңгы портреты «Яшьләр хәйяте»ндәге Сәлимнең безнең тәсаувирыбызда булган, булуы ихтимал тотылган портретының үзе инде. Бу ихтимал тотылган портретның икенчесе исә «Яшь йөрәкләр» романындагы Сәлимдә күрелеп үтте. Анысы Сәлимнең дә канаты сынган кош хәлендәге һәм Җәлил белән очрашкан чагындагы портреты булыр.

* * *

Инде шул югарыдагыларга Даудның төп табигате, рухы салынышы. Шул ук Зәки, Сәлимләрдәгечә булуын кушарга тиешбез.

Зәки – акыллы, зирәк, тырыш, түземле, нык ирекле көрәшче «фидаи». Беренче ( «Яшьләр хәйятендән бер ләүхә»дәге) Сәлим – фидаигал димагълы, үткен назарлы вә гали рухлы, табган бик мөнәссәйер мөтәхәссис кеше, үзгәрүчән, үзенең үзгәрүләренә дә тәкълид мүдәбәләсе дип түгел, сөбатсызлыкта дип түгел, бәлки бик табигый булган бер инкыйлаб дип караучы үзе игътираклы һәм фидаи. Икенче («Яшь йөрәкләр»дәге Сәлим) – акыллы, батыр, зирәк, сабырлы, үткен, уйчан җанлы, нык ирекле фидаи һәм фикрән үзгәрә, үсә баручан, үзендәге бу хәлен «мода, тәкълид» бәласе белән түгел, бәлки *азаң* гакылның хәйят вә тарих фактлары күрсәткән юл буенча тукталып үсүне үзенә мәҗбүр күрүендән дип белүче, шуның белән бергә йөрәгендә бер-беренә каршы мең төрле хиссият кайный торган кеше.

Дауд Урманов баладан ук зирәк җанлы, гакыллы булу белән бәрабәр ул кайбер вакыт гаҗәеп сабыр, гаҗәеп уйчан булып китә («Безнең көнләр». 67 бит).

Менә бу чагыштыруларда Зәки+Сәлим=Дауд булганын һәм Дауд шундый баскычлардан үтеп килеп чыккан бер тип икәнен күз алдыбызга бастыралар.

Шулай итеп Дауд үзен бер фикри эволюция уздырган акыллы, тирән уйлы, киң карашлы, батыр һәм нык ирекле бер «рухи тип» булып эшләнеп чыккан була.

*Мәкалә әдәбият галиме Габдрахман Сәгъди (1889–1956) тарафыннан язылып, «Мәгариф»журналының 1928 елгы февраль санында басылып чыккан. Гарәп графикасында. Гамәлдәге татар хәрефләре белән беренче тапкыр басыла.*

*Текстны басмага филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибрагимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*
*Нуридә Насыйбуллина әзерләде.*

*Г. Толымбайский*

## Искермәгән бер уңлык турында

Галимҗан ага Ибраһимов 1927 нче елда үзенең «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән китабын чыгарды. Бу китапның да, моны яклаучыларның да ялгыш юлдан барулары шул китап чыккан вакытларда ук партия оешмасы тарафыннан ачып салынды. Димәк инде аңа байтак вакыт үткән. Аннары соң вакытта җитешсезлеге дә ачып салынган. Шулай булгач, моңа хәзерге көндә туктауның кирәге бармы?

Кирәге бар, иптәшләр.

Бердән, бу юл Хәнәф Наумга җавап биргәндә Галимҗан Ибраһимов яңалиф мәсьәләсендә зур гына ялгыш ясавын әйтсә дә, милли культура мәсьәләсе турында ялгышканлыгы турында бер сүз дә әйтмәде. Ә Хәнәф Наум[1] аңа төбендә шул мәсьәлә буенча бәйләнгән иде.

Икенчедән, партия оешмасы карарында шул момент өчен Галимҗан Ибраһимов ялгышына караганда, шул ук милли культура мәсьәләсендә шул фразаларга бирелгән Сәләх ип. Атнагулов ялгышлары зуррак итеп күрсәтелгән иде. Кайбер иптәшләр шул карарны бүгенге көнгә дә күчерергә тырышалар. Шул фразага ябынып эш күрергә тырышучылар белән көрәшне бер минутка да туктатмыйча, көрәшнең көчлесен уң тайпылуга каршы җибәрү кирәк булган бер чорда, мондый карашның дөрес булмавын аңламаган иптәшләргә, Галимҗан Ибраһимовтагы реакцион карашны тагын бер кат күрсәтеп үтәргә кирәк була.

Өченчедән, солтангалиевче Максудовлар, Мансуровлар да Галимҗан Ибраһимовның шул китабын яклadылар һәм әле дә яклыйлар. Бу уңай белән дә ни өчен ул китап солтангалиевчеләргә ошаганлыгын ачып салмый ярамый. Димәк, без солтангалиевчеләр белән рәхимсез рәвештә көрәшү белән бергә, бу китаптагы карашлар белән дә көрәшергә тиешбез.

Кыскасы, ул китапны яңадан кайтып карау кирәкле һәм вакытлы мәсьәләләрнең берсе булып тора. Марксизмны ныгыту өчен үткәндәге ялгышларыбызны ныклап исәпкә алу, аларны буямый-нитми ярып салуның кирәклеген дә кушсак, бу турыда сүз озынайтырга да калмый.

---

[1] *Хәнәф Наумның дөреслеге, ялгышлыгы – анысы икенче мәсьәлә. Без монда аңа тукталмыйбыз (Г. Толымбайский искәрмәсе).*

Килик китапның эченә.

«Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән китапның төп җитешсезлеге нәрсәдә соң?

Кыска гына итеп әйткәндә, Галимҗан ага Ибраһимовның милли культураны сизүдә сыйнфый караш диалектик караш белән якын килмәвендә. Милли культураның сыйнфый эчлеген күрми буржуа тегермәненә су коюында. Була шундый китаплар, мәкаләләр, анда гомумән алганда, дөрес фикер йөртелә дә, бер-ике җирдә яңлыш формулировкалар киткәли. Ибраһимовның бу китабы андый кечкенәрәк булган экликтизм чире белән генә авырмый. Бу китапта башыннан ахырына чаклы безгә чит караш үткәрелә. Ул татарның зыялысын да төптә сыйнфый яктан тикшерми. Ул крәстиянның сыйнфый катлауларга бүленүе белән дә күп исәпләшми. Ул гарәп теле белән урыс телен дә япь-янәшә куя. Ул берничә урында милли культураларның эчтәлекләре белән пролетариатча формалары белән генә милли калыпта булуларын әйтсә дә, тикшерүгә килгәндә аның сыйнфый йөзен бөтенләй томалый. Туктыйк аерым-аерым.

Интеллигенция турында Ибраһимовның китабында мондый сүзләр бар: «Әмма хәзер татарларның барлык зыялы көче рәсми дәүләт механизмы өчен дә иң кирәкле һәм тулы хокуклы элемент булып урын алды» (27–28 бит).

Галимҗан ага икенче урында зыялыларны өчкә аера да, шуларның безгә каршы булган ике төре турында болай ди: «1 – чын иске тип милләтчеләр, шулай ук 2 – игътикадында[1] иске, әмма тактикасында «яңарган» кечкенә группа пролетариат революциясе эчендә милли мәсьәләнең чишелү рәвешен һаман да үзләштерә алмаганнар; болар: иске алпавыт буржуа дәверенең хәзерге археология музейлары өчен калдырылган ватык-сыныклар дир» (12–13 бит).

Менә бу ике генә өземтәдә дә Ибраһимовның интеллигенция эчендәге сыйнфый аерылышны күрмәве, «археология музейлары өчен калдырылган ватык-сыныклар» дип, сыйнфый көрәш кискенләшкәнне сизмәве ярылып ята.

Шулар өстенә аның «пролетариат революциясе үзенең зур хәрәкәтләре вакытында бер яктан шулай хезмәт халкы эченнән тартып чыгарып, гамәли көрәш аркасында андый көчләрне үстерсә, икенче яктан төзелгән план буенча татардан гыйльми-мәдәни

---

[1] Игътикадында – ышануында.

көчләр хәзерләү эше бик нык куелды. Казанның, Мәскәүнең, Ленинградның югары мәктәпләрендә байтак татарлар югары мәктәпләр янында гыйльми хезмәтенә калдырылдылар» (30 бит) дип, сыйнфый күзлексез карашын да кушсак, аның бу мәсьәләдәге карашы тагы да ачыла төшсә кирәк.

Галимҗан Ибраһимов интеллигенция мәсьәләсендә тотнаксыз һәм бөтенләй либераль вак буржуа сазлыгына төшкән кебек, милли культура мәсьәләсендә дә шул юлдан тәгәрәде. Менә ике-өч мисал:

«Безнең кебек революциягәчә дә татар мәдәни хәрәкәтендә эшләп килгән карт буын бу юлдагы уңышлы тизлекләргә кайбер вакыт хәйран булып, гаҗәпсенеп карыйдыр» (29 бит).

«Татар җөмһүрияте гәрчә ул вакыттагы талашларда тик сәяси бер нәрсә булып күренсә дә, асылда аерым милли җөмһүрият белән татар мәдәниятенең киләчәге һәм бу мәдәни хәрәкәтнең формасы билгеләнә иде. Чөнки җөмһүрият төзү, димәк милли татар мәдәниятенә төп нигез салмак, татар мәдәниятенең совет хуҗалыгы һәм икътисади нигездә һәммә тармакларында эшләп баетып торучы бер машина кормак дигән сүз иде» (26 бит).

«Пролетариат революциясе милли мәдәнияткә ирек биреп, аңа җөмһүрият кебек рәсми нигез салу белән генә дә калмады, бу мәдәни хәрәкәтнең икътисади фундаменты һәм хуҗалыкның ныгуы турында да татар өчен бик күп ярдәмнәр ясады» (26 бит).

Әнә шул югарыдагы өземтәләр Ибраһимовның милли культурага либераль вак буржуа карашыннан чыгып бәя бирүен бик яхшы ачып салалар. Ул татар пролетариат культурасының пролетар эчтәлек белән ныгып, интернациональ культурага якыная баруы турында сүз йөртәсе урында «татар мәдәни хәрәкәтендә эшләп килгән карт буын», «татар мәдәниятенең киләчәге», «милли җөмһүрияте безнең милли мәдәнияткә нигез салуы» кебек сыйнфый тотнаксыз һәм безгә чит булган карашларга таянып эш итә. Шуңа күрә дә, ул җилләнеп китеп, татарлар милли мәдәниятләрен үстереп, социализмга баручы милли мәдәниятләр кәрванында аерым бер отряд булып дәвам кылырлармы, дигән сорауны алга ташлый һәм шуңар төрле юллар белән боргалап, «әйе» дип җавап та бирә.

Шушы культура турындагы сүз уңае белән Галиҗан Ибраһимовның хәзерге пролетариат кулындагы урыс пролетариат культурасыннан мөмкин хәтле качып, ә башка төрек-татар халыклары белән якынаюга таба юл тоту тенденциясен үткәргәнлеген дә күрсәтеп китәргә кирәк. Ул бер җирдә, «әмма хәзер әдәби тел-

нең, әдәби әсәрләрнең тенденцияләрен–барышларын караганда, без гарәпчәдән дә, урысчадан да мөмкин кадәрле котылуга таба юнәлгәнлеген күрәбез. Матур әдәбият бу юлда беренче булып бара» (35 бит) дип, гарәп теле белән урыс телен япь-янәшә куйса, «урыслашу» дигән сүзне буки ясап, аның белән байтак кына урында куркытырга тырышса, пролетариатның юлбашчылыгы астында бара торган көчле пролетариат урыс культурасыннан файдалану турында бер конкрет сүз әйтмәсә дә, төрек-татарчылыкны онытмый. Ул бу турыда үзенең «Нәтиҗәләр» бүлегендә аерым итеп туктарга кирәк таба – «шуның белән бергә татар мәдәнияте үскән, күтәрелгән саен башка төрки халыклар белән мәдәни-гыйльми тәҗрибәләрне алмашу нокталары да күз алдында тотылачактыр», (40 бит) – ди ул.

Крәстиян мәсьәләсендә дә аның сыйнфый буынсызлыгы ачык күренеп тора. Аның китабында «татар авылы», «татар крәстияне» кебек сыйнфый аерылышсыз сүзләр генә кулланыла:

«Революция аркасында татар крәстияненең җире артты, моның белән мәдәни хәрәкәт нигезе икътисади бер дәрәҗә күтәрелде. Элек татар авыллары шәһәрләргә, зур елгаларга, тимер юлларга якын җирләрдән читкә, аз табышлы урыннарга сөрелгәннәр иде» (27 бит).

«Күп басуга күчә башлау, татар авылына яңа культуралар, агрономнар, тракторлар килү, авыл кооперациясендә татарның нык катнашуы болар – һәммәсе татар авыл хуҗалыгында совет вакытында ныгаюны, димәк мәдәният көчәюне күрсәтәләр» (27 бит).

Крәстиянгә, авыл хуҗалыгына болай карау да, әлбәттә, безгә чит караш. Безнең алдыбызда әлегә сыйнфый катлаусыз крәстиян юк. Тагын шуны да әйтергә кирәк: крәстиән турында Галимҗан Ибраһимов кат-кат әйтсә дә, кулак турында ул ләм-мим әйтми монда.

Галимҗан Ибраһимовның бу китабында әнә шундый сыйнфый тотнаксызлыклар кызыл җеп булып сузылганнар. Ул бу китабында үзенең либераль вак буржуа булган фикерләрен бик ачык итеп мәйданга куйган. Шуңа күрә дә, ул китапка Мансуров, Максутов кебек солтангалиевчеләр дә тавыш бирделәр һәм хәзерге көндә дә шул китапны яклауларын әйтәләр, дәвам иттерәләр.

Шулай булгач?

Шулай булгач инде, шул фразачылар белән көрәшүне ныклап алып бару белән бергә, бу китаптагы карашларга каршы тагын да ныграк рәвештә көрәшергә, аның чын йөзен ныграк рәвештә ачып

салырга кирәк була. Шул фразачыларга каршы көрәшүне һичбер туктамастан бу китаптагы реакцион фикерләргә каршы көрәшүне хәзерге вакытның зур бурычларыннан итеп алырга туры килә.

Бу реакцион карашның коры үзен генә түгел, аның эштә чагылган моментларын да барларга, ачып салырга нык күңел куярга кирәк. Ягъни культура фронтындагы милли чикләнүчәнлек һәм вак буржуа либерализмы күренешләре рәхимсез рәвештә тәнкыйть уты астына алынырга тиеш.

Шуның белән бергә Галимҗан ага үзе дә аңларга тиеш – аның бу китаптагы карашлары объектив караганда, солтангалиевчеләрнең тегермәненә ныклап су коя, хәзерге сыйнфый көрәш көчәйгән бер чорда партиянең эшенә нык комачаулый. Шуңа күрә дә, ул үз ялгышларын үзе дә ачык итеп, ачып салырга тиеш. Яңалиф турындагы ялгышу белән культура турындагы ялгышу – алар бер-берсенә нык бәйләнгән. Ибраһимов моны аңларга тиеш.

*Мәкалә язучы, әдәбият галиме, репрессияләр чоры корбаны Гомәр Җәләлетдин улы Толымбай (1900–1938) тарафыннан язылып, «Безнең юл» журналының 1929 елгы ноябрь санында латин шрифтында басылган. Текст шуннан алынды.*

*Хәнәф Наум* – журналист.

*Максудовлар* – монда сүз җәмәгать эшлеклесе, галим, журналист Гаяз (Мөхәммәтгаяз) Гыйсаметдин улы Максуди (1891–1942) хакында бара. Репрессияләр чоры корбаны.

*Мансуровлар* – монда сүз тарихчы, сәяси эшлекле, педагог Гасыйм Гата улы Мансуров (1894–1955) хакында бара.

*Газыйм Касыймов*

**Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?**
(Г. Ибраһимов, 27 ел, 19 февраль, Казан)

Соңгы көннәрдә генә мин Казаннан, язучының үзе тарафыннан җибәрелгән шушы китапны алдым. Китапның сүз башына караганда аның язылу тарихы шулай тора:

Шушы елның февраль аенда анда (Казанда) әнә шул югарыда әйтелгән мәсьәлә турында бик кызу сүз көрәштерү булып алган булса кирәк. Бу китап Галимҗан иптәшнең шул көннәрдә булган җыелышлардан берсендә ясаган докладында һәм шул доклад буенча җыелышның күпчелеге тарафыннан кабул ителгән аның тезисларыннан гыйбарәт икән. Шул ук сүз башына караганда җые-

лышның азчылыгы ягында «урысчы Сәләх Атнагулов, Гомәр Әлмөхәммәдев, Мортазин һәм латинчы Хөсни Кәримев белән Фатих Сәйфиләр» торганнар. Ләкин бу мәсьәләдә алар нинди карашны алга сөргәннәр – аларның тезислары кулыбызда булмаганга, без бу турыда бер нәрсә дә әйтә алмыйбыз әле. Ә менә Галимҗан иптәшнең карашы турында, инде алар белән танышкач ук, кайбер нәрсә әйтә торырга мөмкин саныйбыз.

Галимҗан иптәш әйтә:

– пролетариат революциясе һәм социализм төзелеше эчендә дә милли мәдәниятләр, шулар җөмләсеннән татар мәдәнияте дә бар (китапның сүз башында. – *Г.К.*), ул яши, үсә, яшәячәк, үсәячәк, ди.

– милли мәдәният белән пролетариат мәдәниятен каршы куярга, аларның икесенә ике нәрсә дип карарга ярамый, ди. (Болар китапның башка урыннарында).

Бу мәсьәләдә аның төп карашы менә шул һәм менә шуңа каршы булса кирәк, әлеге «урысчы Сәләх һәм латинчы Сәйфиләр» тавыш күтәрәләр. Бу тавыш урынлымы? Безнеңчә, һич шөбһәсез, урынлы тавыш бу. Чыннан да – «пролетариат революциясе һәм социализм төзелеше эчендә дә милли мәдәният яшәргә тиеш» дигән сүз, ни дигән сүз ул? Бу бит пролетариат диктатурасы чорында да һичбер сыйныф һәм группаларга бүленмәгән бөтен бер милләт. Бу урында татар милләте яшәргә тиеш, дигән сүздән башка бер нәрсә дә түгел. Ә андый бер бөтен – һичбер сыйныф һәм группаларга бүленмәгән татар милләтенең юклыгын хәзер пионерлар да яхшы беләләр.

Менә сезгә бер мисал:

Тарихны тикшергәндә без ничек тикшерәбез? – Анда без үткән вакытны феодализм, капитализм һәм пролетариат диктатурасы дәвере кебек (мисал өчен генә алам) берничә дәвергә бүләбез: бу дәверләрнең эчендә, дибез, бер вакытта да аерым сыйныф һәм группаларга бүленмәгән бөтен бер халык булмаган, бәлки аларның һәркайсы шул ук бер халыкның үз эчендәге төрле сыйныф һәм группаларның көрәшеннән гыйбарәт булган, дибез; шулай булгач, ул хәзер, бигрәк тә хәзерге кебек сыйнфый көрәшнең кызган бер чорында, ул нинди милләт, нинди бер бөтен татар милләте һәм аның милли мәдәнияте була иде ул?!

Юк, Галимҗан иптәш, ничек кенә аңларга теләсәк тә, без моны аңлый алмыйбыз. Үз карашыгызны куәтләр өчен сез Сталин иптәшнең шушы сүзләрен күчерәсез:

– *без – пролетариат мәдәнияте төзибез* (курсив минеке, бу сүзгә бик нык дикъкать итеп китәргә кирәк. – *Г.К.*). Монда һич шик юк. Ләкин үзенең мөндәриҗәсе буенча социализм нигезендә булган пролетариат мәдәнияте социализм төзелешенә катнашкан төрле халыкларның тормышларында, телләрендә булган башкалыкларга карап (фәкать менә шуның өчен генә! – *Г.К.*) үзенең тышкы калыбында, шәкелендә (фәкать менә шунда гына, ә мөндәриҗәсендә түгел. – *Г.К.*) төрлечә була: мөндәриҗәсендә пролетариатча, форма буенча милли – социализмга бара торган бөтен кешелек мәдәнияте менә шулай булачак».

Бу сүзләр бит, Галимҗан иптәш (сез аларны гүя үз карашыгызны куәтләр өчен күчерәсез), сезгә каршы бит, алар каравыл кычкырып торалар: 1) Сталин иптәш – «без – пролетариат мәдәнияте төзибез» ди, ә бездә милли мәдәният төзибез, дими.

2) пролетариат диктатурасы дәверендә яши торган нинди дә булса бер мәдәният турысында «милли» сүзе кулланыла икән, ул фәкать аның формасы, калыбы турысында гына булырга мөмкин, ә аның мөндәриҗәсе, мотлак, пролетариатча булырга тиеш, ди, ә сез мин уйлыйм, бездә ул форма һәм тышкы калыплар өчен генә сүз көрәштереп тормыйсыздыр бит инде. Шулай ук тегеләрдә форма бит әле ул төп содержание мәдәният үзе дигән сүз түгел. Форма бер – мөндәриҗә башка, бу икене һәрхәлдә аерып йөртә торгансыздыр.

Менә сезгә тагы бер мисал:

Бу мисал ләкин бик кечкенә, шунда да урынлы мисал. Мин, әйтик элекке вакытта шоп-шома милли киемдә йөри торган тап-тар бер милләтче идем, ди. Революция минем карашымда, миемдә үзгәреш ясады да, мин хәзер элекке милләтчелегемнән чыгып, аңлы бер коммунист-интернационалист булдым, ди. Ләкин йә фәкыйрьлектән, йә башка берәр сәбәптән элекке милләтче вакыттагы киемнәремдә калдым, ди. Сезнеңчә фәкать менә шуның өчен – минем өстемдә элекке милләтче вакытымдагы киемнәрем булган өчен генә, мин хәзер дә милләтче дип аталырга тиеш буламмы инде? Юк бит. Әнә тегендә дә, минемчә, нәкъ менә шулай тора.

Ә менә тел мәсьәләсенә килгәндә инде, монда әле, безнеңчә, хәзергә эш башкачарак тора. Дөрест, тел мәсьәләсенә дә без марксистлар төп максат дип түгел, бәлки шул төп максатларга ирешү (ә бу урында әнә шул «гомумкешелек өчен уртак мәдәният»не үзләштерү) өчен кирәкле бер корал (средство) гына дип карый-

быз; ләкин ничек кенә булмасын, хәзергә әле халыкның йөзгә туксаны диярлек ул «гомумкешелек өчен уртак мәдәният»не фәкать үз телендә генә үзләштерә алганын, ә бу исә, шул ук уртак мәдәнияткә бару эшен фәкать тизләтә торган гына бер юл булганын, ниһаять, моны – һәр халыкның ул уртак мәдәнияткә бару эшен мөмкин чаклы җиңеләйтергә кирәклекнең шул ук уртак мәдәниятнең үзе тарафыннан куела торган иң зур шартларның берсе икәнен күз уңында тотып без – тел мәсьәләсенә әле хәзергә алай механический гына карый алмыйбыз. Югарыда әйткәнчә, халыкның йөзгә туксаны әле хәзергә аның арасында йөртелә торган эшләрнең, шул җөмләдән һәм барлык мәдәни чараларның да үз телендә йөртелүенә иген игәр өчен сабанга, ашар өчен кашык һәм су эчәр өчен чүмечкә мохтаҗ булган шикелле бер мохтаҗлык сизә. Шулай булгач, аңа нисбәтән тел мәсьәләсендә әле без хәзергә һичбер төрле яңа тәкъдим ясый алмыйбыз.

Бу мәсьәлә хәзергә фәкать теләгән кешеләрнең, теләгән бер телдә сөйләргә, язарга ирекле булулары һәм радио, телефон, трактор, аэроплан кебек кайбер уртак сүзләр исә, акрынлык белән генә булса да «гомумкешелек өчен уртак бер тел»гә табан барулары юлы белән генә хәл ителеп торырга мөмкин. Бу мәсьәләгә без менә шулай карыйбыз.

Ә менә Галимҗан иптәш бу мәсьәләдә дә үзенең шул югарыдагы карашында садыйк[1] калып, «милләт»нең аерым әгъзаларына нисбәтән аның («милләт»нең) үз гәзитен укымауларына, балаларын «милләт»нең үз мәктәпләренә бирми, башка, әйтик, урыс мәктәпләренә бирүләренә каршы күсәк күтәрә, «милләт» әгъзасы булган кешеләргә нисбәтән «милләт» телен көчләп тагу юлын тотмакчы була. Монда да без ничаклы гына ул аерым кешеләрне элекке урысчы татар мирзаларына чагыштырып провакация таратмасын, аның карашына кушыла алмыйбыз. Гомумән, монда менә нәрсәне әйтеп китәргә кирәк:

Галимҗан иптәш ул хәзерге латинчылык хәрәкәтен элекке урыс миссионерлары тарафыннан йөртелгән хәрәкәт белән чагыштырып та, үзенең диалектика бабында бераз аксый башланганын күрсәткән иде инде. Монда да ул менә шул хатасын тәкрарлый.

Чыннан да иптәшләр элекке вакытта бөтенләй башка шартлар эчендә, бөтенләй башка кешеләр тарафыннан һәм бөтенләй башка

[1] Садыйк – туры.

максатлар белән эшләнгән бер эшне хәзерге хәлләргә, хәзерге шулай ук бөтенләй башка шартлар эчендә, бөтенләй башка кешеләр тарафыннан һәм бөтенләй башка максатлар белән эшләнә торган эшләргә күчерү бу наданлыктан башка бер нәрсә дә түгел бит инде. Элек бер хәл булган. Шуның өчен андагы явленияләрдән бер нәтиҗә туган, ә хәзер бөтенләй икенче хәл, шуның өчен, хәзер шул ук явленияләрдән бөтенләй башка нәтиҗәләр туарга мөмкин, туарга тиеш һәм туа да.

Диалектика кануны безгә бу турыда менә нәрсә ди:

– марксизм диалектикасының төп әсасе – табигать һәм җәмгыятьтәге бөтен чикләрнең вакытлы (условный[1]) һәм күчеп йөри торган бер нәрсә икәнен күрсәтә. Шуның өчен табигатьтә мәгълүм шартлар эчендә үзгәрмәгән, кайвакыт, хәтта бөтенләй элеккенең киресенә әйләнмәгән бер генә явления дә юк» (Ленин).

Диалектика кануны безгә менә шулай ди, ә Галимҗан иптәш менә шуны аңламый, яхуд моны аңлый торган коралы аның көннән-көн тупаслана бара. Юкса хәзерге вакытта үзенең баласын урыс мәктәбенә бирергә теләгән бер татар эшчесен ул элекке вакытның татар мирзалары белән чагыштырып көчәнмәс иде. Тели икән пожалуйста, бирә бирсен, кемдә кемнең эше бар?

Революция бу мәсьәләләрне менә шулай хәл кыйла ул, Галимҗан иптәш.

Моннан соң, татар теле дигән нәрсәне һәм аның өстендә эшләүне бөтенләй ташларга кирәк дигән нәтиҗә чыкмыймы? Юк, чыкмый. Татар теле чөнки әле ул татар халкының йөзгә туксаны өчен мотлак кирәк һәм ансыз яшәп булмый торган бер корал санала. Шулай ук урыс теле дә, аның язмышы да, хәзер нәкъ менә шулай тора.

Кыскасы: бу мәсьәләне хәл иткәндә без тормышның бүгенге конкрет ихтыяҗларыннан чыгып хәл итәргә тиешбез димәкче булам мин. Хәзергә шуның белән җитеп торыр.

*Мәкалә журналист, партия эшлеклесе Газыйм Касыймов (1891–1941) тарафыннан язылып, «Яңа авыл» газетасының 1927 елгы 17 март санында гарәп шрифтында басылган. Текст газетадан алынды.*

*Сәләх (Сәләхетдин) Садри улы Атнагулов* (1893–1938), педагог, сәяси эшлекле, публицист, язучы. 1927–1929 елларда Гыйльми Үзәк рәисе. Татар алфавитын яңалифкә үзгәртү тарафдары. Репрессияләр чоры корбаны.

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән.*

*Гомәр Әлмөхәммәтев (Әлми)* (1895–1939), журналист, партия эшлеклесе.

*Хөсни (Хөснетдин) Минһаҗетдин улы Кәрим (Кәримев)* (1887–1965), язучы. 1926–35 елларда Главлит җитәкчесе.

*Фатих (Мөхәммәтфатих) Камалетдин улы Сәйфи-Казанлы (Сәйфуллин)* (1888–1937), язучы, җәмәгать эшлеклесе. 1923–1929 елларда «Кызыл Татарстан», «Крәстиян гәзите» газеталарының, «Яңалиф» журналының җаваплы мөхәррире.

*Фатих Шиһабетдин улы Мортазин* (1875–1937), журналист. Репрессияләр чоры корбаны.

*Текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны басмага*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының текстология бүлеге*
*өлкән фәнни хезмәткәре Гөлназ Хөснетдинова әзерләде.*

*Шәриф Камал*

## Гарәп хәрефеме, латин хәрефеме

«100%»

Тюркология съездында төрки кавемнәрнең бик зур күпчелеге гарәп әлифбасына караганда «Яңа әлифба»ның техника ягыннан уңайлыгы карарына килде. Татарстан вәкилләре дә «әсасән», моңар каршы булмаган хәлдә, Татарстанның культура һәм икътисадый шартлары гарәп әлифбасыннан аерылырга мөмкинлек бирмәгәнлекне белдерделәр. Шуның өстенә, Галимҗан иптәш Ибраһимовның әйтүенчә, 50 ел буенча гарәп хәрефен татар ихтыяҗына уңайлату юлында тырышып килгән хәлдә, ул хәрефләрне төзәтү эшенә тагын 100 процент көч куярга вәгъдә биреп кайттылар.

Галимҗан иптәш Ибраһимов тюркология съездында тикшерелгән мәсьәләләр турында язган мәкаләләр сериясеннән бер озын мәкаләсен шушы әлифба мәсьәләсенә багышлап чыгарды.

Ул сәбәпләрне Галимҗан иптәш сорты-сорты белән болай саный:

«1) Гарәп әлифбасының, гарәп хәрефләренең бездә бик зур тарихы бар. Татар арасында гарәп хәрефе белән язылган әсәрләрнең 4–5 йөз еллык гомерләре бар. Басмачылыкның бездә 125 еллык тарихы бар. 50 ел буенча без гарәп хәрефен татар ихтыяҗына уңайлату юлында эшләп килдек.

Соңгы 25 елда татар җәмгыятенең төрле катлаулары моңар катнашты. Иң ахыргы 5 елда исә җөмһүрият хөкүмәте үзе бу эшкә тотынды.

2) Хәзер безнең типографияләребез, хәреф җыючыларыбыз, язучыларыбыз, дәреслекләребез, йөз мең басыла торган әлифбабыз, көтепханәләребез, караңгы авыллардагы уку өйләребез – һәммәсе шул төзәтелгән гарәп хәрефләре нигезендәге матбугатка, әдәбиятка корыла.

3) Халкыбызның 30 проценты шул хәреф белән укырга, язарга өйрәнгәннәр.

Менә бу зур мәдәни хәрәкәт машинасы туктаусыз әйләнеп, эшләп тора. Латинчага күчү дигән сүз бу машинаны туктатып, яңа нигездән яңа юлларга күчереп утырту, үсеп торган мәдәни хәрәкәтнең барышын акрынайту дигән сүздер».

Бу сүзләрнең бераз өлеше дөрес түгел дип әйтер хәл юк. Ләкин яңа әлифбаның техника ягыннан гарәп әлифбасына караганда югары икәнчелеген таныган кешегә югарыдагы сүзләр тулы дәлил була алмый.

Мәсәлән, гарәп әлифбасының бездә 4–5 йөз ел гомер сөрү факты бар. Ләкин меңләп ел гомер сөргән хәлдә нигезләре бозык булган кайбер системаларның кабергә күмелергә мәхкүм булуын[1] Галимҗан иптәш бик яхшы белә.

Инде аны төзәтүгә күп эш куелганлык, 50 ел буенча татар ихтыяҗына уңайлату юлында тырышучанлык мәсьәләсен алсак – анысы бигрәк кызганыч!

Менә нәрсәдән:

Галимҗан иптәш шул ук мәкаләсендә 50 ел буенча уңайлатырга тырышылган гарәп хәрефләрен,

– «Хәзердән бер дә кичектермичә төзәтү чарасына ныклап керешергә» тәкъдим итә.

Димәк, тагын 50 ел тырышырга кирәк! «100 процент»тан шулайрак аңлашылган шикелле тоела. Бигрәк тә гарәп хәрефенә хәзергә хәтле ясалып килгән «реформа»да шушы куркынычлы хәлне күз алга китерә, мәсәлән:

Реформа дигән сүзне без һәммәбез дә начарны яхшырту, читенне җиңеләйтү дип аңлыйбыз. Хәлбуки, хәзергә кадәр безнең имля системабыз яхшы ук рәткә салынган хәлдә, гарәп хәрефләренең шәкелләрен төзәтүдә, бигрәк тә язу техникасы өчен җиңеллек ясау, начарны яхшырту ягына баруда эшләнгән эш күренми. Бәлки, киресенчә, җиңелдән читенгә яхшы ук зур адымнар ясалды.

[1] Мәхкүм булуын – бу очракта: дучар булуын.

Моңар мисаллар китереп маташуның кирәге юктыр дип беләм. Бер кырмыска тырнагы урынына ике, ике урынына өч һәм дә санап бетергесез койрыксыз тørткеләр рәтенә, чүпләп бетергесез койрыклы төрткеләр төзелде, вәссәлам!

Димәк ки, без, Галимҗан иптәш, безнең белән 50 елдан соң 90 шар яшьлек шәйхе фани булган хәлдә, кәкре башлы калын таякларга таянып, мөбарәк гарәп хәрефләренең тәмам төзәлеп җитү юбилеена катнашу шәрәфенә ирешеп, картлык көннәребездә булса да бер шатлык көне күрәсебез бар икән!

Ярар, туган, мин моңар бик күнәм. Тик ул вакытка кадәр әлеге үзегез әйткән «әдәби федерация» кошы нишләр икән? Ярый ла ул да безнең белән бергә тантаналы юбилей җыелышына катнаша алса!

Тюркология съезды вакытында, сүз иярә сүз чыгып, бер иптәш белән шул мәсьәлә турында фәлсәфә саткан чакта мин әйтәм:

– Нәрсә инде шул «әдәбиятыбыз, матбугатыбыз, мәдәни хәзинәбез, кыйммәтле тарихи әсәрләребез» дип шапырыналар! Имештер, алардан аерылырга туры киләчәк, дигән булып лыгырдыйлар! Әйтерсең лә инде яңа әлифбага күчкәндә ике-өч ел эчендә һәммә нәрсә эшләнә дә бетә! Табигый бит инде, ул акрынлык белән эшләнә. Берникадәр елларга тартыла. Аңарчы татарның берле-яртылы томдагы китапларын гына түгел, 99 томлы энциклопедияләре булса да, яңа әлифба белән басылып өлгерәчәк. Искеләре музей материалы булып калачак. Тик мәсьәләнең икенче, бер уңайсыз ягы бар: безнең халык бит, аңлыймсың, башка төрле кавемнәр шикелле түгел. Бездә 20 процентка якын грамотный крестьянин массасы бар. Менә алар белән эш уңайсызрак, чөнки аларга инде яңадан әлифба укытып булмый...

Шулай да «машинаның әйләнүе, мәдәни хәрәкәтнең барышы акрынаю» мәсьәләсендә Галимҗан иптәш фикеренә беркадәр кушылырга мөмкин. Бигрәк тә «мәдәни байлык» белән икътисадый ярлылыкның каршылыклары тәгәрмәчне азмы-күпме акрынайтмый хәле юк. Ләкин тарихи туу чорларында аның ише «акрынаю»лар була, аңар карап торылмый...

*Мәкалә язучы Камал Шәриф Камалетдин улы (1884–1942) тарафыннан язылып, 1926 елны «Кызыл Татарстан» газетасының 28 март (№71) санында басылып чыккан. Текст кыскартылып бирелә.*

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ 20 ЕЛЛЫК ИҖАТ БӘЙРӘМЕ УҢАЕННАН ЧЫККАН КАЙБЕР МӘКАЛӘЛӘР

*Исхак Рәхмәтуллин*

### XX еллык бөек әдәби-гыйльми хезмәт бәйрәме

Татарстан хөкүмәтенең карары буенча, 10 нчы мартта Галимҗан иптәш Ибраһимовның әдәби-гыйльми хезмәтләренә 20 ел тулу уңае белән бәйрәм ясала. Бу бәйрәм, әлбәттә, бер кешенең, бер әдипнең генә бәйрәме түгел, бәлки бөтен татар хезмәт массасының зур бәйрәмедер. Бөек әдипнең әдәбият-мәдәният үсеше юлындагы хезмәтенә йомгак ясап, аңа тиешле кыйммәт билгеләп, татар хезмәт массасы һәммә нәрсәдән дә элек үз әдәбияты, мәдәни-гыйльми үсүенә йомгак ясый, шул үсүенең үлчәвен билгели.

Шунлыктан Татарстан хөкүмәтенең бу 20 еллык бөек хезмәтенә бәйрәм итү турындагы карарын бик табигый рәвештә, матбугат дөньясы, киң хезмәт катлаулары алкышлап каршылады. Киң күпчелек бу бәйрәмне бик кирәкле, табигый нәрсә итеп каршы алды. Шулай итеп, бу бәйрәм хөкүмәт карары буенча ясалса да, югарыдан гына ясалган бәйрәм түгел. Хөкүмәт карары төбендә киң күпчелектә бу турыда булган көчле теләккә нигезләнгән булып кына чыкты.

Урман бөресез булмый дигәндәй, Галимҗанның хезмәтләре зур әдәби-гыйльми иҗатлар рәвешендә тәкъдир ителеп, зур бәйрәм ясалырга тиешлегендә шикләнүче ялгыз, аерым кешеләр юк түгел, ләкин болар бик кечкенә бер азчылык төзиләр. Алар үзләре дә моны сизәләр, шунлыктан үзләренең игътиразларын кискен рәвештә куймый, «иптәшләрчә көлү» тирәсендә әйләнәләр.

Галимҗанның әдәби-гыйльми иҗатлары тоташ тик иҗаби яклардан гына тормый, әлбәттә. Анда тискәре моментлар да бар. Реакция бик котырган чорларда бер вакытлар анарда романтизм беркадәр күренде («Яшь йөрәкләр» һәм башкалар). 21–22 нче елгы ачлык та аңа тискәре йогынты ясамый калмады («Адәмнәр»). Ләкин, эш 20 еллык кадәр гомергә сузылган, бик күп тармаклар буенча барган, бик күп катлаулы хезмәт эчендә берникадәр тискәре моментларның булуында түгел. Тискәре яки иҗаби якларның кайсының күпчелек төзүендә, кайсының өстенлек сөрүенә карап хөкем йөртергә кирәк.

Галимҗан хезмәтләрендә тискәре яклар, шиксез, бик кечкенә бер азчылык төзелер. Шуның өстенә Галимҗанның әдәби-иҗади

эшләргә октябрь революциясеннән соң түгел, бәлки революциядән байтак вакытлар элек тотынуын, шул вакыттагы шартларны игътибарга алсаң, аның озын эволюциясендә кайбер кытыршылыклар булуы бик табигый икәнлегенә төшенү авыр түгел.

Үзендә пролетариат катлавы бик юка, вак буржуа күпчелегеннән торган татар дөньясында буржуазия җитәкчелеге астында «шәрыктан гаребкә» күчәргә, буржуача мәдәнияләшергә өметле хөкем сөргән бер вакытта (ягъни татар пролетариатының сыйнфый көрәше йомшак вакытта) Галимҗан әдәби-иҗтимагый хезмәт мәйданына атлады.

Бу мәйданга ул шәкерт гыйсьянчысы булып, көрәшче булып керде. Аннан соң да сизгер күңелле, тәнкыйть ягы үзендә бик көчле талантлы әдип буржуазиянең иң сул сафында оппозициясендә торып, эшләп барды.

Революция чорында, Галимҗан каләм көрәшчесе булып кына калмады. Әдәбият матбугатта кискен көрәшче булу белән бергә, ул гамәлдән революция татар әдәбияты-җәмәгатьчелеге мәйданына Галимҗан «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» исемле әсәре белән башлап керде. Бу әсәр тел, сәнгать ягыннан югары түгел. Шул кимчелекләренә дә карамый, бу әсәр дә ул вакыт татар җәмәгатьчелегендә бик актуаль булган – татар буржуа мәдәнияте, җәдид мәдрәсәсе өчен булган көрәш, шәкерт гыйсьяны бик оста бирелә.

Галимҗан үзенең бу әсәре белән иҗади эшләрне башлады гына, Галимҗанның бөек хезмәтләре шуннан соң киң рәвештә дәвам итте. Ул хезмәтләр:

1) Галимҗан бик күп төрле катлауларга кагыла торган тел, сәнгать ягыннан татар әдәбияты мәйданында бәхәссез рәвештә иң югары торган әдәби иҗатлар бирде.

2) Галимҗан татар телен гыйльми яктан эшләү, имля, сарыф, нәхү, әдәбият нәзариясе, телне укыту методлары мәсьәләләрендә бик кыйммәтле әсәрләр бирде.

3) Татарлар арасында революция хәрәкәте тарихыннан кыйммәтле хезмәтләр бирде.

«Зәки шәкерт»тән «Табигать балалары», «Безнең көннәр» аша (шулар янына татар теленең сарыф, нәхү, әдәбият нәзарияләре, шәкерт гыйсьяны, кәеф хәрәкәтләре кушыла), «Кызыл чәчәкләр» (шуның янына октябрь революциясе юлында актив рәвештә эшләү «Татарлар арасында революция хәрәкәте», «Уралчылар» кушыла)

гә кадәр булган озын юлны Галимҗан озын эволюциясен кыскача болай әйтергә булыр иде:

Бу әдип-сәнгатьче булу ягында, гыйльми эшче, гыйльми тикшерүче булу ягыннан да, шулай ук бөтен бу эшләрнең мөндәриҗәсе, идеологиясе ягыннан да, Галимҗан өзлексез рәвештә үсеп барган кеше, шул үсү нәтиҗәсендә Галимҗан татар хезмәт ияләренең иң бөек әдибе, эшчесе баскычына күтәрелде.

Галимҗан татар хезмәт ияләренең иң бөек әдибе. Аны шул рәвештә тәкъдир итеп, татар хезмәт ияләре бәйрәм итәләр. Кызганычка каршы, бу бәйрәм вакытында Галимҗан безнең арабызда юк, озак, авыр хезмәтләр аны авыру ясадылар. Берникадәр вакытка ул безнең арабыздан китәргә мәҗбүр булды.

Галимҗан яңадан сәламәтләнеп безнең арабызга кайтуын, хезмәт ияләре өчен чиксез кыйммәтле булган әдәби-иҗади һәм гыйльми эшчәнлеген тагын да күп еллар дәвам иттерүен теләп калабыз.

*Мәкалә сәяси эшлекле Рәхмәтуллин Исхак Шиһабетдин улы (1897–1937) тарафыннан язылып, «Мәгариф» журналының 1928 елгы 2 нче санында басылып чыга. Текст басмага журналдан алынды.*

*Текстларны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге хезмәткәре Айгөл Әхмәтова әзерләде.*

*Әхмәт Байтурсынов*

## Галимҗан Ибраһимов – төрк-татар уйчысы[1], төрк-татар белгече, төрк-татар язучысы

Мәдәният юлында артда калган илнең алга чыгып, күзгә күренерлек адәмләре бармак белән генә санарлык була. Бу – бер. Икенчедән, андый адәмләрнең үз халкыннан артдырып, эшенең сәмәрәсен читкә чыгарырлыклары да аз була. Шул азларның берсе – Галимҗан Ибраһимов.

Еракда – далада яткан без – казакъ туганларның күзенә Галимҗан юлдаш күбдән төшкән бер азамат, аның эшләгән эшләре, уйлаган фикерләре татар мохитендән читкә чыгып, безгә дә арткан

[1] *Уйчы дигән сүз мыслитель мәгънәсендә алына.*

бер кеше. Шунлыкдан аның 20 еллык фикер, тел хезмәтен искә алып, аңа хөрмәт күрсәтеп, үз халкы туй кылып ятканда, без дә бер-ике авыз сүз әйтүне тиешле табдык.

Иң элек шуны әйтергә кирәк: бер халык икенче халыкка төрле ягы белән якынлаша, төрле якдан бәйләнешә, ялгана, нинди генә халык булса да беренең мәдәниятендән бере файдаланып, берендән бере үрнәк күреп, өлге алып алга басканы мәдәният тарихындан билгеле. Шул берендән бере өлге алып файдалану ике халык арасында тормыш ягындан, гореф-гадәт ягындан, тел ягыннан якынлык булу белән дә бик нык бәйләнгән. Шундый якынлык булганда гына берендән бере файдалану җиңел була; андый якынлык булмаса, файдалану аз була.

Шул канундан төрк халыклары да котыла алмаган һәм котыла алмый да. Ләкин боларның арасы якынлыкдан «уң кул биргәнне суңысы белми» калып, үз араларындагы йогынты сизелми кала. Мисалга безнең казакъ халкын алсак – ул тирә-ягындагы халыкдан һәркайсының якынлыгына карап файдаланганы күренеп тора. Казакъның тирә-ягындагы халыкның иң мәдәниятлесе нимес, андан соңгысы урыс, аның артында татар белән үзбәк тора. Казакъ халкы шуларның мәдәниятендән файдаланганда азындан аз алып, күбендән күп алып файдаланганы юк, бәлки якынлыгына карап файдаланды. Нимес мәдәниятендән казакъ төрк дә алганы юк. Урыс мәдәниятендән үз ирке белән алганы – иген чәчү. Татар белән үзбәкдән алганы: үзбәк казакъка ишан бирде, татар – мөгаллим бирде.

Патша заманында казакъка мөгаллим хәзерләп биргән, казакъка төрки танытып, укырга-язарга өйрәткән татар булды. Патша хөкүмәте татар мөгаллимен казакъ арасына җибәрмәскә төрле чаралар эшләсә дә, аңа карамады, татар мөгаллиме казакъ эченә тулып китде.

Урыс татардан күп, аның мәдәнияте дә татардан көчле иде, учительләре нигә казакъ арасына чыкмады, нигә казакъка уку-язу өйрәтмәде? Аларның казакъ эченә баруына патша хөкүмәте каршы булмак түгел, баруына ярдәмләшә иде. Татар мөгаллимен казакъ эчендән куып бетерә алмыйча патша хөкүмәтенең азаплануының сәбәбе ни иде? Аның сәбәбе югарыда әйтелгән якынлык иде. Урыс белән казакъның арасында күршелекдә якынлык бар, кәсебенең төрендә якынлык бар: икесе дә иген игә. Кәсебенең төре якын булганлыкдан казакъ урысдан өлге алып иген игәргә өйрәнде. Андан

башка, ни телендә, ни тормышында, ни гореф-гадәтендә якынлык булмагач, урыс учителе казакъ тормышына көйләнә алмады, казакъ тормышы урыс учителен күбләп үз эченә тартып ала алмады.

Мондан ни күрәбез? Мондан шуны күрәбез: арасында якынлык бар халык берәве алга басса, башкалары да шундан өлге алып алга омтыла икән, берсенә берсе йогынты ясый икән.

Соң әнә шул йогынты һәм якынлыкны өзмәскә нинди чаралар бар? Мәсьәлә шунда. Юлның төрле якка карап таралуы шул җирдә. Берәүләр: төрк халыкларының арасы ераклашмасын өчен теле бер булу кирәк, диләр. Теле бер булу өчен мәдәниятдән түбәнләре үз телләрен ташлап, мәдәнияте югары булганларының телен кулланып, шул тел белән укытып, шул тел белән әдәбият тудырсын диләр[1]. Берәүләре төрк халыкларының телләрен берләштерү, әүвәле мөмкин була торган эш түгел; икенчедән, мөмкин булганда да аңа күп көч белән, күп эш кирәк, ул эш төрки халыкның кулындан килми; максат төрк халыкларының барын да бер телдә сөйләштерү түгел, берендән бере өлге алып, мәдәният юлында берендән бере файдаланырлык итү, аның өчен телен берләштермичә генә, беренең әдәбиятын икенчесе аңларлык булса җитә диделәр.

Менә шул мәсьәләдә Галимҗан юлдаш төрки уйчыларның кай тарафында торып казакъ күзенә күренгәнен әйтеп үтмәкче булам.

Без – казакъ халкы саф казакъ телендә матбугат тудырып, әдәбиятыбызны тергезгәндә, балаларыбызны үз телебездә укыта башлаганда татар туганнарыбызның ул вакытда алдагы сафдагыларының күбесе бу эшкә каршы булды. Ул вакытда татарча гәзит-журналларда безгә каршы язылган фикерләргә урын бирелде. Шул вакытда безнең юлыбызның турылыгын әйтеп, безнең эшебезне кулалаган татар азаматларындан Галимҗан Ибраһимов белән Хәсән Гали булды.

Беренче тюркология корылтаенда ясаган доклады буенча Галимҗан юлдашны казакъларның тануы тагы башкарак булды. Мәсьәлә – төрк халыкларының хәзерге кулланмакда булган язуы белән хәреф мәсьәләсе иде. Галимҗан: «Телне беректерү кыен эш,

---

[1] *Атаклы Гаспринский 30 ел буена шул фикерне чәчде. Җәмал Вәлидидә дә шундый уй бар иде («Татар әдәбиятының барышы» дигән китабын карагыз). Ләкин боларның чәчкән фикере һич бер җимеш бирмәде. Казакъ үз алдына әдәбият тудырды. Башкорт, кыргыз кебек саны аз халык та совет хөкүмәте аркасында үз телен тергезеп, үз әдәбиятын аякка бастырды.*

ул кулыбыздан килми; мәдәният казнасы булган әдәбиятдан төрк халыклары уртак файдалану өчен тел бер булу кирәк иде, ләкин алай түгел, тел башка-башка. Аны беректерү мөмкин дә түгел. Шулай булгач, төрки әдәбиятны төрк халыклары бары да файдаланырлык мөлек, уртак казна итү өчен башка чара эзләргә, башка әмәл табарга кирәк» дип чыкды.

Ул әмәл Галимҗанның фикеренчә, 1) төрк телләрендәге барына уртак нәрсәләрне дөресләп, уртак файдалана белүдә, 2) төрк телләрендә юк нәрсәләрне яңадан кергезгәндә төрк халыклары үзара аңлашып кергезүдә булачак.

Төрк телләрендә, бер ягындан, берендән берен аера торган хосусиятләр булса, икенче ягындан, беректерә торган хосусиятләр дә бар ди Галимҗан. Мәсьәлән, фонетика законы барына да бер; морфология ягындан сүзләрнең тамырындагы авазларда уртаклык бар. Шуларны тәртибкә салып, уртак файдаланырлык итәргә кирәк. Алай итәр өчен Галимҗан шундый нигезләрне тәкъдим итә:

А) имляда тик фонетика нигезенә таянмыйча, сүзләрнең туувышы нигезенә дә карарга кирәк.

Б) имляны шивәләргә бәйләүдән качу, бәйләүчеләр белән көрәшү.

П) аваз тамгалары (хәрефләр) бер булу, яңа намга алганда бергә аңлашып алу.

Т) яңа фән атамаларын алганда уртак куллануга яраралыкларын алу.

Җ) шуларның барын тел корамалары аркылы үткәзү.

Төрк әдәбияты төрк халыкларының уртасындагы уртак казна булуы турысында Галимҗанның ничек уйланып, нинди чаралар эзләгәне мондан ачык күренеп тора.

Менә шул әйткән нәрсәләр бары да Галимҗан юлдашны татар чигендән чыгарып, киңерәк мәйданда йөзә торган гомумән төрк-татар уйчысы, төрк-татар белгече, төрк-татар язучысы итеп таныта торган эшләр. Галимҗан юлдашны без шулай таныйбыз. «Юлдаш» дигән сүзне мин бу җирдә гадәтдә нәзакәтән әйтелә торган юлдаш мәгънәсендә алмыйм, чын мәгънәсе белән юлдаш дип алам. Чөнки йөрешебез башка булса да, юлыбыз бер. Юлыбызда төрле сикәлтәләр булыр, кай урында төшеп дә калырбыз, эш анда түгел, эш ниятдә. Ниятебез дөрес булса, юлның сикәлтәсендән күп зарар булмас.

Сүзнең азагында Галимҗан юлдашка теләгебез озын гомер белән саулык. Гомере булса, ниятенә җитүенә иманыбыз камил.

Кызыл Урда.

*Мәкалә галим, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе Әхмәт Байтурсынов (1872–1937) тарафыннан язылып, 1928 елда «Безнең юл» журналының 2 нче санында басылып чыга. Текст шуннан алынып тәкъдим ителә.*

*Текстны басмага Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Илһам Гомәров әзерләде.*

*Шәриф Булат*

**Бөек әдипкә**

*Галимҗан Ибраһимовның 20 еллык юбилеена багышлап*

Микроб йөрәгеңнән иләк ясап
Кан иләсә гомерең күгендә...
Бүген синең исемең – фәхри исем
Миллионлаган эшче күгендә...
Ут каләмең тормыш борылышында
Күп күңелдә утлар көйрәтте,
Тормыш күренешләрен туры ачып
Алгы зур эшләргә өйрәтте...
Бүген... синең иҗат бәйрәмеңдә
Эшләреңне тәкъдир итәбез,
Киләчәктә тагы яңа иҗат,
Эштә яшьнәвеңне көтәбез.

*«Кызыл Татарстан», 1928, № 60.*

*Хәйретдин Вәли*

**Галимҗан Ибраһимовның әдәби үсүе**

Галимҗан Ибраһимовның егерме еллыгы уңае белән аның әдәби үсешенә бераз тукталып китсәк, урынсыз булмас.

Аның беренче әсәре «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясе булып, ул әле әдипнең каләме башлангыч икәнен, язу бабында тәҗрибәләр генә ясаганын күрсәтә. Монда эшләнгән типлар юк, тел-өслүб тә кристаллашып җитмәгән, тормыштан ачык

картиналар да күренми. Тик әдиптә татар иҗтимагый хәятенең мөһим моментларын эләктерергә дөрес омтылыш кына сизелә. Каләм очында бер чәчрәп киткән ялкын бары гына күренә. Шулай да 1907 нче елда чыккан үз иптәшләре арасында «Зәки шәкерт» беренчелекне казана.

1909 нчы елда әдипнең икенче әсәре «Яшьләр хәятеннән бер ләүхә» чыга. Каләменең эшләнүе «Зәки шәкерт»кә чагыштырганда сизелерлек артканы, техниканың да шомара башлаганы күренә. Ләкин монда да әле типлар эшләнеп җитә алмый. Монда да әле психология һәм моментка мөнасиб динамика юк.

«Яшьләр хәятеннән бер ләүхә» баш шәхесе үткен «фәгъгаль димаглы[1], гали рухлы» Сәлим белән әдипнең бишенче ел соңыннан башланган (1907–1912) реакция чорында татар яшьләре арасында пессимизмга бирелгән яшьләр катлавының бер вәкиле бирелергә теләүне күрәбез. Бу Сәлим әле «Безнең көннәр»дәге эшләнеп җиткән типларның прототиплары гына иде. Моннан әдипнең киләчәктә шул чор тормышыннан, шул катлаудан эшләнгән типлар бирә алачагын көтәргә була иде.

1910 нчы елда «Татар хатыны ниләр күрми?» килеп чыкты. Бу озын хикәя инде «Яшьләр хәятеннән бер ләүхә»гә караганда күп артык яхшы сәнгатьчә эшләнгән иде. Монда әдип бу әсәрнең баш героинясы Гөлбану белән урта тормышлы крестьян сыйныфыннан чыккан татар хатынын тулы иттереп бирә алды. Гөлбану чынлап та тормыш шартларына, икътисадый-иҗтимагый хәленә муафикъ эшләнгән тип иде.

Крестьян кызларының күптән булган сыйфатларны җыйган Гөлбану әсәрдә: 1) матур, 2) эшкә уңган, 3) үз-үзен яратулы (самолюбиеле), 4) шат табигатьле, 5) өметле булып гәүдәләнүе белән дөрес тип булып чыкты. Нури карт белән әдип мактанчык, залим, үзсүзле, мөстәбид[2] шәхесне бирергә теләде. Нури карт «Яшь йөрәкләр»дә тәмамлап бирелеп җитәчәк тип «Җәләш мулла»ның прототибы иде. Ләкин әле монда да әдипнең чын Галимҗан өслүбе җитә алмаганын күрәбез, кайсыбер урыннарда гарәпчә сүзләр кирәгеннән артык күп тә күренә.

1911 нче елда «Диңгездә», «Ялчы карт» дигән әсәрләрдә инде сәнгатьчә эшләнү тагы да күтәрелә төшә. Өслүб шомара, тасвирлар

[1] Фәгъгаль димаглы – эшчән зиһенле.
[2] Мөстәбид – изүче, деспот.

байый, сурәтләр арта. Хәзер хуҗа сыйныф белән кол сыйныф арасындагы аерма һәм каршылыкны бирергә теләү дә ялтырап китә.

1912 елда «Карт мулла» килеп чыкты. Моның белән әдип билгеле бер идеология белән коралланып, ул чорда идеология фронтында чын мәгънәсе белән командалык иткән руханилар сыйныфына бер һөҗүм ташлады. Моның үзенә хас бер өслүбе, көчле тәгъбирләре мәүзугына тагын мотабикъ[1] төшә иде.

Инде 1913 нче елда бөек роман «Яшь йөрәкләр»дә әдип үзенең тәрәкъкый баскычына чынлап менеп җитте. Монда инде чын сәнгать иясе әдип булып күренде. Монда авыл күренешләре, табигать тасвирларын соң ноктасына кадәр матур тасвир иттеләр.

Рухның дулкыны баштан кичерүләрне, төрле тойгыларны тасвирның татар әдәбиятында иң уңышлы чыккан җире «Яшь йөрәкләр»дәдер. «Яшь йөрәкләр» кадәр йөрәк тойгыларына бай, «Яшь йөрәкләр» кадәр табигать тасвирлары көчле бер әсәр татар әдәбиятында моңарчы юктыр. Каләм монда һаваларга менәрлек ашкына, әллә кемнәрне утларга салырлык итеп тирги, каләмнән сүзләр генә түгел, утлар оча. Бу ягы аның шул вакыттагы тәнкыйть тарафыннан да әсәрнең артыклыгы саналды.

Бу рухта язылган әсәргә: «Җыласа тантаналы җылый, кызса, куәтле кыза, котыра, шәбәя торган өслүб кенә килешә» диелде (Г. Газиз.)

Галимҗан «Яшьләр хәятеннән бер ләүхә»дә башланган прототипларны «Яшь йөрәкләр»дә тәмамлап эшләп бирде. Вакыйган, «Яшьләр хәятеннән бер ләүхә» белән «Яшь йөрәкләр» арасында тыгыз бәйләнеш бар. Бу шул вакытта «Яшь йөрәкләр» чыккан вакыттагы тәнкыйть тарафыннан әйтелде:

«Яшь йөрәкләр»не Ибраһимовның башка әсәрләре белән чагыштырып карасак, әсәрнең «Яшьләр хәятеннән бер ләүхә»нең башка фонга язылганы дияргә ярый. Ләкин аның белән моны чагыштырганда шагыйранә язылганын, типларның шактый муәффәкыятьле булуларын күрәбез. Шуның өчен шагыйрьнең истигъдадының[2] куәтләнүе белән хөкем итә алабыз» (Г.Г.)

1914 елда язылып бетеп, «Безнең көннәр» басарга бирелә. «Безнең көннәр»дә инде әдипнең тагы да остарганы, тагы да алга киткәне сизелә. Монда инде идеяне бер йомгакка җыйнау, таркау типлар-

[1] Мотабикъ – туры килгән.

[2] Истигъдадының – тырышлыгының, талантының.

дан бербөтен ясау күренә. Бөтен бер дәвернең иҗтимагый типларын дөрес итеп бирә. «Безнең көннәр» романы моңа кадәр татар матбугатында күрелгән әдәби әсәрләр арасында кирәк алынган мәүзугысы, кирәк тасвир иткән буявының көчлелеге, кирәк тәҗәссем иткән[1] типларның реальный булуы, бөтенлеге ягыннан, шөбһәсез, чагыштырылмаслык дәрәҗәдә аерым урында торырга тиештер» (Ф. Сәйфи) дигән отзывны алырга лаек бер әсәр булып чыга.

Монда инде тел, өслүб «Яшь йөрәкләр»гә караганда тагын да эшләнә төшә. Ләкин бераз очыну, ашкыну, урынын чынлыклы төшенү, гакыл белән хисне бергәрәк үлчәп йөртү урын ала.

Иҗтимагый яктан әдипнең үсүе «Безнең көннәр»дә тагын да ачыграк күзгә ташлана. Монда инде аерым кешеләр генә түгел, бөтен бер катлау, бөтен бер сыйныф икенче бер сыйныф белән тартыша. Монда инде турыдан-туры монархиянең эчке йөзе ачыла.

Октябрь революциясеннән соң Галимҗанның өслүб һәм әдәби эшләнүендә күзгә күренерлек алмашыну булды. Бу алмашыну – бердән, өслүбнең һәм техниканың кристаллашып матурлануында булса, икенче яктан простойлашуында күренде. Өченчедән, озын «тезем»нәр (период) урыны кыска. Ләкин көчле, конкрет җөмләләр ала башлады.

1921 нче елда сыйнфый көрәш тормышыннан алып гражданнар сугышы чорын ачык картиналарда биргән «Яңа кешеләр» басылып чыкты.

Әсәрдә Батырхан белән – крестьян тормышыннан чыккан революционер, Камәр белән – укытучылар арасынан чыккан партияле кыз тибы бирелде.

1922 нче елда чыккан «Казакъ кызы» Г. Ибраһимовның әдәби үсүе соңгы ноктасына барып җиткәнен күрсәтте.

Шулай итеп бу әдипнең иҗаты тәдриҗи рәвештә[2] елдан-ел эшләнә, әсәре саен сәнгатьчә эшләнүе үсә барды.

Галимҗан Ибраһимов үзенең иҗатында тормышның очраган бер моментын гына, элеккән бер кисәген генә яки бер почмагын гына тасвирчы булып түгел, тормышны бөтен көе бирүче булып табыла. Ул һәрбер әсәрендә я бөтен бер иҗтимагый дәверне, һич булмаса, иҗтимагый дәвернең бер баскычын шәүләләндерә. Аның геройлары да, күбесенчә, сабыйлык дәвереннән башлап ахыр көннәренә

[1] Тәҗәссем иткән – гәүдәләнгән.

[2] Тәдриҗи рәвештә – акрынлап.

кадәр баралар. Һәр ничек кенә булса да, анда әсәр нәтиҗәләнеп, очланып кала. Ул һичбер вакыт вакыйганың очын югалтып туктамый, шуның өчен Галимҗаннан гади укучы да канәгатьләнеп кала, чөнки аның әсәреннән соң башта бер томанлы уй, күз алдында бер шәүлә генә йөрми, бәлки ачык күренеш куела. Аның әсәрен укыган кеше маякны югалткандай аптырап калмый, ул аңар туры юл ача.

Галимҗан иҗадиятен аеруча яратып, бирелеп укыган һәм иң күп укыган катлау – яшьләрдер. Чөнки аның иҗадиятенең зур бер өлешен яшьләр тормышы ала.

Галимҗанның яшьләре сәяси-иҗтимагый җыелышларда, иҗтимагый мәсьәләләр белән мәшгуль утырышларда, мәктәп-мәдрәсәләрдә, түгәрәкләрдә, казармаларда, сугыш фронтларында, эш, фикер, тартыш мәйданнарында күренүләре белән тагын да әһәмиятләрен арттыралар.

Галимҗан Ибраһимов әсәрләре конкрет рәвештә укучыларга нәрсә бирә? Аның иҗадияте үзендә татарның бер чор иҗтимагыятен дөрес шәүләләндерүе белән үзе аркылы укучының фикерен үстерә һәм тәрбияле, татарда икътисадый-иҗтимагый сыйныфларның психологиясен ачып салу хасияте белән укучыга сыйнфый аерманы таныта, сәнгатьчә нәфис, югары эшләнүе белән укучының йөрәгенә эстетика сала.

*Мәкалә әдәбият тәнкыйтьчесе Хәйретдин Вәли (1893–1969) тарафыннан язылып, «Кызыл Татарстан» газетасының 1927 елгы 16 нчы декабрь (№ 288) санында басылып чыга. Текст басмага газеттан алынды.*

*Нургали Надиев*

## Галимҗан Ибраһимовның педагогия юлындагы хезмәтләре

Галимҗан иптәшне бөек җәмәгать эшчесе, бөек әдип, бөек художник, диләр. Шул яктан аны 20 еллык иҗади хезмәтләре белән бөтен татар дөньясы, ул гына түгел, бөтен төрк-татар дөньясы тәбрик итә. Төрк-татар эшче-крестьян массасы аның белән бергә үзенең мәдәни үсешендә булган уңышларына да йомгак ясап бәйрәм итә. Шул җөмләдән без – мәгариф эшчеләре дә Галимҗан иптәшнең әдәби, иҗтимагый хезмәт бәйрәменә чын күңелдән катнашабыз, аның бәйрәмен үз бәйрәмебез дибез. Чөнки безнең әдәби зәукыбыз, азмы-күпме әдәби өслүбебез эшләнүдә «Безнең

көннәр»нең, «Яшь йөрәкләр»нең, «Кызыл чәчәкләр»нең һәм башкаларның хезмәте аз кермәгән. Бу яктан без Галимҗан иптәшне халкыбызның әдәбияты белән таныш, аны сөюче булып тәкъдир итәбез; гадәттән тыш сәмәрәле хезмәтенә 20 ел тулганда һәрвакыт күңелебездә тулган ихтирамыбызны аеруча белдерәбез.

Ләкин без, мәгариф эшчеләре, Галимҗан иптәшнең саф әдәби әсәрләрен дә, ялгыз сәнгать ягыннан гына, тирән мәгънәле, иҗтимагый яктан әһәмиятле булу ягыннан гына тәкъдир итмибез. Аның һәрбер әсәрен үзебезгә дәреслек, дәреслекләребездә кулланма яки мәүзугъ итеп файдаланып килдек һәм мәңге шулай файдаланачакбыз. Яурупа мәктәпләрендә Цицерон, урыс мәктәпләрендә Гоголь, Пушкин, Некрасов, Толстой кебекләрнең әсәрләре мәңге калган кебек, Галимҗан әсәрләре дә безнең мәктәпләрдә мәңгегә классик әсәрләр булып калачаклар.

Ләкин Галимҗан иптәшнең педагоглыгы шунда гынамы? Юк. Бу кадәресе әле безнең башкалар белән уртак өлешебез генә. Бу кадәресе әле һәрбер талантлы әдип, җәмәгать эшчесе, педагог булганлыктан Галимҗан иптәшнең табигатендә педагоглык барлыгыннан килгән өлеше. Галимҗан үзенең әдәби әсәрләрен язганда аларның мәктәпләрдә тикшереләчәген, укылачагын, яшь буынның матур сөйләү, матур инша дәреслеге булачагын башына да китермәгәндер. Шулай да даһи талант үзенең иясе көтмәгән уңышлыклар биргән. Шуның аркасында Галимҗан татар эшче-крестьян массасының 10 яшьлек баласыннан алып ак сакалына кадәр якын таныш һәм «үз кеше» булып киткән.

Галимҗан иптәш моның белән генә канәгатьләнми, ул үзе татарның бик иске мәдрәсәсендә укып, аны төрле яктан өйрәнеп, ахырдан өстенә төкереп, яхшырагын, яңарагын эзләп китә. «Галия»гә барып яңа методлар белән фәннәр укымакчы була. Ләкин аның киң педагог табигатен мондагы тәртипләр дә, тәрбия системасы да, китаплары да, укытучылары да, методлары да канәгатьләндерми.

Педагог талант бетмәс-төкәнмәс энергиясен урысча укырга сарыф кыла башлый. Галимҗан урысчаны да гади татар шәкертечә аттестатка хәзерләнүгә укымый. Мәдәни халыкларның телләрен фәнни яктан күзәтә. Татар теленең эшләнмәгәнлегенә ачына. Насыйрилар тарафыннан башланып та ташланган тел мәсьәләсенә бил баглап керешә. Бер яктан үзенең әдәби әсәрләрендә татар телен сакласа, аңарга стиль иҗат итсә, икенче яктан аның имлясен эшли, нәхүен фәнни нигезгә куя. Дөрес, Галимҗанга кадәр

дә сарыф, нәхү юк түгел иде, ләкин алар төрле тәэсир астында язылып, татар теленең хосусияте, фонетикасы, морфологиясе һәм нәхүе хосусиятләре ригая кылынмый иде. Галимҗан шуларның барысын да игътибарга алып, татарның мәктәбенә, малаена-кызына ярарлык сарыф-нәхү китаплары, имля кулланмасы бирә алды. Бу бабта беренче приз, әлбәттә, Галимҗанга.

Татар теленең әдәбият кануннарын язу түгел, бәлки барлыгына да бик аз кешенең башына килгән бер дәвердә Галимҗан «Әдәбият кануннары» бирде. Татарның рәтләп уку китабы булмаган бер заманда шул ук Галимҗан «Яңа әдәбият» хрестоматиясен бирде. Шул ук педагог иптәшебез башлап татар теленең методикасын бирде. Галимҗан иптәшнең педагогия-методика юлында иткән хезмәтләренә без тиешле дәрәҗәдә бәя биреп җиткезә алмабыз. Без монда тик күләм ягыннан гына хөласа ясап[1] китәрбез. Аның хаслап мәктәп, мәдрәсәләр өчен биргән әсәрләре:

1 – «Татар сарыфы» – 1911 ел, 82 бит.

2. «Татар нәхүе» – 1911 ел, 74 бит.

3. «Татар имлясы» – 1914 ел, 28 бит.

4 – «Яңа әдәбият» (дәреслек) – 1914, 240 бит.

5 – «Әдәбият кануннары» 1916 ел, 148 бит.

6 – «Татар телен ничек укытырга» 1918 ел, 76 бит.

7 – «Яңа әдәбият» (2 нче китап) – 1919 ел, 231 бит.

8 – «Тел сабаклары» – (беренче китап) – 1918, 36 бит.

9 – «Тел сабаклары» – (икенче китап) – 1919, 47 бит.

10 – «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» 1923 ел, 143 бит.

Моннан башка Галимҗан иптәшнең үз кулында мәйданга чыкмый ята торган әсәрләре арасында «Әдәбият кануннары»ның өр-яңадан эшләнгән кульязмасы ята.

«Шура», «Аң» журналларын актарып караганда, Галимҗан иптәшнең тел, әдәбиятка карата язылган бик күп мәкаләләре очрый.

Галимҗан иптәшнең хезмәтләре турында сүз барганда мин аның 1915 елда Уфа киңәшмәсендәге хезмәтен искә төшерми китә алмыйм. 1915 нче елда Уфада укытучылар һәм мәктәп китаплары язучыларның бер киңәшмәләре булганлыгы, шаять, һәркемгә мәгълүмдер. Бу киңәшмәдә ике генә мәсьәлә куелган иде: 1) имля мәсьәләсе һәм 2) татар мәктәпләренә китаплар сайлау яки китап төзү өчен әсаслар билгеләү. Бу киңәшмәнең иң зур белгече, иң зур

[1] Хөласа ясап – нәтиҗә ясап.

гайрәт, дәрт белән эшләүчесе Галимҗан иде. Ул үзенең туры мөхакәмәләре[1], педагогча карашлары белән бөтен киңәшмәгә тон биреп торды. Галимҗан ул вакытта булган бөтен мәктәп китапларын энәсеннән җебенә кадәр белгәнлеген күрсәтте.

Галимҗан югарыда күрсәтелгән нәзари каләм хезмәтләрен кабинетта гына эшләдеме? Юк, ул практик педагог.

Ул бөтен педагогик-методик әсәрләрен гамәли эш өстендә эшләде. Шул әсәрләргә ихтыяҗны аңлап, сизеп эшләде. Элек үзенең нәзариятен тәҗрибә белән сынап карады. Шуннан соң гына мәйданга чыгарды. Ул Уфада мөгаллимнәр, мөгаллимәләр курсларында мәдрәсәи «Галия»дә, Киевта, Дагстанда, Казакъстанда һәм революциядән соң төрле гаскәри курсларда өлкә партия мәктәбендә һәм татар коммунистлар университетында 1925 нче елга кадәр өзлексез укытып килде.

Инде Галимҗан иптәшнең гыйльми үзәктә вакыттагы хезмәтенә килсәк, ул бу урында үзенең гаять оста оештыручы, гаять нечкә педагог икәнчелеген бик яхшы күрсәтте. Комплекс программаларының Татарстан мәктәпләренә кереп үзләшеп китүе, аларның үз шартларыбызга карата эшләнүләре күп кенә метод, инструкцияләре белән укытучыларга җитәкчелек итүе барысы да Галимҗан иптәшнең онытылмаслык хезмәтләреннән санала. Галимҗан иптәшнең гыйльми үзәктә чагындагы хезмәтләреннән берсе итеп «Мәгариф» журналын алып баруда якыннан торып җитәкчелек итүен исәпләргә тиешбез. «Мәгариф»нең соңгы елларда көннән-көн яхшырып баруында Галимҗан иптәшнең тәэсире, әлбәттә, зур булды.

Бу бер кечкенә мәкалә белән Галимҗан иптәшнең бөтен хезмәтләрен санап һәм тәкъдир итеп бетерә алмабыз. Тик бөек әдип һәм педагогыбызның шатлыклы бәйрәмен бөтен эшче-крестьян халкы белән бергә без дә шатланып үткәрәчәгебезне белдерәбез.

*Мәкалә педагог, 1927–30 елларда Гыйльми Үзәк рәисе урынбасары Нургали Надиев (1882–1940) тарафыннан язылып, 1928 елны «Мәгариф» журналында (№ 2) басылып чыга. Текст басмага журналдан алынды.*

*Текстларны басмага ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре Ләйлә Гарипова әзерләде.*

[1] Мөхакәмәләре – тикшерү-хөкемнәре.

*Ә. Гаффаров*

**Казандагы рус матбугатында Г. Ибраһимовның кайбер әдәби әсәрләре турында фикер, тәнкыйтьләр**

Галимҗан Ибраһимовның әсәрләре турында, гомумән, урыс матбугатында күп кенә нәрсәләр язылды. Аның гыйльми хезмәтләре, әдәби әсәрләре урыс гыйльми дөньясы, бигрәк тә көнчыгышны өйрәнү органнары тарафыннан тикшерелде, алар турында төрле фикерләр, тәнкыйтьләр язылды. Мин монда Галимҗан Ибраһимов әсәрләре турында Казандагы урыс матбугатындагы кайбер тәнкыйтьләргә, фикерләргә генә тукталып китәм: чөнки, гомумән, бу турыда башка иптәшләр дә язалар.

Казанда 1912 нче елдан башлап 1916 нче елга кадәр нәшер ителеп килгән «Инородческое обозрение»[1] журналында[2] Идел буе татарлары әдәбияты шулай ук казакъ-башкорт әдәбияты турында һәрвакыт язылып, тикшерелеп барылды. Айлап-айлап вакытлы матбугат тикшерелеп барган кебек бөтен матбугат турында да еллык тикшерелүләр (обзор) ясала иде. Бу турыда күп язучылар: профессор Катанов, профессор Ашмарин, Емельянов кебек урыс галимнәре иде.

1915 нче елгы «Таң» журналына[3] гыйлавә[4] ителеп нәшер ителгән «Альманах»та басылган Галимҗан Ибраһимовның «Табигать балалары» дигән әсәре турында Емельянов болай дип яза: «Сюжеты ягыннан гади генә булган бу хикәя сәнгатьчә яхшы эшләнгән. Бу хикәя үзенең гадилеге, фабуласының табигый булуы ягыннан Галимҗан Ибраһимовның үткән ел чыккан «Яшь йөрәкләр» романының нәкъ киресе булган. «Яшь йөрәкләр»дә автор мөмкин кадәр фәлсәфә сата, тирәнерәк нәрсә уйлап чыгарырга маташа. Монда ул гади, табигый, шуның өчен аның бу хикәяте тегесенә караганда уңышлы чыккан. Авторның хикәя сөйләүче авызыннан сөйләткән сүзенең төп сыйфаты, характеры, тоны баштан ахырына кадәрле

---

[1] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән «Инородическое обозрение» дип бирелгән.*

[2] *«Инородческое обозрение» – Казан руханилар академиясе тарафынннан нәшер ителгән «Православный собеседник» журналының кушымтасы. 1912–1916 елларны дөнья күргән, редакторы Н.Ф. Катанов. (Г. Ханнанова искәрмәсе).*

[3] *Бередә типография хатасы киткән. Сүз «Аң» журналы редакциясе чыгарган әдәби «Альманах» (хикәяләр вә шигырьләр мәҗмугасы) турында бара (Г. Ханнанова искәрмәсе).*

[4] Гыйлавә – кушымта.

матур сәнгать сорауларына муафикъ булып[1] чыккан. Хикәя сөйләүченең шәхси тән һәм әхлак ягыннан сәламәт булган, авыл табигатен, крестьян хезмәтен сөя торган авыл егете булып безнең күз алдына килеп баса. Аның сүзләреннән батырлык, йөрәклелек рухы аңкып ята. Дөрес, хикәя сөйләүченең сүзе аерым матурлык, ялтыравыклык белән аерылмый. Авыл егете авызыннан моны ишетү, күрү үзе килешсез, гаҗәп тоелыр иде. Ләкин хикәяченең сүзе халык теленең үткен, көчле аңлатулары, ифадәләре белән тулып ята. Ул сүз барышына аерым үзенә хас матурлык, җанлылык бирә.

Хикәяттәге «печән чабу» картинасы этнография, крестьян тормышын өйрәнү ягыннан да бик әһәмиятле (Емельянов хикәятнең кыскача мәфһүмен[2] язып чыга). Емельянов Галимҗан Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы турында да озын тәнкыйть яза. Емельянов мондый зур роман әле татар телендә моңарчы күренгәне булмавын, шуның өчен авторга романын тиешле дәрәҗәдә уңышлы чыгару авыр булуын, әсәрдәге типларның тиешле дәрәҗәдә эшләнеп җитә алмавын сөйли.

Галимҗан Ибраһимов яшь нәсел типларын тиешле дәрәҗәдә ачып бирә алмаган, әсәрнең исеменә карап хөкем иткәндә, аның баш каһарманнары – яшь нәсел кешеләре, ягъни Мәрьям белән Зыя булырга кирәк иде. Ләкин, чынлыкта, бу кешеләр романдагы башка типларга, бигрәк тә, иске нәсел типлары белән чагыштырганда, күп мәртәбә йомшак чыкканнар.

Язучының яхшы каравына карамастан, Мәрьям әсасән[3] сәлби тип[4] булып чыккан, сөйкемсез чыккан. Зыя үзенең дусына язган хатында, Мәрьямнең әллә нинди эчке артыклыгы, аның рухани сөйкемлелеге, матурлыгы турында сөйли һәм хатын-кызга түшәк өчен генә яратылган мәхлук[5] дип карый торган кешеләрнең ул сыйфатларны аңлый алмавын әйтә. Ләкин бу сыйфатлар, аның рухани матурлыгы, артыклыгы нәрсәдән торганы һич тә күрсәтелмәгән. Киресенчә, Зыя Мәрьямнең матур кыяфәте, йөзе, авызы, борыны, матур тавышы турында гына сөйли. Кыскача әйткәндә, аның тышкы матурлыклары гына Зыяның исен ала.

---

[1] Муафикъ булып – яраклы, урынлы булып.
[2] Мәфһүмен – эчтәлеген.
[3] Әсасән – нигездә.
[4] Сәлби тип – тискәре тип.
[5] Мәхлук – җан иясе.

Мәрьямнең өлгереп җиткән кыз булып анасы янында торган чактагы тормышы да үзенең бушлыгы, мәгънәсезлеге белән хәйран калдырырлык.

Әмма иргә чыккан соңындагы тормышы вакытында ул, Мәрьям, безнең каршыга үзенә кызгану хисе дә кузгата алмый торган туп-туры җинаятьче кеше генә булып күз алдына килеп баса.

Зыя шәхесе дә әхлак ягыннан бик югары түгел. Язучыга аның нәзәкате, хатын-кыз табигате, үзеннән үзе туган музыкага осталыгы бик яхшы. Ләкин бу сыйфатлар барысы да Зыядагы җинаятьлелек белән яраша ала. Карт сакчыны үтерү аның вөҗданына бер дә артык зур йөк була алмый. Аның киләчәк тормышына һичбер әсәр итми[1].

Язучы иске кешеләрне, иске нәсел кешеләре типларын яхшы ук зур уңыш белән сыйфатлый алган: Зыяның ата-аналары Җәлал һәм Зөләйха абыстай шәхесләре зур уңыш белән тасвир ителгән. Зыяның атасы үзен сөя торган мактанчык, дәгъвалы авыл мулласы тибы, ул галимлек шөһрәтен ярата, шуны дәгъва кыла. Ул үзенең нәсел шәҗәрәсен бик ерактан 200 елдан бирле алып килә, аның бабалары да гади мулла гына булмаганнар. Һәммәсе «галим» булып үзләренең ишанлыгы белән дан чыгарганнар. Үзен олылау, андагы эгоизм кечкенәдән үк мәгълүм була.

Җәлалнең хатыны Зөләйха абыстай, әгәр дә автор аның шәхесен җанландырып тасвир итәргә күбрәк әһәмият биргән булса, чыннан да романның төп каһарманы булып китәр иде. Бу – дөресен дә иҗаби тип[2], сабырлы, сүзсез бу абыстай өйдәге бөтен авырлыкларны күтәрә, иренең берәр нәрсәгә кәефе китеп кайткан, берәр нәрсә белән аның эгоизмы җимерелгән чакта бөтен начарлык аның өстенә төшә. Ул ире өчен дә, балалары өчен дә чын күңеле белән борчыла. Аларны шәфкать белән карый, тәрбияли. Зыяның сугыш хезмәтенә алынуы соңындагы кайгысы бик зур була. Ул үзенчә кайгыра. Зыя китәсе көнне ул бөтен төн буенча йокламый, җылый-җылый гыйбадәт белән, Коръән укып төрле кайгылы уйлар уйлап үткәрә. Ул соңгы көннәрдә танымасылк дәрәҗәдә үзгәрә. Аның йөзе ябыга, саргая. Зур күзләре эчкә батып, эчке тирән кайгы белән тула. Алар һәрнәрсәгә хиссез рәвештә карый башлаган иде...»[3] ди Емельянов. Шул ук Емельянов Галимҗан Ибраһи-

[1] Әсәр итми – йогынты ясамый.

[2] Иҗаби тип – уңай тип.

[3] *Ул озын тәнкыйттән монда кыска өзмәләр генә алынды. Теләгән кешеләр аны «Инородческое обозрение» нең 1914 елгы 7 нче китабыннан карарга була.*

мовның «Татар шагыйрьләре» дигән әсәре турында[1] һәм дәреслек итеп язылган «Яңа әдәбият» дигән әсәре (Баттал белән бергә язган) турында үз фикерен әйтеп китә. «Яңа әдәбият» турында ул: «бик матур күп рәсемнәр белән зиннәтле рәвештә нәшер ителгән бу әсәр национализм тенденциясе белән язылган, балаларның табигате, аңнары белән җитәрлек дәрәҗәдә хисаплашылмаган» дип әйтә[2].

Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр», «Адәмнәр», «Казакъ кызы» дигән әсәрләре турында Г. Гобәйдуллин татарны өйрәнү җәмгыяте тарафыннан чыгарыла торган «Вестник научного общества татароведения»[3] журналында тикшерү, тәнкыйть язды. «Татар әдәбиятын Галимҗан Ибраһимов соңгы елларда тагын яңа әсәрләр белән баетты, Галимҗан Ибраһимов татар әдәбиятының классик әдипләреннән берсе. Татарларның башка язучылары татарларның иске тормышын җимерү, урта гасыр карашлары белән көрәш юлында Октябрь революциясенә кадәр эшләделәр дә шунда туктап калдылар. Галимҗан Ибраһимов электә дә революция рухы белән рухланган иде, ул хәзердә дә шул юл белән бара. Галимҗан Ибраһимов үзенең «Безнең көннәр» романында татарның иске тормышы һәм 1905 нче елдагы революция картинасын бик матур рәвештә тасвир итә алды.

Аның әсәрләре арасында 1924 елда чыккан «Адәмнәр» хикәясе аерым урын тота. Монда язучы татар тормышына, җәмгыятенә хас даирәдән чыгып, бөтен инсанияткә хас булган мәсьәләне кузгатты. Татар авыл тормышын алып, ачлык аркасында, кеше ашау психологиясе ничек үсүен тасвир итте. Бу хикәядә марксист-материалист язучы ачлыкның урта хәлле крестьян психикасына коточкыч дәрәҗәдә начар йогынты ясаганын, җинаятьнең экономика сәбәбеннән булуын бик ачык итеп аңлата алган.

Мин тарихчы булуым сыйфаты белән Галимҗан Ибраһимовның күптән түгел чыккан «Казакъ кызы» дигән әсәренә аерым әһәмият бирәм. Ул һәр яктан әһәмиятле, бердән, язучы монда кыргыз-кайсаклар тормышын бик шәп, бик ачык тасвир итә алган. Бигрәк тә ул романда бай... […][4]

---

[1] *Инородческое обозрение. Кн. 7, ст. 498.*

[2] *Инородческое обозрение. Кн. № 12, ст. 017 (1915 г.).*

[3] *Чыганакта кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] *Квадрат җәяләр эченә алынган урында текстта өзеклек барлыкка килде. Газетаның бу өлеше кисеп алынган.*

Мондагы ул көрәш картиналары, үзләренең төпле документларга бина кылынган булуына карамастан, томанлы булып кала. Ачык аңлашылмый. Әмма «Казакъ кызы» менә социаль хәлне бик ачык күзгә бәрелерлек итеп тасвир итә. Художник булмаган, тарихчы аңламаслык детальләрне ачып бирде һәм ахырында: «Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы»н укыгач, укучы алдында бөтен нәрсәләре белән ачык аңлашыла, Ибраһимов китабыннан ул тормышны аңлар өчен ачкыч табасың. Икенчедән, Галимҗан Ибраһимовның романы бүгенге кыргыз-казакълар этнографиясен өйрәнү өчен бик әһәмиятле, монда бүгенге кыргызлар тормышы бөтен күренеше белән алга китерелеп бастырылган. Галимҗан Ибраһимов романында казакъ гаиләсенең нидән гыйбарәт булуы, гаширәт[1], кабиләләре, туй гадәтләре, күмү гадәтләре, кымыз сыйлары, кием-салымнары, йорт җиһазлары, халык моңнары, үзара сугышлар, хуҗалык, колонизаторларга мөнәсәбәт – барысы да бик ачык тасвир ителгән.

Өченчедән, бу – тел ягыннан әһәмиятле, роман татар телендә язылган. Ләкин казакъ шивәсенең кайбер сүз төзелешләре, күп сүзләре кергән. Язучы моны ике халыкка аңлашырлык итеп оештыра алган» дип мәкаләсен бетерә. […][2]

*Мәкалә шул еллардагы матбугатта язмалары даими басылып килгән журналист Әхәт Гаффаров тарафыннан язылып, 1928 елны «Кызыл Татарстан» газетасының 10 март (№ 60) санында дөнья күргән. Без караган газета нөсхәсендә мәкалә азагындагы текст киселеп, ахыргы өлеше укылмый калу сәбәпле, язманың авторы «Галимджан Ибрагимов. Библиографический указатель (1907–1977)» (Уфа, 1979) күрсәткече буенча билгеләнде.*

*Миңлекәй*

**Сәлам хат**

*(Галимҗан ага Ибраһимовның әдәби хезмәтенә егерме ел тулу уңае белән)*

Егерме ел буе каләм тотып,
Ак кәгазьгә эзләр саласың,
Егерме ел армый-талмый үткән
Юлга маяк кадап барасың.
Бүген әле синең бәйрәмеңдә
Шул маяклар алда тезелде:

[1] Гаширәт – туганнар.

[2] *Биредә газетадагы текст кисеп алынган.*

Колак төпләремдә
«Кояш чыкты...
Уян шәкерт!...»
Йыры сузылды...
Әнә, баш миләре кузгалдылар,
Яшь йөрәкләр типте дәрт белән.
«Байга хезмәт итеп кем ярый?» дип
Кайтам кырдан «Ялчы карт» белән.
Күз алдында тырыш сабанчылар,
Уракчылар тезелеп үтәләр...
Малай-салай, әнә «Яз башы»нда
Кармак белән балык тоталар.
Таңнан алып кояш баегангача
«Көтүчеләр» көтү көтәләр,
Изү чишеп печән чабучылар
Яңгыратып йыру сүтәләр...
Авыл!
Йорт-җир карап, маллар саклап,
Урман ташып тормыш күрәләр,
Бай, муллалар, мирза, зыялылар
Һәм ярлылар ничек торалар?
Алга баса «Алмачуар» колын,
«Казакъ кызы» – казакъ даласы...
«Ниләр күрми – мескен – татар хатыны?»
Ул да барыбер адәм баласы!
«Безнең көннәр» шунда гәүдәләнде
Алдыбызда «Чулпан» балкыды,
«Яңа кешеләр» дә туып чыкты,
«Кызыл чәчәкләр» дә калыкты...
Синең сизгер акыл, армас каләм
«Адәмләр»не язып күрсәтте.
Әткәй, әнкәй, әбкәй, бабкай сөйләп
Дөнья көткән телне өйрәтте...
Сизәм, сизәм ярлы халкың өчен
Кичә, көндез эчтән син янып.
Сизгер акыл белән эшләп килдең
Билне буып, җиңне сызганып.
Каләм тотканыңа егерме ел
Хезмәт халкы,

Газиз агабыз!
Бәйрәм итә...
Без шул бәйрәмчеләр
Сине котлап сәлам язабыз....
*Ленинград.*

*Шигырь шагыйрь, педагог Сәхаутдин Кашшафетдин улы Миңлекәй (1895–1954) тарафыннан Ленинград шәһәрендә өч еллык югары кооператив курсларында укыган вакытта (1926–1929) язылган. Беренче мәртәбә 1928 елда «Безнең юл» журналының 2 нче санында, гарәп графикасында дөнья күрә. Журналда автор «Миңлекәй». Соңрак, 2001 елны, С. Миңлекәйнең шигырьләрен, аның хакында кайбер истәлекләрне үз эченә алган «Сабанда» (төз. Э. Ханнанова-Галимҗанова, фәнни редакторы М. Әхмәтҗанов) исемле җыентыкта урын алган. Текст басмага журналдан алынды.*

*Г. Кутуй*

**Әй, каләм!**
*(Галимҗан абый Ибраһимовка)*

Әй, каләм, бишегем, кадерлем...
Чалланып бетте чәчең.
Чәчкәнең чын
Чын яралды
Чынсызын, син, чәчмәдең.
Акты яшең, акты корычың,
Булды диңгез
Язганың.
Язганың – сүз,
Һәр сүзең – эш,
Эшләреңнән язмадык.
Язмадык, бардык эзеңнән...
Көзге иттек –
Күргәнең.
Күргәнең – ул чын иде.
Чыннарыннан да –
Белгәнең.
Белгәнең күп,
Күргәнең киң,
Киң иде йырың синең
Йырладың бала – көрәшне...

Инде күр –
Ул,
Зур көрәш –
Йырлый сине!

*Шигырь язучы, шагыйрь һәм драматург Гадел Кутуй (Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев); (1903–1945) тарафыннан язылган. «Безнең юл» журналының 1928 елгы 2 нче санында (Г. Ибраһимовның егерме еллык иҗат юбилеена багышланган санда) дөнья күргән. Текст басмага журналдан алынды.*

*Текстларны басмага Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фәнни хезмәткәре Гөлчирә Ханнанова әзерләде.*

*Уйгур*

## «Татар шагыйрьләре»

Мәдәни халыкларның әдәбиятында тәнкыйд шундый зур урын тота ки, бер мөхәррир әдәбият тарихында тик мөнәкъкыйдлек[1] белән генә үзенә мәңгелек исем калдыра; тәнкыйд әдәби вә гыйльми әсәрләрнең кимчелек вә кәмалəтләрен[2] ачыб бирү илә генә калмыйча, мөхәррир вә мужидләргә[3] юлбашчы да була. Пушкин, Гогольләрнең шигъри әсәрләрен шәрех вә тәфсир итеб, аларның кадер вә кыйммәтләрен бөтен дөньяга ачыб биргән рус мөнәкъкыйде Белинскийның рус әдәбият тарихында нинди зур урын тотканлыгы әрбабына мәгълүм.

Тәнкыйть аркасында яхшы ямандан аерыла, чын вә кыйммәтдар әсәрләрнең бәһаләре укучы җәмәгатькә ачык күрсәтелә вә бу саядә әдәбиятның барышы, язучыларның ишгаль итәргә[4] тиешле урынлары аңгарыла.

Тәнкыйд нәрсә? – «Критериум диб аталган кагыйдә вә әсасларга таяныб, бер әсәрнең кимчелек вә кәмалəтләрен аерым ачык күрсәтеб бирү». Бу мәгънә белән тәнкыйть бездә әле юк иде, диб әйтсәк, күб яңлышкан буламыз.

---

[1] Мөнәкъкыйдлек – тәнкыйть итү.
[2] Кәмалəт – җитешкәнлек.
[3] Мужидләргә – иҗат итүчеләргә.
[4] Ишгаль итәргә – яктыртырга.

«Шура»да тәкъриз[1] вә интикад[2] бабында язылган нәрсәләр, гәзитәләремездә «Яңа әсәрләр» сәрләүхәсе[3] астында басылган мөляхәзәләр[4], әлбәттә, чын тәнкыйть түгел инде алар; бинаән галәйһи[5] минем бу мәкаләмдәге сүзләр дә тәнкыйд булмыйча, тик мөһим бер әсәр хакында ике авыз сүз әйтеб китүдән гыйбарәт булачак.

Чын тәнкыйдкә охшашлы язулар бездә яңа күренә башлады. Г. Газиз белән Н. Хәлфин мондан бер-ике ел элек «Олуг кешеләр вә аларның әсәрләре» сәрләүхәсе белән мөхәррирләремездән Гаяз әфәнде Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз», Н. һәм Й. Акчура углының «Мәүкуфиять хатирәләре»н[6] тәнкыйд итеб караганлар иде. Күбдән түгел «Вакыт»да «Җәләй» имзалы бер егет «Әдәби мосахәбәләре[7]» белән берничә тәнкыйдләр языб алды.

Гәзитә вә журналларымызда байтак мәкаләләре белән үзенең тәнкыйдкә истигъдадын[8] күрсәткән яшь мөхәррир Галимҗан әфәнде Ибраһимов бу юлы тәнкыйдкә гаид 102 битлек бер әсәр языб чыгарган. Галимҗан әфәнде «Татар шагыйрьләре» адлы бу әсәрендә өч шагыйрьне, ягъни Сәгыйд Рәмиев, Дәрдемәнд, Габдулла Тукаевны тикшерә – аларның шигырьләрен тәнкыйд вә тәхлил итә[9]. Китабның тышында вак хәрефләр белән «Беренче бүлем» диб куелган. Моңа караганда китабның икенче, өченче бүлемләре дә булырга охшый. Мәйданга чыгу ягыннан яңа шагыйрьләремезнең иң алдынгысы булган М. Гафурины мөнәкъкыйд киләчәк бүлемләргә калдырган, күрәсең.

Сәгыйд Рәмиевне шагыйрьлек ягыннан күб кеше белми, аның шигырьләрендән 24 битлек бер генә мәҗмуга басылган, бу мәҗмуга диккатьләре җәлеб итеб, Сәгыйдкә халкымыз арасында мәгъруфият[10] бирә алмады. Әмма Г. Ибраһимов аны әсәрендә иң алга куеб, сүзне «Татар шагыйрьләре» дигәч үк хәтеремә Сәгыйд

---

[1] Тәкъриз – язылган хезмәткә мактап бәя бирү.
[2] Интикад – әсәрләрне битараф рәвештә җентекләп тикшерү нәтиҗәсендә җитешсезлекләрне күрсәтү.
[3] Сәрләүхәсе – мәкалә исеме.
[4] Мөляхәзәләр – фикер йөртүләр.
[5] Бинаән галәйһи – шуның өчен.
[6] «Мәүкуфиять хатирәләре»н – «Тоткынлык хатирәләре»н.
[7] Мосахәбә – кара-каршы сөйләшеп утыру.
[8] Истигъдадын – сәләтен.
[9] Тәхлил итә – анализлый.
[10] Мәгъруфият – танылу.

Рәмиев килә...» диб, шук вә интузиазм белән башлаб китә. «Сәгыйд Рәмиевнең шигырьләре»ндә «Уку, уку, уку»лар,

«Имди алайса сакалыңны
казаханә юлына
руслара йолкыб бирәек
гәзит кәгазе урнына»

кеби тупаслыклар вә башкаларны күргәндә һәркем: «Моның дистәләб саналган назыймлардан[1] кай төше артык соң?» – диячәк. Мөнәкъкыйд дә: Сәгыйд хакында сүз ачылганда, аның «Уку», «Муллалар эше», «Хатынлар галәме» атлы әкәмәтләрен, һәм дә «Театру» дигән нәрсәсенең бер-ике мисрагъдан башкасын сызыб ташлаб сүзгә керешәм» диядер.

Мөнәкъкыйд бездә иң беренче урын тоткан шагыйрь – Сәгыйд Рәмиев диб дәгъва итә дә, «С. Рәмиев – чын шагыйрь, аның яздыклары – котлы шигырьләрдән димез. Ничөн?» дигән бер сөаль куя. Шундан соң бу сөальгә, шигырь белән шагыйрьне тәгъриф итеб[2], җаваб бирә вә шул җавабы белән безгә теге дәгъвасының хаклы булганын исбат итәргә тырыша. Мөнәкъкыйднең шигырь вә шагыйрьне тәгърифләре бездә яңа нәрсәләр. Бу тугрыда ул бер вакытлар «Йолдыз»да бераз сүз кыйлган иде, белмим ул сүзләр, ягъни нәзым[3] белән шигырь арасын аерым күрсәтергә тырышылган ул тәҗрибәләр ничә кешенең диккатен җәлеб итде икән?

Һәрхәлдә мөнәкъкыйднең ул язулары хәзерге «Татар шагыйрьләре»ндәге бәхәсләренә бәгъзе гакылларына бераз хәзерләгән булса кирәк. Мондан элек бездә һәрбер озынлы, кафияле[4] сүз «шигырь» диб атала иде. Бу бер истыйлях[5], моңа каршы бер сүз дә каршы әйтеп булмый. Шунлыкдан мөнәкъкыйднең 12 нче битдә «бездә шигырь белән нәзымны, шагыйрь белән назыймны һаман бутыйлар, боларны аерырга күбдән вакыт!..» диб орышуы урынсыз.

Без бүген сүзнең мәгънә вә эчке ягындан карап, ягъни грекчадагы поэзия урынына «шигырь» сүзен, поэт урынына «шагыйрь» сүзен истыйлах итеб куйсак да, ул безнең генә истыйлах бит, тегеләр шигырьне сүзнең тышкы ягындан караб, үлчәүле вә кафияле

[1] Назыймлардан – шагыйрьләрдән.
[2] Тәгъриф итеб – аңлатып.
[3] Нәзым – тезмә.
[4] Кафияле – рифма.
[5] Истыйлах – термин.

сүзгә итлак кылганнар[1]. Без хәзер шигырьне нәзым мәгънәсендә кулланган кешеләрне орышмыйча, аларга нәзым сүзен үлчәүле вә кафияле сүз мәгънәсендә, шигырьне бөтенләй яңа мәгънәсендә истигъмаль кылабыз[2], диб үземезнең истыйлахларымызны гына гарыз кылырга[3] кирәк.

Мондан шигырь вә шагыйрьне үзенчә тәгъриф итеб алгач, Сәгыйдне, шул якдан тикшереб, күкләргә күтәрә. Әлегәчә халыкка алай бигүк танылмаган Сәгыйд, Галимҗан әфәнденең тикшерүе аркасында, хәзер татар дөньясында шагыйрьнең гәүдәләнгән тәмаселы булыб[4] берүзе тора.

Бу күп кешеләргә сюрприз – көтелмәгән бүләк булачак. Галимҗан әфәнденең С. Рәмиев хакында бу әсәре чыккач, Г. Газиз дә аның хакында охшашлы бер мөляхәзәсен «Аң»да басдырырга батырлык итде. Бу да «Татар шагыйрьләре»ндәге фикерне тәкъвия итәргә[5] яраячак. Әсәрдә Рәмиевкә 28 бит урын бирелгән.

С. Рәмиевдән соңра мөнәкъкыйд шагыйрьлек белән халкымызга тагын да азрак танылган «Дәрдемәнд» дигән псевдоним иясен куя. Дәрдемәнд «Шура»ның иге-чиге булмаган күб шагыйрьләрендән берсе. Ләкин ул күб шагыйрьләрдән «гариб»,[6] «фәраг»[7] дигән, псевдоним ияләре ничөн мөнәкъкыйднең диккатен җәлеб итмичә, Дәрдемәнд генә җәлеб иткәндер, анысы безгә мәгълүм түгел. Дәрдемәнднең аерым рисалә булыб, «Балалалр өчен вак хикәяләр» генә басылыб, шигырьләре басылганы юк әле. Мөнәкъкыйд Дәрдемәнднең татар әдәбияты дөньясына «Кораб» шигыре белән чыкканлыгын, ягъни аның басылган беренче шигыре шул булганлыгын аңлата. Занымча, бу – яңлыш. «Кораб» «Шура»да басылды. Хәлбуки, Дәрдемәнднең андан элек дә «Вакыт»да әллә нинди коры нәзымләре басылыб чыккан иде. Әсәрдә Дәрдемәнднең «Кораб»ына бик зур асылият (оригинальлек) бирелеб, аңа әллә нинди олуг мәгънәләр иснад ителә[8], озын-озын шәрехләр языла. Ләкин Г. Тукаевның «Әлли-бәлли итәр бу»ының мәәхәзен[9]

---

[1] Итлак кылганнар – исем биргәннәр.
[2] Истигъмал кылабыз – файдаланабыз.
[3] Гарыз кылырга – аңлатырга.
[4] Тәмасыле булыб – тиңдәше булып.
[5] Тәкъвия итәргә – куәтләргә.
[6] Гариб – ят-чит.
[7] Фәраг – бушлык.
[8] Иснад ителә – бирелә.
[9] Мәәхәзен – чыганагын.

Лермонтовдан казыб чыгарган Галимҗан әфәнде, әгәр тикшерсә, «Кораб»ны да шул ук Лермонтовдан таба алмас идеме икән?

Мөнәкъкыйд Дәрдемәнднең телен бик мактый, ләкин шигъриятне исбатда телнең ул хәдле зур роль уйнамаганлыгын ул үзе дә игътираф итә[1]. Бу җәһәт һәрхәлдә бик мөһим түгел, монда ягъни мөнәкъкыйднең Дәрдемәнд хакындагы мөляхәзәсендә минем дикъкатемне бигрәк башка бер нәрсә җәлеб итде: мөнәкъкыйд Дәрдемәнднең шигырьләрендә аерым бер хосусият итеб бәдбинлек[2] – дөнья вә ма фиһага[3] тонык күзлек аркылы аларның тискәре ягындан карау икәнлеген күрсәтә вә: «Аның әшгарендәге рух шундан гыйбарәт: «Җиһан фани, һәр нәрсә зәваллы!» ди. Монда мин искитәрлек хосусият вә мөмтазият[4] күрә алмыйм: бу рух шундый гомуми, шундый искергән бер нәрсәдер ки, аны һәрбер гарәб вә төрек шагыйрьләренең нәзымларындан ашаб йөри торган бер токым «шагыйрьләр», ингам ихсанлар[5] азайган саен, дөньядан зарлана, тәкъдирне пинәли вә инсанларны шелтәлиләр иде. «Дөнья фани, ахирәт бакый»лыгын нинди хак мөселман белми дә, нинди хак мөселман һәрбер хәрәкәт вә эшләрендә шуны дәстүрел-гамәл[6] итеб тотмый?

Җаһилият шагыйре Ләбид тарафыннан да:

Илля көллү шәйин мәә халәә Аллаһү батыйлүн
Вә көллү нәгыймин лә мәхәләтә зәилүн[7],

диб әйтелеб киткән бу фикер мөселман шәркындә шул хәдле чәйнәлгән вә тетелгән ки, Дәрдемәнд аны озын сүз белән әйтеб дә бик соңга калгандыр. Бер вакыт ифрат модада булган бу фикернең Дәрдемәнд әшгарендә самими булуы да бик шөбһәле...

Дәхи мөнәкъкыйд Дәрдемәндне һич берәүнең тәэсире астына төшмичә, бөтенләй мөстәкыйль йөргәнлеген аңлата. Мин аның бу фикерен бүлешә алмыйм. Дәрдемәнд тел ягыннан госманлы әдәбияты тәэсирендән котыла алмадыгы кеби, рух вә мәгънә ягыннан

---

[1] Игътираф итә – таный .
[2] Бәдбинлек – күңел төшенкелеге.
[3] Ма фиһага – аның эчендәгегә.
[4] Мөмтазият – өстенлек.
[5] Ингам ихсанлар – яхшылыклар.
[6] Дәстүрел-гамәл – күрсәтмә, кулланма..
[7] Әмма Аллаһтан башка барлык нәрсә дә ялган һәм барлык муллык юкка чыгачак.

бөтене белән шуның тәэсире астында булыб, тәүге дөньяга начар күз белән карау да аңа мотлакан[1] шул әдәбиятдан сәраит иткән[2].

«Татар шагыйрьләре»ндә иң күб урынны Габдулла Тукаев ишгаль итә[3]. Мөнәкъкыйд нигәдер, аның хакындагы мөляхәзәләренең тышына «Бер тәҗрибә» диб куйган. Галимҗан әфәнде Сәгыйд белән Дәрдемәндне бөтенләй диярлек, иң-якдан тикшереб, аларның тискәре якларына бармаклар аша гына караб уза, әмма Г. Тукаевка килгәч, эш башара. Тукаевны мөнәкъкыйд бик нык, җентекләб тикшерә, шунлыкдан аның хакында сүз озая, китабның 52 бите аның белән мәшгуль була. Монда әлбәттә Тукаевның күб язганлыгыны да дәхеле бар. Янә Тукаевның халкымыз арасында шагыйрь диб зур мәгъруфият[4] казануы да сүзнең озаюына сәбәб булган. Чөнки мөнәкъкыйд аны шагыйрь түгел яки бик кечкенә шагыйрь диб табкан, бәс, бу дәгъваны исбат итәр өчен аркылыга да буйга да җәелергә, сүзне озайтырга – бәсет итәргә[5] тугры килгән ахыры. Бу тугрыда мөнәкъкыйднең сүзләре дәлилсез вә әсасыз[6] түгел. Сәгыйдне шигырьнең мөҗәссәм[7] итеб күрсәтү, Дәрдемәндне дә аның янына кую күб кешеләргә ят тоелачагы кеби, Тукаевның шагыйрьлеге хакында шөбһә күрсәтү дә байтак адәмләргә гариб күреләчәк, ләкин этрафлы дәлилләр вә бәхәсләр белән тулган бу тәнкыйдләрне укыгандан соң, фикер вә зәвык ияләре ничек дә бераз уйланырга мәҗбүр булсалар кирәк.

Галимҗан әфәнденең бу әсәре – чын тәнкыйд. Әдәбиятымыз мондый тәнкыйдләргә күбдән мохтаҗ иде. Без мондый әсәрләрне күргәч, әдәбиятымыз җидди юлга кереб бара, диб шадланамыз, һәм Галимҗан әфәнденең тәнкыйд галәмендә алга таба бик зур адым атлаганлыгын күрәмез. Бер әсәрнең мөндәриҗәсе[8] тәнкыйддән гыйбарәт булуы ул әсәрнең озын тәнкыйддән коткармый, дөньяда антикритика – тәнкыйдне тәнкыйд дигән нәрсә бар, шунлыкдан, «Татар шагыйрьләре»н тәнкыйд итәргә дә бик мөмкин; «Мөсадәмәи әфкярдән[9] барика хакыйкать чыкар» ның мәгънәсе

[1] Мотлакан – һичнәрсәгә карамастан.
[2] Сәраит иткән – күчкән.
[3] Ишгаль итә – били.
[4] Мәгъруфият – танылу.
[5] Бәсет итәргә – җентекләп аңлатырга.
[6] Әсасыз – нигезсез.
[7] Мөҗәссәм – гәүдәләнгән.
[8] Мөндәриҗәсе – эчтәлеге.
[9] Мөсадәмәи әфкярдән – каршылыклы фикерләрдән.

шунда ачык күренәчәк. Минем монда язганларым тәнкыйд булмыйча, тик бер гәзитә ишарәсендән гыйбарәт икәнлеген башда ук сөйләдем.

Гыйлавә[1]: минем бу мәкаләм пароходда язылган иде, Казанга килгәч, «Вакыт»ның 1257, 58 вә 59 номерларында «Җәләй»нең «Татар шагыйрьләре» хакындагы тәнкыйдләрен күрдем. Минем «Бер әсәрнең мөндәриҗәсе тәнкыйддән коткармый» дигән сүземне «Җәләй» гамәлә күрсәткән була.

«Җәләй» С. Рәмиев тугрысында иркен вә матур гына фикер йөрткәне хәлдә, Дәрдемәндкә йиткәч, нигәдер, әйтергә теләб дә әйтә алмый калган төсле күренә, «Җәләй»нең, үзе әйтмешли, «Бәлки бунда бер аңламый торган бер хикмәт бардыр». «Җәләй» Г. Тукаевның шагыйрьлеген исбат итәргә тырыша, ләкин ни сәбәбдәндер мөнәкъкыйд бунда да иркенләб, җәелеб китә алмый. Теләсә, ул Тукаев файдасына тагын да төблерәк вә этрафлырак сөйли алыр иде.

*Мәкалә «Йолдыз» газетасының 1913 елгы 8, 11 август саннарында «Уйгур» имзасы белән басылган. Әлеге тәхәллүс белән сәяси эшлекле, публицист Фуад Туктаров (1880–1938) язуы мәгълүм.*

## Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун[2]

Идарәмезгә хәбәр итүләренә күрә, Уфа губернасы Эстәрлетамак өязенең карт вә могътәбәр хәзрәтләрендән Гыйрфан әфәнде Ибраһимов җәнабләре (Галимҗан Ибраһимовның атасы) мартның екерме йидесендә вафат булыб, 28 ендә гүр иясе улмышдыр.

Мәрхүм шул өяздә хосусый вә әүвәлге буынлары, халык арасында гыйлем вә мәдрәсәгә хезмәтләре, игътибарлары илә мәшһүр булган Ибраһимовлар нәселендән улыб, яше алтмышдан узган, шул гомеренең яртыдан артык имамәт[3] белән уздырган иде. Саф күңелле, җиңел мосахибле[4] булган бу зат үзенең иске шук әхлакларындан кайбер сыйфатлары илә хәзерге көннең надирләрендән[5] иде. Аның мөсафир пәрвәрлеге – һәрбер гаҗизгә, һәрбер бичарага

---

[1] Гыйлавә – өстәмә.

[2] *Коръән. 2:156. Без, әлбәттә, Аллаһ бәндәләре һәм хөкемгә Аллаһуга кайтучыларбыз, шуның өчен Аллаһ биргән казаларга сабыр итәбез (Ногмани тәрҗ.).*

[3] Имамәт – имамлык.

[4] Мосахибле – сөйләшүгә катнашучы.

[5] Надирләрендән – сирәкләрдән.

ярдәм кулы сузуы. Бигрәк дә үз тәгъбиренчә әһвале галәмгә хөрмәт вә дуслыгы чикдән тыш иде. Элек үзенең әниләрен вә бакынларын укытды, соңра картлыгына, авырлыгына һәм ялгызлыгына карамыйча, угылларын, ерак йирләргә, үзе иң яхшы диб табкан мәдрәсәләргә йибәреб тәрбияләде. Гомер буена авылында тирә-ягында галәмгә дәрдле бер ятим, бер гаҗизне очратса, тота да шуны бер мәдрәсәле йиргә озата, аңа үзендән вәкаләт мәктүбләре бирә. Аның бу эше аркасында байтак ятимле аякга басыб, бүген Оренбург, Орск, Троицкида, шулардан берничәсе мәрхүмне яхшылык илә яд итәләр. Бик күб сыйфаты илә шәрыкнең борынгы голямасын хәтерләткән бу әфәнде тәгаҗҗеб иделәчәк[1] бер хәл ки, заманымызда кузгалган үзгәрүләрнең һичберенә исе китми, угылларының шул якга авулары аның кәефен йибәрми иде. Берничә вакыт аңа «Хәзрәт, угылларың фәлән-төгән», диб, килеб сөйләгәнләр. Аның буңа каршы «Миңа суфилар кирәкми, адәмләр кирәк. Теләсә-ни эшләсенләр, тик кеше булсыннар, фәкать инсан булсыннар», – дидеге мәрвидер[2].

Мәрхүм Троицки Зәйнулла ишанның хәлфәләрендән улыб, хәзер исән җәмәгате Хәсәнә ханымга шунда өйләнмеш. Тик атасы Нурмөхәммәд Ахунд вафат булгандан соң, халыкның теләве белән Солтанморадка кайтмышдыр. Тирә-якда мөмтаз булган[3] мәсҗедендә шул Троицки байларындан мәрхүм Шәриф байның иганәсе илә салдырмышдыр.

Мәрхүм әһле галәмгә гаҗиз вә ятимләргә фәүкыльгадә[4] хөрмәте илә бәрабәр, хакыйкать сөюче, чын диб ышанганын, үзенә күреләчәк зыянга илтифат итмичә, һәр заман сөйләүче иде. Бу сыйфаты илә гомерендә күб зарарларга да очрамышдыр. Җәмәгате Хәсәнә ханым сәламәт улыб, аңа башка өч угылы, бер кызы калмыш. Калганларга сабыр җәмил[5] бирсен!

*Мәкалә «Йолдыз» газетасының 1913 елгы 16 апрель санында басылып чыккан.*

*Текстларны басмага Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге*
*фәнни хезмәткәре Алия Мөбарәкшина әзерләде.*

[1] Тәгаҗҗеб иделәчәк – гаҗәпләнерлек.
[2] Мәрвидер – китерелә.
[3] Мөмтаз – башкалардан өстенрәк торган.
[4] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.
[5] Җәмил – күркәм сыйфатлар.

# Г. ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫ ТУРЫНДА ФӘННИ-ТӘНКЫЙДИ МӘКАЛӘЛӘР

## Галимҗан Ибраһимовның бер автографлы китабы

Атаклы каләм осталарының һәрбер язмасы, алар турындагы истәлекләр әдәбият сөючеләр тарафыннан кызыксынып кабул ителә. Бу шулай булырга тиеш тә. Зур традицияле әдәбиятларда эш нәкъ шулай тора да. Бик еракларга китеп тормастан рус әдәбияты һәм укучылары арасындагы хәзерге мөнәсәбәткә күз төшерсәк тә, алдагы фикернең дөреслегенә ышану кыен булмас. Мәсәлән, рус шагыйре Пушкинның яки Грибоедовның, Лев Толстойның яки Максим Горькийның кулы куелган китаплар яки рәсемнәр, инде ул да булмаса, күренекле классикларның шәхси әйберләре табылу турында газета-журнал битләрендә, аерым китаплар рәвешендә мавыктыргыч очерклар, язмалар даими чыгып торалар. Андый материаллар аша укучы үз әдәбиятының күренекле вәкилләре – аларның иҗат лабораториясе, иҗтимагый эшчәнлекләре, тормышларыннан кызыклы сәхифәләр белән танышып баралар. Шул сәбәптән теге яки бу әдипнең, шагыйрьнең киң халык күңелендә халыкчанлыгы арта, аның шәхесе ачыграк күренә.

Татар әдәбияты да борынгы һәм зур традицияле әдәбиятларның берсе. Аның да күпгасырлык тарихында йөзләгән әдип-шагыйрьләре булган. Аларның гасырлар дәвамында халык кулында сакланып килгән әсәрләре безнең замангача килеп җиткәннәр. Соңгырак гасырларда яшәгәннәрнең автограф кульязмалары, китаплары дә бар (мәсәлән, Батырша, Габдерәхим Утыз Имәни, Кандалый, Гали Чокрый һ.б.). Алар турында халык телендә искиткеч риваять-легендалар, мәзәкләр дә сакланган. Мондый характердагы материаллар белән кызыксыну татар әдәбиятында соңгы елларда гына көчәйде. Моңа кадәр татар әдәбиятын өйрәнгәндә фәкать язучы яки шагыйрьнең биографиясен бик примитив хәлдә, аның иҗатына бәйләнешсезрәк рәвештә күрсәтү хөкем сөрә иде. Соңгы елларда бу өлкәдә дә боз кузгалды. Мисалга фәнни үзәкләргә

әдәби-культура мирасларын туплау, аерым шәхесләр белән кызыксынып, аларның биографик материалларын өйрәнү, истәлекләр бастырып чыгару һ.б. шушы җәһәттән башкарылган эшләрдән саналырга тиеш.

1987 елның мартында татар әдәбияты классигы һәм күренекле галиме Галимҗан Ибраһимовның тууына йөз ел тула. Татар әдәбиятчылары бу олы әдипнең иҗатын һәм тормышын өйрәнүдә шактый зур эшләр башкардылар: әдипнең сигез томлык әсәрләр җыелмасын төзеп бастырдылар, биографиясе буенча капиталь хезмәт дөнья күрде, аның хакында истәлекләр җыентыгы чыкты. Ләкин, шуңа да карамастан, әдәбиятчыларыбыз аның шәхесе алдында бурычлы булып калалар сыман. Әдипнең мирасын һәм үзен пропагандалау җитешми әле. Соңгы елларда яңа материаллар нигезендә язылган кызыклы тикшеренүләр дә күренми диярлек. Архивларда, шәхси кулларда кызыклы материаллар саклануы шөбһәсез. Шундый әйберләр табылу – Г. Ибраһимовның иҗатын өйрәнүне үстерүгә этәргеч булыр иде.

Эзләнгәндә ни булса да табылу мөмкинлегенә үрнәк итеп, шушы юлларның авторы тарафыннан табылган әдипнең бер автографлы китабы хакында язып үтмәкче булабыз.

Әдипнең тулы архивлары, китапханәсе булса да, безгә килеп җитмәгән, шунлыктан аның анда-санда гына калган аз санлы автограф язмалары безнең өчен кыйммәт.

Бөтен гомерен Казанда үткәргән финанс хезмәткәре Зөфәр ага Абдуллин безгә үзе тапкан бер төргәк төрле иске китаплар биргән иде. Шул төргәкнең материалларын актарып утырганда аннан тулы гына сакланган бер китапка күзем төште. Бу Галимҗан Ибраһимовның тарихи «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» исемле әсәре иде (Казан, 1922, 147 б.). Китапның тышлыгы юк, беренче битенә «Бу хезмәт Шәрекъның вакытсыз һәлак булган бөек революционеры Мулланур иптәш Вахитов хәтирәсенә багышлана» дип зур итеп басылган. Ул язудан өстәрәк коңгырт кара белән кулдан «Г. Газиз иптәшкә ядкарь итәм буны. Галимҗан Ибраһимов. 1922 – май 26, Казан», – дип язып куелган. Әлеге язма китапның кызыклы тарихы булуы хакында сөйли. Г. Ибраһимов аны күренекле татар язучысы һәм тарихчы Газиз Гобәйдуллинга (Г. Газиз) биргән булган. Димәк, әлеге китап Г. Газиз китапханәсенә чыккан. Зөфәр ага Абдуллин аны Казандагы Нариман урамы тирәсендәге бер ташландык сарайдан тапкан. Ул

сарайда Ватан сугышына китеп вакытсыз һәлак булган татар әдәбиятчысы Мөхәммәт Маминның да кайбер китаплары булган. Ихтимал, автографлы китапны башта М. Мамин тапкан булгандыр, ләкин аның саклануы өчен без Зөфәр агайга бурычлы. Бу китап күп нәрсәләр хакында сөйли ала. Шуларның берсе Г. Ибраһимов һәм Г. Газизнең үзара мөнәсәбәтләре мәсьәләсе. Алар арасындагы мөнәсәбәтләр чыганакларга караганда төрле төсмерләр алган. Мәсәлән, егерменче еллар ахырында Г. Ибраһимов Г. Газизгә каршы кискен чыгышлар ясый. Әгәр без татар әдәбиятының бу ике күренекле вәкиленең үзара мөнәсәбәтен егерменче елларның ахырларында булган халәткә нигезләнеп кенә билгеләсәк, аны берьяклы хәл иткән булыр идек. Яңа табылган автограф әлеге мөнәсәбәтләрнең иптәшләрчә булуын да күрсәткән бер документ булып хезмәт итә.

*Марсель Әхмәтҗанов,*
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге*
*баш фәнни хезмәткәре*

## Егерменче елларда Г. Ибраһимовның әдәби тәнкыйть концепциясе

1917 елгы инкыйлабтан соң тарихи аренада пролетар сыйныфларның төп рольне уйный башлавы сүз сәнгатенә юнәлеш бирергә тиешле тәнкыйтькә зур үзгәрешләр алып килә. Большевиклар бары тик марксизм-ленинизм гына әдәби тарихны дөрес яктыртуның нигезләрен бирә, тәнкыйди реализмның асылына төшенә һәм, шуннан этәрелеп китеп, әдәбият барышын инкыйлаби көрәш кысаларына кертәчәк, гади халык ихтыяҗларына хезмәт иттерәчәк дигән караштa тора. Беренче рус марксисты саналган Плеханов, теоретик яссылыктагы язмалары белән, иҗтимагый, эстетик-сәнгати-әдәби проблемаларны үзе күзаллаган юнәлештә чишүгә зур көч куя. Күпләр өчен аның язганнары бер үрнәк була, эш программасына әверелә. Татар марксистлары, инкыйлаби көрәшне тагын да җәелдерү, массаларны бу көрәшкә тарту өчен, бигрәк тә Плехановның, Ленинның, башка рус-революцион демократларының карашларын татар әдәби тәнкыйтенә уздыру һәм әдәбиятны яңа нигезләргә утырту хыялы белән яна башлый. Әлбәттә, бу төр хәрәкәтнең башында танылган каләм иясе Г. Ибраһимов тора.

Г. Ибраһимов «Китаплар арасында»ның (1925) «Ленинизм фикерләрен тарату юлында» бүлекчәсендә юлбашчының һәр юнәлештәге күзаллауларын халык арасында җәелдерүнең төп гамәлләрен ачыклый һәм бу эшне татар әдипләренә йөкли. Ул ленинизм идеяләрен тәрҗемә һәм оригиналь әдәбият аша массаларга тарату проблемасына алга таба да кабат-кабат әйләнеп кайта. Г. Ибраһимов дингә каршы эшчәнлекне шуның янәшәсендә күрә, чөнки аны алмаштырачак ленинизмны яңа дин дәрәҗәсенә күтәрә (Китаплар арасында: Дингә каршы көрәш фронтында // 6 том. Б. 394–395). Югарыда аталган хезмәтнең «Яшь каләмнәр» өлешендә К. Нәҗми, Ф. Әсгать, Һ. Такташ, Ш. Госманов, И. Хәйруллин, М. Максуд, М. Җәлил, Г. Галиев, К. Гайнан, Ш. Салаватов, М. Амурский, Асламский, З. Мәҗид, Г. Хәбиб, Г. Толымбайский, З. Бәширова, Й. Госмановлар иҗатына мөнәсәбәтле, әдип түбәндәгеләрне әйтә:

«Болар барысы да пролетариат революциясе дәверендә кузгалып, күбе канлы көрәш эченнән, гражданлык сугышларыннан кайнап килеп чыгучылар, әмма кайберләре – башта адашып, чит сыйныфлар тәэсирендә азапланганнан соң, пролетариат идеологиясе чишмәсенә килеп егылучылардыр. Ләкин һәммәсе җыйган уртак бер әйбер бар: болар барысы да көйләп яки көйсез рәвештә Владимир Ильичне җырлыйлар, аның пролетариатка юлбашчылык ролен төрле күренешләр, төрле сурәтләр аркылы укучыга күрсәтәләр».

Г. Ибраһимов матбугат иреген, әдәбиятка һәркемнең килергә хаклыгын таныган Ленинның 1905 елда ук язган «Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» мәкаләсендәге яңа заман сүз сәнгатенә бирелгән билгеләмәсен, алдыбызда төрле рәвештәге әдәби эшләрне социал-демократик эшчеләр хәрәкәте белән тыгыз һәм өзлексез бәйләнештә оештыру бурычы тора, «бөтен социал-демократик әдәбият партияле булырга тиеш» дигәннәрен үзенә маяк итеп ала. Ул да, Ленин кебек, бер яктан, һәр төр эчтәлектәге, сәнгати дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге әдәбиятның яшәргә хаклыгын таный да кебек, икенче яктан, художество эшләнеше түбән, заманча булмаган, бигрәк тә эчтәлеге инкыйлаби хәрәкәткә зыянлы тоелган әсәрләргә, шуларның авторларына каршы көрәш уты ача, шул рәвешчә, киләчәктә әдәбиятны тар кысага кертеп утырту юлына ишекләрне киң ача. Әдип бөтенләй башка уңайдан язган мәкаләләрендә дә оппоненты санаган язучыларның исемен атап, чеметеп узарга ярата. Мәсәлән, «Габдулла Кариев иптәш рухына»да (1920): «Тормышның төбеннән, ярлы крестьян эченнән

чыккан Кариев, моннан берничә ел элек үз сыйныфының юлыннан, демократик нигезеннән бераз читкәрәк тайган, аннан ары Исхаков-Туктаров компанияләренә эләгеп, бераз адашып киткән икән, моннан Кариевнең үзеннән бигрәк заман агышының тәэсире гаепледер»,– дип белдерә.

Шәһәрдә генә түгел, авыллардагы мәдәни тормышны өйрәнгән, сәнгать чаралары уздыруны коммуна эшчәнлегенең бер өлеше дип санаган Г. Ибраһимов, алар аша үткәндә, ячейка әгъзаларының шул юнәлештәге гамәлләренә бәя һәм инструкция бирә. Дим буендагы бер авылда яшьләр оешмасына кергәч, тиздән куелачак пьесаларының исемен сорый һәм әлеге әсәрне сайлауларын ошатмавын әйтә, башка әсәрләр тәкъдим итә (Авылда яңа эшләр, яңа кешеләр // 6 том. Б. 235). Әдип, гомумән, Яңа рухи тормышны төзүдә революцияне чын күңелдән кабул иткән һәм «яңа фикерләргә, яңа эзләнүләргә, яңа иҗатларга урын бирәчәк» коллективларга зур өмет баглый. Әйтик, ул, яңа буынны тәрбияләчәк дәреслекләрне «дәүләт механизмында даими винтларның берсе» дип күреп, эчтәлеге заманга лаек булуны, коллектив рәвештә хәл ителүне кайгырта. (Яңа мәдәният төзү юлында гыйльми әдәби коллективлар // 6 том. 237–243 б.). Г. Ибраһимов нәкъ менә егерменче елларда әдәбият, аны халыкка җиткерүче матбагa эшен партия контролендә тоту кирәк дип саный, һәрдаим «матбага эшчеләрен гаскәри хәлгә кертү» проблемасын күтәрә (Кызыл штык һәм кызыл каләм // 6 том. 219 б.)

Г. Ибраһимов әдәби тәнкыйть язучыга туры юлны ачык сызып күрсәтергә тиеш дигән караштa тора, әлеге юлны гади халык арасыннан чыкканнарның аңласына, башта адашып йөргән очракта да, ахыр чиктә барыбер ленинизм тарафдарларына әвереләселәренә һәм, иҗатлары белән, халыкка шул ук идеяләрне таратуга хезмәт итәселәренә ышана. «Кызыл чәчәкләр»нең беренче вариантына исем итеп куйган, соңыннан башламында калдырган «түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелү» хакындагы сөйләм штампын әдип егерменче елларда публицистикасында һәм әдәби тәнкыйтендә төрле вариантларда әледән-әле куллана. Ул, бер яктан, «гади халыктан чыккан» сәнгатькәрләргә кул суза, икенче яктан, халык батырларын яңа әдәбиятның төп һәм искене җиңүче каһарманнары сыйфатында күрергә тели. Сүз уңаеннан шуны да әйтик, «халыктан чыгу» гыйбарәсе революционер шагыйрь, танылган химик Л.П. Радинның 1898 елны Таган төрмәсендә язган

«Иптәшләр, кыю рәвештә бер аякка» (Вышли мы все из народа. / Дети семьи трудовой // Смело, товарищи, в ногу) җыры белән революционерлар арасында бик популярлашып киткән, ахыр чиктә хәтта сөйләм штампына әйләнгән була.

Г. Ибраһимов егерменче елларда марксистик-пролетар күзаллауларны шул кысага сыешмаганча фикер йөртүчеләрнекенә һәрвакыт каршы куя, чит карашларның өскә калыкмавы өчен тырыша. Әдипнең «Яңа кешеләр» драмасы зур бәхәсләргә сәбәп булгач, оппонентларына «Кара интригаларга юл бирелмәсен» (1921) мәкаләсе белән, нәкъ менә шул рәвешчә җавап бирә. Әдип «Дүртенче елга кергәндә» (1920) язмасында, зур гомумиләштерүләр ясап, болай ди: «Без бер дә шикләнмичә, әдәбиятка, фәлсәфәгә, театрга, мәктәпкә, сәнаигы нәфисәгә буржуазный яки пролетарский дип үлчәү сала алабыз, шундый гөруһка, шундый дәверләргә аера алабыз» (5 том, б. 243). Г. Ибраһимов татар тарихындагы иҗтимагый дәверләрне һәм шуларга мөнәсәбәттә барлыкка килгән рухи-мәдәни мирасны чагылдыруны төп бурычларыннан итә. Әдәбиятны дәвергә бәйле аңлату проблемасын ул алга таба әлә ничә хезмәтендә яктырта. Болар: күзәтү-хисап алгарак чыккан «Татар әдәбияты», аналитик характердагы «Татарның соңгы тарихында өч дәвер (эпоха), «Бөек өмидләр алдында» һәм башка язмалар.

Галим бигрәк тә егерме икенче елгы фәнни-тәнкыйди эзләнүләрен сүз сәнгатен өйрәнүнең принципларын ачыклауга багышлый, концепциясен эшли һәм берничә күләмле мәкаләдә махсус яктырта. «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» дигән язманың, атамасыннан ук күренгәнчә, әдип хәзер үзе әдәби мирасны ачканда таянган алымның марксизмга нисбәтлеген ассызыклый һәм төп эчтәлектә милли әдәбиятыбызны, гадәтенчә, шуның ярдәмендә баскычларга бүлә. Әлеге мәкаләдә Г. Ибраһимов әдәбият белемендә агитациягә урын калдырылмаска тиешлекне, чын фәнни принципларга таяну кирәклеген әйтә, ә марксизмның төп тикшерү ысулы сыйфатында тарихи материализмны күздә тотканлыгын шушы рәвешчә төшендерә: «идеологияне, әдәбиятны матди туфракка үсеп чыккан җимешләр дип карау, әдәбияттагы үзгәрешләрне, хасиятләрне мөндәриҗә, төп фикерләрне аларның шул дәвернең техникасы, икътисади иҗтимагыяте белән ни дәрәҗәдә бәйлануларын ачып бирә бару ысулы» (5 том, б. 390).

Г. Ибраһимовның егерменче еллар тәнкыйтендә Яңа әдәбиятның нинди булырга тиешлеге дә һәрвакыт нигез һәм өскорма бәй-

ләнешләре аша гына күз алдына китертелә. Ул алда телгә алынган «Дүртенче елга кергәндә»дә, Яңа төр сүз сәнгате барлыкка килүнең төп шарты итеп, икътисади мөнәсәбәтләрдәге үзгәрешләрне күрсәтә: «Гыйлемнең, әдәбиятның, сәнаигы нәфисәнең, театрның төп нигезләре, ысуллары, тышкы рәвешләре шул элеккечә, ләкин фикер, мәгънә алган чишмәләре, үсеп чыккан тамырлары, күзәткән әмәлләре бөтенләй башка – элекке икътисади мөнәсәбәтләр әдәбиятны, сәнаигы нәфисәне милек, милли, дини, ватани дошманлык рухында сугаралар, шуңа хезмәт кыйлдыралар иде; капитализм гыйлемендә, фәлсәфәдә, сәнаигы нәфисәдә үзен аклый, үзенә юл ача торган идеология эшли иде. Тарихның хәзерге бөек кузгалышлар дәвере исә, үзенең кызыл каһарманнары, сугышчан егетләре белән бергә, икътисади азатлык әмәлләрен җырлаучы шагыйрьләр, җир йөзен яңа, якты, иркле тормышка чыгаручы әдипләр, философлар, гыйлемне, фәнне яңа әмәлләргә тәтбикъ кыйлучы галимнәр, техниклар тудырды» (5 том, б. 241).

1923 елны «Татар әдәбиятын өйрәнү юлында» мәкаләсендә Г. Ибраһимов, тагын да кыскарак һәм ачыграк итеп: «Элек матди тормышны, аннан соң аның өстендә үсеп чыккан һәм аңар хезмәт иткән, аңар организаторлык кыйлган идеологияне шулай һәр дәвернең, һәр баскычның үзендә тикшерә килеп, аеруча әдәбияты нәфисәгә тукталгач, моның инде безгә тагы да тәфсилгә, тагы да нечкәлекләргә күп урын ачыла», – дип белдерә (5 том, б. 387). Ул, әсәрләрнең идеясен, эчендә тасвирланган сыйнфый-иҗтимагый мөнәсәбәтләрне ачу тәнкыйтьчеләр һәм укучылар тарафыннан әдипнең кыйбласын билгеләү өчен дә кирәк, дигән караштa тора. Шулай итеп, әдәби әсәр концепциясен аңлау юлындагы гамәлият авторының марксистларга тарафдармы, әллә башка юлдан барамы, пролетариатка, революция эшенә идеяләргә хезмәт иткән әдәбиятны кайгыртамы, дигән сорауга да җавап бирәчәк булып чыга.

Базис һәм өскорма күренешләр аша әдәбиятны аңлату проблемасына Г. Ибраһимов башка мәсьәләләрне чишкәндә дә әйләнеп кайта һәм аны әдәбиятта тормышны тарихи принципларга таянып яктырту белән тыгыз үрә. Теоретик планда сүз йөрткәндә, әдәбиятның чынбарлыкны анализлау, аннан материал сайлап алу кебек якларына, идея эчтәлегенә зуррак урын бирүгә карамастан, тәнкыйтьче әсәрләрнең сәнгати эшләнеше проблемасын да күз уңыннан тәмам чыгарып ташламый, әмма аңа үзләренә тарафдар булмаганнар арасында игътибар зурраклыгын билгели: «иҗтимагый

нигез хәтердән чыгарылмау белән бергә, «әдәби кыйммәт», «әдәби дәрәҗә», «әдәбилек», «тел-өслүб», чыгарылган типлар, реалист, романтик, символизм кебек ноктала‌р тибагый тикшереләләр.

Болар марксист булмаган тикшерүчеләрдә зур урын алалар. Бездә дә әһәмият бирмичә үтәргә ярамый» (5 том, б. 388).

Әдәби тәнкыйтьне пролетариат әдәбиятын тудыруга хезмәт иттергән Г. Ибраһимов «Пролетариат әдәбияты турында» язмасында бик хаклы рәвештә, әгәр әдәбияты турында сөйләшәбез икән, бездә пролетариат бармы, ул нинди; аны пролетариаттан чыккан язучы гына язамы, әллә башкалар дамы; аңа завод-фабрика-шахта тормышы яктырткан әсәрләр генә керәме, әллә ул киңрәк әдәбиятмы, кебек сорауларны куя һәм аларга җавап бирүнең вакыты җиткәнне әйтә. Ул анда тарихта әдәбиятның бурыч-максатларын аңлауны чагыштырма планда, янәшәлекләр ярдәмендә тасвирлый. Г. Ибраһимов әдәбиятка мөнәсәбәтнең үзгәрүен XIX йөзнең алтмышынчы елларындагы «азатлыклар»дан соң башланган иҗтимагый хәрәкәтләр белән бәйләп карый. Шушы вакытта тәнкыйтьче симпатиясенең әдәбиятны халыкка корал дип караучы Добролюбов, Чернышевский, Некрасовлар ягында икәнлеге ачык күренә. Автор хәтта үзе бу хакта белдермәгән булса да, шушы юлда фәнни эзләнүләр алып бармаучыга да Г. Ибраһимовның, китабын язганда, рус революцион-демократларының һәм марксист эстетикларының хезмәтләрен кулланганы аңлашыла булса кирәк. Ул бигрәк тә Г.В. Плехановның «Искусство и общественная жизнь», «Письма без адреса», «Сәнгать турында» мәкаләләреннән мул файдалана, язмаларындагы төп гыйльми-теоретик фикерләрне үз фәнни-публицистик стилендә сөйләп бирә, хәтта башка каләм ияләренең әйткәннәрен дә, Плеханов текстларыннан гына алып, мәкаләсенә, урыны-урыны белән, ирекле тәрҗемә рәвешендә кертеп җибәрә. Моннан чыгып һәм бу чорда иҗат ителгән башка язмаларының да Плеханов мирасы белән бәйләнеше барлыгын истә тотканда, егерменче елларда Плеханов тәнкыйте Г. Ибраһимов өчен төп теоретик чыганак, методик-методологик ярдәмлек вазифасын башкарган, дигән нәтиҗә дә ясарга мөмкиндер.

Тәнкыйтьче әдәбиятның бурычлары проблемасына, шул исәптән «Сәнгать – сәнгать өчен» дигән фикергә ачык һәм төгәл мөнәсәбәтен мәкаләнең «Бу мәсьәләгә марксистларның карашы» бүлегендә белдерә. Монда Г. Ибраһимовның сүз сәнгатенең иҗтимагый функцияләрне үтәвен доминанта позициягә чыгарганлыгы

күренеп тора. Кайчандыр әдәбиятның сәнгати камиллеген нык кайгырткан каләм иясе: «…бик күп белогвардеец шагыйрьләр, әдипләр революция әдәбиятын – әдәбият түгел, сәнгать түгел, диләр. Шигырь – плакатта, заборда булмаска, агитация эшенә корал ителмәскә, урамга хезмәт кыйлмаска тиешле; Демьян Бедный – шәп сатирик, шәп көйле фельетончы, ләкин һичбер хәлдә шагыйрь түгел, чөнки ул – бөтен язганнары белән, көндәлек тормышның кирәкләреннән үтә алмый, диләр.

Менә болар, үзләренең бу карашлары белән, тарихның хәзерге дәверендә, әлбәттә, зур зарар кыйлалар. Чөнки кирегә өстериләр».

Югарыдагы өзектән күренгәнчә, Г. Ибраһимов әдәбиятның сугышчан рухын чор, алгарыш таләбе белән бәйләп карый. Сүз сәнгатенең иҗтимагый функцияне гади халык файдасына үтәвен даими кайгыртуына карамастан, үзе дә зур художник булган әдип аның сәнгатилек дәрәҗәсе өчен эченнән көяргә дә мөмкин, әмма революция агымына марксистлар ягыннан кушылган икән, тарихи барышта әдәбиятны корал сыйфатында пропагандаларга мәҗбүр. Шул ук вакытта басма сүзнең сугышчанлыгы аның ихтыярыннан гына да тормый, чор ихтыяҗыннан чыккан, заман тудырган бер күренештер. Әдәби барышны ачуга марксистларча якын килүенең сәбәпләре, беренче чиратта, Яңаны төзәргә кирәклектән килеп чыкканлыкны Г. Ибраһимовның шушы сүзләре дә аңлата булса кирәк:

«Шигырьдә, сәнгатьтә, әдәбиятта булган төрле үзгәрешләрне тикшергәндә, бигрәк тә марксист булмаган тарихчыларны актарганда, безгә башка күп сәбәпләр арасында өч нәрсәгә күбрәк очрарга туры килә:

1 – җәгъръфи сәбәпләр;

2 – талантлар, даһилар;

3 – чит тәэсирләр.

Без боларның рольләрен бөтенләй юкка чыгара алмыйбыз, ләкин идеализм тарафыннан утыртылган урыннарыннан куып төшерергә мәҗбүрбез, юкса вакыйгаларны аңлауда адәмнең башын чуалталар, яңлыш юлга җибәрәләр».

Алга таба язмада Г. Ибраһимов шушы сәбәпләрнең әдәбиятның нинди эчтәлеккә ия булуында төп рольне уйнамавын ача, ләкин артык чиккә ташлана, бигрәк тә иҗтимагый фикер үсешендә, әдәбият яңарышында тышкы тәэсирләрнең, шәхесләрнең ролен соң дәрәҗәдә киметергә, төрле тип йогынтылар эчке үзгәрешләр аркасында гына була алуга нык басым ясарга тырыша. Хезмәттә

әдәбиятның килеп чыгышы, әдәби өслүб һәм башка күп кенә нәрсәләр дә Плехановча ачыла.

Г. Ибраһимовның әдәби тәнкыйть язмалары стилендә дә Плехановчалык үзен шактый сиздерә. Аның кебек урыны белән «шома», «кызыклы» сүзгә, читкә алып китүчән асмагънәле сөйләмгә урын бирмәсә дә, ул киң, чорны гына түгел, дәверләрне сыйдырган мәкаләләрне остазыдай уңышлы, җиңел, ачык, төшенчәләрне урынлы кулланып һәм фикерләрне дөрес формалаштырып яза. Аларның икесенең дә текстлары талантлы каләм иясе, зур художник икәнлекләрен күрсәтеп торса да, хатиплар (ораторлар) сөйләмен дә хәтерләтә, син аны авторның тавышы, аһәңе белән укыгандай буласың, сүзен бүлә, туктата алмыйсың, бәхәсләшеп тә җиңә алмассың кебек. Татар җирлегендә инкыйлаб юламаннарының берсе булуына карамастан, Г. Ибраһимов язмаларында да, әйдәманчы интонациясенә караганда, күзәтүчән аналитик, һөнәри публицист, кырыс тәнкыйтьче, универсаль күзаллауларга ия галимнеке көчлерәк.

Л. Троцкий асылда Россиядәге 1917 елгы инкыйлабны кабул итмәгән, ахырдан Ленинның оппонентына әверелгән маркист хакында «В.Г. Плеханов турында йөгерек уйлар» («Беглые мысли о Г.В. Плеханове») мәкаләсендә болай ди: «Ул зур кеше иде. Һәм ул рус иҗтимагый фикер тарихына зур фигура буларак керде.

Плеханов тарихи материализм теориясен тудырмады, аны яңа фәнни җиңүләр белән баетмады. Әмма ул аны рус тормышына алып керде. Ә бу биниһая мөһим хезмәттер». Чыннан да, инкыйлабкача чит илдә яшәвенә карамастан, В.Г. Плехановның рус иҗтимагый тормышының нинди агым буларак формалашуында роле зур. Бу шулай ук, ихтыяҗга мөнәсәбәттә баруына карамастан, тышкы тәэсирләрне бәяләп бетермәүнең хата икәнлеген күрсәтә. Икенче яктан, Г. Ибраһимовның үз эшчәнлеге дә В.Г. Плеханов үрнәгендә бара. Моның шулай икәнлеген татар әдибенең егерменче еллардагы Яңа әдәбиятны тудыру һәм чор иҗтимагый фикерен калыплаштырудагы гамәлләре аеруча ачык күрсәтә.

Шунысы кызык: инде русларның үзләрендә Плеханов мәкаләләре тәнкыйть ителә башлаган, шактый каршылыклы һәм киң актив кулланышта йөри алмый дип табылган, «Искусство и общественная жизнь», «История русской общественной мысли» һәм кайбер башка язмалары гына элек алган кыйммәтләрен югалтып бетермәгән бер вакытта Г. Ибраһимов беренче рәсәйле маркसист

әсәрләрен өйрәнүдән туктамый, әлбәттә, ул мәкаләләрендә аның әлеге дә баягы актуальлеген һәм мәгънәви кыйммәтен югалтмаган әсәрләренә мөрәҗәгать итә.

Г. Ибраһимовның 1917 елдан соңгы тәнкыйте революцион һәм аналитик рухтагы рус тәнкыйтендәге эстетик концепцияләрне татар җирлегенә күчерүне, алга таба үстерүне һәм шулар ярдәмендә халыкның күзаллауларын киңәйтүне, әдәбиятны инкыйлаб эшенә, заман кешесен тәрбияләүгә хезмәт иттерүне күздә тота. Бу чорда язган хезмәтләренең тирәнлеге, идеялеге, төрле формада һәм характерда булуы, җәмәгатьчелек, бигрәк тә каләмдәшләре тарафыннан игътибарга алынуы язучының шушы чор тәнкыйтендә тоткан роле турында да сөйли.

Ана телебездә чыгучы вакытлы матбугатка рөхсәт алынгач та, белгәнебезчә, аның битләрендәге әдәби барышка кагылышлы язмалар эчендә фельетон, рецензия һәм башка кече жанрлар өстенлек итә, әмма алар зур аналитик мәкаләләрнең артуына җирлек хәзерли. Моның шулай икәнлеген Г. Ибраһимов мирасы да ачык күрсәтә. Унынчы елларда ул, «Татар шагыйрьләре» кебек аналитик, чагыштырма-типологик һәм башка яссылыклардагы язмасы белән, бөтен әдәби җәмәгатьчелекне кузгатып җибәрүенә карамастан, нигездә, рецензияләр, юбилей мәкаләләре язу белән канәгатьләнә. Чираттагы унъеллыкта исә әдип һәр язганын актуаль проблемалы, бәхәскә тартырлык итәргә тырыша, татар әдәбияты тарихын язуга, этапларга бүлүгә, аны тикшерү ысулларын ачыклауга күп көч куя. Билгеле, Г. Ибраһимов, әдәби барышны «марксизм ысулы» белән яктыртудан тыш, аерым әсәргә, ваграк күренешкә, иҗатка… сәнгати ноктадан, фикерләү яисә фикерләү тибы яссылыгыннан, эчтәлек тирәнлегеннән һәм геройлар бирелешеннән бәя биргән мәкаләләр язуны һәм әдәбиятны яктырту төп максат булмаган хезмәтләрендә аңа кагылышлы репликалар әйтеп узуны да туктатмый.

Тәнкыйтьче егерменче елларда бигрәк тә театр язмышын, аны үстерәчәк драматургиянең эчтәлеген кайгырта. Г. Ибраһимов Зур (Большой) театрда «Янгура» тарихи драмасы сәхнәгә менү уңаеннан язган «Татар сәхнәсе» рецензиясендә һәм уенчыларның, һәм авторның сыйнфый көрәш тарихына караган материал ярдәмендә тирән идеяләр уздыра алырга мөмкинлекләрен, әмма моңа ирешә алмауларын һәм шуның сәбәпләрен күрсәтә. Әдип сәнгати йомшак язылган, әмма «сәяси зарарсыз» пьесаның, куелганнан соң,

«сәяси яктан да зарарлы бер төс» алуын билгели. Г. Ибраһимов, белгәнебезчә, драматургиягә караган текстларны анализлау белән генә канәгатьләнми, аларның, театр эчтәлегенә дә йогынты ясавын исәпкә алып, театраль рецензияләр язу да кирәк саный. Сәнгатьнең, шул исәптән әдәбиятның да предметы буларак иҗтимагый мөнәсәбәтләрдәге, психологик хәл-халәттәге кеше торганны аңлаган тәнкыйтьче аларда шулай ук алдынгы идеяләр уздырылуны мәҗбүри күрә, әсәрнең сәнгатьлелек дәрәҗәсен өлешчә идея эчтәлеге белән дә бәйләп карый. Ул бер вакытта да кайсы карашларның Яңаны корган гади халыкка зарарлыгын ачыклауны күз уңыннан чыгармый һәм әдипләрнең аңлы рәвештә идеяле язуын таләп итә.

Әдәбиятның төрле ысул һәм алымнардан торганлыгын, форма ягыннан алга таба да үзгәрешләр кичерәчәген аңлаган Г. Ибраһимов егерменче елларда эзлекле рәвештә аның реалистик рухта, тормышчан булуын кайгырта, чөнки нәкъ менә шундый әдәбият кына халыкка ачык аңлаешлы, шушы чорда үтә кирәкле һәм үзаңын үстерерлек дип саный, сәнгатьнең – сәнгать өчен булмыйча, массалар өчен кирәклеген пропагандалый. Әдип әдәбиятка марксист тәнкыйтьчеләрчә якын килә: ул – сыйныфларның, социаль төркемнәрнең хыял-өметләреннән оешкан идеологиясен аерым бер калыпларда һәм сүз ярдәмендә образлы чагылдыру чарасы дигән караштә тора.

Г. Ибраһимов ышандыргыч фактларга таянып, дәлилле язарга омтыла, аның әсәрләре нәкъ шул ягы белән кызыклы да. Ул тәнкыйтьтә үзенә тиңнәрне күрми һәм «Өч җавап» (1922) язмасында үзен моңарчы һичбер мәсьәләдә дәлилле җиңә алмаулары хакында махсус сүз алып бара. Аның тәнкыйте дәлилле генә түгел, сугышчан да, моннан тыш, аның вакыты белән кирәгеннән артыграк кискенлеге күзгә ташлана. Г. Ибраһимов бу хакта әле телгә алынган һәм үзенең тәнкыйди принципларын, әдәбиятның нинди булырга тиешлеге турындагы карашларын яктырткан мәкаләдә шушы рәвешчә белдерә: «Мин – рәхимсез тәнкыйть тарафдары һәм шундый тәнкыйтьләрнең зур файдасына ышанган кешеләрнең берсемен» (5 том, б. 310).

Бигрәк тә Г. Ибраһимовның каләме ярдәмендә, егерменче елларда татар тәнкыйте үзенең үткен, шифалы, файдалы, конструктив сүзе белән, Яңаны төзешү эшенә ныклап керешә, әдәби барышның аерылгысыз өлешенә әверелә. Танырга кирәк: XX гасырның икенче яртысыннан башлап инде ул бервакытта да шул

чордагы оперативлыкка, хирыслыкка, максатчанлыкка, активлыкка ия була алмый. Монда егерменче елларда берничә дистә саллы тәнкыйть мәкаләсе язган Г. Ибраһимовның өлеше аеруча зур.

Узгандагы әдәбиятка ныклы күзәтү ясаган, алдагы дәверләр сүз сәнгатенең заман өчен кирәкле якларын күрү белән беррәттән, инде үтелгән этаплар дип караган һәм киләчәктә әдипләребез һәр төрдә, жанрда зур уңышларга ирешерләр, бигрәк тә реалистик иҗат халыкка файдалы эшләрне ныграк башкарыр дип исәпләгән Г. Ибраһимовның егерменче елларда Плеханов, Луначарский, Ленин һәм башкаларның агарту-пропагандалау тәнкыйте йогынтысына нык бирелгәнлеге күренә. Ул ленинизм һәм марксизмда мәдәниятны өйрәнү методологиясен эзли, таба һәм укучылар массасына шуны аңлату эшенә тотына. Бу максат әдип язган хезмәтләренең стиленә дә тәэсир итми калмый: Г. Ибраһимовның егерменче еллар тәнкыйтендә публицистизм шактый көчле, һәр мәкаләсенең әдәби җәмәгатьчелеккә генә түгел, башка катламнарга да адресланганлыгы аңлашыла.

Г. Ибраһимовның егерменче еллар тәнкыйте, беренче чиратта, теге яки бу гыйльми проблемаларны чагылдырган монографик яссылыктагы мәкаләләре һәм күзәтү характерындагы язмалары белән истә кала. Кыска күләмдәге мәкаләләре арасында төрле тип рецензияләр, юбилей язмалары шактый. Эчтәлекләреннән һәм ачык күренгән язылу максатларыннан чыгып, аналитик, публицистик-агитацион тәнкыйть өстенлек итә, дип тә билгеләргә мөмкиндер. Ниндидер сәбәпләр аркасында, галимнең әдәбият һәм сәнгать турындагы кайбер хезмәтләре күптомлыгының саф публицистика дип фаразланган бишенче тупланмасына кертелгән. Араларында егерменче елларга караганнары да бар.

Әдәби тәнкыйть төрле өлкәләр кисешкән урында туса да, анда әдәби барышны яктырту иҗтимагый тормыш белән тыгыз бәйләнештә булса да, аңа багышланган махсус том булганда, шунда урнашуы хәерлерәктер. «Яңа әсәр» (1911)«Яңа мәдәният төзү юлында гыйльми-әдәби коллективлар» (1921), «Беренче Бөтенрусия күргәзмәсе хакында»» (1923), «Ислам тирәсендә» (1923), «Кара маяклар, яки ак әдәбиятлар» (1924), «Китаплар арасында» (1925) әдәбият һәм сәнгать дөньясындагы кайбер проблемаларны, күренешләрне иҗтимагый тормыш җирлегендә яисә, әдәбиятны киң мәгънәсендә алып, иҗтимагый-сәяси ракурстан яктырткан мәкаләләрне, шулай ук тәрҗемә әдәбият хакындагы язмаларны

алдагы күптомлыкны эшләгәндә, әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр томлыгына күчерү урынлы булыр.

Г. Ибраһимовның егерменче еллар тәнкыйте хакында йомгаклау рәвешендә фикер йөртеп, анда идеологик юнәлгәнлек, ижтимагый күзаллаулар яссылыгыннан һәм социаль-мәдәни кыйммәтләр ноктасыннан бәяләмә, әдәби әсәрне, иҗатны, сүз сәнгатен эпоха һәм шул дәвердәге мәдәни барыш җирлегендә ачу өстенлек иткәнне, тәнкыйтьченең, урыны белән, компаративистик, биографик методларны кулланганын, мәкаләләрен бөтен, проблеманы ахыргача ачып, логик эзлекле һәм ачык аңлаешлы язганын билгеләргә кирәк.

*Р. Харрасова,*
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*текстология бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

## Ак тапларны киметәсе иде...

Быелның март аенда мәшһүр әдип, күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм галим Галимҗан Ибраһимовның тууына 130 ел тулды. Әдипнең беренче иҗат үрнәкләре дөнья күрә башлауга да 110 ел була. Шул уңайдан матбугат битләрендә аңа аерым сәхифәләр багышланып килә, олуг әдипне искә алу чаралары үтә, конференцияләр оештырыла. Элегрәк елларда матбугатта чыккан кайбер мәкаләләрдә дә, конференцияләр барышында да Г. Ибраһимовның кабере сакланганмы соң, дигән сораулар да булды. Аның иҗат биографиясендә бүген дә ачыкланып бетмәгән башка төр ак таплар барлыгы күпләребезгә мәгълүм.

Әйе, иҗат итә башлавына йөз елдан артык вакыт үтүгә карамастан, аның иҗатына да, җәмәгать эшчәнлеге һәм биографиясенә дә бәйле ак таплар тулаем өйрәнелгән һәм ачыкланган дип төгәл генә әйтә алмыйбыз әле. Әйтик, аның үз мөхәррирлегендә нәшер ителгән «Ирек», «Безнең юл», «Чулпан» газеталарында чыккан, милләтебез язмышына кагылышлы фикерләре өстенлек иткән күпсанлы хезмәтләре бүгенге заман укучысына тулаем мәгълүм түгел дияргә дә була. Чөнки әле санап кителгән газеталар, шул исәптән Үзәк мөселман комиссариаты нәшер иткән «Чулпан» да башлангыч чорда сул эсерлар йогынтысында булган. Алар мил-

ли мәсьәләләргә зур әһәмият биргән татар сул эсерлары газетасы саналган. Совет хакимияте елларында эсерлар эшчәнлеген искә алу катгый тыелган темаларның берсе иде. Егерменче елларда Казанда Гыйльми үзәк җитәкчесе булып эшләгәндә дә Галимҗан Ибраһимов элекке милли карашларыннан тайпылмаган. Патша заманнарындагы каләмдәше һәм фикердәше Габделбарый Баттал да 1925 елда Төркиядә басылып чыккан «Казан төркиләре» китабында аны: «Ул милли большевик булды», дип яза. Үз халкына, милләтенә файда китерәчәгенә, татар милли мәдәниятен төзүгә өлеш кертә алачагына ышанып яшәде, ди. Шул ук елларда Г. Ибраһимов «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән хезмәтен дә яза. Әмма ул хезмәтне һәм аның Академик үзәктәге эшчәнлеген милләтчелеккә бәйле итеп бәяләүчеләр аңа аяк чалырга керешкәндә генә олуг әдип авырып китә. Альберт Мөслимовның 1991 елда «Казан утлары»нда басылган «Рәсми әләк» мәкаләсе шул вакыйгаларга багышланган иде. Һәм егерменче ел урталарында корылган капкын Галимҗан агабызны каһәрле 1937 елда арабыздан алып та китә. Әйе, нәкъ милләт язмышына кагылышлы элекке хезмәтләре һәм шул юнәлештәге эшчәнлеге өчен олуг әдибебез зинданда җәфалап үтерелә дә. (1950 елларда аның төрмәдәш иптәшләре һәм Пләтән төрмәсе хезмәткәрләре белән аралашкан Афзал ага Шамов шундый бер күренешне сөйләгән иде. Г. Ибраһимовтан сорау алучы берәү, кышкы суык көннәрдә берничә мәртәбә аны бозлы чолан идәненә бастырып, өстенә бозлы су койдыртып җәфалый. Шуннан соң әдип төрмә хастаханәсенә эләгә һәм озакламыйча вафат та була.)

Совет хакимияте дәверендә әдипнең милләт язмышына кагылышлы эшчәнлеген барлау, аларны тәфсилләп язып чыгу мөмкин түгел иде. Ә 1991 елдан соң, элекке «ябык» архивларның тимер ишекләре бераз ачыла төшкәч исә, Галимҗан Ибраһимов шәхесе һәм язмышы белән кызыксыну нишләптер кими төште шикелле. Аның иҗатын һәм эшчәнлеген өйрәнүче элекке олпат галимнәр картайды яисә вафат булды. Мәрхүмә Фатыйма Ибраһимова, егерменче еллар вакыйгаларын чагылдырган байтак кына материал туплап, өч калын папканы китап нәшриятына тапшырган иде. Соңрак ул язмалар әдипнең «Сайланма әсәрләре»нең 9 нчы томы буларак басылып та чыктылар. Ләкин ул томда да алдарак искә алынган, милли хәрәкәткә багышланган язмалар тупланмаган иде. Чөнки ул папкаларга кергән материаллар да әле Совет

хакимияте дәверендә, архивларның «яшерен»лек билгесен йөрткән бүлекләренең ишекләре ябык чакта тупланганнар иде шул.

Шушы уңайдан бер-ике кечерәк фактка тукталып китәсем килә. Әдипнең иң актив иҗат иткән елларында аның иң якын ярдәмчесе һәм кайбер хезмәтләренең рус теленә тәрҗемәчесе дә булган Өммегөлсем апа Мөхәммәдева 1960–1980 еллар аралыгында иренә багышлап берничә биографик очерк, өч документаль повесть язган иде. 1980–1990 елларда мин аның шундый эчтәлекле, бай мәгълүматлы ике китабын – «Эзләнүләр» белән «Олы юл»ын бастырып чыгаруда катнаштым. Ул китапларның мөхәррире дә, алар турында матбугатта беренче хәбәр бирүче дә булдым.

Шул документаль повестьларын язарга керешкәнче Өммегөлсем апа Г. Ибраһимовны якыннан белгән кешеләр белән аралаша, хатлар алыша, төрле-төрле документларның күчермәләрен алдыра. Әдипкә кагылышы булган фотоларны туплый. Әдипнең 1920–1921 елларда бергә яшәгән беренче «зәүҗаны» Мәчтүрә Фәйзуллина һәм Киевтә чакта якыннан аралашкан якташы, Уфа кызы Гөлсем Әхтәмова-Ордубатская белән дә хатлар алыша. Өммегөлсем апа сөйләвенчә, Уфа-Бәләбәй төбәге морзалары нәселеннән булган Гөлсем туташ белән Галимҗан арасында дуслык мөнәсәбәтләре бөреләнеп килгән бер вакытта Киевтә байтак кына татар яшьләрен кулга алалар. Шул исәптән Галимҗан да төрмәгә ябыла. Әдип белән Гөлсем баштарак хат язышып торалар. Аннары аралары өзелә. Әдип төрмәдән чыккан мәлдә Гөлсем каникулда, Уфада була. Г. Ибраһимовның 1914 елда Кавказга ял итәргә барышлый яңадан Киевкә «кереп чыгуы»ның бер сәбәпчесе дә әлеге Гөлсем булган, дип сөйләгән иде Ө. Мөхәммәдова. Ләкин инде ул вакытта Гөлсем Әхтәмова Киев университеты студенты Фирүз Ордубатскийга вәгъдә биреп өлгерә. Шул сәбәпле әдипнең Гөлсем белән үзара мөнәсәбәтләре ялганмый кала... Калган гомерен иренең туган илендә – Азәрбайҗанда уздырган Гөлсем 1960 елларда Казанга юлланган хатларында шул хакта язган икән...

Шул ук папкада Мәчтүрә Фәйзуллинадан алынган ике-өч хат та бар дип сөйләгән иде Гөлсем апа. Ул хатын ни сәбәпле Галимҗан белән аерылганлыгын тәфсилләп язмаган, «туган ягымны сагынып, Уфага чыгып киттем», дип кенә хәбәр иткән булырга тиеш. Ө. Мөхәммәдова әсәрләрендә ул хатын образы Хәнифә исеме белән теркәлгән. 1937 елда Галимҗан төрмәгә ябылгач, шул Хәнифәнең Казанга килгәнлеге «Олы юл» әсәрендә әйтеп кителә.

Ө. Мөхәммәдова тарафыннан тупланган менә шундый хатлар, фотолар, документ күчермәләре калын-калын папкаларда әдибәнең өстәлендә өелеп торалар иде. Ул папкаларның хәзергә язмышы миңа билгесез. Гөлсем апа вафат булгач, бер очрашу вакытында аның кызы Сөмбел дә: «Мин аларның кайда икәнлеген белмим», – дип җавап биргән иде. Әмма ул хатлар, ул документлар бөтенләй үк юкка чыкмагандыр дип уйлыйм. Гөлсем апа аларны, бәлки, Дәүләт музее мирасханәсенә тапшырып өлгергән яисә Г. Ибраһимов иҗатын барлау өлкәсендә зур эшләр башкарган олуг галим Мансур Хәсәновкә бүләк иткән булгандыр. Афзал ага Шамовның көндәлек язмаларында да шул мирас хакында берәр төрле хәбәр булуы бик ихтимал. Бу ике шәхес Өммегөлсем апаның иң якын киңәшчеләре дә, фикердәшләре дә булдылар. Гөлсем апа 1988 елның март аенда арабыздан китте. Ул вакытта әле кызы Сөмбел белән кияве Рафил Сафиннар – КДУ укытучылары – исән иделәр. Алар Гөлсемападан аерым торалар иде. Әби фатирында исә аларның кызлары, кияүләре һәм яшь баланың яшәгәнен хәтерлим. Ә менә татар халкы өчен бик затлы саналган, «әби өстәлендә сакланган» папкаларның язмышы әлегә билгесез кала.

Шуңа охшаш тагын бер очрак искә төшә. Алтмышынчы елларда Казанда Галимҗан Ибраһимов исемен йөрткән мәктәп бар иде – Ленин районының Восстания урамындагы 89 нчы татар мәктәбе. Урыныннан кузгала алмыйча ятакта ятучы булачак халык шагыйре Фәнис Яруллинны урта белемле итеп тәрбияләүдә үз өлешен керткән мәктәп. 1960 еллардан бирле аның директоры Вазыйх ага Надриев белән ара-тирә аралашып яшәдек. Бер районда туган кешеләр идек. 1990 елларда бугай, мин аны бик тә борчылган кыяфәттә Язучылар берлеге урнашкан бина ишегалдында очраттым. «Галимҗан Ибраһимовка багышлап утыз биш ел дәвамында тупланган истәлек язмаларын һәм фотоларны югалттык. Ике-өч ел элек, илдә зур үзгәрешләр башлангач, аларны без шушында китереп биргән идек. Шуларны хәзер таба алмыйлар. Ул кыйммәтле истәлек язмаларын, фотоларны кем, кая куйган – белмиләр. Анда әдипне соңгы елларда карап, тәрбияләп торган соңгы хатыны Хәдичә апа Фәтхуллинаның истәлекләре дә бар иде. Ул истәлекләр башка беркайда да басылмады, бездә аның тулы нөсхәсе иде. Мансур Хәсәнович әйтә: «Нигә анда тапшырдыгыз, ул папкаларны Үзәк музейга бирәсе булган», ди. Нишләргә инде хәзер?» Шул тарихи истәлекләрнең язмышын ачыклый алмыйча

якташым тиздән вафат та булды. Берничә «иске» альбомны, кулдан язулы истәлекләр тупланган картон папкаларны кемдер, «кирәкмәс нәрсәләр» дип чүпкә ташлагандырмы, яисә «киләчәктә кирәге чыгар әле» дип, ераккарак җыеп куйгандырмы, ни дип фаразларга да белмим. Вазыйх ага әйтүенчә, ул истәлек язмалары бик авырлык белән тупланган булган. «Авыру Хәдичә апа янына күкрәгенә Ленин орденын таккан әдәбият укытучысы үзе барып йөрде. Ул апа укучыларны гына кабул итми иде», – дип тә өстәп куйган иде якташым. Хәер, Афзал ага Шамов та Хәдичә ханымның истәлек сөйләргә ни өчендер авырсынганлыгын искә алалар иде. Шул сәбәпле, Хәдичә Фәтхуллина язмалары «Г. Ибраһимов турында истәлекләр» (1966) китабына да кермәгән.

* * *

Әйе, Галимҗан Ибраһимовка багышланган язмаларның кайберләрендә «аның кабере билгесез» дигән сүзләр дә еш кына күзгә чалынып киткәли. Ил башы И. Сталин идарә иткән елларда эзсез югалучы татар зыялылары исемлеге бик зур. Алар турында сүз чыкканда бик еш кабатлана торган әйтем инде ул: «эзсез югалды, кабере дә билгесез» диюләр. Чынлап та, аларның күпчелегенең кайларда үлеп калганлыгы да, җәсәде җирләнгән җире дә билгесез. Әйтик, Казан зинданнарының берсендә атып үтерелгән дип фаразланган Кәрим Тинчуринның кайсы зиратта җирләнгәне әле дә ачыкланмаган. Совет хакимиятен урнаштыруда актив катнашкан комиссар һәм классик язучы Шамил Усманов каберенең дә кайдалыгы билгесез. Фәтхи Бурнаш соңгы айларын хәзерге Самара шәһәренең Безымянка исемен йөрткән лагеренда үткәргән, шунда үтерелгән. Ул лагерьда булган тоткыннар зур бер хәрби завод төзелешендә эшлиләр. Шундый заводлар төзелешендә төп кул көче саналган һәм вакытсыз вафат булган меңнәрчә тоткыннарның каберләре билгесез кала. Шул исәптән Фәтхи Бурнашның да «асыл сөякләре менә шушында ята» дип, төгәл генә әйтә алмыйбыз. Аларны ачыкларлык мөмкинлекләр дә тудырылмады. Күпчелек тоткыннарның кайсы лагерьда җан биргәнлеге турындагы хәбәрләр дә якыннарына бик соңлап җиткерелде. Кайберәүләргә андый мәгълүматны 1990 еллардан соң гына ачыкларга мөмкинлек тудырылды. Совет хакимиятенең «иң явыз дошманнарын» аклау карары да СССР таркалгач кына чыгарылды.

Галимҗан Ибраһимов шәхесенә бәйле вакыйгалар башкачарак тора. Бердән, ул рус телендә «Гулаг» дип исемләнгән махсус лагерьларның берсендә үлеп калмаган. Ул төрмәдә вафат булган. Хокукый яктан – юридик караштан чыгып фикер йөрткәндә, беркадәр өстенлеге булган урында, дәүләтнең бер махсус оешмасы карамагында вафат була. «Гулаг»лар исә ярым яшерен оешмалар. Алар һәм андагы тоткыннар турында рәсми мәгълүматлар ярым яшерен төстә сакланган. Теге яки бу хәлне ачыкларга теләгән берәр оешма вәкиле яки әрсезрәк кеше төрмәнең кайдалыгын белгән һәм анда керү юлларын ачыклый алган. Шул җәһәттән караганда Г. Ибраһимовның язмышы күпчелек башка тоткыннар язмышыннан аерылыбрак тора. Икенчедән, И. Сталин вафат булгач ук күпчелек тоткыннарның аклануы турында карар кабул ителде. 1954 елның ахырларында Казанда Галимҗан Ибраһимовның акланырга тиешлеге турында да уйлана башлыйлар. Шул елның декабрендә «Тел, әдәбият һәм тарих институты»нда үткәрелгән бер җыелышта язучы Афзал Шамов чордашы Шамил Усманов язмышын, Әмирхан Еники исә якташы Галимҗан Ибраһимовка багышлы вакыйгаларны ачыкларга кирәк, дип сүз башлыйлар. Тиздән республика күләмендә гаепләнеп кулга алынучыларның язмышын ачыкларга тиешле комиссия төзелә. Аның җитәкчесе итеп партия өлкә комитетының өченче секретаре Салих Батыев билгеләнә. Ул комиссиягә Язучылар берлеге идарәсе рәисе Гомәр Бәширов та керә. 1955 ел башында С. Батыев аңа Мәскәүгә барырга, СССР Язучылар берлеге җитәкчесе Александр Фадеев белән дә киңәшеп кайтырга куша. А. Фадеев аңа гаепсез дип фаразланган тоткыннарның аклануын үтенеп, дәүләт оешмаларына аерым-аерым хатлар юлларга киңәш итә. Ул хатлар туганнары исеменнән язылса отышлырак булыр, ди. Шушы уңайдан Гөлсем Мөхәммәдеваның Г. Ибраһимов язмышына багышланган «Олы юл» повестена күз салыйк. «Г. Бәширов, Казанга кайткач, Әмирхан Еникине чакырып ала (олуг әдипнең якташы һәм үзен аның рухи шәкерте дип санаган язучыны), аңа Галимҗан Ибраһимовның эшен яңадан карауны үтенеп, Партия Үзәк комитетына гариза язуны тәкъдим итә. Бик хәвефле хәлгә калу ихтималын уйласа да, әдип Еникиев, мондый йөкләмәне үтәү үзенең намус эше дип, риза була. Озакка кичектермичә гаризаны яза да Гомәр Бәшировның кулына тапшыра». Берничә ай үткәч, 1955 елның 29 октябрендә СССР Прокуратурасы Әмирхан Еникинең өй адресына

Г. Ибраһимовның аклануы турында хат юллый. Шуның нигезендә тиздән Татарстан хөкүмәтенең Галимҗан аганың исемен һәм мирасын халкына кайтару турындагы махсус карары чыгарыла.Ул карарда әдип әсәрләренең күптомлыгы тиз арада нәшер ителергә тиешлеге, аңа багышлап истәлек язмаларын туплау кирәклеге турындагы тәкъдимнәр белән янәшә, каберен барлау бурычы да куелган була. Шул карар җирлегендә оештырылган дәүләт комиссиясенә Язучылар берлегеннән дә берничә кеше керә. Язучылар оешмасы һәм нәшрият вәкилләре төркеменең җитәкчесе итеп сугыш ветераны Афзал Шамов билгеләнә. Ул комиссиягә билгеләнүенең сәбәпләрен үзе болайрак дип аңлаткан иде. 1930 елларда китап нәшриятында эшләгәндә ул Г. Ибраһимовның иң соңгы әсәрләрен бастырып чыгарырга әзерләгән, әдип белән хатлар аша аралашкан була. Булачак китапның корректура вариантын редакцияләгәндә бер-ике җөмләне үзенчәрәк төзәткәне өчен автор бер хатта аңа шелтә дә белдергән була. Дөрес, әдип кулга алынгач, ул китап («Безнең көннәр» романының дәвамы, «Караңгы төн мәңге булмас» романы) чыкмый кала, корректурасы юк ителә. «Шуларны да истә тотып, миңа аның өч томлыгын туплап, бастырып чыгару һәм башка эшләр йөкләтелде», – дигән иде Афзал ага.

А. Шамов шулай ук әдипнең кайчан, кайда җирләнгәнен ачыкларга тиешле булган, хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән икенче бер комиссия утырышларында да катнаша. Аның сөйләвенчә, ул комиссия Пләтән төрмәсе эшчәнлегенә бәйле булган дистәләгән кеше белән әңгәмә оештыра. Шул кешеләр арасында әдип белән бер вакыттарак төрмәдә утыручылар да, төрле дәрәҗәдәге төрмә хезмәткәрләре дә була. Шулар арасында әдипкә карата яхшы мөнәсәбәттә булган бер татар хатынын да искә ала иде Афзал ага. Нишләптер минем хәтердә ул табибә буларак истә калган. Исемен инде оныткანмын. «Олы юл» повестенда исә автор аны «санитарка Фатыйма» дип телгә ала. Болар икесе ике кеше булгандырмы – әйтә алмыйм. Шул ук Афзал ага сөйләвенчә, комиссия эшләгән вакытта төрмәдән мәетләрне зиратка илтүче олаучы да, шул вакыйгада катнашкан тагын берничә кеше, шул исәптән Казанның Архангел бистәсе зираты хезмәткәре дә әле исән булалар. Алар сөйләгәнгә нигезләп, комиссия Галимҗан Ибраһимов җәсәденең кай тирәдә җирләнгәнен ачыклый. Һәм шул хакта махсус акт төзелә. Бүгенге көндә ул комиссия документлары архив киштәләрендә сакланган булырга тиештер дип уйлыйм.

Хәзер шәһәр уртасында калган Архангел зиратының үзәк аллеясыннан ерак булмаган бер мәйданчыкта олуг әдип истәлегенә куелган затлы кабер ташы бар. Татарча язулы зур гранит һәйкәл. Галимҗан аганың җәсәден төрмәдән алып чыккан төндә күмелгән 4–5 кеше кабере өстенә куелган ул. Алда атап үтелгән комиссия ачыклаган урын шушы була. 1960–1970 елларда шуннан ике-өч метр арырак, бер төркем агачлык ышыгындарак, икенче бер татарча язулы истәлек ташы да бар иде. Ул кабердә әдипнең замандашы һәм зиндандашы булган Закир Самитов ята дип язылган иде ташъязмада. Афзал ага белән Зәйнәп апа Самитова сөйләвенчә, бу ике кабер ияләрен дә Пләтән төрмәсеннән бер үк төндә, бер чанада алып чыгалар. Ләкин Зәйнәп апа ул төндә үз ирен читкәрәк алып китеп җирли.

Әлеге комиссия тарафыннан шулар да ачыклана: төрмәдә үлүчеләрне кыш айларында атнага бер мәртәбә генә җыеп җирләгәннәр икән. З. Самитов хатыны Зәйнәп апа бу вакыйгаларны болайрак искә ала иде. Үзе әйтүенчә, төрмә вакыйгаларына кагылышлы комиссия утырышларында ул да катнашкалаган. Шул комиссия төзегән актта аның да култамгасы булырга тиеш икән. Әйе, үзе әйтүенчә, комиссия актларына кул куючылар арасында ул да була. Ире Гражданнар сугышы чорындагы бер гаскәри берәмлекнең комиссары булган. Аннары Закир Самитов 1934 елга чаклы Казанда урнашкан милли укчы дивизиядә хезмәт иткән. Шул елның көзендә аны «Кызылармеец» газетасының элекке мөхәррире, яңарак кына Язучылар берлеге идарәсе рәисе итеп сайланган Кави Нәҗми Татарстан әдәби фондына эшкә чакыра. Ә 1937 елда аларның икесен дә кулга алалар. Әлеге Беренче татар укчы дивизиясенең элекке командирларыннан берсе булган Якуб Чанышев белән бергә ниндидер бер «милли хәрәкәттә катнашуда» гаеплиләр. Закир Самитов шул «яшерен оешманы» оештыруда ук гаепләнгәндер, мөгаен. Шул сәбәпле, 1938 елның гыйнварында ул төрмәдә атып үтерелә. Аның белән бер вакыттарак кулга алынган К. Нәҗми белән Я. Чанышев бераз соңрак азат ителәләр.

Шул элекке комиссарның чая хатыны Зәйнәп апа ирен зинданга илтеп япкач та аның белән элемтә урнаштыру мөмкинлекләрен эзли башлый һәм төрмә тирәсендәге татар бистәләре кешеләрен якыннан белүе сәбәпле, тиздән үз дигәненә ирешә дә. Ире белән ара-тирә хәбәрләшә башлый. Закир атып үтерелгәч, иренең җәсәден төрмәдән кайчан алып чыгачакларын да алдан белә. Шул

төндә эшләүче олаучы белән дә таныша. Ирен башкалардан аерып күмү чарасына керешә. Зират кешеләре төркеменә эләгеп, әлеге олауны каршы алуда катнаша. Төрмә кешеләре киткәч, үз ирен читкәрәк алып чыгып җирли. Шул олаучы аңа «Болар арасында язучы Галимҗан да бар» дип әйткән була. Әдипнең каберен ачыклаучы комиссия эшенә дә Зәйнәп Самитова шул төнге олаучы һәм башкаларның күрсәтмәсе буенча эләгә.

Зәйнәп апа Самитова белән миңа берничә мәртәбә озаклап сөйләшеп утырырга да насыйп булды. Төрмәдә хезмәт итүче милләттәшләребез белән ни рәвешле элемтә урнаштыра алганлыгын да сөйләгән иде ул. Өстәп шуны гына әйтәсе кала: тоткынлыкта вафат булган яисә үтерелгән башка бер генә татар язучысының каберен ачыкларга булышлык иткән комиссияләр төзелми... Ә тарих тузаны калынайганнан-калыная гына бара...

*Лирон Хәмидуллин, язучы,*
*Г. Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе*

## Галимджан Ибрагимов и музыка

Галимджан Ибрагимов известен сегодня современному поколению соотечественников, прежде всего как выдающийся писатель. Между тем его отличало разнообразие интересов, идейных устремлений, которые нашли отражение не только в литературном творчестве и наследии, но и в социально-политической деятельности. Он занимался весьма значительными и важными для общества проблемами, связанными с государственным устройством, просвещением, развитием науки и краеведения. Наряду с этим Г. Ибрагимов уделял внимание явлениям, масштаб которых был не такой большой. К их числу относятся вопросы, касающиеся музыкальной культуры татарского народа. В данной статье попытаемся кратко охарактеризовать тему «музыка в судьбе и творчестве Г. Ибрагимова».

В жизнь писателя музыка начинает активно входить в пору юношества. В годы его учебы в медресе Оренбурга в конце недели устраивали чайные посиделки шакирдов. Здесь звучали песни «Тафтиляу», «Уел», показывали шутливые номера, в которых учащиеся изображали поющих и танцующих женщин сначала под аккомпанемент такмаков и собственных хлопков, а затем их сме-

нила игра на скрипке. По воспоминаниям современников в таких мероприятиях будущий писатель принимал деятельное участие. Его в связи с этим называли даже «атаманом». По всей видимости, большую часть музыкальных впечатлений Г. Ибрагимова и в дальнейшем составляли фольклорные образцы татар и башкир, преимущественно песни, а также игра на мандолине, скрипке и гармони. С годами круг вокальных образцов увеличивается за счет появления произведений обличительной, революционной тематики уже не только татар, но и других народов. Сейчас трудно сказать: пел ли их Г. Ибрагимов, будучи взрослым. Во всяком случае в домашней обстановке члены семьи (жена) не слышали его вокала. Но во время его встреч с молодежью звучали в их коллективном исполнении песни «Садә» (судя по всему, так называемая «Беренче Садә»), «Марсельеза». Присоединялся ли в эти минуты писатель к данным ансамблям, а также и к другим – в моменты отдыха, например, совместно с Ш. Бабичем, Дж. Абдюшевым и В. Хангилдиным, – точно сказать нельзя. Но вполне вероятно, что это могло иметь место. Зато он охотно слушал исполнение других людей. Так по его просьбе пел писатель Ф. Бурнаш. В рассказе о нем М. Будайли всего в нескольких строчках ярко охарактеризован тот удивительный человек (также как и Г. Ибрагимов, подвергнувшийся репрессиям): «Какое бы трудное дело не поручали Ф. Бурнашу, он не считал его для себя сложным, не ленился, даже «эх» не сказав, выполнял, Работать с ним было легко, весело. Не только по возрасту, но и по своей природе он был молодым, энергичным, озорным, широкой души поэтом. Этими качествами он и Галимджан-ага и других преображал в себя, «околдовывал». Он хорошо играл на рояле, красиво пел» [Бөдәйли, 178]. Также по просьбе Г. Ибрагимова протяжные песни «Агыйдел», «Ашказар» и «Мәдинәкәй» исполнял известный впоследствии писатель Ф. Хусни во время ночных лодочных прогулок по реке Деме. Именно ему тогда Г. Ибрагимов поручил организовать развлечения: игры, пение. Ф. Хусни, вдохновленный красотой ночной реки и тишиной, видимо, импровизировал в такие минуты, напевая экспромтом сочиненные поэтические строки:

Тып-тыныч ил, һич исми җил,
Серле, моңлы җәйге төн.
Нәкъ табигать җиргә иңдергән
Бу төннең бар хикмәтен [Кәримова, б. 180].

Г. Ибрагимов поощрял молодежь, в том числе и своих близких, к занятиям музыкой и содействовал этому. Он пригласил к своей жене Гульсум, обладавшей определенными навыками игры на пианино, мандолине и думбре, педагога по фортепиано. Г. Ибрагимов посоветовал ей научиться играть по нотам: «каждое полюбившееся дело надо освоить как можно лучше и основательней» [Мөхәммәдова, б. 346], – сказал он при этом. В медресе «Галия», где Г. Ибрагимов работал учителем, благодаря нему (так считали его ученики, например, С. Кудаш) ввели занятия по музыке. По предложению Г. Ибрагимова на должность педагога был приглашен эвакуированный в Уфу во время Первой мировой войны профессор Варшавской консерватории Вильгельм Клименц. Он организовал хор и струнный оркестр. Впоследствии этот оркестр стал одним из любимых коллективов для уфимской публики. Шакирды в общежитии имели инструменты и играли на них. Например, тот же С. Кудаш вспоминал, как наигрывал на скрипке мелодию «Ай, былбылым» в дуэте со своим другом – мандолинистом. Г. Ибрагимов, заходивший иногда в это общежитие, и, застав учащихся порой в удрученном состоянии, предлагал им поднять настроение с помощью музицирования на гармони или мандолине. Медресе «Галия», видимо, было довольно прогрессивным для своего времени. В нем функционировали несколько кружков. Один из самых больших (по составу учащихся) и продолжительных по времени своему существования был кружок под названием: «Национальная мелодия, сцена и литература» («Милли көй, сәхнә һәм әдәбият»). Фактически он был организован с момента открытия медресе. Его название неоднократно менялось. В него входили разные объединения: кружки музыки, песни, драмы и фольклора. Члены кружка летом занимались сбором фольклорных образцов. А в это же время в других религиозных медресе посещать театры, кино и концерты, играть на инструментах шакирдам не разрешалось. Например, один из них (Л. Гомер), вспоминая свою учебу в медресе Сатыш Мамадышской волости в 1913 году, отметил, что не было никаких занятий по светским предметам. Более того, не разрешалось читать научные книги, официально печатавшиеся газеты и журналы. А уж о том, чтобы познакомиться с рассказами, стихами и песенными сборниками нельзя было и думать.

Не только народная музыка, но и творчество татарских композиторов интересовали Г. Ибрагимова. Он выступил на сцене со вступительной речью (разные свидетели называли ее то докладом, то лекцией) в день премьеры оперы «Сания», созданной коллективом авторов в составе: С. Габаши, Г. Альмухаметов (сочинители музыки) и В. Виноградов (гармонизатор и оркестровщик музыкального материала). Г. Ибрагимов воспринял это произведение как праздник татарской культуры. Его речь произвела большое впечатление на аудиторию. Текст этого выступления до сих пор не опубликован. Хотелось бы его найти, если он, конечно, существовал. Спустя более 30 лет после этого события профессор И. Бороздин, сам некогда написавший рецензию по поводу первого показа оперы «Сания», признавался, что до сих пор помнит выступление Г. Ибрагимова, а также волнение писателя по поводу того, как пройдет дебют спектакля и его искреннюю радость, когда опера получила высокую оценку. И. Бороздин считал, что именно в то время была заложена начальная основа татарской музыки. Следующая опера указанного авторского коллектива фактически появилась благодаря инициативе Г. Ибрагимова. Дело в том, что С. Габаши задумал вместе с Г. Альмухаметовым написать оперу по пьесе «Бүз егет», к которой С. Габаши ранее создал музыкальные номера и в таком виде театральный спектакль уже был успешно показан на сцене. Во время гастролей музыкантов в Ташкенте и Самарканде при встрече с молодежью, интересовавшейся постановкой оперы «Сания», они поделились своими творческими планами, сведения о которых потом появились в газете «Красное знамя» («Кызыл байрак»). Когда об этом узнали в Казани, то поднялся большой шум. Оба композитора по возвращении в столицу татарской республики были приглашены в Наркомпрос (Народный комиссариат просвещения), где их отчитали за то, что они самовольно в других республиках посмели сказать о своих планах по написанию оперы на сюжет «прогнившей» литературы. Г. Ибрагимов, занимавший пост директора Научного центра в Наркомпросе, позднее также призвал к себе на встречу С. Габаши, Г. Альмухаметова и мандолиниста И. Илялова. Отметив, что драма «Бүз егет» возможно и является хорошим художественным произведением, он все же посчитал, что в то время необходимо было создать оперу на сюжет из рабоче-крестьянской жизни. Г. Ибрагимов посоветовал познакомиться в связи с этим с поэмой

М. Гафури «Эшче». Музыканты, прочитав произведение М. Гафури, пришли к решению о сочинении музыки на этот сюжет при условии, что автор поэмы сам возьмется за создание либретто. От Научного центра к М. Гафури в Уфу было послано письмо с соответствующим предложением. Поэт ответил согласием. Опера «Эшче» с успехом была впервые показана в 1930 году на сцене Татарского академического театра в Казани, а затем в Москве – во время проведения олимпиады национальных театров. Однако эта опера не стала шедевром татарского музыкального искусства. Основная причина этого, пожалуй, связана все же с содержанием оперы. Трудно найти даже во всей советской музыке удачные сценические произведения на сюжеты из рабоче-крестьянской жизни. Создание по заказу «нужных» сочинений не привело к хорошему результату. Но, возможно, совет Г. Ибрагимова сочинить оперу по поэме М. Гафури, отодвинул на несколько лет репрессионные меры, которые были предприняты позднее в отношении авторов «Эшче». Они привели к расстрелу одного из них (Г. Альмухаметова) и высылки, а затем и ранней кончины другого (С. Габаши). Опере «Сания» этих композиторов в свое время тоже в этом плане не повезло. Писатель Ф.Амирхан убедил авторов изменить концовку оперы, сделав ее благополучной (счастливой). Он не хотел, чтобы представители богатого сословия взяли верх над бедняками. Получилась развязка, в которой правда жизни была изменена в угоду политическим амбициям. Сейчас можно только посетовать, что не была создана опера «Бүз егет». Знакомство даже с одноголосными мелодиями С. Габаши из этой драмы в исполнении Гульсум Сулеймановой сразу же обратили на себя внимание своей оригинальностью звучания, интонационным своеобразием. Завершая обзор темы «музыка в жизни Г. Ибрагимова», отметим, что, кроме упомянутых ранее композиторов, писатель, вероятно, был знаком и с С. Сайдашевым, т.к. известно, что последний навещал его в Ялте.

Г. Ибрагимов и в своем художественном творчестве, а также в статьях («Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз»), рецензиях («Бөек өмидләр алдында»), этнографических зарисовках («Нугай туе») заводил разговор о музыкальной культуре, прежде всего татарской. Он не пропускал театральные премьеры, в том числе и музыкальные. В своих печатных откликах он рассказывал о сценических произведениях опять-таки того же С. Габаши (которого

он называл первым татарским композитором) и о выступавших в них артистах, в частности, о певице С. Садыковой в роли ханской дочери Сахипджамал из спектакля «Бүз егет» 1922 года. В статье «Перед большими надеждами», автор выразил свое восхищение от ее голоса и артистической игры, отметив, что такое сочетание – проявление новых сил и талантов. Возможно, его оценка дарования юной певицы повлияла на решение руководства республики отправить в 1922 году С. Садыкову на учебу в Московскую консерваторию. В связи с творчеством первого татарского композитора – Ахметсултана Габаши (Г. Ибрагимов в статье указывает полное имя музыканта) – писатель отметил, что его песня «Гөлкәем» получила широкое распространение и стала уже народной, а мелодии его арий, хоров и танцев из трагедии «Тахир и Зухра» люди с любовью слушают повсеместно. Он сделал очень важный вывод, к которому, к сожалению, не прислушались:«Задача революционных организаций заключается в том, чтобы этой, пришедшей в наш мир новорожденной звезде, придать особое значение, ради изящных искусств открыть ей широкую площадь, чтобы она не погасла, чтобы свет и деяния ее распространялись» [Ибраһимов, б. 306]. В музыке драмы «Бүз егет» Г. Ибрагимов услышал близкие и родные нам звучания, источающие аромат духа древнего Востока. Фактически именно за этот восточный колорит произведений С. Габаши его обвинили позднее в музыкальном национализме (оформленном под термином «габашизм») и он был вынужден уехать из нашей республики.

В художественных произведениях Г. Ибрагимова – рассказах, драмах и романах – встречаются различные эпизоды, связанные с музыкой. Особенно много их, пожалуй, в романе «Молодые сердца» в связи с глубокой увлеченностью главных героев этим видом искусства. Персонажи рассуждают о значении музыки в жизни человека, ее свойствах. Писатель обращает внимание на то, как по-разному татарский слушатель воспринимает произведения своего народа и инонациональные. Можно выделить несколько тематических блоков в данном романе: 1) ислам и музыка; 2) фольклорные песенные образцы и инструменты; 3) народные обряды и традиции; 4) профессиональная татарская музыка и ее проблемы. Г. Ибрагимов показывает отрицательное отношение мусульманского духовенства к людям, занимающимся музыкой: играющим на различных инструментах (кубыз и гармонь, мандолина

и гитара), а также поющим. Кроме того, есть краткие описания чтения Корана, хотя, пожалуй, в этом плане больше подобных фрагментов в романе «Наши дни». Современному читателю сегодня, наверно, было бы интересно узнать: а что представляли собой в музыкальном отношении знаменитый египетский напев, а также мотивы Шахмирзы-кари и Бедри-кари, на которые читал суры Баязит – один из персонажей этого произведения? Какие у них интонационные особенности и отличия от других макамов? Кстати, упоминание о чтении суры «Таквир» каирском напевом попадается и в произведении другого писателя – К. Наджми («Весенние ветры»).

Описание народных обрядов и традиций в романе «Молодые сердца» связано с групповыми осенними работами-посиделками девушек в доме (аулак өй), а также с проводами рекрутов. Последним из них отведено много страниц. В связи с этим событием Г. Ибрагимов включает в текст своего литературного сочинения фрагмент из песни «Баламишкин», измененный в соответствии с ситуацией. Эта мелодия, по всей видимости, является своего рода кочующей, поскольку есть записи использования ее во время проведения других мероприятий, например, свадеб (у кряшен). Весь музыкальный материал, встречающийся в романе, можно распределить на две группы: 1) имеющие конкретные названия; 2) безымянные. По их поводу возникает вопрос: являются ли они плодом творческой фантазии писателя или все же отражают реально существующие фольклорные образцы? Безусловно, такие песни, как «Тафтиляу», «Зиляйлюк», «Баламишкин», упомянутые в «Молодых сердцах», давно известны и не вызывают сомнений в своей принадлежности к народным творениям. Но вот, например, песня «Моңлы Гайшә»потребовала поиска аналогий в татарском фольклоре. Большей частью среди баитов есть похожие в определенной мере по названию произведения: «Моңлы хатын Бибигайшә», «Моңлы кыз Галимә бәете», «Суга баткан Гайшә», «Гайшә матур белән гашыйк Камил бәете», а из песен – «Келәү Гайшә». Предполагаем, что название «Моңлы Гайшә» писатель, видимо, сформировал, опираясь особенно на первый из перечисленных выше баитов. Но по событию, которое вызвало ее создание, она перекликается с другим произведением – «Тегермәнче Шәйхелислам бәете», в котором тоже повествуется о гибели молодого мужчины на мельнице. Возможно, стоит поискать аналогичные

произведения среди образцов фольклора Башкирии, учитывая, что Г. Ибрагимов родился, некоторое время учился и работал в этой республике. В связи с созданием песни «Моңлы Гайшә» в романе приведено народное выражение «көй чыгару». Но главный герой – Зия – считает, что в данном случае человек не просто «выпустил» (создал) мелодию, песню, а она сама вышла из глубины его сердца. Заметим, что по отношению к самодеятельным творцам, профессиональные композиторы (например, Дж. Файзи) позднее стали применять термин, имеющий более узкое, прикладное значение: «көйче» – мелодист.

Безымянные фольклорные образцы, а также имеющие названия, представлены в романе в виде поэтического фрагмента или краткого прозаического пересказа сюжета. Среди последних обратили на себя особое внимание два произведения. Первое из них, по мнению одного из филологов [Садекова, с. 50], встречается в татарских анекдотах. Речь идет о солдате, который вернулся с долгой царской службы, и ошибочно принял свою дочь за жену, лежавшую в то время на печи. Удивительно, но этот шутливый короткий рассказ напомнил о трагической песне М. Блантера на стихи К. Симонова «Как служил солдат», специально написанной в годы Великой Отечественной войны в духе старинной русской народной песни. В ней по сюжету жена не дождалась возвращения своего мужа, покинула этот мир, оставив дочь полусиротой. Возможно, в русском фольклоре есть ее аналогии. Другой прозаический фрагмент романа «Молодые сердца» связан с татарской колыбельной песней, в которой младенцу желают стать муллой. Но этой фольклорной песне автор данной работы планирует уделить отдельный анализ.

Литературное наследие Г. Ибрагимова – большое и разнообразное по содержанию и жанрам. Многие его страницы посвящены музыке. Поэтому тема «музыка в жизни и творчестве Г. Ибрагимова» – весьма сложная и трудоемкая. В статье была предпринята попытка постановки некоторых вопросов ее исследования на примере преимущественно романа «Молодые сердца», а также с использованием воспоминаний современников писателя. Но, конечно, необходимо продолжить дальнейшее изучение этой темы.

**Литература**

*Бөдәйли М.* Сирәк очрый торган талант // Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. Б. 176–179.

*Ибраһимов Г.* Бөек өмидләр алдында (Яшь талантлар) // Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр. Сигез томда. 5 т. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 304–306.

*Кәримова З.* Ул безнең якын дустыбыз иде // Галимҗан Ибраһимов. Мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 174–192.

*Мөхәммәдова Г.* Зур тормыш // Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. Б. 336–416.

*Садекова А.* Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова. Казань: 1995. 130 с.

*Г. Юнусова, старший научный сотрудник*
*Центра письменного и музыкального наследия*
*Института языка, литературы и искусства*
*им. Г. Ибрагимова АН РТ*

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ИҖАТЫНА ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ КАРАГАН АРХИВ ДОКУМЕНТЛАРЫ

Җыентыкның бу бүлегендә Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясенең Федераль иминлек хезмәте идарәсе архивында саклана торган документлардан Г. Ибраһимовның кыскача биографиясе һәм Февраль революциясеннән соңгы еллардагы иҗтимагый эшчәнлеген чагылдырган белешмәсе, М. Солтангалиевның Г. Ибраһимовка хаты һ.б. тәкъдим ителә.

Шулай ук биредә 1913 елның апрелендә Киевтә Г. Ибраһимовның кулга алыну вакытында тикшерү органнары алып барган 5 язма урын алды. Беренче документта Г. Ибраһимовны тентү нәтиҗәләре (17–18 апрель, 1913 ел даталы арестант турындагы записка) хәбәр ителә, икенчесендә 1913 елның 17 апрелендәге сходкада тоткарланганнар исемлеге китерелә, өченчесендә – Киевтәге полиция участогы приставының Киев губернасы жандарм идарәсенә кулга алынганнар турындагы язмасы, дүртенчесендә икенче бер приставның язмасында әлеге торкарланган кешеләрнең сигез ачык хаты кулга керүе хакында әйтелә, бишенчесе – Украина ССР Үзәк дәүләт тарих архивыннан 1913 елның апрелендә Г. Ибраһимовны кулга алу буенча тикшерү нәтиҗәләре турындагы белешмә. Әлеге документларның күчермәләре Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана. Язмалар Г. Ибраһимов тормышын тасвирлаучы чыганак булудан бигрәк, шул дәһшәтле чорның рухын гәүдәләндерүче истәлекләр булып саналалар.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БУЕНЧА РФ ФЕДЕРАЛЬ ИМИНЛЕК ХЕЗМӘТЕ ИДАРӘСЕ АРХИВЫННАН АЛЫНГАН ДОКУМЕНТЛАР

Копия
РЕЗОЛЮЦИЯ: «копию мне».
Арасланов. 16/III-27 года.

**Галимзян Ибрагимов**
(председатель АКАДЦЕНТРА)

1) В жизни ИБРАГИМОВА нужно разобраться по следующим данным характеризующим его как человека консервативного убеждения и как человека использовывающего революцию в интересах своей личной жизни и как идиолога в начале панисламиста и после Октября пантатариста.

Биография ИБРАГИМОВА Г.

ИБРАГИМОВ сын муллы фанатика деревни Крмыскалы Стерлитамаковского кантона Башреспублики. Он принадлежит к татарской нации. С детства до зрелого возраста ИБРАГИМОВ учился в гор. Оренбурге в религиозной школе реакцион. муллы Валия ХУСАИНОВА. Вали ХУСАИНОВ с 1906 года стал издавать реакционнейший журнал (черносотенный) «ДИНЬ ВА МАШШАТ» (ВЕРА И ЖИЗНЬ). ИБРАГИМОВ с 1907 г. учился в Уфе в школе «ГАЛИЯ». ИБРАГИМОВ в бытность в Галии принимал участие в ученическом движении исламистов (реформаторов). Одно время занимаясь частными уроками он попадает в Киев домашним учителем детей вокзального буфетчика. Здесь в КИЕВЕ вмешивается в студенческое движение мусульманского кружка. В этом кружке были студенты и Казанские и Уфимские и Кавказские татары. В программе Киевского кружка главенствующую роль играла идея панисламизма но отнюдь не подготовка к революционной деятельности. Царским правительством панисламисты преследовались и поэтому Ибрагимов со своими сотоварищами детьми уфимских дворян и кавказской аристократии попадает якобы как революционер в тюрьму.

Просидев в тюрьме 2 месяца выпускается без всяких последствий. С ИБРАГИМОВЫМ вместе в Киеве сидел уфимский дворянин Халля ЕНИКЕЕВ, который в данное время служит в Наркомздраве – врачем. Этот ЕНИКЕЕВ насколько мне помнит-

ся вмешан в белогвардейское движение. ИБРАГИМОВ до самой революции был видным сотрудником газеты «ЮЛДУЗ» (ЗВЕЗДА) издаваемой пантатаристом Гады МАКСУДОВЫМ.

ИБРАГИМОВ одно время состоял редактором журнала «АНГ» изд. в Казани на средства купца мануфактуриста ХАСАНОВА.

Галимзян ИБРАГИМОВ до революции был своим человеком татарской буржуазной интеллигенции. ИБРАГИМОВ написал один большой роман «Безнең көннәр» (Наши дни), повесть «Яшь йөрәкләр» (Молодые сердца) и несколько мелких рассказов. Во всех произведениях ИБРАГИМОВА красной нитью проводится и с особенной пошлою смаковкой обрисовывается порнография. Даже в книге напечатан в 1922 г. «Кызыл чәчәкләр» (Красные цветки) порнография в большей мере, чем нужна. Во всех произведениях ИБРАГИМОВА ярко чувствуется тяга к людям вышедшим из духовенства и буржуазной интеллигенции. В его дореволюционных произведениях встречаются места преднамеренной насмешки над башкирским народом в отдельных обстоятельствах.

2) ТАТАРО-БАШКИРСКИЙ ВОПРОС ПОДНЯТЫЙ ИБРАГИМОВЫМ.

ГАЛИМЗЯН ИБРАГИМОВ после февральской революции состоял редактором одной газеты издаваемым в Уфе, вел в печати эсеров свое толкование к дальнейшему бытию револоюции. Участвовал в периоде до I-го съезда советов во всех губернских съездах Уфимской губернии как левый эсер и был командирован в Оренбург для организации татарских эсер. Галимзян ИБРАГИМОВ до разгона I-го съезда советов был не только активным левым эсером, но и лидером татарских эсер. ИБРАГИМОВ с самого начала февральской революции имел весьма существенный план гегемонии татарской культуры над всем ближним востоком, над башкирами, киргизами, узбеками и т.д.

В жизни башкирского трудового народа под влиянием его такой тенденции разыгралась стихийная драма. ИБРАГИМОВ выдвинул лозунг татаро-башкирский вопрос, т.е. вопрос лишения самостоятельности башкир и колонизации их татарской культурой, татарской мощностью.

Башкиры, восстав против большевистского движения, если они были обмануты авантюрой Закия ВАЛИДОВА, то с другой стороны были направлены против большевизма выдвинутыми ИБРАГИМОВЫМ вопросом татаро-башкир.

Темная башкирская масса наускиваемая своей буржуазной и кулацкой интеллигенцией не могла разобраться откуда исходил вопрос татаро-башкир и она думала, что это исходит из лагеря большевизма, ибо ГАЛИМЗЯН ИБРАГИМОВ выдавал себя и свою партию самой крайней левой и он эту работу не прекращал даже встав в ряды РКП(б). В самом деле ИБРАГИМОВ обманывал и левых эсеров, он не был левым эсером, а был правым эсером.

Вопрос о татаро-башкир много принес зла в революционном движении национальностей. Под агитацию ИБРАГИМОВА много народилось интеллигенции вставших под татаро-башкирскую ориентацию. И этим ядом были отравлены даже члены РКП(б), вышедшие из трудового крестьянства. Эта идейная травля двух народов – татар против башкир и обратно под руководством Г. ИБРАГИМОВА длилась вплоть до 1924 года и лишь после 1924 г. ИБРАГИМОВ угомонился от этой пагубной своей небольшевистской агитации.

Под влиянием этого вопроса, который агитировал поглощение татарами башкир стал как отрицательное явление деятельности татарской партийной интеллигенции отражался на всех восточных республиках и поэтому не только партийцы РКП(б) примкнувшие к татаро-башкирской ориентации, но и лучшая часть члены РКП(б) из татар стали изгоняться поголовно из всех республик – и киргизской и узбекской и крымской и башкирской, ибо каждая национальность беря в пример детище ИБРАГИМОВА татаро-башкирской ориентацией принимал татар-партийцев за колонизаторов пантатаризма, а в Башкирии этот вопрос и сейчас не изжит и является постоянным злом.

Насколько для революции опасен великорусский шовинизм настолько опасна для революции и идея желания гегемонии татарской культуры над более отсталыми народами чем татары.

Поход Г. ИБРАГИМОВА против нового тюркского алфавита, алфавита латинского на 95% основан на вопросе пантатаризма.

Агам-Али-Оглы – председатель Азербайджанской республики выпустил печатную книгу на русском языке под названием: «в защиту нового тюркского алфавита». В этой книге Г. ИБРАГИМОВУ посвящена целая статья. Этой книги в Казани только один экземпляр, по получении будет доставлена. Эту книгу нужно пришить к личному делу Г. ИБРАГИМОВА, я убежден что ИБРАГИМОВ не опровергнет фактов Агам-Али-Оглы и тогда ИБРА-

ГИМОВУ не только остаться на ответственном посту, но едва-ли удержаться в рядах ВКП(Б).

3) Как была аннулирована вследствие агитации и интриг Г. ИБРАГИМОВА, воля В.И. ЛЕНИНА в 1918 году об отпуске одного миллиона рублей Башкирскому народу для издания революционной работы на башкирском языке в Москве.

При разборе этого вопроса главными свидетелями могут быть – генеральный секретарь ВКП(б) тов. Сталин и член ВКП(б) Хабибулла ГАБИТОВ. ГАБИТОВ в данное время работает в Уфе, состоя зам.пред. распространения в Башкирии латинского алфавита.

Дело было так:

В марте или в апреле 1918 г., когда в Башкирии стали возникать крупные к.-революцион. движения под руководством Закия ВАЛИДОВА с одной стороны и с другой стороны под начинающим возникать великорусским шовинизмом и также сильным влиянием татаро-башкирских ориентилистов из глубины Башкирии, именно – с завода Баймак тайком пробирается в Москву башкирин, ныне член ВКП(б) упомянутый ГАБИТОВ и он получает пропуск к В.И. ЛЕНИНУ чтобы лично рассказать В.И. ЛЕНИНУ о башкирских делах.

В.И. принимает ГАБИТОВА и когда видит вошедшего в его кабинет типичного башкира в оборванной башкирской шубке, он встает с своего места и сам же дает стул Габитову. Видя растерянность ГАБИТОВА В.И. начинает успокаивать Габитова, дает ему папироску и начинает говорить с ним о самых простых слов.

Когда ГАБИТОВ успокаивается В.И. сразу становится серьезным и переходит на деловой тон.

ГАБИТОВ начинает сыпать обиды на русских и татар-баймаковцев. Тогда В.И. прерывает его словами: «революция без жертв не бывает» и просит сказать конкретно – что нужно. ГАБИТОВ просит денег издавать газету в Москве на башкирском языке. В.И. ЛЕНИН пишет тов. СТАЛИНУ, тогда он был наркомнац, отпустить один миллион рублей для издания газеты на башкирском языке.

В это время Г. ИБРАГИМОВ работал в Москве в Мусульманском комиссариате и узнал, что какой-то ГАБИТОВ без ведома Мусульманского комиссариата осмелился идти к ЛЕНИНУ и узнав, что ГАБИТОВУ отпускается один миллион рублей на издание башкирской революционной газеты через М.Н. ВАХИТОВА

председатель Мусульманского комиссариата сообщает тов. СТАЛИНУ, что башкирам особой башкирской газеты не надо, что это лишняя работа, т.к. есть издаваемая в Москве татарская газета «ЧУЛПАН». Тов. СТАЛИН под своим председательством в Мусульманском комиссариате назначает заседание. ГАЛИМЗЯН ИБРАГИМОВ как человек ученый и выдавая себя за знатока башкирского народа начинает доказывать, что у башкир особого языка нет, что башкирам достаточна газета на татарском языке. ИБРАГИМОВ хорошо знал, что башкирам нужна газета на своем языке и сознательно действовал против нее потому, что он в это время был левый эсер и идеолог татарско-башкирской ориентации.

Возможно тов. СТАЛИН этот случай помнит, дело было в 1918 г. весной в комиссариате. На этом совещании был покойный М.Н. ВАХИТОВ и Шариф МАНАТОВ.

По интриге Г. ИБРАГИМОВА воля В.И. была аннулирована, башкирская газета не вышла, а кто знает, если бы ИБРАГИМОВ хоть в этом вопросе отказался бы от своего пресловутого пантатаризма – очень возможно газета из Москвы из очага революции уменьшила бы все те трудности борьбы с башкирской к.-революцией. Вокруг газеты нет сомнения сплочились бы лучшие башкирские революционеры. Ведь это было еще весною 1918 года, а сколько трудностей представлял после этого башкирский вопрос. Это известно ЦК партии.

Были и есть враги открыто идущие и убивающие кр-цев, но ИБРАГИМОВ данным случаем вполне приравнивается к десяткам белых собак потому, что он это совершил не по ошибке, а преднамеренно.

4) Как маскировал ИБРАГИМОВ свое неверие к победе революции и как он бежал за чехами до Петропавловска.

Гаяз ИСХАКОВ известен своей к.-революционной работой. Он в данное время в эмиграции и там тоже в газетах издаваемых на русском языке, пишет свои небылицы по национальному вопросу СССР. До Февральской революции Г. ИСХАКОВ на глазах учащейся молодежи и трудовой интеллигенции казался революционером. ИСХАКОВ был уже укрепившимся до революции татарским литератором.

Г. ИБРАГИМОВ боролся как литератор и как журналист с Г. ИСХАКОВЫМ, бывали серьезные газетные скандалы, что еще более обострилось после февральской революции Г. ИСХАКОВ

совершил преступление в 1917 г. на I-м Московском съезде ИСХАКОВ определенно примкнул к кадетам и стал явным к.-революционером. Г. ИБРАГИМОВ как эсер имел полное право презирать кадета ИСХАКОВА и ему был дан козырь в руки использовать преступление ИСХАКОВА не столько за его преступление, а как своего конкурента литератора. Эсер ИБРАГИМОВ и кадет Г. ИСХАКОВ всегда могли сойтись. Факты говорят за это, но как борцы за первенство в литературе они простить друг другу никогда не могли. Как тот так и другой стихию революции или к.-революцию использовали бы несомненно до физического уничтожения друг друга. ГАЯЗ ИСХАКОВ безусловно и без Г. ИБРАГИМОВА был бы расстрелян – он и достоин этого и ИБРАГИМОВ на почве взаимной ненависти старался бы этот акт ускорить. В 1919–20 гг. в стане белых в Сибири стала расти к.-революция и малодушные люди отдавались панике. В этот момент Г. ИБРАГИМОВ внезапно скрывается из Казани. Его нет ни в Москве, ни в Уфе, ни в своей деревни и никто не знает где он. Как выяснилось ИБРАГИМОВ не будучи даже коммунистом переходит фронт, отрастив бороду, одевшись до неузнаваемости, покупает лошадь, телегу и становится возчиком и нанявшись к отступающим богатым татарам спокойно едет в тыл фронта белых. Насколько помнится он вез екатеринбургских купцов и семейство Агафуровых. Этот случай был и есть факт.

Но становится вопрос – что его тянуло в тыл белых. Подпольная работа – он в это время не был членом РКП(б). Литературная подпольная работа. В тылу у белых татарской подпольной газеты не было. Устная агитация. Состоя возчиком у отступающей буржуазии он этого делать не мог.

Переживания как литератору. Они здесь были гораздо полнее и более целесообразные.

Г. ИБРАГИМОВ как мастер пера здесь в тылу РК власти в момент саботажа татарской интеллигенции был более нужен.

Если он действительно был в подпольной работе в тылу у белых и давал нужные материалы в штаб фронтовой армии или в другое революционное учреждение, то это его достоинство, а по моему дело обстоит иначе. Я думаю он в этот момент струсил, у него не было веры в победу революции. Он думал с белыми возвратится. ГАЯЗ ИСХАКОВ со своим товарищами как Фуад ТУКТАРОВ и Гумер ТЕРЕГУЛОВ и думал конец революции. Конечно при таком обороте Г. ИСХАКОВ постарался бы розыскать ИБРАГИМОВА и

ИБРАГИМОВ разделил бы участь сотни тысячи трудящихся. ИБРАГИМОВ думал таким образом скрыть себя там, где его не могли искать. Зная уловки этого человека я думаю, что дело было так как я думаю. А если по проверке я окажусь правым, то его нельзя отнести к партийцам с 1918 года, как он себя восстановил. Я знаю – он до 1920 года был собатирующим пассивным эсером.

5) ДРУГАЯ ЕГО УЛОВКА.

В 1926 году в Казани состоялась конференция сторонников арабского шрифта.

ИБРАГИМОВ лидер арабистов, но он перед конференцией внезапно захворал и выезжает в Крым, ибо он знает – оставшись в Казани как лидер ему придется бороться с латинистами и еще больше будет отталкивать от себя молодежь, а ему лавировать еще хочется это ему выгодно. Лавирование, а не истинное служение делу культуры его основная профессия.

Года три тому назад дискуссировался вопрос об изменении правописания внутри арабского алфавита. Было два лагеря, лагерь 4 и лагерь 6 и в этом случае ГАЛИМЗЯН ИБРАГИМОВ остался в лагере «4», который более отсталый и более консервативный, но жизнь взяла свое. Ибрагимов проиграл в этом вопросе оставшись в лагере консерваторов.

ИБРАГИМОВ и в данном вопросе смотрел тоже с своей личной выгодой потому, что по правилу правописания «4» у ИБРАГИМОВА имеются учебники, приносящие ему материальную пользу.

Писать учебники и служить просвещению масс дело одно и дело культурное, но защищать отсталую и трудную для усваивания масс лишние отжившие правила в мире культуры есть дело злое нереволюционное. Недаром по постановлению Совнаркома еще в 1918 году был издан декрет на уничтожение «ять», «твердый знак», «і» знаки. Ведь кажется с вопросом «ять» можно подождать. Нет это было сделано во время и она облегчила и сделала письменную работу доступнее малообразованным.

ИБРАГИМОВ же пред. АКАДЦЕНТРА и кажется он в этих вопросах должен идти впереди, а не в хвосте. Г. ИБРАГИМОВ как уже сообщалось АКАДЦЕНТР наполнял беспартийными интеллигентами.

ЕЩЕ ОДИН ФАКТ.

В Татгостеатре были недовольные артисты главрежиссером ТЕНЧУРИНЫМ. Наркомпрос назначил из партийцев комиссию

для обследования дел. ТЕНЧУРИН оставшись недовольным назначением комиссии подал в отставку. В Комиссию вошли главлит Хуснутдин КАРИМОВ, редактор журнала «Безнең юл» и ГАЛИЕВ и председатель Татглавполитпросвета ДОРОФЕЕВ. Комиссия выяснив все детали в театре внесла на утверждение коллегии Наркомпроса принять отставку ТЕНЧУРИНА, освободив гостеатра от его полного феодализма, директором назначить Сулеймана ВАЛЕЕВА, члена ВКП(б). ВАЛЕЕВ несмотря на то, что он из чисто пролетарской семьи академически подготовлен больше чем другой и союз Рабис которого тоже выставил на пост директора, но ИБРАГИМОВ остался верным себе, по рекомендации ИБРАГИМОВА ТЕНЧУРИН оставлен главрежем, а директором назначен ФАТХИ БУРНАШ. Первое дело Фатхия БУРНАША было то, что он дал перевод пьесы «Маркитантка Сигарат» за 170 рублей бывшему белому офицеру Садрию Джалял, тогда как этот перевод совершенно не нужен и если бы дать на перевод, были бы лучшие переводчика из партийной студенческой среды.

Постоянная дружба и попойка Ф. БУРНАШ с братом сказанного выше Гаяза ИСХАКОВА – эмигранта уже одна говорит, что Ф. БУРНАШ как крайний националист имеет связь с эмиграцией. Брат Гаяза ИСХАКОВА Хасан ИСХАКОВ в 1923 году получил из эмиграции пьесу своего брата. Пьеса эта в 1923 г. была включена Тенчуриным в репертуар, но Главлитом снята и брат ИСХАКОВА Хасан ИСХАКОВ в 1923 году состоял суфлером театра.

Нет сомнения и ТЕНЧУРИН и Фатхи БУРНАШ в связи с Гаязом ИСХАКОВЫМ, иначе как же могла проникнуть пьеса Гаяза ИСХАКОВА в Казань из эмиграции и не даром ТЕНЧУРИН перед Посредрабксом и Наркомпросом поднял вопрос о гастролях с татгостеатром в Турции.

Фатхи БУРНАШЕВ заняв пост директора этот вопрос стал усиливать. Направлять Татгостеатр на гастроли в Турцию имеет исполнительное политическое значение, но выпускать ТЕНЧУРИНА и БУРНАШЕВА в Турцию имеет еще большее значение.

Безусловно Тенчурин и Фатхи Бурнашев должны остаться в пределах СССР.

(подпись).

Верно: Пом. Уполномоченного: (подпись).

8/IV-27 г.

(Копия с татарского)

г. Казань АТССР Редакция газеты «Татарстан» писателю Галимджан ИБРАГИМОВУ.
Из Москвы Большая Татарская 7 л. д. № 24, кв. I М. Султан-Галеева.
Заказное письмо.
Москва, 27 февраля.

Уважаемый тов. ГАЛИМДЖАН

Хотя вначале я думал написать письмо по длиннее, но пока принужден удовлетвориться этим маленьким письмецом. Вы, может быть, немножко будете в недоумении, подумав, как этот человек решился написать мне письмо. Но если Вы будете так думать, то я с самого начала должен сказать, что я Вашему мнению ни капли не буду обращать внимания… Это конечно так себе сказанные слова. У нервных людей встречающийся обычай… Вопрос в том. В Москве по моему предложению Госиздатом предполагается на русском языке выпустить сборник татарских литераторов и поэтов. Сборник будет делиться на 2 части: дореволюционная татарская литература и после революционная. В обоих частях, конечно, Ваши произведения должно держать большое место. Причина посылки письма эта. Вопрос в том: 1) для меня самое трудное это просить у Вас разрешение на перевод мною Ваших произведений на русский язык и поместить вышеупомянутый сборник напечатать их – я думаю, что Вы и сами поймете.

Конечно, в этом вопросе к Вам я мог бы совсем не обращаться потому, что если смотреть с официальной стороны я не получая от Вас этого разрешения Ваши произведения найденные мною нужными считаю себя вправе перевести: я ведь госиздатский человек, вернее сказать работаю для Госиздата. Но я в этом вопросе такое действие считая в отношении Вас большим преступлением и не действуя так, как сказано выше, вынужден просить Вашего разрешения, 2) Если с Вашей стороны по этому вопросу не будет сопротивления (я почему-то думаю, что сопротивления не будет), то я у Вас просил бы нижеследующие вещи: Первое: Из Ваших дореволюционных произведений какие по Вашему

собственному мнению должны перевестись. Мне самому по этому вопросу порядочно пришлось голову ломать. Конечно, среди них самое первое место должно было бы держать «Безнең көннәр» (Наши дни), но его поместить в сборник неудобно, потому, что оно целый сборник. Конечно, это произведение должно перевестись, но отдельной книжкой. По-моему, в сборник пришлось бы поместить следующие произведения: «Табигать балалары» (Дети природы), «Мәрхүмнең дәфтәреннән» (Из дневника покойного), «Абдрахман Салихов» и «Диңгездә» (На море), можно и «Ялчи» (…).

Кроме этих по моему хорошо было бы «Татар хатыны ниләр күрми» (Что только не видит татарка). Правда, в художественном отношении у Вас в этом произведении есть некоторые недостатки. Про это, если помните, Вы сами говорили. Но в свое время когда ставится вопрос об освобождении татарки в татарской литературе должно имеет первенствующее место. Смотря даже вообще это произведение несмотря на то, что оно является Вашим первым шагом, произведение очень большого художества. Может быть перед Вашими глазами оно кажется по другому, может быть это результат впечатления оставшийся после прочтения в молодые годы, но мне это так кажется, конечно если это уже не в моем распоряжении: относительно этого произведения я хотел бы услышать Ваше собственное мнение. Второе: относительно Ваших после революционных произведений. У вас эти произведения конечно написаны так, что легко перевести. Об этом не может быть и речи. Вопрос только в том: из этих произведений, по Вашему мнению, которые должны в первую очередь перевестись. Третье: для помещения … Вашу фотографическую карточку (если можно последний снимок 2 шт) и краткую характеристику. Вопрос пока этим исчерпан.

В ожидании ответа (Мирсаид Султангалеев)
Если можно ответ пришлите до 1-го апреля.
Адрес так:
г. Москва, Б-Татарская ул. д. № 24, кв. 1.
Султан-Галееву.

Секретно.
Арестантское.

ЗАПИСКА
о лицах, обысканных и арестованных в ночь
с 17 на 18 апреля 1913 года, в г. Киеве.

| Фамилия, имя, отчество и звание | Причина обыска или ареста | Где содержится | Результаты обыска |
|---|---|---|---|
| РУСТАМБЕКОВ Пафи-Бен Мустаф-Бек, студент Киевского университета. | По связи с лицами, задержанными 17 апреля с.г. на собрании в доме № 15 по Назарьевской улице. | При Либедском участке | Взята переписка по делу магометанского съезда, письма для просмотра и брошюры революционного направлеения. |
| ИБРАГИМОВ Галимчан Гирфандович | То же | При Бульварном участке. | Взято «Знамя Труда» от № 41 до 41 по 49, а также «За народ», «Студенческое дело» и переписка для просмотра. |

№ 3626.
18 апреля 1913 года.
Начальник Киевского Охранного
отделения Подполковник (подпись)

*ЦГИА УССР. ф. 274, д. 2734. л. 118.*

В КАНЦЕЛЯРІЮ КІЕВСКАГО ГУБЕРНСКАГО ЖАНДАРМСКАГО УПРАВЛЕНИЯ.

СПИСОК
лиц, задержанных на сходке 17 апреля 1913 года
в доме № 15, кв. 7, по Назарьевской улице

| №№ по порядку | Фамилия, имя, отчество и звание | Где проживает | В каком участке содержится |
|---|---|---|---|
| 1. | АХУНДОВА Сона Ханум, курсистка высших женских курсов, естеств. факультета | Назарьевская ул. № 15, кв. 7. | |
| 2. | ТАЛЫШИНСКИЙ Мир Абульфат Хан-Мир-Риза-Хан-Оглы | Рейтарская ул. д. № 17, кв. 21. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | ОРДУБАЦКИЙ Фарус-Бек, студент Киевского Университета | М. Благовещенская ул. д. № 73, кв. 1. | |
| 4. | МЕХТИЕВ Мир Ягуб, студент С.-Петербургского Политехнического Института. | Гостиница Гладынюка, комната № 48 (не знает когда приехал) | |
| 5. | КАДЫРОВ Нуралій Нысобаевич. Киргиз 5 аула, Карибальской волости, Тургайской области, из Казани. | Степановская ул. д. № 25 кв. 2. Приехал 17-го апреля 1913 г. | |
| 6. | КУРБАН Наджиб Галиевич, студент С.-Петербургского университета | Гостиница Гладынюка, комната № 48. Приехал 16 апреля 1913 г. | |
| 7. | АХУНДОВ Гусейн Бек Гендан Бек-Оглы, студент Киевского Политехнического Института. | Гоголевская ул. д. № 38, кв. 5. | |
| 8. | ЕНИКЕЕВ Халилулла Ибетулинович, студент Киевского Университета | Степановская ул. д. № 25 кв.2. | |
| 9. | НАСЫРБЕКОВ Алульфен-Хан Карим Хамович, студент Новороссийского Университета | М.Благовещенская ул. д. № 73, кв. 1. Прибыл 15-го апреля. | |
| 10. | ВЕЗИРОВ Джемиль Бек Измаилович, студент Киевского Политехнического Института. | М. Благовещенская ул. д. № 73, кв. 1. | |
| 11. | КОРИМОВ Мухамед-Гориф Гильманович, крестьянин Самарской губернии, Бузулукского уезда, Ниже-Чершалевской волости, бывший студент Московского Коммерческого Института | Рейтарская ул. д. № 17, кв. 2. Приехал 16-го апреля 1913 года. | |
| 12. | ШИРИН Бек Сафар-Алибек, студент Харьковского Университета | Гоголевская ул. д.№38, кв.5. | |
| 13. | АХТЯМОВА Гульсум Абдульсугумовна, курсистска Высших женских курсов | Тарасовская ул., д. № 40, кв. 17. | |
| 14. | АЛИБЕКОВ Алибек Алибекович, студент Киевского Университета | Столыпинская ул. д. № 32, кв. 4. | |

Начальник Киевского Охранного Отделения
Подполковник (подпись)

*ЦГИА УССР, ф. 274, дело № 2734, л. 119.*

СЕКРЕТНО
М. В. Д.
Пристав Бульварного Полицейского
г. Киева участка № 1377
18 апреля 1913 г.

Начальнику Киевского Губернского Жандармского Управления

17 сего апреля в 7 час. вечера в доме № 15 по Назарьевской улице в квартире курсистки Киевских Высших женских курсов Соны Ханум АХУНДОВОЙ задержана сходка из 14 человек, вместе с нею, а именно: Абулфет Насирбеков, Мир ягуб Мехтиев, Джамиль бек Везиров, Гусейн бек Ахундов, Али бек Алибеков, Мир Абульфат Тялышинский, Нургалий Кадыров, Мухамед Гариф Каримов, Ширинбек Алибеков, Наджиб Курбан-Галиев, Хали Еникеев, Умма Ахтямова, Фируз-бек Ордубацкий и Сона Ахундова, все они магометанского вероисповедания. В квартире Ахундовой и при личном обыске задержанных лиц ничего явно преступного не найдено, взята у некоторых из них, личная переписка для просмотра Киевским Охранным Отделением, которому пре¬провождено дознание об этой сходке и такое же дознание Киевскому Полицеймейстеру для наложения на задержанных взыскания в административном порядке. Задержанные лица объяснили, что целью собрания их в квартире Ахундовой имелось в виду рассмотреть устав Киевского землячества студентов-магометан и ознакомления с ним прибывших в Киев делегатов из других городов.

Задержанные исключительно студента и курсистки, которые содержатся под стражей при вверенном мне участке впредь до распоряжения Охранного Отделения и Киевского Полицеймейстера.

Об изложенном уведомляю Ваше Васокоблагородие.

Пристав (подпись)

*ЦГИА УССР , ф . 274, дело № 2734. л. 120.*

Арестантское
Секретно.
М. В. Д.
ПРИСТАВ Старокиевского
полицейского г. Киева
участка № 3259
14 апреля 1913 г.

Начальнику Киевского Губернского Жандармского Управления.

При сем препроводим Вашему Высокоблагородию на распоряжения 8 открытых писем, адресованные разным лицам содержащимся при вверенном мне участке, задержанные на сходке 17 апреля в квартире С. Ахундовой.

Пристав (подпись)
Надзиратель (подпись)

*ЦГИА УССР, ф. 274, д.2734. л. 123.*

СПРАВКА
о результатах проверки архивных документов
Киевского губерн. жандармского управления об обстоятельствах
ареста татарского писателя Г. Ибрагимова в апреле 1913 г.

В начале 1913 года в Киеве студентами-мусульманами проводится работа по созданию руководящего центра в целях объединения студентов-мусульман, как наиболее сознательных и прогрессивных элементов мусульманского населения. Эта организация должна была заниматься главным образом вопросами просвещения и культуры мусульманского населения, в частности женщин. Некоторые члены так называемой руководящей группы выступали и говорили о необходимости борьбы против национального гнета.

Во главе руководящей группы стояли: 1) Еникеев Х.И. – студент Киевского университета, уроженец Уфимской губернии, Белебейского уезда, дер. Каргалы; 2) Ахтямова Г.А. – курсистка высших женских курсов, из Уфимской губернии; 3) Ибрагимов Г.Г. – репетитор и литератор из Уфимской губернии (см. ЦГИА УССР ф. 275, д. 858, лл. 17, 22, 57 за 1913 г.).

Из проверенных архивных материалов жандармского управления видно, что Г. Ибрагимов принимал активное участие в

заседаниях руководящей группы, на которых обсуждались вопросы о созыве съезда студентов-мусульман, «Изучения политического морального духа татарской молодежи и интеллигенции» (см. там же, лл. 100–103).

17 апреля 1913 г. в Киеве, на квартире курсистки Киевских Высших женских курсов Сона Ханум Ахундовой был созван съезд представителей студентов-мусульман. На съезде были представители студентов-мусульман Киевских высших учебных заведений, Петербургского, Харьковского, Новороссийского университетов, из Московского коммерческого института. Из Казани на съезде был Кадыров Нургалей Насыбаевич, киргиз, из 5 аула, Карибальской волости, Туграйской области.

Съезд не успел обсудить ни одного вопроса, 17 апреля в 7 ч. вечера все участники съезда (14 чел.) были арестованы (см. там же, ф. 274, д. 2734, лл. 117–119, за 1913 г.).

В ночь с 17 на 18 апреля, в 12 ч. 30 м. были арестованы за связи с делегатами съезда Ибрагимов Г.Г. и Рустамбеков Пафи-Бен Мустафа-Бек (см. там же, ф. 274, д. 2734, л. 118). У Ибрагимова было взято «13 номеров «Знамя труда» (с 1–48 номера за 1912–1913 гг.), «За народ» № 51, за 1912 г., «Студенческое дело», брошюра «Дом самозванных», конверты с адресом Еникеева, в котором было вложено письмо, относящееся к съезду (студентов-мусульман. – *К.Т.*), переписки, фотографии, записная книжка, альбом и литература на татарском языке в большом количестве. Пять свертков (см. там же, ф. 275, дело 858, лл. 91–92, за 1913 г.).

У Рустамбекова при аресте было взято так же «брошюры революционного направления» (там же, ф. 274, д. 2734, л. 119, за 1913 г.)

Вещи, отобранные у арестованных в делах жандармского управления не обнаружил.

При допросе «задержанные лица объяснили, что целью собрания их в квартире Ахундовой имелось в виду рассмотреть устав Киевского землячества студентов-магометан и ознакомление с ним прибывших в Киев делегатов из других городов» (там же, ф. 284, д. 2734, л. 120).

В документах Киевского жандармского управления имеется сообщение Казанского губернского жандармского управления где сказано, что «киргиз Н. Кадыров никакого участия во всем этом деле не принимал» (см. там же, ф. 275, д. 858, л. 159 за 1913 г.)

Но Кадыров присутствовал на собрании у Ахундовой и 17 апреля 1913 г. вместе со всеми участниками собрания был арестован. Возникает вопрос – почему жандармское управление считает Кадырова совсем не виновным «во всем этом деле?»

Документы, говорящие о связи Кадырова с охранкой, мною не были обнаружены.

Постановлением Киевского губернатора от 21 апреля 1913 г. Ахундова была подвергнута аресту в административном порядке на два месяца, а остальные 13 чел. на один месяц каждый (там же, ф. 275, д. 858, л. 77).

В архиве Киевского жандармского управления и охранного отделения других документов по делу Г. Ибрагимова я не обнаружил, и в документах нет указания какому наказанию он был подвергнут.

В архиве Киевского жандармского управления имеется много донесений жандармских управлений: Петербургского, Московского, Казанского, Саратовского и др. губерний о движении среди татарской интеллигенции и студентов.

Прилагаю(на 6 листах) копии некоторых документов из ЦГИА УССР, относящиеся к делу Г. Ибрагимова.

К. ТОЛСТЯКОВ

## ЭЧТӘЛЕК

**Кереш** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
**Г. Ибраһимовның иҗат мирасыннан** . . . . . . . . . . . . . . . 9
***Әдәби әсәрләр*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Татар хатыны ниләр күрми (Роман. Беренче басма) . . . . . . . 10
***Әдип публицистикасы*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
Шәкертләр һәм уку . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Уфа, мәдрәсәи «Галия»дә тентү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
Пролетариатның яңа гыйлем йортлары арта . . . . . . . . . . . 99
Бондюг пролетариаты арасында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100
Татарстан җөмһүриятенең дүрт елы эчендә партия оешмасы . . 106
Әдәби тарихыбызның кадерле битләре болай
таптатылмасын иде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
***Рәсми чыгышлар*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Галимҗан Ибраһимовның Беренче Бөтенсоюз Тюркология
съездында ясаган төрки телләрнең орфографиясе турындагы
докладлары һәм чыгышлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
I. Галимджан Ибрагимов об орфографии тюркских языков . 128
II. Заключительное слово докладчиков . . . . . . . . . . . . . 131
III. Выступление Г. Ибрагимова на прениях . . . . . . . . . . 133
Галимҗан Ибраһимовның Беренче Бөтенрусия
мөселманнары корылтаендагы чыгышлары . . . . . . . . . . . . 138

**Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр** . . . . . . . . . . 145
*Ф. Корбангалиев.* Галимҗан Ибраһимов турында... . . . . . . 146
*К. Хәсән.* Галимҗан Ибраһимов янында . . . . . . . . . . . . . 166
*Г. Мухамедова.* О Г. Ибрагимове . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
*Б. Умеров.* Кырым язучысының әдәби ватаны . . . . . . . . . . 174
*Л. Мухамедова.* Память . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
*Г. Алмаев.* Галимҗан Ибраһимовка турында хатирәләр . . . . 190

**Әдип турында вакытлы матбугат (1910–1930)** . . . . . . . . 199
*Тупый.* Яңа әсәрләр. Татар хатыны ниләр күрми . . . . . . . . 199
*Г. Газиз.* Яшь әдәбиятыбызда «Яшь йөрәкләр» . . . . . . . . . 201

*Әхмәтзәки.* Шәрекъкә гаид яңа әсәрләр . . . . . . . . . . . . 209
*С. Атнагулов.* Безнең көннәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 219
*Г. Рәхим.* «Казакъ кызы» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 222
*Г. Ходаяров.* «Яңа кешеләр» турында бер-ике сүз . . . . . . 225
*З. Нуркин.* Кем җинаяте? *(Галимҗан Ибраһимовның «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә»се мөнәсәбәте белән)* . . . . . . . 229
*Г. Сәгъди.* Галимҗан Ибраһимов иҗатында типлар эволюциясе . 233
*Г. Толымбайский.* Искермәгән бер уңлык турында . . . . . . . . . 246
*Г. Касыймов.* Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак? . . . . . 250
*Ш. Камал.* Гарәп хәрефеме, латин хәрефеме . . . . . . . . . 255
*И. Рәхмәтуллин.* XX еллык бөек әдәби-гыйльми хезмәт бәйрәме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 258
*Ә. Байтурсынов.* Галимҗан Ибраһимов төрк-татар уйчысы, төрк-татар белгече, төрк-татар язучысы . . . . . . . . . 260
*Ш. Булат.* Бөек әдипкә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 264
*Х. Вәли.* Галимҗан Ибраһимовның әдәби үсүе . . . . . . . . . 264
*Н. Надиев*. Галимҗан Ибраһимовның педагогия юлындагы хезмәтләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 268
*Ә. Гаффаров.* Казандагы рус матбугатында Г. Ибраһимовның кайбер әдәби әсәрләре турында фикер, тәнкыйтьләр . . . . . . . 272
*Миңлекәй.* Сәлам хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 276
*Г. Кутуй.* Әй, каләм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 278
*Уйгур.* «Татар шагыйрьләре» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 279
Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗыйгун . . . . . . . . . . . . . 285

**Г. Ибраһимов иҗаты турында фәнни-тәнкыйди мәкаләләр** . . . 287
*М. Әхмәтҗанов.* Галимҗан Ибраһимовның бер автографлы китабы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 287
*Р. Харрасова.* Егерменче елларда Г. Ибраһимовның әдәби тәнкыйть концепциясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 289
*Л. Хәмидуллин.* Ак тапларны киметәсе иде... . . . . . . . . . . 300
*Г. Юнусова.* Галимджан Ибрагимов и музыка . . . . . . . . . . 308

**Г. Ибраһимовның иҗатына һәм иҗтимагый эшчәнлегенә караган архив документлары** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 317

**ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ**
**поиски и открытия**

Выпуск 3

Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.А. Булатова*

Подписано в печать: 12.04.2017 г.
Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная, печать офсетная
Усл.-печ. л. 18,9. Уч-изд. л.16,7. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12